

# Казан утлары

6.1986



*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карары*

## 1986 ЕЛ ӨЧЕН ТАТАРСТАН АССРның ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА


Язучы Х. Н. Камалов.


Рәссам В. И. Куделькин.

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1986 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирергә:

1. Камалов Хисам Нуретдиновичка — язучы, «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» дигән китаплары өчен.
2. Куделькин Виктор Ивановичка — рәссам, Татарстан хезмәт алдынгыларына, авыл эшчәннәренә һәм культура эшлеклеләренә багышланган картиналары өчен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре
Г. УСМАНОВ.

Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе
М. ШӘЙМИЕВ.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**1986**

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

М. ХӘСӘНОВ. **Язгы ажаган.** *Роман* . . . . 3
Р. МИҢНУЛЛИН. **Марафон.** *Шигырьләр* . . 69
БАТУЛЛА. **Алып батыр мажаралары.** *Повесть-экият* . . . . . . . 73
Р. МИНГАЛИМ. **Җыр канаты.** *Шигырьләр* . 106
М. ГАЛИЕВ. **Сатурн һәм умач.** *Хикәя* . . . 110
Х. ӘЮПОВ. **Яшен вакытында язылган шигырь.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . 121

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

М. МӘҺДИЕВ. **Шагыйрьнең бишеге** . . . . 126

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Н. Б. БАҺРАМОВ. **Әгерҗегә килегез!** *(Әгерҗе районы)* . . . . . . . . . . . . . 146

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

М. БИБИШЕВ. **Кешеләр хакына** . . . . . 148

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

Ф. БӘЙРӘМОВА. **Көрәш** . . . . . . . . 151

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МОСТАФИН. **Язучы һәм телевидение** . . . 155
**Киләчәк бүген башлана.** *(Г. Төхвәтов белән М. Вәлиев әңгәмәсе)* . . . . . . . . 162
**Тәрҗемә турында сөйләшәбез** *(Л. Хәмидуллин, Ә. Баянов)* . . . . . . . . . . . . 170

КОНКУРСКА

Р. КУКУШКИН. **Шигъри күперләр остасы** . 173

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

А. РАСИХ. **Фатих Әмирхан хаты** . . . . . 178

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

С. МИХАЙЛОВА. **Халык мәгарифен әйдәүче** . 179

АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

Р. ИШМОРАТОВА. **Кичке җидедән соң.** *Пьеса* . . . . . . . . . . . . . . 182

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . 188

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

**ӘХӘТ ГАФФАР**

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

**ФЛҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**

**НУРИХАН ФӘТТАХ**

**СИБГАТ ХӘКИМ**

**РИЗВАН ХӘМИД**

**НИЛ ЮЗИЕВ**

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

## *В нашем номере*

Роман М. ХАСАНОВА «Весенняя зарница» (продолжение). Повесть-сказка БАТУЛЛЫ «Приключения Алып батыра». Рассказ М. ГАЛИЕВА. Эссе М. МАГДЕЕВА «Колыбель поэта» (к 100-летию Г. ТУКАЯ). Стихи Р. МИННУЛЛИНА, Р. МИНГАЛИМА и Х. АЮПОВА.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Агрызского райкома КПСС Н. Б. БАГРАМОВА.
Литературный пост журнала — ТатАЭС. Выступление начальника ДСК «Камгэсэнергострой» М. БИБИШЕВА.
Очерк Ф. БАЙРАМОВОЙ «Конфликт».
В рубрике «Литературная критика»: статья Р. МУСТАФИНА «Писатель и телевидение», беседа критика М. ВАЛИЕВА с комбайнером Г. ТУХВАТОВЫМ.
В журнале продолжается дискуссия о проблемах перевода (Л. Хамидуллин, А. Баянов).
Рецензия Р. КУКУШКИНА на новую книгу А. Исхака.
К истории литературы: А. РАСИХ «Письмо Ф. Амирхана».
К истории культуры: статья С. МИХАЙЛОВОЙ «Роль Казанского университета в просвещении народов Сибири».
В рубрике «За трезвый образ жизни» пьеса Р. ИШМУРАТОВОЙ «После семи вечера».
Дневник культурной жизни.
На наших обложках — творчество художника Ш. Шайдуллина.

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, Ч. Фәтхуллина.*

Производствога бирелде 4.04.1986 ел. Басарга кул куелды 29.05.1986 ел. ПФ 05217. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62749. Заказ В-146. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

**Мәхмүт Хәсәнов**

# ЯЗГЫ АҖАГАН

РОМАН



Хатын бермәлгә тынып калды һәм, Иргалигә мөрәҗәгать итеп, исем-фамилиясе белән кызыксынды. Үзе үк: «Миргалиев түгелме?» — дип сорап та куйды.

Иргали, нәрсә эшләгәнен дә белештермәгән кеше сыман: «Так точно... Миргалиев!» — дип, рапорт биргәндәге кебек кычкырып җибәрүеннән шул кадәр оялды, җир тишегенә кереп китәрдәй булды.

Телефон трубкасын элеп, рычагын борып, «отбой» биргәндә, Ксения Семеновнаның йөзе ачылган, тавышы таный алмаслык булып мөлаемланган иде инде.

— Хәзер кайтып җитәрмен, диде. Исемегезне ишеткәч: О-о, господи! дип кычкырып җибәрде. Ышанмыйча тора, не может быть! ди.— Ксения Семеновна, көлеп-елмаеп, болдыр баскычы янына килде.— Ә хәзер, әйдәгез, чишенегез. Марфа, кунакка ярдәм ит. Киемнәрегезне әнә теге шкафка элегез.

Иргали күн итекләрен дә салды, ап-ак йон оекбаштан гына калды. Иелеп карасаң, йөзең чагылырлык дәрәҗәгә җиткерелеп ялтыратылган паркетларга басып, баскычтан өскә күтәрелде. Залның буеннан-буена җәелгән кыйммәтле келәмнәр өстенә барып керделәр.

Аңардан бер адымга да калмаган ике хатын, кулларыгызны юып чыгыгыз дип, бер бүлмәгә күрсәттеләр. Монда янә хәйран тамаша. Бәдрәфнең стеналары тоташтан бизәкле чынаяк плитәләр белән капланган. Үзе якты, үзе чиста, үзе җылы.

Кулларын юып, күтәренке бер рух белән кухняга кергәндә, анда инде табын әзерләнгән, Иргали алдына берничә төрле ризык тезеп куелган иде.

Ксения Семеновна да өстәлнең каршы ягына килеп утырды. Салкын ит салынган савытны, өстенә алка-алка суган туралган кызыл балыкны кунак алдынарак этәреп куйды. Графин белән җитереп куелган эчемлекне дә бәллүр рюмкага хуҗабикә үзе салды.

Шунда Иргали Ксения Семеновнаның кыйммәтле ташлар белән бизәлгән йөзекле шундый да нәфис, шундый да җыйнак кулларына, хуҗабикәнең үзенә сиздермичә генә, йөзенә, муеннарына күз төшереп алды. Бу кадәр дә аклык, бу кадәр дә пакьлык булмас, моның юынганы да сөт белән дер, дип уйлап куярга мәҗбүр булды.

Иргали: «Кагылган нәрсәм түгел»,— дип, рюмкасын читкәрәк алып куйды. Моны күргән хуҗабикә, җәйге челләдә яуган кар сыман, уйлама-

Дәвамы. Башы 5 санда.

ганда-көтмәгәндә килеп төшкән кунагына тагын да ышанычлырак күз белән карый башлады.

Әллә ни күп вакыт та үтмәде шикелле, тышкы ишекнең ачылып-ябылган тавышы ишетелде. Ничәмә-ничә еллар үтүгә дә карамастан, Илья Олеговичның: «Яле, яле! Чыннан да улмы?» — дигән тавышын шунда ук таныды Иргали. Тамагын туйдырып, чәйләп алган мосафир да, менә ул, мин фәкыйрегез! дигән сыман, элеккеге командирын аягүрә торып каршы алды.

Илья Олегович керә-керешли үк Иргалине күрде дә, якын, үз итеп, күзләрен мөлдерәтеп бермәлгә карап торды, аннары: «Дорогой мой, родной!» — дип, кунагын кочагына алды. Рус гадәтенчә өч тапкыр үпте. Куанычына бер дә чик-чама юк иде аның. Тавышыннан үк күңеле тулуын, сулышы кысылуын төшенүе әллә ни кыен түгел иде.

— Ксана! Менә ул, күр, минем коткаручым! — Үзе һаман да Иргалине, шапы-шопы китереп, аркасыннан, иңнәреннән сөя. Бу мизгелдә авызы елмайса да, капчыкланып торган күз төпләре дымланган иде аның.

Еллар үзенекен иткән, дип уйланды Иргали. Чыннан да, Илья Олегович шактый ук бирешкән. Тар җилкә, батынкы күкрәк. Тутырган тавык кебек йомры, шул ук вакытта ифрат нәзакәтле хатыны янында яшүсмер сыман гына. Чәчләр дә кирәгеннән иртә чаларган.

Илья Олегович, бик әһәмиятле нәрсә исенә төшкән кеше сыман, хатын-кызлар ягына борылып: «Кадерле кунак хөрмәтенә бүген үк, хәзер үк пир на весь мир оештырыгыз! Кунагыбыз лаек аңа... Әтигә дә шалтыратмадыңмы? Ярар, үзем шалтыратырмын, иртәрәк кайтсын», — дип әмерләр бирде дә, җилкәсеннән кочаклап, Иргалине үз кабинетына алып кереп китте.

Илья Олегович кунагын күн белән тышланган тирән креслога утыртты да бик тә үз итеп Иргалинең сугышчан юлы, кайчан кайтканлыгы, тормыш-көнкүреше турында сораша башлады. Рухы күтәрелгән Иргали, җәһәт кенә чишелеп китеп, ачлыкта-мохтаҗлыкта интегүен, иза чигүен чыгарып селекмәде. Гомумән, табигате белән горур Иргалигә мескенләнү, түбәнсенү ят нәрсә иде. Әмма әнисенең ярты авыл халкы кебек үк ачлыктан үлгәнлеген, хәзер дә кеше өстендә торуын яшермичә ачыктан-ачык сөйләп бирде.

Илья Олегович та Иргалинең тормышы, хәл-әхвәле турында бары тик сүз югында сүз булсын өчен генә кызыксынмый. Моны шәйләү әллә ни зирәклек сорамый иде. Менә ул үрелеп кенә солдатның иңенә сыңар кулы белән кагылып, гап-гади һәм эчкерсез итеп әйтә салды.

— Дорогой мой человек! Шуны бел: мин сиңа кулымнан килгән кадәр ярдәм итәчәкмен. Син моны вәгъдә дип тә, изге әманәт дип тә кабул итә аласың.

Җылы, ифрат ягымлы, чын теләктәшлек белән әйтелгән бу сүзләр Иргалигә җан азыгы булды да куйды. Аңа кинәт рәхәт булып китте, ятсыну минутлары узды, тынычлана төште, тавышына кадәр тигезләнде. Барлык икеләнүләр томан кебек эреп юкка чыкты. Шул инде, яхшылык кыл да диңгезгә сал, адәм белмәсә, балык белер дип әйтмәсләр иде аны.

Шулчак Илья Олегович, җәһәт кенә урыныннан күтәрелде, елмайды һәм, куанычлы хәбәр тапшырган кыяфәткә кереп:

— Әти дә кайтты, — диде.

Алар икесе дә өлкән Клочкинны каршы алу өчен залга чыктылар.

Килеш-килбәте шәп иде мәшһүр докторның. Чак кына юаная башлаган таза, төз гәүдә. Чәчләре, сакал-мыегы гына түгел, көя төшкәнгә охшап, тузгып торган калын кашларына кадәр чал йөгергән иде аның. Пенсне артында мөлдерәп торган соры күзләр үткен карыйлар, киң маңгаенда еллар сызган сырлар. Йөзе якты, чиста. «Әй-йе, — дип

уйлап куйды Иргали.— Чыннан да, үзенә карата һәркемдә ихтирам хисе уята торган могтәбәр, ягымлы, нәзакәтле кеше икән...»

Ул арада залга күтәрелгән доктор, ерактан ук елмаеп, Иргалигә таба якыная башлады.

— Исәнме, саумы, служивый! — дип күрешү өчен, нәкъ мөселманнарча, берьюлы ике кулын сузды.— Миңа Илюша Сезнең ничек итеп бергә хезмәт итүегез, ничек итеп аны газ эченнән, ут астыннан алып чыгуыгыз турында бер түгел, мең тапкырлар сөйләгәне бар.

Өчәүләшеп яңадан Илья Олегович кабинетына керделәр. Әмма аларга монда озак юанырга туры килмәде, аш әзер дип, табын янына чакырдылар.

Сүз иярә сүз китеп, Иргалинең ниндирәк шартларда үз офицерын үлемнән коткаруын, Аркадий Алексеевичның, җан дусты газаплануына чик куярга теләп, атар өчен пистолетын чыгаруын һәм Илья Олеговичның йөрәгенә тирәвен куәлларлык итеп кабат искә төшерделәр.

Өлкән Клочкин Тарановның кем булуын, аңа карата үзенең мөнәсәбәтен, ике авыз сүз белән әйтте дә бирде.

— Аркадиймы? Аңа ышансаң, күзең дә йоммаячак, хәтта туган атасын да атачак...

Сүз кинәт кискен борылыш ясады. Сәбәпчесе — яшь Клочкин. Чак кына башына китте ахрысы. Ул, Иргалинең язмышын шушында, табын янында ук бер селтәнүдә хәл итәргә җыенгандай, барысының да игътибарын җәлеп итеп, болай диде:

— Әтием!.. Ксана, син дә тыңла. Сезнең каршыгызда мине үлемнән йолып калган кадерле кешем утыра. Әйтергә теләгәнем шул: әгәр дә бу кеше исән калып, очрашырга язса, алдында тезләнер идем, ярлы булса, кулымнан килгән кадәр ярдәм күрсәтер идем, авыру булса, дәвалатыр идем дигән әманәтем-антым бар. Күреп торасыз, ул минем тезләнүемә мохтаҗ түгел. Ә ярдәм кирәк булачак.

Барысы да тынып калдылар. Илья Олегович шул кадәр үк турыдан ярыр дип уйламаган Иргали, уңайсызлануын яшерә алмыйча, башын иярга мәҗбүр булды. Баягынак кына, әнисенең ачтан үлгәнлеге, хәзер дә кеше өстендә торганлыгы турында әйтеп зарланганына чынлап торып үкенеп куйды. Ул арада кече Клочкин тәкъдим сыман нәрсә дә кертте.

— Минемчә, ярдәм кулы сузуны нинди дә булса табышлырак берәр эшкә урнаштырудан башларга кирәктер.

Яклап та, каршы да сүз әйтүче күренмәүне тәкъдименең кабул ителүе дип уйлады булса кирәк, Илья Олегович шундук кызыл мал белән сату итүче зур мөлкәтле бер атаклы купецның исемен телгә алды. Шул сәүдәгәрнең шушы көннәрдә генә Рига кадәр җирдән өчме-дүртме вагон товар алып кайтуы турында әйтте. НЭПның чәчәк аткан чагы, нигә дип шул форсаттан файдаланып калмаска, янәсе. Бәлки шул нэпман белән сөйләшеп карарга кирәктер. Җитмәсә тагын Олег Авдеевичның якын танышы да икән. Иргали аның өчен шактый кулай кеше булыр иде, телне белә, бераз грамотасы да бар...

Өлкән Клочкинның йөзендәге бер генә мускулы да селкенмәде. Менә ул салмак хәрәкәтләнеп, якасына кыстырып куелган салфеткасын алып, иреннәрен сөртештерде дә яртылаш бушаган тәлинкәсе янына куйды. Бары тик шуннан соң гына сүзгә кушылды.

— Белмим,— диде ул, шушы беренче сүз белән үк Илья Олегович тәкъдименә кушылмавын аңлатырга теләгән сыман итеп.— Мин үзем җиргә береккән, тумыштан күкрәгендә крестьян йөрәге типкән кешене туган туфрагыннан аеру ягында түгел.

Кече Клочкин, этисенең киңәшен ишетергә, аның әйткән сүзләренә колак салу гына түгел, берсүзсез кушылырга интегеп утырган диярсең, янәшәсендәге Иргалинең йөзенә туп-туры карап, искәрмәстән генә:

— Син үзең бу турыда ничегрәк уйлыйсың? — дип сорап куйды.

Кеше икмәгеннән дә ачы, аннан да яман нәрсә юктыр бу фани дөньяда.

Үз уйларына бирелеп утырган Иргали кырт кистереп бирелгән әлеге сорау-дан бермәлгә югалып калды. Әмма бик тиз кулга алды ул үзен.

— Бу очракта Олег Авдеевич хаклы,— диде ул.— Бездә, татарлар-да: иген иккән — нужаланмый көн иткән, дигән мәкаль дә бар...

— Әлбәттә шулай! — дип хуплап элеп алды өлкән хуҗа.— Үз акылы уенда булган кешегә хәзер авыл җирендә дә тормышны җайга салып була. Ә инде ярдәм итүгә килсәк, бездән калмас. Һәрхәлдә ач-ялангач булмас. Баш өстендә түбә булдыру чарасын да күрербез...

Аштан соң ир-атлар янадан Илья Олегович кабинетына җыелды. Сүз иярә сүз китеп, Чаллыда яшәүче ниндидер Кузька-Бурлак исемле бер баш-кисәрнең исемен телгә алдылар. Аның турында сүз кузгату Клочкиннар-ның икесенә дә кызык иде ахрысы — бик аңлаешлы итеп елмаештылар. Иргали аша шул Кузька-Бурлакка хат җибәрергә, ярдәмне таш астыннан чыккан шул «зимагур» аша күрсәтергә булдылар. Юкны да таба торган кеше диделәр аның турында.

Шактый юандылар. Ике-өч урында шәмнәргә охшатып эшләнгән электр лампочкалары янудан ялт итеп торган кабинетта утырулары бик тә, бик тә рәхәт иде. Илья Олегович йомшак креслода таралып утырып челем суырган арада, өлкән Клочкин Иргалинең изүен ачып, ярасын кара-ды. Канәгать калды. Чын хирург кулына эләккәнсез, моның белән яшәп була, дип нәтиҗә ясады.

Күпмедер вакыт узгач, кичке чәйгә дип, аларны кабат аш бүлмәсенә чакырдылар. Чәй янында яңарып киткән әңгәмә янә Иргалигә ярдәм итү-гә кайтып калды. Бу юлы күбрәк өлкән Клочкин сөйләнде.

— Дөнья күргән, тормыш итүнең ибен-җаен белгән кешене туган җи-реннән аерырга ярамый. Кеше үз эшен тапсын, шунда гына җаны тыныч-лана аның. Татар халкы тырыш, иген игәргә дә, мал-туар асрарга да хи-рыс. Әйтергә теләгәнем шул: җире булыр, мал-туарын алышырбыз. Көч — җирдән, байлык — көтүдән ди бит.— Шунда өлкән Клочкин аңлаган ке-шегә бик аңларлык сүз ычкындырып куйды.— Җитмәсә без дә буш калма-быз... Югыйсә әнә бал-май, ит-мазар тирәсенә якын килерлек түгел. Коточ-кыч кыйммәтчелек.

Бу сүзләр айнытып җибәргәндәй итте Иргалине. Аларның ярдәм итү дигәннәре шулай әҗәткә акча биреп торуга гына кайтып калыр микәнни? Ай-һай, белмим, белмим, дип уйланды ул. Уртак көймә сумала күрмәс дигәндәй, бурычка алып көн күрү төпсез көймәгә утыру булмасмы икән соң? Һәркем әҗәткә генә алып яшәр иде аны. Мәрхүм Миргали карт: өлеш бар җирдә үлеш бар, дияргә ярата иде. Урыны оҗмахта булсын, акыллы, зирәк карт иде.

Иргали күңелен янә тирән борчулы, хәвефле уйлар биләп алуын та-бын янында сиздермәскә тырышты. Авызыңда кара кан булганда да сер бирергә ярамый, дип уйлады ул. Әйдә, хәерлегә язсын, бурычлы үлмәс, дигән булып, үз-үзен юаткандай итте.

Залдагы сәгатьнең доң-доң килеп, төнге унберне сукканы ишетелде. Табын янындагылар тынып калган сыман булдылар. Шулчак горничная кереп, кунакка урынны Илья Олегович кабинетында җәюе турында хәбәр салды.

Иргали бушаган чынаягын әйләндереп каплады да, ачык йөзле, юмарт күңелле хуҗаларга кабат-кабат рәхмәтләр әйтеп, гафу үтенеп, урынын-нан купты.

...Кемнәрнең генә теләкләре кабул килгәндер, Иргалинең юлы коты-рып унды: Казаннан ат җигеп кайтты. Крестьян хезмәте белән көн күрә башларга ниятләгән кеше өчен ат кадәр атның нәрсә икәнен аңлатып то-руның хаҗәте юктыр. Аты юкның заты юк диләр.

Шуның өстенә әле чанада, торыпша астында, ике капчык он, бер кап-чыкка якын солы, кеше җилкәсеннән төшкән булса да, ярты авылны киен-дерерлек кием-салым да бар.

Өйдәгеләрнең шатлык-куанычлары баштан ашты. Тормыш көтмәгәндә-уйламаганда бәйрәм төсе алды. Бары тик Иргали генә үзен тыенкы-басынкы тотты, бүгенгә тамак тук, өс — бөтен, дип, артык туарылып ташламады. Хәер, моның сәбәбе дә юк түгел иде шул...

Бер хәстәр икенчесен тудыра, дигән сүз бик дөрес. Ат җигеп кайту гына да әллә ни кадәрле өстәмә мәшәкатьләр тудырды: кайда асрарга? Нәрсә ашатырга?..

Башта, берәрсенең буш абзарына куеп торыргамы әллә? дип тә уйлаган иде Иргали. Әмма баш вата торгач, бу уеннан кире кайтты. Өй хуҗасы Зәйтүнәнең кайчандыр кәҗә асраган, соңрак өч-дүрт баш тавык тоткан куышы бар, вакытлыча шуны файдаланып торасы итте. Әмма әлеге куыш бик бәләкәй, алды белән кертсәң, ат та борылырлык түгел иде. Арты белән чигендереп кертермен, дип уйлап куйды Иргали, нәрсәгәдер мыек астыннан гына елмаеп.

Иргали иң әүвәл, әлеге куышны иске каз ояларыннан, сынган көрәк, сапсыз сәнәк, иске себерке, яраксыз тимер-томыр ише нәрсәләрдән арындырды. Шул ук көнне Гыйззәт хәзрәттән бер олау салам сорарга мәҗбүр булды. Салам бердән ат астына салырга кирәксә, икенчедән иске алачыкның тишек-тошыкларын томаларга да кирәк иде. Гаҗәп хәл! Тегесе, бер түгел, ике олау салам бирде. Шуның өстенә әле ындыр табагыннан бер чана солы саламы да төяп алырга кушты.

Иргали, ягар өчен сүтелгән өенең ныграк такталарын сайлаштырып, куыш алдына бөркәү сыман нәрсә дә әтмәлләп куйгандай итте. Югыйсә улак куярга да урын юк иде. Бу эшләрне ул ләззәт табып, ибен белеп башкарды. Саф һавада башы ачылып киткән сыман булды. Сулыш алуларына кадәр рәхәт иде.

Аты алдына йомшак солы саламы салды да, алачыкның бөркәвен чак кына томалый төшеп, өйгә керергә булды. Кերә-керешли үк, яңа гына мичтән чыккан ипи исен абайлап алды. Юк, аның өчен гап-гади арыш ипие чак кына әчкелтем, җанга ял, тәнгә сихәт бирә торган муллык исе генә түгел, сүз белән генә аңлатып булмый торган үзенә бер төрле могҗиза сыман иде. Житмәсә, җылылык төшеп, котсыз өйгә бердәм ямь иңгән. Я-а, ходай! дип уйлап куйды Иргали. Һәр тумыш көнне, үз әҗәлен көткән сырхау кебек, калтырап иза чикмичә, менә шулай интекми-нитми яшәсәң иде икән!

Шулчак почмак яктан аш-су әзерләп йөргән Гөлниса чыкты. Йөз-битләре алсуланган, хәрәкәтләре өлгер-җитез, күз тия күрмәсен тагы, яшәреп тә, матураеп та киткән ич! Кулында иләк. Күрче зинһар, керфекләренә кадәр он кунган. Тавышына кадәр үзгә бит.

— Кердеңме, этисе? Әйдә, чишен дә, чәйләп алырбыз. Әнә, комганда җылы су...

Казаннан кайтканның икенче көнендә үк Иргали атын җикте дә Чаллыга китте. Клочкиннарның ниндидер Кузька-Бурлак исеменә атап язылган хатын илтә барды ул. Утлы башка ут кабар, дияргә ярата торган булган Иргалинең бабасы Миргали карт. Иргалине дә юлның юл буе берсеннән-берсе шыксызрак уйлар борчыды. Җанына ял, күңеленә тынгылык табарга язмагандыр инде, күрәсең. Бигрәк тә төнен авыр уздырды ул, үлеп арыган булса да, күзләренә йокы кермәде. Шулай күңеле кыйналып, көеп, сызып, таңны каршылады. Җанын кыйнаган, тынгылыгын алган нәрсә — әлеге дә баягы бурычка батып кайту иде. Әҗәткә эчкән ике исергән, диләр бит. Уйлый калсаң, бик тирән мәгънә ята ошбу сүзләрнең төбендә. Бирәләр дип бурычка алып, дөрес эшләдеме соң ул? Ничекләр итеп котылыр икән әлеге әҗәтеннән? Мондый уйлар аны тәмам пошаманга төшерде. Әҗәткә күп кергән бүре, бурычын тиресе белән түләр, диләр бит...

Кузька-Бурлак, Иргалигә мөрәҗәгать итеп, аның кайчан Казаннан кайтуы, тормыш-көнкүреше, семьясы белән кызыксынды.

— Н-да-а!..— диде ул, үзалдына сөйләшкәндәй итеп.— Заманалар шактый ук четерекләнде...

Ул арада, кабаланудан булса кирәк, тыны кабып:

— Тыңлыйм, Кузьма Данилович! — дип, Динис атлы бәндә дә килеп житте. Ул кирә-керешли үк: боерык сездән, йөгермәк бездән, дигәндәй ни кушсаң, шуны минуты белән башкарырга әзер булуын белдереп, тожрап тора иде.

Өй хуҗасы Иргали белән Динисны таныштырды. Иргали, урыннан кубып, яңа танышының кулын кысты. Динис, тышкы кыяфәте белән русны хәтерләтсә дә, солдат белән саф татарча исәнләште, хәтта, дуслык тәкъдим итәргә теләгәндәй, «яшьти» дип мөрәҗәгать итте.

Өй хуҗасы сүзне кыска тотты. Иргалинең кем булуын, нинди йомыш белән йөргәнен әйтте, кичекмәстән ярдәм итәргә кирәклеген өстәп куярга да онытмады. Моның өчен Динис бүген үк, хәзер үк солдатның тормышы-көнкүреше белән танышып кайтырга тиеш иде.

— Элемтә дә, барлык йомышлар да Динис аша йөртелер,— диде Кузька-Бурлак, кадак каккан сыман итеп.— Нәрсә кирәк, аңа мөрәҗәгать итәсең. Кулдан килгәнне, мөмкин булганны эшләргә тырышырбыз. Олег Авдеевич өчен җан фида...

Динис ул көнен тулысынча Иргали белән уздырды. Кузька-Бурлактан чыгу белән Салаязга кайттылар. Иргали юлда ук аны үзенең уй-ниятләре белән таныштырды. Клочкиннардан әҗәткә бераз акча алып торуын да яшермәде. Бурычны, алдан сөйләшенгәнчә, ит-майише нәрсә белән каплаячак. Моның өчен ул аяклы эре мал-туар алып, бераз икмәк каптырып, ит кундырып, суеп, Казанга илтергә тиеш иде. Аның бу фикерен яшьтие дә хуплады.

Динис белән Иргали бер-берсенә бик тиз ияләштеләр. Бигрәк тә Динис үзен гади һәм иркен тотты. Өйдәгеләр аны беренче күрүдән үк үз иттеләр. Мөгаен, саф татарча сөйләшә белүе араларны шулай якынайткандыр.

Иргалигә «яшьтиенең», тагын бер ягы — чын мәгънәсендә эш кешесе булуы ошады. Чәй дә эчеп тормады Динис, Иргалине җилтерәтеп диярлек ишегалдына алып чыкты. Дәрья кадәр ишегалдында, чүмәлә кадәр генә булып торган «кәҗә куышы» янына килеп, эченә күз салгач, сызгырып ук җибәрде.

— Ат кадәр ат ничек сыя соң монда? Ятарга теләсә, кашынанитә калса, бүселеп килеп чыкмасмы соң?

Иргалинең йорт урынына күчтеләр. Яшьтие бик ошатты өй-каралты буласы җирне. Шундук, кар ерып, олы-олы адымнар белән аркылыгабуйга үлчәп тә чыкты. Булачак каралты-кураның кайда, ничек урнаштырыласын чамалап карагандай итте.

— Менә бу якка буйдан-буйга абзар-каралты урнаштыру хәерлерәк булыр. Ә менә бу төштә, чарлаклы алты почмаклы өй! Тыкрык почмагы — таш келәт өчен үтергән дә куйган...

Иргали түзмәде, дустының сүзен бүлергә мәҗбүр булды.

— Һәй-й, яшьти!..— диде ул, юк белән башыңны катырма әле, дигән мәгънәне аңлаткандай кулын селтәп.— Кая инде ул безгә таш келәтләр белән чарлаклы өй турында уйлау. Ул бит тылсымлы таяк белән бер селтәнүдә генә эшләнә торган нәрсә түгел. Баш очыбызда кары-яңгыры үтмәслек үз куышыбыз булсын иде әле ичмаса. Өйдәш булып яшәгәнне үзең күреп торасың ич. Кеше түбәсе астында калачның да тәме юк димәсләр иде аны.

— Син, яшьти, алай өметсезләнмә әле. Олы максат олы көч тудыра ди. Кузьма Данилович әйткән икән, син аны барга сана. Ике сөйләшә торган кеше түгел ул. Менә әйткән иде диярсең, исән-сау булырга язса, менә шушы урында ялт итеп, кояшка каратып салынган йортың торачак...

Иргали янә көлде.

— Һәй-й, Динис туган! Авызыңа бал да май иде кана да бит. Әйдә, һич югында шулай дип юаткан бул инде. Кая инде ул безгә андый йорт-

җирләр! Монда әле әнә төнгелеккә ат алдына салырга сыңар сәнәк печән заты юк...

— Анысы аның вак мәсьәлә, булмаса булыр,— диде Динис конкрет бер карарга килгән кеше сыман итеп.— Бүген үк булыр. Әйдә, атыңны бор, Чаллыга киттек. Берьюлы мине дә озатып куюың булыр...

Шул ук көнне кичен Иргали, чанасына тау кадәрле итеп бер олау печән төяп, җилкапка төбенә кайтып туктады. Бу хәлне күргән өйдәгеләр, өсләренә дә киярга онытып, шаклар катып, урамга йөгерешеп чыктылар. Гөлниса белән Зәйтүнәгә бала-чага да ияргән иде. Кайдан килде шул тиклем хәзинә? дип аһ та ваһ иттеләр. Җилкапканы каерып ачып, олауны ишегалдына керткәч кенә тынычландылар. Бераздан Иргали янында, шәлен бөркәнеп, сырмасын киеп чыккан Гөлниса гына калды.

— Ай-һай ла, печәне! Урман печәне икән ләбаса. Исенә генә игътибар итче, сиңа әйтәм, чәй урынына салып эчәрлек, билләһи!..

Печәнне, атка да җылы булсын, дип куышның җил ягына өйделәр. Күрше-күлән кәҗә-сарыгы кереп пәрвайсызламасын өчен, иске такталар белән әйләндереп, койма ише нәрсә дә әмәлләп куйгандай иттеләр.

Ир белән хатын өйгә ут алгач кына керделәр. Аркалары лачма су булса да, йөзләре шат, йөзләре алсуланган, күзләре бәхетле елтырый иде. Өйгә кергәч тә мәзәк сүзләр әйтешеп, көлеп-шаярышып алдылар. Ни әйтсәң дә, бүгенге көндә, ходайның биргәненә шөкер, җан асрарлык мөмкинлекләре бар, ризыкка интекмиләр.

Ир белән хатын ашап-эчеп йокларга яткач та әле, байтак вакыт йокыга китә алмыйча, пышылдап сөйләшеп яттылар. Башта Иргали бүген башыннан кичергәннәрен сөйләп бирде. Билгеле инде, өй-фәлән хәстәренә керешкәнче, җылы абзар әмәлләп, аяклы мал алып, ит кундырып, әкренләп әҗәттән котыла башларга нияте барлыгын да киңәш-табыш итте. Күндәм Гөлниса берсүзсез риза булды. Гомумән, алар арасында ялгышлык белән генә дә аңлашылмаучылык, ачуланышу-үчләшү кебек нәрсәнең чыкканы юк. Ул көнне ир белән хатын арасында сүз шактый озакка сузылды. Гөлнисаның иң исе-акылы китеп тыңлаганы, әлбәттә, Кузька-Бурлак булды. Әлеге хикәятнең хатынының күңеленә шаккату белән бергә шомга охшаган шик тә салуын Иргали аның тын да алмыйча ятуыннан төшенде. Әмма тынычландырырга ашыкмады, чөнки ул үзе дә әлеге сәер яңа танышы турында икеле-микеле уйда иде. Хәер, бер Кузька-Бурлак кына түгел, хәзергә әле Динис «яшьтие» дә аның өчен ватып булмаслык каты чикләвек иде.

Икенче тапкыр Чаллыга баруында Кузьма Данилович янына «яшьтие» генә керде һәм аннан асыл кош тоткандай авызын ерып чыкты. Иргалинең иң әүвәл сыер-мазар алып симертеп, Казанга, Клочкиннарга илтергә теләвен хуҗа да бик хуплаган имештер һәм, менә, минутында ярдәм итәргә дә керешкән...

Динис Иргалине арткы урамнарның берсенә алып китте. Бер зур гына йортның, чуарлап-бизәкләп эшләнгән капкасы янында атларын туктаттылар. Яшьтие әлеге өйдән дә тулган айдай балкып чыкты. Тар тыкрык буйлап, әлеге йортның бакча ягына төштеләр дә, ике-өч киртәне алып, тезелешеп торган печән кибәннәре янына кереп туктадылар.

— Сыйдыра алган кадәр төя...— диде Динис, үз малы турында сүз алып баргандай итеп.

— Олавы күпме торыр икән соң?..

Яшьтие аны шундук бүлде:

— Юк белән баш катырып торма әле, төявеңне бел. Бәлки әле кибәне белән алырга туры килер.

Ул арада Динис, бакчага тирес ташыган сукмак буйлап, өйнең арткы капкасына таба юнәлде. Бераздан ул аннан, каен агачыннан ясалган һәйбәт бастырык, юан арканнар һәм бер сыңар тимер сәнәк күтәреп чыкты.

Печән төягән арада Иргали тынгылык бирмәгән, Казанда ук үзен кызыксындырган сорауны бирергә җөрьәт итте: үгезнекедәй иләмсез юантык муенлы, шакмак ияк Кузька-Бурлакның кем булуы белән кызыксынды. Яшьтиенең җавабы да сәеррәк: хикмәтле кеше, Кузьма Даниловичны Идел-Кама буйларында белмәгән кеше юктыр, диде ул. Заманында пароходлар тотуын да әйтте. Әмма бөтен булган байлыгы, ничек кергән булса, шулай чыгып та киткән: картада оттырган, дигән имеш-мимешләр йөри, янәсе. Иргалинең күңелендә Динис сөйләгәннәрнең бары тик «хикмәтле кеше» дигәне генә уелып калды.

Печән төяп кайтканның икенчеме-өченчеме көнендә таң белән җилкапка янына, ат сыртына җитәрлек итеп юан-юан имән кискәләре һәм кайрылары каезланган төп-төз бүрәнәләр төяп, берьюлы өч-дүрт олау килеп туктады.

— Әй-й, яшьти, давай каршы ал!..— Бу Динис тавышы иде.— Менә, әзер абзар бурасы китердек, бисмилла әйтеп, күтәреп куясы гына. Яшь мал-туар өчен мич чыгарылган җылы бүлеге дә булачак. Тот та хет үзең яшә!

Сүз белән озак булышмадылар. Көрәкләр белән юл ачкандай итеп, йөкләрне Динис күрсәткән урынга кертеп бушаттылар.

Иргалигә дә атын җигеп, әлеге олауларга ияреп, Чаллыга чыгып китәргә туры килде. Ул бер юллап кайтканда, каралты-кура буласы урында, бушатылган бүрәнәләр арасында калган Динис, күрше-күләннән алып чыгылган агач көрәкләр белән карны көрәп, ачылган җирнең җиде-сигез урынына учаклар ягып җибәргән иде инде. Аның янындагы ике-өч кеше баулар сузып, нәрсәдер үлчиләр, нидер билгелиләр.

— Яшьти, вакытлары булса, хатын-кызларга әйтче, өеңнең моржасын сүтеп, тазарак кирпечләрен балчык-сөремнән арындыра торсыннар әле. Иш янына куш булыр.

Ә инде икенче тапкыр юллаганда киртләнгән бүрәнә башлары гына сыярлык итеп, буеннан-буена уемты ясалган, кеше кочагы җитмәслек берничә имән кискәсе утыртып та куелган иде.

Шундый, имән сайгаклар җәелгән олы абзарны шулай тиз салып була дисәләр, Иргали үз күзләре белән күрмәсә, һич кенә дә ышанмас иде. Өске өлешен кыеклап, түбәсен тоташтан өр-яңа такта белән ябылган иләмсез озын ялт итеп торган абзарны күргәч, «бөтен авыл мал-туарын ябарга җыенасызмы әллә?» — дип теш агартучылар да, өй салмас борын каралты-курага тотынгангамы, «ат алганчы ияр ярәшкән, дип менә шуны әйтәләр инде», дигән булып мыек астыннан гына көлүчеләр дә табылды.

Иргалинең чираттагы базар көнне Чаллыдан чанасы артына бура кебек тулышкан берьюлы ике буаз сыер тагып кайтуын күргәч, авыл халкына янә җитә калды: китте гайбәт, китте сүз — түз генә. Имештер, «Иргали калага барып, зур табышка юлыккан...» Икенчесенең, дөньяга аеграк карый торганының җавабы әзер: «Шулайдыр, аңар дип атап төшереп калдырганнардыр». Хәер, арада дәреслеккә тартым ышын-пышыннар да булгалады. Янәсе, Иргали сугыш кырында Казан каласында яшәүче бик олуг, бик атаклы докторның бердәнбер газиз улын үлемнән йолып калган. Әлеге доктор аңа шул тиклем мал-мөлкәт биргән, ул байлыкларның бер дә чутлап чутына, санап санына чыга торган түгел, имештер.

Базарның икенче көнендә үк, яшьтие чакыруы буенча, яңадан Чаллыга китте Иргали. Бу юлы да буш кул белән кайтмады, берьюлы сигез капчык фуражлы булды. Динисның Чаллыдагы бөтен Чулман буена атаклы элеваторында да әшнәләре бар икән, Иргалине озата чыкканда: «Килеп алырга гына иренмә, әлеге чүп-чарның исәбе-хисабы юк монда»,— дип калды.

Шул көннәрдән башлап, өйдәгеләрнең барысы да диярлек, абзар тирәсендә мәш килеп ябышып яттылар. Тиресеннән чыгардай булып иң тырышкан кеше, әлбәттә, Миңсылу иде. Орчык кебек бөтерелде ул малтуар тирәсендә. Аның хәтта кайчан торып, кайчан ятканын һичкем бел-

мәс иде: син күргәндә инде аның ду-у китереп эшләп йөргән чагы булыр. Иң хәйранга калдырганы шул: нинди генә эшкә алынса да, умырттырып, җиренә җиткереп башкарып куя иде.

Ә эш баштан ашкан. Сыерлар янына тагын дүрт баш сарык, ике оя каз, егермеләп тавык та өстәлде. Бер заман, мин сиңа әйтим, сыерлар бозаулый, сарыклар бәрәнли башлады, хәйран-тамаша. Бу хәлләрнең һәркайсы барысы өчен дә үзенә бер бәйрәм төсе ала иде.

Яшь булуына да карамастан, бу эшләрнең үзәгендә, әлеге дә баягы Миңсылу бөтерелер иде. Иң әүвәл, таң атар-атмас борын, йөгерә-йөгерә су ташый, яшь мал-туар бүлеген җылыту өчен, утын хәстәрләп, мичләргә яга, су җылыта, терлекләргә, кош-кортларга азык бирә, асларын тазарта. Аның шулай очынып эшләвендә бер күндәмлек кенә түгел, ә үзенә бер төрле ниндидер үҗәтлек тә бар иде төсле. Кая карама, бөтерчектәй ул бөтерелә. Өйгә дә күз бәйләнгәч кенә керер иде.

Анда да, тын алып, чак кына ял итү юк. Бер караганда, тез арасына гөбене алып, дөмберен шундый итеп уйната, туганнан бирле бары тик май язу белән генә мәшгуль булган диярсең. Икенче караганда инде, юып киптерелгән керләр белән мәш килә: сырлы бәләк белән дөбердәтеп кием-салым тәгәрәтә, таслап-йомшартып һәйбәтләп җыеп куя. Өченче караганда инде, ул почмак якта, сукыр лампа яктысында дөпе-дөпе китереп, он или, җилпучын кага-кага онын җыештыра, көрпәләрен урнаштыра.

Шулай мал-туар, кош-корт белән мәш килеп, ярты кышның үтеп киткәне сизелми дә калды. Ниһаять, Иргали, ит ише әйберләргә югары бәяне базар үзе билгеләгән бер чорны туры китереп, калага җыена башлады. Хәер, моның хәстәренә шактый ук элек керешкән иде инде. Беренче бозавыннан котылган яшь сыерга, сугымга дип билгеләнгән ике баш сарыкка алдан ук инде икмәк каптыра башладылар. Үзләре, угызны исәпкә алмаганда, бер генә сыңар чынаяк та аермаган сөтне авызларына алмадылар, сыерлар бозаулаганның икенче көнендә үк, Казанга алып бару өчен май яздырырга керештеләр. Бу эшләрнең барысы белән дә Гөлниса үзе шөгыльләнде: сыерларны ул сауды, сөт өстен җыйды, яздырылган майны һәйбәтләп үзе йомарлады. Аларны чүп-тузан ише нәрсәнең әсәре дә кермәслек итеп томалап, махсус олы куәстә саклады. Казандагы карт докторның: татарлар чиста, ару, пакь халык, дигән сүзләрен бер генә минутка да исеннән чыгармады ул. Бу турыда Иргали аңа зинһарлап, кат-кат тәкрарлап әйтте.

Ниһаять, килеп җитте ул көн. Сыерны суярга аргы урамның Мүкләк Гатаулласын чакырды Иргали. Кулы җиңел, ул чалган малның ите тәмле була имештер.

— Тә-тә-тә!..— дип куйды сугымчы, абзар буена чыгарып бәйләнгән боландай сыерны күздән кичереп.— Сөбханалла! Симез малга чүп-чар да ябышмый, дип дөрес әйтәләр шул, ялтырап торуларын гына күр син аның.

Ир-ат үз эшенә кереште. Алар янында йомыш йомышлап, кая кусалар, шунда йөгереп, җиңел сөяк Миңсылу гына бөтерелде: кайнар су, сөлге, табак, ләгән ише әйберләр алып чыкты. Өйдәге хатын-кызлар да ачы таңнан шундый ук җаваплы эш белән мәшгульләр иде. Бер тәпән сары май кайнаттылар, ике тәпәнгә атланмай тутырдылар. Тәпәннәр яңа гына оста кулыннан төшкән, борыннарны рәхәт кытыклап юкә исе аңкып тора иде. Тәпәннәрнең авызлары, кояш күзенә җаеп агартылган кершәндәй, ак киндерләр белән томалап бәйләнде. Чисталык, чисталык, тагын бер тапкыр чисталык.

Хатыннарның эшеннән Иргали канәгать калды. Хәзер дә ул Мүкләк Гатаулласының өстендә тора, үтенеч бер: тунаганда ит канга буялмасын, ялгышлык белән генә дә тәк-йон ише нәрсә кала күрмәсен.

Иртәгә таңнан сәфәр чыгасы дигән көнне, өйдәшләр яшәгән түбә астында моңарчы һичкайчан күрелмәгән бәйрәм үткәрелде. Сыер кадәр сыерның, ике сарыкның эч-башы, тезбаш-тубык сөякләре — барысы да үз-

ләренә калды. Казан тулы итле аш, мичтә вак бәлешләр пешә. Тормышкөнкүрешнең бөтен ачысын-төчесен үз җилкәләрендә татыган адәм балаларына тагын ни кирәк ди?!

Китерелгән ит-майны ризалык белән генә кабул итеп алсалар ярар иде дип, көянәк җаны юлның юл буена тынгылык белмәде Иргалинең.

Казанга якшәмбене көздә тотып сәфәр чыкты Иргали. Максаты — Клочкиннарны өйдә туры китерү иде. Юл йөреп, өченче көннең төш вакытларына мәшһүр калага килеп керде. Ашкынуы тикмәгә генә булмаган икән, олуг кунаклар өстенә барып төште Иргали. Кайчандыр аны сукранып каршылаган хуҗабикәнең бертуган абыйсы Карл Семенович аларда иде. Хатыны, ике баласы белән. Үзе нык бәдәнле, таза-егәрле кеше, ә хатыны элеп киптерелгән балык сыман үтә дә чандыр, үтә дә юка иде.

Кунак бар дип тормадылар хуҗалар, Иргалине дә ихлас күңелдән күтәреп диярлек каршы алдылар. Алып килгән әйберләрен күргәч, бөтенләй аһ-һ иттеләр. Бигрәк тә Карл Семеновичның хатыны үзенең соклануын яшерә алмады, хуҗабикә сыман кыланды, иң әүвәл итләрнең киндерләрен йолкып атты, тәпәннәрнең дә авызын ачты. Шундук: «Безгә дә өлеш чыгарасызмы?» — дип, Ксения Семеновнаны тинтерәтә үк башлады. Хуҗа кунак кубызына биер, дигәндәй, чандыр хатынның теләге бернинди каршылыксыз үтәлде: бер сарык түшкәсе, сыерның сыңар арт боты һәм дә килеп, бер тәпән атланмай шундук бер читкә алып куелды.

Иргалинең атын күрше ишегалдында яшәүче бер татар абзыена тапшырдылар. Баш өсте, җаныгыз тыныч булсын, дип бик теләп рази булды әлеге абзый. Ул да ат тота, Клочкиннар белән якын мөгамәләдә икән, аларның ишегалларын җыештыра, чүп-чарларын каядыр кала читенә илтеп түгә, башка төрле йомышларын үтәп көн күрә икән.

Иргали яңадан ындыр табагы чаклы өстәл артында утыра. Бу юлы инде хуҗаларның җандай кадерле кунаклары белән табындаш булып. Барысының да күзе Карл Семеновичта. Ул үзе яшәгән, үзе эшләгән Паратов затоны, суднолар ремонтлау заводы, ай үсәсен көн үскән яшь кала турында сөйли.

Аңынчы Карл Семенович Америка предпринимателе Ропста, соңрак Франциянең Вишер акционерлык җәмгыятендә хезмәт иткән була. Идел аша салынган дөньядагы иң зур тимер күпер телгә алынгач, Иргали кайсы тирәләр турында сүз барганын абайлап алды: күп дигәндә, Казаннан кырык чакрымнар гына булырга тиеш. Ул малай чакта алар ягыннан да, әлеге күперне салырга дип, Кабачише дип аталган җиргә китүләре хәтерендә уелып калган.

Кунаклар китәргә җыена башлады. Күрше агае баскыч төбенә таңкәле, чуклы-чачаклы дирбияләр белән җигелгән пар ат китереп туктатты. Атлары да, чуарлап мөгезләр куеп бизәлгән бөркәүле артлы чанасы да сокланып туярлык түгел иде. Атларны каяндыр килеп чыккан кучер кабул итеп алды.

Чыгып китәр алдыннан юан-йомры гәүдәле, шакмак иякле Карл Семенович, түш кесәсеннән итек кунычы кадәрле бумажнигын чыгарды да Иргалигә бер баш сыер алырлык акча тоттырды. Иргали аяк терәп алмаска тырышып караган иде дә, кая ул, авызын да ачтырмадылар. Итмайны мактап кына калмадылар, туп-туры үзебезгә килегез дип, визит карточкасы бирделәр, тиздән, бик тиздән берьюлы ике сыер түшкәсе алып килүен үтенделәр.

Хуҗалар Иргалине көчләп диярлек кунарга калдырдылар. Иртәнге якта аталы-уллы Клочкиннар эшкә җыена башлады. Иргали дә: калган көтү калган дигәндәй, иң әүвәл кибетләрне әйләнеп килергә булды. Шактый вакыт югалып торып, аллы-артлы төенчекләр асып кайткан кунакны Ксения Семеновна каршылады. Юк йомышын бар итеп өсләрен салдырды, кабат табын янына утыртты, якты караш сирпеп, бик тә инде ипле-ягымлы мөнәсәбәт күрсәтте, әйткән һәрбер сүзе күңелгә сары майдай ятышлы иде.

Горничнаясын каядыр олактырган Ксения Семеновна, бөтен өйне бер итеп, Иргалине моңарчы күрмәгән бүлмәләр буйлап йөретте. Йокы бүлмәсендә бугай, биеклеге түшәмгә кадәр җиткән көзге каршында бәләкәй генә сандык төсле итеп ясалган бизәкле тартмадан бер кызыл унлыкны алып: тыгып куй әле шуны, эчеңне тишмәс... дип, кунагы кесәсенә салды. Үзе һаман күзләрен уйнаткалап, артын биетеп, Иргали тирәсендә чуалды, аның таза-ныклыгына соклануын яшереп маташмады: «Менә ичмаса ир!.. Кровь с молоком!» дип, иң-күкрәк тирәләренә кагылгалап алды. Тел төбенә күп төрле мәгънә салып: «Хатының бәхетледер...» — дип өстәп куярга да тартынмады. Аннары инде, аңлаган кешегә бик аңлаешлы итеп, ире Илья Олеговичтан зарланасы итте:

— Безнең ирләрнең рәте-чиратлары юк, аларны аракы, тәмәке, чит хатын-кызлар янына йөрү эчтән сыздырып, ябыктырып-таркатып бетерә...

Бу юлы Иргали Казан каласыннан тагы да баебрак кайтты. Һәрхәлдә, ул инде элеккеге кебек тормыш агымына карусыз буйсынып яшәүче түгел иде. Чыннан да, тормышы күзгә күренеп үрләде, алга китте.

Аның озын юлдан кайтуына да карамастан, пар атын олы урамнан җил уйнатып чаптырып үтүен күреп калучыларның янә телләре языылып китте. Билгеле инде, «шикле кәсеп белән баеп китте» дип тә, моңа дию пәриләре ярдәм итәдер дип тә теш чарладылар. Әмма эшчән Миргали картны хәтерләүчеләр, шулай ук Иргалинең дә бар көчен-ихтыярын туплап, тиресеннән чыгардай булып тырышуларын күрүчеләр, башкача фикер йөртте: хикмәтнең башы — хезмәттә! Кеше ни сөйләмәс, тел сөяксез бит.

Бу юлы Казан бүләгенең иң зурысы, эш дип ут кебек очып йөргән Миңсылу балдызына булды. Аның җилкәсенә һәйбәт якалы өр-яңа бишмәтне үз кулы белән салды Иргали. Калача тегелгән бишмәтнең барлык төймәләрен дә каптырып куйгач, барысы да бермәлгә тынып калдылар. Чыннан да, күзгә күренеп үсеп киткән икән ләбаса кызыкай. Күр син аны, карап сокланып туймаслык бит!

Иргали дә буй җиткән балдызкаена карап, телен шартлатырга мәҗбүр булды.

— Әттәгенәсе лә, күрче зинһар! Минем балдызыммы соң бу? — Кызның комачтай кызаруын күреп, сүзен икенчегә борырга ашыкты.— Ярар, үскәнем, җылы тәнеңдә тузарга язсын.

— Рәхмәт, җизни!..

Миңсылу, яңа бишмәтен һәйбәтләп элеп куйды да, иске сырмасын җилкәсенә салып, атларга солы салырга дип чыгып та йөгерде. Иргали аның артыннан:

— Менә бүләкләрне өләшеп бетерәм дә үзем дә чыгармын,— дип кычкырып калды.

Әкренләп көннәр язга таба борылды. Аңарчы инде Иргали ике тапкыр Казанны әйләнеп кайтырга өлгергән иде. Соңгы баруында хәтта Карл Семеновичларга — Паратов затоны дигән яңа калага да сугылып чыкты. Юлы һәрчак ул көткәннән дә артыграк уңды аның.

Нәкъ шул көннәрдә, юллар өзелгәләгәнче дип, Динис булачак алты почмаклы өйнең әзер бурасын ташыта да башлады. Иргалигә дә, кырык эшен кырык якка ташлап, берьюлы ике атын җигеп, Чаллыга чыгып китәргә туры килде. Шәмдәй төз, бер төптән киселгәндәй тигез, сагыз исе аңкытып торган нарат бүрәнәләрен күреп, халык янә хәйран калды.

Өй салучы осталарга акчаны эш башыннан түләргә дип сөйләшенде. Әлеге дә баягы, Кузька-Бурлак әмере шундый булган. Хәер, бу чараны эшне башлап йөрүче Динис та хуплады: төзү эше тизрәк тә тотылыр, сыйфаты да менә дигән булыр, диде ул әлеге фикерне кабат яклап.

Әйтерсең лә яшьтие, Иргалинең күңеленә вәсвәсә төшүен сизенгән, буш минут сайлап, болайрак сөйләнеп алды.

— Хәер, бу кадәресен генә син үзең дә белергә тиеш идең. Синә хәзер тормыш итәргә өйрәнә башларга вакыт. Шуны бел, ярда утырып кына йөзәргә өйрәнеп булмый. Аннары тагы бер киңәш: һәр эшкә йөрәксе-

неп керешергә кирәк. Тормыш — аягында нык торганнарны ярата. Сүз дә юк, зур эшкә алынабыз. Дивана әйтмешли: мүкләве дә, чутлавы да бездән. Эш күп булачак. Әмма бу хәл өркетми безне. Эш күп булганда, вакыт үзе ярдәмгә килә ди бит. Мин монда осталарның бик кәттәләрен, эш теткәзми торганнарын алып килдем. Күңелең тыныч булсын, бернинди дә хилафлык булмас.

Дүрт кешедән торган осталар әртиле, урам аша гына яшәүче Салиха карчыкта туктады. Ире Герман сугышыннан кайтмаган, тартып-сузып үстергән бердәнбер улы Кызыл Армия сафларына алынып, Бөгелмә каласы өчен барган каты сугышларда башын салган иде. Әртилчеләр ике көнгә бер тәкә алып суйдылар. Эшкә беренче әтәчләр белән чыгып, караңгылык иңгәч кенә туктыйлар иде.

Осталар, кайдандыр таш китертеп, биек итеп нигез салдылар. Калганы ничектер бик тиз эшләнде сыман. Биек болдырлы өйнең бурасы өч-дүрт көн эчендә күзгә күренеп диярлек күтәрелде. Үтеп-сүтеп йөрүчеләргә, бу хикмәтне күреп: боларга пәриләр ярдәм итәдер, бер дә бүтән түгелдер дип теш агартырга янә ярап куйды.

Ишегалды ягында буйдан-буйга тоташ тәрәзәле веранда сузылды. Ул биек болдырлы, култыксалары сырлап-бизәп ясалган баскычка барып тоташа иде. Шулай итеп өй әкренләп түбә астына да керде. Түбә һәйбәтләп ышкыланган тоташ нарат тактасы белән ябылды. Чират ишек белән тәрәзәләргә дә җитте. Динис көннәрнең берендә, иртәнге кояш нурлары сибелә башлаганда, тулы бер олау тәрәзә рамнары, йөзлекләре һәм тагын бик күп төрле нәрсәләр алып килде. Барысына да яңарак кына останың алтын куллары кагылган. Һәркайсы карап туймаслык. Агачка чигү чиккәнгә охшатып, уймыр белән ясалган челтәрле бизәкләрне, чуарлап эшләнгән өлгеләрне күргәч, Иргали сөенергә дә, көенергә дә белмәде, бары тик җилкәләрен җыера төшеп:

— Бу кадәр үк булмаса да ярар иде...— дип кенә әйтә алды.

Тынгы белмәс Динисның үз сүзе сүз.

— Юк, яшьти, мондый өйгә килде-китте генә тәрәзәләр ярамый. Югыйсә алар нәкъ керфексез күзгә охшаячак. Синең бәләкәй генә, тонык кына тәрәзәле өйләргә игътибар иткәнең бармы? Бардыр, билгеле. Кемгә ничектер, әмма миңа алар көчләп күзләре йомдырылган адәм башын хәтерләтәләр.

Динис, зур капканың як-ягына да кояш нурларына охшатып ясалган бизәкләр кактырды. Хәтта, урамның өй буе рәшәткәләренең өске өлешләре дә бизәк-чачаклар белән челтәрләп ясатып алынган иде.

Я-а, ходай, тиздән яңа өйгә күченәбез бугай инде дип кенә торганда, Кузька-Бурлак яңадан үз хәстәрен китереп кыстырды. Кунарга дип кайтып киткән Динис янә дә өч оста ияртеп килде. Болары ташчылар иде.

Очлы күз Динис үзләрен фатирда торкан Салиха карчыкның, бөтен өй тирәсе ямен җибәреп, түбәсе ишелеп төшкән, күптән инде ташландык хәлгә килгән, тирә-юнен котырып алабута, сукыр кычыткан баскан таш келәтне шәйләп ала. Бу турыда Динис Кузьма Даниловичка да сөйләп бирә. Тегесе: бик хуп, ди. Шулай итеп Динис, хуҗабикә белән килешеп, «харабә»не ике капчык арыш онына алыштырып та ала. Фәкыйрә карчык иксез-чиксез рәхмәтләр әйтеп, бик рәхәтләнеп риза була. Кузька-Бурлакның нияте изге: мал-туар белән эш итү һәйбәт, игенчелек тә ярый, ди ул, әмма кибеткә берни дә җитмәс, аннан кесәгә акмаса да тамар ичмаса ди. Салаязда кибет ачып җибәрергә карар кыла. Әйткән сүз — аткан ук. Осталар шул ук көнне эшкә дә керештеләр. Каяндыр кемнеңдер коймасын сүттереп булса кирәк, тагын җиде-сигез олау таш кайтардылар. Шулай итеп Иргали ихатасының тыкрык почмагында ташпулат үсеп чыкты. Түбәсен калай белән яптылар, кайдадыр лапас астында тутыгып яткан тимер ишекне табып алып, аны керосин белән җебетеп, һәйбәтләп кырып, юып, яшелгә буяп, күгәненә асып куйгач, әлеге ташпулат үзе бер урам ямена әверелде.

Иргалинең бу адымын Гыйззәт хәзрәт кенә хупламады, баксаң, әлеге таш келәткә үзе күптән кызыгып йөргән булган икән. Ә инде күршесенең Мичһаҗетдин бай көндәше булып, кибет ачып җибәрергә җыенуы турында ишеткәч, бөтенләй кара көйде. Әмма сер бирергә теләмәде. Иргалинең зурдан кубарга, кызыл мал белән эш итәргә теләмәве турында сүз алгач, бөтенләй тынычланды, хәтта, хуплагандай, сөйләнеп тә алды: «Сәүдә — игелекле эш, батырлык, тәвәккәллек, тапкырлык сорый торган кәсеп. Синдә, мелла кем, ходайга шөкер, бу сыйфатларның һәммәсе дә бар. Хәрам кермәгән кәсепнең бернинди гөнаһысы да юк: алла каршында да, сәвит каршында да. Әнә, үзең күреп-ишетеп торасың, дәрт иткән кешегә юл ачык...»

Хәер, Гыйззәт хәзрәтнең туганы Минһаҗетдин бай турында хафалануы юкка гына булган икән, көндәлек кирәк-ярак: чәй-шикәр, сабын-тоз, шырпы-керосинише әйберләр белән генә сату иткән Иргали бу кәсептән котая алмады, алай гына да түгел, бөтенләй уңмады. Ярты ел чамасы уздымы икән, юмарт, киң күңелле Иргалине, нәкъ әрсез тигәнәк кебек булып, авылның ярлы-ябагасы, гарип-горабасы сырып алды. Ике исәп — бер хисап, дигәндәй, счет төймәләрен кат-кат тартып караганнан соң, һәммәсе дә ачыкланды: кибет киштәләрендә бары тик әҗәткә дип алып торган кешеләрнең исемнәре теркәлгән күн тышлы калын-калын амбар кенәгәләре генә утырып калды. Иргали, яшелгә буялган богаулы тимер ишекне ишегалдына күчереп, урам якны әйбәтләп томалатты да, әлеге шөгылен түгәрәкләде дә куйды. Шулай итеп, кеше эзе суынмаган таш кибет салкынча һавалы, ни куйсаң да сыярлык келәт вазифасын үти башлады.

Ул арада Минһаҗетдин байның да көймәсе комга терәлде: авылда халык теленә «хөкүмәт кибете» дип кергән кооператив магазиннары ачылды. Тормышлар чак кына җайга салынды, крестьян өчен иң кирәкле товарларга кытлык бетеп килә иде инде.

Иргали бөтен көчен туплап, ун тырнагы белән берьюлы җиргә ябышып, терлекчелек һәм игенчелек белән шөгыльләнә башлады. Яхшы сүз йөгәнле дә, иярле дә була дип, тикмәгә генә әйтми торганнардыр шул, Иргали дә күп нәрсәләрне рәхмәтле бәндә Динис кушканча, аның киңәше белән эшләде. Иң әүвәл җир-биләмәләр булдыру хәстәренә кереште. Бу мәсьәлә дә ничектер үзеннән-үзе хәл ителде: һәркайда фәкыйрьлек, ятимлек, күпчелек хуҗалыкларның сөрим дисә аты, чәчим дисә орлыгы юк иде. Шунлыктан калдау җирләр дөнья кадәр, кодрәтеңнән, көч-хәлеңнән килә икән, теләсәң күпме эшкәрт: сукала, тырмала, умырып, уңышын җыеп ал. Иргалинең терлек белән әвәрә килүен исәпкә алып, күбрәк мал азыгына басым ясарга — борчак, ясмык, солы, кәрешкә ише нәрсәләр чәчәргә киңәш итте Динис. Хәтта сортлы яхшы чәчүлек тә табышты.

— Шуны бел, яшьти, җылы абзар ярты азык булса, яхшы артым алуның, мул сөт савуның нигезе — терлек азыгы.— Гомере буе бары тик шул кәсеп белән генә шөгыльләнгән кешедәй, бик белдекле кыяфәттә болай дип тә өстәде.— Ел килеше игенчене болай да, тегеләй дә сыный. Ни өчен әйтәм әле аны... Аксымга бай үсемлекләр чәчү алдагы ел уңышына да уңай йогынты ясый. Сынап баккан, зур тәҗрибә туплаган кешеләрнең әйтүенә караганда, быел борчак чәчелгән бер гектар җир, киләсе ел игене өчен җитмеш-сиксән олау тирес чыгару бәрабәренә тиң ди.

Иргали игенчелек эшенә керешүнең беренче елында ук, калдау җирләр белән бер рәттән, гасырлар буе сука күрмәгән ак кылганлы аланнарны да, авылдан читтәрәк яткан, кеше кулы тимәгән чирәм җирләрне дә эшкәртте. Яз башында ук сатып алган тимер сабаныннан, үзе уйлавынча, бик тә уңды. Хәер, төрәннәре елык-елык ялтырап торган, атлар өчен дә җиңел булган әлеге сабанга күрше-күләннәр дә кинәнде. Иң әүвәл, әлбәттә, хуҗабикәләре Зәйтүнәнең бакчасын-кырын сөреп, тырмалап, чәчәсен чәчеп, утыртасын утыртып бирде. Югыйсә узган елларда

ул имана җиренең нибары өчтән бер өлешен генә чәчеп килгән — калганына хәле җитмәгән.

Нинди хикмәт кодрәтедер, еллар, һичкайчан да булмаганча матур килде, дөньялар имин, тормыш та ничектер сизелеп алга киткән сыман иде. Ике ел рәттән бәрәкәтле җир моңарчы күрелмәгән, кеше әйтеп, кеше ышанмаслык уңыш бирде. Кырларын, булсын дип, җиренә җиткереп эшкәрткән, мул итеп тиресләгән Иргалинең җигүле атны кумәрдәй арыш басуларын күргән кешеләр янә аһ-һ иттеләр. Адәм баласының бүресе бер уласа улый икән, күр инде ә, кай арада өйле-йортлы булды да, кай арада якты көнгә чыгып, михнәттән котылды, диген. Тәки күк капусы ачылды кешенең, байлык-дәүләт үзеннән-үзе керә бит! Тикмәгә генә: хәле барның әмәле бар дими торганнардыр, күрче, әнә нинди мул тормышлы булды да китте бит, мин сиңа әйтим.

Чыннан да, ул елларда Иргалиләр ике арыш, бер бодай кибәне куйдылар. Борчак, солы, ясмык ише нәрсәләрнең мул уңышы турында әйткән дә юк. Билгеле, боларның берсе генә дә үзеннән-үзе килмәде, күпме көч, күпме егәр сарыф ителде, һәр эшкә күңел җылысы, җан кайнарлыгы салынды. Тиреләреннән чыгардай булып эшләделәр Иргалинекеләр. Аның ял белми, төн йокылары күрми эшләвенә авыл халкы да хәйран калды. Иртә яздан кара көзгәчә шулай: эш, эш, эш. Башта чәчү, печән әзерләү, чак кына хәл алырга да өлгермисең — урак өсте, көлтә кертү, ындыр суктыру.

Кыш кердеме, янә ял юк: терлек симерт, илтеп сат, янә абзар тутырып мал-туар ал. Әмма Иргали һичкайчан да ару-талудан зарланмады, аяктан егылыр хәлгә җиткәндә дә күңеле көр, тәнендә сихәт артуын тоя, башкарган эшеннән тәм, тел белән аңлатып булмый торган нindидер рәхәтлек, олы ләззәт, хозурлык ала, канәгатьләнү хисе кичерә иде.

Иргалинең, өй туе сыман нәрсә ясап, үз нигезенә керүенә дә өч ел вакыт тулып узды. Аның нәсел-нәсәптән килгән байларны да артта калдырып салынган, йөзек кашы сыман балкып торган йорты, бөтен авылга ямь биреп, урамның кайсы ягыннан гына карасаң да, ялт итеп күренеп тора иде. Шулай итеп Иргалинең гаиләсе тормыштан тәм, яшәүдән ямь табып көн күрә башлады. Бер генә дә җитешмәгән җирләре юк иде. Ак мунчалары да күп кенә кешеләрнең өйләреннән болайрак — болдырына кадәр бурадан буратылган. Соңрак каралты-кураны уратып алган киртәләр дә, әле нык булуларына карамастан, өйнең ямен җибәрәләр дип, алып ташландылар. Алар урынына абзар-каралты бурасы биеклегендә башлары киртәләнгән, ышкыланган тактадан өр-яңа утыртма койма койдылар. Иске сирәк читәннән башка нәрсә күрмәгән караңгы тыкрыкның да буеннан-буена, бакчалар артында агып ята торган Агыйнеш елгасына чаклы, такта койма сузылды. Элеккеге өйдәшләре — Зәйтүнәләр белән мәңге йомыш-юлга керешеп яшәрбез дип, ике ишегалды арасында җилкапка калдырылган иде, эш белән артык мавыгып-кызып киткән осталар, әлеге капканы алып атып, кош та очып үтәлмаслык иләмсез биек койманы тулаем тоташтырып куйдылар.

Койма биегәюгә карап, ут күршеләр арасына күләгә ятмады. Һаман да башы фәкыйрьлектән чыкмаган Зәйтүнәгә күршеләре әледән-әле ярдәм кулы суза тордылар. Балалары өсте алынган сөттән, катык-эремчектән өзелмәде. Ә инде Иргалиләр май язган көнне янә бәйрәм, бер-берсен тапташып үсеп килгән өч ташбашы — Гази, Таҗи һәм иң татлы төпчеге — Һади эчләре күпкәнче әйрән эчәрләр иде. Әйрәне әйрән генә идеме соң, «өреле» әйрән, өстендә тары бөртеге кадәрле генә булса да мае йөзеп йөри торган әйрән.

Тормыш дәвам итте. Иргали аякка басты, кеше булды, һичнәрсәгә мохтаҗы юк дип тормады олы җанлы Динис, ике араны суытырга ашыкмады, һаман да килә-китә йөрде. Үзе һичкайчан да буш кулы белән килмәде. Берсендә арбага сузып салып, унлап төп алмагач, чия үсентеләре, башка төрле җиләк-җимеш куаклары алып килде. Янә дә бик белдекле кыяфәттә баулар сузып, үлчәп, оялар ясады да, төпләренә тирес аралаш-

тырылган туфрак салып, үзе үк утыртып та бирде. Карлыган, кура җиләге, крыжовник ише нәрсәләр койма буена урнаштырылды.

Икенче килгәндә арбасына, тау кадәрле итеп өеп, берьюлы ун баш умарта алып килде. Үзе үк бакчада, тиешле якка каратып, урнаштырып та бирде. Ә инде аннан соңгы килүендә, Иргалине чынлап торып гаҗәпкә калдырып, куеныннан бәләкәй бияләй чаклы гына бер әнчек чыгарды. Коңгырт-көрән төстәге йоп-йомры эт баласы юньләп йөри дә белми иде әле. Йонлач булса да, корсагы шәп-шәрә үзенең.

— Монысы тагын нәрсәгә? — диде Иргали, һаман да көлүеннән тыела алмыйча.

Аның каравы Динис көлмәде.

— Син, яшьти, көлмә әле, көлмә. Тормышың тагын да алга китсен әле, этнең нәрсәгә кирәклеген шунда белерсең. Синең шулай тамагың тук, өстең бөтен булуга күпләр сөенәдер дип уйлыйсыңдыр. Бар, көт, сөенерләр! Үзеңә әллә ни сиздермәгәч тә, бик күпләр тиреләреннән чыгардай булып күпсенә, ярсый торганнардыр әле. Көнчелек, кара хөсетлек һәрчак булды, әле дә бар, булачак та...

Аның каравы Гөлүсә чат ябышты көчеккә. Шундук кулына алды. Ә тегесе үзенең кыска, әмма юан аякларын алмаш-тилмәш китереп тыпырчына. Гөлүсә кулыннан ычкынмак була. Җан-фәрманга тыпырчыну да ярдәм итмәгәч, чынлап торып тешләшә, тырмаша ук башлады. Гөлүсәгә кызык.

— Эти!.. Эти дим... Күрче бу усалны! Әнә, ничек тырнаша... Тырнак та соң үзендә. У-у, тырнак батыр!..— Шул сәгатьтән алып, әлеге килбәтсез эт малаена, шушы исем ябышты да калды: — Тырнак!

Күп тә үтмәде, көчек малае күзгә күренеп диярлек үсте, матурайды, килешле гәүдәле, яшен ташыдай җитез, карап туймаслык эткә әверелде дә куйды. Шуның өстенә әле, адәм акыллары бар иде үзендә, сүз катырга теле генә юк иде. Таныган кешеләр: инглиз овчаркасы диделәр, әлеге нәсел этләрен мактап күкләргә чөйделәр.

Еллар бер-бер артлы уза торды. Хәзер инде Миңсылу да кызарып пешкән җиләктәй җиткән кыз. Гөлүсә дә үсте, дүртенче сыйныфка укырга йөри. Иргалигә торып-торып: «Һай-й, бу гомернең узулары!» — дип аһ орырга гына кала иде.

Тормыш итүләре исә торган саен катлаулана, четерекләнә барды. Эш муеннан ашкан: хуҗалык бик нык зурайды, мал-туар, кош-корт ишәйде. Дүртесе дүрт яктан ат кебек җигелеп ял белмичә тартсалар да, байтак кына эшләренә куллары җитми иде. Бу хәл үзен соңгы вакытларда аеруча нык сиздерә башлады. Умарталар үзләре генә дә аяк-кулны тоташ бәйли, гелән күз-колак булуны таләп итә торган мәшәкатьле, четерекле эш булып чыкты. Әле дә ярый күршеләр кул арасына кергәлиләр. Зәйтүнә каралты-кура тирәсендә, аш-су хәзерләгәндә ярдәм итсә, олы улы Гази җәйләрен атларны төнгелеккә йөртә, кышларын басуга тирес чыгарыша.

Иң яманы шунда: ярдәмче чакыру, хезмәтче яллау турында уйларга да ярамый. Әле дә инде аның мул тормышта яшәвен өнәп бетермәүчеләр бар. Бигрәк тә «авыл хәбәрчесе» үшән Халәп каныга. Аның җыен тузга язмаган уйдырмалар белән тулы бер «жалуы» аркасында, Иргалине Чаллыга да чакырып алдылар инде. Шунда аның үзенең байбәтчә дә, сыйнфый дошман — кулак та түгеллеген исбат итеп маташырга туры килде.

Иргали көне-төне бөтерелсә дә, ир-ат кулы җитмәве үзен барыбер бик нык сиздерә башлады. Бу хәл язларын кыр эшләре башлангач аеруча җанга тия иде. Җитмәсә тагын узган язда алар гаиләсенә зур гына бәхетсезлек килде...

Әлеге фаҗига басуда җиргә ашлама керткәндә булды. Иргалинең бу эшкә карата сыналган үз ысулы бар. Ул аны «җиргә әҗәт кайтару» дип атый. Бу ысул түбәндәгедән гыйбарәт: иң әүвәл терлек абзарыннан чыгарылган тирес, кош тизәге, көл Чаллыдан махсус алып кайткан

ашлама белән бик һәйбәтләп аралаштырыла. Бары тик шуннан соң гына басу башына илтеп тау-тау итеп өеп куела. Ә инде яз җиткәч, кыш буе парланып янып чыккан тиреснең бер генә сәнәге дә кояшта киптерелми, җилдә җилләтелми. Тау кадәрле итеп төялгән арба өстенә менеп баскан Гөлниса дүрт җәпле тимер сәнәге белән яңа гына Иргали ярып үткән буразнага таратып бара. Иргали икенче әйләнеш ясаганда, әлеге пар чыгып торган тирес җир белән томалатып үтелә. Шундук тубаларын киеп алып, эшкәртелгән җиргә икесе ике яктан чәчеп чыгалар һәм тимер тырма белән орлыкны күмдереп тә куялар.

Көннәрнең берендә, караңгы төшә башлаганда, Иргали артына борылып караса, ни күрсен, ат туктаган, ә Гөлниса, сәнәген бер читкә атып, тау кадәрле итеп өелгән тирес өстенә авып төшкән. Бөтен гәүдәсе бөтәрләнеп килгән хатыны, ике кулы белән эчен тотып: «Уф-ф, сиңа әйтәм, үләм!..» — дип, шыбыр тиргә батып, иреннәрен чәйнәп ята иде инде.

Иргали иң элек хатынын күтәреп алып ызанга чыгарды. Бил тирәләрен капшаштыргандай итте. Юк, җиңеллек килер төсле түгел иде. Хатынының чәчрәп каннар чыкканчы чәйнәлгән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып: «Зинһар, сиңа әйтәм... өйгә алып кайта күр. Шунда үлим»,— дип өзгәләнүен күргәч, Иргали, куәт кайдан килгәндер, иң әүвәл тиресне берьюлы аударды, аннары арбага торыпша җәеп, Гөлнисаны шунда күчерде. Сабанга җигелгән атларны җәһәт кенә туарып тышаулады да әле яңарак кына тибеп чыккан үләнле яр буена җибәрде. Бары тик шуннан соң гына атны җан-фәрман авылга таба куа башлады. Хатынының әрнү-ыңгырашулары, арбаның яман келтерәгән тавышына күмелеп, юк булды.

Ай-һай ла авырга килде ул яз! Миңсылуның: каячы, җизни, ярдәмгә үзем барыймчы — дип, атлыгып торуына да карамастан, җизни кеше ияртмәде балдызкаен, бары тик: «Кияүгә чыккач та җигелергә өлгерерсең әле»,— диде. Кыр эшләрен үзе генә түгәрәкләде Иргали. Ашламаны да гадәти ысул белән генә кертте.

Басудан кайткан көнне Иргали мунчага кереп чыкты да, ястыкмендәр түшәлгән тимер хут арбага Гөлнисаны сузып салып, Казанга дип чыгып китте. Әмма, Олег Авдеевич Клочкин да берничек ярдәм итә алмады. Сырхауны якын таныш коллегаларына күрсәтеп карады. Һәркайсы: безнең кулдан килә торган хәл түгел дип, җилкәләрен генә җыердылар. Шулай итеп Иргалигә, бу юлы Казаннан борчулы күңел белән кайтырга туры килде.

«Сүзем сүз, барыбер аякка бастырам мин аны, боерган булса...» — дип, дәвалауга имче Мәгыйшә карчык алынды. Пәри кияүләгән сихерчеләр чыккан булса да, Иргали каршы килмәде. Әйдә, Гөлниса шулай тели икән, дәваланып карасын, күңелендә төер калмасын дип уйлады. Мәгыйшә карчык алардан атналар буе чыкмыйча ятты. Берничә тапкыр мунчалар яктырды, сылады-сыйпады, әллә никадәрле үлән төнәтмәләре дә эчереп карады, әмма берни дә майтара алмады. Шулай итеп Гөлниса гомерлеккә билен тота алмас, сыңар кулы белән тезенә таянып кына хәрәкәтләнә торган зәхмәтле сырхау булып калды. Тормышның төп терәге, бөтен йортны үз кулында тоткан Гөлниса урын өстенә аугач, Иргали үзен аяк чалып егылган кеше сыман хис итте. Гөлниса сау-сәламәт чакта ирләр иңе сыгылырлык эшләрне дә ялт иттереп куйган вакытларны сагынып искә төшерә торган булды. Чыннан да, әлегә хәтле тормыш алып барулары уен гына булган икән ич.

Бу фаҗигане иң авыр кичергән кеше, әлбәттә, Гөлниса үзе иде. Аның кеше-кара күрмәгәндә кая булса да капланып, сыктап-сыктап елаган чаклары күп булды. Шулай ут йотып яшәгән көннәрнең берендә ир белән хатын арасында шактый ук җитди, шул ук вакытта бик тә сәер бер сөйләшү булып алды. Иргалинең йокыга китә алмыйча борсаланып ятуын сизенгән Гөлниса:

— Сиңа әйтәм... бер сүз җиткерергә ниятләнәм үзеңә...

Бу хәл ниндидер эчке бер борчу тоеп уянган Иргалине сагайта калды. Хатынының әйтәсе сүзен дәвам итмәвен хаерлегә юрамаса да:

— Я-ә, тыңлап карыйк,— диде.

— Иргали...— Тагын бермәлгә тынлык урнашты.— Күрәм... Бик авыр сиңа. Хезмәттән башың чыкмый... Үч иткән кебек, эшнең дә бик тыгыз чагы.— Гөлнисаның хәйлә-фәләнсез әйткән бу сүзләре, тавышының да, еларга җыенган кешенеке сыман, нечектер калтырап чыгуы кабат сагайтты Иргалине.

— Минем... ир икмәге ирекле, дигән сүзне ишеткәнем бар иде. Ни уңай белән әйтелә торган булгандыр ул сүз, әлегә кадәр төшенә алганым юк.— Гөлниса кабат тынып калды, тик озакка түгел.— Әйтергә теләгәнем шул, сиңа әйтәм... Бәлки берәр сау-сәламәт... яшьрәк хатынга өйләнерсең. Хәзер мин бит нәрсә... Хатын дисәң, хатын-кызлыгым да... Имгә калган — имгәкле димәсләр иде аны. Бер күз күеге генә бит мин хәзер... Иргали, мин риза-бәхил...— Бүтән сүз әйтә алмады Гөлниса, тамагы төбенә утырган күз яшьләрен йотып, ястык почмагын чытырдатып тешләде дә янә тынып калды.

Күңелендә аңлатуы читен моң-зар кузгату өчен җитә калды шушы сүз. Иргали урыныннан ук сикереп торды. Хәтта тузынып, әрле-бирле йөренеп тә килде. Үзе кызып-кызып сүгенә-тиргәнә иде.

— Дивана!..— диде ул, ятак янында туктап.— Башка сүзең юк идеме? Син нәрсә? Кемгә санныйсың син мине, ә? Өсте бөтенәк, тамагы икмәккә тую белән яшь хатын алырга — кем дип уйлыйсың син мине? Мае котырынудан сикергән байбәтчәгә санныйсыңмы әллә син мине? Әйттең сүз! Әгәр дә мәгәр арт биетеп, җил куып, берәр җирдә себерелеп йөргәндә шундый көнгә төшкән булсаң, бер хәл иде. Күрче, зинһар, нәрсә ди бит! Моннан ары ишетмим ыштубы мондый сүзләреңне. Гомумән, бу сөйләшүне безнең арада булмады дип сана. Бөтенләйгә оныт! Моңарчы ничек яшәгән булсак, моннан ары да шулай яшәрбез. Тыныч бул, әнисе...

Иргали калага китәргә җыенып яткан нәкъ шул көннәрдә арткы урамда яшәүче бер карчык килеп керде. Әйберләр төялгән чана янында кайнашкан өй хуҗасы башта аны танымады, берәр хаерчедер, дип уйлады. Карчыкның һәрбер хәрәкәтендә мескенлек чагыла иде. Ул телгә килгәч кенә бар да ачыкланды. Бу Иргали әнисе Мәүлиханың яшьлек еллары ахирәте Нәгыймә түти иде. Бик тә бетеренгән, бик тә бичара кыяфәттәге карчыкны танугач, өй хуҗасы уңайсызлана калды.

— Әйдүк, Нәгыймә түти... өйгә уз! — диде ул, эшеннән бүленеп.

— Кая инде, Иргали олан, өйләргә кереп торулар. Болай да бик тә оялып, бик тә зур гозер белән килүем иде.— Карчык әйтергәме, юкмы дигән кыяфәттә икеләнеп калды.— Зинһарлап сорыйм, кем, Иргали олан, моңарчы мин сине киң күңелле, кешелекле адәм итеп кенә беләм. Дөньялыкта тагын бер изгелек эшләсәңче. Кая барып бәрелергә белмәгәч, янә дә сиңа килдем...— Алланың рәхмәтләре явар иде үзеңә...

Сүз алыша торгач, әкренләп бар да аңлашылды. Көннәрнең берендә авыл яшьләре: йорт-җирсез избач булмый, дип ике-өч ат җигәләр дә элеккеге алпавыт Никитинский урманына китәләр. Ниятләре изге: биналы бүрәнә юнәтеп, бер ташландык өйне сипләп, избач Хаятка бер почмак әмәлләп бирү. Әллә ни юан булмаса да, шомдай төз ике-өч наратны аударырга да өлгерәләр. Шулчак каяндыр бер төркем атлылар килеп чыга. Барысы да коралланган. Кыяфәтләре яман. Башта: «Кем рөхсәте белән кисәбез?» — дип сорау алгандай итәләр, аннары: «Сез әзергә хәзермени әле, совет этләре!..» — дип, адәм карамаслык хәлгә китереп дөмбәсләләр боларны. Югары оч Исмәгыйль малаеның тимерле камчы белән сугудан күзе агып чыга. Әмма җәзаның иң яманы, иң рәхимсезе үксез-ятим үскән Рәхимҗанга эләккән. Атларыннан сикерешеп төшкән әлеге бандитлар, як-яктан эләктереп күтәреп алалар да моны, җан-фәрман чайкап, әле генә аударылган нарат төбенә арты белән

бәргәли дә башлыйлар. Үзләре бәрәләр, үзләре сөйләнәләр: «Урманны иң элек үстерәләр, аннары гына кисәләр...» Аңын югалткач та, җиргә салып, үңәче изелгәнче таптыйлар бичараны.

Бу бәладән бердәнбер исән-имин котылган кеше авыл комсомол ячейкасы башлыгы Кадыйр була. Барысыннан да яшьрәк булуына карамастан, өнлерәк булып чыга егет, атлыларны күрү белән, юньле кешеләр түгеллеген чамалап ала да, башта куаклар артына поса, аннан текә яр астына сикереп, су буйлатып кына авылга шыла.

Рәхимҗан исә бары тик икенче көнне генә зиһененә килә һәм, тәмам кешелектән чыгарылган гәүдәсен сөйрәп, көч-хәл урман авызына шуышып чыга...

— Үз телләрем белән әйттем мин аңа: иярмә шул Кадыйрга, язылма шул камсамул дигән нәмәстәгә, җүнлегә илтмәс, дидем. Юк, тыңламады. Әнә, ята хәзер өзелеп-тилмереп, күз көеге булып. Хәзер бөтенләй аяктан язды, саргайды, чырагачтай кипте. Хараплар гына иттеләр шул дөлдел кебек ир-егетне. Аяк-кулы тартышты, хәрәкәтләнү юк та юк инде. Өшкертеп-төкертеп тә карагандай иткән идем, юк. Үлән төнәтмәләренең дә шифасы тимәде. Үңәч зәхмәтенең бик тә яманы, бик тә катысы тигән ахры. Җанын өзгәннәрдер тәгаен...— Карчыкның тавышы тигезләнә төште.— Әүвәлдән килгән хәл бит инде: чабаталык курыс төшергән өчен дә кешенең аяк-кулларын сындырып кайтарырлар иде ул урманнан. Миңа калса, асып куябыз дисәләр дә, андый юлга бармас идем...— Нәгыймә түтинең тавышы янә үзгәрде, йөзенә ялвару чалымнары чыгарып дәвам итте.— Синең, кем, Иргали олан, кайда да сүзең үтә, калада бик зур таныш духтырың бар дип сөйлиләр. Хактыр ич ул сүз? Әллә, мин әйтәм, шуңа күрсәтеп карарга микән дим? Үлә-нитә калса, үкенече күңелдә төенләнеп калмас иде, ичмаса. Мескенемнең әрнеп-сызып, тилмереп күзләремә карап хәл өстендә ятуларын күрү бигрәкләр дә яман шул.

Әтисе Герман сугышында башын салган, әнисе егерме беренче ел афәтендә дөнья куйган бу ятим егет турында Иргали бары тик ишетеп кенә белә иде. Шулай да ул тәмам бетәшкән, коелып төшкән фәкыйрь карчыкның гозерен җиргә саласы итмәде.

— Ярар, Нәгыймә түти, кулдан килгән кадәр ярдәм итеп карармын. Булдыра алганны эшләмәскә хакым юк. Хәзер, кереп, чәйләп алам да, сәфәр чыгам. Бар, кайт та оныгыңны олы юлга хәстәрли башла...

Карчык, тиле бәрән орлыгы ашаган кеше сыман миңгерәүләнеп, бер урында әйләнгәләп торды да, кинәт кенә айнып киткәндәй, мең-мең рәхмәтләр әйтә-әйтә капкага таба юнәлде. Газаплы уйлар басkангамы, карчыкның ансыз да бәләкәй гәүдәсе, тагын да куырыла, сыгыла төшкән иде. Аның медер-медер үзалдына сөйләнгән соңгы сүзләре генә аермачык ишетелеп калды.

— Я-а, таңрем, я-а, аллам! Без ятимәләргә күрсәткән бу изгелекләрең өчен, бер урынына ун булсын, юл-сәфәрләрең гелән уң булсын...

Атларын Нәгыймә түтинең карга күмелгән өе турысында туктатып, сырхауны алып чыгарга дип кергән Иргалинең, сәке йөзлегенә аркылы яткан Рәхимҗанның үзен күргәч, йөрәге жу-у итеп китте. Шундук: юк, барыбер кеше була алмас бу дигән уй чагылып китте аның башында. Кырык ямаулы бишмәт, иске чабата киеп сәфәр чыгарга җыенган әлеге тере мәетнең чыкмаган җаны гына калган иде. Иргали, шундый да инәлеп, ялварып-өметләнеп үзенә таба төбәлгән, нур әсәре калмаган күз карашын күтәрә алмады. Йөзен Нәгыймә түти ягына бора төшеп, Рәхимҗанны чанага кадәр алып чыгарга ярдәм итү максаты белән, сәке янына атлады. Шунда сырхау телгә килде:

— Үзем... Үзем, Иргали абый.

Менә ул сәкедән тәгәрәп диярлек идәнгә төште. Биле сынган сыман, арт санын сөйрәп, ишеккә таба шуыша башлады. Аһ та ух итсә итте, әмма пар ат җигелгән чанага кадәр үзбаш чыкты.

Рәхимҗанның өсте бик юка, бу килеш олы юлга кузгалуны уйларга да ярамый иде. Иргали, ярым елаган тавыш белән:

— Хәерле сәгатьләрдә була күрсен берүк... Күрешү куанычы насыйп булсын иде...— дип өзлексез тәкрарлап арттан ияргән Нәгыймә түти белән саубуллашты да атларын өенә таба борды. Тагын бер толып табып, Рәхимҗанны шуңа төреп салганнан соң гына, атларын олы юлга әйдәде.

Казандагы йомышлар да Иргали уйлаганча ук җиңел генә үтәлмәде. Беренчедән, доктор Олег Авдеевичтан уңайсызланды. Чирләгән Гөлниса белән дә шактый ук мәшәкать тудырган иде инде ул. Хәтта ике-өч көн буена куна-төнә яшәп тә ятканнар иде. Бичарадан ничара дип, Рәхимҗанны да туп-туры Клочкин шифаханәсенә алып барды. Бәхетенә, Олег Авдеевич эш урынында иде. «О-о, Иргали! Нинди җилләр ташлады?..» — дип күтәреп каршы алды ул. Аның нинди йомыш белән килгәнлеген белгәч, авыруны шундук кабуллау бүлегенә керттерде. Берничә доктор җыелып, бик җентекләп карадылар, консилиум сыман нәрсә үткәрделәр. Ахыргы сүзне доктор Клочкин әйтте: егетнең өлешчә күкрәк читлеге, күкрәк авызы изелгән, шуның өстенә умыртка сөягенең аскы өлеше — койрык кимерчәге зарарланган. Шунлыктан авыруны аларда түгел, хирургия белән шөгыльләнүче бүтән больницага илтергә кирәк икән. Олег Авдеевич бу мәсьәләне шундук хәл итү чарасын да күрде: башта телефон аша кирәкле шифаханә белән элемтәгә кереп карады, кирәк кешесен туры китерә алмагач, тиз генә язу сызгалап, Иргалигә тоттырды.

Тел Төркестанга илтер диләр. Кирәк больницаны бик тиз тапты Иргали. Олег Авдеевичның язуы могҗизалы көчкә ия иде ахры — Рәхимҗанны шундук носилкага салып алып кереп тә киттеләр. Иргалинең үзенә соңрак, бүген булмаса иртәгәләргә килеп чыгарга куштылар.

Иргали иртәгесен, кайтып китәсе көнне генә килеп чыга алды әлеге шифаханәгә. Авылдашы яткан палатага алып керделәр. Иргали кергәндә Рәхимҗан тәрәзә буендагы караватларның берсендә, чип-чиста урын өстендә ята иде. Авыру аның кергәнен абайламыйчарак калды ахрысы, дөньялардан киткән сыман, күз карашларын түшәмгә төбәп, хәрәкәтсез калган. Ап-ак арык куллары, юка юрганы өстенә чыгарып салынганнар. Бу минутларда аның ниләр кичергәнен саргаеп-суырылып килгән йөзеннән үк чамаларга мөмкин иде.

Караваты янына килеп баскан Иргалине күргәч, әллә нәрсә булды Рәхимҗанга: күзләрендәге өметсезлек, бөген барлыгын биләп алган битарафлык, җилдә тузгыгандай, шундук юк булды. Ул хәтта сикереп торырга җыенгандай хәрәкәтләнеп алды, яңадан өмет һәм ышаныч галәмәтләре чагыла башлаган бөтен йөзе белән берьюлы елмайды.

— И-и, Иргали абый! Синмени бу?..— Чак кына тын алганнан соң, сүзен дәвам итәргә ашыкты: — Рәхмәт, Иргали абый! Рәхмәтнең чиксезе сиңа. Бу мәрхәмәтләреңә каршы изгелек белән җавап бирми калмам. Әйткән иде диярсең менә...

— Юк белән башыңны катырып ятма әле,— диде Иргали, елмаеп.— Әйдә, савык тизрәк. Шунда сөйләшербез.

— Операция ясарга уйлыйлар. Аякка бастырабыз дип вәгъдә итәләр. Шулай була калса, мин сезгә тормышым өчен бурычлы булачакмын.

Иргали Казанга моннан соң бары тик көннәр ызга авышкач, кояш шактый ук туры карый башлагач кына килә алды. Русларның пасха бәйрәменә туры китеребрәк. Алдан сөйләшенгәнчә, чанадагы тана, сарык итләре янына һәркайсы кимендә егермешәр-егерме бишәр кадак тартырлык утызга якын күркә түшкәләре дә төяп килгән иде Иргали. Һәркайсы, сыңар төк тә калдырмыйча эскәк белән йолыккандай чип-чиста, һәркайсы аерым ап-ак киндергә төрелгән, шалкан кебек тыгыз, өреп тутыргандай симез күркәләрне күргән Ксения Семеновна аһ итте, үзе үк та-

ныш-белешләренә, күрше-күләннәргә таратып та бетерде. Шуның өстенә әле, сатып алучыларның һәркайсы диярлек икеләтә диярлек бәһа биреп, чиксез рәхмәтләр әйтеп, күркә түшкәләрен Иргалинең кулына да йоктырмадылар.

Эшләре тәмам түгәрәкләнгәч, Иргали авылдашы яткан шифаханәгә юл тотты. Таный алмаслык булып үзгәргән, шактый ук төс керергә өлгергән Рәхимҗан аны койкасына утырып торган килеш каршылады. Иргали алып килгән күчтәнәчләрне күргәч, бала кебек шатланды. Тик менә авылдашының алып килгән хәбәрләре генә куанычлы түгел иде. Март ае башларында Нәгыймә карчык, түшәк хастасы булып кешефәләнне борчымыйча гына, дөнья куйды. Аны җирләп атна-ун көн үттеме икән, малай-шалайлар «ялган» йозакны ачып кереп, өйдә ут-күз белән шаяралар. Янгын чыга. Ул да әллә ни зыян-зәбер китерми, хәтта сулар сибеп сүндереп тә маташмыйлар, берничә ир-ат килеп, тавык кетәге кебек кенә куышны төртеп аударалар да кар белән күмеп куялар.

— Өйнең өй диярлек җире юк иде инде,— диде Рәхимҗан, бу яңалыклар турында ишеткәч.— Тик менә әби кызганыч. Җирләгәндә үземнең була алмавым үкендерә. Шунысы аяныч...

Иргалине иң куандырганы шул булды: күчтәнәчләр өчен кабат мең-мең рәхмәтләр әйткәннән соң, авылдашы аны сыңар култык таягына таянып, тышкы ишеккә кадәр озата чыкты. «Болайга киткәч, булган бу егетем!..»

Ә инде игеннәр буйга сикереп, сабан бодайлары «тупсагa» утырганда, арышлар баш кысып серкә очырганда, Рәхимҗан үз аяклары белән туган авылына кайтып төште. Егетнең танырлыгы юк. Клочкиннар аның да өс-башын бер кат юнәткәннәр, юлына акча да биргәннәр. Рәхимҗан туп-туры Иргали абыйларына кайтып керде.

— Иргали абый...— диде егет оялчан инсафлык белән.— Теләсәң нишләт, хәзер мин ни кушсаң, шуңа риза булып, күнеп яшәячәкмен... Мин бүгеннән синең карамакта. Әбине дә күмешкән икәнсең: кәфенлеген дә биргәнсең, сәдакасын да өләшкәнсең. Газиз җаным тәндә чагында бу изгелекләреңне онытасы кеше түгел мин.

Бернинди хәйлә-мәкерсез, саф күңелдән әйтелде бу сүзләр. Моның шулай икәнлеге егетнең кыяфәтеннән үк күренеп тора иде.

— Ярар, Рәхимҗан, уйлап карарбыз,— булды Иргалинең җавабы.— Хикмәт — савыгып, үз аягың белән кайтуда. Калганы хәл ителер. Хәзергә, әйдә, яшәп тор...

Имгәнгәннән соң шактый ук көйсезләнеп, холкы да ярыйсы гына кырысланып киткән Гөлниса гына иренең бу адымын хуплап бетермәде. Икәүдән-икәү генә калгач, яшереп-нитеп маташмады, үзенең ризасызлыгын белдерде. Иргалинең: хәзергә алгы якта яшәп торыр дигән сүзенә каршы берничә төрле дәлиле әзер иде инде. Иң әүвәл өйдә житкән кыз-Миңсылу барлыгын хәтергә төшерде. Аннары үзенең дә сау-сәламәт түгеллеген китереп кыстырды. Вакыты белән тәрәтен дә шул кече якта гына үтәвен өстәп куярга да онытмады. Әмма дәлилләренең кире каккысызлары алдарак булган икән. Ишетмәсәң ишет дигәндәй, тезә дә башлады. Заманаларның ифрат көйсез, хәвефле чагы, диде ул бик белдекле кыяфәт белән. Әнә анда нindидер колхоз дип гөр киләләр. Хезмәтче тота, батрак яллаган дип күзләреңне ачырмаулары бар бервакыт.

Сүз дә юк, ул якларын да исәпкә алсаң, хатыны хаклы иде. Шулай да Иргали аның тар күңеллегенә, бик үк катгый-кырыс рәвештә булмаса да, чик куясы итте. «Ярар, әнисе,— диде ул,— күз-баш алгалаганчы гына бездә яшәп торсын да, аннары, шәт, җае чыгар. Аның алгы якта куныуын теләмисең икән, синеңчә булсын, хәзергә әнә, печәнлектә йоклап торыр.»

Ул арада Рәхимҗан башы-аягы белән чат ябышып хезмәткә керешге. Эшкә бик тә җаптәш булып чыкты, кушканны көтеп тормастан һәр эшне ялт иттереп, җиренә җиткереп, коеп куяр иде.

Боерык сездән, йөгермәк бездән, дигән көндәм бер кыяфәттә, тиресеннән чыгардай булып, ут уйнатып эшләп йөргән Рәхимҗанны торабара хуҗабикә дә үз итә башлады. Күңеле йомшарган чакларда, җаен туры китереп:

— Кулыңнан куан, Рәхимҗан,— дия торган иде.

Рәхимҗанга моңарчы бары тик ишетеп кенә белгән эшләргә дә алынырга туры килгәләде. Бер күрше авыл остасы белән бакчада кое казып бура батыру нәкъ менә шундыйрак күз күрмәгән шөгыль иде. Теләге булган кешегә сабакны тормыш үзе бирә, диләр бит. Күп тә үтмәде, умарта белән җиләк-җимеш бакчасы да тулысынча Рәхимҗан кулына күчте. Каядыр баргалады, кемнәрдәндер сораштырды, хәтта кирәкле китап-кулланмалар да эзләп тапты. Бакчаның бер почмагында умарта өе шикелле бер нәрсә дә оештырып куйды. Көндәлек эшләрдән чак кына бушау белән шунда кайнаша: кәрәз рамнары ясый, умарта ояларын рәтли, кирәкле җайланмалар юнәтә. Күч аерылып чыга-нитә калса, юкә кабыгыннан ясалган олы тубалы да шунда гына. Умартачылык белән шулкадәр мавыгып китте ки, бал аерткыч аппаратларына кадәр алдыртты.

Кайчандыр Гөлниса әйткән сүзләр хакка чыкты, ниһаять, халык арасында: Иргали хезмәтче тота дигән сүз телгә керде. Билгеле, бөтенләй юктан бар булган хәбәр түгел иде бу. Моңа Рәхимҗан да чак кына гаепле иде ахрысы. Аны бер-ике тапкыр фәлән-төгән дип, комсомол җыелышына чакыра килделәр. Ул исә шактый ук дорфа рәвештә: «Мин хәзер эш кешесе, юкны бушка аударып йөрергә вакытым да, т... эгем дә юк»,— дип кенә җибәрде.

Әлеге эш әллә ни зурга китмичәрәк калды, нәкъ шул арада, «хезмәтче» дигән шыксыз сүзгә дә, ничектер, үзеннән-үзе чик куелды. Рәхимҗан белән Миңсылу арасында уйламаганда-көтмәгәндә якынлык туды. Яшьләрнең бер-берсенә тартылуларын беренче булып Иргали сизенде, ахрысы: я, тагын нишләрсез? — дигән сыман, мыек астыннан гына елмаеп йөрде. Яшьләр үзара шаярышып шук сүзләр әйтешәләр, шырык-шырык көлешәләр, хәтта үзара тәпәләшеп тә алалар. Эшләгәндә дә бер тирәдәрәк булырга тырышалар. Миңсылу болдыр баскычларын, сайгакларны чырагач белән кырып, гәрәбәдәй сап-сары итеп юган чакта Рәхимҗан да шунда: ялт иттереп, ишегалларын себерә, чүпләрен түгә. Бу эшләрне алар ничектер үзара ярышкандай, берсеннән-берсе уздырырга теләгәндәй башкаралар.

Калганы бик тиз, ничектер үзеннән-үзе эшләнде. Шул ук көзне тоттылар да, Гыйззәт хәзрәттән никах укытып, ике яшьне кавыштырдылар да куйдылар. Туй да бик күңелле узды. Гомергә бер килә торган йола ич, ничек инде аны әвеш-тәвеш китереп кенә уздырасың ди. Яшьләргә табын янында тазалык-саулык, тигез гомерләр теләделәр. Иргали, уенын-чынын бергә кушып: «Бирнәгә әнә абзардагы бер баш ат, бер сыер, өч-дүрт баш сарык сезнеке»,— дигән булды.

Туйдан соң ай да үтмәгәндер, Чаллыда яшәүче бер карт маякчыдан җыйнак кына әзер бура сатып алып, ишегалды түренә сыерчык оясы сыман гына йорт та салып куйдылар. Ишеге, сыңар тәрәзәсе ишегалдына, ике тәрәзәсе җиләк-җимеш бакчасына каратып салынган әлеге өй йорт-җиргә ямь өстәп җибәрде. Яшьләрне шулай итеп «башка чыгардылар».

Иң әһәмиятлесе, әлбәттә, бүтәндә иде. Кеше теленә «батрак» дип кергән җиде ят Рәхимҗан гаиләнең иң якын кешесенә — кияү баласына әверелде дә куйды. Аңа карап, сүз тиз генә басылмады, сүз күп булды. Берәүләр: «Тәки егетнең башына бәхет кошы кунды»,— дисәләр, комсомол вожагы Кадыйр: «Комсомол башы белән шул гөрәздән кенәз булган адәми затка ялчы булып ялланууын барыбер исенә төшерәчәкмен»,— дип әйткән, ди.

Кеше ни әйтмәс, тел сөяксез. Тик ничек кенә булмасын, Иргалинең дөньясы түгәрәкләнде дә куйды. Дөрес, аңа карап хуҗалыкта эш тә, мәшәкать тә кимемәде. Әйдә, була бирсен, үзе теләп алган мәшәкать бит. Боланның мөгезе авырлыгыннан кайчан зарланганы бар?! Иргалинең дә шулай — мәшәкате дә таудай, юанычы да.

## Өченче көн

### I

Бүген дә промыселчылар янында булдык. Аерма тик шунда: бүгенге әңгәмә-киңәшмәдә Кама каскадының иң эре ГЭСын салачак «Камгэсэнергострой» вәкилләре дә катнашачак иде. Уналты турбина-агрегатлы, Урта Идел белән индустриаль Уралны бергә тоташтырачак, Европа электр системасына ток бирәчәк әлеге гигант, һич тә көтелмәгән бик күп төрле мәсьәләләрне көн тәртибенә куйды. Чулман-дәрья суы проекттагы югарылыкка күтәрелгәнче, иң әүвәл елга ярларын ныгыту, уңдырышлы җирләрне саклау дамбалары өю белән бергә, республикабызны илгә, дөньяга танытkан нефть ятмалары мәйданы турында да кайгыртырга кирәк иде.

Моның өчен нефть ятмалары мәйданнары булган урыннарны кичекмәстән күтәртү, өелгән дамбаларны, дулкыннар юып җимермәсен өчен, тимер-бетон плитәләр белән тышлау бурычлары тора иде.

Нефтьчеләрнең бөтен өмете илле меңнән артык төзүче тупланган «Камгэсэнергострой» идарәсе коллективында. Дамбаларны шулар карамагындагы земснарядлар өячәк, плитәләрне дә идарәнең тимер-бетон әйберләр заводы коячак икән. Шундый карар кабул ителгән. «Икенче Баку» төбәге илебезнең төп нефть чыганагына әверелгән бер заманда башкача булуы да мөмкин түгел.

Көндезге сәгать нәкъ икедә мин редакция белән элемтәгә кереп, беренче тапкыр телефон аша хәбәрләр тапшырырга тиеш идем. Шунлыктан мин, тавыш-тынсыз гына җыелыш-киңәшмәдән чыгып китеп, комиссия әгъзаларын йөртүче машиналарның берсен алдым да Чаллыга таба юл тоттым.

Бүген иртәрәк кайтуымның тагын бер бик әһәмиятле ягы бар: бәлки әле өендә авырып яткан яшьлек дустым Гази янына да барып кайта алырмын дип уйлаган идем мин. Әмма әлеге ниятем, торган саен, икеләнү хисе белән алышына барды. Чыннан да, кеше үз-үзен күрергә теләмәгән бер вакытта аны өенә барып бимазалау җанын кыйнап йөрү генә булмасмы икән?

Мондый уйлар тууы да бөтенләй сәбәпсез түгел иде. Газиның, баш врач белән бәрелешкәннән соң, зиһенен җыя алмыйча торуы, ифрат та авыр халәттә исерек кеше кебек, әкрен-салмак атлап китүе әле дә булса күз алдымнан китми, һаман да мине эзәрлекли сыман иде.

Утларда янып, суларда батып, тау кадәрле авыр газаплардан тинтерәп, янә бер төн узды. Бик авырлык белән узды. Очы-кырые юктыр сыман булып тоелган төннең кайсыдыр өлешендә, үч иткән кебек, тулы ай калкып, яктысы Газиның баш очына төште. Начар да, ниндидер табигый булмаган сәер дә яктылык иде бу — мие кайнап чыга икән дип тора. Аҗаган балкышына караганда да яманрак тәэсир итте әлеге могҗизалы яктылык. Аҗаган, калтырап-уйнаклап, офыктагы төн пәрдәсен ертkалап, күк йөзен телгәләп, бар дөньяны бер итеп ялтыратып алганнан соң, тирә-юнь шундук дөм караңгылыкта кала. Аның ялт-йолт килеп канат кагуыннан күңел түренә ниндидер салкын шомлык иңгәндәй була.

Гази, җан әрнеткеч сызланулардан җәфа чигә-чигә, ярым онытылып, шактый бәргәләнеп-суккаланган булса кирәк, урын өстендәге җәймәсе тирләүдән юешләнеп кенә калмаган, аркан сыман бөтерелеп беткән иде.

Гази, ниндидер юаныч эзләгәндәй, янә дә уйлар тавы, хәтер чоңгылларын актарырга кереште. Күрче зинһар, бик теләгәндә, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, уйлый калсаң, аның да күңеленә дәва, җанына азык булырлык, гомер-бакый онытa алмаслык илаһи истәлекләре бар икән ич. Хыял канатлары аны инде менә ничәмә-ничә еллар тоташтан һаман да бер юнәлешкә — Гөлүсәгә таба йөгертәләр иде.

Гөлүсә! Күрче, колагыңны салыбрак тыңлачы, исеме генә дә җырларга кушып җырларлык бит. Татлы да, берүк вакытта үкенечле дә хатирәләргә чумды Гази. Әлеге уйлар, бердән ялгызлыктан котылып торырга ярдәм итсә, икенчедән әрнү-сызлануларны чак кына оныттырып торалар сыман иде. Я-а, гомер дигәннәрең! Балачак — баллы чак, аннары үсмер еллары, яшьлеге, иксез-чиксез күк йөзеннән аккан һәм һичкайчан да кире борылып кайтмас болытлар кебек, китәләр дә югалалар икән.

Уйлый калсаң, ачлы-туклы, ярым-ялангач узган балачак хатирәләре арасында да мәңге җуелмастайлары бар. Әле дә булса хәтерендә, Иргали абыйларының ниндидер могҗиза белән баеп китеп, яңа өйләренә күченеп чыккан еллары иде бугай. Ике ут күршеләрне кош та очып уталмаслык биек койма аерса да, Гази белән нәни Гөлүсә арасына күләгә яткыза алмады. Һәрхәлдә, җәяүле атлыга юлдаш түгел дигән мәкаль аларга һич кенә дә кагылмый иде.

Нәкъ менә шул вакыт Гази бик тә хикмәтле, бик тә кыйммәтле сүз ишеткән иде. Баштарак ул бу сүзгә әллә ни игътибар да итмәде кебек, әмма тора-бара әлеге сүзләрнең асылы, чын мәгънәсе, бәһасе бинihая зурая барган сыман тоелды.

Кояш туры карап, табигатьнең күңеле йомшарып, миһербанлана башлаган бер чоры иде. Түбәләрдән көнозын тып та тып тамчылар тамды, баскыч төпләрендә, ишегалларында күзләрне чагылдырып, күлдәвекләр хасил булды. Гази да, Таҗи белән Һади да рәхәткә тиенделәр, яланаяклап кына ишегалларын әйләнеп керәләр, көн тагын да җылыта төшсә, урамга ук чыгып йөгергәлиләр. Хәер, бер алар гына түгел, бөтен авыл малай-шалайлары шулай итә.

Шул вакыт ишектә, өстенә плюш жакетын гына киеп алган сылу Миңсылу күренде.

— Исән-сау гына яшисезме, Зәйтүнә тәтә!

Хуҗабикә бу көтелмәгән хәлдән бераз гына каушап, берүк вакытта чак кына сәерсенеп тә калды.

— Без исән, ходайга шөкер! Үзегездә бер-бер хәл булмагандыр бит?..

— Гөлүсә авырып китте ич әле, Зәйтүнә тәтә.

— Ай-й, ходаем! Нәрсәләр булды икән балага?

— Салкын тигән булса кирәк. Беркөн әнә сезнең ташбашларыгыздан күрмәкче, ул да ишегалдына яланаяк чыккан.

— Ай-й, ходаем ла! Хараплар икән. Әйтәм аны берничә көн инде күренгәне юк...

Миңсылу шундук йомышын да чыгарып салтәде. Уттай янып яткан Гөлүсә чак кына аңына килгән һәм хәзер үк Газины күрергә теләгән икән.

— Хәзер, хәзер керер, күрше. Менә, тиле, ник кермәсен ди, бик рәхәтләнеп керер...

Газига нәрсә, киенеп-нитеп торасы юк, кипкән утын агачы белән сабына тикле тимердән ясалган авыр пычагын мич алдына тотып атты да чыгып та йөгерде. Миңсылу да, эче катып көлә-көлә: «Тукта, шайтан малай!» — дип, аның артыннан чыгып чапты.

Гази ишектә күренү белән Гөлүсә, ятагыннан яртылаш күтәрелеп, аны кулларын сузып каршы алды. Ул арада караватъ янына урындык

китереп куйдылар, әмма җан дустын күрү бәхетеннән дөньяларын онытыр дәрәҗәгә җиткән Гөлүсә Газины үз янына утыртты. Алай гына да түгел, дусы чыгып китә күрмәсен дигәндәй, чытырдатып җиңенә үк ябышты. Ә күзләре, күзләре нәкъ ике бөртек фирүзә ташы диярсең инде менә. Гөлүсә шундук үзенең үпкәсен дә белдерә башлады.

— Гази! Ник моңарчы кермәдең?

— Авырганыңны белмәдем бит, Гөлүсә.

— Ә ник белмәдең?..

Җавап табып кара син шундый сорауларга.

Ул арада кызның әнисе — Гөлниса апасы да сүзгә кереште.

— Менә Гөлүсәбез авырып китте бит әле...

Мич буендагы эскәмиядә чуклы йөгәнен җиз төймәләр белән бизәп утырган Иргали абыеның да сүзе булган икән.

— Барысы да сез ташбашлар аркасында. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, сездән күреп, ул да тышка яланаяк чыккан... И-и, малай актыгы!

Юк, ачуланып әйтмәде ул бу сүзләрне. Аның каравы Гөлүсәгә әллә нәрсә булды. Ул кабат ачыргаланып: «Ник кермәдең? Мин көттем сине... гел көттем!..» — дип иң әүвәл өстендәге сырган юрганын аяк очына тибәреп атты, аннары чырылдап елап, бәргәләнә-суккалана башлады. Тәмам каушап-югалып калган ата-ана Гөлүсә янына ташланды. Тәмам ярсыган бала, алар кулыннан ычкынып, ике куллап Газига ябышып һәм аны, янына ук тартып китереп, кочагына алгач кына тынычланган сыман булды. Анда да әле һаман берүк сүзләрне тәкърарлады:

— Хәзер керерсеңме инде, Гази? Көн дә кер, ямме... Югыйсә мин сине сагынып беттем. Син дә сагындыңмы?

— Бик сагындым...

Тәмам тынычланып, йөзенә сәламәтлек алсулыгы кергән Гөлүсә, ниһаять, күз яшьләре аша елмайды. Һәм алар, бер-берсен уздырырга теләгәндәй, кемнең ныграк сагынуы турында сүз көрәштерә башладылар.

— Әгәр дә бик беләсең килсә, мин сине инде әллә ничә тапкыр төшләремдә күрдем,— диде Гөлүсә, күзләрен сөртештереп.

— Мин дә гелән сине уйладым.

— Төшемдә син мине күтәреп, су аша да алып чыктың әле...

Гази Иргали абыеның: «Малай актыгы!» дигән сүзләреннән соң, Гөлүсәнең урын өстендә ятуында чыннан да гаебе бардыр сыман хис итте. Һәм ул, акланырга теләгәндәй, Гөлүсәнең озын ап-ак күлмәге эченнән күренеп торган шәрә тәпиләрен кушучына алып, сулышы белән өреп җылытырга теләгәндәй хәрәкәтләр ясап, сөйләнгәләде.

— Сиңа, Гөлүсә, һич кенә дә яланаяк йөрергә ярамый. Ишетсен колагың. Синең бу тәпиләрең туңар... Күр син аларны: нинди ап-аклар, нәфисләр. Ә безнеке... Әнә күр!

Гази сыңар аягын күтәреп үк күрсәтте. Тузудан чуклана башлаган ыштан балагы эченнән чыгып торган тәпие чебиләп тәмам каешланып каткан иде.

— Безнең аяклар суыкны бар дип тә белми. Кар өстеннән йөгергәндә табаннардан ут чәчри, бик беләсең килсә...

Яңа гына балалыктан чыгып килә торган кыз белән яшүсмернең үзара мөнәсәбәтләре сәер дә, сокландыргыч та иде. Гази белән Гөлүсәнең, җан атып, бер-берсенә омтылуларын күреп торган ана әйтә куйды:

— Бу балаларны ходай бер-берсе өчен яраткандыр ахры, сиңа әйтәм.

Ата кешенең талканы коры, күзенең агы белән генә карап, хатынының авызын бик тиз томалады.

— Телеңә күбрәк салынып тор әле!..

Ләкин бу юлы да тиргәү булып яңгырамады аның бу сүзләре.

Вакыт үтә торды. Чак кына үсә-исәя төшкәч, Гази Иргали абыеның кул арасына керә башлады. Иң беренче эше — төн кунып, ат сакларга бару булды. Ә алар һәр җәйне ике яки өч баш була. Хәер, бу куна ба-

руны эш димәсәң хәтере калыр. Уйлый калсаң, үзе бер куаныч, үзе бер бәйрәм. Учак тирәсенә түшәлгән печән өстенә кырын ятасың да, и-и китә, мин сиңа әйтим, әкият сөйләү, адәм әйтеп, адәм ышанмаслык хикмәтләр турында гәп сату. Табигатьнең гүзәллегенә хозурланып, күк тулы йолдызларны күзәтеп ятулар турында әйткән дә юк. Көлгә күмеп пешерелгән бәрәңгенең тел йотардай тәмлелеген кем генә белми икән! Аннары башлана уеннар, төрлечә шаярулар. Йокыга китә-нитә калсаң, бетте, көлкегә калачагыңны бел дә тор. Көйрәгән мамык иснәтеп кенә калмаячаклар, шаяруның шактый ук усалын да уйлап табалар. «Мандалина уйнату» белән «Самакатта йөртү» нәкъ менә шундыйлардан санала. Моның өчен йокыга киткән малай-шалайның кул яки аяк бармаклары арасына кәгазь кисәге кыстыралар да, ут төртәләр... Элегрәк байбәтчәләр, мулла-мунтагай азгыннары ярлы-ябагай балалары белән тагын да мәрхәмәтсезрәк кылана торган булганнар: аякларыннан арканга бәйләп, ат белән сөйрәткәннәр.

Баштарак Газига да «мандалина уйнарга» да, «Самакатта йөрергә» дә туры килде. Шуның өстенә әле аны: «Әй-й, кияү егете, ярәшкән кәләшең бар диләр, кайчан өйләнергә исәбең?» — дип тә ирештергәлиләр иде. Әмма Газиның моңа әллә ни исе китмәде, башкалар кебек әтәчләнмәде, күтәрелеп бәрелмәде, үртәлеп, кеше өстенә дә ташланмады. Житмәсә тагын, ялланып, биш-алты хуҗалыкның атларын көтүче Шәяхмәт карт та: «Бер дә исең китмәсен, Газиулла улым, әйт үзләренә: һәркемгә дә тәти торган бәхет түгел ул диген».— дип бик телләнгәннәрнең авызын тиз томалады.

Көтүгә куна баруларның тагын бер ягы бар: тамак үтүе иде. Газига дип, алдан ук хәстәрен күреп хәзерләп куелган киндер букчада, һәрчак каймактан куе бер шешә сөт, бодай күмәче кыерчыгы, янында тагын берәр кабартма, берничә коймак, яисә бәлеш катылары булыр иде. Гази атларны алырга кerә-керешли үк, Иргали абыйларының ишегалдында табада кыздырылган сызык исе тоя торган иде. Димәк, ул тагын берәр төрле таба ашыннан авыз итәчәк...

Гомумән, Гази үзенең тормышыннан бик тә, бик тә канәгать иде. Ике атны тезгеннәреннән як-якка бәйләп, уртадагы озын торыклы җирән кашкага атланып, бик егетләрчә, бик эре кыяфәттә чыгып китүләре, шул тирәдә кайнашкан Гөлүсәнең кул болгап озатып калулары гына да берни белән чагыштыргысыз, гомер онытылмаслык, искә генә төшкәндә дә тоташ караңгылык баскан күңел күген сихри бер яктылык белән бизи торган күренешләр иде.

Әле тагын Иргали абыеның аңа бик тә разый булганлыгын өстәсәң, бар да аңлашылыр кебек. Хәер, төнге томаннарда коенып, таң җилләрендә ялларын таратып кайткан көр малларын күреп, кем генә канәгать булмас иде икән!

Тагын бер вакыйга хәтеренә бик нык уелып калган Газиның. Мәктәпкә төшәр елы иде. Иртәгә сабакка барасы диган көнне Иргали абые аны таш кибетенә чакырып кертте. Башта зурларча кул биреп исәнләште, хәл-әхвәл сорашты. Берәр йомышы төшкәндер дип уйлады Гази. Ялгышмаган икән. «Менә шушы әйберләрне киеп кара әле, Гази».— диде Иргали абые. Иң әүвәл акка буй-буй зәңгәр сызык төшкән өр-яңа күлмәк тоттырды. Аннары карадан нәкъ калача итеп тегелгән чалбар сузды. Аннары төймәләре елкылдап торган костюм кияргә ярдәм итте. «Монысын да киеп кара әле».— дип, катыргы тартмадан яхшы күн исе аңкып торган өр-яңа ботинка чыгарды. Очларына җиз тимер куелган шнурларына кадәр үзендә. Иң соңыннан, киемнәр киелеп беткәч, Газиның башына кара бәрхет кәләпүш чәпәп куйды Иргали абые.

— Кара әле, Гази, бу киемнәрнә кигәч, ярыйсы гына егеткә охшап киттең бит, әй,— дип, мыегы астыннан гына көлеп тә җибәргән иде әле Иргали абые.

Гази, аны-моны абайламыйча, шушының белән эш тә беткәндер инде дип уйлап чишенә дә башлаган иде. Әмма Иргали абые аны бу

эшеннән булде: чишенеп мәшәкатьләнмә инде,— дип, кием-салымнарның аның өчен атап Казаннан алып кайтканлыгы турында әйтте.

Иргали абыйсы аны озата чыкты. Шунда, койма буендагы бүрәнәләр өстендә гәп сатып утырган абзый кешеләргә тап булдылар. Тегеләргә теш агартырга сәбәп кенә булсын, китте сүз, китте фикер алышу.

— Бәс, Газиулланы әйтәм әле, тач кияү егете булган...

— Әйтерең бармы!

— Тәки күз өстендәге каш иттең бит малайны, Иргали күрше.

Иргали абые да җавап эзләп баш вата торганнардан түгел.

— Малай шәп бит: үзе эшчән, үзе акыллы, үзе тыйнак.

— Анысы хак, малай чыннан да шәп! Ләкин бит алар өчәү. Нигә соң син аның монысын гына якын итәсең?

— Монысы аның чат этисе, якын дустым Хаҗи абыйга тартым. Холкы-фигыле белән дә. Ә тегеләре югала торганнардан түгел, бигрәк тә уртанчысы — Таҗие. Бик шома күренә. Менә әйткән иде диярсез, бик ерак китәчәк анысы. Ә кечесе, нәкъ керпе, кадалырга гына тора.

Улын баштанаяк өр-яңа затлы киемнәрдән күреп, иң куанган кеше, әлбәттә, Газиның әнисе булгандыр. Иргали күршесенә рәхмәтләрен белдергәндә, аның хәтта тавышы чатнады, еларга җыенган кешенеке сыман калтырап чыкты. Куануларының һич тә чиге-чамасы юк иде.

— Ятимне куандырган өчен, ходай тәгалә үзеңә тагын да зуррак табышлар, көтелмәгән яклардан дәүләт һәм бәрәкәтләр иңдерсен...

— Ярар, игелеген күреп, җылы өстендә тузсын,— диде Иргали абыйсы.

Ул елны Гази бөтен авыл балаларының күзен яндырып, сабакка тузан да кунмаган өр-яңа киемнәр киеп барды.

Бер-ике елдан Гөлүсә дә укырга керде. Ул вакытта инде аларның үзара мөнәсәбәтләре дә чак кына үзгәрде, сәерләнә төшкән сыман булды. Аларның сабакка бергә барып,бергә кайтуларын күргәндә: «Кияү белән кәләш» кебек сүзләрне, кайчандыр бер дә исләре китмәгән үртәшүләрне, шактый ук авыр кичерә башладылар. Ул елларда инде Гази да Иргали абыеның чын мәгънәсендә ярдәмчесенә әверелгән иде. Атлар белән куна баруны энеләренә калдырып, үзе җир тырмалады, игеннәр өлгергәч, ат менеп ургыч тарттырды, ындыр табагына көлтә кертеште. Көз җитте исә, укудан бушаган вакытларында туңга сөрүгә дә чыккалады.

...Гази урын өстендә ята. Әрнү-сызланулар авыру йөрәген кайтакилә талкый. Әле дә ярый кешенең балачагы, яшүсмер чагы булган, югыйсә нишләр иде икән? Гази да хыялында шулай үткәннәргә китеп адаша да миңгерәйгән бер хәлдә, чарасызлыктан гаҗиз булып, бүгенгесенә кире кайта алмыйча тинтерәп тик ята.

Менә хәзер дә аны хыял канатлары хәтердән мәңге эзе җуелмас, гомере буена үзенең бөтен гүзәллеге белән күз алдында җанланудан туктамас Гөлүсәсе янына очырып алып китте. Кайбер күренешләрне күз алдына китергәндә генә дә Газиның йөрәге җилкенер, күңел күге пакьланып калган сыман булыр иде.

Көннәрнең берендә ындыр табагы ягыннан кайтып килә иде, авыл кырыеннан, бакчалар артыннан агып уза торган Агыйнеш елгасы ягыннан бала-чагалар, кыз-кыркыннарның чыр-чу килеп су кергән тавышлары ишетелде. Бала-чага тавышы арасында Гөлүсәнекен дә аермачык ишетеп калды. Гази туктарга мәҗбүр булды. Берьюлы берничә төрле уй туды аның башында: иң яманы — тирән урынга кереп бата-нитә күрмәсә ярар иде.

Гази качып-посып әрәмәлеккә керде. Күрде, чыр-чу килеп коенучылар бик бәләкәйләр икән, Гөлүсә исә өч-дүрт дус кызы белән яр кырыенда, хәтфә үлән өстендә утыра.

Шулчак алар төркеме дә, нindидер карарга килгән сыман, җанланып алды. Кеше-фәлән күренмиме дигәндәй як-якларына каранып

алдылар да су читенә йөгерешеп килделәр. Калганы бик тиз булды. Иң беренче булып Гөлүсә чишенде. Күз дә иярмичә калды, әйтерсең лә күлмәгеннән чыгып кына төште. Читтән, Гөлүсәнең яшүсмер малайларныкына охшаган чандыр гәүдәсен күргәч, Гази үзеннән-үзе оялып, карашын читкә, каршы як яр буйларын каплаган куе таллыклар ягына борырга мәҗбүр булды. Йомшак җилдә лепердәп уйнаклаган тал яфраклары аша баю ягына авышкан кояш чагылып китте. Ул, нәкъ җәтмәгә кереп чуалган алтын-җиз тәңкәле сазан балыгы кебек, ничекгер калтыранган-тыпырчынган сыман булып күренә иде.

Ул арада Гөлүсә, нәрсәгәдер чиксез шатланган сыман авазлар чыгарып кычкырып җибәрде дә, сыек гәүдәсе белән бөгелә-сыгыла, кулларын яман селтәп-чайкап, тезләрен кирәгеннән артык күтәреп, сайлыкка йөгереп керде. Тирә-якка мул булып су чәчрәде. Ул да булмады, кинәт урталай ярылган су Гөлүсәнең сихри гәүдәсен үзенең кочагына алды. Як-якка бәргәләнгән толымнары гына чагылып калды...

Нәкъ шул мизгелдә Гөлүсәнең башы өстендә вак-вак кисәкләргә өзгәләнгән салават күпере хасил булды.

Менә ул, малайларныкы сыман арык beләкләрен алга ташлап, колач салып, яр буендагы җикән камышларны, су үләннәрен, сирәк-мирәк чәчелеп яткан төнбоек яфракларын чайкалдырып, йөзеп китте.

Ул арада башка кызлар да суга сикерештеләр. Тирә-юнь янә чыр-чу, шау-шу белән тулды, як-якка дулкыннар йөгереште, башларын су өстенә салган талларга, су үләннәренә, аш тәлинкәсе кадәрле яссы төнбоек яфракларына кинәт җан керде... Гөлүсә рәхәтлектән ләззәтләнеп кычкыра-кычкыра йөзде дә йөзде, юри шаярып, дус кызларына сулар чәчрәтте. Ниһаять, сайлыкка чыкты, аягүрә басты. Тик озакка түгел, янә шаярып шапылдап суга ауды. Янә йөзгәнсыман итеп кыланды. Агым аның нәни толымнарын бер якка кага, каера... Менә ул яңадан аягүрә басты. Бер урында зырылдап әйләнгәндәй итте. Зәңгәр күккә карап, мине үзеңә ал дигән сыман кулларын өскә таба сузып көлде, елмайды, күзләрен кысты. Кемгә елмая ул? Үз-үзенәме? Әллә бөтен галәмгәме?..

Гази, инде китим дип, бер-ике тапкыр талпынган да иде. Әмма ниндидер көч аны яңадан тоткарлады. Китә-нитә калса, һичшиксез, бер-бер көтелмәгән бәхетсезлек чыгар, кичекмәстән аның ярдәме кирәк булыр сыман иде.

Еллар үтте. Әмма Гөлүсәнең салават күпере эчендә нурланып су коенуларын, аның яшүсмерләрнеке сыман җитлекмәгән чандыр гәүдәсен, кояш нурлары белән чуарланган йөзен, балкып елмаюларын соңгы сулышына кадәр онытасы юк.

Шуннан соң, ничәмәдер ел узгач, нәкъ шуңа охшашлы тагын бер вакыйга булачак, тик ул вакытта Гөлүсә хур кызыдай гүзәлгә, Гази да буй җиткезгән ир-егеткә әйләнәчәк.

## 2

Малай-шалай чактан ук, авылда яшәгән заманнан бирле, «Авыл Советы» дигән сүзгә карата күңелем түрендә, ниндидер, тел белән аңлатып булмаслык тирән ихтирам хисе сакланып калган. Гаҗәп тә түгел, чөнки ул дәверләрдә яңа властьне тәшкил иткән бердәнбер идарә аппараты — авыл Советларының хокуклары да, мөмкинлекләре дә чикләнмәгән, шунлыктан киң катлам халык арасында аның абруе да ифрат зур, аңа һәркем — олысы да, кечесе дә зур өметләр баглап, үзенең бөтен киләчәген бәйләп карый иде. Андый-мондый каршылыклар туса, үзара аңлашылмаучылыклар килеп чыга-нитә калса: «Менәтерәк, авыл Советына барып җәвит итәм әле, аннары белерсең» яисә «Фәлән-фәләнгә авыл Советыннан кәгазь бар», «Фәлән-фәләнне авыл Советына чакырткannар, и-и ходаем, ниләргә генә икән инде»,— дип, ярым пошаманга төшеп, шактый ук шик-шөбһә белән әйтелгән сүзләрне дә ишетергә туры килә иде.

Ачлык-хәерчелектән иза чиккән, үзен борчыган мең төрле сорауларга җавап эзләп, тәмам башы каткан крестьян кая барсын ди, янә авыл Советы бусагасын таптарга мәҗбүр. Дөрес, Совет власте, нужада интеккән халыкның хәлен кулыннан килгәнчә җиңеләйтү өчен, күп төрле чаралар күрде: авылларда ярлылар комитетлары, төрле ярдәмләшү оешмалары төзелде, ячейкалар барлыкка килде. Алар ярлы хуҗалыкларга, батракларга бүлеп бирелгән җирләрен эшкәртергә аеруча булышты. Чәчү орлыклары юнәтеште, налоглардан азат итте, мал-туар алу өчен әҗәткә акча бирде.

Ул вакытта инде без дә яшүсмерләр рәтенә кереп килә идек, авыл Советында үтә торган өлкәннәр телендә «моназара кичләре» дип йөртелгән әлеге җыеннарга сирәк-мирәк кенә булса да эләгү ягын карый идек. Чөнки ул кичәләр вакыт-вакыт тамаша төсен ала торганнар иде.

Иң кызыгы, әлбәттә, «авыл хәбәрчесе» дип аты чыккан Үшән Халәп белән Иргали абыйның сүз көрәштерүе булыр иде. Әлеге бәхәс һәрчакта да Иргали абыйның җиңүе белән тәмамланыр иде. И-и, гарьләнер иде Халәп агай, ачу-ярсуыннан кара көеп чыгар иде, бермәлгә әйтер сүзен әйтә алмый торыр иде.

Җиңелгән йодрык төйнәр дигәндәй, аягүрә торып баскан Халәп агай, бөтен дөнья белән көрәшергә җыенгандай, йодрыгы белән өстәл кырыен төя-төя, сүзләрен кысылган тешләре арасыннан сыгып чыгарып, Иргали абыйга яман да хәтәр янар иде.

— Ну-у, мал-лай!.. Ут белән уйныйсың, матри аны! Тыел лутче! Бу сүзләрең бик кыйммәткә төшәчәк сиңа. Артык остарып киттең. Сүзем сүз — телең муеныңны кистерәчәк.. Үзеңне ник тудым көненә төшермәсәмме? Исемем дә, әниемнең күкрәк сөте дә харам булсын. Ну-у, матри аны!

Шулай ярсып-янап өркетер иде дә, каядыр соңга калудан курыккандай, җәһәт-житез атлап чыгып китәр иде. Ямаулы сырган бишмәтенең итәкләре генә чагылып калыр иде. Ишекне шундый итеп ябар иде, керосины бетә башлаган асылмалы лампаның ялкыны куыгыннан атылып чыга язып калыр иде.

Халәпнең күңелгә шом коярлык итеп, куркытып-өркетеп әйткән сүзләре үзенекен итәр, халык бермәлгә тынып калыр иде.

Кайсыдыр кыюсыз гына:

— Артык катырак бәрелдең ахрысы,— дип куя.

Икенчесе дә: «Әйе шул»,— дип, әлеге фикергә кушыла.

— Тагын шул кадәресе дә бар,— дип элеп ала иде өченчесе,— аңа тел-теш тидереп, Иргали күрше, чыннан да ник дәштем көненә калуың бар. Язу-сызуны белә...

— Әйтмә дә! Тинтәкнең аның таягы кырык ди, берсе тимәсә, берсе тиеп куюы бар...

— Эт күзе төтен белмәс...

— Чыннан да, бәласеннән башаяк. Әткә бәйләнсәң, итәксез калырсың диләр.

Соңгы сүзне, әлеге дә баягы, Шәвәли карт әйтер иде:

— Ничава! Үгезенә күрә чыбыркысы дигәндәй, кешесенә күрә таман гына!

## 3

Ә бит, уйлый калсаң, Газиның да хәтер күгендә күп төрле фаҗигалар, кайгы-хәсрәтләр, тагын әллә ниткән афәтләр белән бергә, гомерлек бәхетләргә биргесез, берни белән дә чагыштыргысыз көннәре булган икән ләбаса. Булмыймы соң! Үткәннең төннәре дә якты димәсләр иде аны.

Гази үзенең шундый күңеленә дәва, җанына азык булырлык, атнасын елына алыштыргысыз вакыты итеп 1934 елның җәен саный. Ул җәйнең печән өсте яшьлегенең һичкайчан да кабатланмас бер мог-

җизасы булып һаман да хәтерендә, күңел түрендә саклана. Гази еш кына: чыннан да булды микәнни шундый бәхетле чаклар? — дип уйлап, аһ орып куйгалый.

Үзенең күгелҗем-яшькелт дулкыннарын биетә-биетә нурланып, әллә нинди сихри төсләр белән төрләнеп, талгын гына агып яткан Идел-Чулман буйларында печән чапкан вакытлар исләргә төшкәндә генә дә, Газиның күңел түрендә аллы-гөлле салават күперләре кабынып, хәтер чоңгылларын айкап-актарып, берсеннән-берсе матур истәлекләр кузгала, мең төрле кадерле мизгелләр баш калкыта.

Ул вакытта кем бәхетлерәк булды икән: Газимы, Гөлүсәме? Чөнки нәкъ шул көннәрдә шактый гомер ык-мык килеп, күршеләр, гадәттә, бик сирәк туганлашалар диеп, кырлы-мырлы сөйләнгән Иргали, ниһаять: «Әйдә, хәерле булсын. Хаҗи күрше белән егет чагыбызда ук балаларыбызны кавыштырып туганлашырбыз дигән нәзеребез бар иде»,— дип, яшьләрне кавыштырырга ризалык бирде. Күздән дә калдырмыйча йортлы-җирле, атлы-сыерлы итеп, туй ясарга булды. Бу хәбәр, бер-берсенең күз карашына зар-интизар булып торган Гази белән Гөлүсә өчен генә түгел, барлык туган-тумачалар, күрше-күләннәр өчен дә тел белән әйтеп аңлатып булмастай зур куанычка әверелде. Иң сөенгән, күңеле мәтәлчек аткан кеше, әлбәттә, Газиның әнисе Зәйтүнә булгандыр. Урам уртасы дип тормады, Гөлүсәне туктатты да, сылу йөзенә елмаю кундырып, күзләрен кыса төшеп әйтте: «Өч ташбашымның берәрсе кыз булмавына уфтангалаган чакларым да бар иде. Ниһаять, менә кызлы да булам... Ходай бәхет-тәүфигыңнан аермасын, төкле аягың белән килә күр, балам!» — дип, чын ихласлык белән Гөлүсәне кочагына алып, аркасыннан сөйде. Шулай булгач, ничек итеп инде кыз баланың күңел түрләрендә якты омтылышлар тумасын, канатлар үсеп, матур җырлар уянмасын ди.

Гөлүсәнең дә үлепләр төшәсе килә шул өмәгә. Тик алар әле һаман да аерым хуҗалык. Эх-х, этисенең шул кире беткәнлеге вакыты белән суя ла!...

Яшерен-батырын түгел, Гөлүсә, эти-әнисенең рөхсәтен алганчы ук, инде әлеге өмәгә әзерләнә башлады... Гөлдәй киенерлеге булса да, аның башкалардан берни белән дә аерылып торасы килмәде. Җиде бала итәкле юка күлмәк, чигүле алъяпкыч төрде, энҗеле калфак урынына гапгади кәшемир яулык салды. Рәхимҗан абыеннан уенчык кебек җыйнак тугыз юкәле җиңел чабата ясатып алды. Миңсылу апасы бер дә кимәгән ап-ак тула оегын чыгарып бирде. Хәтта, кыздырылган тимер белән үзләренең тамгасы сугылган, җиңел булсын өчен тал сап куелган тырмага кадәр күптән әзерләнгән. Тик менә этисенә генә ничекләр итеп сүз катарга белмичә аптырады ул. Бу йортта аның сүзеннән узган кеше юк. Ике аягының берсен атламыйсың дисә, нихәлләр итәрсең!..

Гази да: «Ничек кенә булса да төшү ягын кара», — диде аңа. Шулай булгачтын, баскан урынында очынып биеп торган унҗиде яшьлек кыз ничек итеп инде шундый Сабан туена тиң җыеннан читтә кала алсын ди?

Иртәгә өмәгә төшәсе көнне Гөлүсәнең күзенә йокы кермәде. Җаны урынында түгел иде аның. Сәбәбе бар: этисенең кәефе юк иде, шунлыктан Чулман буена өмәгә төшү-төшмәү турында кичтән үк хәл итеп куя алмады. Менә ят инде хәзер күзле бүкән кебек!

Чалкан яткан килеш күзләрен күккә терәде. Күгәрчен күкәе чамасы алмалар сырган олы алмагачның тәрәзәгә иелгән ботаклары арасыннан галәмне күзәтте. Әкренләп караңгылык иңде. Тирә-юнь тәмам тынды. Шуны гына көткән сыман, күк йөзе чәнечкеле йолдызлар белән тулды. Шул иксез-чиксез күк капусын нәкъ урталай бүлеп, бәс төшкәнгә охшап, чак кына ак болытлар белән өретелеп, киек каз юлы сузылган иде.

Изрәп онытылып киткән Гөлүсә аңына килгәндә көн тәмам яктырган, авыл уянган, өйдәгеләр дә аякланган иде инде. Бу хәлне абайлап алган Гөлүсәнең йөрәге жу итте: соңарган ич. Җәһәт кенә торып киенде, юынды, көзге каршына килеп, чәчләрен тарады, бизәнде. Бар борчыл-

ганы — этисенең анда-монда чыгып китүе иде. Мондый чакта җаны бар кеше өйдә ята аламы соң?

Шулчак печәнчеләрнең озын арбаларга төялешеп урам әйләнүләре, егетләрнең кыңгыраулы гармунга кушылып, дәртле җыр сузуы, сызгырынып узулары ишетелде. Дугаларга тагылган җиз кыңгырауларның, көмеш шөлдерләрнең зыңы Гөлүсәнең күңелен тәмам ярсытты. Ул, язын зәңгәр күкләргә атылган сабан тургае кебек, ашкынуын басарга теләгәндәй, этисе белән әнисе янына түрге бүлмәгә килеп керде.

— Этием!.. Мин дә төшимче...

Ачык тәрәзә янында урамдагы хикмәткә колак салып тыңлап торган Иргали авызын ачкалаганчы, Гөлниса сорау бирде.

— Гази да төшәме соң?

— Барысы да төшәләр, әнием. Әнә!.. — Гөлүсәнең шатлыклы түземсезлек белән тулган йөрәге бермәлгә туктап калган сыман булды: этисе ни дияр?

— Ярар, төшәрсең... — булды эти кешенең җавабы. Әмма сүзе бетмәгән булган аның. — Алдыңны-артыңны чамалап, итәк-чабуыңны җыебрак йөре, кара аны!

Соңгы сүзне әнисе әйтте. «Бар, балам, ирек ачып мен бер».

Гөлүсә, ятагы янына килеп, алдан ук әзерләп куелган кием-салымнарын барлый, төргәли башлады. Шул вакыт ачык калдырылган түр як ишегеннән этисенең сүзләре колагына чалынды.

— ...Әнә бит, эшләр кая таба тәгәри. Бабаларыбызның бабаларыннан тартып алынганнан бирле Рәчәй патшасының атлы гаскәрен печән белән тәэмин итеп торган атаклы Чулман болынлыкларын янә халыкка кайтардылар, колхозларга бүлеп бирделәр. Нилектән әйтәм әле аны: безгә дә, әнисе, дөнья белән исәпләшмичә ярамас. Ике исәп бер хисап дигәндәй, быел ук ике якның берсен сайларга кирәк. Җиткәндер! Колхоз күзгә күренеп тернәкләнеп килә... Торган саен иген уңышы алуны арттыра барганы өчен республикабыз әнә Ленин ордены белән бүләкләнде. Болайга китсә, ныгый, тәки аякка баса колхоз. Шушы көннәрдә колхозга тагын берме, икеме трактор кайтачак ди...

Әнисенә җитә калды. Гадәттәгечә йомшак күңеллеләнеп әйтә салды: «Һай-й, рәхмәтләр яусын, этисе! Күптән шулай кирәк иде инде. Күрәләтә торып, халыкның кырын каравын күтәргәнче, ни булса да ил белән булыр, ичмаса».

Этисенең сүзе бетмәгән икән: «Көзгә, ходай кушып, хәвеф-хәтәрсез генә игеннәрне җыеп алып, яшьләрнең тормышын җайга салабыз да тәртәләрне Советка борабыз». «Һи-и, шулай итми ни аны!». Әле беркөн генә, Бәһрам җизни дә шул турыда сүз куертып маташкан иде. «Икмәк игүнең ибен, җирнең серен, мал-туарның телен беләсең, әйдә, тот та колхозга кер. Әһ тә итмәбез, үзеңне дүрт куллап тотарбыз да шундук икенче бригадага бригадир итеп куярбыз», — ди.

Бу сүзләр Гөлүсә өчен әйтеп бетергесез зур куаныч, берни белән дә чагыштыргысыз шатлык иде. Йа-а, хода! Аның да колхозчы булып: без кемнән ким дигәндәй, башын төз тотып урамнардан үтәсе көннәре бар икән!

Мәхәббәте яшереп булмас дәрәҗәгә җиткән Гөлүсә очкан кош җитезлеге белән ишек алдына атылып чыкты. Аны анда Миңсылу көтеп тора иде.

— Менә, Гөлүсәкәем, җүри сиңа дип атап, мул итеп пешердем... — дип, тирән коштабак тулы кабартмаларын күрсәтте. — Китер төенчегеңне...

Гөлүсә төенчеген күтәреп, капкага таба йөгерде. Күңеле белән сизде ул: этисе белән әнисе, ян тәрәзә янына килеп, башларын янәшә куеп, елмаешып, аның артыннан карап калдылар.

Җил уйнатып, уйнап-көлеп, кояш астында әлсерәп яткан юлның тузанын күтәреп, Чулман буена төшеп җиткәннәрен сизми дә калдылар.

Тирә-юнь шау-шу, ыгы-зыгы белән тулды. Бөтен болынлык нәкъ бәйрәмчә чуп-чуар. Ир-атка, карт-корыга житә калды, печәнен чалгы белән каерып ала алмаслык котырып-күпереп торган болын өстенә бактылар да: уңса уңар икән! дип тел шартлатырга керештеләр.

Болында хәйран тамаша. Монда ирлек, монда егетлек сынала. Син кеше күзендә. Беләкләреңә кан саусын, билләрең кәкрәеп катсын, кызулыктан гөлт итеп кабыну дәрәҗәсенә җит, әмма сер бирде юк. Елгырлыгыңны югалтма, уяулыгыңны җуйма, үлсәң үл, әмма артыңнан килүченең сызгырыплар килгән чалгысы астыннан үкчәңне алып өлгер...

Күпмедер вакыт узгач, хатын-кызларга да эш булды. Үлән оны, тузан кермәсен өчен, авыз-борыннарын яулыклары белән томалап алган җиңгәчәйләр, яшь киленнәр, җилбәзәк кызлар, тырмаларының саплары белән ир-атлар чабып узган тигез, тыгыз тезмәләрне әйләндерә дә башладылар. Кичә чабып узылган урыннарда вак-вак чүмәләләр дә калкып чыктылар. Борынгы Чулман-Кама ягыннан искән дымсу җил йөзләрне рәхәт сыйпап-назлап үтә, чебен-черки, кигәвеннәрне читкә очырта.

Эшли торгач әбәт тә озак көттермәде. Шунда Гөлүсә тагын бер нәрсәгә төшенде: күмәк табында ашап-эчүләре генә дә рәхәт икән. Итле тары өйрәсе аңа ашап туйгысыз тәмле булып тоелды. Тик кемнеңдер аны телгә алуы, яхшы эшләде дип мактавы гына әллә нишләтте, оялуларыннан җир асларына керердәй булды. Зиһенлегә эшнең сере үзе ачыла, эшмәкәр нәселеннән шул ул дип куйды кайсыдыр.

Әмма сүз моның белән генә чикләнмәде, шунда кызларның кайсыныңдыр теле авызына сыймады: «Бәһрам абый, әйдәгез Гөлүсәне колхозга алыйк», — дип, тәкъдим ясагандай итте.

Сүз нярә сүз китте. Кайсыдыр: әти-әниләреннән башка алып буламы? кебек сорау ташлады. Әмма шул чак комсомол ячейкасының сәркәтибе Кадыйрның катгый тавышы ишетелде: имештер, аерым хуҗалыктагыларны комсомолга алу устав буенча катгый рәвештә тыела.

Әмма түр башында утырган, һәрчак игътибарлы, кеше җанлы Бәһрам абый, сүзне башкачарак түгәрәкләде.

— Ә нигә? Кыз бала гомере буе ата-ана түбәсе астында яшәми. Так что, килер бер көн, Гөлүсәне колхозга да, комсомолга да алырбыз. Ул әле үзенең удар хезмәте белән безнең барыбызны да шаккатырыр.

Гөлүсәнең, тиздән бөтен гаиләләре белән колхозга керергә җыенулары турында әйтергә бик теле кычытса да, тыелып калды, кыюлыгы җитмәде.

Кеше җанлы Бәһрам абыйлары бер Гөлүсәне генә түгел, Газиның да исемен телгә алды:

— Чистый җен икәнсең, Гази энем, баягынак чалгы селтәүләреңне җүри карап тордым. Очып китәсеңме дип торам... Хет чәлт иткән тамчы тир чыксын үзеңнән.

«Кая инде!» — дип уйлап куйды Гази. Сер бирергә теләмәгәч тә, үз хәлен үзе генә белде...

Әбәт төгәлләнде. Халык яңадан бердәм эшкә алынды. Әле яңарак печәнчеләр өстенә коелган бүз тургайларның көмеш чыңы да, әрәмә-тугай кыңлекләрендә сайрашкан башка төрле кошлар тавышы да дәртле хезмәт шавы астында күмелеп калды. Әмма өмәнең беренче көне дип, артык җилләнмәскә, аяк-кулны, бил-иңне сакларга булдылар. «Бил яздыргач, бик җиткән»,— диештеләр.

Печәнчеләр, баштан ук сөйләшеп куйган сыман, икегә бүленде. Ир-атлар — агымның өске өлешенә, елга уратма ясап аккан урынга, хатын-кызлар исә куе әрәмәлек каплаган култык артына, сары комлы кашлак ягына китеп бардылар.

Чулман иделенең чоңгыллар ясап, ашкынып-талпынып аккан турысында, текә яр өстендә берничә егет зур итеп учак ягып җибәрде. Күп тә үтмәде, печән тирмәләреннән чак кына читтәрәк янган әлеге ут янында, коенасы коенып, юынасы юынып, өс-башларын алыштырырга өлгергән

яшьләрне үз янына чакырып, җыен тоткасы гармунчы үзенең тальянын сыздырып җибәрде...

Бу авазлар чәчкә, үлән исләреннән үк исергән яшьләрне һушларыннан яздырыр дәрәҗәгә җиткерсә дә, күз-башлары тонып ут янына чыбыш-мадылар. Бигрәк тә кыз балалар үзләрен тыйнак-инсафлы тоттылар. Монда алак-шалаклыкка урын юк. Монда кыз белән егетнең төркемнән аерылып китүен, кайдадыр ышык-аулак урыннарда очрашуларын күрмәссең. Бар, бер генә кыек адым ясап кара, гайбәт шундук үзенең шыксыз йөзен күрсәтәчәк. Кыяктай зәһәр телле җиңгәчәйләр, бергә бишне кушып арттырып сөйләргә йөдәп торучы түтәйләр шунда гына.

Газига да шактый озак көтәргә туры килде үзенең Гөлүсәсен. Ниһаять күрде! Бу мизгелдә ул Газига, адәм баласы булудан бигрәк, күктән иңгән фәрештәне хәтерләтә иде. Бала итәкле алсу төстәгә күлмәге, билен өздереп буган канатлы алъяпкычы аны шактый озын буйлы итеп күрсәтә. Башындагы кәшемир яулыгы да ниндидер хикмәти көч ярдәмендә генә баш очында эләгеп тора. Кыл урталай ярып ике толым итеп үрелгән авыр чәч толымнары, хәрәкәтләнгән саен, атынып-атынып куялар. Әнә ул, янында янәшә атлаган ахирәтенә нәрсәдер әйтте... Һәм бит очларын чокырайтып ихлас елмайды. Карап туйгысыз, һушларны алырдай сылу иде аның Гөлүсәсе бу минута.

Дөнья дигәнең шундый да матур, шундый да ямьле, бөтен әйләнә-тирәдә бары тик бәхет, бары тик яхшылык кына, бары тик мәхәббәт кенә ак канатларын җәйгән. Газиның күңеле тәмам шашып чайкалып түгелү дәрәҗәсенә җиткән, күңелләргә кояш нурыдай булып сөенеч иңә дә берни белән дә чагыштыргысыз куаныч агып керә иде.

Әйе, язмыш дигән нәмәстәнең кукрәүле көннәре алар өчен хәзергә билгесез, алар өчен ят иде шул әле...

Гази белән Гөлүсәнең йөрәк бәгырьләренә үтәрдәй күз карашлары, ниһаять, очрашты.

— Бик арымадыңмы, Гөлүсә?

— Юк. Һич кенә дә арымадым. Ә син?

— Мин дә...

Аларның аяк очында күз карашы иңли алмаслык дәрья җәйрәп ята. Кояш үзенең соңгы нурларын тулысынча Кама өстенә сипкән. Су өсте, нәкъ беренче боз каплап киткән сыман, шундый да тыныч, шундый да шома, таеп егылырлык.

Шулчак су буйларын яңгыратып, яр буе әрәмәлекләрен, шау чәчәктә утырган гөләп җимеше куакларын сискәндереп, тальян гармун кабат аваз салды. Ул да түгел, чаярак егетләрнең берсе, яшьләрне түгәрәккә чакырып, җыр башлады.

Безнең бакча эчләрендә
Сайрый сандугачлары;
Башка көйгә тавыш бәрмый
Дисәң «Алмагачлары!..»

Кайсыдыр, биергә җыенгандай, борынын бик тә яман өскә чөеп, кулларын җибәреп, килбәтсез кукраеп, ут янына якынлашучы кызлар төркеме яныннан үткән булды. Тыныч кына уза аламы соң, берничә кыз, берьюлы чырылдап, читкә тайпылып калды...

Бераздан бар да үз җаена төште. Егетләр, кызлар кулга-кул тотынышып әйлән-бәйлән җырын башладылар. Ул да түгел, җырны уен алыштырды.

Бер-берсен күрү белән күзләрендә нур кабынып, дөньялардан китәрдәй дәрәҗәдә гашыйк Гази белән Гөлүсә дә шунда. Хәзер инде аларның сөйләшүләре генә түгел, ярәшелгән булулары да беркем өчен дә сер түгел иде...

Ул көнне халык ару-талуны онытып эшләде. Иң алда дан тоткан чалгычылар барды. Егет-җиләннәр бер төркемдәрәк. Гази да шунда. Аяктан егылыр хәлгә җитеп арыса да, сер бирде юк: әнә, печән кабартучы кыз-

лар арасында аның йөрәк пәрәсе Гөлүсә дә бар. Андый чакта кая ул сынату!

Җиңел тарантаска җигелгән юргасына утырып, авыл белән ике арада йөргән Бәһрам агай да ажгырып килеп җитте. Канатлы тарантасыннан җәһәт кенә сикереп төште дә, бик әһәмиятле хәбәр салырга җыенгандай, печәнчеләрне үз янына чакырып алды. Шундук киңәшләшеп, әзерләнгән печәнне явым-төшем башланганчы кичекмәстән кибәннәргә өяргә, ә алы аландагы кибәннәрне богылга салырга дигән карарга килделәр. Бу җаваплы эшне Шәвәли абзыйга тапшырырга булдылар. Эскерт өю, кибән кую, богыл салу кебек эшләрне аңардан да оста башкаручы юк, аныкылар төптән юанаеп килә дә, өскә таба килешле генә очлана, «җилкәле» булмый, янәсе.

Утлап йөргән атлар да, күл буенда мәш килгән малай-шалайлар да шунда ук эшкә җигелделәр. Өлкәннәр сүзе хак булды. Кибәннәр куелып, богыл өелеп беткәндә, табигать әлсерәп хәлдән тайган сыман, сәер тынлыкка талган, ә кайдадыр офыкта оеп торган аксыл болытлар хәрәкәтләнә башлаган иде инде. Ул да түгел, нәкъ шул яктан, авыз эченнән генә мыгырданган сыман, әкрен генә булып күк күкрәгән тавыш ишетелеп куйды. Бу авазга, бик тонык ишетелгәнгәме, әллә ни әһәмият бирмәделәр. Чөнки хәзерләнгән кадәр печән җыелган, кибән-богыллар бастырыкланган, әйдә, ява бирсен.

Яшьләр кояш баеганчы, яңгыр коя башлаганчы, җәтрәк су коенып, юынып, өс-башларын алыштырып калырга ашыкты. Барысы да өсләре торыпшалар белән томаланган куышлар янына җыелып, шаян сүзләр әйтешеп, шаярышып алдылар. Шунда Гөлүсә белән Гази дә очрашты. Гази кызга, чәчәк бәйләменә охшатып, чеме белән җыелган җир җиләге бирде. Шатлык үргып торган Гөлүсә аһ итте.

— И-и, Гази! Кай арада җыйдың шул хәтле итеп? Җалга-фәләнгә дә туктамаган идегез пич.

— Җыйдым инде...

— Рәхмәт, Гази.

Ә күзләрендә мең балкыш үзенең.

Алар, янәшә атлап, елга буена таба киттеләр. Гөлүсә, егеткә сиздермәскә тырышып, бәхете мөлдерәп ташыган кешедәй ялтырап, кашлары астыннан өздереп кенә күз сирпеп алды. Чыннан да сөеп, табынып туймаслык иде Гази бу минутта. Уртачадан калкурак буй-сын, төз гәүдә. Дәрт һәм тәвәккәллек сирпеп торган күзләр. Шулчак кызның Газига тагын да якынрак киләсе, киез эшләпәсенә кунган печән чүпләрен кагасы, тирләп-пешкән, тузанлы йөзенә юл-юл булып эзләр калдырган тирне сөртеп аласы килде. Тик ярамый. Тирә-юньдә мең күз. Шулай да Гөлүсә күңел түрендә: үңганым минем, булганым, насыйбым минем кебек сүзләрнең хасил булуын тойды. Әтисе дә Газига мөстәкыйль тормышка басарга аяк киенүче егет итеп карый, еш кына: «Сүз әйтерлек түгел егеткә, эш өчен җан атып тора», — ди бит.

Газиның да күзләре Гөлүсәдә. Күзләрне камаштырырлык сылу иде кыз да бу мизгелдә, карап туйгысыз иде. Кыл урталай ярып тарап үргән чәч толымнарының берсе аркасында, икенчесе — калку күкрәге өстендә. Бит алмалары алсуланган, маңгайларына, күз төпләренә ләйсән кебек кенә вак, үтәдән-үтә күренмәле тир бәреп чыккан. Озынча нәфис муены, чәчәк таҗчыгыдай чак кына бүлтәеп торган алсу иреннәре, сизелер-сизелмәс кенә чокыраеп торган ияге — барсы, барсы да кабатланмас гүзәл, башны югалтыр дәрәҗәдә матур иде.

Алар, әкрен генә атлап, юлларын дәвам иттеләр. Менә текә яр. Елга кырыена килеп чыгу белән дөнья бердәм ямьтырып, киңәеп, нурга күмелеп китте кебек. Икесе дә елга ягыннан искән талгын җилдән йөзләрен сыйпаттылар...

Бу мизгелдә Гази, сулышы буылыр дәрәҗәгә җитеп, эчке бер рәхәт, тел белән әйтеп бетергесез куаныч кичерә иде. Ул янә ирен читләренә елмаю кунудан нурланып торган Гөлүсәгә таба борылды. Борылды да хәй-

ран калды. Бу мизгелдә кыз, чыннан да, үзе әйтелмәгән сер йомгагы иде. Күр син аны! Алга төбәлгән күзләрендә оялчанлык, сафлык, гыйффәтлелек һәм мәңгелек сихри тылсым, наз. Я, хода, бу гөнаһлы фани дөньяга ялгышлык белән генә килеп эләккән фәрештәдерсең син! Гази эченнән генә бер үк сүзләрне кабатлады: «Бәхетем минем! Якты өметем, шатлыгым... Җанкисәгем!..»

Газиның күңел түрен татлы кытыклап, әллә ниткән нурлы уйлар, канатлы хыяллар кузгала. Адәм баласының шундый да рәхәт кичерүләре мөмкин булыр икән! Гази күңеле түрендә: әле дә ярый туганмын, минем бит бу фани дөньяда булмавым да, шушындый чамасыз бәхетне татымавым да мөмкин иде ич дигән уй тууыннан үзе дә гаҗәпкә калды.

Шулчак Гөлүсә, гөләп җимешенең чәнечкеле ботаклары арасына яшеренеп үскән кыңгырау чәчәген күреп алды. Сузылып өзде дә, нидер төшенергә теләгәндәй, шәмәхә төстәге әлеге чәчәкне бик җентекләп караштыра башлады.

— Гази, син нинди чәчәкне күбрәк яратасың?

Егет җавапны алдан ук хәзерләп куйган диярсең:

— Син үзеп биргәнне...

Гөлүсә, ялт итеп озын керфекләрен сирпеп, егетнең йөзенә күтәрелеп карады. Шул арада янадан аның күзләрендәге саф күгелҗем зәңгәрлек чагылып китте.

— И-и, тилекәй! Шашкан! Һаман шаяру үзенең уенда...

Шулай диде дә елмаюын яшерә алмаган бер халәттә яулыгын җиңелчә чөеп артка бәйләде һәм коенырга китеп баручы кыз-кыркыннар төркеменә таба йөгерде.

Күңеленә тулган шатлыкка, рәхәткә тәкать тота алмаган бер кыяфәттә калган Гази да аңына килде һәм ир-атлар су керә торган якка китте. Рәхәтләнделәр егетләр, бөтен су буен бер итеп коендылар. Җәйрәп яткан елга өстендә агымга каршы да, аркылыга да, буйга да колач сала-сала йөзделәр.

Гази агымга каршы йөзеп китте. Шулчак аның күзенә, ярларын кызыл тал, биек камыш, су өстен төнбоек һәм саз үләннәре белән каплаган култык сыман нәрсә чагылып китте. Күрче, яшереп куйганга охшап, көймә дә тора түгелме соң!

Гази култыкка йөзеп керде. Мондагы су, нәкъ ут өстендә җылытып куйган кебек, талгын иде. Үзе үтәдән-үтә күренмәле тонык, саф. Сары, ак төнбоекларның нечкә сабаклары төпкә таба сузылганнар. Күп алар. Араларында көмеш чабаклар мәш килә.

Менә көймә. Аңардан балык, дегет, ләм һәм камыш исе аңкып тора. Гази яртылаш суга баткан көймә эченә сикереп менде. Шунда, көймә эчендә үк урталай ярылган агач соскы йөзүен абайлап алды.

Гази, көймәне күздән кичерде дә, житез хәрәкәтләнеп, ярык соскы белән каек эченә тулган суны түгәргә кереште. Нәкъ шул вакытта, капылт каты әче җил исеп куйды. Җилнең кар исе аңкып торган салкын сулышы култыкны уратып алган кызыл таллыкны, камышларны шаулатты, һәркайсы аш тәлинкәсе кадәрле күе яшел төстәге төнбоек яфраклары, икенче якларына әйләнеп ятарга теләгәндәй, су өстеннән кубып, хәрәкәтләнеп куйдылар. Әле баягынак кына чыр-чу килеп, һаваны аркылыторкылы сызгалап, күз иярмәслек тизлек белән тыз-быз очкан яр карлыгачлары кинәт юк булдылар. Караса, ни күрсен, еракта, бөтен офыкны иңләп, күгелҗем-кара болыт укмашып маташа иде. Нәкъ шул мизгелдә кабат тонык кына күк күкрәгән тавыш ишетелгән сыман булды.

Гази җиңеләеп калган көймәне юшкынлыктан ачыклыкка, елга уртасынарак алып чыкты да: «Эх-х-ма! Юл бирегез!..» дип бөтен су буен яңгыратып, яр буена җыелган егетләр янына агып төшә башлады. Иптәшләре аны шундук шау-гөр килеп урап та алдылар.

— И-и, Гази, каян алдың бу каекны?

— Таптым.

— Күрче, йөзәрлек көймә ич бу!
— Бар, йөзеп кара!..
— Әйтмә дә! Ә ишкәкләре кайда?..
Гази ярга сикереп төшеп, җәһәт кенә күлмәк-ыштаннарын киеп алды. Егетләр коенып чыгу белән, казандыр, савыт-сабадыр юарга хатын-кызлар төшәсен ул белә. Чыннан да, нәкъ шул вакыт куыш-тирмәләр турысыннан кутәренеп төшеп килүче апайлар да күренде.
Гази көймәне яр өстенәрәк тартты, шаулатып суын түкте. Балакларын сызганды да, хатын-кызлардан буш чиләк алып, көйменең эчен һәйбәтләп чистартты, төбенә утырган лайдан арындырды. Кабат суга төшергәч күрделәр, көймә төбенең ике урыныннан сиптереп су керә. Шунда егетләрнең берсе каек турында соңгы нәтиҗәне ясады:
— Көймә түгел бу... әҗәл тагарагы.
Нәкъ шул мизгелдә, барысының да дикъкатен тартып, якында гына гөрселдәп күк күкрәде. Бу иләмсез дөбердәү, үзенә иркенлек яулагандай, бөтен тирә-якка таралып китте. Барысы да яңгыр килгән якка борылдылар. Әле бая гына офыкта оеп торган болытлар, хәзер инде кара-кучкыл төскә кереп, бөтен дөньяны басып китәргә теләгәндәй, кабарынып-бүртенеп, якынлаша да башлаганнар иде. Ул да булмады, бөтен күк йөзен иңләгән болытларның ишелеп-кайнап торган урынын кискәләп, ботлы-чатлы, берничә җәпле яшен камчылап алды. Шуны гына көтеп торгандай, кабат озакка сузылган дөбердәү ишетелде.
— Ай-яй, шөкәтсез килә бу! Өннәрең алынырлык, мин сиңа әйтим...— диде савыт-саба юган апаларның берсе.— Хәвеф-хәтәрсез генә уза күрсен берүк.
— Тикмәгә генә шулай кыздырды дисеңмени син аны!
— Әнә салкын сулышы килеп тә җитте инде.
Чыннан да, иркенләп сулыш алырга да ирек бирмәгән тынчу-тымызык һаваны теткәләп-өзгәләп, көчле җил исте. Елга буенда кинәт яңгыр алды эңгере өретелде. Күрде Гази: актарылып аккан күгелҗем-кара төстәге болытлар ташкыны аларның баш очына ук килеп җиткәннәр.
«Гөлүсә кайда соң?..» Караса, гарасат якынаюы тегесенең исендә дә юк. Кыз-кыркыннар, яшь киленчәкләр коенырга киткән куе таллыклар каплаган борын ягыннан якынлашып килүен күреп алды. Кыз күлмәкчән генә, алъяпкычына кадәр салган. Башында да чәчәктән үрелгән такыя гына. Оек-чуларын, кием-салымнарын төенчек итеп култык астына кыстырган да, вак-вак атлап, дулкыннар ялмап алган дымлы ком өстеннән килә. Бер кулы белән күлмәк итәген чеметеп тоткан. Чөнки ярга каккан дулкыннарның кайсылары аның аягына кадәр ыргылгалыйлар. Гөлүсә шул дулкыннар белән шаярып, кинәнеп, уйнап килә иде булса кирәк.
Менә ул, җиңел гәүдәсен уйнаклатып, төенчеген бер читкә куйды да хатын-кызларга савыт-саба җыештырырга ярдәм итә башлады. Нәкъ шул вакытта якынлашып килүче кызлар төркеме дә күренде.
Гази да, авыр кара болытның канатлары белән бөтен галәмне иңләп, уңга-сулга утлы сөңгеләрен ыргытып, җилләп-давыллап килеп җитүен күреп, көймәдән чыгып киенмәкче дә иде инде, тик өлгермичә калды. Җыелып торган егетләр төркеменнән аерылган Кадыйр, посып кына якынайды да савыт-сабалар белән мәш килгән Гөлүсәне җәһәт кенә күтәреп алып Гази янына бастырды һәм көймәне җан-фәрман яр буеннан этеп тә җибәрде. Гөлүсәнең ризасызлык белдереп: «Китчәле!..» — дип кычкыруы белән, егетләрнең шаркылдашып көлешә башлавы гына ишетелеп калды.
Нәкъ шул вакыт күз ачыргысыз әче салкын җил исте, ком бураны дөньяны томалады. Күк йөзен авыр яңгыр болытлары сарып алды. Гази белән Гөлүсәнең баш очында гына яман чатырдап яшен яшьнәп күк күкрәде дә, орып-бәреп, тузгып-«төтенләп», яңгыр коя башлады.
Бер генә мизгелгә каушап-югалып калган Гази аңына килгәндә, ярсып-ярсып искән җил этәрүдән һәм көчле агымга эләгүдән, көймә бе-

лән яр арасы күзгә күренеп ерагайганнан-ерагая бара иде инде. «Уены уен түгел... сакаллы сабый»,— дип мыгырданды Гази. Һәм ул нәрсә эшләгәнен үзе дә абайламаган кеше сыман, көймә кырыена чатырдап ябышкан кулларын ычкындырмыйча гына, суга сикерде. Ишкәксез-җилкәнсез көймәне ярга сөйрәп чыгару иде аның нияте. Әмма баштан тиң суга чумса да, аяклары төпне капшап таба алмады аның.

Сизде Гази: көчле агымга, торган саен зәһәрләнә барган җилгә эләккән көймә ифрат зур тизлек белән һаман елга уртасынарак йөзә. Ул чалт та чолт көймә кырыен каккан дулкыннар арасыннан мәче тизлеге белән Гөлүсә янына күтәрелде. Үч иткән кебек, бөтен дөнья кинәт шомлы караңгылыкка чумды. Әнә инде әле яңарак кына алар кузгалып киткән яр да, эңгер эчендә эрегәндәй, бөтенләй күренмәс булды.

Нәкъ шул вакыт чал башлы дулкыннар биешкән Чулман өсте күзләрне камаштырырлык яктылык эчендә калды. Ул да булмады, җирне кыл урталай ярырга теләгәндәй яман чатырдатып, тирә-юньне дер селкетеп күк күкрәде. Бу иләмсез гөрселдәү Гөлүсәнең өнен алды булса кирәк, ул атылып килеп Газига ябышуын үзе дә сизми калды.

Гази да куркып китте. «Чыга алырбызмы?..» — дигән шыксыз уй бөрмәлгә аның ихтыярын богаулагандай итте. Тәне буйлап салкын йөгерде, калтыратып алды. Ул арада көчәйгәннән-көчәя барган дулкыннар, ак тешләрен ыржайтып, яртылаш су тулган көймәне йомычка урынына биетепме-биетә: зәһәр ачу белән йә өскә чөя, ул да булмый, җаннарны тетрәндереп, ике дулкын арасында хасил булган бушлыкка, упкынга атып бәрә башлады.

Газиның бар борчылганы — Гөлүсә. Шулчак елга өстен янә яшькелт салкын төскә манып яшен уйнаклады. Күрде Гази: яр инде әллә кайда калган, алар Каманың урта бер җирендә чайкалалар. Көймә су астына китә-нитә калса, Гөлүсә ярга кадәр йөзеп чыга алырмы? Эчендә кабат нәрсәдер өзелгәндәй булды.

Гази яңадан ярсып-нәфрәтләнеп, яше утызга якынлашып килсә дә, әле һаман комсомол вожагы булып йөргән Кадыйрны сүгеп алды: «Аһ-һ, кабахәт! Тапты бит уенын да...»

Инде нишләп карарга? Җавап урынына көймә тирәсендә дулкыннар шаулашты да, баш очларында тау-ташлар актарылгандай, берьюлы берничә урында яман дөбердәтеп, гөрселдәп күк күкрәде.

Ялт та йолт килеп уйнаган яшен яктысында Гази, көймә эчендә йөзеп йөргән агач соскыны күреп алды. Шуны кулына эләктереп һәм көймә читенә иелеп, җитез хәрәкәтләнеп ишәргә маташып карады. Әмма берике селтәнү белән бу чараның котылу юлы түгеллеген шунда ук абайлап алды. Соскыны курку-каушаудан телсез калган Гөлүсәгә тоттырды да көймә эчендәге суны түгәргә кушты. Ә үзе утыргыч тактага ташланды. Муртаеп беткән такта әллә ни карышмады, кадаклары-ниләре белән бергә йолкынып та чыкты. «Менә ишкәк тә булды...»

Гази көймәнең арткы өлешенә күчеп билдән тиң суга чумып утырды да, көймәне ярга таба борып, җан-фәрман ярсып-кабаланып ишә башлады. Шунда аның, тирә-юньдәге зилзиләне басып, беренче тапкыр көр тавышы яңгырады:

— Гөлүсә! Җәһәтрәк хәрәкәтлән... җылынырсың.

Кадаклары тырпаеп торган, ифрат та җайсыз такта белән куллары суелганчы ишү, ару-алҗу, хәлдән таю бушка китмәде. Нindидер афәт көче яман да чатнап күкрәгәндә, елга өсләрен шаулатып-күбекләндереп, чиләкләп яңгыр коя башлаганда, аларның көймәсе сөзәк ярга чыгып җитеп, борыны белән сайлыкка килеп төртелгән иде инде.

Шунда күрделәр: тирә-юньдә шәрә, шомлы бушлык. Нindидер кыргый урын. Кереп ышыкланырга ник берәр аулак җир булсынчы. Андасанда оя-оя вак таллыклар. Убылып купкан дәһшәттән котылырмын димә. Ә өстән яңгыр түгел, тоташ ташкын коя. Өс-баш лычма су, хет тотып сык.

Гази бу бәладән котылу юлын бик тиз тапты. Ярга төшүгә, көймәне янтайтып, суын түкте. Һәм алар икәүләшеп, көймәне як-ягыннан эләктереп алдылар да яр өстенәрәк, кашлаграк урынга сөйрәп менгезделәр. Гази күз иярмәслек тизлек белән иң элек көймәне гөрселдәтеп әйләндереп атты. Шундый ук җәһәтлек белән, көймәнең бер ягын күтәреп, шуышып керерлек кенә ярык калдырды да «ишкәк» тактаны кыстырып та куйды. Рәхим ит, менә сиңа әзер куыш!

— Гөлүсә!.. Кер тизрәк...

Алар көймә астына кереп яшеренгәнне генә көткәндәй, яңгыр да иләп-селтәп, давыллап-котырып, яңа көч белән коя башлады.

Гази белән Гөлүсә иң элек куш куллап, юешләнүдән өске өлеше оешып киткән комны як-якка эшерделәр. Ә аста көне буе кояш күзендә ятып, яңгыр астында да суынырга өлгермәгән, уттай кызган коры ком. Берәздән көймәнең ачык урыннары, бигрәк тә җил бәргән як, тәмам томаланды. Хәзер инде көймә асты салкын сулышын бөрки-бөрки котырынган гарасатның яңгыры түгел, җиле дә үтеп керә алмаслык ояга әверелде.

Егет белән кыз бәладән шулай котыла алуларына куанышып һәм көтелмәгән уңайлыкның рәхәтен тоеп, сузылып яттылар да бер-беренең кочагына елыштылар. Гөлүсә җылы эзләгәндәй, йөзен егетнең куенына төртте. Алар шулай кочаклаштылар да тынып калдылар.

Көймәнең ачык калдырылган өлешеннән күренгән төн караңгылыгын чатыр да чотыр ярып ялт-йолт ялтырата иде, күк күкри. Тик инде хәзер ул гөрселдәүләр баягы кебек үк шыксыз түгелләр, ничектер хәлсезләнебрәк, як-якка таралган сыман булып ишетелде. Аның каравы, яңгыр куәтләнде, тоташ ташкын сыман, көймә төбен шыбырдатып, ыргып-дулап койды. Ә көймә астына хет бер генә тамчы яңгыр үтеп керсенче. Монда сумала, ләм һәм балык исе генә хакимлек итә иде.

Гази, хисләнеп китеп, кызны тагын да үзенә таба елыштырды, ныграк кысты. Шунда ул Гөлүсәнең тыгыз тәнен, кайнар калак сөякләрен, бил батынкылыгын тойды. Бер үк вакытта аяклары кызның ботлары, шомайомры балтырлары белән аралашты. Шунда ул бөтен барлыгын моңарчы таныш булмаган ашкынулы дулкын биләп алды: хисләре ташып, тыны кысылды, сикереп чыгардай булып йөрәге какты, гәүдәсе буйлап өзлексез йөгереп үткән вак дерелдәүне баса алмаудан гаҗиз иде ул.

Назга сусаган, хис иркенә бирелүдән сулышы ешайган Гөлүсә дә, йөзен Газиныкына якынайтканнан-якынайта барып, ярым пышылдап кына:

— Сөясеңме?..— дип сорап куйды.

Акылын җуяр хәлгә җиткән Гази бу сүзләрнең мәгънәсен аңлап та бетермәде ахрысы, күкрәгенә кызны тагы да ныграк кыса төшеп, исенакылын җыя алмаган хәлдә, бары тик бер сүз әйтте:

— Үлеп!..

Шунда аның иреннәре Гөлүсәнең яңа ачылган чәчәк таҗчыгыдай сафлык, самимилек бөркелеп торган иреннәре белән кушылды. Бу назлану-иркәләнү үзенекен итте. Шунда Гази гомерендә беренче тапкыр буларак үз хәлен үзе аңламас халәткә килүен, тәненең ниндидер бер тансык нәрсәне таләп итүен, нидер көткәндәй ләззәтле оеп сыкравын, рәхәт ашкынуын тойды. Башында гомер булмаган сәер, иләс-миләс уйлар чагылып китте: «Ә нәрсә? Без бит барыбер бергә булачак... Безне хәзер инде кабер генә аерса аера алыр... Тиздән, шушы көздә үк кавышып, ир-белән хатын булачак кешеләр. Гөлүсәнең: «Сөясеңме?..» дигән соаль бирүе дә, бәлки: син минем насыйбым, алдагы көндәге тәрәгем, мин синеке, теләсәң нишләт, дип ишарә ясавы булгандыр...»

Мәхәббәт исереклегеннән дә татлырак тагын нәрсә бар икән бу дөньяда? Ул вакытта Гази өчен мәхәббәт дигән бөек могҗизаның тылсымлы серлелек белән өретелгән кодрәте әле яңа гына ачылып килә торган нәрсә иде.

Гази иң элек эчке калтыравын тыярга, тигез сулыш алырга тырышып карады, аннары акыл-фикерен җыеп, ихтыяр көчен туплап, бу шашынкы-саташулы, моңарчы билгесез тойгылардан аерылырга кирәклекне чамалап, үз-үзен кулга алды. Аңа кинәт түзә алмаслык бөркү, эссе булып китте. Һәм тулысынча аның ихтыярына буйсынып, тойгылары ташудан һуштан язар дәрәҗәгә җиткән кыз баладан чак кына читкә тайпылды. Зиһене ачылып китү белән, янә уйлар өермәсе туды. «Юк! Ярамый!.. Һич тә ярамый. Ярсыган хис-тойгыларны җайга салырга, тезгенли дә белергә кирәк. Ямен җибәрмик... Без барыбер бергә булачак. Шулай булгач, бәхет сәгате сукканны көтә белергә дә кирәк...»

Шулчак кинәт якында гына ялкынланып учак яна башлаганга охшап, тирә-як яктырып китте. Бу хәлгә иң элек Гази игътибар итте. Тиз генә көймәнең ачык ягына борылды һәм күрде: бөтен күк йөзен иңләп каядыр ашыккандай, ертык-пыртык итәк-чабуларын җилфердәтеп, күксел-кара болытлар тоныклык кына дөбердәү-гөрселдәүләр эчендә көньяктан төньякка таба йөзеп китеп баралар иде. Әлеге яктылык шул болытлар әсирлегеннән котылган тулы ай елмаюы икән. Ә иксез-чиксез булып киңәеп калган галәм киңлегендә — бихисап йолдызлар...

Көймә астыннан беренче булып Гази чыкты. Чыкты да хәйран булып катып калды. Сөттән ак төн. Сызылып кына таң беленеп килә. Кама өсте томанга төрелгән. Агымсу иркенә буйсынып хәрәкәтләнгән әлеге томан ертыклары арасыннан, кара урманнар белән капланган аргы яктагы текә тауларның бары тик тонык күләгәләре генә абайлана. Елга буенда шундый тынлык, бер якта эрерәк балык сикерсә, икенче якта аермачык булып ишетелерлек иде.

Гази елга буена килде. Су өсте тулы аксыл-сары күбек йөзә. Томан елганың сулышын тыңлап торды. Чак кына читтәрәк, яңгыр сулары белән ермакланган яр читендә, әкәм-төкәм кабырчыклары белән чуарланган сайлыкта сызгырынып, озын сыйраклы ике тәлләтәвеч йөгерешеп йөри. Алар янында тагын ниндидер ак муенлы кошчык, кемнедер эзлиме, күзәтәме. Шулчак болыннар киңлегеннән тартай белән бытбылдыкның аваз биргәне дә ишетелде.

Сихри хозурлык үзенекен итте, Гази түзмәде, кызны да үз янына чакырды.

— Гөлүсә! Чык тизрәк. Күр бу хикмәтне!..

Үзе, ай һәм таң яктылыгы астында җәйрәп, сулыш алгандай талгын гына чайкалып яткан суның җылылыгын белү өчен, тубыктан тиң суга керде. Су әле яңа гына сауган сөт кебек җып-җылы иде. Гази түзмәде, кабат Гөлүсәгә дәште һәм каядыр соңга калудан курыккан сыман кабаланып, комга буялып беткән киемнәрен бер читкә салып атты да, тирә-якка көлтә-көлтә көмеш тамчылар чәчрәтеп, алкын суга кереп тә чумды. Тәненә талгын рәхәтлек, көч-куәт иңгәнен тойды ул. Колач салып бер-ике селтәнү белән, кинәт каерылып, яр ягына күз салды. Көймә астыннан чыгып өлгергән Гөлүсәне кабат үз янына чакырды. «Әй-йем!..» диде кыз, су керүдән баш тартып.

Сәбәбен белә Гази. Гөлүсә бер кат юка күлмәктән генә. Әмма ул кызның карышуын ишетергә дә теләмәде, икебезнең дә киемнәребезне чайкамыйча торып, барыбер киярлекләре юк, ком белән ләмгә буялып беткән. «Тиз генә чайкап, әнә теге тал куакларына эл дә суга кер; тартынма, мин карап тормыйм, эчкәрәк йөзеп кереп торам»,— диде.

Әмма үзе яр ягыннан күзен ала алмады. Әнә Гөлүсә, кулларын баш очына күтәреп, чәчләрен рәтләде. Әллә ниткән сихри сыек яктылык һәм серлелек эчендәге сылу гәүдә, зифа сын бу мизгелдә аңа ак мәрмәрдән коеп ясалган могҗизалы һәйкәл кебек булып күренә иде.

Гази кабат чакырды. Якын килмәм, диде һәм, сүзен раслагандай, су чәчрәтә-чәчрәтә тирәнгәрәк йөзеп кереп тә китте.

Гөлүсә турылыклы дустының шулай итәчәгенә һич кенә дә шикләнми иде.

— Карама бу якка...— диде ул ахыр чиктә.
— Юк...

Гөлүсә вак таллык янына килде дә, тез чүгеп, күкрәге турысында кулларын аркылы-торкылы китереп, баш аркылы күлмәген сала башлады. Аннары җәһәт кенә тураеп, салган күлмәге белән буй-сынын каплагандай итеп, Газиның киемнәре янына килде. Аннары суга кереп чүгәләде дә кер чайкарга кереште. Ят күзләрнең күреп калуыннан курыккандай, судан йөгереп кенә чыкты да, бер оя булып утырган тал куаклары артына басып, җиләтеп алу өчен, киемнәрне таратып элеп куйды. Бары тик шуннан соң гына, куллары белән күкрәк тирәләрен каплап, муеннан тиң суга керде.

— Җылымы? — дип сорады Гази, үз тавышын үзе танымыйча.
— Бик...

Елга уртасындарак һаман хәрәкәтләнеп-йөзеп торган Гази читләтеп-читләтеп кенә Гөлүсәгә таба якынлаша башлады. Кыз: «Килмә»,— димәде. Ул үзенең шәрә тәнен күрсәтергә кыенсынып, кулларын кушырып, үз-үзен кочаклап тора иде. Гази, ниһаять, аягы астында комлы нык төпне тоеп, аягына басты. Битен югандай итеп сыйпаштырды да Гөлүсәгә күз төшереп алды. Кинәт телсез калды. Кызның чак кына күренеп торган юеш җилкәләре, су тамчылары кунган чәчләре таң яктысында ниндидер тылсымлы бер яктылык белән елкылдыйлар. Юк, таң яктысы гына түгел. Гөлүсәнең кабарыбрак торган чәчләрендә ай-йолдызларның да җемелдәүләре чагыла иде булса кирәк. Гөлүсәнең пакь, матур йөзендә оялчан елмаю кабынуын абайлады Гази. Бу мизгелдә кызның күзләре ниндидер эчке нур белән тулы иде. Әлеге нур зәңгәр күзләрнең карашын кабатланмас назлы, ә йөзен искиткеч мөлаем итә иде. Гази, Гөлүсәнең рәхмәт белән тулы күзләренә карады да, нәрсә дип әйтергә, ни дип сүз башларга да белмәгәндәй: «Туңмыйсыңмы?..» — дип сорады. Аннары җылытырга теләгәндәй итеп, кызның кулларын үзенекенә алып, җилкәләренә салды. Кыз аңлады: Газины кочаклап, йөзен аның җилкә турысына куйды да тынып калды.

Гази кызны кочагына кысты. Шулчак Гөлүсәнең калку нәфис, әмма салкын күкрәгенең кагылуын тою, бөтен тәнен көйдереп-өтәләп алды. Бәгырьләрне эретерлек утлы ләззәт иде бу. Газиның кабат тыны кысылды, башына кан йөгерде. Һәм ул тиз генә читкә тайпылырга мәҗбүр булды... Чумгандай итенде, аннары алны-артны, уңны-сулны абайламыйча суның тәнне рәхәт кытыкландыруын тоеп, кабат елга уртасынарак йөзеп кереп китте...

Алар кайтырга чыкканда, кояш әле күтәрелмәгән, әмма офыкның буеннан-буена сузылган үтә күренмәле кауры́й болытларның итәкләренә ут капкан, аларны комач-кызыл төскә кертеп, ашыкмыйча гына яңа көн туып килә иде.

Аның караву су өсте байтактан бирле инде алсу нурга коена, күзләрне камаштыра. Елга өсте урыны-урыны белән таң нурлары астында шадраланып җемелди. Димәк, таң җиле исә.

Төнге яңгырдан соң җир өстеннән мул булып пар күтәрелә. Гази белән Гөлүсә җитәкләштеләр дә үзәнлек буйлап, билдән тиң үләнне чажчож китереп, өмәчеләр янына кайтырга чыктылар. Аяк асларыннан яңгыр суы белән аралашып, бармак араларына эләгеп, өзелгән ромашка һәм башка чәчәкләрнең башлары да очкалый. Күзләрне камаштырып, җәүһәр ташлары сыман чәчрәгән тамчыларда салават күпере хасил була. Ә артларында, юеш болын өстендә, буланган пыяла буйлап агып төшкән тамчылар сызыгына охшап, аларның янәшә эзләре генә кала иде.

Ялан өстеннән, чайкалып торган томан сыман булып, җылы җил шуыша. Баш очларында, шашынып, тургайлар сайраша. Янә кояш чыкты, җиһан ачылды, дөнья яктырды, тирә-юньне сафлык-җиңеллек биләп алды. Шулай итеп нурларга күмелеп җем-җем уйнаклап торган чыклы-томанлы иртәсе белән яңа көн туды.

Бу могжизалы хәлләр булып узганнан бирле күпме гомерләр үтте, күпме сулар акты, чәчләргә чал бәрде, әмма әлеге иң татлы, иң изге, бер үк вакытта газаплы хатирәләре, кабатланмас яшьлегенең иң кадерле ядкаре булып, соңгы сулышына кадәр сакланыр, күрәсең. Шул вакыйгалар исләренә төшкәндә генә дә Газиның күңел түренә кайнар дулкын кагыла, тыны кысыла, йөрәге еш-еш тибә башлый, бөтен әгъзалары тартышып куя. Кинәт тирән сагыш, әрнү, әллә ниткән бер сызланулы ләззәттән, билгесез бер сөенечтән хәтта елыйсы килеп китә. Чөнки бер түгел, ике гомер кичерсәң дә, кабатланмаслык истәлекләргә бәйле иде шул ул көннәр. Һай-й, хыялый яшьлек! Һай-й, шашынкы бәхет мизгеле кичергән чаклар!..

## Дүртенче көн

### I

Автобуста урыныбыз янәшә туры килде. Галина Николаевнаны күрү белән, кәефем күтәрелеп, җаным тынычланып киткәндәй булды. Димәк, Анатолий Степановичның хәле рәтләнү ягына борылган.

Галина Николаевна үзе дә бик мөлаем, ачык чырайлы, төнен тыныч уздырганлыгы, яхшы ял иткәнлеге йөзенә чыккан иде. Әле беркөн генә мин аның күзләрендә күргән тетрәндергеч дәһшәтнең эзе дә калмаган. Операциянең икенче көнендә дә әле аның керфек тирәләрендә ялкынсыну-йокысыз үткәрелгән төн галәмәтләре аермачык булып ярылып ята иде.

Кузгалып киттек. Машина алга ыргый. Ничектер шулай булды, алдан ук сүз куешкандай, әңгәмәбез дә нәкъ шул мәрхәмәтсез төннән башланып китте. Ул низагның нәрсәдән килеп чыгуына ачыклык кертергә, әлеге тәмсезләнүнең серенә төшенергә тырышып карадым. Мин, әлбәттә, телем бик кычытса да, операция ясарга рөхсәт ителмәгән хирург Газиның авылдашы, балалык дусты икәнлегемне әйтеп тормадым.

— Операцияне ясаган сылу ханым сәбәпче түгелме икән?..— дигән булдым мин. Һәм ярым шаярып өстәп тә куйдым: — Гауганың башын хатын-кыздан эзлә ди бит француз мәкале.

— Моны мин дә сизендем кебек,— дип кушылгандай итте Горцева. Аннары шундый фикергә килүенә ачыклык кертүдән бигрәк, расларга телəгәндәй, болай диде: — Хикмәт шул коеп куйган матурда. Башка беркемдә дә түгел. «Яблоко раздора» нәкъ шул булгандыр, минемчә...

Ләкин ул вакыйгага без башка яктан да килеп карадык. Сүзне дәвам итү максаты белән, мин баш врачның хирург Гази хакында: «Үткәне яман, әсирлектә...» — дип, шомлы сүзләр әйтүен дә искә төшердем.

Бу юлы күндәм Галина Николаевна минем белән һич тә килешә алмавын белдерде.

— Белмим, кем ничектер, әмма мин, мәсәлән, сугыш чорында әсирлектә булган дип, кешене гомере буена эзәрлекләү ягында түгел. Безнең законнар катгый, җинаятьчеләрне лаеклы җәзага тарта. Әмма шәфкатьле дә безнең законнар. Күпләргә чын кеше булырга, кабат аягына басарга ярдәм дә итә...— Шулчак Галина Николаевна, эчендәге бөтен тынын берьюлы чыгаргандай итеп әйтә салды.— Һай-й, бу сугышны!.. Нинди генә бәла-казалар китермәде ул безнең халкыбызга?!

Горцеваның башлаган темабыздан чак кына тайпыла башлавын сизү белән, кабат Газины телгә алдым. Сугыштан соң күпме томер үтеп тә җинаятьчеләрнең һаман да табыла торуы, суд алдына бастырыла торулары турында сүз кузгаттым.

— Хирург Хәмзинның гаепләвен үзе дә кире какмады ич...— дидем мин.

— Белмим, белмим!..— дип дәвамлады Галина Николаевна.— Лев Толстой әнә әсирлектә булган Андрей Болконскийны герой дип атый.

— Нинди генә батырлыклар күрсәтсә дә, әсир — әсир инде ул...— дидем мин, үсзүзләнгән булып.

Галина Николаевна бу юлы да минем белән капылт кына килешергә ашыкмады.

— Пленда булып та, могҗизалы батырлыклар эшләгән кешеләрне беләбез бит. Искиткеч күп булды андыйлар.

Ул көнне сәяхәтебез кемгә ничек тәэсир иткәндер, әмма мин бораулаучылар янында үткәргән вакытыбыздан бик тә, бик тә канәгать идем.

## 2

Һади машинаны авылларына җиткәнче үк туктатты. Төшәм диде. Бу хәлне күреп, бераз сәерсенгән шофер егет аңардан акча алып тормады.

Машина таш җәелгән юл буйлап буш кузовын яман доңгырдатып, тузан күтәреп китеп барды. Һади исә биштәрен җилкәсенә салды да олы юл дамбасыннан арыш басуы кырыендагы тар сукмакка төште. Күз күреме җитмәслек мәйданда серкәләнгән арыш басуы дулкынланып ята. Аның җылымса әчкелтем исе борыннарны кытыклый. Никадәр якын, никадәр кадерле ис! Сукмак буенда, арыш сабаклары белән аралашып, күкбаш чәчәкләре утыра. Мул гына тузанга баткан алар. Кояш баю ягына авышса да, бик бөркү иде әле. Юл кырыйлары, сукмак өсләре ярылып-ярылып киткән, димәк, җир яңгыр тели.

Каршыдагы үргә күтәрелү белән, авыл манзарасы да күзгә төште. Иң беренче булып мәктәп бакчасы, зират агачлыгы һәм ферма биналары янындагы силос башнясы күренде.

Авылына бер күз салу белән, Һадигә әллә нәрсә булды да куйды. Туган авылы өстен кинәт кенә кара күләгә каплады. Гүя ул йөзен чытты, аның кайтып килүен күреп йөз чөерде, кара көйде. Караса: ап-аяз күк гөмбәзендә, кояшны каплап, ястык кадәрле генә булып бер ак болыт асылынып тора икән, авыл өстеннән шул болытның күләгәсе шуыша икән...

Шул юк кына нәрсә дә әллә ничек тәэсир итте Һадигә. Адымын әкренәйтте. «Бераз пристань тирәсендә юанасы калган...» — дип уйлап куйды ул, үзенең шулай иртә кайтып төшүенә үкенеп. Якты көздә авылга килеп керәсе килми иде аның. Ничек кенә булмасын, кунактан кайтып килми ич. Аның турындагы гайбәт, имеш-мимешләр әле дә булса басылып бетмәгәндер. Хәтта төрмәдә утыра икән дип тә чыгарганнар лабаса. Шулай булгач ничек итеп кеше күзенә күренмәк кирәк!

Һади адымнарын әкренәйтеп кенә дә калмады, арышны таптап үткән бер эз күреп, шунда борылды. Күкрәк авызына җитеп үскән арышны ерып бераз керде дә, җайлырак урын сайлап, шунда туктады. Башта утырып торды, аннары инде биштәрен баш астына салды да сузылып ятты. Бөтен тәне, тез буыннары рәхәтләнеп китте. Тәмәке кабызды. Яткан килеш берике генә суырды да ташлады. Талгын гына чайкалган башаклар аның өстенә иелеп-иелеп алалар. Һади шуларның берсен тагын да ия төшеп, караштыра башлады. Әйе, арыш та, серкәсен коеп, баш кыса башлаган. Димәк, тиздән уракка да төшәчәкләр.

Тирә-якта тынлык. Күңелне кытыклап, шомлы кыштырдап һәм ниндидер саңгырау авазлар чыгарып, арыш чайкала. Барлык авазларны басып китәргә теләгән кебек итеп, чикерткәләр чырылдый. Шулчак көчәйгәннән-көчәя барган тоташ гөрелте ишетелә башлады. Таш юл буйлап яман доңгырдап, бер-бер артлы ике машина узып китте. Берәр юлаучы очрагандыр ахры, машиналарның берсе, хәтта, сигнал биреп куйды. Ул да булмады, күңелле генә келтерәтеп, тарантаска җигелгән атлы узды. Тарантаста утырганнарның медер-медер килеп үзара сөйләшүләре дә аермачык булып ишетелеп калды.

Яңадан тынлык урнашты. Бу тынлык Һадиның күңелен тынычландырмады, киресенчә, берсеннән-берсе яманрак, берсеннән-берсе шом-

лырак уйлар өермәсен уятты. Уйларны исә бер-бер артлы туып торган сораулар алыштырды. Сораулары да нинди.ләр бит әле, баш житмәслек.ләр. Шул сорауларның иң авыры, иң житдие, әлбәттә: «Ник кайттым мин монда?» — дигәне иде.

Чыннан да, ник кайтты соң әле ул? Нәрсә калган аңар монда? Хәзер инде Айзәрәсе дә юк... Быел май бәйрәме алдыннан гына тормышка чыккан. Һадины көтмәгән. Димәк, яратуы шул чаклы гына булган. Кемдер, мәхәббәтне, аерым торып, вакыт белән сынап карарга кушкан. Вакыт — нәкъ ыргып искән жил кебек икән. Пыскып, шәм кебек кенә булып янып торган зәгыйфь, ялган мәхәббәтне шунда ук сүндерә, юк итә. Ә инде сыналган чын хисне, киресенчә, дөрләп янган ялкынга, хәтәр көчкә әверелдерә, имештер. Эх-х, Айзәрә, шул булдымы вәгъдәләрең?! Фикрәтне генә күр әле син, тәки үзенекен итте бит, сволочь! Этләнсә этләнде, әмма сүзендә торды...

Ә бит төптәнрәк уйлый калсаң, тормышының шулай пыран-заран килүенә Һади бары тик үзе гаепле. Бик күпләрнең төшләренә дә кермәгән бәхет аңа елмайган иде, авылда иң беренчеләрдән булып, университет кадәрле университет студенты булу бәхетенә ул ирешкән иде. Тик бу хәл бик күпләрнең канына тоз салды булса кирәк: көннәрнең берендә Һади авылдан имзасыз хат алды. Анда: «Айзәрәгә өметеңне сузма, ул хәзер Фикрәтнеке...» — диелгән иде.

Шул ук көнне юлга чыкты Һади. Авылына кайтып, Фикрәт белән кара канга батканчы сугышты. Егетләр, кеше-кара күзеннән качып, караңгы тыкрыкка кереп сугышкан дип тормаганнар, кайсы жүнсезедер районга, милиция идарәсенә шалтыраткан. Бөтен гаепне Һади өстенә өйделәр. Кулга алып өч көн буе районда тоттылар. «Утырталар...» — дигән коточкыч сүз дә озак көттермәде. Әле дә ярый район прокурорының өлкән яшьтәге беренче ярдәмчесе Һади әтисенең элеккеге әшнәсе булып чыкты. Соңгы сүзне ул әйтте: «Аттан ала да туа, кола да туа — менә шушы була торгандыр инде. Әтиеңнең абруйлы исеменә тап төшереп йөрисең, ич, жүнсез! Ярар, бер юлга кичерәбез үзеңне...» — дип, Һадины чыгарып жибәрде.

Әмма бу хәл зур бәланең башы гына булган икән: Казанда Һадины университеттан чыгарылуы турында боерык көтеп тора иде инде. И-и гарьләнде, бәргәләнде дә соң Һади! Университеттан документларын да алып тормады, шул көнне үк бер елга килешү төзеде дә Камчаткага китеп барды.

Һади үткәннәр турында уйламаска тырышты, хәзер нәрсәгә дип юкка баш ватып торырга? Кояш баегач, бакча артлатып кына Жәүһәрия жиңгәсенең хәлен белешеп, аңа рәхмәтен әйтеп чыгар да Тажи абыйсы янына нефть районнарына китеп барыр... Жиңгәсенең тормышка чыгып, күп тә тормыйча аерылуы турында ишеткән иде ул. Кем белә, бәлки кабат чыккандыр?.. Һич тә булмас димә. Типсә тимер өзәрлек таза хатын. Үзе матур, үзе уңган. Шундый хатыннар турында бит инде кылны кырыкка ярыр дип әйтәләр. Тормышы житенке. Менә дигән йорт-жире бар. Шуның өстенә бөтен районда дан казанган савымчы. Орден белән дә бүләкләнде. Акчаны да көрәп кенә ала.

...Ул вакытлар бик еракта калдылар инде. Шулай да Һади жиңгәсен кабат күз алдына китереп карады. Гажәп хәл! Жәүһәрия һәрвакытта да аның күз алдына ачык йөзле, мөлаем карашлы, игелекле бер жан булып килә дә баса.

«Һәрхәлдә, бу юлы да куып чыгармас әле...» — дип уйлады Һади жиңгәсе турында. Кем белә, бәлки бу якларга бүтән кайтырга да туры килмәс. Берьюлы шунда әтисе белән әнисенең каберенә дә баш иеп китәр...

Һади шундый уйларга бирелеп ятты да ятты. Кояш баю ягына авышкан саен, арыш башаклары белән шаяручы жил дә тына төште. Бераздан Һади да яткан жиреннән торды. Ашыкмыйча гына өс-башларын каккалап рәткә китерде. Бары тик шуннан соң гына биштәрен жилкәсенә салып, баягы эз буенча олы юлга чыкты.

Авылга җитәрәк, кепкасын тагын да батырыбрак киде дә капылт кына сулга, бакчалар артына борылды. Җиңгәсенә ул бәрәңге бакчасы аша гына керергә булды. Яр буендагы тар гына кәҗә сукмагы буйлап бераз баргач, җиңгәләре турысына җитте. Яңа булсалар да, мал-туар кимерүдән алалы-колалы булып калган киртәләр аша атлап, бакчага төште һәм ике күрше арасындагы ызан буйлап каралтыларга таба атлады.

Җиңгәсенең бәрәңге бакчасы тигез итеп утыртылуы, чиста уталуы белән күршенекеләреннән аерылып тора. Бәрәңге тепләре һәйбәтләп өелгән. Быел бик уңганга охшый бәрәңге, төпләр бик нык яргаланган. Менә каралтылар. Бу терлекләр абзарының түбәсен җиңгәсе белән бергә япканнар иде. Ул вакытта Җәүһәрия сыер асрый иде. Соңыннан инде мәшәкате күп дип, сыерын бетерде, бары тик биш-алты баш сарык белән ике оя каз гына калдырды.

Ишегалды. Аның хәтфә үләненә басып оекчан йөрерлек. Чүп-чар, тирес-салам кебек нәрсәләрнең әсәре генә дә юк бит, ичмаса. Бар нәрсә дә үз урынында, берни дә үзгәрмәгән. Әйтерсең лә исрафка уздырылган ике елга якын гомер бөтенләй булмаган! Һади, тирә-якка күз салгалап, ишек янына килде. Караса, йозак. Фермададыр дип уйлап куйды ул.

Менә ян тәрәзә. Һади, аның янына килеп, тәрәзә төбендәге яран, тамчылы гөл савытлары арасыннан өй эченә күз салды. Каршы якта чипчиста итеп акшарланган мич күренеп тора. Аның кашагасында ялт иткән самовар утыра. Түшәм белән мич башы арасына, күренеп тормасын өчен, челтәрле ак пәрдә эленгән.

Һади, тәрәзә яныннан китеп, яңадан баскыч төбенә килде. Биштәрен элеп куеп, үзе дә шунда утырмакчы иде дә, урамнан үтүчеләр күреп калыр дип, каршыдагы бәләкәй генә җиләк-җимеш бакчасы буена сузып салынган бүрәнәләр өстенә күчеп утырды. Моннан кеше-фәлән күрерлек түгел, җиңел тактадан эшләнгән җилкапка ышыгында ул.

Һади ашыкмыйча гына сигарет чыгарды. Кабызды. Һәм бик тәмләп кенә бер-бер артлы суырып, башын артка ташлап, төтенен һавага җибәрде. Шул, божраланып, өскә таба күтәрелгән төтенгә ияреп, уй-фикер йомгагы да сүтелә башлады...

Һадины сискәндереп, капка келәсе шалтырады. Җил-җил килеп Җәүһәрия кайтып керде. Өстендә җилбәгәйгә җибәрелгән җиңел пиджак. Башында чәчәк аткан көнбагышка охшашлы саргылт-кызыл косынка. Ул аны, колакларын ачып, артка бәйләгән.

Капкадан керү белән, урыныннан күтәрелә башлаган Һадины күреп алды.

— Һади, җаным! Син түгелме соң бу? Син ич... Кайттыңмыни?..— диде дә, йөгереп килеп, үзеннән дә калкурак егетне кочагына алды. Һади җиңгәсенең тыгыз һәм шактый мул күкрәкләренең җылысын тойгандай булды.

Җәүһәрия, бермәлгә онытылып киткән сыман, аны кочагыннан ычкындырмыйча торды. Аннары, кинәт аңына килгәндәй, җәһәт кенә: «Һай-й, җаным!.. Һади ла...» — дип, чак кына артка тайпылып, кунакны яңадан баштанаяк күздән кичерә башлады.

— И-и, Һади!..— дип гөрләде ул.— Олыгайган, әллә тазарып та киткән дип әйтимме? Шаккатам! Үзгәргәнсең... Бик нык үзгәргәнсең.

Моңарчы бер авыз сүз әйтергә дә өлгерә алмыйча торган Һади, ярым шаяргандай итеп, сорап куйды:

— Әллә, начарланганмынмы?..

— Кая ул! Киресенчә, шәбәйгәнсең.

Аннары утта янгандай кызыша башлаган бит алмаларына учлары белән баскалап алды да, тавышын тагын да күтәрә төшеп, Һадины җилтерәтә башлады.

— Нәрсә дип монда торабыз соң әле? Әйдә, әйдә! Син нәрсә, йозакның бикләнмәгәнен белә идең ләбаса. Нигә дип өйгә керең, бераз хәл җыеп, ятып тормадың? Әйдә, әйдә, өйгә керик...

Керделәр. Җиңгәсе Һадига авыз ачарга да ирек бирмәде, һаман үзе сөйләнде. Бер почмак якка, бер олы якка чыкты. Шунда ук чиләге белән су чыгарды, каяндыр чүпләмле киндер сөлге йолкып алды.

— Менә сиңа су. Юынгыч әнә тышта. Чишенеп ташлап, рәхәтләнеп бер юын. Сабыны-мунчаласы шунда. Менә, сөлге. Тик аңынчы бар әле, чормага менеп, каклаган каз алып төшеп бир. Эрерәген, симезрәген карап ал. Чиста киемнәрең бармы? Булмаса, өстеңнән салганнарны тиз генә юып бирермен. Ә мин хәзер сиңа ашарга әзерли торам. Хәзер әллә ни иркенәя алмам, кичке савымга барасым бар. Билгеле, анда озак булмаска тырышырмын. Өйрәнчек кызым бар. Бик тиз тотарбыз...

Ул пошкырына-пошкырына юынган арада, Җәүһәрия дә шул тирәдә чуалды. Бакчадан төпләп кенә яшел суган йолкып чыкты, җил-җил килеп, келәткә кереп китте. Анда да әллә ни тормады, ялт итте дә кире чыкты. Һади янынннан үткәндә барыбер теле авызына сыймады, тагын сорау биреп куйды.

— Кара әле, Һади... Баядан бирле сорарга итеп торам. Бөтенләйгә кайтуыңмы?

— Бөтенләйгә. Бер ел үтте бит,— диде Һади, сабынлаган йөзен Җәүһәриягә таба борып.— Килешүем шулай иде.

— Бигрәкләр генә дә шәп булган инде.

Һади, юынып, өс-башын алыштырып өйгә кергәндә, Җәүһәрия тырыша-тырыша, каклаган каз турый иде. Өстәл уртасында зур гына таба белән йомырка тәбәсе чыжылдап утыра. Шунда ук тау кадәрле итеп юып өеп куйган яшел суган.

— Әйдә, Һади, утыра башла... Хәзергә кыты-мыты белән карын ялгап алгандай ит тә, кичкә берәр төрле таба ашы әзерләрмен...— Читтәрәк торган яртыны кулына алды, әмма Һади алдына куйгалаганчы, он утырган шешәне тастымал белән һәйбәтләп сөртештерде.— Келәттә саклана иде. Тегермәнчегә охшап калган, хәерсез!

Бу чагыштыру үзенә дә ошады ахры, кинәт кенә буынсыз булып бөгелә-сыгыла рәхәтләнеп көлеп алды.

Шул вакыт Һади искәрмәстән генә сорау биреп куйды:

— Әйт әле, җиңги... Кайтып борчыган өчен ачуланмыйсыңмы?

Җәүһәрия йөзендәге нурланып елмаю-көлүне җил тузгыттымыни?! Ул кинәт житдиләнде. Аннары: нигә шундый юк-бар сораулар белән рәнҗетәсең син мине, дигәндәй тезә дә башлады:

— Шыр тиле икәнсең син, Һади... Шаккатам! Шундый сүзләр әйтергә ничек телең әйләнә? Әйтче зинһар, сездән башка кемем бар минем? Бер генә кешем дә юк ләбаса. Бу турыда син дә беләсең ич...— Аннары кинәт тавышын күтәреп тезеп китте.— Эх-х, Һади җаным! Белмисең генә. Абыеңның ташлавына да ул хәтле уфтанмыйм. Аны барыбер тота алмаган булыр идем. Җаны теләгән елан итеп ашаган ди. Мин тиң түгел шул аңар. Урын-дәрәҗәне бик ярата иде шул. Шулай да үкенечем бар... Бала булмады. Балалы булып кала алмавым гына үзәкләремне өзә. Нәрсәдән шикләнгәндер, белмим. Сакланды шул. Сакланды... Ана булу назын бирмәде. Җәлләде. Алимент-фәлән сорар дип курыккандыр бәлки. Кая ул! Сорар идемме соң! Акча гарипкә тансык ди. Минем бит үземнеке артып ашкан... Һай-й, яман ла ялгыз яшәүләре! Баласыз хатын — җимешсез агач кебек бит ул, берәүне дә куандырмый. Бөтен нәрсәм житенке, бар да бар, тик менә балам гына юк. Шул гына үзәкләремне өзә. Төшләремдә бала белән саташып бетәм...

Җиңгәсе сөйләнгән арада, бер чокыр аракы эчеп куйган Һади, каклаган каз кисәге кабып чәйнәп йотты да, янә кинаяле генә итеп сүз кыстырып куйды.

— Жиңги... Әгәр дә хак булса, сине тормышка чыккан дигәннәр иде ич.— диде. Һади бу сүзләрне бик гади итеп, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән әйтергә тырышты.

Җәүһәриянең дә әллә ни исе китмәде.

— Булды андый хәл,— диде ул тыныч кына итеп.— Йортка керткәндәй иткән идем берәүне. Әлеге дә баягы, ана була алмаммы дип өметләнү иде. Юк, булмады. Бер җүнсез нәмәстә булып чыкты, эчүдән бушамады. Ә исерек баштан, гадәттә, җинаять кенә эшләнә... Аннары, дөресен генә әйткәндә, тәнем тартмады. Бөтен уй хисләремне, хыял-максатларымны, мәхәббәтемне абыең үзе белән алып китте, күрәсең. Уйладым, уйладым да, мондый ир белән торганчы, сагышлы-моңлы тол хатын булып калу мең кат артык дидем дә аерылдым.

Җәүһәрия кинәт кенә бик әһәмиятле нәрсә исенә төшкән кыяфәт белән, табынны рәтләде дә:

— Кая әле, мин тиз генә камыр башы ясап куйыйм,— дип җәһәт кенә кече якка кереп китте. Бераздан аның иләкне таңы-топы китереп, он иләгәне ишетелә башлады.

Һади җиңгәсен бер дә кече якка кертеп җибәрәсе килмәгән иде. Ул аңардан Айзәрә турында, аларның тормыш-көнкүрешләре турында сорашмакчы иде. Бераз башына киткәч, бу теләк тагы да көчәйде, тел очына чак кына эләгеп тора башлады. Әмма ул, теләген җиңеп, бөтенләй башка нәрсә турында сорап куйды.

— Җиңги!.. Дәү абыйдан хәбәр-хәтер юкмы? — диде ул.

Җәүһәрия эшеннән туктап җавап кайтарды:

— Бар. Тел төбеннән — бәлки әле туган якларны да бер әйләнермен дигән мәгънә аңлашылды. Һәй-й, кайтсын иде!..

Һади җиңгәсенең эштән туктавыннан файдаланып, тагын сорау бирде.

— Монда, авылда нindirәк яңалыклар бар соң?..

— Яңалык дип, ул кадәр искитмәле әллә ни зур үзгәрешләр юк. Айзәрәне тормышка биреп куйдык... Шул булды менә яңалык.— Һадиның дәшмәвен, сүзне дәвам итәргә теләмәвен сизенепме, Җәүһәрия онлы кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, олы якка чыкты. Өстәл янына житкәләгәнче үк сөйләнә башлады: — Син, Һади, үпкәләмә аңар. Гаепләмә аны. Тормыш бу... Ә тормыш, белгәнеңчә, бик катлаулы. Һәй-й, катлаулы! Уйлап кына кара, кулында ярты гәүдәсен паралич суккан авыру әнисе. Эше, тегесе-монысы, шуның өстенә мең төрле мәшәкать. Ифрат та авыр булды Айзәрәгә. Ә Фикрәт аңар төрлечә ярдәм итте. Больницага-фәләнгә илтергә кирәк булганда, әтисенең машинасына кадәр алып биргәләде. Кирәккәндә бит әле аның тиешле даруын да табып булмый. Ә Фикрәт барысын да тапты. Хатын-кыз күңеле балавыз кебек бит ул, ягымлы җылылыкны аерүча тоючан була. Гыйнвар аеның чатнама бер көнендә әнисе үлеп китте. Айзәрә ялгыз калды. Төннәрен өендә кунарга да курка башлады. Эх-х, Һади! Белмисең шул. Ул түгел, минем күрше-күләнгә кереп кунарга житешкән көннәрем була...— Аннары Һадиның күзләренә сынаган сыман текәлеп карап торды да капылт кына сорау бирде.— Күрешергә телисеңме соң? Айзәрә белән дим...

Һади: «Ә ул теләрме соң?» — дип сораудан чак кына тыелып калды. Әле дә ярый җиңгәсенең сүзе бетмәгән икән.— Хәзер без кичке савым вакытында очрашабыз... Ул да, Һади, сине оныта алмый. Нәселегез белән шундый бит сез. Хак әгәр! Әллә инде сөйкемле сөягегез бар? Мескен Гази абыегыз гына бәхетсез булды. Әле дә булса халык арасында аның язгы ажаган күргәнлеге турында сөйләштергәлиләр...

Җәүһәрия вак-төяк өй эшләрен караштырды да фермага китәргә җыена башлады. Иң элек ул ялт итеп электр утын кабызды. Тәрәзәләрнең пәрдәләрен тарткалап чыкты. Үрелеп, кунак турысындагы ян тәрәзәнең пәрдәсен каплаганда, Һади кабат кул башы белән җиңгәсенең күлмәк изүләрен төртеп торган күкрәкләренең тыгызлыгын тоеп калды.

— Чакырып карыйм алайса?..— дип кабат сорады Җәүһәрия. Бу сүзләрне әйткәндә, аның ансыз да сылу, ансыз да күркәм йөзен бизәп торган озын керфекле сөрмәле күзләре бермәлгә Һадинықылар белән очраштылар.

Һади күзләрен читкә алды. Шулай да җилкәләрен җыерып, бер генә сүз әйтеп куйды:

— Килсә...

— Чакырсам, килә,— диде җиңгәсе, сүзенең барыбер өстен чыгачагына бик нык ышанган кебек итеп.

Җәүһәрия чөйгә эленгән пиджагын йолкып кына алды да: «Мин әллә ни озак булмам» — дип чыгып та йөгерде. Аның артыннан капка келәсенең шалтырап бикләнүе генә ишетелеп калды.

Һади чокыр төбендәге аракысын эчте дә, кәлтәсе белән юып куелган суган өеменнән бер төбен алып, тозга манып, шалканланган башына шатырдатып тешләрен батырды. Урыныннан торып ишекле-түрле йөренеп килде. Аннары, нәрсәдер исенә төшергән сыман, ишекне яртылаш ачып куеп, уң якта торган диванга килеп утырды. Сигарет чыгарды. Бармак арасында һәйбәтләп әвәләде дә авызына капты. Кабызды. Бик тәмләп бер-ике тапкыр суырды. Сигарет пачкасы белән шырпысын сузылып кына тәрәзә төбендәге гөл чүлмәкләре арасына куйды. Уй-фикере әле һаман да бер тирәдәрәк болгана иде аның...

«Килерме, килмәсме?.. Әгәр дә мәгәр чыннан да килсә?..— Һадины ниндидер бер киеренкелек, дулкынлану хисе яулап алды. Ничегрәк итеп күрешерләр икән? Шулай да, ни күзләре белән күренә алыр икән ул Һадига?»

Һади, бөтен барлыгын яулап алган бу уйларыннан арынырга теләгәндәй, урыныннан торды, тагын ишекле-түрле йөренеп килде. Тәмәке дә бер-ике суыру белән күңеленә тиде. Аннары инде җиңгәсенең тиз генә кайтачагына өметен җуя бушлап, җыеп куелган караватӂ янына килде. Баш-башына икешәрдән аслы-өсле өеп куелган, челтәр белән капланган мендәрләрнең берсен алып диван башына салды да сузылып ятты.

Әмма озак ятырга туры килмәде. Тышкы баскыч төбендә аяк тавышлары ишетелеп, корт чаккандай торып утырды. «Капкадан кермәделәр. Бакча артлап кына кайттылар. Димәк, Айзәрә дә килгән...» — дигән уй чагылып китте Һадиның башында.

Беренче булып ишектән Җәүһәрия керде.

— Менә, без кайттык та...— диде ул бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. Һәм шунда ук, ишекне тагын да киңрәк ача төшеп тезеп тә китте.— Әйдә, әйдә, Айзәрә! Кер. Зимагорны күреп чык инде. Менә ул...

Һади җәһәт кенә үрелеп, сүнгән сигаретын тәрәзә төбенә куйды. Һәм кыяр-кыймас кына кереп килүче Айзәрәне күреп, баскан урынында ташташтай катып калды.

— Исәнме, Һади!..— диде Айзәрә, ишек катында туктап.— Кайттыңмы?..

— Исәнмесез, Айзәрә!.. Кайттым менә.

Һади үзен шулкадәр каушар, шулкадәр югалып калыр дип, һич кенә дә уйламаган иде. Җитмәсә тагын күрешкәндә үк «сез» дип дәшүе, аннан соңгы сүзләренең дә ятышсыз, урынсыз чыгуына уңайсызланды, җир тишегенә кереп китәрдәй булды. Шунда ук ул үз-үзен эченнән сүгеп, тиргәп алгандай итте. «Эх-х, син, малай актыгы! Син түгел, ул каушасын, ул тетрәнсен каршыңда...»

Җиңгәсе аның уйларын бүлде.

— Ярар, сез сөйләшә-серләшә торыгыз. Минем чак кына караштырасы эшләрем бар,— дип чыгып китәргә җыена башлады. Әмма ишек тоткасына кулын салгач кабат туктады.— Менә нәрсә. Кеше-караның күз салып үтүе бар... Ут янмасын әле,— дип рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, черт иттереп, утны сүндереп тә куйды. Һәм үзе, бу ярамаган адымы өчен шелтә сүзе ишетүдән курыккан сыман, каерып ишекне ачты. Анда

да әле сүзе бетмәгән булган икән.— Тартынып-нитеп утырмагыз... Өстеңездә йозак булыр,— диде дә үзе артыннан ишекне япты.

Киеренке тынлык урнашты. Тик озакка түгел. Айзәрә искәрмәстән генә аркасына төртеп җибәргән кеше сыман: — «Һа-ди!..» — дип, егетнең муенына килеп сарылды. Ул елый иде. Бераз үксегәч, сүз әйтер халәткә килгәч, әйтергә теләгән сүзләрен әйтеп бетерә алмаудан курыккандай, ашыгып-кабаланып тезә башлады.

— Һа-ди!.. «Көтүең шушы булдымы?!» — дип битәрләмә. Кичер син мине... Бу адымымны мин барыбер ничек тә аңлата алмам. Әни үлгәннән соң, әллә ни булды миңа... Миңгерәүләнеп киттем димме?.. Тормыш, ничектер, мәгънәсез бер нәрсәгә әверелеп калгандай булды. Эх-х, Һади! Янымда син дә юк идең бит, ичмаса! Син генә булсаң да...

— Тынычлан! — диде Һади, аны юатырга теләп.— Тынычлан... Хәзер үткән бит инде. Әйдә, утырып тор...

Алар диванга утырдылар. Айзәрә Һадиның күкрәгенә тагын да елыша төшеп, егетнең ияк, муен тирәләрен үбеп алгандай итте. Ә үзе, сүз югында сүз булсын дигән кебек итеп: «Димәк, кайттың?.. Бик һәйбәт, Һади... Бик әйбәт...» дип тәкрарлап алды.

— Үзең ничек соң? — Бу сорауны Һади бирде.— Тормышың ничек? Канәгатьсеңме?

— И-и, Һади! Сорама инде... «Бәхетлеме?» — дип тә сорарсың әле тагын. Бар, яулап кара син ул бәхет дигән нәрсәне. Юк инде! Булмады. Һай-й, булмады, Һади бәгърем!..

— Зарланма! — Егетнең тавышы шактый кырыс иде.— Сиңа аны көчләп такмадылар. Ташла! Нечего шыңшырга!.. Әллә миңа җиңел булды дип уйлыйсыңмы? Булыр, бар көт... Шуңар күрә чит-ят җир диләр аны. Өстәвенә кияүгә китү хәбәрең. Акылыма зәгыйфьлек килә микән әллә дип торам. Син бит мине белә идең. Мин сине, барыбер үземнеке була дип... күз карам кебек саклаган идем.

— Беләм, беләм, Һади. Зинһар, үзәкләремне өзгәләмә! Барысын да беләм...

— Урманда кунуыбызны... Печән куышын!.. Үлгәндә дә онытасым юк минем.

— Мин дә хәтерлим, Һади!..

Әйе, ул хәтерли иде. Андый истәлекләр тиз генә онытылмыйлар алар.

Айзәрә, егетнең муенына сарылды да ничектер елаган сыман тавыш белән тезә дә башлады.— Эх-х, Һади! Әллә мине үкенми дисеңме? Үзеңнеке генә итәсең калган... Аңар карап, барыбер җүнле сүз ишетмәдем. «Һади калдыгы...» булды минем исемем. Хәер, ул кадәресендә үземнең дә гаебем бар. Сине оныта алмауда иде гаебем. Кул күтәреп, эт итеп кыйнауга кадәр барып җитте... Әле дә хәтеремдә, иң әлек урыннан тибеп төшерде, аннары уңлы-суллы яңаклап йөземне кара көйдереп бетерде. Кеше күзенә күренерлегемне калдырмады...

Һади, еш-еш сулыш алып, тешләрен шытырдатып куйды.

— Ах-х, сволочь!..

Айзәрә, Һадины кирәкмәгән, ярамаган адым ясаудан йолып калырга теләгәндәй, егетнең терсәкләренә ябышты.

— Тимә аңар! Аның урынында теләсә кем шулай итәр иде. Онытылып китеп, ялгышып, үзен: «Һа-ди-ым!..» — дип атаганмын. Эх-х, Һади! Белмисең хәлләремне! Уйларымнан бер генә минутка да чыкмадың. Күз алларымда тоттым үзеңне. Ниһаять, менә, яңадан син... Минем янымда. Ышанырга да, ышанмаска да белмим. Синме соң бу, Һади?

— Мин, Айзәрә...

Айзәрә кайнарланып-шашынып яңадан Һади кочагына елышты, иреннәреннән, муеннарыннан үпте. Егет тә кинәт кенә ихтыярын җуйгандай булды, уй-фикерләре томаланып китте. Ниндидер тыелгысыз теләк, тетрәткеч хис иркенә бирелеп, кочагындагы хатынны, буып үтерердәй итеп, күкрәгенә кысты. Куллары белән сыйпаштырды. Кулы астында Ай-

зәрәнең кайнар тәнен, чак кына дымлы култык асларын, тәмам җитлеккән тыгыз күкрәкләрен тойды. Һаман да шашынып иреннәреннән суырып үпкән Айзәрәне, кочагыннан ычкындырмыйча гына, диванга яткыра башлады...

Хатын карышмады, җаны-тәне белән тагын да ныграк елыша төшеп, егетнең ихтыярына бирелде. Аннары, кайнар сулышы белән Һадиның муен тирәләрен өтәләп, әкрен генә пышылдады:

— Һади... җаным! Бәгърем!..

3

Юк, Гази белән Гөлүсәгә кавышырга насыйп булмаган икән, тормыш дигән мәрхәмәтсез нәрсә башкачарак хәл итте аларның язмышларын.

Алар өйләнешәсе елның көзе бик ямьсез килде. Декабрь азагына кадәр кар ятмады. Тагын дәһшәтле егерме беренче ел кабатланыр микәнни дип, халык пошаманга төште. Кар яумаган елны мал-туар да үрчеми имештер.

Нәкъ менә шундый пошаманлы көннәрнең берендә, бик күпләрнең якты өметләрен өзгән, хыял-максатларын пыран-заран китергән яман хәл булды: халык теленә «авыл хәбәрчесе» дигән абруйлы аты чыккан Үшән Халәпне үтереп ташладылар. Гәүдәсен су буена төшә торган караңгы тыкрыктан — Иргалиләрнең коймасы буеннан табып алдылар. Заманында волость дип йөртелгән, хәзер инде район үзәгенә әверелгән Чаллыдан көне-сәгате белән прокурор һәм милиция вәкилләре килеп җитте.

Тикшерүләр башланды. Бик җентекләп инәсеннән-җебенә кадәр казындылар. Күбрәк Иргалиләр өе тирәсендә чуалдылар. Бу хәлнең бик үк ошап бетмәгәнлеге өй хуҗасының йөзенә чыккан иде. Иң беренчеләрдән булып ишегалдына бәреп кергән, кызыл кырпулы фуражка кигән милиционер, моны сизенеп, Иргалинең йөзенә сынаган сыман итеп карап торды да:

— Безнең шулай ачы таңнан килеп керүебез кәефегезне кырды ахрысы? — дигән булды.

Чак кына ят булып тоелды милициянең сүзне болай башлавы. Әмма Иргали бер дә читләп-сипләп тормады, күңелендәген чалт та чолт иттереп әйтте дә салды.

— Белмим, сезне күрү шатлыгыннан кем генә үрле-кырлы сикерер икән соң?

Тегесе ирен читләре белән генә елмайгандай итте.

— Һе-е! Кызык әйттегез...

— Юләр сүзгә йөгән юк, ди бит.

Ул арада тыкрык буенда, бакча эчендә тыз-быз килеп, адымлап нәрсәдер үлчәп йөргән вәкилләрнең берсе, тыны-көне бетеп, Иргали янындагы милиционер янына йөгереп килде. Кулында канга буялган чүкеч иде. Әлеге вәкил чүкечне бик мәзәк итеп, ажгырып торган зәһәр еланны койрыгыннан аскандай, ике бармагы белән генә чеметеп кулына алды. Чүкеч җил дә очып үтә алмаслык утыртма койма буендагы карлыган куагы төбеннән табылган икән. Иң әүвәл шул урынны барып карадылар. Янына наган таккан, арада үзен өлкән итеп тоткан әлеге кызыл кырпулы фуражка кигән милиционер, күзгә күренеп үзгәрде, кулына бирни белән дә кире кагып булмый торган дәлил төшергән сыман, тавышына кадәр кырысланды аның. Шундук үзләренә ияргән Иргалигә сорау артыннан сорау бирә башлады.

— Чүкеч кемнеке?

— Безнеке,— диде Иргали.— Менә тамгасы да бар...

Иргалиләрнең сажинга охшаган сурәт өстенә ике сызык сызылган тамгасы авылда һәммә кешегә дә мәгълүм иде.

— Тамгасын да үзегез суккан идегезме?

— Юк. Тамганы Рәхимҗан сукты.

— Анысы кем тагын? Хезмәтчегезме?

— Юк. Хезмәтче тотмадым. Рәхимҗан — безнең туганыбыз, ягъни киявебез.

Тинтерәткеч сорауларга җавап бирергә генә өлгер.

— Чүкечегез кайда саклана иде?

— Кайда дип... Гадәттә лапас астындагы киштә-шүрлектә. Балта, пычкы, ышкы, келәшчә ише җыен вак-төяк шунда саклана. Яки чүнниктә...

— Берәрсе алып тормадымы соң? Чүкечегезне дип соравым?

— Кем хәтерләгән инде аны,— диде Иргали, әллә ни исе китмәгән, ваемсыз бер кыяфәт белән.

Әмма район милиция идарәсе вәкиле тавышын моңа кадәр ишетелмәгәнчә җитдиләндереп, хәтта кырысландыра төшеп, аяусыз рәвештә раслап куйды.

— Бу бик җитди мәсьәлә, әйтер идем, ифрат зур дәлил. Безнең кулда кеше үтергән корал... Аңлыйсызмы шуны?..

Беренче авыздан «Үтерү» сүзен ишетү Иргалинең курку белмәс йөрәгенә беренче кат борчу өеткысы салгандай итте. Ул бары тик: «Коралларны гадәттә Рәхимҗан тота иде»,— дип кенә әйтә алды.

Ишегалдына кайттылар. Җилтерәтеп кенә Рәхимҗанны чакырып китерделәр. Канга буялган тамгалы чүкечне күргәч тынсыз-өнсез калып, коелып төште ул. Соңгы тапкыр кайчан тотканлыгын исенә төшерә алмыйча газапланды. «Бу бик әһәмиятле мәгълүмат булачак, исегезгә төшерергә тырышыгыз»,— дип тинтерәтә башлагач, «Соңгы атна-ун көн эчендә кулыма корал тотканым булмады»,— диде. Дөньялардан китәр дәрәҗәгә җитеп курыккан Рәхимҗан шуннан гайре әйтер сүз таба алмады.

Ул арада мәет тирәсендәге тикшеренүчеләр яныннан да берәве килеп җитте. Үтергәндә Халәпнең башына бөркәлгән арыш капчыгына да кара буяу белән нәкъ чүкечтәге төсле тамга сугылган булуы турында хәбәр китерде ул.

Менә шунда наган таккан милиционер үзенең кырыс-катгый сүзен әйтте.

— Сезгә хәзер үк безнең белән барырга туры килер...— диде ул.

Бары тик шушы шыксыз әмердән соң гына, Иргали ешрак тибә башлаган йөрәгенә үзәккә тиярдәй салкын шом, кара күләгә үрләвен сизде. Бар шатлыгы, бар дәрте кинәт кенә сүрелгән кебек булды аның.

— Кая? Озаккамы?..— дип сорады Иргали, әкрен һәм дәртсез тавыш белән.

— Хәзергә авыл Советына. Калганын прокурор хәл итәчәк. Нинди санкция бирсә, шулай булачак.

Әлеге вакыйганың шушындый борылыш аласын башына да китермәгән Иргали, рухы сынып, ихтыяры какшагандай булды. Аны алып китәргә җиенулары өйдәгеләргә дә минуты белән барып җиткән иде. Болдырга чыгып баскан хатыны Гөлнисаны калтырау алды, һәм аның бернинди тартынусыз:

— Монысы нинди җәза тагын?!. Ниткән гөнаһларыбыз, кайчан кылган языкларыбыз өчен?.. Я-а, тәңрем!..— дип илереп җылый башлавыннан Иргали тетрәнеп китте.

Әнисенең иңенә авып төшеп, Гөлүсә елый. Шунда ук, болдыр янында, кай арададыр баласын алып чыгып өлгергән Миңсылу тора. Ул да аптыраган бер кыяфәттә иде.

Бу хәлләрдән соң Иргалинең тузан бөртеге кадәр генә шик-шөбһәсе кинәт кенә таудай булып үсте дә китте. Ул: «Дөньяныкын белмәссең»,— дип, җәһәт кенә өстенә гадәттә кия торган туның киеп чыкты. Каушаугалу галәмәтедер инде, тун каптырмаларын таба алмый азапланды. Ә үзе һаман сөйләнде, һаман баскыч буена җыелган хатын-кызларны тынычландыру сүзләре тәкрарлады.

— Зинһар, борчыла күрмәгез. Бар да һәйбәт булыр. Бу бер аңлашылмаучылык кына, вакытлыча хәл... Кем ышансын ди андый тузга язмаган мәгънәсез нәрсәләргә?.. Минә хәзер авыл Советына гына барып киләбез дә, әйләнәм дә кайтам...— Иргали кызыл кырпулы фуражка кигән милиционерны ярдәмгә чакыргандай, аңа мөрәҗәгать итте: — Агай-эне, әйт әле шуларга!.. Авыл Советына гына барабыз, диген...— Шундук тавышын күтәреп җикеренә үк башлады.— Я-ә, кемгә әйттеләр! Живо тынычланыгыз! Житте диләр сезгә!..

Коралды кешеләр арасында урам уртасыннан авыл Советына кадәр утүләре сират күпере кичүләре белән бер, үлемгә тиң булды Иргалигә. Башы тәмам исәнгерәде. Үзен яман төш күргәндәгедәй хис итте ул, аяклары атласа да атлады, атламаса да атлады. Тәмам катып киткән башында берсеннән берсе яманрак уйлар. Күр инде, ә!.. Адәм хурлыгы бит. Нәсел-нәсәптә булмаган хәл. Бу түбәнлекләргә, хурлыкларга ничекләр итеп түзмәк кирәк?!

Башта чыш-пыш кына, имеш-мимеш кенә башланган сүзләр, Иргалинең кулга алынуы турында хәбәр таралгач, кинәт чынбарлыкка әйләнгәндәй, расланган булды. Шундук бернинди тартынусыз: үтерүдә Иргали гаепләнә икән дип, авыз тутырып, төкерек чәчәргә керештеләр. Озын сыйраклы бу хәерсез хәбәр, кара гайбәт сәгате-минуты белән бөтен авылны бер итеп, әллә ничә кат әйләнеп чыкты. Әлеге адәм әйтеп адәм ышанмаслык яман хәбәр аяз көнне күк күкрәп яшен суккандай тәэсир итте авыл халкына.

Иргали башына ишелеп төшкән бу дәһшәтне төрле кеше төрлечә кабул итте. Күпчелеге, әлбәттә, ышанмады: кешегә игелек, изгелек кылудан башканы белмәгән турылыклы, саф иманлы кешене бер дә юкка харап итмәсләр, андый заманнар үтте, хәзер Совет власте диделәр. Иргалинең мөлкәтеннән, дәрәҗәсеннән, көченнән, гомумән, төбәкнең мәшһүр кешесенә әверелеп яши башлавыннан көнләшеп: «Ә-ә, шулаймы! Гердәдән кенәз булганны күптән бер төнәтергә кирәк иде инде... Менә килешкән. Гайрәтенә сугып, кикриген шиңдерсеннәр әле бер. Шулай ул: шеш кайчан булса да бер тишелә ул! Хәрамнан килгәнне тормыш һәрчак каза белән түләтә!..» — дип, ачыктан-ачык тантана итүчеләр дә булмады түгел. Илдә илле, берсеннән-берсе җилле, дигәндәй, нинди генә затлар юк дисең син бу фани дөньяда.

Ниһаять, үлгән Халәпнең дә исеме телгә керде: «Юраганы юш килүен күрче мөртәтнең... Үлгәч чынлап торып кеше рәтенә, кеше санына керде чукынмыш, бөтен районны аякка бастырды. Әнә ничекләр итеп бииләр...»

Конвой белән китерелгән Иргалине, хәзергә шушында утырып торыгыз дип, ишегә янында үрә каткан мылтыклы солдат торган кечкенә генә бүлмәгә китереп яптылар. Авыл Советында мондый бүлмәнең барлыгын ул белми дә иде. Түрдәге нечкә бүрәнәләрдән салынган янкорманың ике генә бүрәнәсен уеп эшләнгән тәрәзә буена, эскәмиягә барып утырды Иргали. Бүлмә эче ярым караңгы иде. Иргали, чебен кунудан, тузан басудан пыяласы каракучкылланып беткән тәрәзәгә күз салды. Аннан янгын каланчасының насос-мичкәләр беркетелгән арбасы, шул арба торган каралты һәм стена буенда котырып үскән сукыр кычытканның киндернекенә ошаган биек сабаклары гына күренә иде.

Я-а, ходай! Нигә уйландыра да, нигә шомландыра икән шул чаклы! Кем әйтмешли: утсыз, төтенсез, кинәт ялкын. Шул мизгелдә Иргали күңелен яулап алган болгавыр уйларының көчәюен, йөрәгенә бозлы салкынлык үрмәләвен ачыграк, ныграк тойгандай булды.

Әмма аны әлеге тынчу, тычкан тизәге исе аңкып торган кысан бүлмәдә озак тотмадылар, сорау алырга керештеләр.

Авыл Советындагы Бәһрам җизнәсе утыра торган иң зур бүлмәне кай арада тикшерү, сорау алу урынына әверелдереп өлгергәннәр диген син. Артык нәрсәләрдән җилләр искән. Түрдәге ике өстәлне бер итеп яшел постау белән япканнар. Аның артында салкын, битараф бер кыя-

фәттә прокурор һәм район милиция идарәсе начальнигы Сабиров утыра. Иргали аны күреп-танып белә иде. Советка кадәр озата килгән милиционер да шунда.

Иргали, тәбәнәк ишектән иелеп килеп керү белән, барысын да берьюлы сәламләде. Аңа ишарәләп бүлмәнең урта бер җирендә торган урындыкка утырырга куштылар. Шундук сорау артыннан сорау яудыра да башладылар, җавап бирергә генә өлгер. Сорау белән җавап арасында хасил булган бер генә мизгел тынлыкта тәрәзә буендагы сыңар өстәл артында утырган таныш түгел бер күзлекле егетнең каләме шыгырдаганы аермачык булып ишетелеп кала. Сораулар бик ерактан, ата-бабаларны телгә алудан башланды. Алар кемнәр булганнар? Күпме имана җире биләгәннәр? Иргали үзе революциягә кадәр һәм революция елларында кайда булган? Патша армиясендә пехота полкының 11 нче ротасында рядовой булып хезмәт итүләренә кадәр теркәп куйдылар. Әйткән кадәресе документлар белән расланамы? Сүз әкренләп авыл хәбәрчесенә, үтерелгән Халәпкә күчте. Аның белән үзара мөнәсәбәтләре нинди булган?

Халәп турындагы сүзен Иргали уенга сабыштырган сыман итеп җаваплады:

— Мин аның турында авыз чайкарга да теләмәс идем.

Арада иң битараф кеше — прокурор иде. Хәрәкәтләре салмак — дәртсез, нииндидер ифрат зур эш башкарудан хәле бетеп, тәмам алҗыган бер кыяфәттә утыра бирде. Сүзләре дә артык тонык-җансыз. Күз карашында да җан өшеткеч битарафлык. Үзе болай карап торырга шәп: тыгыз-таза буй-сын, ыспай-җыйнак киемнән.

Менә ул башын калкытты. Иргалинең хәтерен калдырудан курыккандай, йомшак кына, иплә генә итеп янә сорау бирде.

— Бу фаҗига булган көнне кайда идегез?

— Өйдә идем.

— Нәрсә эшләдегез?

— Көндәлек эшләр, зарури шөгыльләр белән мәшгуль булганмындыр инде. Бетәсе-нитәсе юк крестьян тормышында эшнең...— Иргалине җавабы канәгатьләндерә алмады. Һәм менә нәтиҗәсе.

— Кияү тиешле кешегез...— прокурор алдында яткан кәгазьгә күз төшереп алды.— Исеме Рәхимҗан бит әле?

— Әйе.

— Ул сездә кайчаннан бирле яши?

— Өченче ел.

— Аңынчы шул кадәр зур хуҗалыкны ничек итеп алып бара идегез соң?

— Барылды инде. Авыр булса да түздек.— Иргали елмайгандай итте.— Мөгезе авырлыктан үгез зарланмый ди бит, тарттык инде.— Бу юлы да җавабының рәте-чуты булмавын сизенгән Иргали, төзәтеп өстәп куясы итте.— Өй күтәргәндә, каралты салганда, осталар яллаадым. Җиңелгә килсен өчен, көнлекләп түләдем. Ә инде урак уру, эвен сугу ише сезонлы эшләр китереп кысканда, өмә ясадым.— Ул: «түләвеннән тормадым, өмә саен тояклы мал суя идем, шунлыктан кешеләр бик теләп киләләр иде»,— дип тә өстәмәкче булса да, бөтенләй үк туарылып-чишелеп китәргә ярамас диеп, бу уеннан кире кайтты. Шулай да әйтте.— Андый вакытта, үзегез беләсез, килү-китүләр, чыгымнар белән санашып тормыйсың. Заманы шундый, бер эш тә әҗерсез булмый...

Прокурор, айнып киткән кеше кебек, кинәт үзгәрде, тавышы да кырысланганнан кырысланды. Менә ул, Иргалинең дошманнары булу-булмавы белән кызыксынды.

Дулкынлану хикмәтедер инде, Иргали канәгатьләнерлек җавап таба алмады, бары тик: бу турыда, ничектер, уйланылмаган, дип кенә әйтә алды.

— Күренеп тора, сез күп нәрсә турында уйламагансыз...— Прокурор бу сүзләрне үтә җитди итеп, тел төбенә ниндидер кинаяле мәгънә салып әйтте.

Янә сорау.

— Бу җинаять турында сез нәрсә әйтә аласыз?

— Бер сүз дә әйтә алмыйм,— диде Иргали кырт кисеп.— Тегеләйболай диярлек дәлилләрем дә, вакланып йөрергә вакытым да юк...

Тагын да конкретрак сорау:

— Шул җинаятьтә үзегезне гаепле саныйсызмы?

Бу салкын, кырыс тавыш белән искәрмәстән бирелгән сорау үзенекен итте, башына күсәк белән китереп тондырылган кешедәй, Иргали бермәл миңгерәүләнеп калды.

— Юк! — диде ул катгый-кырыс тавыш белән.— Нахак бу. Гаепсезгә гаепләү. Аның белән, ул беткән җан белән кулымны пычратаммы соң!

— Бу аклану түгел.

— Гаепле кеше аклансын...

Иргалинең киреләнеп, үзсүзләнеп маташуы һич кенә дә аның файдасына түгел иде. Моны прокурорның кыяфәтеннән дә күрерлек иде.

— Хода бәндәсе!..— диде ул, тавышын әллә ни күтәрмичә генә. Һәм шундук катгый-аяусыз карар укыган сыман итеп тезә дә башлады.— Сез кеше үтерүдә гаепләнәсез, һаман да шуңа төшенеп җитә алмыйсызмыни соң әле? Бездә шактый ук мәгълүматлар, дәлилләр тупланды. Дәлил дигән нәрсә — аяусыз. Ә алар сезгә каршы. Һәрхәлдә, сезнең файдага түгел. Җинаять күз алдында. Һәрбер җинаятьнең, белгәнегезчә, тиешле җәзасы да була. Так что үзегезне акларлык дәлилләр турында да, бу җинаятькә ни дәрәҗәдә катнашыгыз булуы-булмавы турында да сезгә уйларга вакыт җитәрлек булачак. Һәртөрле көтелмәгән хәлләргә, өстәмә сорау алуларга, аңлатма-ачыклауларга әзерләнә торыгыз...

Кабат караңгы, тынчу бүлмәгә кертеп япкач кына, Иргали гомер булмаган, булыр дип башына да китермәгән бу вакыйгаларның рәхимсез чынбарлык, чын хакыйкать икәненә төшенгәндәй булды. Исләреңакылларың китәрлек хәлләр бит! Шулай итеп кеше үтерүче дигән яманат тагарлар микәнни? Илгә яман исемнәре чыгар микәнни? Шулайлар итеп хөкем ителүчеләр эскәмиясенә утыртырлар микәнни? Ил алдында абруеңны җую, күздән төшү генә түгел шул ул! Әнә аңлаган кешегә аңларлык итеп: әлеге җинаятьтә, ягъни кеше үтерүдә гаепләнәсез дип ачыктан-ачык әйттеләр. Ничекләр итеп күтәрер ул бу хурлыкларны?!.

Иргали күкрәк турысында кинәт кенә нәрсәнеңдер бик әрнеп, бик сызып, тартылып өзелгәнен тойгандай булды. Искәрмәстән китереп суккан кара кайгы, ачы хәсрәт, хәерсез хәбәр шулай телә, шулай кисә иде аның бәгырен. Ул да түгел, караңгыланып киткән күз алдына өйдәгеләр килде... Янә имәнеп киткән сыман булды Иргали. Ничекләр итеп күтәрерләр бу берьюлы башка сыйдыра алмаслык кара кайгы, яман хәсрәтне? Аягы йөгерек коточкыч имеш-мимешләр, йөрәк әрнеткеч яман хәбәрләр, тагын да серлерәк томанга төрелеп, күптәң инде бөтен төбәкне аркылыга да, буйга да айкап өлгергәндер. Авыл халкының ул якка колагы сизгер, теле чос аның. Тирә-юнь, нәкъ тузгытылган умарта күче кебек, гөж килеп торадыр. Минем гаебем юк, күрәләтә торып нахак бәла тагалар, юкка гаеплиләр дип, җилгә таралган сүзләрнегайбәтләрне җыеп, кырык мирның авызын томалап кара син, бар!

Иргали үзенең бөтен гомерен күз алдыннан кичерергә тырышып карады. Чыннан да, кайчанрак башланды соң әле тормышының менә шулай сүтелә, коела, күзгә күренмичә, сиздермичә җимерелә башлавы? Ә бит ул үзен белә-белгәннән бирле дөньяга һәрчак аек акыл, ачык күз белән карап яшәде кебек. Һәрхәлдә, дөрес яшим дип уйлый иде ул үзе турында. Бер кешегә дә баш бирмәде, бер кеше алдында да түбәнсенеп бөгелмәде, сыгылмады. Хәрам килешмәгәнне белә иде, бәлки шуңадыр, гомерендә кеше малына кызыкмады, кеше исәбенә яшәргә тырышмады,

кеше өлешенә кермәде, тикмәгә кеше җәберләп, рәнҗеш алмады. Шуның өстенә гайрәтле иде, тәвәккәл иде, көч-егәре дә, ходайга шөкер, буа буарлык иде. Кулыннан эш килде, бер хезмәттән дә тартынмады, курыкмады. Теләсә кем әйтер: йөзенә кер кундырмаслык итеп яшәде. Бәлки шуңадыр, ил өстендә абруйлы, туй-мәҗлесләрдә, бәйрәм-җыеннарда урыны түрдән булып, үз көнен үзе күреп, үз өенә, үз тормышына үзе баш, үзе түш булып, дошманга сер бирмичә яшәде.

Әмма, ничек кенә булмасын, Иргали әчке бер тоемлау белән күңеленең кайсыдыр бер почмагында, тел белән әйтеп аңлатып булмый торганниндидер яшерен зәгыйфьлекме, мохтаҗлыкмы яшәвен тоя килде. Әлеге җан кабул итмәс ят нәрсәнең кайчан да булса бер үзен сиздерәчәген, бер калкып чыгасын тоеп яшәде.

Шулай чуалган йомгак очын эзли торгач, Иргалинең зиһенен тагын бер яман фикер көйдереп алды: күрче зинһар, аның бит акыл-киңәш бирерлек, кирәккәндә таяныч булырлык бер генә кешесе дә юк икән ләбаса! Бер генә мизгелгә үз-үзен кызгану хисе җилпенеп куйгандай булды. Шул инде, дип уйлады ул, баш очында күк аяз булганда, тормышың да көйле генә акканда, бар да җайлы, бар дә шәп. Әмма тормыш дигән нәрсәнең бер алдын, бер артын күрсәтә торган гадәте дә бар. Күк йөзе дә гелән аяз, күңелдә дә гел яз гына хакимлек итә алмый. Юкка гына: кояшта яфрак матурлыгы күренсә, давылда тамыр ныклыгы сынала, димәсләр иде аны.

Уйлана торгач, үзенә карата хәерхаһ, ихлас теләктәшлектә булган кешене дә тапты Иргали, бу — Бәһрам җизнәсе иде. Әмма соңгы елларда, үч иткәндәй, тормыш дигән мәрхәмәтсез нәрсә алар арасына да үзенең кара күләгәсен салырга өлгергән иде инде. Барысына да Иргали генә гаепле.

Иргали, берсе икенчесен алыштырып, яңарып торган ямьсез уйларыннан качарга теләгәндәй, тун якасын күтәреп, кулларын кушырып җиңнәре эченә яшерде дә җайсыз, тар эскәмиядән идәнгә төшеп ятты. Аркасын стенага терәп, бөгәрләнеп ята торгач, үз сулышы беләндер инде, чак кына җылына башлавын тойды. Бу җылы күңеленә дә инде ахрысы. Менә ул борынын якасы эченнән чыгарды, ойый башлаган аякларын сузып җибәрде. Уйлары да аккан юнәлешләрен чак кына үзгәрткән сыман булдылар. Ник чукынып китми шунда дип уйлады Иргали, йөрәк сыза, йөрәк әрни дип, башны ташка бәреп булмый бит инде. Гомумән, йөрәге сызмаган, җаны сызламаган кеше бармы икән бу фани дөньяда! Әйдә, без күрәсен кеше күрмәс, шагыйрь әйтмешли, ир-ат башына ниләр килеп, ниләр китми...

Иргали күтәрелгән якасы эченнән башын чыгарды да, тирә-юньгә колак салып, чак кына тыңлап ятты. Берни дә ишетә алмады. Тынып калган авыл өстендә кайдадыр бик ялкауланып, теләр-теләмәс кенә этләр өрүеннән башка тавыш юк иде.

Иргали, йөрәк тибешен дә туктатырга теләгәндәй, сулыш та алмыйча, янә колак салып тыңларга кереште. Бу юлы ул өргән этләр арасында Тырнак тавышын ишетергә ниятләде. Тик шундук бу уеннан кире кайтты. Моннан өч атна чамасы элек юкка чыккан этнең ничек итеп инде бүген генә өргән тавышы ишетелсен ди. Чыннан да, суга салгандай, җир йоткандай булды Тырнакны. Үлгәндер дигән нәтиҗәгә килде өйдәгеләр. Яше дә бар иде инде. Читкәрәк киткәндер дә үлгәндер. Яхшы эт үлгәнен һичкайчан да хуҗаларына күрсәтмәс ди халык. Хак сүздер.

Бер шом икенчесен тудыра, дигәндәй нәкъ менә шул мизгелдә генә Иргалигә этнең эзсез югалуы белән әлеге фаҗига арасында ниндидер уртаклык бардыр сыман тоела башлады. Дөрес, Тырнакның әлегрәк тә югалып торган чаклары булгалады. Андый хәл гадәттә февраль ае азакларында, март башларында кабатлана иде. Әмма ике-өч көннән соң тырналып-яраланып, корсагы эчкә батып, тәмам йолкышка әверелеп

кайтыр иде дә, берәр тәүлек оясыннан чыкмыйча хәл җыеп, яраларын ялап-дәвалап ятканнан соң, яңадан үз вазифаларын үтәргә керешер иде.

Күпме гомер үтеп, бер генә бала-чагага да, бер генә кешегә дә тимәде. Бер дә юкка өрмәде. Тик ни хикмәттер, Гыйззәт хәзрәтне өнәмәде. Үзе түгел, күләгәсе генә күренсә дә, чылбырын өзәрдәй булып ярсып, ыргылып-томырылып, буыла-буыла өрә башлар иде. Хәзрәтнең кигән киеме башка кешеләрнекенә караганда үзгәрәк булгангадыр дип уйлый иде Иргали.

Хәзрәт тә Тырнакны өнәп бетерми иде. Берничә тапкырлар: «Котыргандыр бу, зәхмәт... Күрче үзен, тач бүре бит. Кешегә ташланып зыянзәүр күргәләгәнче, аттырырга кирәк үзен»,— дип киңәш тә биргәләгән иде.

Иргали онытылып киткән сыман булды. Тирә-юнь, бар галәм көчәйгәннән-көчәя барган нинди дер гөрелте белән тулды. Дикъкать беләнрәк тыңлап карагач, төшенде: бөтен урамны биләп алган авыл халкы шулай гөжелди икән. Ил кавемендә, Иргалиләрнең нәсел-нәсәбендә булмаган әлеге фаҗигале хәлгә иң куанган, шатлыгыннан үрле-кырлы сикергән кеше Гыйззәт хәзрәт имеш. Әнә ул, халык арасына кереп алган да, кулындагы чукмар башлы таягы белән селтәнеп-кизәнеп, кемгәдер янагандай зәһәрләнеп кычкыра, каргый-каргый нәләтләр укый. «Я-а-а, тәңрем! Догаларым, ниһаять, сиңа барып җитте тәгаен. Тәки башына җиттең мәлгуньнең. Бер түгел, мең шөкер үзеңә. Тәки башына җиттең шул кафернең. Бик күп җәбер-җәфа күрсәткән иде, нәкъ котырган эт кебек иде йөзе кара! Язгына күрә җәзасы булыр дип әйткән идемме? Әйе, әйткән идем. Ул имансызны мин кичергән тәкъдирдә дә алла кичермәс иде. Менә күрегез, белегез!.. Һәр өргән сәвит этен шул язмыш көтә. Я-а-а, ходаем! Бер түгел, мең-мең рәхмәтләр үзеңә...» — Ул да түгел, хәзрәт эче катып каһкаһәләп көлә башлый. Аның шулай тәкбир әйткәндәй, вәгазь укыгандай, бөтен халыкка мөрәҗәгать итеп кычкырынулары үтерелгән Халәпкә әйтелгәнлеген төшенгәч, Иргали чак кына тынычлангандай булды. Әмма озакка түгел, аның күңелен җан өшеткеч икенче уй өтәләп үтте: «Күрче зинһар, безнең Тырнак та хәзрәтькә өрә иде ич! Аның да башына Гыйззәт хәзрәт каргышы төшмәдеме икән?!.»

Иргали шыбыр тиргә батып уянып китте. Уф-ф!.. Төшкә дә кереп борчымасаң соң, дип эченнән генә хәзрәтне тиргәп тә куйды.

Яшерен-батырын түгел, динне танымаса да, мәчет белән алыш-бирише булмаса да, Иргали Гыйззәт хәзрәт белән тату яшәде кебек. Күрше хакы дип, кайчандыр ат биреп торып кылган яхшылыкларын истә тотып, һичкайчан да хәер-садакасыннан калдырмады. Яңа өйне өлгертеп керү белән: «Коръән укып, дога кылып, өемә фатиха биреп чыксаңчы, хәзрәт»,— дип, иң әүвәл остабикәсе белән аны чакырды. Садакасына аяклы мал — бүлтерек бәрән бирде. Түрнең башында утырды хәзрәт. Хәтсез утырды. Тәгаменнән житеш дип, бик кыстагач, хатынкыз кавеме сизенә күрмәсен дип, сакланып кына: «Мондый нигъмәтне пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам да кире какмаган»,— дип, ачы балдан да авыз итте.

— Хәлләндең, бөтенәйдең... Ходай тәгалә биргән дәүләтеңнең игелеген күреп, кинәнеп яшәргә язсын. Бәла-казалар күрергә насыйп итмәсен берүк. Амин!..— дип бик озаклап дога кылды.

Дөньяви хәлләр турында да гәп сатып утырды хәзрәт. Мәрхәмәтсез кыланалар дип, «бәлшәвикләр»гә дә тел-теш тидереп алды. Ак патша Микулайны ничек итеп кулга алулары турында да гәп сатты.

Әмма күпмедер вакыттан соң тату гына яшәп яткан ике күрше арасына күләгә ятты. Барысы да Салиха карчыкның ярым җимерек таш келәтен сатып алудан башланды.

Әмма җәй башында, Камада саллар туктагач, хәзрәт белән Иргали арасында янә бер җитди сөйләшү булды. Авылда яңа мәктәп салу

өчен хөкүмәт бер зур сал агач биргән. Шул салны сүтеп, бүрәнәләрен кичекмәстән ташып куярга кирәк икән. Авылның избачы, мөгаллимәсе, әле һаман да үзенең сылулыгын җуймаган Хәят: Иргали абый, җаным дип сорыйм, берәр атыңны биреп тора алмассыңмы? дип гозерләп килгән иде. Көлеп-елмаеп торган хатын-кызның гозерен ничек итеп инде аяк астына саласың ди, бер түгел ике атын биргән иде Иргали. Төнге томаннарда коенып, соңгы елларда төнгелеккә абыйлары урынына йөргән Тажи белән Һади чабышып кайтканда, таң җилләре ялларын тараган атлар сокланып туймаслыклар да, тотып тыярлыклар да түгел иде.

Менә шул иртәне Гыйззәт хәзрәт, Иргалине туктатып, бик җитди мәсьәлә турында әңгәмә корырга җыенгандай сүз катты.

— Нәрсә, күрше,— дигән булды ул, йонлач кашы астыннан сөзеп кенә карап.— Калхузга керергә ниятләндеңме әллә? Ә?..

Иргалинең әллә ни исе китмәде.

— Ник алай дидең әле, күрше? — диде ул, хәзрәтнең соравына сорау белән җаваплап.

— Ник дип... Шул инде. Өч атыңның берьюлы икесен биргәнеңне әйтәм...

— Колхозга түгел бит, хәзрәт. Әнә, яңа мәктәп салырга җыеналар. Укысыннар балалар. Тукаебыз әйтмешли: өч наданга алышынмас бер язу белгән кеше. Надан кеше бу заманда сукыр белән бәрабәр...

Аның соңгы сүзләренә бөтенләй игътибар итмәде хәзрәт, әйтергә теләгәне дә бик кыска иде аның.

— Барыбер сәвиткә!..

Ә икенче тапкырында сүз тагын да кискенрәк, хәтта чак кына янауга да охшаган иде. Хәзрәтнең көйләп-вәзенләп әйткән сүзләре әле дә булса колагы төбендә яңгырап тора Иргалинең.

— Син, мелла кем, ике арада, бер турыда кала күрмә. Дөнья хәлен белмәссең. Әй-йе! Заманалар да тыныч түгел, буталып-нитеп китә калса, кыйблаң булырга тиеш, югыйсә авырга килүе бар дип әйтүем. Тормыш бөтәйгәч, йортка хафа килә дигән борынгылар. Берәр зәхмәте тиеп, йорт-җиреңнән бәрәкәт качмагае дип борчылып кисәтеп куюым. Ике ут арасында калып, зыян-зәүрәткә юлыгып куйма, дип әйтүем. Килер көн килми калмый. Әй-йе!...— Бу сүзләрне әйткәндә хәзрәтнең урыныннан купкан зәһәр күзләре яман ялтырый, ә ияге бизгәк тоткандагы сыман бии иде.

Хәер, бу сөйләшүгә кадәр үк инде Иргали ниндидер хәвефле берәр хәл, фаҗига якынлашуын сизенә башлаган иде. «Нишләптер хәзрәт сине чит күрә, ят итә башлады, яшерен таш төрән сындыра ди, искәрмәстән генә берәр кырын эш эшләп куймагае»,— дип сүз салучылар да булды. Хәзрәтнең ниндидер шикле кешеләр, кара көчләр белән тыгыз элемтәдә торуы, аралашуы, еш кына караңгы төннәрдә бакча артларында шөбһәле күләгәләр хәрәкәтләнүе, бу турыда авыл халкы арасында да ышын-пышын сүзләр йөрүе Иргали өчен дә сер түгел иде.

Очы-кырые юктыр сыман булып тоелды ул төннең, әйтерсең лә җир шары ниндидер ерып үтә алмаслык куе караңгылыкка барып эләккән дә шунда туктап калган. Иргали яңа көнне каршы алуына тәмам өметен өзү дәрәҗәсенә җиткәндә, авылда тереклек барлыгын белдерергә теләгәндәй, ачы таңны ертып, беренче әтәчләр аваз салдылар.

Беренче әтәчләрне генә көтеп торган диярсең, авылга да җан инде: кайдадыр җилкапка шапылдады, якында гына кое сиртмәсе шыгырдады. Моңарчы тавыш-өне булмаган бер сыер, бозавы белән кавыштыруны сораптыр инде, өзми дә куймый мөгри башлады. Күрше каралтыларның берсендә, бик ачыргаланып, бик түземсезләнеп, сарык бәрәне кычкыра иде.

Авыл Советына килүләрен көтеп яту янә бер төн озынлыгы тоелгандыр. Ниһаять, сыңар өлге кадәр генә тәрәзәгә дә яктылык иңде. Аннары инде әллә ни озак көтәргә туры килмәде, Иргалине янә тикшерү бүлмәсенә чакырып алдылар.

Анда бар да кичәгечә иде. Аерма тик шунда: тәрәзә каршындагы озын эскәмиядә Бәһрам җизнәсе дә утыра иде. Иң әүвәл аларның күз карашлары очрашты. Бәһрамның күзләрендә сәерсенү катыш борчылу. Керфек төпләре ялкынсынган — ул да йокысыз төн үткәргән булса кирәк. Димәк, җизнәсе дә Иргали өчен янган-көйгән.

Ул арада йокысы туймаган сыман бүртенеп утырган прокурор Иргалигә ым кагып урын күрсәтте дә сабыр-салмак кына тезә дә башлады.

— Сезне менә авыл Советы рәисе иптәш Кәрамов халык исеменнән хәзер порукага бирүне үтенде. Тикшерүнең әле башлануын гына исәпкә алып, без дә үз чиратыбызда моңа каршы килмәскә булдык...— Прокурор, алдында яткан папкасыннан иң өстә яткан бер кәгазь битен чыгарып, Иргали алдына салды.— Менә шушы документка кул куюыгыз сорала. Башта укып чыгыгыз. Анда, тикшеренүләр тәмамланмыйча торып, авылдан беркая да чыгып китмәскә дигән кисәтү ясалган.

Иргали документны укып та тормады, имзасын салды. Прокурор, кәгазьне папкасына кире тыкканда, әллә ни әһәмияте булмаган сүз әйткән сыман, болай диде:

— Хәзер берничә көнгә сез азат. Тагы бу «дело» белән башка оешма кызыксына дигән хәбәр дә бар...

Урамга чыккач, Иргали кинәт башы әйләнүдән авып китә язды. Ни күрсен: тирә-юнь ап-ак, беренче кар төшкән. Иргалинең үлеп ярата торган чагы иде бу. Әмма бүгенге хозур манзара аның күңеленә мыскал да юаныч бирмәде, алай гына да түгел, бу минутта бөтен галәм ак кәфенгә төренеп ята сыман күренде аңа.

Алар, сүзләре беткән кешеләр сыман, янәшә атлап баралар.

— Нәрсә, Бәһрам җизни, болар чынлап минем башка житәргә чамалыйлармы әллә? — диде Иргали, сорау бирүдән бигрәк үпкәләгән, җәберсенгән бер кыяфәт белән. Чыннан да, бу мизгелдә Иргалинең танырлыгы калмаган, тәмам сөмсере коелган иде.— Билләһи дип әйтәм, нинди дер мөгез чыгарырга маташалар болар. Уйга да килеп карамаган нәрсә бит. Күр инде, әй! Башлар себер китәрлек нәрсә бит бу, уйлый калсаң...

Алга таба сөрлегә төшеп титаклаган Бәһрам җизнәсе, Иргалине юату-тынычландыру турында уйламый да иде булса кирәк, шуңадырмы, бары тик сыңар сүз генә әйтте:

— Тырышалар...

Юлларын дәвам иттеләр. Бәһрам җизнәсенең соңыннан әйткән сүзләре дә җан кайтаргыч өметсезләр иде.

— Шулай инде ул, бәла-каза һичкайчан да көткән яктан килми.

Беравык тын атлаганнан соң, рәис тагын сөйләнеп алды:

— Ул, аяклы каза, үлде дә котылды. Монда, менә безгә калды гөрзинең чукмарлы башы. Тиз генә китәргә ниятләмиләр. Сизенгәнсендер, ниятләре зурдан кубу...

Иргали башта Бәһрам җизнәсенең нәрсә турында сүз алып барганлыгын абайламыйчарак барды, бары тик үз нужасын китереп кыстыргач кына, барысын да төшенде.

— Аның бит әле тамак ягы да хисапта. Өрлек кебек алты-җиде ир-ат. Көненә өч тапкыр ашат. Колхозныкына кул сузу — янә четерекле. Аларга бит тавык суеп кына котылып булмаячак. Шуның өстенә әнә өч-дүрт баш җигүле ат...

Иргалинең башында: «Куянга — җан кайгысы, аучыга — мал кайгысы дию менә шушы була торгандыр инде» уе чагылып китте. Һәм ул, өлкән кардәшенең хәленә керергә теләгән сыман итеп, әйтә салды.

— Юк белән хафаланма әле, Бәһрам җизни. Әнә, миннән ике-өч баш сарык алып тор...

Авыл советы рәисе, коточкыч сүз ишеткәндәй, башта кулын селтәде, аннары як-ягына каранып алганнан соң, шактый кырыс тавыш белән өстәде:

— Бу турыда әчтән тын, тешеңне дә агартасы булма. Каш ясыйм

дип, күз чыгарып куярсың, шул булыр. Район прокуроры белән тикшерүчеләргә ришвәт бирде дип, бөтен дөнья сасыр, күзеңне ачырмаслар.

— Баш өзелгәч, чәч турында кайгыртмыйлар, Бәһрам җизни.

Иргалинең тавышында нииндидер ят, кара өметсезлек яңгыравын тоепмы, Бәһрам җизнәсе тизрәк аның авызын томалау ягын карады.

— Куйчы, зинһар! Нинди баш өзелү ди ул тагын. Үз-үзеңне кәфенләми тор әле. Адәм баласы нинди генә бәлагә тарыса да, өметен өзмәскә тиеш...

Иргали үзсүзләнүен белде.

— Соң үзең уйлап кара, Бәһрам җизни. Эшнең зурга китәсе көн кебек ачык. Үзең үк күреп торасың ич, иң яман җинаятьтә, кеше үтерүдә гаеплиләр бит. Моңа зиһен җитә торган гынамы соң! Хет мыскал гына чаклы хакыйкать, хаклык булсачы! Юк бит!.. Аның бит әле «кеше үтерүче» дигән исемен күтәрүе генә дә ни тора. Ничекләр итеп мир алдында яшәмәк кирәк. Хурлыгыңнан авылны ташла да кач, билләһи!..— Бу юлы Иргалинең тавышы ничектер калтырабрак, сынып чыккан сыман яңгырады.

Бәһрам җизнәсе ирексездән аның ягына күз салырга мәҗбүр булды. Аннары, әйтергә җыенган сүзенә җиңел төсмер өстәргә теләп, янә сөйләнеп алды:

— Алай димә әле син, Иргали туган, вәсвәсәгә бирелмә...

— Аптырагач әйтүем. Эшләр мондый борылыш алгач, белмим шул.

— Башыңны элмәккә тыгарга да ашыкма. Эшләр хәзергә син әйткәнчә үк өметсез дә түгел...

Бу сүзләр Иргалине айнытып җибәргәндәй итте, ул хәтта адымнарын әкренәйтте.

Туганының сораулы карашын тойган Бәһрам дәвам итте:— Бәлкем әле бар да хәвеф-хәбәрсез генә узып та китәр. Бая сине чакырып чыгарганчы, доктор әнә нәрсә дип тора иде: Халәп, сезнең тыкрыкка китереп ташлаганчы ук инде нииндидер озынча йомры тимер белән сугып үтерелгән булган. Чүкеч белән бары тик синең койма буена китерелеп, башына капчык кидерелгәннән соң гына төелгән ди. Мәет яткан җирдә дә кан заты юк дәрәҗәсендә, капчык та бары тик оешкан канга җиңелчә генә буялган, ди. Докторга да әлеге мәгълүматын ничек булган шулай язарга куштым. Бәхетебезгә, ул арада чын җинаятьчене дә табып куймаслармы әле...

— Ходай кушсын иде кана да бит, Бәһрам җизни, белмим шул...

Ул арада бөтен тыкрык башын биләп торган Иргали өе күренде. Әмма бүген йорт хуҗасы өчен ул башка вакытлардагы кебек бөтен урамны яктыртып, бизәп, ямь биреп тормый иде. Төннәрен соңга калыбрак кайтканда, кучкарда сукыр лампа гына кабызылган чакларда, нәкъ менә хәзерге кебек төссез, иләмсез зур һәм шөкәтсез булып күренә торган иде.

Бәһрам адымнарын әкренәйтеп кенә калмады, бөтенләй туктады.

— Өйдәгеләр тәшвиштәдер инде? — диде ул. Аның бу сүзләре сорау бирүдән бигрәк раслау булып ишетелде.

— Әйтмә дә инде, Бәһрам җизни. Кайгы-хәсрәт, кара пошаман баштин ашкандыр.

— Чөй өстенә тукмак дигәндәй, ичмаса Гөлниса киленнең дә сәламәтлеге чамалы.

— Әйтерең бармы.

Бер мизгелдә генә тынып калган Бәһрам, янә телгә килде.

— Менә нәрсә, Иргали туган. Моңарчы ир-егет идең, берүк моннан соң да шулай булып кала күр. Ир-ат башына төшкән кайгы-хәсрәтне, бәла-казаны, гадәттә, бусага тышында калдыра белергә тиеш. Нәрсә әйтергә теләгәнемне төшенгәнсеңдер шәт.

— Төшендем, Бәһрам җизни. Бер бәлане унга бүлүдән ни файда да, ни фәтвә!..— Иргали, юлдашы ягына борылып, искәрмәстән генә әйтә салды.— Әллә, Бәһрам җизни, кереп чыгасыңмы? Ә?..

Рәис бәла иңгән йортка керәсе итмәде. «Башка вакытта»,— дип, йорт хуҗасы белән хушлаша ук башлады. Иргали үз чиратында: «Башка вакытның булмавы мөмкин...» — дип әйтмәкче иде дә, тыелып калды.

Ул арада Бәһрам кабат саубуллашты да, кисәк кенә борылып, ниндидер хәвеф буласын көткән сыман, тынып калган урам буйлап китеп тә барды.

Өйдәгеләр шатлык-куанычларыннан нишләргә дә белмәде: Гөлүсә, кулларын чәбәкләп, үрле-кырлы сикеренде, хуҗабикә белән Миңсылу, авызларын ямьшәйтеп, еларга ук керештеләр. Ярты авылны диярлек кәнсәгә чакыртып, җыен килде-китте сораулар биреп, беркетмә төзүләре алар өчен сер түгел иде инде. Җитмәсә тагын Иргалине ябып төн кундырулары, шуның өстенә берсеннән-берсе яман гайбәтләр белән күңелләренә шом салып, «Тәки Иргалинең башын ашыйлар икән!» — дип өннәрен алып бетергәннәр иде инде аларның.

Ул да түгел, кабалану-ашыгудан хәл-әхвәл дә сорап тормастан: «Сөенче, күршекәйләрем!.. Сөенче! Ходайның биргәннәренә шөкер»,— дип, күршеләре Зәйтүнә атылып килеп керде. Шатлыгы тутсыл йөзенә бәреп чыккан иде аның. Әле яңарак кына прокурорның да, район милициясе начальнигы Сабировның да солдат-каравылчылары белән олауларга төялеп китеп баруларын үз күзләре белән күреп калган имеш.

Тик иртәрәк сөенгәннәр икән: шул ук көннең төнендә, яман дөбердәтеп өйгә басып керделәр дә, Иргалине атка утыртып, кораллы конвойлар арасына алып, район үзәгенә — Чаллыга алып киттеләр. Шул китүеннән суга салгандай юк та булды Иргали.

...Күзеияләшә төшкәч, күрде Иргали: дымлы кирпеч стена буенда тар гына эскәмия тора икән.

Бу мизгелдә Иргали ни үле, ни тере хәлдә иде. Зиһене чуалган, исен җуйган бер халәт биләп алды аны. Ул да түгел, өстенә бозлы дәрья каплландымыни, бөтен тәненең нәкъ бизгәк тоткандагы кебек калтырана, туңа башлавын тойды. Гүр салкынлыгы тәненә үтеп кереп кенә калмады, җанына да тәэсир итә башлады... Уйлары да чамасыз авыр, хәлләре дә үтә мөшкел иде аның бу мизгелдә. Кинәт кенә тагын нидер булды: башы түнеп, зиһене чуалып киткән сыман тоелды. Күз аллары әлҗе-мәлҗе очкыннар белән тулды. Аяк астындагы таш идән дә, җан кергән сыман, кинәт убылып бер якка шуыша башлады. Бермәлгә мие дә, йөрәге дә туктап калгандай булды. Һәм ул үзен җәһәннәмгә убылып төшә башлагандай хис итте...

Иргали соңгы көчен җыеп, башта стенага тотынды, аннары, авып китмәс өчен, эскәмиягә килеп утырырга мәҗбүр булды. «Әллә әҗәлем шушы микән?..» — дигән шыксыз уй чагылып китте. «Я-а-а, язмыш, тагын ниләр күрсәтәсең бар икән әле?!.»

Тәмам аптырап калган, нахакка гаепләнүдән гаҗиз булган Иргали, ниндидер иңгерәүле, газаплы хисләр өермәсе иркенә бирелде. Рухы сынган, ихтыяры тәмам какшаган иде инде аның. Бәлки шуңадыр, баштарак эзлекле фикер йөртә алмыйча иза чикте. Чите-кырые күренмәгән чуалчык-чәбәләнгән уйларының очын табарга тырышкан саен, уй-фикерләре отыры чияләнә генә барды аның.

Ниндидер көч, төртеп диярлек, Иргалине урыныннан кубарды. Үзүзен кая куярга урын тапмагандай гасабиланып, арлы-бирле йөренә башлады. Читлеккә ябылган ерткыч кебек күпме генә йөренсә дә, күпме генә баш ватса да, үз хәленә җиңеллек китерерлек бер генә өмет чаткысы да кабынмаячагын күңеле белән сиземләде ул. Бар, адәм баласында алдан сиземләү көче бар ул. Иргали дә тормышында килеп чыгачак бу борылышны күңеленең кай җире беләндер сизенә, тоя торды. Тагын бер нәрсәгә бик ачык төшенде ул: өсте-өстенә актарылып-ябырылып килә икән адәм башына кайгы-хәсрәтләр, бәла-казалар.

Моңа кадәр Иргалигә фани дөнья бу кадәр үк катлаулы, мәрхәмәтсез, болай ук гаделсез түгелдер кебек тоела иде. Ниһаять, аңа да яшәеш-

нең аяусызлыгы белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Аңа да шулай җиңелү ачысын татырга язган микәнни?! Мөгаен, язгандыр. Гаделсезлекнең өстен чыгуын, тантана итәсен тою, ай-һай ла, авыр. Ничекләр итеп түзмәк кирәк!..

Әйләнчек чире йоккан сарык кебек, шыксыз тәмуг базында ике-өч адым саен борылырга туры килгәнгәме, Иргалинең башы әйләнеп, күңеле болгана башлады. Мондый хәл кабатланмасын өчен ул, камераның башына бер атлаганда — уңга, икенчесенә юнәлгәндә — сулга борылырга кирәклекне абайлап алды.

Кара уйлар җанны да каралта ди. Күңеле, өмете кырылган бу мизгелдә Иргалинең дә уйлары, ай-һай ла, яман иде. Бу уйлар, өйдәгеләрнең хәлен күзаллагач, йөрәк бәгырьләрен телгәләп, чыдый алмас дәрәҗәгә җитеп күкрәкне кысып, яңа көч белән кузгалалар иде. Ничекләр итеп мир гайбәтен күтәрерләр, җаннарым?.. Ничекләр итеп кеше күзләренә туры карап яшәрләр?.. Аның үзенә дә кирәкме соң мондый яшәү?.. Бик теләгән тәкъдирдә бу бәлаләрдән үзен дә, якыннарын да коткара ала бит...

Ләкин шундук күңел түрендә икенче бер тавыш аваз сала: «Тилермә!.. Кеше кадәр кеше исеменә лаек икәнлекне исбатлар өчен иң әүвәл авырлыклар алдында югалып калмаслык кыю ир-егет була белергә кирәк. Тилерә күрмә! Кеше бул. Дөрес, син моңарчы тормышның әлегедәй кискен борылыш ясауларына әзер түгел идең. Менә сыналу сәгатең дә җитте. Түз! Тешеңне кысып булса да чыда. Үзеңә-үзең кул салып, мордар китәр идеңме әллә? Аннан да җиңел юл юк ул. Үзеңнең кеше икәнлегеңне онытма. Кеше икәнлегеңне исбат ит. Сүз дә юк, язмышның кулы нык. Язмыштан узмыш юк димәсләр иде аны. Язмыш тукмый, язмыш сыный дип, елап-шыңшып, ялынып-ялварып кына берни дә үзгәртеп булмый. Тәкъдирнең шундый шаяруларын да ир-егетләрчә кабул итә, каршылый белергә кирәк. Тормыш сынауларыннан курыккан — яшәүдән курыккан ди. Кешенең гомере бер генә. Димәк, өлешеңә тигән көмешең шул булган. Димәк, тормышның синңа карата үз исәбе-хисабы булган...»

Тынгысыз, хәтәр уйларыннан качарга, арынырга теләгән кебек, Иргали яңадан эскәмиягә барып утырды. Бәгыре иңрәвенә, җан сыкравына чама юк. Тирә-юньдәге сәер тынлыктан чыдый алмаслык дәрәҗәгә җитеп башы чатный, колагы шаулый башлады. Тоткынның башында мең дә беренче кат инде: «Нишләргә? Нишләп карарга?» — дигән, һичкайчан да өзеп җавап бирә алмаслык сораулар туа. Болай җаны бәргәләнүенең бер дә иге-чиге булыр төсле түгел иде. Әмма кешене өмет дигән изге хис, изге көч яшәтә ди бит. Шулчак Иргалинең күңел күгендә дә, кара болытларны телгәләп үткән яшен ташы төсле, өмет чаткысы чагылып киткән сыман булды. «Чыннан да!..— дип уйлады Иргали, башында туган әлеге фикергә ябышып.— Үзе тавыш салмаган кешегә кайтаваз да ишетелми... Әллә чыннан да, Казан белән, доктор Клочкиннар белән элемтәгә кереп карарргамы? Ятып калганчы атып кал диләр бит. Теләгән тәкъдирдә, Рәхимҗан көнендә барып җитәчәк...»

Ярсуы бераз басыла төшкәч, күңелендәге боз булып каткан рәнҗүе чак кына эри төшкәч, аеграк акыл белән фикер йөртә башлагач, ул әлеге карарыннан шундук кире дә кайтты. «Юк!.. Ярамас... Кеше үтерүдә гаепләнә дигән коточкыч хәбәр хет аларга барып җитми торсын әле. Моннан да яманрак, моннан да шыксызрак гаепләнүнең бу фани дөньяда булганы юктыр, мәңге-бакый булмас та...»

Батканда кеше саламга тотына ди. Әмма Иргали баса алмый бу юлга. Аягы да тартмый. Аның бар өмете, бар хыял-максаты — бу хәлләрне, бу сынауларны гаделлек белән ерып чыгу иде. Ул бит ниндидер төшеп калган мәми авыз, әлләзи түгел...

Берничә урында учаклар ялкынланган сыман, Иргалинең дә миендә берьюлы берничә төрле фикер туды: берсе икенчесен эзлекле алыштырып торса бер хәл иде, вакыты белән берьюлы әллә никадәрле уй туып, үзара чуалып-чәбәләнеп беттеләр. Миенең кайсыдыр күзәнәгендә адашып йөр-

гән Кузька-Бурлак та чагылып үтте кебек. Ул аның Әстерхан якларына киткән жиреннән суга баткандай хәбәрсез юк булуы турында «Яшьти»е аша ишетеп белә иде инде. «Бәхилләтә алмадым кешене»,— дип уфтанды Иргали. Дөрес, ул аңа акчалата да, ит-май ише нәрсә дә тәкъдим итеп караган иде. Әмма тегесе ишетергә дә теләмәде. Бердәнбер кабул иткән нәрсәсе Иргалинең үзе тарафыннан хәзерләнгән казылык булды. «Чудо-закуска!..» дип һушлары китәр иде Кузьма Даниловичның. Казылыгы чыннан да шәп була торган иде Иргалинең. Моның өчен ул камыт күрмәгән елкы алып симертер иде. Өйнең калай түбәсе астында еллар буе торып тәмам җитлеккән, камыт бөятедәй итеп бәйләнгән казылыкның майлары тибеп торыр иде.

Ике кулы белән чигәләрен кысып, күпме утыргандыр, искәрмәстән генә күңелен нинди бер моңсу юаныч биләп алды. Бу мизгелдә Иргали үзе өчен иң кадерле, иң тансык уйларына бирелгән иде: язмышының иң зур бүләге, мәхәббәт кошы, балдызкае Миңсылу турында уйлап, изге мизгелләр кичерә иде. Менә кем аның уен, күңелен, бөтен барлыгын үзенә бәйли алды. Менә кем аның күңелен канатландырып, уй-хәсрәтләрен таратып, күңел күген чак кына аязландырып, пакьландырып җибәргәндәй итте. Сүнә башлаган зиһене дә ачылып, сафланып, эзлекле фикер йөртер халәткә кайтты. Шунда төшенде Иргали: йөрәгенең яртысы гына түгел, күпчелек өлеше барыбер Миңсылу дөньяга китергән күз нурыдай улы Азатта икән. Әнә аның Миңсылуы да янында, кул сузымында гына. Әнә ул күзләрен зур итеп ачкан да: «Җизнәкәем, хәлләрең ничек?.. Бик авыр түгелме? Зинһарлап сорыйм, түзә күр, улыбыз хакына, минем хакка түзә күр»,— дип, үгет-нәсихәт биреп кенә калмыйча, ялынып-ялвара сыман иде.

Аңа кадәр, алар югында, Иргали күңелендәге белән тормыш-яшәеше арасында нинди бер тәңгәллек җитмәвен һәрчак тоеп яши иде. Соңрак бар да үз урынына утырды кебек: ярсудан тәмам алҗыган йөрәге тынычланды, арган тәне сихәтләнгән сыман булды.

Иргалинең тормышына гына түгел, хезмәтенә, хуҗалыкта чуты бетмәгән мәшәкатьләренә карата да мөнәсәбәте үзгәрде. Соңгы вакытларда хезмәте канәгатьләндереп кенә калмый, тынычландыра, юата торган нинди сихри көч, рухи ныклык өсти иде. Эшләгән саен, нәкъ хәят суы эчкәндәгедәй, үзенә көч-егәр иңүен, җаны-тәненең яшәрә баруын, күңеленең көрлеген, йөзенең аклыгын, тормыш-яшәешенең алга китүен, күзгә күренеп диярлек бәрәкәт иңүен тоеп яшәде. Ару-талуның нәрсә икәнен тәмам онытты ул. Эшләгән саен эшлисе килә иде. Эш көчледән түгел, уңганнан шөлли диләр. Иргалидә исә көч-егәр дә җитәрлек, уңганлык та биш кешегә бүләрлек иде. Ул үзен баш имәс, буйсынмас, Алып батырдай җиңелү белмәс, теләсә нинди эшкә сәләтле, әгәр дә кирәксә, тормышның үзен бугазыннан эләктереп, кирәксә, чүп-чарын селтәп атып, аның килдекитте мәшәкатьләренә исе китми яши торган кеше хисаплый башлады. Бу халәт аның хәрәкәт-йөрешенә, үз-үзен тотышына да тәэсир итмичә кала алмады. Тын алуларына кадәр рәхәт, сулышы иркен, дөнья ифрат та матур, чиксез киң булып тоела иде.

Миңсылу белән үзара мөнәсәбәтнең ничегрәк башлануын күзалларга тырышып карады Иргали. Уйлары бик ераклардан урадылар аның. Әле дә булса хәтерендә: яз исенә, яз шатлыгы белән ярым исереп йөргән көннәр иде. Нәкъ шул көнне, таң белән, Рәхимҗан чанасына берьюлы ике сыер, дүрт-биш сарык түшкәсе, берничә тәпән бал, май салып, Казанга дип чыгып киткән иде. Күчтәначкә дип, биш-алты каз түшкәсе дә салды. Соңгы елларда Иргали, Клочкиннарны гына түгел, аларның туган-тумачаларын да, Казаннан 40-50 чакрымда урнашкан Паратск дигән җирдә яшәүче Ксения Семеновнаның бертуган абыйсы атаклы Губиннар гаиләсен дә азык-төлек белән тәэмин итә иде.

Базарларда ит, май ише нәрсәләрнең иң кыйммәт чагы, янкарына килерлек түгел. Димәк, Рәхимҗан яңадан уч тутырып акча алып кайта-

чак. Юллары гына уңа күрсен берүк. Рәхимҗан кайтканның икенче көнендә үк, яңадан аяклы мал-туар алып җибәрерләр: сыер, тана ише эре малның иң арзан чагы хәзер.

Шундый уйларга бирелеп, өенә якынлашып килә иде Иргали. Көн чалт аяз. Кояш астында кар җемелдәвеннән күзләр камаша. Я-а, ходай, тагын язлар җитәмени! Тагын күккә сабан тургайлары күтәрелер чаклар якынаямыни! Андый чакта игенченең йокысы кача, җаны чуарлана, өмет-юанычлары кузгала. Крестьян, нәкъ сабантуй якынлашуын сизенгән чаптар кебек, тәмам тынгылыгын җуя. Иргалинең дә күңеле җырлый иде бу минутта. Каидандыр, басу якларыннан епшек кар исе, каен бөресе, тал каерысы исе, чәчәк аткан көнбагыш исе килеп бәрелгән сыман булып китте.

Менә бөтен урамга ямь биреп торган урыс капка. Бөтен иңе белән һәйбәтләп көрәлгән. Койма буйларына мул итеп көрт салган. Өске өлеше беләүләнеп ялтырап ята. Кар шундый пакь, шундый ак, астан, ниндидер ут белән яктыртылганга охшап күренә. Аның каравы күләгәдәге көрендәләп салынган көртнең дулкынга охшап торган түбәләре, сизелер-сизелмәс кенә искән язгы җилдән дә тузгып, тетенләп утыра.

Иргали, кече капканы ачыйм дип, келәгә кулын гына сузган иде, каршысында, нәкъ җир астыннан калкып чыккан сыман: «Аллаһу, бисмилләһу...» — дип, Мәгыйшә кортка пәйда булды. Күрәзәлек кылу, фал ачу, юрау, им-том ише нәрсәләр белән шөгыльләнүче карчыкны күргәч, Иргалинең баш очында гына карга кычкырдымыни, шундук кәефе кырылды.

Кортканың өстендә бәрхете кыршылып беткән плюш бишмәт, аягында киез ката, башына зур кәшемир яулык өстеннән сай мескен бүрек чәпәп куелган. Йөзе зур эш башкарган кешенеке сыман алсуланып чыккан, күзләрендә ут. Бу тынгысыз, төс ташламас карчык заманында эче төшкән Гөлнисаны да өшкереп-төкереп мунчалар яктырып төрле үләнтөнәтмәләре белән дәвалагандай итеп караган иде, төрлечә алдалап-юмалап, акчаны да, бүләкләрен дә шактый үк сауган иде. Тик файдасы гына тимәде. Шуннан соң Иргали аның өе тирәсеннән эзен суыткан да иде инде. Бәлки шуңадыр, бу юлы да:

— Бу пәри комалаган нәрсәгә ни калган бу тирәдә? — дип, шактый үк кырыс бәрелде.

Тегесе аның бу төртмә сүзләрен әллә ишетте, әллә ишетмәде, бәрәбәрә килеп, шундук телләнә дә башлады.

— Һай-й, аллам! Алай дияргә язгыннан курык, кем... Һай-й аллам! Оятлылар гына булдым. Син кайткалаганчы китеп өлгерерменме әллә дип уйлаган идем...

Телгә остарып беткән им-томчы карчыкның бу сүзләре йорт башының күңеленә шом салгандай итте, ул аның юлына каршы төшеп диярлек, янә сорау бирде:

— Нәрсә күреп чуаласың әле син бу тирәдә? Нишләп йөрисең?

Теле төк ярырдай карчык бер генә мизгелгә югалып калды, тотлыга ук башлады.

— Нишләп дип... ни инде. Ни дип торам... Килгән идем әле менә.

— Бездә булдыңмы? Кем чакыруы белән килдең? Кем янына? Тагын алдашып, тагын бушны юкка аударып йөрисеңме?

— Юк, юк! Сездә түгел...— булды кортканың җавабы.— Сездә булмадым...

— Бездән чыгып киләсең ич!..

Мәгыйшә карчык зур серен ачарга мәҗбүр булган кеше кебек, авыз тирәләрен каплагандай итеп, ярым пышылдап әйтте:

— Тегә, түрге өйдә булдым...

Бу сүзләр янә шик кузгатты Иргалинең күңелендә.

— Анда сиңа нәрсә калган ди?

— Нәрсә дип... Анда да җан ияләре яши ич.

Иргали чын-чыннан тиргәшергә үк керешә.

— Син, пәри кияүләгән нәмәстәкәй, боргаланма, яме. Дөресен әйт!..

— Алла белән ант итәм, әгәр... Ике күзем чәчрәп чыксын мәгәр...

— Алдыйсың ич! Рәхимҗан ачы таңнан калага китте...— Һаман да сихәткә туя алмаган Рәхимҗанның бу корткага йомышы төштеме икән дигән уй туган иде Иргалидә.

— Китә бирсен! Хәерле сәфәр була күрсен берүк,— диде Мәгыйшә карчык, исе китмәгән бер кыяфәттә.— Миңа нәмәстәгә ди ул? Мин ир-ат белән эш итмим. Иткәндә дә бик сирәк, онытканда бер...

— Кем янына килдең соң алайса?

— Аллаһу, бисмилләһү! Үзеңне дә әйтер идем... Шулай итеп соңгы серемне дә ачтырырсың микәнни инде...

— Әйт, яшермә!

— Сылу балдызкаең янына килдем...

— Анысы нәрсәгә тагын?

Бу сорауны көтеп алган диярсең инде менә: кортка элеп алып тезә дә башлады.

— Һай-й, алла! Соң ул да җан иясе ләбаса! Сезнең өчен хезмәтче вазифасын үтәүче генә булгач та, ул да бит хатын-кыз... Әллә аның үзенең төп вазифасын үтисе килми дисеңме?.. Ягъни ана буласы, бала табасы килми дисеңме? Бала тели ул, бала!.. Аңлыйсыңмы шуны? Менәтерәк, чүлмәк салып, өшкергәндәй иттем әле үзен...— Мәгыйшә карчыкның, карчыганыкы сыман зәһәр күзләре, өй хуҗасының йөзенә текәлде. Тегесенең күтәрелеп бәрелергә, ачуланып-тузгый башларга атлыгып тормавын күргәч, тагын да кыюлана төште.— Тик белмим, кем, Иргали, бәгырь... Тыны шифалы, фәлән-төгән дип, күпме генә даным чыккан булмасын, монда минем әфсүн-төфсеннәрем, ырым-шырымнарым, өшкерү-төкеренүләрем генә әллә ни майтара алмастыр кебек... Чын әгәр. Сихер, зәхмәт кенә йоккан булса бер хәл иде, бәлки шифасы да тиеп куяр иде. Монда белмим шул. Үземнең бөтен табиблык осталыгымны җиккән хәлдә дә әллә ни кыра алмамдыр төсле. Монда хәлләр тылсымлы сүрә укып, өреп-өшкереп кенә савыктыра алудан узган...— Исе китүдән, авызына су алгандай торган Иргалинең терсәгенә җиңелчә генә кагылгандай итте дә, күзләрен яман мәкерлеләндереп, тавышына шайтан вәсвәсәсе кушып, өстәп тә куйды.— Әллә, кем, Иргали бәгырь, син ярдәм итеп карыйсыңмы? Ә?..

Им-томчының көтмәгәндә ясаган бу тәкъдименнән Иргали көләргә дә, ачуланырга да белмәде.

— Ничек итеп?..— дигән булды ул кортканың тел төбен аңламаган сыман итеп.— Әллә минем дә өшкерү-төкерү белән маташуымны теләр идеңме? — Әмма йорт башы узынган убырлы карчыкның авызын томаларга булды. Ул күзгә күренеп кырысланды һәм чынлап торып әрли үк башлады.— Моңардан соң ничек инде сине «пәри комалаган нәрсә» димисең, ә! Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетәме соң синең, ә? Нәрсә тәкъдим иткәнеңне төшенәсеңме соң син? Миңа бит хәзер кырык яшь! Ишетәсеңме шуны: кы-ры-ы-к яшь! Кызым кияүгә бирерлек бит минем...

Телчән корткага сүз таба торганмы соң! Әнә күр, теле телгә йокмый бит мөртәтнең, тәтелдәпме-тәтелди. Йөзендә-сүзендә кинәялек җитмәсә...

— Һай-й, бәхетең арткыры! Күрче зинһар, авызын кыеш-мыеш китереп: «Кы-рык яшь»— дип торуларын гына күр! Күңелеңә берүк авыр алма, Иргали бәгырь, дивананың да диванасы икәнсең. Әгәр дә бик инде беләсең килсә, кырык яшь ул адәм баласының акыл утырткан, сабырлык-зирәклек туплаган, иң егәрле, кодрәтле, беләгендә көче, йөрәгендә дәрте ташып торган чагы. Менәтерәк, тиле түгел диген инде сине шуннан соң! Шуны бел: кырык яшь ир-ат затының иң дәртле, иң илһамлы, хатын-кызның һушын ала торган чагы. Яа-а, ходаем! Булса да булыр икән үз кадерен үзе белмәгән тилемсә бәндәләр!..— Мәгыйшә карчык шаярткан сыман итеп Иргалинең касыгына төрткәләп алды.— Тфү-тфү, берүк күзләр

тия күрмәсен үзеңә! Шушындый типсәң — тимер, орсаң өрлек сындырырлык Салсал батырдай килбәтле гәүдәләрең барда, авызыңны күтәреп: «Кы-рык яшь!» — дип торган була бит әле. Тиледер син, валлаһи! Ә аның балага сусап тәкать тотмай торган чагы. Синең ише имәндәй нык, әзмәвердәй сау-сәламәт ир тансык аңа... Я-а, ходаем, булса да булыр икән хатын-кызда шундый кайнарлык... Таза-ныклыгы әллә кайлардан бөркелеп тора инде менә. Ул, мин сиңа әйтим, буй-сынының иплелеге һушлардан яздырырлык инде менә. Тәненең тыгызлыгы турында әйткән дә юк, иңнәренә һич тә ир-ат кулы сарылган димәссең, тач житлеккән кузак инде менә...

Ниһаять, Иргалинең сабырлыгы сынды, авызыннан ут чәчеп, чамасын югалта башлаган сихерче карчыкны тыярга булды. Шактый ук каты бәрелде:

— Життеме сиңа, юкмы, канса кәнис! Ул кадәр узынам дигәч тә, чак кына чама да белергә кирәктер ич. Син нәрсә, әллә аның минем туганым, балдызым икәнлеген онытып жибәрдеңме? Югыйсә исеңә төшерергә дә күп сорамам. Ул бит сиңа каяндыр килгән килмешәк яки анда нindидер асрау кыз түгел...

Бар, тыеп кара син Мәгыйшә кебек дөнья күреп, остарып-шомарып беткән ил корткасын.

— Һай-й, алла! Авызын күтәреп: туганым, балдызым дип торган була бит әле. Булса соң! Балдызларны якын күрү, үз итү, балдызларның биленә кул салу — борынгыдан калган йола. Андый эшне әүлиялар, пәйгамбәрләр дә инкарә итмәгән. Синең жылы канатың астында жил-яңгыр күрмичә, ожмахның ожмахында — башка берәүләрнең төшләренә дә кермәгән сый-хөрмәттә яши. Әйтсәм әйтим инде алайса: сиңа бер түгел, мең хәләл ул. Берәү дә — алла да, бәндә дә сине гаепләмәс. Аннары ул сиңа туры балдыз да түгел бит әле. Хәләл жефетең — Гөлниса белән карындаш туган түгел дип әйтүем...— Мәгыйшә карчык өздереп кенә янә Иргалигә күз төшереп алды. Өй хужасының сүз таба алмаган сыман тораташ булып катып торуын күргәч, тагын да кыюланды, күзләрен майландыра төшеп, авызыннан янә зәһәр чәчә башлады.

— Андый хәлләр, Иргали бәгырь, тормышта атлаган саен. Тикмәгә генә: күрше хатыны күршегә кунак кызы булып күренә димәгәннәрдер. Ире ир булса бер хәл иде. Юк бит! Моңарчы түзгәннәреңә дә шөкер итәрлек инде. Синең урында башка берәү булса, күптән инде...— Кортка, кеше-кара ишетмиме дигәндәй, як-ягына каранып алды да, әйтәсе сүзен әйтеп бетерә алмаудан курыккандай, ярым пышылдауга күчеп, дәвам итте.— Алла шаһит, кем, Иргали бәгырь, минем бүтән чарам да, чамам да калмады. Әллә мин әйтәм, чыннан да, үзең генә... Ни... ни дип торам. Дәрт-дәрманга әжәткә керерлек түгелсеңдер әле шәт. Әнә күр, көч-гайрәтең ташып ашкан ирсең. Керсәнә хәлләремә... Бердән ходайга, икенчедән сиңа мең-мең рәхмәтләр укыр идем. Шуны бел, бала тапмаган хатын — кысыр сыер ул. Мин сиңа азып-тузып, зина кылу ише хәрам эш тәкъдим итмим ләбаса. Бары тик аллага инанган кебек күзләреңә генә карап торган, сез дип жанын фида кылырга, сез дип, чәчләре белән жир себерергә әзер торган сөекле балдызыңа бер изгелек эшлә дип кенә ялынып-ялваруым. Дөньялыкта ул да үз вазифасын үтәсен инде. Савабы үзеңә булыр иде...

Моңа кадәр булган барлык сабырлыгын туплап түзгән Иргали, ниһаять, ычкынды. Иң әүвәл, хәйран булудан исе киткән кешедәй, башын селкеп торды, аннары кортканың үжәт күзләренә туп-туры карап, эттән алып эткә салып сүгә башлады.

— Иман дигән нәрсәнең заты да юк икән син бәндәдә. Чистый иблис икәнсең. Авызын тутырып: «Изгелек», «Савап»,— дип торуларын күр әле син моның. Аһ-һ, аждаһа, аһ-һ убырлы!..

Бер авызын ачкан кортка, тиз генә бирелү турында уйламый да, Иргалине бүлеп, тәтелдәвен белде.

— Абау-у, изгелек, савап дими, ни диим тагын?!. Юкны бар итсәң, савап булмый ни булсын ди. Бер бездән генә калган нәрсә түгел. Икәү ятып өчәү торганны китап та хуп күрә... Алайга киткәч, әйттем исә кайттым. Ире, ире чамалы шул. Орып-сугып хараплар иттеләр шул бахырны. Гарип-горабага әверелдерделәр... Болайга киткәч, читтәнрәк белешермен... Әй-йе! Андый, чибәрлеге күзгә төшеп торган сау-сәламәт, яшь сылу хатынга күзләре янучылар табылмас дисеңме әллә? Кәсеп итсәң, насыйп була ул...

Иргали үзенең чынлап торып ярсый башлавын тойды. Ахыр чиктә үзенең иң яман, соңгы чутта гына әйтелә торган сүзен дә әйтте.

— Аһ-һ, мур кыргыры! Аһ-һ, үләт! Белешермен мин сиңа, пәри комалаган нәмәстә. Икенче бу тирәдә ялгышлык белән генә күренсәң дә, үзеңә үпкәлә.

Тегесе бер дә «Китәм!» дип каударланып тормады. Ахыр чиктә Иргали Мәгыйшә карчыкны этеп-төртеп куып чыгарды. Әмма бу очрашу, очрашудан да бигрәк әлеге әңгәмә, аның күңелен урыныннан кузгатты, җанына таракан йөгерткәндәй итте.

Өйгә кергәч тә тиз генә тынычлана алмады Иргали, җанын кая куярга белмичә бәргәләнде.

Әкренләп акшам вакыты җитте. Өйгә әңгер иңә башлады. Шулчак ишек артында туңган идән сайгакларының шыгырдавы ишетелде. Ни өчендер, бары тик бер генә мизгелгә үзен җинаять өстендә тотылган кеше сыман хис итте Иргали. Чыннан да, балдызының керүен көтеп утырмый идеме соң ул? Нәрсә булды соң әле аңа?..

Ишек ачылып китте. Иң әүвәл, бүлмә эчен иңләп, ап-ак суык җәелде. Ниһаять, көянтә-чиләкләрен күтәргән Миңсылу күренде. Бит алмалары комач кызыл, мамык шәле кырыйларына, сыпылып чыккан чәч бөртекләренә мул булып кунган бәс, кыйммәтле ташлар кебек, җем-җем итә. Балдызына ияреп, өйгә рәхәт салкын, күңелне күтәрә торган саф һава, юып тышта киптерелгән кер исе бөркелеп керде. Миңсылу да билдән тиң су ерып үткән кебек, көянтә-чиләкләрен күтәреп, аралык аша кече якка кереп китте.

Иргали йөрәгенең ләззәтле сулкылдавын һәм ешрак тибә башлавын тоеп, балдызкае кереп киткән якка колак салды. Менә Миңсылу чиләкләрен тәрәзә буенда торган эскәмиягә куйды. Чиләк төбенә катарга өлгергән боз сөңгеләренең идәнгә тигәч, күңелле генә кетердәп уалуы аермачык булып ишетелде.

Иргалинең ачы бал турында сүз кузгатуы булды, Миңсылу:

— Хәзер эшлибез аны, җизни,— дип, урыныннан сикереп үк торды.

Ничә минут үткәндер, озынча муенлы чүлмәккә салынган, салкын идән астында әчеп кымырҗуы җиткән бал Иргали каршында утыра иде инде.

Икенчеме, өченчеме тустаганны тутырганда, балны мактады, тәмам җитлеккән диде, табын янындагы хатын-кызларны да авыз итеп карарга кыстаган булды. Бу сүзләрне әйткәндә күзләре балдызында иде. Җитмәсә тагы сүзләре дә ничектер табигый чыкмады. Моны ул үзе дә сизде. Уңайсызланды. Болай ярамас, дип үз-үзен кисәтеп тә куйды. Сихерче карчык ни димәс. Хисләрне дә йөгәнли белергә кирәк. Алла сакласын, яман яктан бер телгә керсәң, ил өстендә ничек яшәрсең. Күңеләңә шундый бер бозык уй, бозык исәп кенә керсен, аннары инде бетте, кешелегеңне җуйганыңны бел дә тор.

Ниһаять, табын җыештырылды. Урын-җир җәйгән арада Миңсылу, өйдәгеләрнең барысына да берьюлы мөрәҗәгать иткән сыман, абзардагы ике сыерның берсе бүген-иртәгә бозаулаячагы турында хәбәр салды. Бары тик шуннан соң гына, тыныч йокы, татлы төш теләп, үз өенә чыгып китте.

Утлар сүндерелде. Тирә-юнь тынлыкка чумды. Мич аралыгында сыңар чикерткә генә үз җырын сузыпмы суза. Әмма Иргалинең күзенә йокы кермәде. Тынып калган дөньяны гизгән тулы ай да, ниһаять, ян тәрәзәгә күз салды. Иргали һаман ята. Уйлары һаман бер тирәдә чуала аның. «Чукынып кына китсен инде»,— дип, чынлап торып сукранып та алгалый ул. Чыннан да, сихерче карчык сүзеннән соң әллә нәрсә булды аңа, күңел түренә әллә ниткән тынгылык бирми бимазалый торган өр-яңа бер хис кереп оялавын тойды. Бая гына бөтен табынны бизәп утырган Миңсылу, аның алсу йөзе, зифа буй-сыны, кызларныкы сыман төртеп торган күкрәкләре, җитез-өлгер, ипле-килешле хәрәкәтләре күз алдыннан китми газапладды. «Мөгаен, яз галәмәтедер...» — дигән нәтиҗә ясагандай итте Иргали үзенчә. Ни әйтсәң дә, күңеленең бик сизгер, бик нечкә, бик тәэссоратлы чагы. Кан шаяра, һәр җан иясе яңара, һәр тереклекнең саф һавага, һәр кояшлы аяз көнгә сөенә-сөенә яши торган вакыт җитте.

Иргали, барыбер йокыга китә алмаячагын тәмам төшенепме, ухылдап урыныннан торды. Йокыга ифрат та сизгер Гөлниса иренең бу халәтенә әллә ни дикъкать итмәде. Бозаулыйсы сыер, колынлыйсы ат-мазар булганда, ким дигәндә биш-алты мәртәбә абзар тирәләрен әйләнеп керү йорт иясенең фарыз эше ләбаса.

Әмма бу юлы Иргалине ниндидер башка көч, башка фикер урыннан күтәрде. Нәрсәгәдер күңеле кытыклана, йөрәге күкрәк читлегеннән сикереп чыгардай булып тибә, бөтен барлыгын ниндидер бер татлы, бик тансык бер ашкынулы теләк, бер генә минутка да тынгылык бирмичә, бимазалап торуын тойды.

Тагын бер ят уй тууын абайлап алды ул: бу минутта балдызы янында берәр ят ир-ат бардыр сыман булып тоела башлады. Әлеге шыксыз уй тууы булды, Иргалинең тыны кысылып кына калмады, йөрәк тибеше чигәсен кыйнарга ук кереште. Бу яман уйны тизрәк башыннан чыгарырга тырышып карады. Ә бит ул яхшы белә: Тырнак чылбырыннан ычкындырылган чакта, ишегалдына кеше түгел, күрше тавыгы да керә алмаячак.

Иргали, шундый уйларга бирелеп, алгы якка чыкты. Ялан аягына киез катасын киеп алды. Мал-туарны карарга чыкканда йөртә торган фонарен кабызды. Сөремләнгән куыгын сөртештергәндәй итте. Бары тик шуннан соң гына ишек катындагы чөйдә эленеп торган толыбын җилкәсенә салып, тышка чыкты.

Аны җил урынына абзарлар өстеннән очып төшкән Тырнак каршы алды. Куанычыннан нишләргә белмәде, хуҗасының аякларына сарылды, тиен урынына бөтерелде. Иргали буш кулы белән Тырнакны сыйпаштырды, сөйде һәм үз урынына сакка басарга кушты. Эт иң элек үз оясы, аннары абзарлар өстенә сикереп менде дә, таштан коеп куйган сын кебек булып, яңадан тыкрык буйларына, бакчалар артына карап, тынып калды. Гомумән, кирәксә-кирәкмәгәнгә өрә торган гадәте юк иде Тырнакның.

Иргали түрдәге кече өй ягына күз салды. Анда тынлык. Бары тик ишек алдына караган сыңар тәрәзәгә генә ай яктысы төшеп, өй эчендә ут янганга охшап тора иде. Ул янә һәр күзәнәгендә ниндидер ашкынулы, җилкенүле хис кайный башлавын тойды.

Иргали, нәфесен котыртмаска теләп, тизрәк абзар ягына борылды, фонарен җиргә куеп торып, иң әүвәл аран бөркәвенең сыңар канатын гына ачып, эчкә үтте. Шундук борынына шулкадәр дә таныш, шул тикле дә якын мал-туар, печән һәм юеш яңа тирес исе килеп бәрелде. Иргали, фонарен баш өстенә күтәреп, терлекләрне барлады. Әнә имән сайгак җәйгән кырый бүлектә бүген-иртәгә бозауларга тиешле сыер тора. Нәрсәдер өмет иткәндәй, олы күзләрен сәер мөлдерәтеп, Иргалигә таба борылды. Бик авырыксынып, теләр-теләмәс кенә хуҗасы ягына таба хәрәкәтләнеп куйды.

Иргали, филтәсен чак кына кыса төште дә, фонарен баганадагы кадакка элде. Сыер янына килде.

— Нәрсә, хәлләрең хәлме? Зарар юк, бар дә һәйбәт булыр...

Сыер, авыр гәүдәсен авыш-тәвеш китереп, тагын бер-ике адым алга таба атлады да үзенең кайнар, дымлы, чалгы янавычыдай кытыршы ирене, теле белән Иргалинең сузылган кулына төртелде. Хуҗасы да үз чиратында күнегелгән хәрәкәтләр белән аның муенын, колак артларын сыйпаштырып алды.

— Чак кына түзәргә, сабыр итәргә туры килер... Нишләмәк кирәк, дөнья шулай яратылган инде.

Иргали сыер алдындагы буй тагаракка күз салды. Җебетелгән икмәк, көрпә апарасы исе аңкып торган парлы башакка кагылмаган да бичара малкай.

— Болайга киткәч, бүгеннән дә калмассың инде, ходай кушса...

Сыер белән сөйләшсә дә, бу мизгелдә Иргалинең уе, хыялы һаман да, әлеге дә баягы, кече йорт тирәсендә иде. Ул тагын бер нәрсәне бик анык төшенде: бик теләгән тәкъдирдә дә, дәртен кузгатып җибәргән балдызкае турында уйламыйча булдыра алмас иде. Күңел җилкеткеч әлеге тынгысыз теләктән тыелып калырга тәкате юк иде инде аның.

Иргали ни кылганын да белештермәгән кеше сыман, үрелеп фонаренең филтәсен тагын да кыса төшеп, абзардан чыкты. Кече өйнең ишеге әнә генә, күп булса ун-унбиш адымда гына. Нишләргә? Аны ниндидер киеренкелек биләп алды. Йөрәк урыныннан купты. Сулышы үзгәрде. Тәненә әйтеп бетергесез рәхәтлек, татлы хәлсезлек таралган сыман булды.

Менә ул ишек катында. Тез буыннары гына түгел, бөтен әгъзаларының җиңелчә генә калтыравын сизде ул. Шашкан күңеле тәмам тилертте аны. Һәм Иргали тәвәккәлләде, йөрәкләнеп китеп, бөтен ихтыярын бергә туплады да җиңелчә генә ишек келәсенә кагылды.

Миңсылуның ялт итеп өйалдына чыкканы ишетелде.

— Кем бу?

Иргали янә югалып калды.

— Бу мин...— диде ул калтыранган тавыш белән.

— Һай-й, ходаем ла, Гөл апага бер-бер хәл булдымы әллә?

Ишек ачылып китте. Ай яктысында ап-ак эчке күлмәктән Миңсылу басып тора иде.

— Борчылма...— Ул-бу юк,— диде Иргали, кинәт кенә тамагы кибеп чатный башлавын тоеп. Менә ул иелә төшеп, бөтен ишекне тутырып, эчкә үтте. Ишекне ябып, үзе артыннан эшермәле бикне этәреп куйды.

Тәмам каушап-югалып калган Миңсылу, кулларын күкрәге турысында кушырып, артка таба чигенә башлады.

— Җизни... Ут алыйммы?

— Кирәкмәс...

Иргали, җилкәсендәге толыбын шунда почмакта торган бүкән өстенә генә шудырып төшерде дә янарак кына юрган астыннан чыккан балдызкаеның кайнар гәүдәсен шашкын бер дәрт белән кочагына алды.

— Һай-й, җизни!..— дип өзгәләнде Миңсылу ярым пышылдап.— Ярый торган эш булмас бу... Гөл апа сизенә-нитә калса, нишләрмен?..

Хисләре ташып, тыны кысылган Иргали бары тик бер генә сүз әйтә алды:

— Сизенмәс.

...Иргали яңадан абзарга чыкканда, фонарьнең мае бетеп, филтәсе күмерләнгән, сыер бозаулаган, салам өстендә ямчылар кия торган тире бияләй кадәр генә булып йомарланып яткан бәләкәчен ялтыратып ялап куярга да өлгергән иде.

*Дәвамы киләсе санда.*

# Роберт Миңнуллин

## Марафон

Мәңгелек марафон кебек —
Кешелек, алга барыш!
Ул шулай мең гасырларга
Сузыла алган ярыш.

Син дә, халкым, киткәнсең дә
Кешелеккә ияреп,
Киләсең ерып чорларны —
Алдыңда баш иярлек!

Абынып та егылгансың,
Чалып та екканнардыр.
Шуңа кайчак кайберәүләр
Алга да чыкканнардыр.

Тик карамый давылларга,
Ялкыннарга, утларга,
Атлы рәтләрдә киләсең! —
Исәбең юк туктарга.

Киңәя генә сулышың,
Тының ачыла гына.
Финиш әле күренми дә.
Юл — озын. Чыда гына!

Егылсаң да, яңадан тор!
Абынсаң, алга талпын!
Старт бер алынган инде,
Туктау юк сиңа, халкым!

Туктарга синең хакың юк.
Туктау — үлем белән бер.
Туктый күрмә! Алга таба
Меңе белән түләнер.

Сокланып сиңа гасырлар,
Чорлар кул болгаячак!
Марафон дәвам итә.
Тик
Финишы булмаячак...

## Шагыйрьләр

«Тукай яшен узып барам»,—
Дип язган идем күптән.
Ул шигырь язылганга да
Гомерләр шактый үткән.

Тукайлар, Бабичлар яше
Сизелми дә узылды.
Ах, безнең бу өлгерүләр
Озаккарак сузылды.

Әйтәләр әллә үз итеп,
Әйтәләр әллә көлеп,
«Яшь шагыйрьләр»,— диләр безне
Ун ел элекке кебек.

Мин — яшь шагыйрь — озакламы
Җитәм Пушкин яшенә.
Ә гомерем — йомгагының
Очын һаман яшерә.

Гомер җитез... Бу дөньяда
Туфаннар яше дә бар.
Үзенчә яши һәр шагыйрь,
Һәркем үз яшен табар!

Яшибез... ә гомерләрнең
Кыйммәте ни, тәме ни?
Үз яшенә җитәр һәркем —
Тик хикмәт яшьтәмени?!

---

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН (1948) — шагыйрь, «Бәхетле булыгыз», «Айга очтык», «Мәңгелек сәфәр» һ. б. зурлар һәм балалар өчен татар һәм рус телләрендә басылган шигырь китаплары авторы, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.

## Бабамнарның каны уйный синдә...

Бер тынмас җан булдың инде, энем!
Тора алмыйсың бер урында.
Син яшисең әле, әйтерсең лә,
Күчмә кабиләләр чорында.

Бер караганда син Әстерханда,
Я Казахстанда, я Казанда,
Я Шәммәттә! Тик һаман да сиңа
Нидер җитми, нидер аз анда.

Юлы булса, ике уйлап тормый,
Чыгып китәр идең Айга да.
Тик аңладың микән — шул ук икән
Дөнья дигәннәре кайда да...

Ерак җирләр сине тарта һаман,
Каян килгән сиңа күчмәлек?
Ул, мөгаен, ерак гасырлардан —
Бабаларыбыздан истәлек.

Дала җитми синең күңеленә,
Киңлек кирәк синең кебеккә.
Аргамаклар кирәк чабар өчен
Батырганчы ап-ак күбеккә.

Чыгар өчен ерак сәфәрләргә,
Торыр өчен һаман ыргылып...
Бабамнарның каны уйный синдә,
Шул бирмидер сиңа тынгылык.

Тик без күптән утрак тормышта шул,
Туры килә шунда кайнарга...
Әнкәй тагын бик борчылып язган —
Җыенасың тагын кайларга?

## Сагыш

Зур бер сагыш яши күкрәгемдә.
Зур бер сагыш оча күкләремдә.
Зур бер сагыш!

Зур бер сагыш җанда, юк, тик ятмый.
Зур бер сагыш мине, юк, йоклатмый.
Зур бер сагыш!

Зур бер сагыш телим сиңа да мин.
Зур бер сагыш килсен сиңа. Амин!
Зур бер сагыш!

Зур бер сагыш янсын күкрәгеңдә.
Зур бер сагыш очсын күкләреңдә.
Зур бер сагыш!

Зур бер сагыш янсын, тик ятмасын.
Зур бер сагыш сине йоклатмасын.
Зур бер сагыш!

Зур бер сагыш... ансыз тыныч күңел.
Зур бер сагыш тик... куркыныч түгел!
Зур бер сагыш!

Зур бер сагыш... Ул иң олы табыш.
Ул — мәхәббәт, ул һәркемгә таныш.
Зур бер сагыш!

❁

Халкым күргән хәсрәтләрне,
Кайгыларны, михнәтләрне
Йөрәгемә җыеп барам
Һәм нәфрәткә әйләндерәм —
Дошманым өчен!

Халкымдагы аклыкларны,
Бәхетләрне, шатлыкларны
Йөрәгемә җыям да мин
Мәхәббәткә әйләндерәм —
Дусларым өчен!

❁

Төнем якты, нурлы булыр —
Кояшның соңгы нурын
Алып калдым мин үземә,
Бер нурсыз калмас борын.

Кояшта нур — кеше саен.
Тиеш миңа үз нурым.
Кояш нуры булса гына
Балкыр минем күз нурым!

## Алтын алма

Сине генә яратырмын дидең,
Иң бәхетле кеше иттерсәң —
Әгәр мине оҗмах бакчасыннан
Алтын алма өзеп китерсәң.

Яратыласым бик килә иде —
Башка чара миңа калмады.
Ничек итсәм иттем, ләкин табып
Китердем ул алтын алманы.

Һәм яраттың мине. Ә алмасы
Әй тәмле дә, ал да иде ул —
Үзегезнең алма бакчасыннан
Урлап чыккан алма иде ул.

❁

Галактика. Галәм. Йолдызлыклар...
Күпме алар йолдыз кырында!
Тик башкалар кебек шәп шигырьләр
Язалган юк алар турында.

Ниндирәктер? Нинди матдәдәндер?
Гыйбарәтме алар ялкыннан?
Бөтенләй ят дөнья. Мин аларны
Күргәнем юк бер дә якыннан.

Ерак йолдызларга багышлап мин
Шәп шигырьләр язар идем дә...
Һаман барып чыга алганым юк
Шул галәмгә — йолдыз иленә.

## Гомер

Гомер уза...
Йөрим гомер
Турында уйлап —
Гомер узмый,
Без узабыз
Шул гомер буйлап!

## Ерактагы кояш

Син беләсең микән, безнең сөю
Башкаларныкыннан татлырак.
Юкка гына әйтмәгәннәр икән:
Ерактагы кояш яктырак.
Ерактагы кояш —
Йөрәктәге кояш.
Йөрәктәге кояш яктырак!

Нишләргә дә белмәгәндә кайчак,
Йөргән чакта ялгыз аптырап,
Мин үземне ышандыра башлыйм:
Ерактагы кояш яктырак.
Ерактагы кояш —
Йөрәктәге кояш.
Йөрәктәге кояш яктырак!

Очар идем кайнар кочагыңа,
Син яшәгән якты як ерак.
Булсын, әйдә, булсын! Ә шулай да
Ерактагы кояш яктырак.
Ерактагы кояш —
Йөрәктәге кояш.
Йөрәктәге кояш яктырак!

Безнең кебек беркем яраталмый —
Мәхәббәткә без бит хаклырак.
Торган саен ныграк аңлый барам:
Ерактагы кояш яктырак.
Ерактагы кояш —
Йөрәктәге кояш.
Йөрәктәге кояш яктырак!

## Кайда да...

Тар ла миңа Казан гына,
Үскәнгәдер иркендә.
Туган яклар тарта мине —
Түгел мин үз иркемдә.

Җырлыйм туган якларымны
Каладагы көемә.
Кайтып китәм Актанышка,
Илешемә — өемә.

Китеп барам Исәнбәтләр,
Еникилар ягына.
Ул якларда, беләсезме,
Нинди көйләр агыла?

Ул якта да иң борынгы
Көйләр бар — без белмәгән.
Ничә гасыр җырланганга,
Алар исән, үлмәгән.

Ул көйләрне аңлап була
Үзең көйләсәң генә.
Бер көйләсәң, моңлы затка
Әйләнәсең мәңгегә!

Әле дә кайтсам, йөрим мин
Исереп шул көйләргә.
Үзем көйлим, үзем шуны
Юрыйм әллә ниләргә...

Һәм кайтам мин Казаныма
Яктырып, канатланып!
Кайда да үзебезнең моң,
Кайда да безнең халык.

*1984—1985.*

# Батулла

# АЛЫП БАТЫР МАҖАРАЛАРЫ

ПОВЕСТЬ-ӘКИЯТ

## Батырның тууы

лып батыр шулкадәр олы гәүдәле булган ки, ул чабата каккан җирдә тау өелеп кала икән. Таулы җирләрнең барысы да Алып батыр узган юллар ди. Урал тавы Алып батырның уң чабатасыннан коелган өем икән дә Каф таулары аның сул чабатасыннан төшеп калган кантарлар имеш.

Дөньядагы явыз затлар белән сугышып арыганнан соң Алып батыр Иделгә әйләнеп кайткан. Бик тә уңган, бик тә матур бер кызга өйләнгән бу. Шуннан моның ике углы туган. Игезәкләрнең берсенә Болгар, икенчесенә Буртас исеме кушканнар. Болгар иленең тарихы, имеш, шуннан башлана дигән риваятьләр йөри.

Алпамша батырны шул нәселдән, ягъни Алып нәселеннән чыккан кеше, дип сөйли картлар. Алпамшаның туруны — ягъни оныгының баласы — Алып Мәргән булып чыга. Алып Мәргәнгә «мәргән» исеме төз атучы булганга күрә бирелгән.

Яманлыкка каршы гомере буе көрәшсә дә, Алып Мәргән үзенең иң зур дошманы — куәтле Аждаһаны җиңә алмады. Җиңүен җиңгән дә булыр иде, Аждаһаны очрата-тота алмады ул. Малларны талый да кача, кызларны урлый да юкка чыга теге мәлгунь. Аждаһаның кайда кышлаганын, кайда җәйләгәнен һичкем күрсәтә алмады.

Әүлияләр әйтүенчә, Аждаһаны Алып Мәргәннән туган батыр җиңәргә тиеш иде. Нишләмәк кирәк, Алып Мәргәннең баласы булмады. Картаеп та бара, ни аяныч: хатыны — бичара аңа угыл түгел, кыз бала да китермәде.

Ходаның рәхмәте киң диләр, дөньяда нинди генә могҗизалар булмый! Илле яшькә җиткәндә, Алып Мәргәннең хатыны балага узмасынмы!

Һиҗрәттән соң тугыз йөз дә унөч ел узгач, Елан елында, Сәфәр аеның дүртенче атна уртасы — Кан көнендә, таң алдыннан Алып Мәргән йортында бер ир бала дөньяга килде.

— Әйтергә генә ансат: буе өч чирек ярым, унике кадак авырлыгы! Карыш буе бәләкәй генә шушы хатын бу баланы ничек күтәреп йөргән дә ничек тудырган! — дип бөтен хатын-кыз шаккатты бу хәлгә.

---

РОБЕРТ БАТУЛЛИН (1938) — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татар Дәүләт драма һәм комедия театрының баш режиссеры. «Әбугалисина», «Кичер мине, әнкәй», «Өчәү чыктык юлга» һ. б. әсәрләре төрле сәхнәләрдә уйнала. «Серле сандык», «Ташламам, җанкисәгем», «Чебен гөмбәсе» һ. б. дисталәгән әкият, хикәя, пьеса җыентыкларының авторы. Казанда яши.

Алып Мәргән, баланы үзе тудырганнан да яманрак көчәнеп, өй тирәли егерме сәгать буе тилмереп, сызланып йөрде.

— И Тәңрем, бала исән-сау тусын да; әнисе өзлегеп китә күрмәсен! — дип чын күз яшьләре белән елап, изге теләкләр теләп, ашамыйча-эчмичә кайгырды бичаракай.

Баласы да сау-таза, хатыны да шөкер генә, күз тимәсен дигәндәй, бу куанычтан Алып Мәргән бөтен кешене бәбәй туена чакырды. Бар да бәйрәм итә. Ләкин ана кешенең күңеленә шом инде:

— Сәфәр аенда туды, улым өйдә тормас инде. Елан елында туды — эшләре хәтәр булыр, мөгаен. Атнаның икенче көне — Кан көнендә туды, башы сугыштан чыкмас микәнни? — дип кайгырды ана.

Ә кунакларга ашау-эчү, җыр-бию булсын. Рәхәтләнеп күңел ача халык, берсеннән-берсе уздырып, яңа туган баһадирга исем эзлиләр. Ләкин тупырдап торган бу пәһлеванга ярашлык исем һаман табылмады.

— Ярар! — диде атасы.— Үзе сау-таза булса, исеме табылыр әле.

Чыннан да, шулай булды. Бәбәй туена килгән кунаклар арасыннан берәү:

— Әбәү, кара чутыр! Бигрәкләр дә кара булып туган! Кашы кара, күзе кара, үзе кара. Тефү-тефү, күз тимәсен! — дип, бәләкәчнең ике битен, маңгаен корымга буяп куйды да: — Каракүз! — дип баланың колагына пышылдады.

Шул исем бу оланга ябышты да калды.

Каракүз туган көнне Алып Мәргән ихатасында бердәнбер биясе колынлады. Авылның күрәзә багучылары, дөнья күргән аксакаллары — һәммәсе дә бу вакыйганы үзләренчә юрадылар.

— Бик хуп, бик күркәм эш! — диделәр.— Ир бала туган көнне курада ат колынласа, зур эшләр галәмәте булыр! — дип, бу угланның киләчәктә зур каһарман булачагы, үзе белән бер көнне туган айгырына атланып, бихисап күп батырлыклар эшләячәген әйттеләр.

Шулай итеп, чем-кара бу колынга Таштояк дип исем куштылар. Ләкин, ни хикмәттер, Таштояк әллә ни мантып китә алмады. Чәндер сыйраклы, кыска торыклы булып чыкты. Шуңа күрә хуҗасы аңа «Корангыш» дип дәшә башлады. Корангыш кына димәссең, үзе тагын бик чарыш-тернәкле тай булып үсте. Ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп дигәндәй, Каракүз дә үсмер булып җитте.

Шулай бервакыт Каракүз, көндәгечә ат эчерергә дип, инешкә төшкән иде. Ни өчендер аты Корангыш суга әйләнеп тә карамый. Каракүз и сызгыра, и сызгыра, янәсе, сызгыргач, эчәсе килмәсә дә, ат су эчәргә тиеш! Әмма Корангыш ул сызгырганга карап кына инешкә иренен дә тигезмәде. Ул, су агымы уңаена башын борган да, озын керфекләрен шап-шоп бәргәләп, каядыр карап тора.

Каракүз:

— Нигә эчмисең, Корангыш? — дип сораган иде, кинәт ат телгә килде:

— Дивана! — диде Корангыш саф үзебезчә.— Күзең юктыр синен! Күрмисеңмени, басмада Нәүмизә кер чайкый!

Каракүз аты ишарәләгән якка карады. Чыннан да, басмада Нәүмизә, чүгәләгән килеш, кер чайкый иде.

— Шундый матур, уңган кызны күргәнгә телгә килдем. Бу кыз телсезне телле, сукырны күзле итәр! Ә син — «фиу-фиу», сызгырудан башканы белмисең, сыбызгы!

Чынлап та, Каракүз шул матур кызны моңарчы ничек күрмәгән икән? Нәүмизә, үзенә чекерәеп карап торганнарын сизенеп, итәген тартып куйды да яулыгын төшеребрәк бәйләде. Эшен бетергәч, керләрен чиләкләргә тутырды да, тыкрык буйлап авылга менеп китте. Үзе җырлаган була:

Ат эчерә торган ие,
Сызгыра торган ие.

Ә чулпылары! Чулпылары йөрәккә бәрелеп зеңгелдимени!

Шуннан соң алар тагын бер очраштылар. Бу юлы әрәмәдә. Каракүз, кәрҗин үрергә дип, тал чыбыгы кисеп азаплана иде. Якыннан гына каз бибиләре куа-куа, такмаклый-такмаклый Нәүмизә үтеп китте. Юл кырында гына чыбык тураучы Каракүзне күрде кыз, әмма күрмәмешкә салышты. Үзе Каракүз турында җырлый:

Таллар кисә, таллар кисә,
Үтми шул пәкеләре.

Каракүз аның артыннан авызын ачып карап калды. Бер сүз дә әйтә алмады.

— Яп авызыңны! Карга нитмәсен! — дигән тавышка Каракүз, сискәнеп, артына борылды.

Караса, үз аты Корангыш аны үртәп тора икән. Кеше булса, Каракүз шулкадәр оялган булыр иде дә, үз Корангышы булгач, әллә ни исе китмәде. Ачык авызын ябып, чыбык көлтәләргә кереште.

Нәүмизәнең ата-анасы да, Каракүзнекеләр дә егет белән кыз арасындагы бу карашларны тиз сизделәр.

— Атасы! — диде Нәүмизәнең әнисе.— Каракүз батырлар нәселеннән, әллә кодалашабызмы дим?

— Сабыр, кортка, сабыр! — диде Мортыш бай.— Батырын батыр, тик курасында бер корангыш атыннан башка бете дә юк. Атасы Мәргән батыр була торып та мантый алмады. Монысы тагын, атасы баласы, йөри шунда вакыт уздырып, чабата туздырып.

— Карчык! — диде Алып Мәргән.— Нәүмизә дә Каракүзгә матур карый бугай. Каракүз дә хәзер йокыга китә алмый озак ята. Әллә тәвәккәлләп соратабызмы? Каракүз кебек баһадирга бирми калмаслар.

Шулай иттеләр дә. Тирә-юньдәге атаклы яучыны кыз соратырга юлладылар. Ләкин яучы карчык аларга яхшы хәбәр алып кайтмаган иде шул.

— Юк! — дигән Мортыш бай яучыга.— Читкә чыгып, тернәкләнеп кайтсын әле. Аннан соң карарбыз.

Көннәрдән бер көнне Каракүзне ата-анасы чакыртып алып, каршыга бастырдылар.

— Улыкаем, син яхшы бала булып чыктың, рәхмәт! — диде анасы.— Инде хәзер атаң сүзен тыңлап бак!

Атасы бераз дәшми утырганнан соң болай әйтте:

— Балам, син алыплар нәселеннән икәнлегеңне онытма! Синең бабаларың — халык бәхете өчен гомер буе җеннәр белән алышкан, диюләр белән көрәшкән кешеләр. Инде мин картайдым. Син алыплар, Алпамшалар тармагының бердәнбер туруны. Авылда син халыкка яхшы хезмәт иттең, анысы әйбәт! Хәзер инде сиңа олы көрәшкә, Аждаһага каршы яу чабарга вакыт җитеп килә. Әнә, өч көнлек, өч төнлек юлдагы авылларны, шәһәрләрне Аждаһа тагын талап киткән дигән хәбәрләр бар. Мине чакырып чапкын җибәргәннәр. Ләкин минем куәтем андый яуга җитмәс. Инде син әзерлән, балам! Яудан җиңеп кайткач, Мортыш бай кызын сиңа бирми булдыра алмас, иншалла!

Тора-бара Каракүз мәйдан уртасында көч сынаша башлады. Ул тотса, батырның җә умырткасы шытырдый, җә билгә салган сөлге шартлап өзелә. Шуңа күрә, Каракүз үзе өчен телгән каештан бау үрде. Менә шуннан соң ул батырларны күтәреп ала да баш аркылы җиргә әйләндереп кенә сала.

Яңа батырның даны бөтен тирә-якка таралды. Каракүз исеме онытылды, аны «Алып Бәргән» дип йөртә башладылар.

Аннан соң Алып Бәргән кылыч уйнатырга өйрәнде, атасы аны җәядән төз ату серләренә төшендерде. Мәргәнлектә Алып Бәргән атасыннан калышмый иде инде.

Бер дә бер көнне ук-җәя, кылыч-хәнҗәр алып, ат менеп Алып Бәргән ил гизәргә, ягъни Аждаһаны эзләп табарга һәм дөмектерергә дигән ният белән юлга җыенды.

Аерылышу авыр булса да, ата белән ана уллары Алып Бәргәнне үз куллары белән сәфәргә әзерләп, басу капкасы төбендә хәерле юл теләп калдылар. Алып Бәргәнне яуга озатырга бөтен авыл халкы җыелган иде. Озатучылар арасында бары тик Нәүмизә генә күренмәде.

Атасы Мортыш:

— Йөрмә! Анда сиңа ни калган?! — дигәч, Нәүмизә һич сүзсез бүлмәсенә кереп китте.

Шулай да алар кичен күрешеп-саубулашып өлгергәннәр иде инде. Коралгышны су эчерергә алып төшү сылтавы белән Алып Бәргән басма янында кызны көтте. Нәүмизә дә юк келәрен бар итеп су буена төште.

— Мине көт, җанашкаем! — диде дә Алып Бәргән Нәүмизәгә сөяк саплы хәнҗәрен бирде.— Миңа бәла килсә, хәнҗәремнең бер ягы күгәрер. Мин вафат булсам, ике ягы берьюлы караер. Бер ягы гына күгәрсә, мине көт. Мең бәлане узып, синең янга кайтырмын. Әгәр ике ягы да каралса, көтмә мине. Үз җаеңны үзең кара!

— Тефү-тефү, авызыңнан җил алсын андый сүзләреңне! — диде Нәүмизә.— Мин сине көтәрмен, Алып Бәргән!

Нәүмизә егеткә чигешле кулъяулык тоттырды. Яулыкның бер ягына Нәүмизәнең үз исеме, икенче ягына «Алып Бәргән — сөйгәнем» диеп язылган иде.

— Миңа бәла килсә,— диде кыз,— минем исемем җуелыр. Мин вафат булсам, икебезнең исем дә юкка чыгар.

— Тефү-тефү, авызыңнан җил алсын! Яшә, Нәүмизә, мине көтеп яшә! — диде батыр егет.— Мин китәм инде, сау бул, җанаш!

Алып Бәргән тәбәнәк кенә атка атланган, ике аягы да җиргә тия язган. Корангыш юыртканда, егетнең итеге башы юл кырыендагы чәчәкләргә тиеп-тиеп китә. Сул ягына кылыч таккан, уң ягында йөз ук тутырылган садак, муенына көянтәдәй зур җәя кигән, бизәкле тире калкан аскан, ияренә таккан зур чукмары җиргә чаклы асылынып төшкән...

Һиҗрәттән соң тугыз йөз дә утыз ике ел узгач булды бу хәл. Эт елында, мөхәррәм аеның беренче атнасы башында, Тудый көнне Алып Бәргән беренче сәяхәтенә китте.

## Курыкканга — куш

Ата-бабаларының каһарманлыклары хакында Алып Бәргән күп ишетте бала чакта. Гомере буе хыялланды алар кебек батыр булырга. Әгәр дә ки килеп чыкса хәзер аның каршысына Дию, Аждаһа, тагын әллә нинди җеннәр — бөтенесен берьюлы кырып салыр иде Алып Бәргән. Юк бит, тирә-як тып-тын, явыз затлар түгел, хәтта кешеләр дә очрамый аңа.

Алып Бәргән батыр әнә шундый уйлар белән дала буйлап бара иде. Шул чак Алып Бәргән офык ягында алагаем зур, кара-кучкыл бер нәрсә күрде.

— Әһә! — диде Алып Бәргән.— Менә батырлык сынар чак килеп җитте. Алда Аждаһа яки бер-бер зобани мине сагалап тора булыр.

Алып Бәргән кылычын капшады, калканын рәтләп куйды. Җәясен салды, садагыннан уклар алды. Олуг бер сугышка әзерләнеп беткәндә, бара торгач, теге кара-кучкыл нәмәстәнең ни икәнлеге ачык күренә башлады: бу — кара урман иде.

— Ха-ха-ха! — дип көлеп җибәрде Алып Бәргән.— Курыкканга — куш, койрыгы белән биш!

Шулай итеп, Алып Бәргән урманга килеп терәлде. Урман авызына кергәндә ул кыюлык өченме, әллә җырлыйсы килепме, җыр башлады:

Карурманда карак бар,
Атларыңны карап бар;
Без китәбез таң алдыннан,
Тәрәз ачып карап кал...

Җырның ертыгы юк ди, әйбәт җыр, матур җыр. Карурман бит ул киек-җәнлек, аю-бүре, арыслан-кабан белән генә түгел, каракчачкын, юлбасарлары белән дә данлыклы. Карурманга керсәң, колагың сак, күзең очлы, кылычың үткер булсын:

Карадай гынай урма-ан,
Караңгы-лай тө-өн,
Яхшы атлар кирәк-ләй узарга-ай...

Урман чыкканда, Алып Бәргәнгә шүрәле дә, урман иясе дә, диюләр дә очрамады. Урман сирәкләнә төште. Бераздан ачыклык күренде. Алып Бәргән тагын далага килеп чыкты. Урманны чыккач та Алып Бәргән атын туктатты. Юл өчкә аерылып китә икән. Уртада зур гына таш ята. Ташка болай дип чокып язганнар:

«Уң якка китсәң, башыңны югалтырсың. Сулга китсәң, атыңнан колак кагарсың. Уртадан китсәң...»

Шул төштә язу өзелгән. Кемдер тырышып-тырышып шул урындагы язуны балта беләнме, кискеч беләнме, кылыч беләнме каезлап, ватып бетергән.

— Менә сиңа өч юл чаты! — диде батыр арт чүмечен кашыйкашый.— Уңнан китсәм, үземнең баш — кых. Сулдан китсәм, син, Караңгыш, аяк сузасың. Уртадан китсәк... Шайтан белсен анда ни буласын? Нишлибез, Караңгыш?

— Синең дә минем дә үләсе килми, уртадагысыннан киттек! — диде бахбай.

Киттеләр болар урта юлдан кереп. Тирә-як серле томан белән капланган. «Куркыныч юлдыр бу, сак булырга кирәк!» — дип уйлады батыр.

Алып Бәргән кынысыннан кылычын суырып чыгарды. Шул чак барган җиреннән ат шып туктады, колакларын шомрайтты. Алып Бәргән якында гына ниндидер тавыш ишетеп, куырылып килде. Кемдер чыбыкка бастымы, артта нидер шартлады. Алып Бәргән аны-моны уйлап-нитеп тормастан, кылычын тавыш килгән якка селтәде. Кылыч нәрсәгәдер бәрелде, кемнеңдер шартлап муены өзелгән сыман булды. Ат кинәт алга ыргылды, Алып Бәргән ат өстеннән тәгәрәп, юлга барып төште. Батыр сикереп торды. Юл уртасында ниндидер кара гәүдә сузылып ята иде.

— Караңгыш! — дип кычкырды Алып Бәргән.— Мин аны үтердем, курыкма, бире кил!

Бераздан Караңгыш килеп житте. Ул чыдый алмыйча пошкыра, кешни.

— Менә ул кабахәт Аждаһа! — диде батыр.

Караңгыш ыңгырашу аша сукранып алды:

— С-сантый, нинди аждаһа булсын? Минем койрык бит ул, дивана!

Алып Бәргән атының артына чыгып карады. Чыннан да, Караңгыш койрыксыз иде. Ә юлда яткан кара нәмәстә Караңгышның киселгән койрыгы булып чыкты.

— Алайса, кем соң ул мине шулай куркытты? — диде хуҗа.

— Дивана! — диде Караңгыш.— Өч тәүлек килеп тә тавыш чыгармагач, ул нинди айгыр була инде!

— Ярар! — диде хуҗа, атын юаткандай.— Киселгән койрык киселгән инде. Аны кире ябыштырып булмый. Калсын шунда!

— Ал койрыкны! — дип кычкырды Караңгыш.— Бер кирәге чыгар әле. Ичмасам, миңа ияргән кигәвеннәрне шул койрык белән куып барырсың!

Юлдагы койрыкны алып, батыр атына менеп атланды. Алар тагын алга киттеләр. Өченче тәүлек узып барганда, дала бетте. Томан тарала төште. Таң ата башлады. Юлчылар алдында бер авыл пәйда булды. Өч көн, өч төн баргач, Аждаһа талаган авыллар очрар, дигән иде атасы. Мөгаен, таланган авыл шулдыр.

— Трр! — диде Алып Бәргән, атка гына ишетелерлек итеп.— Сак бул, Караңгыш, алда ниндидер шәһәрме, авылмы күренә. Тып-тын, этләр

дә өрми, этәч тә кычкырмый, кошлар да сайрамый. Бу — үлек кала. Димәк, монда Аждаһа йоклап ята булыр.

Уйлап тормастан, кинәт һөҗүмгә атылырга кирәк! Корангыш күкрәген тутырып, сулыш алды. Алып Бәргән бер кулы белән кылычын, икенчесе белән ат койрыгын болгый-болгый:

— Томырыл, Корангыш! — дип фәрман бирде.

Айгыр, шуны гына көтеп торгандай, алга ыргылды. Ут өермәседәй томырылып, алар авыл урамына килеп керделәр. Урамга керүгә Алып Бәргән бар көченә тамагын киереп, муен тамырларын кабартып кычкыра башлады:

— Ажда-аа-һа-аа! Алып Бәргәннең кылычын татып ка-ар-ра-аа!

Шул чак казлар каңгылдаша, дәррәү этләр өрә башлады, кемдер чаң кагарга тотынды. Урамда ыгы-зыгы купты. Урам борылмасына җитәрәк кемдер Корангышны авызлыгыннан шатырдатып тотты. Корангыш ярсып-кешнәп, арткы аякларына басты, Алып Бәргән җиргә тәгәрәде. Сикереп торып, зобанинның башын чабарга кизәнгән иде, Алып Бәргән, этисен танып, өнсез калды. Улының күзеннән үк ата кеше аның адашып, кире кайтканлыгын аңлады.

— Дивана! — диде Алып Мәргән.— Нигә халык куркытып акырасың?

Алып Бәргән әйтергә сүз табалмады. Корангыш та гаепле сабыйдай, башын туфракка кадәр салындырып, тын гына тора.

— Янгын бармы, ни булды, дошман явы килдеме? — дип уянган кешеләр ятак киемнәреннән генә балта, сөңгеләр тотып, болар янына җыелды.

Эшнең нәрсәдә икәнлеген белгәч, и көләргә тотынды халык! Алып Бәргән белән Корангышка карыйлар да эчләре ката тегеләрнең. Кайсылары чыдый алмыйча, эчен тотып, чирәмдә тәгәри, авызлары ерык, күзләре йомык килеш көләләр дә көләләр. Алып Мәргән дә, бичара батырның анасы да бу кызыктан тыела алмадылар. Шулай көлешә-көлешә, халык таралды. Урамда өчәү генә калды. Бичара Алып Бәргән, аның аты Корангыш та Мортыш бай кызы Нәүмизә. Кыз нидер әйтмәк булган иде, атасы килеп чыкты да, сүзсез-нисез генә кулыннан тартып, Нәүмизәне алып кайтып китте. Урам уртасында Корангыш белән Алып Бәргән икесе генә тырпаеп калды.

Ниләр генә күрми ир-егеткәй белән ат башы!

— Ярар! — диде Алып Бәргән.— Кайгырмыйк әле, Корангыш! Арылган, бераз ял итик тә, тагын Аждаһаны эзләргә чыгып китәрбез. Болай булгач, барыбер табам мин ул зобанины!

## Яуга киткән ятып кайта

Бу юлы Алып Бәргәнне берәү дә озатмады. Бәлки озаткан булырлар иде дә, Алып Бәргән үзе теләмәде. Аһ-ваһ килеп озатып та, баягыдай әйләнеп-тулганып, кире үз авылыңа кайтып керсәң, оятыңнан җир тишегенә кер дә кит инде, валлаһи! Алып Бәргән ата-анасына да берни әйтмәде, бары тик язу гына калдырды. Ул таң алдыннан Корангышын иярләде дә ындыр артына чыкты. Монысында ул ашарына да, эчәренә дә алмады. Бары тик коралларын вә дәхи Нәүмизә биргән кулъяулыкны тотып, качкын кешедәй шыпырт кына сәфәр китте.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз утыз өч ел узгач булды бу хәл. Кабак уңган елда, Шәгъбан аеның азакки атнасында, Утларый көнне Алып Бәргән икенче сәяхәтенә чыкты.

Өч юл чатына хәтле Алып Бәргән ләм-мим бер сүз дә әйтмәде, бер җыру да җырламады. Хуҗасының мөшкел хәлен аңлаптыр инде, Корангыш та телгә килмәде.

Язулы ташка җиткәч, Алып батыр атыннан сикереп төште дә капчыгыннан кискеч, чүкеч алып: «Бу юлдан киткән, Алып Бәргән кебек оятка калыр»,— дип үзенең төзәтмәсен язып куйды.

Эшен бетергәч, ул канәгать елмайды да:

— Беткән баш беткән,— диде шат-көр тавыш белән.— Уңнан китәбез, Корангыш! Карап карыйк әле, ничек итеп минем баш югалыр икән бу юлы?

Көн киттеләр, төн киттеләр, өченче көн таң алдыннан Алып Бәргән ялан җирдә дар агачы күреп, атын туктатты. Үлем исен сизенеп ахрысы, Корангыш колакларын шомрайтты да сак кына кешнәп куйды.

— Корангыш! — диде батыр.— Качып кына карап торыйк, монда нинди эшләр булыр икән?

Шулай диде дә Алып Бәргән агач башына менеп урнашты. Корангыш куаклар арасына кереп күмелде. Ерактә ниндидер авыл күренә. Шул авыл капкасыннан бөркәвечле арбага җигелгән пар ат чыкты. Атлар якынайгач, Алып Бәргән арба күперчегенә утырган ат әйдәүчене шәйләп алды. Менә арба дарагач төбенә килеп туктады. Ат әйдәүче күперчектән сикереп төште дә, дарагач күтәрмәсенә менеп китте. Бауларны җайлады, бүкәннәрне баулар астына шуыштырды да янә арба янына сикереп төште.

— Әзер! — дип кычкырды ат әйдәүче.— Алып төшегез кабахәтләрне!

Бөркәвечле арбаның киез ишеге ачылып китте. Аннан кылычлы адәмнәр җиргә сикереп төште. Алар артыннан күзенә капчык кидертелгән, куллары артка каерып бәйләнгән бер хатын-кыз күренде. Хатын-кыздан соң күзенә шулай ук капчык кидертелгән, куллары артка каерып бәйләнгән ир затны җиргә төртеп төшерделәр. Дүрт кылычлы бу ике тоткынны дарагачка таба алып киттеләр. Бичара тоткыннар аяклары белән карышалар, кызганыч тавыш белән кылычлыларга ялваралар.

— Мин яшь бит әле, кызганыгыз мине! — дип кычкыра хатын-кыз.— Зинһар, харап итмәгез. Сез ялгышасыз бит, агайлар, минем гөнаһым юк!

— Кардәшләр! — дип ялына ир кеше.— Үзегез гөнаһлы буласыз бит. Безне үтереп, сезгә ни файда? Безнең гаепсез икәнлекне белерсез, ләкин соң булыр...

Ат әйдәүче ярдәмендә дүрт кылычлы бичараларны дарагачка менгезделәр дә, муеннарына бау кигезеп, түмәрләргә бастырдылар.

— Абыйлар, коткарыгыз! — дип елый кыз.

— Агайлар, зинһар, җанымны кыймагыз! — дип ялвара ир кеше.

— Үкермәгез, зобанилар! — дип кычкырды ат әйдәүче.— Юха елан белән Иблискә, күз яшьләре белән еласа да, ышанмагыз!

Алып Бәргән агач башында түзеп утыра алмады, сикереп төште дә дарагач янына килде.

— Һәй! — дип кычкырды ул кылычлыларга.— Җибәрегез аларны! Җибәрегез, югыйсә үзегезнең башыгызны кыеп төшерәм!

— Син кем? — диде ат әйдәүче кеше.— Нигә син безнең эшләргә тыкшынасың? Юлыңда бул, егет!

Бичара тоткыннар икесе берьюлы Алып Бәргәнгә ялвара башладылар.

— И батыр егет, зинһар, безне бу явызлар кулыннан азат ит! Без гөнаһсыз. Без икебез дә патша балалары. Әгәр коткарсаң, атабыз сине алтынга күмәр!

— Тик кенә торыгыз, зобанилар! — диде ат әйдәүче.— Ә син аларның сүзләренә ышанма, егет, юлыңда бул!

— Өчкә хәтле саныйм! — диде Алып.— Җибәрегез тоткыннарны! Бер!

Ат әйдәүче Алып Бәргәнгә якын ук килеп болай диде:

— Юлчы егет, боларның берсе Юха елан, икенчесе Иблис булыр! Биштишек авылына күпме зыян эшләгәннәрен белсәң, син үз кулың белән аларның башын кыеп төшерер идең.

— Коралсыз кешеләрне үтергәнне мин тыныч кына карап тора алмыйм! — диде батыр егет.— Җибәрегез! Ике! Өч!

Алып Бәргән тәвәккәл рәвештә бишесенә каршы атлады. Тегеләр берьюлы биш кылыч белән Алып бәргәнгә кизәнделәр. Алып Бәргән яшен тизлеге белән аларның кылычларын бәреп-бәреп төшерде дә йодрыгы белән бишесен биш якка тәгәрәтте. Шуннан файдаланып, тиз генә тоткыннарның кулларын буып торган бауларны кисте, башларыннан капчыкларын салдырды. Капчык астыннан гүзәлләрнең гүзәле бер кыз килеп чыкты, икенче капчык астында асыл зат бер егет булган икән. Тоткыннар шайтандай акырып арбага сикерделәр. Егет дигәне дилбегәне алып, атларга берн сукты да әче итеп сызгырып җибәрде. Атлар алга ыргылып чабып та китте. Ул арада һушларын җуйган кылычлылар да, ат әйдәүче дә исләрен-акылларын җыеп аягүрә торып бастылар. Бастылар да янә кылычларына тотындылар. Алып Бәргән аларны сырт якаларыннан алып, берәм-берәм маңгайлары белән чәкәштереп чыкты.

— Астырырмын мин сезгә кеше! — диде ул, тегеләргә бармак янап.— Шундый чибәр кыз белән асыл шаһзадәне дарга асалармыни?

Алып Бәргән белән сугышудан файда юклыгын күргәч, кылычлылар шешкән маңгайларын уып, ыңгыраша башладылар.

— Их, син ахмак бәндә! — диде ат әйдәүче кеше.— Көчеңне кая куярга белмәсәң, таш ват! Куәт булса, акыл нәрсәгә! Синең бу тиле көчеңнән кешеләргә зыян гына!

— Нишләп мин зыян эшлим? — диде батыр.

— Син Юха елан белән Иблисне качырдың! Без аларны илле ел буе сагалап та тота алмаган идек. Бүген менә алар икесе дә безнең тозакка капканнар иде... Ах, дивана, куәтле ахмак!

Ат әйдәүче гарьлегеннән елый ук башлады.

— Әнә, авыл халкы килә. Иблис белән Юханы качырганыбыз өчен, безнең бишебезне дә тотып, шушы бауларга асачаклар. Сиңа да рәт булмас!

Чыннан да, авыл ягыннан коралланган ирләр, хатыннар килә иде. Аңы-моны уйлап өлгергәнче, кешеләр дарагачка килеп тә җиттеләр.

— Кайда ул Иблис? Кайда ул Юха? — дип бигрәк тә хатыннар ажгырып эзләнә башладылар.

Ат әйдәүче кеше монда ниләр булганны сөйләп бирде.

— Без гаепле түгел, әйттек без аңа, комачаулама, дидек...

Ачудан күзләре акайган хатыннар өере Алып Бәргәнне урап алды.

— Син качырдыңмы шул кабахәтләрне? — дип сорады хатыннар.

Алып Бәргән нидер әйтергә җыенган иде, башлап йөрүче үтә усал карашлы бер хатын аңа ирек бирмәде, дарагач күтәртмәсенә менеп кычкырырга тотынды:

— Җәмәгать! Кызларыбызны, хатыннарыбызны аздыручы, гаиләләребезне туздыручы Иблисне, ир-егетләребезне бозучы, гаилә таркатучы Юханы качырганы өчен, нинди җәза бирәбез бу алыбаякка?

— Үлем! Үлем! — дип кычкырдылар хатыннар.

Шуны гына көтеп торгандай, котырган хатыннар өере Алып Бәргән өстенә ыргылды. Иң беренче булып әлеге зәһәр хатын дарагачтан батыр өстенә сикерде. Кемдер тырнаклары белән Алыпның битен суеп төшерде. Унлап хатын аның чәченә тотынып, башын аска таба идерделәр. Егермеләп кул батырның чәчен йолкый башлады. Тырныйлар, тешлиләр, йолкыйлар, чеметәләр, төкерәләр. Алып батыр ирләргә каршы ничек көрәшәсен белә, ләкин хатын-кызлар алдында ул каушап калды. Бу эшкә ирләр дә катнашырга теләгәннәр иде, хатыннар аларны корбаннарына якын да җибәрмәделәр.

Хәлдән таеп, тырнаклары сынып беткәч кенә хатыннар берәм-берәм читкә китте. Болыннан маллар кайта башлагач, авыл халкы Алыпның чиләнеп, канланып беткән ярым-үлек гәүдәсен дарагач янында калдырып, көтү каршыларга таралды.

Алып Бәргән аңына килгәндә, таң аткан иде инде. Иң беренче ул дар агачка кунган козгыннарны күрде.

— Минем күзләрне чукырга өмет итеп утырасызмы? — диде ул козгыннарга.

Якында гына ат кешнәгән тавыш ишетелде. Бу — Корангыш иде. Алып Бәргәннең тырналмаган җире, тешләнмәгән урыны калмаган. Чеметүләрдән кара көйгән куллары сулкылдап сызлый. Иреннәре кабартмадай калынайган. Чәчен йолкып бетерә язганнар...

Батырның тере икәнлеген күргәч, козгыннар ялкау гына очып китте.

«Аждаһа белән сугышырга дип киткән батырны хатыннар кыйнаган!» — дигән хәбәр авылдашларына ишетелсә — ни хурлык!

— Колаксыз, ыштансыз батыр! — диде ул үзен мыскыллап.

— Колак чүп кенә ул! — диде Корангыш.— Баш исән булсын! Менеп ят!

Корангыш җиргә тезләнде. Алып Бәргәннең ияргә утырырга җае калмаган иде, ул көч-хәл белән генә Корангышның сыртына менеп, бүксәсе белән ияргә ятты. Тугры ат хуҗасының канлы гәүдәсен күтәреп, кайтыр юлга чыкты.

...Өч көн үткәннән соң Алып Бәргәннең анасы борчыла башлады.

— Атасы! — диде хатын.— Төшемә дә бик начар булып керде, әллә бер-бер хәл булдымы икән? Мин яурымчыга барып, фал ачтырып кайтыйм әле.

— Һәй, кортка! — диде Алып Мәргән.— Тегә юлы да күрәзәчегә барган идең. Шуннан нәрсә булды? Бөтен мир каршында оятка калдырды бит, дивана бала!

Чыннан да, улы беренче сәяхәтенә чыгып киткәч, ана күрәзәчегә барган иде. Бер каз, бер кадак май, бер гөрәнкә язгы йон алып килгәнен белгәч, күрәзәче агай батырның анасына карап авызын ерды:

— Бик һәйбәт, аллаһы боерса!.— диде дә күрәзәче сәке йөзлегенә утырып, нидер мыгырдый башлады. Аннары ике күзен шытырдатып йомды да кулларын җәйде. Ике имән бармагын тырпайтып, бер-беренә якынайта башлады.

— Минем телем түгел, дәрья кичкән инәкәйләр теле... Минем кулым түгел, Әйшә-Батман кулы... Әнгәречкә-әнгәречкә-әнгәречкә, тертинкәй!

Ике бармак калтырый-калтырый озак кына якынайды. Һәм, ниһаять, икесе бергә кушылды.

— Һай, рәхмәт төшкере! — дип кычкырды күрәзәче.— Әйттем бит, бар да шәп дидем! Алып Бәргән исән-сау, озакламый дошманнарын җиңеп яудан кайтыр!

Бу юлы батырның анасы күрәзәгә бармаска булды. Бер күркә, бер тавык, бер киләп эрләнгән киндер җебе тотып, яурымчыга фал ачтырырга китте. Зур күчтәнәчләрне күргәч, яурымчы тәсбих тартып утырган җиреннән кымырҗып куйды. Капчыктай кабарынкы төенчекне бүлмәчкә урнаштыргач, фалчы шүрлектән нидер үрелеп алды. Бу — фал ача торган сөяк иде. Сарыкның калак сөяге фал ачудан шомарып, ялтырап, саргаеп беткән. Яурымчы фалны зур гына җиз төпсәгә куйды. Сөякне куллары белән сыпыргалады, аннары янчыгыннан бер уч борчак алып, сөяк өстенә сипте. Борчаклар сөякнең ян-якларына, алдына, артына тәгәрәде. Яурымчы озак кына борчакларны санады, чагыштырды, хисаплады да сөяккә карап, нидер мыгырдарга тотынды:

Иннә-иннә, чүри-чүри,
Дөпе-дөпе, дөп-дөп!

— Җә! — диде фалчы.— Анакай, синең улың бик зур җиңү белән кайтачак. Ул — исән-сау. Бәлешеңне әзерләп, мунчаңны яга тор!

Ана кеше яурымчы өеннән атылып чыкты, үз өенә ничек кайтканын да сизмәде. Бусагадан атлап кергәч:

— Атасы, Алып Бәргән җиңеп кайта! — дип кычкырырга теләгән иде, сәке йөзлегендә утыручы Нәүмизә белән ирен күреп, тертелеп калды.

Икесе дә бик кайгылы кыяфәттә иде.

— Менә! — диде Нәүмизә еламсырап.— Алып Бәргәннең хәнҗәре күгәрә башлады.

— Чү-чү, кызым! — диде Мәргән батыр.— Син аны дымлы җиргә куйгансыңдыр...

— Юк! — диде Нәүмизә.— Мин Алып Бәргән хәнҗәрен бирнә сандыгында саклыйм.

Шулчак ишегалды ташында дага чыңлаганы, ат пошкырганы ишетелде. Өйдәгеләр сагаеп калды. Алып Мәргән үрелеп тәрәзәгә карады. Баскыч төбендә Караңгыш басып тора иде. Алып Бәргәннең ат өстендәге канлы гәүдәсен танып, ата кешенең йөрәге «жу-у» итеп китте...

...Алып Бәргән кайтканга берничә көн узды. Аның кан катнаш туфракка укмашкан тәнен куе сөткә салып, озак җебеттеләр. Аннан соң каймак сылап, пәрәвез белән урап чыктылар. Пәрәвез өстеннән әрекмән яфрагы капладылар. Әкренләп Алып Бәргән ыңгырашудан туктады, сызлануы кимеде. Хәтта аның кабартма иреннәре дә кыймылдар хәлгә килде. Бер-ике атнадан соң ул сөйләшә дә башлады.

— Батыр ярасыз йөрмәс! — диде ул атасына.

Аңа каршы атасы әйтте:

— Кәҗә казасыз булмас! Тик шунысын гына аңлый алмадым. Аждаһа дисәң, охшамаган. Дию дияр идең, аның кулы түгел. Кем белән сугыштың соң? Син шулай җәрәхәтләнгәч, ул мәлгуньнең йоны күккә очкандыр инде!

Алып Бәргән дәшмәде. Ишегалдында Караңгышның озын итеп пошкырганы гына ишетелде. Шулчак урамдагы малай-шалайлар бик каты бәхәсләшә башлады.

— Һәй, малай! — диде берсе.— Алып Бәргән абыйның аты үлгән Дию күтәреп кайтты беркөнне. Көчкә сөйрәп кайта, валлаһи. У-у, күрсәң, котың очар. Борыны беләк буе, маңгаенда бер күзе. Ямьсез дә соң!

— Җүләр! — диде икенче бала.— Дию түгел бит ул, Бәргән абый үзе шулай аркылы ятып кайтты.

— Беләбез инде! — диде өченчесе.— Алып Бәргән абыйны Биштишек авылы хатыннары кыйнаган. Атайга мал куучылар сөйләгән!

— Яуга киткән ятып кайтты! — диде тагын берсе.

Алып Бәргән бу сүзләрне ишеткәч, гарьлегеннән ыңгырашып куйды. Караңгыш, малайларны өркетмәк булып, пошкыра, кешни, коймага тибә башлады. Балалар чыр-чу килеп таралдылар...

Алып Бәргәннең икенче сәяхәте әнә шулай тәмам булды.

## Алып Бәргән Иблисне эзли чыга

Шулай вакыт уза торгач, Алып Бәргән ныклап савыкты, яргаланган тәне төзәлеп бетте. Алып Бәргәннең күңеле нидер сизенеп кытыклана, шатлана, әйтерсең лә аны алда нindидер бәхет көтә.

Карурмандай карак бар,
Атларыңный карап бар,
Без китәбез таң алдыннан,
Тәрәз ачып карап кал,—

дип җырлавыннан ук күреп-сизеп тора Караңгыш — аның хуҗасы тагын юлга җыена.

Шулай урманга утынга менгәч, Алып Бәргән атына дәште:

— Караңгыш, бүген китәбез, дускай!

Чыннан да, таң алдыннан атка атланып, яуга киткәндә, бер генә кеше дә уянмады, бары тик бер генә тәрәзәнең кашагасы күтәрелде. Бу Нәүмизә иде. Кыз, өзелеп, сөйгәнен яуга озата, тәрәзә ачып карап кала.

Корангыш дәртле итеп кешнәде дә алга, өченче сәяхәткә ыргылды. Болын ягыннан яшь бер байталның Корангышка кешнәп җавап кайтарганы ишетелде.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз утыз биш ел узгач, Рамазанның башында, Кече атна көнне булды бу хәл.

Ике тапкыр көлкегә калган Алып Бәргәннең нияте нык, карашы үтәли тишәрдәй каты. Корангыш кына бик күңелсез, авыр юырта башлады. Бу юлы өченче сукмактан — «Атыңны югалтырсың» ягыннан киттеләр. Шуңа күрә Корангышның эче поша иде.

— Курыкма, Корангыш! — диде хуҗасы.— Баш сау булсын!

Шулай дигәч, атка бераз җан керде.

Ай киттеләр болар, ел киттеләр, бара торгач, ялга туктадылар. Егет чакма белән ташка бәреп, куга ут төшерде. Учак тергезде. Иярен салдырып, атын сәйранга җибәрде. Шуннан соң үзе ауга китте. Кыр тавыгы атып алды да каурыйлары белән үзле балчыкка төрде. Зу-ур күмәч хәтле шул үзле балчыкны шаулап торган учакка ташлады. Корангыш якында гына утлап йөри. Алып Бәргән җиргә чалкан ятып, башын ияргә куйды. Батырның мендәре — ияр, ястыгы — җир, юрганы — күкболыт!

— Аждаһа калып торсын! — диде Алып Бәргән үзалдына.— Иблис белән Юханы тотарга кирәк. Шуларны Биштишек авылы кешеләренә кире кайтармый торып миңа көн юк!

Ул арада аш та пешеп чыкты. Үзле балчык шакыраеп каткан, чүлмәк төсенә кергән иде. Алып Бәргән кылычы белән тәгәрәтеп, балчыкны учактан чыгарды да таш белән бәреп ватты. Кошның каурыйлары балчыкка ябышып калган, уртада мәмердәп пешкән тавык ята иде. Аны күргәч Алып Бәргәннең авыз сулары китте. Тамак ялгап алгач, тагын кузгалдылар. Шулай киттеләр болар, ай киттеләр, ел киттеләр, энә буе җир киттеләр дигәндәй, зур гына бер шәһәргә килеп җиттеләр.

Ерактан ук балкып тора бу шәһәр. Тау өстендә таш диварлар. Ук ата торган тәрәзәчекле ныгытмалар, зур-зур тимерләр белән беркетелгән имән капкалар артында йөзләгән манаралар тезелеп киткән. Шәһәр читендә, таш диварларның бу ягында, кара халыкның агач өйләре күренә. Көтүлекләрдә мал утлап йөри. Су буендагы бакчаларда хатын-кызлар, бала-чагалар яшелчәләргә су сибә. Яр кырыена дистәләгән мунчалар урнашкан. Шулчак нечкә матур тавыш белән азан әйтә башладылар. Өйлә вакыты җиткән иде. Тирә-яктагы барча кеше дә эшен ташлап, сәҗдәгә егылды. Җайдаклар ат өстеннән сикереп төштеләр дә уч төбе чаклы гына намазлыкларга капландылар. Беркем сөйләшми, тып-тын. Алып Бәргән шәһәр капкасыннан керде. Төз урамнар буйлап бара торгач, ул киң мәйданга чыкты. Алда гаҗәп матур сарай калыкты. Мәйдандагы бөтен халык туңкаеп намаз укый иде.

— Трр, бахбай! — диде Алып Бәргән.— Һәй, сарай капкасын ачыгыз! — дип кычкырса да, капкалар ачылмады.

Шулай авызын күтәреп, капкачы ягына карап торганда, кемдер Алып Бәргәннең муен тамырына берне орды. Алып Бәргән ирексездән җиргә тезләнде. Башын ике кул сыртына куеп, намаз укыган булып, ул тирә-яктагы кешеләрне күзәтә башлады. Якында гына бер кеше янында яткан гөрзине күргәч, ул аңлап алды, шушы агай аны сугып еккан икән. Әлеге ага кеше, башкалар күрмәсен дигәндәй, ялт-йолт каранып алды да чак ишетелерлек итеп кенә болай диде:

— Башың ике булмаса, намаз вакытында аягүрә торма. Кычкырып, намазларын боздырма. Бу илнең патшасы үтә диндар кеше. Намаз калдырган кешене асалар бу калада. Һәр өйләдән соң патша үзе кара халык алдына чыгып вәгазь сөйли. Тырышыбрак укы догаларыңны, егет!

Ниһаять, намаз тәмамланды. Кешеләр аягүрә басып, намазлыкларын кага-төрә башладылар.

— Хәзер Яхур патша чыгачак! — диде агай Алып Бәргәнгә.— Яхшылап бак, егет, бөек хаким ул безнең Яхур патша.

Зур барабаннар кагарга тотындылар, барабанга сорнай, быргы тавышлары кушылды. Сарай капкасы ачылып китте. Капкадан иңенә кызыл комач салган мәһабәт бер ир-егет чыкты. Аның янәшәсендә генә күз явыңны алырдай матур бер кыз атлый. Алар артыннан кырык вәзир һәм тагын бер өер сарай агалары терек-терек юырта.

Алып Бәргәннең янәшәсендәге әлеге агай тагын пышылдады:

— Яхур патша шушы булыр! Аның хатыны — Җәмлия гүзәл. Патшабикәнең сул ягында җиңелмәс баһадир Әлҗаман булыр. Патшаның уң ягында сугыш эшләре вәзире Чукмар-бәй. Аннан ары сәүдә эшләре вәзире Ертлач-әкә, аннан кала җарияләр башлыгы Зинабай булыр. Кара халыктан салым-ясак талаучы Кап-Йот. Патшаның колагына иелеп, нидер пышылдаучысы шымчылар башлыгы Җасус-җан...

Яхур патша җирне селкетердәй нык вә тиз-тиз атлап, таш мөнбәргә менеп басты. Халык берьюлы җиргә егылып, патшасы каршында башын җиргә орды.

— Көненә биш тапкыр шушылай башын ташка ора-ора халыкның мие шулпаланып бетте инде! — диде әлеге карт.

Шул мәлне барабаннар шып туктады. Мәһабәт патша Яхур халыкка карап сүз башлады:

— Солтан Яхур падишаһ сүзем! И вәзирләрем, и сарай әһелләре! Итчеләр, чүлмәкчеләр, сәүдәгәрләр, мосафирлар, и кара халык! Аллаһ тәгалә исеме белән сезгә вәгазь башлыйм. Аллаһе тәгалә вә тәбәрәкә хәзрәтләренең кодрәте илә мәмләкәтебез көннән-көн матурая, шәһәребез сәгатьләп төзекләнә бара. Арыкларда су чылтырап ага, гөлбакчаларда кошлар Алланы мактап сайрый. Патшалыгыбызда юллар төзек. Ләкин арабызда бозык затлар бар. Гөнаһлы кешеләр күбәйде. Аллага тел тидерүчеләр ишәйде. Әшәкеләр, гайбәт, зина белән дөнья тулды. Бозыклар арткан саен, Аллаһе тәгалә өстебезгә бәла җибәрә. Әнә өченче ел корылык булды. Әнә узган ел кояш чыкмады, бөтен иген череп бетте. Быел тагын берәм-берәм кешеләр югала тора. Гөнаһлыларның йортларына ут каба. Балаларны җен алмаштыра. Чистарырга кирәк, гөнаһларыгызны ярлыкавын сорап, Аллага гыйбадәт кылырга кирәк. Биш намазның бересен дә калдырмаска! Кем дә кем әлеге кагыйдәне боза икән, ул кешене шул көнне үк җәзага тартырга боерам! Аң булыгыз, кешеләр! Гөнаһлыны җәза көтә! Бер генә гөнаһкяр да, бер генә зиначы да, бер генә гайбәтче дә җәзасыз калмаска тиеш. Гаделлек өчен мин Алла каршында җаным фида булганчы тырышырмын. Әмма минем бу изге эшемә аяк чалучылар да бар. Шундый бер кабахәт җинаятьче качып котылды. Ул иректә. Андый кабахәтләр иректә йөргәндә, бер генә кеше дә тыныч йокларга тиеш түгел. Сез аны беләсез, ул минем элеккеге вәзирем Йормаш карт. Сарай әһелләре турында гайбәт таратканы өчен, аны диван вәзирләре мал көтәргә куган иде. Инде ул анда да телен тыя алмады. Хәтта сарыкларга, сыерларга безнең турыда гайбәт сөйләп йөри башлады. Шуннан соң ул үлемгә хөкем ителгән иде. Качып котылды. Кем дә кем җинаятьче Йормаш картның кайдалыгын әйтә, тере яки үле килеш хөкемгә тапшыра, шул кеше гаиләсе белән сарайга алынып, казна хисабына яши башлаячак. Аллага иман китерегез, гөнаһ кылмагыз, кеше өлешенә кермәгез! Ягез, бер фатиха!

Барысы да патша белән бергә дога кылдылар. Янә зур барабан кага башладылар, патша зур бер эшлекле кыяфәт илә сараена кереп китте. Халык, башын ташка орып, патшасын озатып калды. Сарай капкалары ябылу белән, атлы өндәүчеләр халыкны куа башладылар:

— Барыгыз, бар! Икенче намазга чаклы эшегездә булыгыз!

Халык дәшми-тынмый гына таралды.

— Ярар! — диде Алып Бәргән атына.— Кәрвансарайларын эзләп табып, тамак ялгап, ял итеп алырга кирәк.



Т. Хажиәхмәтов рәсеме.

Шулай атын житәкләп барганда, кемдер Алып Бәргәннең жиңеннән тартты. Бу теге карт иде.

— Улым! — диде карт.— Кунар урының булмаса, мине озата бар. Йортым тар булса да, күңелем киң минем!

Чит шәһәрдә ике сүз каткан кеше дә якын дуска әйләнә дигәндәй, Алып Бәргән бу сүзләргә бик сөенде.

Шәһәрне чыкканчы, алар сөйләшмичә бардылар. Карт нидәндер шикләнә, алак-ялак карангалый.

— Жә! — диде карт кырга чыккач.— Син безнең Яхур патша турында ни уйлыйсың?

Алып Бәргән мәһабәт патшаның сүзләрен һаман да оныта алмый иде әле.

— Һай, уңган патшагыз. Һай, дини икән! — диде батыр.— Үзен күреп бер соклансам, сүзен ишетеп мең сокландым. Гадел патша, мең яшәсен! Андый патша сирәк бу дөньяда!

— Дөрес! — диде карт.— Күзеңне алалмыйсың аңа карап. Батыр егеткәй, синдә куәт күп икән, шөкер. Син шул куәтең белән халыкка хезмәт итәргә чыккансың, күрәм. Ләкин куәт белән генә жиңеп булмый дошманны. Хәйлә кирәк. Ә син сабый гына әле! Син ерак жирдән килгәнсең, сиңа ышанырга була.

Бабай тагын як-ягына каранып алды.

— Мин бая Яхур патша әйткән Йормаш карт булырмын!

Тыңлап торучы юкмы дигәндәй, карт тагын сагаеп калды.

— Курыкма, Йормаш бабай, мин сине сатмам! — диде дә Алып Бәргән үзенең кем икәнлеген сөйләп бирде.

Йормаш карт әйтте:

— Үлемнән качып, мин чит илләрдә байтак каңгырып йөрдем. Жаным түзмәде, дөреслекне сөйләргә дип, тагын кайттым.

Бара торгач, алар урман белән капланган тауларга килеп життеләр.

— Мин әнә шул таулар арасындагы яшерен мәгарәдә торам,— диде Йормаш карт.

Яшерен сукмаклар буйлап алар озак бардылар һәм, ниһаять, куышка кайтып керделәр. Йормаш карт Алып Бәргәнгә барын да сөйләп бирде.

— Яхур патша — матур куркыныч ул, олан! Аның матурлыгы тыштан гына.

Яхур патша яшь чакта бик тәртипле, итагатьле бер бала булып үскән икән. Йормаш карт аның остазы булган. Шулай бик матур яшәгәннәр алар. Егет булып житкәч, шаһзадә дөнья гүзәле Жәмлиягә өйләнгән. Ипле, сабыр бу кызны Йормаш-вәзир үзе табып димләгән. Өйләнгән көнне үк Яхур патша үзгәрә башлаган. Кырысланган, гел изгелек, намус турында гына сөйләнә икән. Ике сүзнең берендә телендә гөнаһ, жәза, намаз, алла ди. Халыкны эшеннән аерып, көненә биш тапкыр мәйданга жыеп, намаз укыта. Кырык эшен кырыклай ташлап, бөтен кеше сәждәгә егыла торган булып киткән. Аның бу диндарлыгыннан халык иза чигә башлаган.

— Ишеттеңме, бая сөйләгәндә ул Алла сүзен йөз тапкыр кабатлады. Кеше изгелек турында кирәгеннән артык үҗәтләнеп кычкыра икән, шикләнергә урын бар дигән сүз. Үз намуссызлыгын каплар өчен, үз жинаятен йомарга дип, кешеләр намус, гаделлек турында акыра башламыйлармы икән дигән фикер килде минем башка теге чакта. Шуннан соң мин Яхур патшаның кылганнарын күзәтеп, сөйләгәннәре белән чагыштыра башладым. Сарайда нииндидер астыртын эшләр башкарыла. Туры сүзле вәзирләр көннән-көн сирәгәя, юкка чыга башладылар. Яхур янында әнә бая син күргәннәр генә сөзелеп калды. Яхур патша үзе бозык, Алып Бәргән! Үзе гөнаһ иясе! Аның сараенда харам йорты бар. Шул харам бүлмәләрендә ул урлаган яшь хатыннарны ирексезләп тота. Моны хәтта Жәмлия дә белми. Ул ирен чыннан да изге кеше дип уйлый, муеннан гашыйк шул кансызга. Ул гына түгел, халыкның күпчелеге

Яхурга табына. Бик азлар гына дөреслекне сизенә. Сизенсә дә, дәшми. Үсеп буйга җиткәч, һәр чибәр кыз юкка чыга бу шәһәрдә. Кая китә алар? Һичкем белми. Суга баткан булсалар, бер калкырлар иде. Урманда бүреләр ботарлаган булса, сөякләре бер табылыр иде. Йөз кыз шулай җир упкандай юкка чыкты. Кайда алар? Алар бар да Яхур патшаның яшерен харамында иза чигә. Шуларны азат итеп кенә халыкка дөреслекне күрсәтеп була. Коткарсаң, син генә коткарасың безне бу бәладән! Сине күрми калды патша шымчылары. Әгәр күрсә, сиңа бер-бер гаеп ташлап, дарга асарлар, җә сине җиңелмәс Әлҗаман белән сугыштырып харап итәчәкләр иде. Әлҗаманны җиңгән батыр юк. Йөз пәһлеванны ул мәйдан уртасында, халык каршысында кычкыртып суйды. Читтән килгән батырларны үлем көтә монда. Чөнки алар исән китсә, мондагы патша турында башкаларга сөйләр дип куркалар.

Йормаш карт сөйләгәннәрдән Алып Бәргән менә нәрсә белде.

Әлҗаман батырның иң яраткан коралы җәя икән. Ул мең адымнан чебеннең сул күзенә тигезә ала ди. Ул аткан ук айга җитә икән. Күп батырлар беренче уктан ук һәлак булганнар.

— Беренче ату хокукы аңар чыга. Чөнки чөелә торган акчаның ике ягы да кун! — диде карт.— Сак бул! Әгәр дә уктан исән калсаң, ат өстендә сөңге орыш булыр. Сөңге белән аны бәреп төшерә алсаң, кылыч сугышы булыр. Кылычтан да исән калсаң, көрәш булыр. Көрәштә ул оста түгел. Аның көрәшмәгәненә биш былтыр инде. Ул җә ук, җә сөңге, җә кылыч белән дошманының эшен бетерә. Шуңа күрә, ул көрәшне сугышка санамый да. Йөз батырның бары берсе генә көрәшкә чаклы килеп җитте. Анысын да Әлҗаман озын чәченнән урап җиңде. Әгәр дә син Әлҗаманны җиңсәң, аның урыны сиңа кала. Син Яхурның җан сакчысына әверелерсең. Шунда син аның бөтен серен белерсең. Җә, ничек уйлыйсың, батыр?

— Ярый, Йормаш бабай,— диде Алып Бәргән, авыр сулап.— Мин атым белән киңәшеп керим әле...

Алып Бәргән аты янына чыгып, нишләргә икән инде дип, озак кына сызгырынып торды да Караңгышка дәште:

— Җә, бахбайкаем, нишлим соң инде? Иблис белән Юханы эзләп китимме, Аждаһага каршы барыйммы? Әллә монда калыйммы?

Караңгыш һичнинди файдалы киңәш бирә алмады.

— Их, корт чаккыры! — дип, Алып Бәргән кәпәчен салып җиргә орды. Шулчак:

— Алла-ла, башымны яра язды, җүнсез! — дигән тавыш ишетелде.

— Бәрәкәт! — диде Алып батыр.— Кәпәчем телгә килде. Бу нинди хикмәт тагын?

— Көчеңне кая куярга белмәсәң, Йормаш бабайның утынын яр! — диде кәпәч.— Җан ачуы белән җиргә орсалар, син дә үкерер идең.

— Нишләргә соң? — дип сорады Алып батыр кәпәченнән.

— Монда кал, бабай әйткәннәргә колак сал! Яхур патша эчендә Иблис булмагае! — диде кәпәч.

— Ә син нәрсә уйлыйсың, Караңгыш?

— Мин дә калу ягында! — диде ат.— Сынашып карыйк бер Яхур патша белән, ә?

Алып Бәргән мәгарә эченә кереп китте.

— Мин монда калам, Йормаш бабай! — диде ул карт вәзиргә.

Йокларга яттылар болар. Ат тышта аягүрә ойый. Мәгарә эчендә Алып Бәргән батырларча гырлый башлады. Ни гомер юл килеп нык арыганнар бичаралар. Батыр да, аты да өч көн, өч төн йоклады. Йормаш карт, хәл җыйсын дип, Караңгышны да, Алып Бәргәнне дә уятырга базмады. Дүртенче көнгә киткәндә, таң алдыннан Алып Бәргән үзе уянды. Хуҗасы кыймылдауга, тышта ат та кешнәп җибәрде.

— Аң бул! — диде Йормаш карт, Алып Бәргәнне юлга әзерләгәндә.— Сиңа бер-бер гаеп тагарлар. Шул гаебең өчен сине әсир итәрләр...

Алып Бәргән шуннан соң тап-такыр итеп чәчен кыркып ташлады. Кәләпүшен киде. Их, рәхәт ул чәчне пәке белән ялтыратып кыру. Рәхәтлеге корысын, уңайлыгы шәп бит. Атта ут өереп чапканда да кырган баштан кәләпүш төшеп калмый. Такыр башка бөҗәкләр оя кормый. Иң шәбе — дошман синең чәчеңнән урап тота алмый.

Ул сарай капкасына җиткәндә кешеләр өйлә намазына дип җыелганнар иде инде. Нәкъ узгандагы кеби: патша сарай капкасыннан чыгуга, бөтен халык шартлап җиргә ауды, башлар тагын ташка орылды. Кеше нишләсә, Алып Бәргән дә шулай эшләде.

— Корангыш! — диде ул, чак ишетелерлек итеп.— Корангыш, син кире якка карап, сыртыңны патшага төзәп ят!

Корангыш нәкъ шулай эшләде дә. Патша узганында нәрсә сөйләгән булса, тагын шул ук нотыгын кабатлады, изгелек, бозыклык, гөнаһлар турында төкерек чәчте. Аннан соң тагын бер кешене асып, күргәзмә җәза бирделәр. Шулчак шымчылар башлыгы Җасус, Алып Бәргән белән Корангыш ягына ымлап, патшаның колагына нидер пышылдады. Патша агарынды, күгәренде, аннан ачуына буылып:

— Җинаять! — дип кычкырды.

Барча халык куркуыннан аягүрә басты.

—Кем син? — дип кычкырды Яхур патша Алып Бәргәнгә.

— И бөек патша!— диде Алып Бәргән.— Мин ерак Болгар илендәге Утыз Имәнле авылының Алып Бәргән атлы батыры буламын!

Шул чак хөкемдар телгә килде:

— Сине җәза көтә, Алып батыр. Ирекле илебездә җинаятьчегә сайлау иреге бирелә. Сине турыдан-туры дарга асыйкмы, әллә син җиңелмәс Әлҗаман батыр кулыннан шәһит китәргә телисеңме?

— Мич башында үлгәнче, мәйданда үл! — диде Алып Бәргән.

Бөтен халык мәйданга кереп тулды. Диван вәзирләре белән Яхур патша да кояштан күләгәләп торган беркәвечле урынга утырдылар.

Мәйданның бер ягында җиңелмәс батыр Әлҗаман басып тора. Әлҗаманның аты алтын-көмешләр белән бизәлгән дирбияләргә уранган. Йөгәнендә йөз алтын тәңкә, тезгенендә йөз көмеш тәңкә, өзәңгесенең берсе алтыннан, икенчесе көмештән коелган. Айгыр пошкыра-кешни, тоягы белән җирне казып, чөеп-чөеп, чирәм ыргыта. Күзләрен кан баскан. Әлҗаман аны көчкә-көчкә генә тыеп тора кебек. Әлҗаман батырның өстендә алтын көбә, кылычының кынысы да алтын белән йөгертелгән, җәясенең сабы асылташлар белән чуарланган. Күкрәге сәке киңлегендә булыр, йодрыклары бала башы чаклы күренә. Ике кашы маңгаенда кушылган. Каш астыннан ике күз карый. Ул караш куәтле батыр карашы, үз җиңүенә нык инанган караш иде.

Алып Бәргән үзенең Корангышы белән мәйданның каршы ягында тора. Ул бертуктаусыз атының муенын сыйпый. Корангыш ажгырып торган айгыр ягына боек кына карап ала да авыр итеп пошкырып куя. Атның сыртында киез ияр, мунчала дирбия, тезгене дә тузып, чачакланып беткән. Якын килгән чебен-черки-кигәвеннәрне куарга матур койрыгы да юк мескеннең. Чебеннәрне кулындагы үлән сабагы белән хуҗасы Алып Бәргән куып тора. Алып Бәргәннең тимер башлыгы астыннан куе кара ат койрыгы күренеп тора.

Уен башлыгы болай дип кычкырды:

— Менә бакыр акча. Күн төшсә, Әлҗаман батыр беренче булып Алып Бәргәнгә өч ук ата. Әгәр дә тәңкә иләк ягы белән төшсә, беренче атыш Алып Бәргәнгә чыга.

— И бөек патша, и олуг вәзирләр, и мәйдан гавамы! — диде Алып Бәргән.— Сезнең гадел илегездә үлемгә хөкем ителгәннәргә соңгы сүз бирелү гадәте булса, мин әйтер идем: акчаны мин биргән бакыр белән чөйдертсәгез иде. Минем акчамда хыянәт, хәрәмләшү һич юк. Менә, карагыз, аның бер ягы күн, бер ягы иләк. Ә уен башлыгының кулында мин ике ягы да күн акча күрәм!

Мәйдан халкы гөж килә. Вәзирләр киңәшә башладылар. Озак кына пышылдашканнан соң:

— Юк! — диде хөкемдар.— Алып Бәргән иленең кануннары безнең илгә ярамый. Алып Бәргән иленең акчасы безнең илдә йөрми!

Уен башлыгы һавага үз бакырын чөйде. Акча зырлап-бөтерелеп җиргә төште дә кабыргасы белән кадалып калды. Мәйдан берьюлы:

— Ике батыр бер очтан атарга тиеш! — дип кычкырды.

— Йола буенча, батырлар, исемнәрегезне әйтеп чыгыгыз! — диде уен башы.

— Һәй! — дип кычкырды Әлҗаман.— Син кем буласың, ябалак? Үлемең алдыннан әйтеп кал. Мин Будил хакиме Яхур патшаның җан сакчысы, җиңелмәс батыр, йөз пәһлеванны шушы мәйданда үз куллары белән үтергән Әлҗаман атлы каһарман торырмын!

— Тыңла, Әлҗаман каһарман! — диде Алып Бәргән.— Мин Болгар илендәге Утыз Имәнле авылының Мәргән батыр улы Алып Бәргән булырмын! Бу минем беренче сугышым!

Әлҗаман шаркылдап көлеп җибәрде:

— Беренчесе һәм соңгысы булыр!

— Карап карарбыз! — диде Алып Бәргән.

— Һәй, син, Алып Бәргән, Утыз Имәнленең йолкыш батыры, койрыксыз корчаңгы атың белән шәһәрнең атаклы батыры Әлҗаманга каршы көрәшүдән баш тартмыйсыңмы? Әйтеп кал!

— Һәй, Әлҗаман батыр! — диде Алып Бәргән.— Мин саланың койрыксыз, кораңгыш таена атланып, каланың алтын дагалы айгырына менгән түмәр башлы батырына каршы үз теләгем белән чыктым!

Батырлар кара-каршы бастылар да җәяләренә берәр ук куеп, керешләрен тарттылар.

Уен башы:

— Һа-ат! — дип кычкыруга ике ук берьюлы сызгырып очты. Уклар юл уртасында бер-беренә бәрелеп, шартлап сынды. Мәйдан «аһ» итеп куйды. Калган ике ук та нәкъ шулай уртада бер-берсен сындырды. Әлҗаманның күзендә курку чагылып узды.

— Сөңгеләргә-ә! — дип кычкырды уен башы.

Батырлар әзерләнде.

— Һүр-рә-ә! — дип кычкыруга, ике батыр да сөңгеләрен алга тебәп, җан-фәрманга чабып китте.

Ат башлары бер-беренә бәрелде дигәндә генә, Кораңгыш кинәт уңга ыргылды. Әлҗаманның сөңгесе бушлыкка очты. Алып Бәргән сөңгесе белән Әлҗаманның калканына китереп орды. Әлҗаман ияреннән чыгып очты да «дык» итеп җиргә барып төште. Дошманы җирдән торгалаганчы, ат өстендә килеш аны Алып Бәргән кылыч белән чаба ала иде. Ләкин ул алай эшләмәде. Үзе дә ат өстеннән сикереп төште дә җирдән тора алмый азапланучы Әлҗаманга торырга булышты.

Кара халык ягы умарта күчедәй гүли иде:

— Чабып үтер, чап мәлгуньне! — дип кычкыра кемдер.

Кайсыдыр:

— Бирешмә, Әлҗаман, бирешмә! — дип акыра.

— Кылычларга-а! — дип үкерде уен башы.

Ике батыр да кылычларын кыннарыннан суырып чыгарды. Әлҗаман тешләрен кысып, ачу белән кылычын айкый башлады. Алып Бәргән кинәт кенә иелгәндә аның муены ачылып китте. Әлҗаман кирәмәйләп Алып Бәргән муенына кылыч белән чапты. Ни хикмәт — Алып Бәргәннең муены моны сизмәде дә. Ат койрыгы аның муенын нык саклый иде. Әлҗаман дошманын үтердем дип ялгышты. Шулчак иелеп торган җиреннән күтәрелеп, Алып Бәргән Әлҗаманның балтырына кылычы белән чапты. Тик Әлҗаман аягына да эчтән тимер калкан кигән булып чыкты. Батырлар тагын кара-каршы бастылар.

Чаң да чоң кылычлар бәреләә, очкыннар чәчри. Аяк табаннары астыннан чирәм учмалары чыгып-чыгып оча. Батырлар икесе дә тирләп пешкән. Шулчак Әлҗаман кылыч белән Алып Бәргәннең кылычын эләктереп-бөтереп алды. Алып Бәргәннең кылычы һавага очты. Кылыч сызгырып җиргә кадалды. Алып Бәргән үзенә сузылган кылыч каршысында коралсыз, япа-ялгыз калды. Вәзирләр:

— Чап! Ча-ап, када! — дип акыра башладылар.

Халык ягыннан бер тавыш та ишетелми иде. Әлҗаманның күзендә шайтан шатлыгы уйный. Ул Алып Бәргәннән күзен дә алмыйча, әкрен генә кылычын аның бугазына китерә башлады. Алып Бәргән артка чикте, ләкин кылыч аннан бер карыш та калырга теләми. Бөтен мәйдан аягүрә басты. Әлҗаман шулай чигендереп алып килеп, Алып Бәргәнне патшаның аяк астында үтерергә уйлаган иде ахрысы. Кинәт кенә Алып Бәргән тимер башлыгын салып атты да ат койрыгы белән кылычка кизәнде. Кылыч Әлҗаман кулыннан ычкынып китте. Кылычны җиргә ташлап, Алып Бәргән, ат койрыгы белән кыйнап, Әлҗаман батырны мәйдан буйлап йөртә, мәйдан көлә, вәзирләр акыра. Баш уенчы Алып Бәргәнне туктатмаган булса, Әлҗаманның хәлләре мөшкел иде. Батырлар бераз хәл алгач, уен башлыгы тагын кычкырды:

— Ялан кул белән көрәшкә-ә!

— Әлҗаман! — диде Алып Бәргән.— Минем атым Алып Бәргән. Мин — бу исемне көрәш мәйданында яулап алган кеше. Үз теләгең белән баш тартасыңмы көрәштән? Әгәр баш тартмасаң, миннән шәфкать көтмә!

— Мин көрәшәм! — диде Әлҗаман.

Тотындылар. Башта алар, бер-берсен сынау өчен, озак кына шулай тотынышып йөргән булдылар. Тартышып-тартышып карадылар. Әлҗаманның төрле ягын капшап караганнан соң, Алып Бәргән кинәт аска кереп, көндәшенең билен шатырдатып тотып алды да «һек» иткән тавыш чыгарып, Әлҗаманны янбашка күтәрде, аны-моны абайлап өлгергәнче, дошманын баш аркылы һавага чөйде. Әлҗаман һавада җансыз зур курчак кебек ике тапкыр әйләнде дә, башы белән «дыңк» итеп җиргә төште.

Патша Алып Бәргәнне үз янына, сарайга чакыртып алды.

— Син — бөек батыр, Алып Бәргән! — диде Яхур.— Алтын-көмеш, бал-май — бар да сиңа! Син минем сарай батырым булырсың!

— Баш өсте! — диде Алып Бәргән.

Батырга гөлбакча эченнән күп бүлмәле матур бер йорт бирделәр. Унлап хезмәтче, аш пешерүче, ат караучы аңа кол булды. Бер дистә кәнизәк кызлар батырның бер алдына, биш артына төшә-төшә уйнаклыйлар. Яхур патша яңа батырын үзеннән калдырмый. Сәйрәнгә чыкканда да, сунарга барганда да Алып Бәргән Яхур патшаның арка ягында булырга тиеш. Арттан ук очса да, арттан кылыч янаса да, арттан бау ташлыйсы булсалар да Алып Бәргәнгә эләгергә тиеш. Алып Бәргән булган җирдә кем андый эшләргә батырчылык итсенди! Яхур патша нык вә ышанычлы сак астында яши!

Алып Бәргәнгә сарайда яшәве рәхәт. Әзергә-бәзер дигәндәй, тамак тук, өстә алтын-көмеш. Гади кәпәчен салдырып ыргыттылар да алтын ука белән чигелгән чалма кигезделәр, кәпәчне чүп чуманына ташладылар. Корангыш та онытылды. Бичара атны чыбыркылап, шәһәр читенә кудылар. Шулай итеп, Алып Бәргән чынлыкта исә Әлҗаманнан да яманрак җәлладка әверелде.

Бичара Корангыш, кая китәргә белми аптырап, шәһәр читендәге чүплек башында иренен салындырып озак торды. Шулчак шәһәр ягыннан килүче бер адәм аның янында туктады. Атның тезгенен йөгән сагалдырыгына бәйләп куйды. Карбыз кабыклары арасында аунап яткан кәпәчне алып какты да ияр астына кыстырды. Кылычны җингән ат койрыгын ияр җәясенә бәйләде. Бу кеше Йормаш карт иде.

— Соңгы өметем өзелде! — диде бичара Йормаш.— Алып Бәргән берни хәтерләми! Элеккесеннән дә хәтәррәк җаллад бирдем Яхур мөртәткә. Бар, Корангыш, авылыңа кайт. Алып Бәргән атлы батырның харап булганлыгын белсен халык.

Корангыш кайтыр юлга чыкты. Ул да елый иде. Аның кап-кайнар яшьләре юл туфрагына тып-тып тама.

## Ат өстендә аксакал

Нәүмизә бер көнне Алып Бәргәннең хәнҗәрен сандыгыннан алган иде, чак кына һуштан язмады: хәнҗәрнең ике ягы да күгәргән иде. Ул йөрәгенә иңгән бу кайгыдан сыгылып төште:

— Алып Бәргән үлгән! Алып Бәргән вафат булган! — дип кычкыра-кычкыра, Мәргән картларга йөгерде.

Бу хәбәрне ишеткәч, бөтен авыл кан-яшь түкте. Бары тик Мортыш бай гына шатлыгын яшерә алмады.

— Эшләр җайлана! — диде Мортыш бай кешеләргә ишетелерлек итеп.— Нәүмизәне Мөхти бай улы Чаргыйга бирермен, иншалла!

Нәүмизә өенә кайтты да сәкегә менеп:

— Аннан башка миңа ни тормыш!— дип, күгәргән хәнҗәрне йөрәгенә төбәде. Атасы Мортыш кызы кулындагы хәнҗәрне тиз генә тартып алды. Нәүмизә сәкедәге ястык-түшәкләргә капланып сулкылдый башлады.

— Тиле! — диде Мортыш.— Ул үлгәннән дөнья бетәмени? Әнә сиңа кияүләр — бер чуман! Теләсәң кайсысын сайла! Чаргый аннан ким егетме, ә?

Берничә көннән соң авылга Алып Бәргәннең аты кайтып төште. Йөгәнгә кыстырылган тезгенне, ияр җәясендәге ат койрыгын, Алып Бәргәннең кәпәчен күреп, авыл халкы батырның чыннан да үләгенә ышанды. Мәргән карт бичара бахбайны кочаклап елый башлады.

— Эзли чыгарга кирәк! Җәсадын табып, сөякләрен булса да алып кайтып, җирләргә кирәк! — дип, Мәргән карт юлга чыкты. Үзе белән ул ат койрыгын, улының кәпәчен, ук-җәясен алды. Мәргән картны юлга озатышырга дип, Нәүмизә дә килгән иде. Кешегә күрсәтмәскә тырышып кына Нәүмизә, җиң эченнән чиккән кулъяулык чыгарып, Мәргәнгә сузды.

— Мәргән абзый! — диде кыз.— Күз яшьләрем белән чиктем мин бу яулыкны. Өстенә гатырша мае сиптем. Алып Бәргәнне эзләп тапкач, аның ярасына шуны капла, бәлки терелер...

— Рәхмәт, Нәүмизә кызым! — диде кайгылы ата.

Мәргән атының тезгенен бушатты. Корангыш, белгән юлыннан туп-туры барып, Мәргәнне Йормаш карт мәгарәсенә алып килде. Ике карт сәлам алмашып эчкә уздылар. Кич утырып алар бер-беренә башларыннан узганнарны бәйнә-бәйнә сөйләп аңлаттылар. Улының сау-таза булуы, әмма ләкин коточкыч җалладка әверелүен ишетеп, Мәргән батыр егылып үлә язды.

— Башка юл юк! — диде Алып Мәргән.— Мин тугры җәямне ала килдем. Мәйданга чыгып, мин аны бер ук белән атып үтерәчәкмен!

Бераз сулыш алгач, картлар икәүләп шәһәргә таба юл тоттылар.

Тагын шундый ук хәл кабатланды. Сәҗдәгә киткән вакытта аягүрә басып торганы өчен Мәргән картны үлемгә хөкем иттеләр. Халык тагын мәйданга җыелды.

— Һәй, кем син? — дип кычкырды Алып Бәргән атасына.— Бер аягың кабердә, икенчесе гүрдә килеш минем белән алышмак буламсың? Бу мин — Будил иленең хакиме Яхур патшаның җан сакчысы, җиңелмәс батыры торырмын!

— Һәй, Яхур патшаның койрык сакчысы, исемең кем синең? Кем нәселеннән торырсың? — дип сорады Алып Мәргән.

— Минем исемем юк! — диде Алып Бәргән.— Мин нәселемне белмим!

— Ат өстенә менгәч, атаңны танымыйсыңмыни, миңгерәү бала? — диде Мәргән карт.— Синең беренче исемең Каракүз, аннан ары сиңа Алып Бәргән исеме бирде халык. Хәзер синең исемең Койрык! Патшаның артыннан калмыйча аның койрыгын саклап йөргәнең өчен мин, атаң сиңа шундый ат тактым. Син — Койрык батыр! Минем атымны беләсең килсә, мин Болгар илендәге Утыз Имәнле авылының атаклы укчысы Алып Мәргән, ягъни синең атаң булырмын! Чөегез ялган акчагызны, мин бу хыянәтче баланы үз кулым белән атып үтерәчәкмен!

Күн як Койрык батырга чыкты. Ул җан ачуы белән җәясенең керешен тартты.

— Атма! Атаңа ук атма, бала! — дип кычкырды кемдер.

Бу Йормаш карт иде. Шымчылар башлыгы Җасус иелеп кенә патша колагына нидер әйтте. Куштаннар бичара картны дарга сөйрәп алып киттеләр.

— Бу мин, Йормаш карт булам! — дип кычкырды ул, дарга алып менгәндә.— Бу мин, тыңлагыз, кешеләр! Яхур патша эчендә Иб...

Сүзен әйтеп бетерә алмады, аның аягы астындагы тартманы тибеп очырдылар...

Шулчакны Алып Бәргән керешен ычкындырды. Ук туп-туры Алып Мәргәнгә таба очты. Бичара картның җан биргәнен карарга теләмичә, мәйдан халкы аска иелде. Патша һәм вәзирләр:

— Һәр-рә-ә! — дип кычкыра башлады.

Мәргән, батыр карт булса да, батыр икән әле, ул укны тимереннән тешләп авызына эләктергән икән. Мәргән авызындагы укны җиргә төкерде. Вәзир халкы уһылдап куйды.

— Ат тагын, мәлгунь бала! — дип кычкырды Мәргән карт улына.

Мәйдан халкы аның тавышын ишетеп баш калкытты. Мәргәннең исән-сау икәнен күргәч, халык бердән шөкер сүзләре кычкыра башлады.

Калган ике укны да Мәргән батыр тешләп өзде.

— Хәзер миңа чират! — диде Мәргән карт.

Ул җәясенә ук куйды да төзәмичә генә атып җибәрде. Ук сызгырып очты да, Алып Бәргәннең алтын башлыгына тиде. Башлык урталай ярылды. Алып Бәргән ат өстеннән җиргә тәкмәрләде.

— Торып бас, мәлгунь бала! — диде ата.— Тагын ике угым калды!

Алып Бәргән аякка басты. Мәйдан тын алмыйча шымып калды. Патша белән вәзирләр дә куырылып көтәләр. Икенче ук Алып Бәргәннең алтын кылычын урталай сындырды. Өченче ук алтын дирбияле атның тап маңгай бөтерчегенә төбенәчә кереп батты. Ат гөрселдәп җиргә ауды. Алып Бәргән, башына күсәк белән суккандай, нәрсә булганын аңламыйча тик басып тора.

— Һәй, Будил хакименең койрык сакчысы! — дип кычкырды да Мәргән карт атыннан сикереп төште.— Хәзер безгә ялан кул белән сугышасы калды! Алыштанмы, салыштанмы?

Алып Бәргән инде батырларча кәперәйми, атасы боерганга буйсынып, кыюсыз гына уртага чыкты. Көрәш башланды. Таза яшь батыр хәлсезләнгән картны биленнән кысып, күкрәгенә күтәрде. Мәргән картның биле шытырдады, тыны өзелде. Шунда гына бичара карт әҗәленең баласы кулыннан килгәнлеген аңлады. Уң кулы белән ул Нәүмизә биргән яулыкны билбавыннан тартып чыгарды да, соңгы ихтыярын җыеп, баласының чыраена каплады. Ул арада Алып Бәргән атасын һавага чөеп өлгерде. Мәргән карт ике кат әйләнде дә җиргә барып төште, аның сыны каткан иде. Алып Бәргән битендәге кулъяулыкны сыпырып ташламакчы иде, борынына, күзләренә, тамагынаниндидер таныш ис бөркелде, аның башы әйләнә башлады. Бер-ике тапкыр урынында бөтерелеп алганнан соң, ул атасы янына килде дә чак ишетелерлек итеп:

— Эти! — диде.— Атакаем, бу синме? Нишләп син болай ятасың? Кем сине имгәтте?

— Иел...— диде ата.— Иел, улым. Соңгы сулышым белән әйтәсе сүзем бар...Яхур патша эчендә Иблис утыра, балам. Аны ук та, агу да, кылыч та алмый. Аның көче-җаны койрыгында. Койрыгы комач астында булыр. Шул койрыкны кулына урап тоткан кеше генә яки шул койрыкны кисеп алган кеше генә Иблисне үзенә буйсындыра ала... Эшне сизә күрмәсен... Аны тотуы кыен...

Шулчак ике куштан җаны чыгып бетмәгән Мәргәнне ике аягыннан сөйрәп, мәйданнан алып чыгып китте. Яхур патша җиңелмәс батырын үз янына дәште:

— Егет икәнсең! — диде Яхур.— Сиңа бу батырлыгың өчен алтын катыштырып коелган дәмәшкъ кылычы бүләк итәм...

Баш вәзир кынысы асыл ташлар белән бизәлгән дәмәшкъ кылычын батырга тапшырды. Халык, авызына су капкандай, дәшми-тынмый гына тарала башлады. Вәзир-вәзара патшага юл сапты. Патша артыннан ук койрык сакчысы Алып Бәргән иярде. Шулчак ул тиргә баткан битен сөртергә дип кулындагы яулыкны маңгаена китерде: Нәүмизә, ата-ана, Туган Ил дигән төшенчәләр бер-бер артлы аның зиһенен бораулап узды. Шуннан ул, үзе дә сизмәстән, барган уңайга Яхурның комачын күтәрде дә койрык сыман нәрсәне кулына урап тотты. Бөтен көче белән кинәт үзенә тартты. Батырның кулы шытырдаган галәмәт сизде. Яхур патша җан өшеткеч әшәке, коңгырт аваз белән кычкырып җибәрде дә дүрт аякланды. Сакчылар, хәрби эшләр вәзире патшага ярдәмгә ыргылганнар иде, Алып Бәргән кылычы белән аларны урталай өзгәләп чыкты.

— Һәй, гавам! — дип кычкырды Алып Бәргән.— Таралмагыз!

Койрыгыннан сөйрәп, Алып Бәргән Иблисне мәйдан уртасына алып чыкты.

— Һәй, халык! Менә ул кем сезнең Яхур патшагыз! Ул — Иблис! Чын Яхур патша калыбына кергән, комач бөркәнгән, йонлач-пычрак койрыклы Иблис! Изге суфыйдай, көн-төн Алла исеме белән авыз чайкаучы Иблис шушы булыр, сезнең актык малларыгызны сәдакага талаучы Иблис шушы булыр!

— Җибәр, егет! — диде Иблис Алып Бәргәнгә генә ишетелерлек итеп.— Җибәр син мине. Мин сине алтын-көмешкә манармын. Асыл ташларның кайсы тауларда ятканлыгын, алтын базларының кая яшеренгәнлеген сиңа гына әйтермен. Син дөньяда иң мәшһүр кеше булырсың! Зинһар, җибәр, Алып батыр!

Ләкин батыр егет алтын тауларына алданмады.

Шуннан соң Алып Бәргән яшерен базлардагы тоткын егетләрне, бичара яшь хатын-кызларны азат итәргә боерды. Халык вәзирләрне, куштаннарны дарга асып чыкты.

Кешеләр зинданнардан йөз яшь кызны җитәкләп алып чыктылар. Иблискә каршы кыек сүз әйткән мең ир кешене баздан чыгардылар. Шуннан соң иң ерак базга яшерелгән бер ямьсез затны кыйный-кыйный мәйдан уртасына, Алып Бәргән каршысына китерделәр.

— Кыйнамагыз аны, ул пәри зат түгел! Ул сезнең чын Яхур патшагыз! — диде Алып Бәргән.

Кешеләр арасында аптырап, елый-елый ярдәм сорап йөрүче Җәмлия патшабикәне чакырып алды да Алып Бәргән болай диде:

— Менә бусы, Иблис кыяфәтендәгесе — чын Яхур патша булыр. Менә монысы, койрыклысы — Яхур кыяфәтендәгесе — чын Иблис токымы! Синең чибәрлегеңә кызыгып, халыкны куркытып яшәүче Иблис, патша кыяфәтенә кереп, сезнең илне харап итә язды.

Шулчак Алып Бәргән Иблискә дәште:

— Сихереңне укы! Укы да кыяфәтләрегезне алмашыгыз!

Иблис киреләнә башлаган иде, Алып Бәргән аның койрыгын төбеннән ук урап тотты да чыбыркы белән бер-икене тамызды. Иблис,

авыз эченнән генә нидер мыгырдана-мыгырдана, ямьсез кыяфәтле Яхур патша янында бөтерелә башлады.

Чын Яхур патша үзен коткаручы батырга мең-мең рәхмәтләр укыды. Мәйдан халкы, кыйнап үтерергә теләп, Иблискә ташланды. Кайсы таш алган, кайсысы таяк тоткан. Ләкин Алып Бәргән аларны тиз туктатты.

— Гавам! Мин бу Иблисне бер тапкыр кулдан ычкындырган идем инде. Мин аны Биштишек авылы кешеләренә тапшырырга тиеш, бу Иблистән зыянны алар сезгә караганда да күбрәк күрде. Шулай булгач, мин аны үзем белән алып китәм.

Халык өчен, хакыйкать өчен җанын фида кылган ике картны — Йормаш белән Мәргән гәүдәсен мәйдан уртасына алып чыгып, хөрмәтләү җыелышы уздырдылар. Саубуллашу алдыннан Алып Бәргән Будил халкына карап мондый сүзләр әйтте.

— Туганнар, хөрмәтле Будил халкы! Мәһабәт Яхур патша вә дәхи синең хәләл җефетең гүзәл Җәмлия! Мин илемә кайтып китәм инде. Уяу булыгыз, кешеләр! Матурлык комачы бөркәнгән иблисләрне чын кешеләрдән аера белергә бик вакыт. Намуслы карт Йормаш гомере буе эт типкесендә каңгырып йөрде дә вафат булды. Утыз Имәнле батыры Мәргән карт үз-үзен корбан итте. Мин аны илемә алып кайтып, хөрмәтләп җырләрмен. Рәхмәт Йормаш картка, рәхмәт сезгә, кешеләр! Сезнең илдә минем күзем ачылды.

Мәргән картның җәсәден зиннәтле табутка салып, табутны арбага беркетеп, арбага Корангышны җигеп, Иблисне койрыгыннан урап Алып Бәргән кайтыр юлга чыкты. Аны ерак күпергә хәтле бөтен халык озата барды.

Авылдашлары белән бергәләп, Мәргән батырны олылап җырләделәр.

Ә икенче көнне Бәргән батыр Иблисне Биштишек авылына алып китте.

## Юханы эзләп, ерак юлга

Картын җирләгәннән соң, Алып Бәргәннең әнисе бик бетереште, бичара. Болай да бодай көлтәсе чаклы гына карчык тагын да кечерәеп калды шикелле.

— Атаң да мәрхүм инде, балам! — диде ана.— Йортка ир хуҗа кирәк. Әллә өйләнеп, авылда гына төпләнәсеңме?

Бу сүзләрне ишеткәч, Алып Бәргәннең йөрәге кысылып куйды. Әнисенең сагышлы, ялварулы карашы батырның бәгырен телгәләде. Бик калыр иде Алып Бәргән авылда. Бердәнбер анасын картаймыш көнендә кадерләп тарбияләр иде. Ләкин явыз затлар белән көрәшүдән баш тартса, гомере буе үкенәчәк бит ул.

— Әнкәй! — диде Алып батыр.— Мин бит бөтенләйгә китмим. Аратирә кайткалап йөрермен. Ярдәмемнән ташламам. Мин хатамны юарга, кешеләргә Юханы тотып бирергә тиеш! Зинһар, ачуланма, сәфәргә фатиханны бир, анакаем!

— Фатиха, балам! — диде әнисе беркөнне. Сагыш аша елмаеп, ана кытыршы бармаклары белән батыр улының иңенә кагылды.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз дә утыз җиде ел узгач булды бу хәл. Шәүвәл аеның беренче көнендә Алып Бәргән дүртенче тапкыр сөекле әнкәсен, мәгъшукасы Нәүмизәне калдырып, Юханы эзләп, ерак юлга чыгып китте.

Көн киттеләр, төн киттеләр, ай киттеләр, ел киттеләр болар. Аларның юлда күргән маҗараларын язсаң — язып, сөйләсәң, сөйләп бетергесез булыр иде.

Гөнаһсызга рәнҗетелгәннәрне яклап, әллә ничә тапкыр гадел сугышларда катнашты Алып Бәргән. Үлем тырнагыннан әллә ничә кызны коткарды, бәлагә тарганнарны йолып ала-ала олыгаеп та, житдиләнеп тә китте батыр егетебез. Шул коткарган кызлар аның муенына сарылсалар да, Алып Бәргән, аларның мәхәббәтен кире кагып, алга барды, сөйгәне Нәүмизәгә тугры булып калды.

Бик күп хикмәтләр, могҗизалар күрде ир-егеткәй белән ат башы! Шулай йөри торгач, ул җиде икълимнең яртысын әйләнеп чыкты. Ләкин Юха еланны очратмады. Урманда, далаларда барган чакта ул һәр күргән еланны Юха дип уйлап, гөнаһсызга күпме елан үтерде. Баксаң, алар гап-гади тузбаш булган икән. Шулай еланнар турап, далада йөргәндә, бер карт очрады моңа:

— Һәй! — дип кычкырды карт.— Алып хәтле гәүдәң белән нигә ул кеп-кечкенә тузбашларны үтерәсең? Ул бичара мәхлук җанварның сиңа ни зыяны тиде?

— Һәр елан эчендә Юха бар, шуңа үтерәм! — дип, Алып Бәргән күргәннәрен сөйләп бирде.

— Һәр елан эчендә Юха түгел, һәр Юха эчендә елан ятыр! — дип төзәтте карт.—Син юхаларны далада, урманда эзләмә, олан! Юхалар авылда, күбесенчә шәһәрдә яши. Юхалар чибәр хатын-кыз кыяфәтендә булалар. Ләкин сак бул, батыр, һәр чибәр эчендә дә елан ятмый. Мин килә торган Шомран шәһәрендә, имеш, елан затыннан булган хатын бар, дип сөйләделәр.

— Ничек белергә соң ул хатынның Юхамы, юкмы икәнлеген, бабай? — дип сорады Алып Бәргән.

Юлаучы карт егеткә:

— Юха хатынның кендеге булмый! — диде.— Бөтен хатын-кызларның кендеге була, чөнки алар ана карынында яткан,— дип, әлеге карт Алып Бәргәнгә юхалар турында белгән-ишеткәннәрен сөйләде.

Алып Бәргән аңа рәхмәтләр укып, ул өйрәткән юл белән Шомран каласына китте. Юханы тотып, Биштишек авылы кешеләренә тапшыру теләге шулкадәр куәтле иде ки, ул атын күбеккә батырганчы куды. Ниһаять, кояш баеганда алда матур гына, җыйнак кына бер шәһәр күренде. Юл кырыендагы тактага «Шомран» дип язылган иде. Алып Бәргән шәһәр кырыендагы бер йортка кереп, эчәргә су сораган булып, хуҗаларның кылын тартып карады. Фәлән дә төгән, фәлән дә фәсмәтән, тегеләй дә болай, шундый кешеләр юкмы сезнең калагызда, дигән булып сорашты. Ләкин бер генә кеше дә, менә бу хатын Юха елан, дип анык кына әйтә алмады.

— Каидан башларга инде? Ничек кенә Юханы фаш итәргә? — дип Алып Бәргән тар урамнар буйлап китте.

Шулай баш вата-вата, төн ката йокламады. Таң атып бетте. Менә бер-бер артлы капкалар шарт-шорт ачыла башлады. Һәр капка саен бер ир чыга. Кайсы баш очына йөк күтәргән, базарга бара. Кайсысы кулына балта-пычкы алып урманга китә. Кайсысы, атына атланып, патша сараена таба юл ала. Шулай барганда Алып Бәргән бер ишегалдына күз ташлады. Ат өстеннән аңа бар да аермачык булып күренә иде. Атының дирбиясен рәтләгән булып, Алып Бәргән йорт эчендәге тавышларга колак салды.

— И, җанкисәгем, исән-сау гына эшләп кайт! — дигән сүзләр ишетелде.— Без әнкәй белән сине зарыгып көтәрбез!

Алып Бәргән күз кырые белән генә караган иде, гаҗәп матур бер яшь хатынны күрде. Баскыч башында карт хатын басып тора. Яшь хатын иренә кылычын, башлыгын, бөтен кирәк-яракларын берәм-берәм өйдән алып чыгып тора. Ир кеше атына атланды да иелеп хатынын үпте.

— Озак торма, улым! — диде анасы.

Бәхете ташудан ир кеше кызарып чыкты. Капка ачылып китте, ат менгән ирне анасы, матур хатыны озатып калды. Ир кеше борылмада югалу белән, әлеге матур яшь хатын кинәт усалланды, карт ананы ишегалдына төртеп кертте. Шартлатып капканы бикләде дә тотынды чәрелдәргә, тотынды кычкырырга:

— Син, убырлы карчык, аяк астында уралма! Бар тиз бул, керләр ю, мичкә ягып, ашарга әзерлә, малларны кара!

Бичара карчык телсез-өнсез калды, шулай тавыш-тын чыгармыйча гына тырыша-тырыша эшли башлады.

— Озак торма, улым, дигән булып син аңа ни әйтергә уйладың, пәри карчыгы? — дип кычкырды килен.— Мине килен кыерсыта, дип әйтергә уйладыңмы, ябалак?

Килен кеше бер-ике тапкыр кайнанасына сугып та алды.

«Менә ул Юха елан!» — дип уйлады Алып Бәргән.

Корбанын тотар алдыннан мәченең койрыгы ничек дулкынланса, Алып Бәргәннең дә күңеле кымыр-кымыр килә башлады. Шуннан соң ул күрше-тирәләрдән сак кына сораштыра башлады: фәлән дә төгән, тегеләй дә болай... Бу кыз бик юаш, итагатьле булган икән, кайсыдыр авылдан монда килен булып төшкән. Ире аңа үлеп гашыйк икән. Тик ире аның Юха икәнен белми икән. Килен төшкәч, ирнең анасы кибәкорый башлаган. Яшь килен ирнең туганнарын капкадан да кертми икән.

Алып Бәргәннең ышанычы тагын да артты. Ул бер карарга килеп, кәпәченә дәште:

— Кәпәчем, син ничек уйлыйсың?— диде.

— Минемча, ул Юха түгел! Авылдан килеп, шәһәргә урнашкач, хатыннар нишләгәнен белми, усаллана,— диде кәпәч.

— Юк, кәпәчем, бу — Юха! Ире алдында ал да гөл, ире киткәч, күрәсеңме, анасын куыра гына,— диде батыр.— Мин аны фаш итәм. Әгәр дә кендеге булмаса, вәссәлам, ул хатын Юха булып чыга!

Алып Бәргән ияр өстеннән әлеге койма аша сикереп, ишегалдына төште. Яшь хатын Алып Бәргәнгә аркасы белән тора иде. Хатын абайлап өлгергәнче, батыр аның авызын томалап алды да, тиз-тиз генә капка бикләрен ачып, атына атланып, шәһәр кырына таба элдерде. Яшь хатын чәбәләнә, тартыла, тешли, ләкин Алып Бәргән кулыннан алай гына ычкыну мөмкинме соң! Ул арада урамнарда шау-шу купты:

— Мөрхәйнең хатынын урладылар!

— Караклар, юлбасарлар! — дигән тавышлар, куа чыккан авазлар ишетелә башлады.

Алып Бәргән бер өер атлыларның һай-һулап чапканын ишетте. Куа чыккан кешеләр арасында хатынның ире Мөрхәй дә бар иде. Мөрхәй җан ачуы белән Алыпка кылычы белән кизәнүгә, аны бер өлкән кеше туктатты:

— Болай ярамас, моңа патшабызның хөкеме кирәк! — диде.

— Ул бит Юха елан! — дип кычкырды Алып Бәргән.

— Нинди Юха булсын ул, Мөрхәйнең хатыны бит ул! — дип үкерде халык.

Алып Бәргәнне сүгә-сүгә, патша янына алып киттеләр. Диван вәзирләре, сарай агалары хөкем оештырды.

— Ватандашыбыз Мөрхәйнең хатынына кул салганы вә дәхи аны урлап китәргә маташканына күрә һәм дә аны мәсхәрә итәргә уйлаганы өчен бу бәндәне үлем җәзасына тартырга! — дип карар чыгардылар да Алып Бәргәнгә соңгы сүз бирделәр.

— Мин Болгар иленең Утыз Имәнле батыры Алып Бәргән буламын. Минем максатым — кеше хатыны урлау түгел, минем ниятем — Юха булган хатыннарны фаш итү! — диде батыр.

Шуннан соң баш вәзир патшага иелеп болай диде:

— Чыннан да, бу безгә ишетелгән Будил патшасын Иблистән коткарган Алып Бәргән батыр булырга тиеш. Әллә минәйтәм, Мөрхәйнең хатыны чыннан да Юхамы икән?

Шаһитләр белән бергә барып, Мөрхәй хатынының кендеген карап кайтырга булдылар. Мөрхәйнең хатыны бик усал нәмәстәкәй, бер дә оялып тормастан итәген ачып шаһитләргә, вәзирләргә кендеген күрсәткән ди.

— Юк! — диде патша.— Син ялгыштың, Алып Бәргән, Мөрхәйнең хатыны Юха түгел, ул гап-гади усал хатын. Теләгең изге булуы аркасында, өстеңнән үлем җәзасын алып, сине бер айга төрмәгә ябарга боерам!

Шулай итеп, Алып Бәргән бер ай төрмәдә утырып чыкты.

Шәһәрдән еракка киткәч, Алып Бәргән, ияренә башын куеп, черем итеп алырга булды. Якында гына чылтырап чишмә ага. Тал-тирәкләрдә кошлар чыркылдаша, янәшәдә генә Корангыш керт-керт печән чемчи. Шул тавышларны тыңлап ята торгач, батырны йокы баса башлады. Аз йоклагандырмы, күп йоклагандырмы, шул матур тавышларга нинди дер ямьсез, шомлы аваз килеп кушылгач кына, Алып Бәргән күзен ачты.

— Коңкь, ко-оңкь! — дип нидер коңгылдый.

Алып Бәргән биектә-биектә берничә козгынның урман-таулар ягына таба салмак кына очып барганнарын күреп алды.

— Кәпәчем, әйтсәнә, зинһар! — диде Алып Бәргән.— Рух козгыннары бер якка салмак кына очса, ни була?

Кәпәч әйтте:

— Рух козгыннары салмак кына очып барса, шул якта мәет көтелә. Кемнедер асаргамы, атаргамы алып баралар дигән сүз. Әгәр дә козгыннар астан гына тиз очсалар, якында гына сугыш булган, шул якта мәет ятыр!

Шуны ишетүгә, Алып Бәргән сикереп торды, тиз генә атын иярләде дә юыртып китеп барды.

— Тиз бул, Корангыш! — диде батыр. Кемнедер үлем көтә. Ашыгырга кирәк!

Хуҗасы өчен утка-суга керергә әзер торучы Корангыш бар сулышын җыеп алга ыргылды. Көнозын чапканнан соң гына алар еракта урман күрделәр. Рух козгыннары шул урманга төшеп кунаклыйлар иде. Бераз барганнан соң Алып Бәргән, чыннан да, агачларны сырып алган козгыннарны күрде. Ашарга китергәнне сабыр гына көтеп утыручылар кебек, козгыннар өере тып-тын, селкенми генә утыра бирә. Алардан читтәрәк, урман авызында, бер ир кеше ашык-пошык бау әзерли, үзе бертуктаусыз нидер мыгырдый. Менә ул сүстән ишкән бауны агач ботагына аркылы атты. Ботаклар буйлап менеп, бауны каты итеп бәйләде. Элмәкле башын муенына кигерде... Козгыннар мәгънәле генә итеп, бер-берләренә карашып алдылар: чукырга азык була, янәсе. Алып Бәргән катып калган җиреннән кинәт айнып китте дә, бар көченә атын куып, агач янына чабып килде. Килгән уңайдан ул кылычы белән селтәнеп бауны кисте. Егетнең ябык гәүдәсе чирәмгә салынып төште. Алып Бәргән тиз генә бауны чиште дә әле үлеп җиткермәгән егетне уңлы-суллы чәбәкли башлады, муен тамырларын ышкыды.

Ир кеше күзләрен ачты да Алып Бәргәнгә карап:

— Син Газраилмени? — дип сорады.

— Юк, мин Газраил түгел! — диде Алып Бәргән.— Синең коткаручың.

Әлеге ир кинәт торып утырды да Алып Бәргәннең якасыннан алды.— Син, тилергән нәрсә, нигә мине коткардың? Кем кушты сиңа мине коткарырга? Нигә минем шәхси эшләремә тыгыласың? — дип елый башлады.

Алып Бәргән аның ябык кулларын каты итеп тотты да:

— Тынычлан! — дип кычкырды.— Егет кешегә хатын-кыз кебек чәбәләнү килешми. Ни булды? Нигә син дөньядан туйдың? Дөнья матур бит, дөнья киң!

Батырның каты тавышыннан куркыпмы, әллә кулы авыртуга айныпмы, әлеге асылынган егет тынычлана төште.

— Түзәрлегем калмады! — диде ул.— Хатын көн күрсәтми, хыянәт итә. Күрмисеңмени, киптем-корыдым, шыр сөяккә калдым.

Асылынган егет башыннан үткәннәрне елый-елый сөйләп бирде.

— Шушы урманны чыккач та бер шәһәр булыр. Дәүләкән каласы. Мин шул илнең атаклы язмачысы Дәүләкән-әл-Шәрабби булам,— диде ир кеше.— Һәр язганымны халык бик сөеп каршылый торган иде. Дан вә шөһрәт, мал эчендә күп кайнадым. Күп гүзәлләр каләмем тигән кәгазьне тотып тору, мин баскан җиргә матур чәһрәләрен куеп, ләззәт алуны бәхет санарлар иде. Мин ләззәт вә рәхәтият дөньясында тормыш кичердем. Аһ, ул керфекләрнең тирбәлеше, ул гашыйк күзләрнең томсык кына карашлары... Шул мең кыз арасыннан мин иң гүзәлен, минем йөрәкне иң нечкә тоя алганын сайлап, Румзия исемле кызга өйләндем. Бөтен шәһәр «аһ» итте. Ул бәхетле кыз, ул гүзәл диделәр. Атаклы Дәүләкән-әл-Шәраббинең хатыны булу, патшабикә булудан мең кәррә артыктыр, диделәр. Бар булган маямны түгеп, туй ясадым. Шул туй төнендә мине кара сагыш басты. Кунаклар таралгач, зөфаф кичәнә кердек. Румзия билбавымның очын озак табалмасын дип, мин аны нык яшердем. Утлар сүнеп, караңгыда калгач, тыйнак кызчыгым ажгырып мине кочаклап алды да абайлап өлгергәнче, чишендереп ташлады... Күпне күргән, күпне белгән хатын булып чыкты ул Румзия. Аерылыштык. Озак еллар йөрдем буйдак булып. Инде кабат алданмам, иң яхшысы — авыл кызына өйләнәм дип, бакчачы кызын сорадым. Риза булды ата-анасы. Ләкин шәһәр хатыннары: атаклы язмачыга авыл кызы тиң түгел дип, колагыма чикерткә булып ояладылар. Шуннан соң миңа олуг бер вәзирнең кызын димләделәр. Монысы Җофия исемле иде. Яманаты чыкмаган. Җофия дә бик чибәр иде. Тыйнак, эшчән, һич тә вәзир кызы димәссең. Теге мәгъшукалар бар да онытылды. Мин үлеп гашыйк булдым Җофиягә. Бар ягы да килгән. Һич аны гаепләрлек нәрсә юк. Зөфаф кичендә дә сәке почмагында гына бөрешеп утырды. Ләкин тора башлагач, хыянәтче икәнен белдем...

Егет тагын өзгәләнеп елый башлады.

— Хыянәт итсә, тотып чыбыркы белән яр! Аннан соң куып чыгар! — диде Алып Бәргән.

Егет тагын әйтте:

— Ышандыра бит. Юмалап, елап ышандыра. Мин гөнаһсыз, ди. Ышанам, валлаһи, ышанам. Күзләре гөнаһсыз сабый күзләре кебек. Үзе юкта көнләшүдән буылам. Үтерәм дип ант итәм. Үзе кайткач, бар да онытыла. Яратам шул мин аны!

— Яраткан хатыныңны ташлап китәргә булдыңмыни теге дөньяга? — диде Алып Бәргән.

— Башка чарам калмады! Ашаганым заяга китә, эчкәнем бушка!

— Шулай ук усалмыни соң? — дип сорады батыр.

Язмачы әйтте:

— Юк, усал түгел ул. Шундый матур, шундый назлы үзе. Кич життеме, чәйгә нидер салып, мине йоклата да каядыр чыгып китә. Төне буе кайдадыр йөреп, таң алдыннан гына кайта. Уяндыңмы, матурым, дигән була кайткач. Мин абзарга гына чыгып кергән идем ди. Ә үзенең урыны сап-салкын.

Алып Бәргән шыр сөяккә калган бу мескенне чын күңелдән кызганды.

— Синең хатының — Юха елан! — диде батыр.

Егет башта аңламады, бараздан сорый куйды:

— Ничек инде ул Юха елан?

Алып Бәргән Юха еланны эзләп йөргәнен аңлатып бирде. Алар икесе дә аягүрә торып басканнар иде. Рух козгыннары — үлем шәүләгәннәре — дәррәү очып киттеләр. Егет тынычланды.

— Син миңа ярдәм итәргә тиешсең! — диде Алып Бәргән.— Мин сиңа юлда кайтканда барын да аңлатырмын. Нәкъ мин әйткәнчә эшләсәң, без аны фаш итәчәкбез! Син еланнан котылып, башкага өйләнә аласың, мин гавам алдында икенче бурычымны үтәгән булырмын!

— Мин нишләргә тиеш соң? — диде әл-Шәрабби.

— Син һични сиздермичә генә өеңә кайт. Кайда йөрдең дип сораса, урманга барып илһам эзләдем диген, сиңа зур бер дастан багышлыйм, диген...

Алып Бәргән язмачы яши торган йортның күршесенә фатирга төште. Дәүләкән-әл-Шәрабби, эшне сиздермәскә тырышып, шигырь сөйли-сөйли өенә кайтып керде.

— Кайда булдың? — дип сорады хатыны Җофия.

— Менә, җаным! — диде язмачы.— Синең турыда бөек бер шигъри дастан язарга дип, урманга бардым. Бик арыдым, йокым килә. Аллага тапшырып, иртәгә ул дастанны яза башларга ниятем бар.

Шуны ишеткәч, Җофия гүзәлнең йөзе яктырып китте.

— И йөрәк парәм, җанкисәгем минем! — дип сырпалана башлады хатын.— Синең иҗатың өчен мин бөтен нәрсәне эшләргә риза. Яз! Иҗат ит! Дастаннар чыгар! Мин сине өзелеп сөям!

Шулай чәй әзерләгәндә Җофия яшереп кенә чеметемләп касәгә нидер салды. Ире моны сизеп торды. Ләкин, Алып Бәргән өйрәткәнчә, күрмәмешкә салышты. Җофиянең кыланышына карап торсаң, аны һич тә хыянәтче хатын димәссең, валлаһи. Йомшак, назлы тавыш дисеңме, ул буй-сын дисеңме; кулларына карасаң да йөрәк турыннан нидер чеметеп-чеметеп ала. Ул арада Җофия Шәраббигә чәй китереп куйды. Алып Бәргән өйрәтүе белән Шәрабби нәкъ шундый ук касә әзерләп, яшерен кечкенә кувшиннан нәкъ шундый ук чәй салды да, хатыны борылган арада касәләрне алмаштырып куйды. Ир белән хатын тәмләп чәй эчә башладылар.

— Хәзер сиңа урын җәеп бирәм! — диде Җофия.

Шәрабби өстәл янында ук йокымсыраган булып утырды. Урын әзер булгач, хатыны ирен иркәли-иркәли түшәккә яткырды. Үзе дә янәшә ятты.

Ире яту белән гырлый да башлады. Ә үзе күз кырые белән генә карап ята. Байтак ятканнан соң хатын, ирне уятмаска тырышып, иплән, кенә юрганны ачты. Сакланып кына торды, чишенә башлады. Ул хатынының матур, тал чыбыгыдай сыгылмалы зифа буена карап, гырлавыннан туктады. Ул гырламый башлагач та, Җофия кинәт сискәнеп, иренә карады. Хатасын аңлап, язмачы тагын да катырак гырларга тотынды. Иренең йоклаганына ышангач кына, киемнәрен бер почмакка ташлап, яңаларын һәм матурларын киенә башлады. Шул чакта Шәррабби хатынының бүксәсе уртасына күз төшерде. Ни гаҗәптер, аның кендеге юк иде. Җофия, киенеп беткәч, тиз генә чыгып та сызды. Ул китеп, бераз торгач, Шәрабби атылып-бәрелеп урамга чыкты. Ул өч тапкыр сызгырды. Күрше ишегалдындагы урында Алып Бәргән аның сызгырганын көтеп ята иде.

— Алып Бәргән! — диде язмачы һәм күргәннәрен сөйләп бирде.

— Тсс! — диде батыр.— Шаулама. Хәзер мине тыңла. Таң алдыннан хатының кайтыр да, элеккеге кыяфәтенә кереп, синең янга ятыр. Хәзер ук өеңдәге суларны чыгарып түк. Бер йотым су калдырма. Шуннан соң ниләр булганын үзең күрерсең. Һич ни сиздермә. Вакыты җиткәч, үзем әйтермен!

Алып Бәргән кереп китте. Шәрабби, ул кушканнарны үтәп, кире урынына ятты да көтә башлады. Төн уртасы җитте. Шулай ята торгач, ша-

гыйрь йокыга китә язды. Менә берзаман ишек ачылды. Хатыны Җофия кайтып керде. Керде дә чишенеп, ире янына юрган астына чумды.

Ләкин ире һаман йоклаганга сабышты. Аның каты йоклаганына ышангач, хатын иплəп кенә торды да, чиләкләр, кисмәкләр янына килеп, су эзли башлады. Өйдә бер тамчы су юк иде. Хатын кисмәкләрдә су тапмагач:

— Тамагым яна, әчәсем килә, су-су! — дип ысылдый-ысылдый, тәрәзә пыяласын ялый башлады.

Пыяладагы юеш кенә аның сусынын басмады, ул ишегалдына чыгып йөгерде, ләкин коеның капкачы кадакланган иде. Ул ут капкандай тагын өйгә йөгереп керде, үзе бертуктаусыз ысылдый:

— Ссу-у, үләм. Тамагым кипте! Бер йотым с-су-у...

Шулчак хатын яшереп куелган бәләкәй кувшинны алды, андагы чәйне калтырый-калтырый эчеп бетерде дә, үлемнән котылган кешедәй хәлсезләнеп, сәке йөзлегенә утырды. Бераз тынычлангач, тагын ире янына ятты. Йокы даруы эчкән хатын һични белмәде, шундук йоклап китте.

Кунак итәм дигән булып, язмачы Алып Бәргәнне үз өенә алып керде.

— Хатының уянгач, эссе итеп мунча яктыр! — диде Алып Бәргән.— Ул күрмәгәндә генә мунча эчендәге бар суны түгеп бетер. Шуннан соң хатыныңны мунчага чакыр. Ул карышыр, синең белән бармас.

— Җофия беренче көннән үк минем белән мунчага йөрми!

— Әсин ир бит! Беренче көннән үк мунчага алып барган булсаң, әллә кайчан белер идең. Шуның өчен дә бит ата-бабаларыбыз кияү мунчасы әзерләгәннәр. Юхага капмас өчен уйлап чыгарылган йола ул. Ире белән мунча керми икән, димәк ул хатын — Юха елан. Мунчага бармаса, ярар алайса, үзең генә бар диген дә, ул керү белән, ишек-тәрәзәне, төнлекне бикләп куй.

Җофия мунчага керү белән, Шәрабби нәкъ кушылганча эшләде. Мунча ишеген терәтеп, кадаклап куйды. Эшне сизенеп, Җофия яман әче тавыш белән кычкыра башлады, аннан соң ялварырга тотынды:

— Җаным, Шәрабби, бәгырем, ач, зинһар!

Аны кызганып, Шәрабби елап җибәрде.

— Ачма! — диде Алып Бәргән.— Ача күрмә, никадәр ялынса да, ачма!

Тора-бара хатынның тавышы кими башлады.

— С-су, бер йотым с-с-су би-ирс-с-нә-ә...

Шуннан соң тавыш тынып калды. Ишекне ачып җибәрсәләр... Ишек сабына теле белән уралган зур гына кара еланны күрделәр.

— Менә синең хатының Җофия шушы булыр! — диде Алып Бәргән.

— Рәхмәт, дустым! — диде язмачы.

— Үзеңә рәхмәт! — диде Алып Бәргән.— Бу Юха җан бирмәгән әле. Мин аның койрык очын кисеп алам да өстенә су сипкәч, ул тагын хатын кыяфәтенә кайтыр.

Алып Бәргән еланның койрык очын кисеп куен кесәсенә тыкты. Аннан соң елан өстенә чиләкләп су койдылар. Кырык чиләк булды дигәндә, елан селкенә башлады. Аннан тагын кырык чиләк сипкәч, ул янә Җофиягә әверелде.

— Баш өсте, ни боерасыз, падишаһым! — диде Җофия Алып Бәргән алдында баш ия төшеп.

— Күрдеңме! — диде Алып Бәргән.— Этнең койрыгын кем кисса, ул шуңарга «җизни» ди. Еланның койрыгын кем кисса, шуңа «патшам» дип әйтә.

— Җофия! — диде язмачы. — Ә минем хатыным кем булыр соң?

Җофия кыяфәтендәге елан әйтте:

— Синең хатының Җофия тау куышында тоткында булыр. Мин аның кыяфәтенә кердем, синең хатының булдым. Шулай итеп, мин бу илне язмачысыз калдырырга уйлаган идем. Барып чыкмады. Минем юлда һәрвакыт менә бу кеше пәйда була.

— Әйе, мин аны бер тапкыр үлемнән коткарган идем,— диде батыр. Хәзер мин аны Биштишек хатыннарына илтеп бирәм. Ул еланга әйләнүгә, синең хатының Җофия кеше кыяфәтенә керер. Бар тау куышына. Тоткынлыктан еланны алып кайт. Курыкма, ул чыннан да синең хатының. Мин Юханы кешеләр хөкеменә тапшырам. Аны үлемгә дучар иткәч, хатының янә кеше булыр.

Кеше-кара, күрше-күлән уянгалаганчы, дип язмачы Дәүләкән-әл-Шәрабби тау куышына барып, елан кыяфәтле хатынын алып кайтты.

Өч көн, өч төн узуга, елан Дәүләкән-әл-Шәраббинең сөйгән хатыны Җофиягә әверелде. Димәк, Алып Бәргән Юханы кешеләр хөкеменә тапшырган. Биштишек халкы каршындагы икенче хатасын батыр егет әнә шулай төзәтте. Иблисне тотып китергәне өчен аны бер атна гына сыйлаганнар иде. Юханы тапшыргач, өч атна кунак иттеләр.



## Ялмавыз белән сугыш

Биштишек авылында шаплап сыйланганнан соң батыр егет Утыз Имәнлегә кайтып, әнисе-карчыкның хәлен белде. Атасы-мәрхүмнең каберенә дүрт кыры да язулы таш куйдырды. Нәүмизә белән күреште. Башыннан кичкәннәрне авылдашларына сөйләп, күп кичләр уздырды. Алып Бәргәннең батырлыгы турындагы хәбәрләр Утыз Имәнлегә аның үзеннән алда кайтып ирешкән иде. Инде хәзер Алып Бәргәнне кияү итәргә Мортыш бай да каршы түгел бугай. Ләкин Алып Бәргән батырны юллар чакыра, алда аны маҗаралы сәяхәтләр көтә. Зур көрәш әле бетмәгән, алда һаман! Җен-пәриләрне җиңү батыр кешегә чүп кенә. Кешеләрнең кан дошманы — явыз Аждаһа. Шуңар барып житмичә торып, Алып Бәргән башка маш-катьләр турында уйлый алмый иде.

Кышлык утын-печән-икмәк әзерләгәч, атна-ун көннән соң Алып тагын юлга җыена башлады.

Һиҗрәттән соң тугыз йөз утыз тугыз ел узгач булды бу хәл. Зөлхиҗә аенда, Олы атна көнне Алып Бәргән Утыз Имәнледән чыгып китте.

Карурманда карак бар,
Атларыңны карап бар.
Без китәрбез таң алдыннан,
Тәрәз ачып карап кал...

Шулай җырлар җырлап, батыр егет сәфәр китте. Чыннан да, таң алдыннан атына атланып урамнан узганда, Мортыш бай өенең тәрәзә пәрдәсе чак кына ачылды. Бу Нәүмизә иде.

— Ниләр генә булса да, гасырлар узса да, мин сине көтәрмен! — диде аңа Нәүмизә.

Алып Бәргән олы юлга чыкты да аптырап калды. Кая барырга соң, бу Аждаһа мәлгуньне кайдан эзләргә дә, ничек итеп дөмектерергә? Арты белән күлгә чумган үрдәк шикелле, шулай кая барып, борын төртергә дип торганда, юл өстендә тузан болыты күренде. Юл буйлап качырга атланган бер кеше килә. Качыр арбага җигелгән, арбада бер хатын вә ике бала утыра. Алып Бәргән юлчыга сәлам бирле. Сәлам алышканнан соң алар икесе дә җиргә төшеп күрештеләр. Алып Бәргән Аждаһа патшалыгына бара торган юлны сораштыра башлаган иде, әлеге агай хатыны белән балаларына дәстәрхан әзерләргә кушты да Алып Бәргәнне бер читкәрәк чакырып, болай диде:

— И батыр егет, әгәр дә син гаделлек өчен сугышка чыккансың икән, иң башта безнең авылны барып күр. Минем, туган авылымнан качып, күзем кая карый, аякларым кая атлый — шунда барышым. Безнең авыл кебек ярлы, безнең авыл кебек үләргә йөз тоткан бер генә ил дә, бер генә халык та булмас.

— Халкыгыз ялкаумы, әллә түрәгез комсыз-саран кешеме? — дип сорады Алып Бәргән.

— Түбән Ширдыклы авылыннан мин, олан! — дип башлады сүзен юлаучы агай.— Түбән Ширдыклы авылы бик бай, бик көр тормышлы иде заманында. Уйный идек, җырлый идек, бии идек. Авылыбыз турында шагыйрьләребез шигырь яза, сорнайчыларыбыз көй чыгара торган иде.

Юлаучының хатыны ирләрне табын янына дәште. Балалар Алып Биргәнгә дә, аталарына да берәр касә кымыз салып бирделәр. Алып Бәргән сүз башларга ашыкты.

— Ни булды соң сезнең Ширдыклыга, агай? — дип сорады.

Ялкау түгел идек без, батыр егет!— диде агай бераз тынычлангannan соң.— Халык иртә-таңнан шәфәкъ сүнгәнче мыш-мыш эшли. Иңрәеп җир сөрә. Шабыр тиргә батып урман кисә, шакы-шокы чана ясый. Хатыннарыбыз керфек йоммыйча дыкы-дыкы палас суга, мәш килеп мал үрчетә. Җәй буе кышкылыкка әзерләнә халык, кыш буе җәй өчен тырыша. Бәла килде илебезгә, хәзер халык фәкыйрьлектә яши. Авылыбызның бөтен малын ниндидер бер явыз зат йотып бара. Менә ничәмә-ничә еллар инде, күзен мал-туар күрәеп, симереп беткәч кенә, әллә каян, әллә нәрсә килеп чыга да, көтүдәге малны ялмап алгандай, йотып бетерә. Бихисап ир-егетләр харап булды шунда. Яу белән дә барып карадылар, берсе дә исән әйләнеп кайтмады. Хәер, бер кеше исән калган иде. Тик малларны харап итүче шул явыз затның кем икәнен, нәрсә икәнен әйтә алмады. Бары:

— Ялмавыз! — диде дә авыл башында җан тәслим кылды.

Ширдыклы халкы хәзер шом астында. Эше эш түгел, ашы аш түгел. Барыбер Ялмавыз йотачак дип, кешеләр мал-туарын да юньләп карамый, мая да тупламый. Шулай ачлы-туклы, очын-очка ялгап, җан саклап килә инде мескеннәр.

Шушы Ширдыклы авылының Җантык атлы бер бичара егете түрәбезнең кызы Хөрмиягә гыйлып гашыйк булмасынмы! Җантык кына гашыйк булса бер хәл, Хөрмияне сорап Колавыз түрәгә затлы-затлы егетләр яучы җибәрде. Колавыз түрә бәлки разый да булыр иде, кызы Хөрмия җык каршы тора: кияүгә чыкмыйм, бетте-китте генә ди.

— Салам түбәле, кырык терәүле кыйшык өйдә бала үрчетеп, аларның ачтан үлгәнен көтеп ятыйммыни? — дигән кыз.

Ата-анасы, күрше-күлән, яучы-димчеләр бик тинтерәткәч:

— Ярый! — диде беркөнне Хөрмия.— Кем дә кем йортыбызны, данлы Ширдыклыбызны явыз зат Ялмавыздан коткара, мин шуның хатыны булам! — димәсенме!

Бу хәбәрне ишеткәч, бер дистә затлы егет Хөрмиягә гыйшык тотудан туктадылар. Мәйдан уртасында Җантык белән ике егет кенә калды.

— Без тотынабыз бу эшкә! — диделәр алар беравыздан.

Шулай итеп, беренче егет чыгып китте Ялмавызга каршы — кире кайтмады. Икенчесе дә хәбәр-хәтерсез югалды. Чират Җантыкка житте. Җантык бик йөрәкле нәселдән түгел иде. Шулай да нишләмәк кирәк, үзе курка, үзе йолка дигәндәй, Җантык та батырлар эзеннән Ялмавызны эзләп китте. Шуннан соң инде менә ничә атналар узгандыр, эзсез югалды Җантык. Бөтен авылны шулай йотып бетергәнче дип, сөйгән авылым Ширдыклыны ташлап, казык кагардай урын эзләп бармыш көнем!

Агай хикәясен сөйләп бетерде. Якты чырай, тәмле кымыз өчен Алып Бәргән рәхмәтләр укып, урыныннан торды. Агай аңа тәфсилләп юл өйрәтеп җибәрде...

Җантык дигән егеткә ни булды соң?

...Бара торгач, юл тарая башлады, тарайган саен, сукмакта кеше сөякләре күбәя-арта бара. Җантыкның болай да куян йөрәге лепе-лепе тибәр-

гә тотынды. Кинәт Җантык язулы тактага тап булды. Тактага менә ниләр язылган:

> Шушы төштә тукта! Бу Ялмавыз биләмәсе!
> Бичара бәндә, шушы тактаны үтсәң, сине
> үлем көтә. Тактаның чит ягында көтеп торсаң,
> мин үзем синең янга чыгармын.
> Имзам: Ялмавыз.

— Ярар!— диде Җантык батыр.— Көтәрбез, ни булыр икән?

Җантык атын куаклар арасына яшерде, үзе бер агач төбенә кереп посты да көтә башлады.

Көн көтте егет, төн көтте, атна көтте. Чыгучы да, керүче дә булмады. Юлга дип алган тәгамын да кырып- себереп ашап бетерде Җантык. Тагын атна узды. Батыр ачыга башлады. Җантык бичара:

— Булмады бу, кире кайтырга кирәк,— дип кузгалган иде, тора алмады. Ачлыктан, озак оеп утырудан ул коралларын түгел, үзен дә күтәрә алмас хәлгә җиткән иде. Шул чак сукмак буйлап сөякләрне шалтыратып килүче атлы кеше күренде. Атлы кеше тактага килеп терәлде.

— Алай икән! — диде юлчы егет, язуны укып чыкканнан соң. — Иблисләрне җиңгән бар, юхаларны бер күрүдә таныйм. Җен-пәриләр үзләре миннән качып йөри. Әмма ләкин Ялмавыз атлы зат белән алышкан юк. Карап карыйк!

— Һәй, Ялмавыз! Үләксә козгыны! — дип кычкырды батыр егет.— Бу мин — Алып Бәргән буламын! Чык мәйданга, алыштанмы, салыштанмы?

Егет үкчәләре белән атына җиңелчә генә кагылган иде, ат пошкырып алга ыргылды да күкрәге белән язулы тактаны бәреп, Ялмавыз патшалыгына кереп китте. Ләкин ерак китә алмады, каты җил чыкты, давыл купты. Кайнар сулыштан шиңгән гөл яфракларыдай, атның тез буыннары шәлперәйде. Алар тактаның бу ягына чыгып, кипкән сөякләр өстенә аудылар. Шулчак бөтен дөньяны селкетеп, коточкыч тавыш яңгырады:

— Дивана Алып Бәргән! Ялмавызның ни икәнен белдеңме инде? Ярый әле тук чагыма эләктең. Юкса мин җиде чакрым әйләнәдәге бөтен җан иясен берьюлы кабып йота алам. Бар, кайтып сөйлә, башкаларга сабак булсын!

Алып Бәргән белән Корангыш байтак вакыт һушсыз ятты. Бер тәүлек булды дигәндә генә, Алып Бәргән аңына килде. Иртә томалаган мунчада каты ис тигәндәге кебек, аның башы авырта, мие сулкылдый, күзләре сызлый, йөрәге чәнчеп-чәнчеп тибә, күңеле болгана иде. Колаклары һични ишетми. Ул көч-хәл белән генә үрелеп, тулымшасыннан су эчте, битен-башын юды. Аннары Корангышка су йоттырды. Шуннан соң гына ул нәрсә булганын абайлады: агулы кайнар җил аны аяктан еккан икән. Бу агулы җирдән китәргә дип, аягына баскан иде, куаклар арасындагы хәлсез бер кешене күреп алды.

— Һәй, бу үләт базында нишләп утырасың син? — дип сорады ул хәлсез кешедән.

Кешенең җавап бирерлек тә хәле юк иде. Алып Бәргән аңа су йоттырды, атына атландырды. Алар әкрен генә сукмак буйлап, кайтыр якка киттеләр. Урманнан якты дөньяга чыккач, сәйранда хәл алгач, Алып Бәргән әлеге егетнең тамагын туйдырды. Аннан сүз башлады:

— Син кем, ни йомыш белән Ялмавыз патшалыгында пәйда булдың? — дип сорады Алып Бәргән.

Егет башыннан кичкәннәрне бәян итте.

— Тактаны узган кешене агулап, узмаганны көттереп, ачтан үтерә икән бу мәлгунь Ялмавыз!— дип сүзен бетерде Җантык.

— Ялмавызның үзен күреп, аның белән сугышкан кеше бармы? Булса, ул кайда? Син миңа юл өйрәт! — диде Алып Бәргән.

— Бар, тик ул чукрак, сукыр, телсез, яза белми,— дип хәлсез Җантык Бәккол картның кайдалыгын өйрәтте.

— Син, Җантык дус! — диде Алып Бәргән атына атлангач,— Шушында ятып тор, менә сиңа азык, су. Мин әйләнеп килермен!

Алып Бәргән җан-фәрманга атын куалап, Шырдыклы авылына таба китеп барды. Чукрак, телсез Бәккол карт иң кырыйдагы ялгыз йортта яшәп ята икән. Авылның мескен бер ятим карты ачлы-туклы, ярым-ялангач килеш соңгы сәгатьләрен кичерә ахрысы. Кояшка битен куеп, ике кулы белән таякка таянып, баскыч төбендә утыра. Кемнеңдер дөп-дөп басып килгәнен сизеп, Бәккол карт, сагаеп, билен турайтты. Алып Бәргән, дус килгәнлеген белгертеп, кулын картның җилкәсенә салды. Бичара карт сискәнеп куйды да, дус кулы икәнен тойгач, бармаклары белән батырның кулын капшап карады. Аннан соң кармалана-кармалана беләк буйлап китте. Алып Бәргәннең битен, тимер күбәсен, башлыгын кулы белән сыпырып карады. Шуннан соң ул кинәт алгысап, куллырын бутый-бутый:

— Һәпә, әп-һәпә! — дип, нидер аңлатырга теләде.

Алып Бәргән аның кипкән кулларын учына алды. Карт елмайды, аның сукыр күзләре яшь белән тулды. Алып Бәргән яшь бөртекләрен кулъяулыгы белән йомшак кына итеп сөртеп алды. Бөкшәеп беткән бабайның ике кулы Алып Бәргәннең торыклы җилкәсен сөя башлады. Алып Бәргән, картның таягын алып, уң кулына тоттырды. Шул таяк белән аяк астындагы такыр җиргә нидер сыза-ясый башлады. Бабай игътибар белән батырның кул хәрәкәтләрен аңларга тырышты. Такыр җирдә зур гына Аждаһа сурәте барлыкка килде. Бабай, иелеп, Аждаһаны бармаклары белән капшап карады да тынып калды. Алып Бәргән картның ике күзенә дә бармак бите белән кагылып алды, аннан колакларына төртеп чыкты, картның авызын ачтырып, теленә ишарә ясады. Янәсе: бабай, сине Аждаһа шулай итте ме? — дигән сүз иде бу.

— Һәпә, әпә-һәпә! — дип, карт башын чайкый башлды. «Юк, юк, Аждаһа түгел!» — ди иде карт.

Шуннан соң Алып Бәргән мөгезле, койрыклы диюне ясап күрсәтте. Карт инде ни сораганны аңлады булса кирәк, иелеп, дию сурәтен куллары белән тигезләде. Такыр өслектәге туфракка янә нидер ясый башлады. Алып Бәргән, дулкынланып, рәсем ясалып беткәнне көтә. Менә берзаманны җирдә коточкыч бер зат сурәте пәйда булды. Сырты пычак кебек сырлы, койрыгы да нәкъ шундый. Дүрт аягында да коточкыч очлы тырнаклар. Киереп ачылган авызыннан нидер сиптереп тора. Ярым кеше, ярым елан, ярым диюгә охшаш бер нәрсә иде бу. Шунысы ачыкланды: Ялмавыз авызыннан агулы сулыш чәчә икән. Бабайга ярты күмәч биреп, Алып Бәргән атына атланды. Юлда барганда ул кәпәче белән киңәшеп алмак булды.

— Ялмавыздан сакланыр өченме? — дип сорауны кабатлады кәпәч.— Менә ни эшләргә кирәклеген аңлатты карт Бәккол. Ялмавыз агулы тын өргән чакта син тын алырга тиеш түгелсең. Тын алсаң, беттең. Башыңа шундук ис тиячәк. Тыны беткәч, Ялмавыз тирән итеп сулыш алырга мәҗбүр була, шул чакта син дә киереп тын аласың. Ун тапкыр өргәннән соң Ялмавызның агулы тыны бетә икән!

Батыр әйләнеп килгәндә, Җантык бичара ашаганнан соң йокыга киткән иде. Алып Бәргән аны уятмыйча гына Ялмавыз патшалыгына таба чаптырып китте. Шулай чабып барган уңайдан ул тактаны узды. Ат тояклары, ачтан үлгән батырларның сөякләрен шалтыратып, Ялмавызны уятты. Ялмавыз, нәкъ Биккол карт аңлатканча, сырлы калкан-сөяккә төренгән иләмсез бер зат булып чыкты. Күз алдында атка атланган Алып Бәргәнне күргәч, Ялмавыз тын ала башлады. Шуннан файдаланып, Алып Бәргән аты белән аның авызы янына ук чабып килде дә кылыч белән берне чапты. Ләкин кылыч, зыңгылдап сөяк-калканга тиде дә, Алып Бәргәннең кулыннан чыгып очты. Ул арада Ялмавыз тын алып өлгергән иде инде. Бер заманны иләмсез зур авыздан сасы, агулы ис ургый башлады. Алып Бәргән белән Корангыш тыннарын кыстылар. Алып батыр бала чактан ук

су астында озак торучылардан иде, ә Корангыш, кыска торыклы булса да, иң озын тынлы чабышкылардан санала. Ялмавыз тынын чыгарып бетерде дә тагын киерелеп сулыш ала башлады. Шул чакны Алып Бәргән гөрзисе белән Ялмавызның башына орды. Тимергә тимер бәрелгәндәй очкыннар чәчрәде. Гөрзи таеп китте, авыр гөрзи артыннан батыр үзе дә җиргә егылып төште. Алып Бәргән Ялмавызга каршы бергә-бер басып калды. Ул кәкре пычагын билбавыннан суырып чыгарды да, тынын каплап, Ялмавызның сулышы туктаганны көтә башлады. Шулчак Ялмавыз дүрт аякланды. Алып батыр аның уң як култыгында бер кызгылт тап күрде. Мөгаен җанварның калкансыз, йомшак урыныдыр бу, дип уйлады батыр. Ялмавыз, сөяк тākталар белән капланган тау шикелле, салмак кына батырга таба атлады. Бу очракта башка батырлар качып котылырга тырышканнардыр. Ләкин Алып Бәргән күп итеп тын алды да, агулы җилгә каршы китте. Елгырлык белән ул Ялмавызның кытыршы култыгына барып керде дә әлеге кызыл тапка кәкре пычагын батырды! Ялмавыз үкерә-үкерә чәбәләнә башлады. Әҗәле килгән бу шөкәтсез зат астында сытылып калмас өчен, Алып Бәргән мәтәлчекли-мәтәлчекли тәгәрәп, урман авызына чаклы барды. Аны Корангыш көтеп тора иде. Ялмавыз якын-тирәдәге агачларны кырып-сындырып бетерде. Тырнаклары белән җирне кызыл балчыгына чаклы актарып туздырды да, хәле беткәннән-бетә барып, бераздан тәмам тынды. Алып Бәргән, Ялмавызның койрык очындагы калкан-сөяген кисеп алып, биштәренә салды.

Ялмавызны җиңеп, сәйранга чыкканда Җантык атлы егетнең җаны уч төбендә иде. Шундый коточкыч сугыштан соң Алып Бәргәнне тере килеш күргәч, сөенеченнән нишләргә белми, Җантык көлә-шатлана башлады. Шуннан соң Алып Бәргән аны Ялмавызның үле гәүдәсе янына алып барды.

— Мең рәхмәт, Алып Бәргән батыр! — диде Җантык.— Мең рәхмәт!

Ул кинәт тынып калды. Моңсуланды. Аннан соң аның йөзенә кара кайгы сирпелде.

— Ни булды, Җантык дус? — диде Алып Бәргән.— Шатлан, Ялмавыздан котылдыгыз!

Җантык Алып Бәргәнгә барын да сөйләп бирде.

— Авылыбызның түрәсе Колавыз кызы Хөрмиядән колак кактым. Бөтен авыл миннән көләр инде хәзер. Ялмавызны мин түгел, син үтердең. Хөрмия дә сиңа булачак! — дип, Җантык үкереп елый башлады.

— Харап икән! — диде Алып Бәргән көлә-көлә.— Хөрмияң үзеңә булсын! Үз илемдә минем сөйгән кызым бар — Нәүмизә!

— Юк! — диде Җантык.— Син алмасаң да, Хөрмия миңа чыкмаячак. Чөнки мин үтермәдем Ялмавызны. Зинһар, Алып Бәргән, бир миңа Ялмавызның гәүдәсен. Зинһар, кешеләргә, Ялмавызны Җантык батыр үтерде дип сөйлә, ә?

Алып Бәргәннең йөзеннән елмаю качты. Ул бераз уйланып торганнан соң, болай диде:

— Ярар, Җантык, синеңчә булсын. Мин сезнең авылга бөтенләй керép тормам. Ал Ялмавызны үзеңә, Хөрмияң дә үзеңә булсын! Хуш! Бәхетле яшәгез, Шырдыклылар!

Алып Бәргән, Корангышына атланып, юыртып китте.

— Бу яхшылыгыңны мәңге онытмам! — дип кычкырып калды Җантык.

*Ахыры бар.*

# Рөстәм Мингалим

## Тагын бер яз...

Тагын бер яз керде тормышыма,
гомергә аны нурлы яз димәм:
ул аерса мине юлдашлардан,
фикердәшләр-яшьтәшләремнән.

Тагын бер яз керде тормышыма,
битләремә җылы кагылды.
Күкрәк баеп калды кырлар сыман,
таңнар булып хисләр кабынды...

Тагын бер яз керде тормышыма,
тау-тау булып тулды моңнарым.
Ун бармагым ун гөрләвек булып
җырлаганны Кояш тыңлады.

Тагын бер яз керде тормышыма,
күзләремә күкләр кушылды.
Кочагымда Идел кыймылдады,—
нәни бәхтем син, дип пышылдыйм.

Тагын бер яз керде торышыма,
гомергә аны нурлы яз димәм:
ул аерса өлкән дусларымнан,
я аерса нәни бәхетемнән.

## Яратуга хәтле...

Бик яратып бардым,
бардым бераз соңлап.
Бик сагынып бардым,
Бардым бераз соңлап...
Соңламагыз диеп,
киңәш бирә алам.
Тормыш менә шулай,
һәм шул килеш кала.

Барсагыз да йөгереп,
минем кебек итеп,
барыгыз да очып,
мине күпкә үтеп:
яратуга хәтле
ара шундый ерак...
Яратырсыз соңрак,
сагынырсыз соңрак.

---

РӨСТӘМ МИНГАЛИМ (1937) — шагыйрь, «Эзләр», «Күз карасы», «Шигырьләр һәм поэмалар» һ. б. шигырь китаплары авторы. Берничә китабы Мәскәүдә рус телендә басылды. Балалар әдәбияты һәм драматургия өлкәсендә дә актив эшли. Казанда яши.

## Йөрәккә якыннарым

Сок суы җылы иде,
җыелып ала идек.
Каз төркеме шикелле
коенып ала идек.
Каз төркеме шикелле
таралып беттекме әле?
Кайларда калдык әле?
Кайларга җиттек әле? —
Йөрәккә якыннарым,
кочакка еракларым!
Саклый алды кайсыбыз
ак килеш канатларын?
...Кайсыбыз ялгыз оча,
ялгыз моңын ишетәм.
Үрләр астындамы ул,
Кояш артында микән?
...Ялгыз моңын ишетәм.

## Күтәрелде чүрәкәй

Күтәрелде чүрәкәй,
чүгеп алды су яры...
Кемдер чалгы чүкеде,
кемдер чалгы кайрады.
...Ут биеде учакта,
утта казан сайрады.
без өмәдә кайнадык —
ел үсәсен көн үстек.
Кашык хәтле малайлар
чүмеч-чүмеч су эчтек.
Ничә чүмеч тир койдык,
саны истә калмады.
Калды истә чәчәкләр
мәңгелеккә алланып.
Ак яулыклы апалар,
гел хәтердә күзләре!
Битен юган абыйлар,
яшел ярга тезләнеп...
Уйлап бүген аларны,
ялгыз торам бу ярда.
Әллә нинди моңым бар,
шуны кая куярга?!
Кем дә килми яныма,
кемдер чалгы кайрамый.
Ут биеми учакта,
утта казан сайрамый...
Күтәрелде чүрәкәй,
чүгеп алды су яры.

## Ак казлары белән

Мондый яшел таулар бездә генә,
ялгыз каен яшел басуда...
Уйладым да шулай киткән язда,
оныттым да кебек барсын да.
Күнегелде күмәк бакчаларга,
уртак йортлар моңын аңладым.
Кибетләргә йөреп балык сөздем,
базарларда куян ауладым.
Ялга сирәк бардым урманнарга,
авылга дип ярсып тормадым.
Күңелемә җыйдым шәһәрләрнең
тәрәзләрдән сипкән җырларын.
Бик яратып бастым таш юлларга,
җирдә туфрак барын онытып...
Бүген килеп уйга авыл керә,
ак казлары белән һәр йорты.
Яшел басу күрәм, ялгыз каен,
таулар нинди яшел, кара син?!
Кара, ничек гомер якынайта
кеше белән үлән арасын,
кеше белән туфрак арасын.

## Ничек йөрмәсен хәтердә

Ничек йөрмәсен хәтердә
хәтергә терәк таулар,
безне тирбәткән каеннар —
ничек онтылсын алар?

Кичке тынлыкта урамнар,
авылда киндер исе...
Ничек йөрмәсен хәтердә
хәтергә дәва хисе?

Бала чактан ук сагынып,
безгә булмаган тиңнәр...
Ничек йөрмәсен хәтердә
йокы күрмәгән төннәр?

Ничек йөрмәсен хәтердә,
онтылсын ничек алар —
шатланып,
этәч шикелле
кычкырып аткан таңнар?!

## Соңгы ямаулык

Без күңелне ямадык,
ямадык та яңардык.
Дөнья тулы ямаулык,—
әгәр калсаң ямарлык:
елмаюлар — ямаулык,
матур күзләр — ямаулык,
матур сүзләр — ямаулык,—
әгәр калсаң ямарлык.

Әллә ничә ямалдык,
әллә ничә яңардык.
Кояш — соңгы ямаулык,—
әгәр калсак ямарлык...
Без күңелне ямадык.

## Җыр канаты

Кала гөлләр изэп
безгә туган кырлар,—
болар — безнең җанны
аңлый торган кырлар.
Безне белгән таулар —
бәрхет тауларыбыз.
Йомшак тауларыбыз,
бәхет тауларыбыз!

Алка-алка юллар,
юлда дуслар табыла.
Кызыл офыкларга
безнең җырлар кагыла.
...Ерак офыкларга,
кайнар офыкларга,
янган офыкларга
җыр канаты кагыла.

## Көз килгән лә...

Көз килгән лә, көз инде бу,
сәлам бездән көзге җилгә!
Сип әле, җил, сәламемне
яфрак төсле сары җиргә.
Гомер көзен сизмәгәннәр
Мәңгелекне уйлаганда...
Мин килештем картлык белән,
аны җиңеп булмаганга.
Бетте сыман язларыма —
яшьлегемә үпкәләр дә...
Сип әле, җил, сәламемне
гомер көзе җиткәннәргә.
Җиткән лә ул, көз инде бу,
көз булса да без әле — без...
Безнең көздәй — сагынырлык
матур булсын көзләрегез.

## Онытып ял итәргә дә...

Онытып ял итәргә дә
киттем байтак ара...
Киткән арам — ни манзара,
көзләренә кара!
Дөнья көзге каенлыктай
үтәли күренә...
Юлларым — еллар төбендә
һәм күкләр түрендә.

Җылынган учагым булып,
ерак кала Кояш...
Хәерле юл! Әй, еракта
арттан килгән юлдаш!
Югалтышсак, билге кара,
килә күр син таныш:
мин юлымны калдырырмын
йолдыз беләнябып.

## Туган-үскән якларда

Туган-үскән якларда,
иркәләнеп җилләргә,
уздым бер бала сыман,
каенлык арасыннан.
Күзләрең карар сыман
каенлык арасыннан.
Туган-үскән якларда,
изү ачып җилләргә,
уздым сулар буеннан,
суда камыш куерган.
Күзләрең карар сыман
камышлык арасыннан.

Туган-үскән якларда,
Күптән узган чаклардай,
уздым бер бала сыман
арышлык арасыннан.
Күзләрең карар сыман
арышлык арасыннан.
Карамады күзләрең,
тик һаман да без әле
икәү барабыз сыман,
каенлык арасыннан...
Арышлык арасыннан.
Камышлык арасыннан.

**Марсель Галиев**

# САТУРН ҺӘМ УМАЧ

*хикәя*



Жирдә һәр жан иясенең, һәр үсемлекнең икенчел варианты бар. Пародиясе дип әйтергә мөмкин. Кеше белән маймылны гына чагыштырып кара. Юлбарыс — песи. Крокодил — кәлтә. Пальма — абага һәм башкалар. Шундый чагыштыру белән китсәң, безнең Жир-планета да бәлки бөек бер тереклекнең кечерәйтелгән шәүләседер, ә?! Кеше хәрәкәтләрен кабатлаган маймыл кебек без дә бәлки...— академик Шикоян кавказлыларга хас кайнарлык белән сөйләгән жиреннән кинәт тынып калды, янып торган кара күзләреннән хәйләкәр елмаю саркытып, Акчуринга төбәлде, аңгамәдәшенең каш жыерыбрак, үз эченә йомылып утыруын өнәмичә, бармагын уйнатып алды:

— Сизәм, килешмисең. Кеше — уникум, бердәнбер, шулай бит?! Ах, нинди эгоистлар без, ә?! Кайдадыр үзебездән акыллырак, көчлерәк жан иясе булу мөмкинлеген шулкадәр кабул итәсебез килми! Бердәнбер була аламы? Табигатьнең параллельлеген онытабыз. Сабыйлык!

Ул арада жир чикләвеген балга катырып әзерләнгән ризык — казинаки белән авыр чынаякларда кофе китерделәр. Ничектер арыбрак киткән Акчуринның акылы ялкауланып калган кебек иде — дәшмәде.

Бүген — «Галәмнәрнең яралышы» дигән темага үткәрелгән халыкара симпозиумның соңгы көне. Тәнәфесләрдә дә сүз гадәти тормыш хәлләренә кагылып тормый, ераклыгы йөз меңнәрчә яктылык елы белән исәпләнгән жисемнәрне теннис шары шикелле генә күреп, ялыкмас галимнәр бәхәс-сөйләшүләрен туктаусыз дәвам итә. Фәндә романтик саналган Шикоянны үзара яратып шагыйрь дип йөртәләр иде. Ул һич көтелмәгән сәер гипотезалар уйлап чыгара, инде бәхәссезгә әйләнгән карашларны да актарып ташлый һәм үзенә каршы килгән салкын акыллы Акчурин белән гәпләшүне хуп күрә иде.

— Мин әлек йолдызлар белән эш иткән астрономнар озын гомерле булырга тиеш дип уйлый идем. Хәзер киресенчә: тиз янып бетәрбез ахры без,— диде Акчурин. Аның шундый сүлпәнлек белән аңгәмәне сүндереп куюына ризасызланыпмы, Шикоян мыек очын чәйни башлаган иде, ярый әле, телефонга чакырып алдылар үзен. Китешли, ул, гафу үтенгәндәй, Акчуринның жилкәсенә кулын куйды:

— Бу сөйләшүне иртәгә дәвам итәрбез, табигать кочагында, йолдызлы күк астында,— дип китеп барды.

Акчурин кайнар кофега иренен генә тигезгән иде, кинәт... башы әйләнеп киткәндәй булды, фарфор чынаякны чеметеп тоткан бармаклары калтыранып куйды. Хуш исле гарәп кофесыннан сирпелеп киткән таныш бер тәм отыры көчәя барып, бөтен тән күзәнәкләрен сулкылдатып күтәрелә башлады. Сәер, кофенең үзеннән килми иде бу тәм, кайдандыр хәтер аша саркып кына өскә калыкты бугай. Гажәп, һич уйламаганда... менә хәзер, кичекмәстән кабып карау теләген котыртып килгән тәме дә нинди диген әле: ачы катык катылган умач ашы... Бик еракта калган иде бит инде югыйсә, бөтенләй онытылган иде. Затлы

---

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ (1946) — прозаик, шагыйрь, драматург. «Еллар чалымы», «Ул чакта», «Ерак урман авазы» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.

ризыкларның тәмен онытырып, менә хәзер исенә төште дә олы бер теләккә әйләнде. Тыярга, тыярга кирәк иде бу ымсынуны. Әмма хәтер үзенекен итә, синең дәрәҗәң белән дә исәпләшеп тормый, асылына кайтара да куя... Өстәл башында ашыга-кабалана, агач кашык белән умач шулпасы чөмергән малай, учында — сугыштан соңгы елларның кадерле ипи сыныгы, коелган валчыкларын җыеп капкандагы тәмлелек! — аны болай гына аңлатып буламыни! Әнисе, алъяпкыч астында кулларын кушырып, улының шулай кабаланып ашавына сокланып карап тора, башын кыңгыр салган, йөзендә моңсу бер елмаю. Аш инде бетә дигәндә, ул коштабактан һава куыклары чыгарып, чупырдап утырган катыкны кашыклап өсти. Ничек атый иде соң әле ул күпереп ачыган катыкны? Онытылган, онытылган икән шул инде.

Хәтерендә чагылып киткән шушы күренешнең чынлыгына үзе дә ышана алмыйча, Акчурин, кинәт уянып киткәндәй, як-ягына каранып алды. Бите кызышып чыкты. Бөтенесе аңа төбәлгәндер, кызыксынып аны күзәтәләрдер, эчке уйларын беләләрдер кебек иде. Янәшә өстәл артындагыларның үз гаме гамь икәненә инангач та, ул сабыйлык шигеннән арына алмады. Кофесын да эчеп бетермичә, урыныннан кузгалды. Эчке бер уңайсызлану, тартынудан бәреләсугыла, өстәлләр арасыннан үтте — кайдадыр тынычрак урын табарга иде, күңеленә мөлдерәмә тулган рәхәт хисне чайпалдырмыйча алып барырга иде — әмма нишлисең, каршыга танышлар очрап тора, арада Европаның атаклы шәһәрләреннән килгән, инде дистә еллар буе аралашкан галимнәр дә бар. Баш кагарга, нидер әйтергә, елмаерга, ачык йөз күрсәтергә кирәк, шушы халәтләргә керү аны отыры тынычсызлый, оялчанлык дәрәҗәсендәге уңайсызлануга этәрә иде. Кулларын нәзакәтле селкеп сөйләшкәндә, Акчуринның гадәттән тыш озын бармаклары, әйткән фикеренә куәт өстәгән кебек, үзеннән-үзе игътибарны җәлеп итә иде. Ә хәзер аның куллары, тагылган протез кебек, бөтенләй тыңлаусыз, артык сыман тоелды. Мәрмәр колонналар, алтын кысалы зур-зур көзгеләр, үз шәүләңне чагылдыра торган ялтыравыклы паркет идәннәр аның эчке уйларын шәрәләндереп калдырган сыман иде. Һәр борылышына грек статуэткалары куелган, калын келәм җәелгән киң баскычларны, гомумән, бу борынгы бинаны ярата иде ул. Ә бүген кинәт кенә барысы да чит-ят булып тоелды. Күпшылык өшетә иде аны.

Ярым караңгы холлда ул күн тышлы диванга чумып утырды. Барокко ысулында эшләнгән тәрәзәләрдән чиркәүнең алтын гөмбәзе күренә. Еракта шәфәкъ нурына манчылган йорт тәрәзәләре учак уты сыман кайнарланып яна иде.

Салкын кышларда әтисенең учак каршына утырып тәмәке тартуын, төтен аралаш буылып-буылып ютәлләвен ап-ачык итеп күз алдына китерде ул. Шундый зәһәр кышларның берсендә дөнья куйган әтисенең йөз чалымы еллар томаны артында калган инде.

Туган авылына профессорның егерме еллар инде кайтканы юк иде. Энесе Шамил хатыны белән ике-өч елга бер санаторийга барышлый сугылып китә, сирәк кенә хат та алышалар, ә кайту — юк, юллар гел бүтән тарафка алып китә иде аны. Фәнни эш, олы мәшәкатьләр авылны бик еракка чигереп, күзаллый да алмас нокта итеп кенә калдырган иде. Авылын гынамы... Күпме гомерен чиксез күк капкаларын ачып, телескоптан гаҗәп йолдызлар мириадасын күзәтә торгач, Җиргә дә мөнәсәбәте үзгәрде аның. Хыял һәм омтылыш галәмнең адәм акылы җитмәс тирәнлекләренә барып ирешә дә, кояштан мең мәртәбә зуррак кояшлар барына инангач, көннән-көн яңа галактикалар ачылуына үзе шаһит булгач, аңарда гүя ниндидер чиксезлек авыруы башлана. Юклык дәрәҗәсендәге нокта гына булып тоелган Җир шарына кире әйләнеп кайткач инде гореф-гадәтләр, тормыштагы вак борчулар аңа мәзәк булып тоела иде. Обсерваториядән чыккач, тәненнән җаны аерылган бер халәттә күнегә алмыйча йөри, төрле төсләрдә балкыган җиһанның төгәл симфониясе белән чагыштырганда Җирдәге кеше кулы тудырган әйберләр сабыйлык тырышлыгы булып кына күренә иде аңа.

Ә бүген ул кинәт кенә җирдә тамырлары барлыгын тойды. Туган авылына кайтып, кату катылган умач ашы эчәсе килү... Әгәр дә бөтен эш-максатларының мәгънәсен җуйдырган шушы теләкне үтәмәсә... Кайнар дулкын тәэсиренә бирелеп, кинәт кенә калтырап куйды... Шуны үтәмәсә, үлеп китәр кебек иде.

Миңа әле әни яшенә җитәргә дә егерме ел бар бит, дип уйлады ул. Шәһәргә күнегеп беткән иде инде әнисе. Җитмештә булса да, җитез йөри иде әле. Авыру көтмәгәндә килде. Әнисенең: «Үзебезнең Дугалы чишмә суын эчсәм, терелер идем»,— диюенә башта колак салмаган иде Акчурин. Соңыннан, әнисе бик ялварып сорый башлагач, энекәшенә телеграмма сукты. Чишмә суы килеп җиткәндә, әнисе дөнья куйган иде инде.

Әнисенең хәлен менә хәзер генә ачынып төшенде профессор. Бер карашка гадәти генә тоелган әлеге теләк — язмыш тавышы булмадымы икән?.. Шул вакытта чишмә суын китереп җиткерсә, бәлки ул һаман да яшәгән булыр иде әле. Теләк — язмышның кисәтүе түгел микән?..

Бүген үк самолетка билет алырга кирәк. Иртәгә китмәсәм... тагын хыял булып кына калачак. Иртәгә... Капылт исенә төште: Шикоянга ничек аңлатырга соң әле? Иртәгә алар Суздальга барырга тиешләр иде бит. Кайчангы хыял инде менә чынга ашарга гына торганда... Шикоян ни әйтер? Үпкәләмәсме? Ул бит борынгы монастырь ишегалдында кунаклар өчен төзелгән агач йортларның берсен атна-ун көнгә алуга ирешкән иде. Машинасын таныш механигына каратып, менә инде бер атна буе гаражыннан чыгармый, әзер тота иде.

«Юк, аңа әйтмичә китәргә ярамый,— дип уйлады Акчурин.— Аңламый калмас, озакка түгел бит, күп булса ике-өч көн торырмын, аннары кайтып җитәрмен, ул әйткәнчә «йолдызлы күк астында» бәхәсне дәвам итәргә вакыт кала бит әле».

Профессор Акчурин соңгы елларда җирдән ике миллиард чакрым ераклыктагы Сатурнны өйрәнә, бу гаҗәп планетаның балдаклары, элеккеге фаразларга, өчәү генә түгел, ә йөзләгән икәнлеге ачылгач, һәм аларның хәрәкәте тотрыклы физик кануннарга туры килмәве беленгәч, дөнья галимнәре арасында шау-шу купкан иде. Академик Шикоян шаяртып:

— Сатурнда Җирнең хәтере тупланган. Балдак эченә кереп, вакыт буенча төрле якка хәрәкәт итә аласың. Мең елларга артка чигенсәң, ерак бабаңнарның тарихи ялгышларын күрергә мөмкин,— диган иде.

Сатурнның үзенчәлеге турында киләсе фәнни конференциядә чыгыш әзерләү өчен Акчуринга ике ай вакыт бирелгән иде. «Баш үзем белән бит, юлда да эшли алам, шул арада ике-өч көнгә авылга кайтып килү берни тормый югыйсә»,— дип уйлады ул.

Учакны хәтерләтеп янган тәрәзәләрнең сүнүеннәнме, эңгер иңә башлауданмы — кинәт кенә Акчурин сүрелеп калды. Икеләнүме бу?

Ничә тапкырлар шулай калкынып та, туган якка кайта алмавын аклый торган сәбәп табып, үз-үзен кичерә-тынычландыра иде ул. Әмма баягы теләк кан тамырларында сиздереп сулкылдый иде. Ерак йолдызның нуры кешегә тәэсир иткән кебек, туган җир әллә гап-гади бер теләк аша кызыктырып, үзенә тарта, чакыра микән?..

Акчурин өй ишеген үз ачкычы белән ачмый, һәрвакыт музыкаль кыңгырауны чылтырата иде. Ишеккә якынайган йомшак чүәкләрнең таныш кыштырдавы, нәни генә көттерү газабы белән йозакның үзенә бертөрле шыгырдап борылуы, аннары хатынының, гадәтенчә, өй җылысы белән сарылып, яңагыннан үбеп алуы, колак артыннан сирпелеп киткән француз хушбуе исе — барысы, барысы да Акчурин өчен арыганлыкны юып ала торган, гаиләнең тату бөтенлеген искәрткән көндәлек бәхет иде, һәм шулай мәңге кабатланыр сыман иде.

Ике яктан да берьюлы «хәерле кич» әйтешүгә, Акчурин туфлиен салып, эт тиресе белән каймаланган чүәкләргә аягын батырды да: «Клара Леонардовна»,— дип, бер мәлгә тотлыгып калды. Үтенеч яисә яңа хәбәр әйтәсе булса, алар шулай ярым шаяртып, «Сез»ләп, рәсми мөгамәләгә күчәләр иде. Клара, шомырт кара күзләрен елтыратып, башын сагаюлы кош сыман кырынайтты да тыңларга әзерләнде. Ләкин иренең озак юануына түзеп тора алмады.

— Кичектергесез эшләр килеп чыкты, иртәгә Суздальга бара алмыйм. Шулаймы, Камил Каюмович?

Әгәр иртәгә авылга кайтам дисә, сәбәбен дә аңлатса, кычкырып көләр иде микән хатыны? Бәлки ачыктан-ачык көлмәс тә, әкрен-әкрен генә, һәр фикерен ягымлы-купшы сүзләргә төреп, кайтмаска күндерә башлар иде. Шундый итагатьлек белән, тавыш күтәрмичә генә буйсындыра белә иде ул.

Гомерендә беренче тапкыр Акчурин хатынына ялганларга булды. Соңыннан күпмедер вакыт үткәч, көлә-көлә дөресен сөйләп бирер әле.

— Киресенчә, Клара Леонардовна, иртәгә — юлга.

Иренең шундый мәгънәле тын торуыннан соң бер яңалык та әйтмәвенә гаҗәпләнүдән Кларaның кабарынкы күз кабаклары кысылып килде.

— Мин әйберләреңне әзерләп куйдым.

— Командировка килеп чыкты, Клара. Иртәгә очарга кирәк.

— Кая? Озаккамы?

— Киевка.

— Ә Шикоян?

— Суздальгә ул үзе генә бара тора. Мин ике-өч көннән кайтып җитәм. Туры — аның янына. Шулай килеп чыкты, борчылырга урын юк,— дип, хатынына туры карамыйча гына аңлаткан Акчурин тизрәк кызы бүлмәсенең ишеген ачты. Стеналарына болан, кыргый кәҗә мөгезләре, пыяла астына чуар күбәләкләр, төрле бөҗәк коллекцияләре тезелгән бүлмәсендә Ләлә әйләнмәле креслода, аягын татарча бөкләп, имтиханга әзерләнеп утыра иде. Унҗиде яшьлекләргә хас булганча, бөтен нәрсәне мин сездән күбрәк беләм дип санаган кызының акыллы, киң маңгаеннан үпте Акчурин, тупылдатып, аркасыннан сөеп алды. Менә бусын инде Ләлә әнәп бетерми, әтисендә һаман бетми калган авыл гадәте дип бәяли иде. Хәзер дә әнә, каш җыерып, әтисенә кинаяле күз сирпеп алды да дәшми генә китабына иелде. Никадәр җитди, олы сыман булырга тырышса да, Ләләнең күзләреннән әле сабыйлык нуры чыгып бетмәгән. Һәм, моңа дәлил булып, пианино өстендә утырган курчаклар Акчуринда кызына карата әчке бер елмаю уята иде.

Ләлә җәйләрне шәһәр тирәсендәге лагерьларда, табигать кочагында үткәрә, тик менә әтисенең туган авылына бер дә кайтканы юк иде. Әйдә, кызым, дип әйтергә иде хәзер, кузгатырга иде китаплар арасыннан — барысын алдан бөртекләп, уйлап кына эшләргә өйрәнгән кызы ничек кабул итәр иде икән әтисенең бу «романтик» кыланышын?

Ләлә әнисе юлыннан китмәкче, биология факультетына керергә җыена, әтисенә киная белән үзенең карашларын да белдергәли иде. Аныңча шулай: космоска кадәр әле кеше үзе басып торган Җир-йолдызны ныклап өйрәнергә тиеш. Әйләнә-тирәдәге бөҗәкләр, үсемлекләр дөньясыннан гыйбрәт алып, көч һәм акылын бары тик изге максатларга кулланыр дәрәҗәгә җиткәч кенә, чистарып, галәмгә чыгарга тиеш дип саный иде.

Акчурин тиз генә юынып чыкты да кабинетында аю тиресенә басып чишенә башлады. Хәзер хатынының, «Камил» дип, кухнядан ягымлы эндәшүе ишетелер. Калын йон халатын кигән Акчурин, йолдыз җиле кагылган галимнән көндәм өй хуҗасына әйләнеп, тәмле исләр килеп торган кухня ишеген ачар.

Бәлки авылга кайтып йөрмәскәдер дигән икеләнү таңга кадәр бер генә какмас әле аның тынычлыгын.

Бөтенләй хәтереннән чыгара язган, игътибарсызлыгын Ләлә кичермәс бит; кабинет ишегенә энә белән каптырылган язуны укып китәргә тиеш ич ул. Кызы афоризмнар, канатлы сүзләрне язып алырга ярата, үзе ошатканнарын әтисенең ишегенә беркетеп куя торган иде. Бүген әнә гарәпләрнең борынгы Әбу-Сөмбел сараена язылган хикмәтле сүзен табып куйган. «Әгәр кеше йолдызларны ни хәрәкәткә китергәнен белә алса, сфинкс шаркылдап көләчәк һәм яшәү бетәчәк...»

Авыл күренүгә, ул адымнарын кызулата төште. Каршында — кызыл маңгайлы тау тезмәләре, карт өянкеләр кулагәсенә ышыкланып, борылып, кире кайта-кайта ашыкмыйча аккан инеш, ак түбәле өйләр, җете чәчәкле гөлләре белән көн яктысына елмаеп караган авыл — менә бит ул: бөтенләй чит-ят җирләрдә, гомерең бетеп, соңгы сулышыңны алганда да һәр яфрак тибрәнешенә кадәр ап-ачык булып күз алдына киләсе, синең белән нәүмизле бәхилләшеп каласы манзара.

Моңа кадәр дистә еллар буе кайтмый йөрүе өчен шушы табигать каршында уңайсыз дулкынлану, үкенү кичергән Акчурин авылга профессор булып та, Каюмович булып та түгел, кулына дипломат тотса да, элеккеге Камил булып килеп керде. Авыл ул белгәндәгедән никадәр үзгәргән, төзекләнгән икән инде. Ә барыбер туган йорт урынын әллә кайдан танып алыр иде. Бабасы утырткан куш карама бары тик алар бакчасында гына иде бит. Әнә ул, карасу яшеллеге белән бүтән агачлардан аерылып тора. Янәшә, иңгә-иң ышыкланып үскән карама, көчле җил вакытларында кочаклашып, очып китәргә талпынган шикелле, кайнап-кайнап шаулый торган иде, хәзер инде бик озын гомер кичереп, арыган карт белән карчык шикелле, ябалдашлары моңсу аерылып, җиргә таба иелә төшкән.

Энесе Шамил шул ук нигездә яңа йорт җиткергәч, фотосын салган иде — чынбарлыкта бөтенләй башкача: мәһабәтрәк, тагы да күркәмрәк икән бит. Зәңгәр, ак буяулары белән балкып, канаттай ачылган капкачлы тәрәзәләр, челтәрләп эшләнгән веранда, бакчадан күбекләнеп ташып чыгасы яшеллекне каймалап, кызлар теше кебек, гаҗәеп тигез, ак койма сузылган.

Кече капка ачылуга, каралты-кура ягыннан чыгып килгән Гөлсинә (Камил өчен килен) гаҗәпләнүле карап торды да, кояшта янган йөзенә кызыллык иңдереп, кулыннан чиләген төшереп җибәрде:

— Бәрәч, Камил абый түгелме соң?! — дип ул таза беләкләрен уйнатып килде дә ике куллап, ирләрчә нык итеп күреште.

— Исәнме, Камил абый. Күземә күренәме дип торам. Кая Клара апа, Ләлә? Үзең генә кайттыңмы? Менә бит, ә! Шамил бүген генә Горькийга машина алырга киткән иде. Ак «Волга» дип хыялланды инде. Ярамаганмы югыйсә бүтән төрлесе. Алдан хәбәр иткән булсаң соң, Камил абый. Адресын да алып калмадым ичмасам, телеграмм сугар идек Шамилгә.

Камил ни әйтергә дә белмичә, каушабрак калган Гөлсинәне тынычландырырга теләп, иңеннән сөеп куйды. Ул арада баскычта күкрәгенә хатын-кыз башы төшерелгән майка һәм джинсы кигән ябык гәүдәле егет чыгып басты. Үзенең гадәттән тыш озынлыгыннан тарсынгандай, урталай сыныбрак килде дә нечкә беләкле зур кулларын күрешергә дип сузды.

— Улыбыз Илһам шушы инде,— диде Гөлсинә, үзе дә әле генә искәргәндәй, кай арада үсеп життең соң әле, дигән бер ярату белән улына карап.— Быел үнны бетерде. Авылда эшләргә исәбе, әтисе кебек шофер булып.

Борын астында тал мамыгы кебек кенә йомшак мыек төкләре шәйләнгән егетнең оялчан торышы, күп сөйлисең дигәндәй, әнисенә тыенкы шелтә белән карап алуы Камилгә үзенең үсмер чагын хәтерләтеп куйды.

— Тәмам егет булган,— дип ул аның җилкәсенә кулын салды.

Шул минуттан башлап, Камил тулысынча Гөлсинә ихтыярына буйсынырга мәҗбүр булды. Кул юып алганнан соң, гаилә хәлләрен сораша-сораша, табынга утырдылар. Өстәлдә — ярмаланып пешкән эре бәрәңге, кыяклы суган, каклаган каз ите, кар базыннан алып менүгә савыты борчак-борчак тирләп чыккан каймак шикелле нигъмәтләр эргәсендә латин хәрефләре төшерелгән ялтыр каплар, кыштырдавык кәгазьле әллә нинди Мәскәү кучтәнәчләре ятрак тоела иде. Гөлсинәнең тыгыз биленнән аска эре дулкын булып төшкән күлмәк итәген җилфердәтеп, өстәл белән кече як арасында булашуы, ачык тәрәзәдән сузылып керергә торган кура җиләк куаклары өстендә бал кортларының безелдәшүе, чәйле тәлинкәдән чагылган кояш нурының түшәмдә биешүе һәм сулышын тыйган гаҗәеп тынлык — барысы да Камилне рәхәт бер дулкында тирбәтә иде. Ул сөйләшә дә, сөйләшми дә, ашый да, ашамый да кебек. Бары тик үзалдына елмаясы, онытылып елмаясы гына килә. Тегендә, үз даирәсендә күнеккән киеренкелек, һәр сүзенә, гәүдә тотышына кадәр эчке бер кагыйдәгә буйсынганлыгы монда бөтенләй киреаксез булып калган. Табигый иркенлек. Вакыт, әйләндереп куелган ком сәгате кебек, кирегә ага да ага, гүя ул әкрен генә малай чагына кайтып бара. Менә хәзер өстәл янынннан сикереп торыр да яланаяк урамга чыгып чабар. Әнисенең кич җиткәч уеннан чакырып алуы да әле генә булган кебек. Барысы да төш кенә шул, кабат кайтарып алып булмый торган төш кенә. Ул чакларның шаһиты — бакчадагы карама гына шул ук, хәтерли микән үткәннәрне?..

— Абау! Кулың, Камил абый, бигрәкләр дә ап-ак,— дип, Гөлсинә Камилнеке янына үзенең кояшта янган кулын куеп карады һәм бу эчкерсез хәрәкәтеннән үзе үк уңайсызланып китте. Чынлап та, Камилнең озын бармаклары, базда үскән бәрәңге сабагыдай чирканыч ак иде чагыштырып караганда. Туры бәреп әйтү — авыл гадәте — бусы да сагындырган бит әле аны.

Чәйдән соң Гөлсинә үз эшләренә кереште. Кунакны ялгыз калдырмас өчен, Илһамга Камил абыйсы тирәсендә булырга кушты. Ләкин ике арада сүз ялганмады. Илһам тартына, Камил исә эре дулкындай килгән хатирәләр тәэсиреннән айный алмый иде. Пыялалы ишекне ачып, калын пәрдәләр тартылган салкынча бүлмәгә керде. Идәнгә җәелгән парчалы келәм, ялтыравыклы сервант, шкафлар — шәһәрчә җиһаз аның хәтеренә кагылып куйды. Идәннәрнең баскач сыгылып куюы, агач караватка өелгән мендәрләр, тәрәзә борысына эленгән кулдан суккан сөлгеләр, ишек башындагы шамаил — кая калды соң әле ул үскән өйнең ярлы пөхтәлеге?..

Тәрәзә төбендә утырган тамчы гөлен күргәч, рәхәт тетрәнеп китте. Ничә еллар инде очратканы юк иде бит аның күзгә туры карарга кыймыйча, чәчәк таҗларын аска игән бу оялчан гөлне. Тамчы гөл — аның үткәне бит; төпсез зәңгәр күк, язның беренче чирәмнәре, өстәлгә җылы сөт килгән кичке эңгер — кешенең сагышлы күз яшьләрен чәчәккә әйләндерә белгән моңлы гөлләр бу...

Хатыны Клара да өйдә гөлләр үстерергә ярата. Чәнечкеле гаҗәп зур телгә охшаганнарыннан башлап, чыпчык йомыркасыдай нәни кактуслар дисеңме, менә мин нинди! дип мактанып ачылган купшы чәчәкле, банан үскән яклардан килгән әллә нинди гибрид гөлләр... Бер карасаң, матур да кебек үзләре, әмма нигәдер битараф иде аларга Камил. Менә бит, үзе дә белмичә, сагынган икән ул дөнья яратылганнан бирле ишләре белән кушылмыйча, үз төсен, табигыйлеген саклап килгән бу тамчы гөлне. Элек күршедән-күршегә ут биреп, учакны сүндермичә

тоткан шикелле, туфрактан-туфракка күчереп, бу гөлнең нәселен авыл шулай бүгенгегә китереп җиткергәндер.

Кызы Ләлә ничек кабул итәр, ошатыр иде микән аны?..

Кабат чыккач кына искәрде Камил, ишегалдында элеккеге чирәм юк икән шул инде, койма кырыйлап калын-калын такталар өелгән, машина тәгәрмәчләре, тагын әллә ниләр.

Ул арада Гөлсинә кыраклап сөрән салган тавыкны култык астына кыстырып лапастан чыкты. Аяклары бәйләүле тавык кан тулышкан бурлат кикрикле башын боргалап, соңгы секунды җиткәнен сизгән шикелле, энҗе күзләрен куркынулы елтырата иде. Итен тәмләп ашаганда, аның кайчандыр тере җан иясе икәнлеген оныту хас булса да, Камил тавыкны кызганып куйды.

— Мәшәкатьләнмә, Гөлсинә, кирәкми, миңа бит...

— Нинди мәшәкать булсын ди. Сарык чалыр идек менә Шамил кайтып җитсә... Их, белгән булсам соң, җибәрер идеммени! Безнең Илһам пычак тота белми, күрше Салих бабайдан суйдырам.

— Картайгандыр инде Салих абзый?

— Таза әле. И, кулы тәмле дә инде. Ул суйган мал ите бөтенләй икенче шул. Сезнең бройлер дигән шәһәр тавыкларын әйтер ием инде, Камил абый... Эчендә кызыл балчык сыман ярты ите артып кала, житешмәгән... Авыл тавыгының сөяге дә тел өстендә эреп бетә аның,— дип Гөлсинә тигез тешләрен елтыратып көлде дә капкага таба борылды.

— Гөлсинә,— дип Камил аны дәшеп туктатты. Аның озынча ак йөзендәге уңайсызлануны Гөлсинә үзенчә юрады:

— Күңелсездер инде сиңа, Камил абый, йортта ир заты булмагач. Илһам сөйләшә белми ул безнең. Ятып ял итеп ал, карама төбендә урын җәйгәнле. Мунча әле ике сәгатьтән генә өлгерә.

— Тагын мәшәкать арттырганмын икән.

— Алай димәле, Камил абый.

— Ни бит, Гөлсинә... Әллә... умач ашы пешерәсеңме, ә?

— Умач? — Гөлсинәнең эчкерсез күзләре зур булып ачылды.— Көләсең инде әллә бездән, Камил абый? Ачлык ел азыгын каян искә төшердең болай?

— Юк, көлмим, Гөлсинә. Кату катып, умач ашы кабып карыйсы килә. Аңлыйсыңмы, ул бит хәтер, хәтер...

Гөлсинә аның кинәт сагышланып, инәлү белән караган күзләреннән, үзе кичермәсә дә, ишетеп белгән елларның авырлыгын да, кадерен дә аңлагандай баш селкеп куйды.

— Ярый алайса, умач уармын...

Аш өлгергәч, Камил аеруча бер дулкынлану белән өстәл янына утырды. Куе сөттән сары төскә кергәнче нык кайнатылып оетылган катык каймак кебек тәмле иде. Камил аны болай гына кабып карады — ашка катмады. Савыттан күтәрелгән буга карап утырды да, оялчан малай кебек, Гөлсинәгә карап эндәште.

— Уңайсыз да инде сине кузгату, арыгансыңдыр...— дип сүз башлауга, Гөлсинә чәчрәп урыныннан куба да башлады.

— Нинди сүз ди, Камил абый, без өйрәнгән инде, әйт кенә теләгеңне.

— Ачы катык табып булмыймы, бер-ике кашык кына?

— Зерәләр дә кызык кеше булып чыктың әле син, Камил абый. Менә бит, иң тәмлесе дип баздан гына алып мендем югыйсә,— дип ул бит очларын чокырайтып елмайды да, иркә кызлар кебек, иренен бөреп ялынырга кереште: — Оятлы итмә инде, Камил аб-бый. Ничек куйыйм инде өстәлгә... Күпчеп беткән катык бар анысы, тавыкларга җим болгатырга дип тотканы... Бер атна инде сөйләшеп утыра.

Камил кычкырып көлеп җибәрде. Менә бит, искә төшерде, ниһаять, «сөйләшеп утыра» — әнисе дә шулай дип әйтә иде. Гөлсинә аңа кушылып көлгән җиреннән машина тавышы ишетеп, тәрәзәгә барып сарылды.

— Юк шул, юк Шамил, агы дигән булып, ярамаганмы зәңгәре, кызылы,— дип ирен яратып шелтәләгән булды да тиз генә өйалдыннан бер тустаган катык алып керде.

Нигә соң әле Камил һаман кашыкка үрелми? Тансыклап кайтты да, инде ачы катык катылган умач ашы алдына килгәч, инде бөтен теләге дә чынга ашкач, шушы ләззәтне азга гына булса да сузарга теләвеме? Бары да әйбәт, барысы да ул теләгәнчә, тик... нидер җитми кебек. Салам түбәле өйме, әнисенең ипине чамалап кына, табындагыларга бүлеп, үзенә иң бәләкәйрәк кыерчыкны сиздермичә генә савыты кырыена алып куюымы? — Юк, бу да сәбәп түгел ахрысы, балачакта йотылып укып та, еллар үткәч, яңадан укып, шул ук китаптан бөтенләй кире тәэсир алган үкенечле халәттә калудан курка иде бугай ул. Кайнар ашны

пешәләнә-пешәләнә ашарга яратмый иде Камил, савытын җиң очы белән тотып, баскыч төбенә, янсә бакчага тизрәк суындырырга дип алып чыга иде элек. Нигә соң әле хуҗалардан гафу үтенеп, рөхсәт сорап, шул гадәтен кабатламаска...

Карама төбе. Тирә-юньгә иртәләп саргайган берәм-сәрәм зәгыйфь яфраклар сибелгән. Хәтер, бер кашык хәтер... Кайда син утын төягән бәләкәй чана сөйрәп, әллә кайдагы үзең дә белмәгән кешеләрне каргый-каргый, тездән карга батып урманнан кайткан малай? Галош эчендә сизрәп тишелгән оекбаштан бәреп кергән карлы салкыннан башта кызышып, аннары бөтенләй сизмәс хәлгә килгән аягыңны сөйрәп кайткан малай син идеңме ул? Боз булып каткан аягыңнан галошыңны кисеп алып, елый-елый кар белән уган, аннары каз мае сөртеп җылы урынга яткырган әниең кайда? Хәтер... Бер кашык кайнар хәтер... Капка төбенә ат килеп туктый. Әниеңне күтәреп кертәләр. Сабан төрәне төшеп кискән аяк йөзендә, тирән яра астыннан өзелеп чыгып, җеп сыман каралып калган кан тамыры. Йөзе сап-сары төскә кергән әниең, шушындый хәлгә дучар булуыннан уңайсызланып, сиңа кулын суза, елмаерга тели. Хәтер, бер кашык хәтер... Менә син шәһәргә укырга китәргә җыенасың. Сугыштан кайткач, сәламәтлеккә тиенә алмаган әтиең ютәлләп урыныннан тора да, еламсыраган тавыш белән:

— Саубуллашмыйча кит, улым. Күтәрә алмам. Монда, ишегалдында гына йөри, хәзер килеп керер дип торырмын. Саубуллашмыйча гына кит, улым.

Ә син тәрәзә янында күңелең тулышканга тын да алмыйча басып торасың. Тышта көз. Шыксыз җил рәхимсез рәвештә агач яфракларын йолка. Күктә алама болытлар.

— Күңелем сизә, соңгы тапкыр күрәм, улым...

Керфекләргә менеп җиткән күз яшеңне чыгармаска теләп, син тешләреңне кысасың. Ә тышта — җил. Ерак та түгел кап-кара киемле, таякка таянган бөкре карчык урамны аркылы чыгарга маташа, пычрактан аякларын тартып алалмый, кулларын сузып кемнедер ярдәмгә чакыра. Син җан тарыгудан ыргытылып урамга ташланасың. Урамда исә шомлы бушлык, беркем юк... Күзгә генә күренгәнме кара киемле бөкре карчык? Ярсу җил генә урамга көрмәкләп-көрмәкләп үле тәнле сары яфраклар сибә. Китәргә, моннан китәргә! — дип, син йодрыкларыңны кысып сүз бирәсең. Хәтер, бер кашык хәтер... Савытның төбе күренгәнче, шулай ачы ул. Битеңне уеп төшкән күз яшенең кашыкка тамуыннан гына ачы түгелдер бу хәтер...

Ул дәвердән соң инде карамага күпме еллар бөҗрасы өстәлгәндер. Ябалдашлары чайкалган көйгә ни сөйли яфраклары? Мендәрен кәүсәсенә терәп, кулларын баш астына салып яткан чал чәчле кешене әкрен генә тирбәтә ул. Ә күк шундый аяз, агар болытларын офык артына яшергән. Онытылып күзләреңне йомдырыр өчен нинди йомшак зәңгәрлек.

Әтәч кычкырган тавышка ул уянып китте. Бөтен буыннарына җиңеллек биреп, тулы бер дәвер ял иткән кебек. Мунчаның эссесе сүрелгәнче уятыйм дип берничә мәртәбә килеп тә, йокысын бүләргә кыймыйча, аяк очларына гына басып киткән Гөлсинәнең ишегалдында зәңгәр яу...ыгы чагылып алды. Койма башына менгән әтәч, түшен киереп, тагын бер кычкырырга әзерләнгән иде дә, бакчадагы ят кешене искәреп, күкрәген шиңдерде, бер урында таптана башлады һәм куркудан, тавыклар каршындагы горурлыгын да онытып, җиргә сикерде. Гөлсинә бакча капкасын ачты:

— Тордыңмы, Камил абый! Мунча әзер. Мич кырындагы краннан кайнар су агызырсың. Җылымса су — казанда. Боз кебек салкыны алгы бүлмәдә булыр. Илһам бераздан кайнар чәй китерер. Иркенләп, озак итеп кер, Камил абый, җәме! Мин хәзер кичке савымга, җәйләүгә китәм. Озакламам.

— Рәхмәт, Гөлсинә. Арыгансыңдыр инде.

— Кунак кайтса — үзе бер бәйрәм бит ул, Камил абый. Тәрәзәләр яктырып китә. Капкалар җырлап ачыла. Кулда эш уйнап кына тора.

Камил әле генә искәреп, мәтрүшкәләргә кадәр утырткансыз икән дип иелде дә, кызгылт-шәмәхә бөреләрне сыйпап, иснәп карады.

— Бер-ике көннән чәчәк атарлар инде. Исе бөтен ишегалдына тарала аның. Урманда азая бара бит, шуңа утырттык. Шәһәрдән машиналар белән килеп, кочак-кочак җыялар. Сабагын сындырып кына алсалар бер хәл иде,— төбе-тамыры белән йолкып җыялар бит, мәнсезләр!

Бакча капкасы ябылуга, Гөлсинәнең «ти-ти, ти-ти, ти-ти, ти-ии» дип бер үк сүзләрне сәйлән кебек тезеп, тавыклар чакырганы ишетелде. Камилнең йөрәге кысылып куйды. Әнисе исенә төште. Тавыкларга ашарга салганда, ул да нәкъ шулай көйли иде бит.

Ул калын такта башлары җәелгән сукмактан мунчага таба китте. Алмагач арасыннан үтүгә — кара син әнекәшен: бөтен урманны кучереп куйган инде әллә — балтырганга кадәр утырткан бит. Нарасый яфрак төбеннән кисеп алынганы урынына яңа көпшә борынлап килә. Карлыган куаклары арасында, кызыл түбәле умарта оялары янында кортлар күңелле безелдәшә. Өйләнешкән елны парлашып кайтканнар иде. Шунда Клараны корт чакты. Корт угыннан аллергия булганын ул үзе дә белми йөргән, күрәсең. Чак үлемнән калды. Ярый әле ашыгыч ярдәм машинасы якындагы нефтьчеләр поселогыннан вакытында килеп җитте. Шуннан бирле, авылга кайту дигән сүз чыкса, Клара перламутр тырнакларын елтыратып, кулын калкан итеп күтәрә.

Ә менә Ләләне бер алып кайтырга иде шул. «Үз кызыма туган җиремне күрсәтә алмаган нинди ата инде мин»,— дип уйлады Камил. Шундый вакытлар була иде: авылын искә төшереп, онытылып утырганда, кызы килеп эндәшсә, ул, үзе дә сизмәстән, татарча җавап бирә. Ләлә «ба!» дип, аңа, бу нинди архаизм дигән кебек, аптырап карап тора. Андый чакта Ләлә шундый чит булып тоела иде аңа, татарчага өйрәтә алмавына ачынып, кызының өйрәнергә теләмәвенә ул беразга үпкәләп тә йөри иде.

Халык моңнарын ярата үзе. Ләлә тапи дә йөрми иде әле, Камил аңа граммтәлинкәләр уйната иде — канына сеңеп калган күрәсең...

Юк, Ләләнең тамчы гөлгә исе китмәс мөгаен дип уйлады Камил. Хикмәт гөлендә генә түгел, исемендә дә бит әле аның, ана сөте белән кергән телнең тәмен тойган кеше өчен.

Мунчага керер алдыннан Камил сабакка үскән кузгалак төбеннән сусыл яфракларын җыйды, кызыгып китеп, суган, укроп үзе дә һәм шуларның барысын да керән яфрагына төрде — менә хәзер татып карарга була җир витаминын.

Кояш кичкә таба авышып бара. Авылда вакыт юмартлыгына чама юк. Хәтерне кузгатып әллә шулай әкрен ага ул?

Үткәннәрне искә төшергәндә, Шикоян, латинчага күчеп, сагышлы гына: «Без бар идек, без юк инде», — дип әйтеп куяр иде. Шикоян күптән инде Суздальгә барып җитеп урнашкандыр. «Миңа кичекмәстән авылга кайтырга кирәк, шулай килеп чыкты»,— дигәч, кара тут йөзе сүрелеп калган иде. Ярый әле, сәбәбен төпченеп тормады.

— Син юк арада мин бик күп нәрсәләр беләчәкмен. Әгәр өч көннән кайтмасаң, мине мәңге дә куып җитә алмаячаксың,— дип, әллә ничек, моңсу елмаеп кул бирде. Камил инде чыгып барганда, янадан дәшеп, вестибюльнең икенче катыннан ашыга-ашыга төште.

— Теге... ничек соң әле, үлән кушып бик тәмле чәй эчерәсең бит, синең якта үсә торган үлән?..

— Мәтрүшкәме?

— Менә, менә! Шуны алып кил, алмассыңмы бераз...

Гаҗәп бит бер уйласаң: самолет, экспресс, тагын шуңа ике чакрым җәяү үтүне дә кушсаң, мең чакрымнан артык юл — берничә сәгать эчендә икесе ике параллельдә. Камилдә нәкъ шушы мизгелдә анда да монда да берьюлы буласы килү теләге туды. Әмма ераклык һәм вакыт төшенчәсен катлаулы шәкелләргә төреп исәпли белгән галим дә андый мөмкинлеккә ия түгел шул.

Камил мунчаның каен, имән себеркеләре, йомшак сөлгеләр эленгән алгы бүлмәсендә үзалдына җыр көйләп чишенде дә, ишекне кинәт кенә ачып, борынгылык исе килеп торган эчкелтем кайнарлыкка чумды. Сулышына капкан коры һавадан куырылып идәнгә чүкте. Бераз иялләшкәч, эскәмиягә утырды, аннары гына, тәмам чирканчык алган гәүдәсен ләүкәгә мендерде. Бөтен күзәнәкләре эреп киткәндәй йомшап, мул тир тамчылары шытып чыккан мәлдә, бу дөньяга яңадан туу кебек бер могҗиза алдында торгандай, йөрәге дәртле кагарга тотынды.

Артык кызуданмы шәмәхә-кызгылт-яшел төскә кергән ташларга су сибүгә, шартлап түшәмгә кадәр күтәрелгән пар, сискәндереп, бөтен тәнен ялмап алды. Камил, үзе дә сизмәстән, «шә-әп!» дип кычкырып куйды һәм аннары... мәтрүшкәле себеркедән манма хуш ис сирпетеп изрәгәнче чабыну, хәл алырга дип, алгы якка чыккач, ишек ярыгыннан сытылып кергән салкынча һаваның тәнне рәхәт кытыклап, өшетеп алуы, беркем белән бүлешә алмаган ялгызлык ләззәте, гомумән, менә шулай, дөньяда яшәүнең кадерен кинәт кенә искәреп алып, гадәттән тыш кайнарлык һәм салкынлык арасында тәнеңнең барлыгын тоеп кинәнү бары тик авыл мунчасында гына буладыр. Ул монда, ял итәргә дип утырып, тәрәзә пәрдәсен сыдырып тышка карагач, тагын бер тапкыр төшенде. Күрше бакчада, тубыктан яшеллек арасында беләкләрен, мул күкрәкләрен уйнатып, әйләнә-әйләнә,

бәрәңге матиклаган яшь хатын булганга мәгънәләрәк күренә түгелме су буендагы өянкеләр дә, ерактагы зәңгәрсу урман да, төпсез күк йөзе дә? Кояш нурында тәтенсу өрфия генә булып калган Әчке күлмәге аша ачык күренгән тән бөгелешләрен, таза балтырларын ыспай кузгатып, ул гүя өнсез табигать сәхнәсендә ниндидер балетлардагы нәзберек хәрәкәтләргә уч иткәндәй, сәламәт рух белән очынып бии иде.

Уттан һәм судан яратылган кешенең мунчада җаны да мәҗүси хәлгә киләдер, күрәсең. Әнә бит, ләүкә астында, кара сәйлән чаклы гына күзләрен акыллы төбәп, нәни һәйкәл булып кымшанмый да утырган бака да бүген аңа чиркангыч тоелмый. Малайлыгы кузгалдымы, Камил елмаеп, аңа күз дә кысып куйган булды. Бака исә, монда мин хуҗа дигәндәй, чуар тамак астын мимылдатып, торataш утыра, ә күзләрендә — сагаюлы-шелтәле тирән бер моң... «Миллион еллар элек тормыш таңында без бит бер биеклектә, тигез идек, аннары гына тереклек шәҗәрәсенең бүтән тармакларына аерылдык, син ары киттең, әмма, масаеп, үткәнеңне онытма, кешем, мәрхәмәтле бул». — диясе киләме аның...

Төн уртасына кадәр Камил йокыга китә алмый ятты. Урамнан ара-тирә үтеп киткән машина, мотоцикл тавышлары да, карама төбендә утырып оеган тынлыкны үтә дә нечкә бораулап бозелдәгән черкиләр дә тынычсызламый иде аны. Туган җир тыныч кына йоклап ятар өчен тартып кайтармаган аны, күрәсең. Камил ятагыннан торып киенде, тирән эчле галошларга аякларын батырды да, агач арасыннан килеп, койма өстеннән генә урамга сикерде. Әрекмән, кычыткан орлыгы исе килеп торган саф һаваның барлыгын тоеп, күкрәген киереп сулый-сулый тыкрыктан тау ягына күтәрелде. Күңелендә туган беренче тәэсирләре инде талгынаеп килә, әкренләп нялэшеп бара бугай монда. Иртәгә күршетирәләр, бергә укыган дус-ишләре белән күрешеп чыгасы булыр. Авыл белән урман арасындагы Дугалы чишмә суын да эчеп карыйсы бар бит әле аның. Ана карынынннан яшәү даулап, көчле аваз салып чыккан сабый шикелле, дәртле ашкынып, җир багыреннән чыккан чишмә суы, чуерташлар өстеннән йөгереп, уйнап үтә дә, кояшны, күк йөзен, зирек куакларын күреп гаҗәпләнгәндәй сабырланып кала һәм, борыла-сырыла килеп, инешкә башын сала. Урманнан кайтканда туктап, хәл ала торган урын иде ул. Үз җиреңнең шифасы сеңгән чишмәң булу үзең дә аңлый алмаган бәхет түгелме. Мин дә шулай, картайган көнемдә дугалы чишмә суын эчәсем килсә, кем үтәр бу соңгы теләгемне? дип, Камил ачынып, тыны бетә башлаган шикелле, тирән сулыш алды.

Баш очында иксез-чиксез күк гөмбәзе, төн караңгылыгында адәм баласына өмет биреп балкыган бихисап йолдыз бөртекләре. Аларның күк җисеме икәнен дә, матди сыйфатларын да, телескоплар барлыгын да онытасы килә. Малай чактагыча, җиргә ятып, салкын сулышлы илаһи галәмгә күзләр арыганчы карыйсы гына килә. Әнә Сириус альфасы талпынып-талпынып яна. Ниндидер кодрәтле кул учлап сипкән шикелле, бакый ераклыкта тоныкланып Орион йолдызлыгы күренә. Серле томан өретелгән Киек каз юлы сузылып, күз күреме җитмәс тирәнлеккә кереп югала. Шушы галәм иркенлегендә йөзгән акылыңны җиргә төшергәч, әллә нинди икеләтә моңсулык били күңелеңне. Озак, бик озак итеп яшисе килә Җирдә...

Аста тәрәзәләре сүнгән авыл, урамдагы сирәк утлар гына төн караңгысын уеп-уеп алган. Бүген Камил самолетта ун чакрым биеклектән җирне күзәтеп кайтты. Уйдык-уйдык кына күренгән күпме авыллар, шәһәрләр өстеннән очып узды. Җир йөзендә күпме икән андый авыллар, шәһәрләр? Аларның барысын белеп, танышып чыгу өчен кеше гомере җитәрлекме? Хәтта, үзең яшәгән бер шәһәрне дә бит колачлап, белеп бетерү мөмкин түгел. Күпме ят урамнар, сиңа таныш булмаган язмышлар, миллион тәрәзәләр. Нихәтле зур шәһәрдә яшәсәң дә, үзең эшләгән хәяттәге йөз, күп булса, ике йөз кешедән артыкны белмисең. Шәһәрдә һәммә кешенең дә үз авылы бар дип уйлады ул.

Камил карама төбендәге салкын урынына кайтып ятканда офык чите кыяркыймас кына яшелләнә башлаган иде инде. Яфраклар арасыннан чәрдәкләнеп күренгән күк йөзеннән ул бер йолдызны эзләп тапты да бар игътибарын шул ноктага төбәде һәм оеп йокыга китте.

Кемдер аның чәченнән сак кына сыйпады, юрганын рәтләп япкандай булды. Карама, иелеп, аны йомшак кына иркәләде бугай. Йокы аралаш ул шулай уйлады... Чынлыкта исә ни булганын, әлбәттә, ул башына да китерә алмас иде. Күрше-тирәләр турында сорашканда, көндез бәрәңге матиклаган хатынның Илгизә исемле икәнен, баласы булмау сәбәпле ирдән аерылып кайтуын Гөлсинә сүз арасында гына әйтеп куйган иде. Төш вакытында ике арадагы бакча капкасы аша йомыш белән кергән Илгизәнең карама янынннан үтүен дә сизми

калган иде йокыдагы Камил. Әгәр Илгизә, бик күп еллар элек кунакка кайткан Камил абыйсының хуш исле киемен, аңа билле прәннек бирүен, «Кемне яратасың?» дип сорасалар, «Камил абыйны!» дип биш яшьлек акылы белән җавап биреп олыларны көлдерүен — барысын-барысын хәтерләвен әйтсә, «Булгандыр, булгандыр...» дип, Камил битараф кына елмаеп куяр иде, мөгаен. Менә хәзер Илгизәнең мыштым гына бакчага керүен, ул белмәгән ниндидер зур җирдән кайткан серле ирнең таралып йоклавын, бала чагында төш кенә булып калган хатирәсенә сәҗдә кылгандай, бүгенге уңмаган тормышына бер дәва эзләгән сыман карап торуын, аннары, үз гомеремдә бер мәртәбә профессор кешенең чәчен сыйпап карыйм әле дип иелүен, юрганын иплән япкач, кинәт кенә сискәнеп, тирәягына карана-карана йөгереп диярлек бакчадан чыгып китүен, баскыч төбенә утырып, әлеге тыйнаксызлыгыннан ояла-ояла, һәм шул ук вакытта уятырга кыймавына үкенеп, алгысыган йөрәген күз яшьләре белән чылатуын бары тик таң эңгеренә чумган карама гына искәргәндер.

Камил уянганда инде кояш, элеккеләр әйтмешли, тартә буе күтәрелгән иде. Ул тиз генә чалбарын киеп, балагын сызганды да, бакча ызанының яланаяк кына су буена төшеп китте. Өянкеләр астыннан үтеп, көмешсу төсткә үги ана яфракларыннан чык тамчыларын коя-коя, яр буена килде дә, басма кырыендагы ташка чүмәшеп юынды. Казлар кыйгылдашуы, атлар пошкыруы, кошлар чыркылдашуы бергә кушыла да, иртәнге тынлыкка җан өреп, су өслегеннән тонык яңгырап ишетелә.

Басма агачлары сыгылып куйганга ул күтәрелеп карады. Көянтә-чиләк аскан Илгизә, бер кырыйдарак торган Камилне искәрмәгән шикелле, күзләрен керфек күләгәсенә яшереп, басмадан чыга башлады. Камил инде дәшмәскә, илтифатсыз гына калырга уйлаган иде. Ләкин Илгизә, ярга чыгып җитүгә, кинәт кенә башын күтәрде дә, үтә бер.кыюлык белән дәшеп, Камилнең сызганулы балагына, юеш мәте буялган яланаякларына күз төшереп алды.

— Исәнмесез, Камил абый!

— Исәнмесез... Салих абзый кызы... Илгизә бит әле, әйеме? Кайчан гына туп кебек уйнап йөргән бәләкәй кызчык идең.

— Сез кайтмый дип, тормыш тукталып тормый шул, Камил абый. Су эчәсезме? — дип, Илгизә яшел таллар күләгәсе тирбәлеп торган мөлдерәмә чиләгенә ымлады. Эчәсе килми иде Камилнең. Әмма Илгизәнең тәкъдименә каршы килә алмады. Үсмер чакта чишмәдән кайтып килгән кызлар чиләгеннән су эчәргә рөхсәт алу — үзе бер горурлык, санга саналу, егет итеп танылу билгесе иде. Камил бер аягына тезләнде, чиләкне иплән кенә янтайтып, теш камаштырырлык суны сөзеп кенә эчте дә, рәхмәт әйтеп, ирен читләрен сөртергә дип, кесәсеннән кулъяулык чыгарды.

— Бу чиләктән дә эчегез, Камил абый. Ату бәхетегез тулы булмас. Оныткансыз авыл гадәтләрен,— дип, Илгизә тигез тешләрен балкытып елмайды. Камилгә икенче чиләк каршында да тезләнергә туры килде. Шушындый могтәбәр ирдән үз теләгеи үтәтә алу канәгатьлеге, чиләктәге судан кайтарылган кояш нуры белән кушылып, Илгизәнең йөзендә серле яктылык булып уйный иде.

— Чәй эчәргә керегез безгә, Камил абый,— дип, Илгизә китеп тә барды. Керфекләре арасыннан сирпелеп киткән бераз моңсу да, дәртле дә карашы бөтен тирә-юньгә сибелеп калды. Камил аның өянкеләр арасындагы сукмактан сыгылмалы атлап баруын карап торды да, чигәсен кысып, бермәлгә күзләрен йомды.

Чибәр, яшь хатын-кызны күргәч, маңгай, күз төбендә сырланган елларны киметәсе килү кайсы ир-атка хас түгел икән соң? Хәер, андый халәттә түгел иде шул Камил. Нигә соң әле аны язмыш болай рәнҗеткән, балалы булудан мәхрүм иткән? — дип уйлады ул.— Бәлки аның да шушы чишмә суын эчеп үскән егете еракларга китеп югалгандыр. Сибелү, чәчелүне рәнҗеп күзәткән туган җир бәлки бөтенләй сизмәгән яктан үчен аладыр... Тамчы гөл... Кактус... Нигә соң әле чагыштырам, киракми тирәнгә керергә, үкенүле уйлар бер читтә торсын, шундый матур иртә бит әле бу, сагынылган иртә...» Күр әле син: күңелле каңгылдашып, оя-оя казлар төшеп килә, кояш нурында күзне камаштырган ак каурыйлары, таллар күләгәсенә кергәч, күгелҗем төс алды. Аргы ярда тышаулы атлар, бөдрә яллы колыннарның арт сикертеп чабуы, сыер көтүе таралган тауда көтүче чыбыркысының шартлап куюы, инеш ярыннан борыла-сырыла ерагая барган өянкеләр — шушы җанны сыйпап юата белгән иртәнге манзараны кочагыңа сыйдырасы иде, бөтен барлыгы белән сулап, эчеп бетереп, күңеленә иңдерәсе иде. Камилнең кайдадыр баш җитмәс формулалар чишеп, күз күрмәс ераклыктагы Сатурнның хикмәтләрен өйрәнүе бу мизгелдә сәеррәк булып тоелды. Әлбәттә, ул ике-өч көннән соң торган җирен, әшен сагына башлар, миннән башка анда

әллә ниләр булыр дигән ашкыну белән юлга җыенып. Хәзергә исә, үткәненең шаһиты — шушы манзара каршында акланасы килгән сыман бер тойгы кичерә иде ул.

Бакча ызанынннан ул күңелендә канатланган малайлыгын көчкә тыеп кайтты. Сызгырасы килә — әмма сызгыру онытылган. Йөгерәсе килә — кешеләрдән кыен, беркем юк димә, авылның киртә казыклары да күзле була. Дөнья иртәнге самими нурга чумган. Артык яктылыктан күз кабаклары кысыла.

Шулай хозурланып кайтып килгәндә, бакча капкасы янында аны Илһам көтеп тора иде.

— Хәерле иртә, энекәш!

Болай исәнләшүгә күнекмәгән Илһам, кызарып, авыз эченнән мыгырданып алды да:

— Сиңа телеграмма бар, Камил абый,— дип, түш кесәсенә тыгылды.

Нинди телеграмма булырга мөмкин соң әле? Камил институттагы секретарена, шоколад кабына кыстырып, сер итеп кенә адресын калдырган, бик мөһим эш килеп чыкса гына хәбәр бирерсең дигән иде. Нинди эш чыгарга тиеш соң әле моңлый көндә, туган җиремне юньләп күрергә дә өлгермәгән килеш, мине моннан тартып алырдай нинди көч булсын! дигән уенчак кәеф белән ул телеграмма кәгазен алды, кубарып ачты да, кинәт... ап-ак тимгелләр чыккан йөзе суырылып килде. Калтыраудан бер-берсенә тия алмаган иреннәре чарасыз пышылдау гына чыгарды:

— Шикоян... Армен Ашотович, нишләвең бу?.. Кадерле кешем... шушындый кояшлы көндә... ничек алай?!.

Суздаль юлында, машинасы белән бәрелеп, Шикоянның һәлак булуын һич кенә дә аңына сыйдыра алмый иде ул.

## Харрас Әюпов

### Яшен вакытында язылган шигырь

Сискәндереп гамьсез көнне кинәт
Телеп узды яшен,
Калтырады тәрәзәләр — Намус,
Синмени соң дәштең?

Синмени соң, Хаклык, ахыр чиктә
Түзалмадыңмыни? —
Азды шул бу мәкер: кешеләрнең
Башларыннан йөри.

Кылычыңны син дә кынысыннан
Чыгардыңмы, әй, Үч,
Тәрәзәләр түгел, җан сатканнар
Калтырарга тиеш!

Син кайттыңмы, үлем белән гүргә
Томаланган Чынлык —
Бу дөньяны бераз дөресләргә
Булдыңмыни... чыгып?

Ялгыштыммы, буталдымы юлым,
Дөрес яшәмимме?
Нәселем рухы! Әллә шулай миңа
Син соң дәшәсеңме?

Сискәндереп гамьсез көнне кинәт
Кемдер телеп узды,
Гөнаһ юктыр корыган карамада —
Анысын белеп узды.

Ялваруларыңны кабул итмәс,
Теләк теләвеңне,
Яшен булмастыр ул — сукса беркөн
Әгәр йөрәгеңне.

Дөньяларны айкап, кемдер йөри,
Түгелдер ул Яшен —
Танымыйсыңмыни күк күкрәткән
Күңелеңне, Кешем!

---

ХАРРАС ӘЮПОВ (1946) — шагыйрь, «Ышаныч», «Кояшлы яңгыр», «Каен балкышы» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.

## Иңнәремә сал башың...

Ай-һай, дөнья, чал башың,
Иңнәремә сал башың,
Бер тирбәтим чал башыңны —
Хәсрәтләрең калмасын...
Күкрәгемдә — йөрәк бу,
Авыр чакта терәк бу,
Синең борчуларың төяп
Китәр өчен кирәк бу.
Буйлыйм Иделләреңне дә,
Уйлыймын илләреңне;
Яндырып кал: беләсеңдер
Мәңге түгелләремне.
Ай-һай дөнья, чал башың,
Йөрәгемә сал башың,
Кайгыларың алып китим —
Бүтәннәргә калмасын!

## Биеклек

Без диңгезгә чыктык.
Тынып тормый,
Һаман сөйли экскурсовод.
Таулар белән таныштыра бара,
Күңелләргә бара уй салып.

Таулар белән таныштыра бара:
Кара Тау да — янар тау булган,
Түбәсендә аның таш балталы
Кешеләрнең эзе табылган.

Бу тауларга Вакыт таянгандыр...
Тауларның да була терәге:
Әйтерсең лә күккә тартып тора
Тау түбәсен шагыйрь йөрәге[1].

Акчарлаклар уйный — Озын Сырттан[2]
Күтәрелгән очкыч шикелле;
Кыюларның даны — мәңгелеккә
Очып киткән бер кош шикелле.

Таулар белән таныштыра бара —
Кешеләрне сөйли тау диеп.
Уйлый китсәң, таудай гынамы соң:
Кешеләрнең җаны һай биек!

Карап барам шундый биеклектән,
Карашларым әллә кайларда.
Сизеп торам: безнең белән бергә
Биегәя бара таулар да...

---

[1] Шагыйрь М. А. Волошинның кабере Коктебельдә — тау түбәсенә куелган.
[2] Озын Сыртта космик корабльләр конструкторы С. П. Королев яшьлегендә планер белән беренче очышларын ясаган.

## Йөгермәктә кеше...

Сабый чакта кеше йөгермәктә,
Йөгерүе белән сөйдермәктә;
Бер гамең дә куып җитә алмас,
Җилләр генә туладыр күлмәккә...

Үсеп җиткәч кеше йөгермәктә:
Юл белмәктә уе, җир күрмәктә;
Туган өйдән еракларга китеп,
Аналарын, ярын көйдермәктә.

Олыгайгач та кеше йөгермәктә:
Ил йомышын йомышлап йөрмәктә;
Әйткән сүзе, кылган эше белән
Җирдә яшәгәнен белдермәктә.

Картайгач та кеше йөгермәктә:
Үткәннәргә кабат кул бирмәктә —
Хыял белән көнгә ничә тапкыр
Дөньяларны гизеп өлгермәктә.

Гомер буе кеше йөгермәктә,
Бөтен күргәннәре — бер йөрәктә...
Гомерләрдән чыгып китәлмыйбыз,
Никадәрле генә йөгерсәк тә..

*

Иң беренче телгә төшә каргыш,
Әгәр сине язмыш каргаса...
Талга кунып сандугачлар бер көн
Кычкырмаслар димә каргача.

Юкка гына булыр әйтүләрең,
Карга түгел бит син, сайра дип.
Бәхәсләшер алар синең белән:
Мин — сандугач түгел — карга, дип...

*

Бер яман сүз җиткерделәр миңа —
Эчкә йомдым аны, таратмадым,
Җаным кара көеп янса янды —
Якты калды дөнья, каралтмадым.

Җилләрне дә тыңлый белү кирәк —
Колагыңа килеп, ниләр салмас!
Каян килә аклык җир йөзенә? —
Үзе каралмаган — аңлый алмас...

## Чакыру бар...

Урманнарда көзге яфрак исе —
Хушлаша көз... Соңгы хушбуйлары;
Һавалардан безгә чакыру бар:
Күчмә туйлар йөри — кош туйлары.
Сызгырынып сөрән салып уза,
Авылларга кереп, шәһәрләргә —
Һәр күңелнең чиртә тәрәзәсен,
Әйдәкләп җил ерак сәфәрләргә.
Сузылып килә җир өстенә кичләр,
Әллә кая тарта, ашкындыра;
Кыялардан ташланырга әзер:
Яшь кызларның күңеле ташкын гына...
Ышандырмый — нитми генә, җирдә
Башларының исән каласына,
Чакыру бар —
Кай тарафка карап
Йөгерәсе адәм баласына?..

## Ык буенда җил исә...

Ык буенда тын каберлек,
Ык буенда җил исә...
Искән җилдә сибелә комнар,
Сибелә берни белмичә.
Сибелә ачык ярага
Гасырларның ярасы.
Ничек түзә археолог? —
Көяр күк пумаласы.
Сибелә комнар... Асларыннан
Богаулы куллар чыга,
— Чишегез! — дигән шикелле
Каршыга еллар чыга.
Салдырсалар да богавын,
Җанда әрнү, газап тик:

Кемгә шатлык — ничә гасыр
Соңга калган азатлык?!
Чорларны азат иткәндә,
Чишкәндә богауларын,
Археолог бар дөньяга
Бирәдер сорауларын:
«Елларны һаман да шулай
Богаулап салабызмы?
Кемнәр килеп, богаулардан
Аралап ала безне?..»
Ык буенда тын каберлек,
Ык буенда җил исә;
Искән җилдә сибелә комнар,
Сибелә берни белмичә.

## Кояш

Кояш белән без бит авылдашлар:
Ничә еллар бергә уйнадык;
Бергәләшеп кичен өйгә кайттык,
Аның белән бергә уяндык.

Озын көннәр буе Кояш — бездән,
Без — Кояштан тотам калмадык.
Озаграк чыкмый торса әгәр,
Майлы ботка биреп алдадык...

Безнең белән бергә ул да көлде,
Безнең белән бергә елады;
Хәлне белде төшеп тәрәзәгә,
Мин бит — Кояш диеп тормады.

Барган саен, яктырдылар еллар,
Тартылдылар һаман Кояшка.
Юлларыбыз аннан аерылмады
Инде, менә, ирләр булгач та.

Кояш белән без бит авылдашлар —
Бергә янып, бергә туңганнар.
Каралтырга базмас бу дөньяны
Күңелендә Кояш булга:

## Минем яшем

Дүрт дистәне очлыйм...
Ә бит миңа
Алай гына түгел чынлыкта:
Гомеремнең минем күп өлеше
Узган ахры... Җирдә мин юкта.—

Елкы елы ничә кабатланган...
Яулар кубып, яулар басылган...
Терлек үрчетелгән... өй салынган...
Ут тергезеп, казан асылган...

Бабайларым килер көнгә карап
Яшәгәннәр, миңа эндәшеп.
Кайгырамын алар өчен дә,
Мин —
Ким дигәндә, инде мең яшьлек...

Үткәннәрнең алтын бодайларын
Киләчәккә бүген кем чәчә? —
Бик фәкыйрьдер кеше,
Гомерен әгәр
Тик үз яше белән үлчәсә.

Яшим диеп яшәгәнгә Җирдә
Гасырлар да җитми, чорлар да.
Еллар белән үлчәнмидер гомер,
Чын яшебез — тоткан юлларда

Дистәләрем ваклыйм...
Яшем минем
Әллә кая кадәр менмәс тә,
Бүтән гомер безгә нигә кирәк? —
Халкым белән булыйм бер яшьтә!..

# Мөхәммәт Мәһдиев

# ШАГЫЙРЬНЕҢ БИШЕГЕ

*И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.*
Г. Тукай.

Казан арты... Ул ни? Ул нинди географик район, ни өчен ул як Казан арты дип йөртелә?

«Казан арты» дигән кечкенә бер регионга хәзерге Биектау, Дөбъяз, Әтнә, Кенәр, Арча, Балтач тирәсендәге авыллар керә. Урманлы, кечерәк кенә елгалы, чокыр-чакырлы, ташлы басулы җирләр, яланнар. Катнаш урманнар бер яктан мәһабәт наратлы Илләткә барып тоташса, икенче яктан Киров өлкәсе урманнарына, Вятка зонасына тоташа. Елгаларның иң зурысы, әлбәттә, Казанка яки Казан елгасы. Казан шәһәреннән 80 чакрым ераклыкта Чыпчык, Бимәр исемле рус авылларын тоташтырган урман эчендәге кечкенә генә тибешле ашъяулык кадәр бер чыганактан башлана. Моннан тыш Казан артында Кесмәс, Көче Му, Бирәзә, Шушма, Ия, Ашыт сулары бар, тыйнак кына, күбесе инде хәлсез генә инешләр, ләкин гыйфрит кебек куәтле машиналарга, елгаларның җелекләрен киптереп киселгән элеккеге урманнарга, көйгән әрәмәлекләргә карамыйча, ул елгачыклар һаман агалар, әле заманга бирешмичә, яз көннәрендә «юл өзеге» дигән дәһшәтләр ясап куялар, җәйнең иң коры вакытында да, менә бетәмкибәм ди-ди, һаман кыштырдап, челтерәп, чурлап алга үрмәлиләр, әйтерсең, кырыс Каспий дулкыннарына кушылып Иран ярларына бәрелеп агарга, аннан күккә пар булып күтәрелеп, океаннар өстеннән узып туган якка яңадан кайтырга ашыгалар...

Казан артының этнографик ягы чуар: марилар, удмуртлар, руслар белән аралашып яшәү эзсез калмаган: җыйнак кына гәүдәле, кечкенә күзле, кызыл чәчле, кызыл сипкелле татарлар очрый икән — гаҗәп түгел, татар белән мари гомер буе ил-умач килеп яшәгән бу төбәктә. Балтач-Кукмара ягында сап-сары чәчле, зәңгәр күзле — эре яңаклы, таза сөякле татарлар очрый икән — гаҗәп түгел, удмурт белән татар катнашкан авыллар Казан артында гадәти хәл. Руслары да шулай: үз телләрен онытып гел татарча сөйләшеп йөргән, татар кызына өйләнгән, тагын әллә ничек, әллә ничек туганлашып таралышып беткән руслар байтак анда. Әнә шул бай калейдоскоп эчендә татарның әдәби теле сакланган: Казан арты татарлары турында фикер йөртеп, Тукай болай ди: «Милли әдәбиятымыз фәкать шулар телендә, шулар рухында булуын телим» (С. Сүнчәләйгә хаты, 1910, 9 ноябрь).

Шулай да — ни өчен Казан арты? Нигә Норлат, Буа, Апас яклары «арт» түгел, нигә Әтнә-Арча? Бу төшенчә уналтынчы гасырдагы мәгълүм тарихи вакыйгалар нигезендә туган булса кирәк. Мәскәү-Зөя ягыннан карaганда Арча — Әтнә-Дөбъяз төбәге, чыннан да, Казанның арты бит һәм ул шулай тарихка кереп киткән дә. Тукай үзе бу төшенчәне бик яратып кулланган, мәкаләләрендә, очеркларында, хатларында ул аны ниндидер бер сагышлы җылылык белән, кайвакытта халыкның авыр тормышына газаплы сыкрану, ә кайчакта сатирик интонацияләрдә куллана. XX гасыр башында

Казан артының мәдәният-мәгърифәт ягыннан бик нык артта калуына сыкранып шагыйрь болай яза:

Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:
Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.

(«Казан вә Казан арты», 1912).



Әмма тарихка эчкәрәк керик әле. Казан арты халкы кемнәрдән, ничек формалашкан? Казан арты — Казан губернасында җан башына имана җиренең күләме ягыннан иң фәкыйрь регион. Анда — урман, ташлы басу, кызыл балчык, кантарлы кырлар. Тарихи хезмәтләрдә Казан артында Болгар чорында ук татар авыллары булганлыгы мәгълүм. Моның шулай икәнлеген бүгенге ономастика фәне дә раслый.

Казан ханлыгы чорында бу төбәктә байтак татар феодаллары яшәгәнлеге мәгълүм. Совет чоры галиме Гали Рәхим, мәсәлән, Зур Сәрдә, Кече Әтнә, Иске Мәңгәр, Өҗем, Рус Урматы һ. б. авылларда 1494—1548 елларга караган кабер ташларын искә ала. Ерганаклар, кызыл-сары ярлар, вак ташлы инешләр. Уналтынчы гасырның икенче яртысында Казан һәм Казан тирәсендәге бистәләрдән бик күп халык әнә шул яктагы урман аланнарына китеп урнаша, элеккеге шәһәр һөнәрчеләре, сәүдәгәрләре, укымышлылары үзләре өчен яңа, әмма ерак бабалары өчен таныш булган игенчелек һөнәрен үзләштерергә керешәләр. Игенчелек белән рәттән — урман эше, йорт-җир салу, каралты-кура торгызу, аучылык, умартачылык эшенә тотыналар. Урман яндыру (ышна әрчү), төп чыгару, иген басуы «ясау»... «Шәһәрдә яшәгән татар халкының авылларга күчүенең авыл өчен зур әһәмияте булган. Үз һөнәрләре белән шөгыльләнүләрен дәвам итеп, татарлар анда да һәртөрле производстволар булдырганнар: күн иләгәннәр, тун теккәннәр, итек басканнар, агач эшкәрткәннәр, слесарьлык һәм ювелирлык эшләре белән шөгыльләнгәннәр»[1]. Казан артына күчеп килгән бу халык мари, удмурт халкы белән тиз аралаша, ике арада дини-милли каршылыклар бөтенләй үк булмый кала. Казан артындагы байтак татар авылын халык әле дә булса «ар» авылы дип йөртә («ар» дип удмуртларны атап йөрткәннәр) һәм аларның кайчандыр удмурт булганнарын бүгенге сөйләшләрендәге фонетик яңгыраш әле дә сиздереп тора. Казаннан һәм шәһәр тирәсе бистәләреннән күчеп килгән татар халкы еллар узу белән Казан артында мануфактуралар — «фабрикалар»га нигез сала. Тар гына — өч ягыннан урман белән кысылган Казан арты. Арчадан көнчыгышка китсәң — удмурт урманнары, төньякка китсәң — Балтач-Уржум чыршылары, төньяк-көнбатышка егермешәр-утызар метр биеклектәге нарат урманы — Иләт ягы. Әмма шул Казан белән урман кыскан тар җирдә татарлар (өлешчә рус алпавытлары һәм купецлары) искиткеч зур өлгерлек белән промышленность тудыралар. Кышкарда, Бәрәскәдә, Орнашбашта, Орыда 1775—1798 еллар эчендә Муса Усманов, Корбан Борнаев, Рәхим һәм Хәмзә Мамышевлар, Хәмзә Сәитовларның комач мануфактуралары, Алатта аракы заводы (рус алпавыты Шувалов), бакыр эретү (1747) заводы эшли башлый. Кайбер өлгерләр авылдан кире шәһәргә — ата-бабалары чыккан Казанга да үрмәлиләр. Ибраһим Йосыповның, мәсәлән, (Кишет авылы фабриканты) Кишеттә дә, Казанда да комач эшләү фабрикалары була[2]. Тире эшкәртү, сабын кайнату мануфактуралары нигездә йомышлы татарлар кулында булган. Алар Кышкар, Бәрәскә, Орнашбаш, Оры, Ашыт авылларында урнашкан булганнар.

Элеккеге шәһәр халкының токымы монда сәүдә-промышленностьны җәелдереп кенә калмаган. Казан артына үз холкын, үз культурасын, гадәтен, иҗатын да сеңдерә башлаган. Җир эшкәртә, иген чәчә, урман кисә, умарта, терлек-туар асрый башлаган элеккеге шәһәр һәм бистә халкы җирле крестьяннарның авыз иҗатына шәһәр культурасын үрә башлаган. Нәтиҗәдә авыл халкының авыз иҗаты белән шәһәр халкының авыз иҗаты бергә кушылып бер-берсен баету нигезендә фольклорның аерым бер катлавы — ике культураның синтезы туган. Казан артының җырга, мәкаль-әйтемгә, сынамышларга, әкиятләргә аеруча бай булуы әнә шуннан килә. Кызганычка каршы, заманында Казан артының үз Каюм Насыйрие тумый калган, әмма Тукай

---

[1] Татарстан АССР тарихы. Казан, 1970, 103—104 бб.
[2] Алишев С. Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании. Казань, 1973, 206—208 бб.

китапларына кергән җырларның, экият, мәкаль-әйтемнәр, афоризмнарның барсы да диярлек — Казан артыныкы. Тукай аларның бер өлешен Уральскида язган ич диярләр. Шулай, ләкин Уральск турында сүз алдарак әле.

Казан арты илебез тарихындагы зур вакыйгаларның шаһиты. Пугачев гаскәренең зур отрядлары 1773 елда Арча — Балтач, Арча — Казан юлларын үз кулларында тоталар, монда Мәсгут Назиров, Габделфаикъ Усманов, Гомәр Ибраев отрядлары йөри. Казан артының бик күп авыллары — Югары Сәрдә, Алат, Кечкенә Аты, Аты, Чыршы, Югары Арбаш, Түбән Арбаш, Субаш, Шәләнгер, Чүриле, Төбәк Чокырча, Чокырча, Корайбан, Югары Курса, Түбән Курса, Иске Му, Ташкичү, Мөндеш, Божа, Кишмәт, Бөреле, Шәпше, Көек, Кырлай авыллары баш күтәрә. Минем өчен ачыш: мин туган Гөберчәк авылы да (ул вакыттагы исеме Кечкенә Му) Пугачев восстаниесендә катнашкан, баш күтәргән. Менә юаш кына минем авылдашлар! Пугачев гаскәренең бер отряды Кышкар авылына да килеп чыга. Гаскәриләр Кышкарның иң зур баен талыйлар, мөлкәтен алып бетерәләр. Бу хәбәрне ишеткән Кишет авылы фабриканты Ибраһим Йосыпов тиз генә патша армиясенә барып хезмәткә керә: Пугачев гаскәре җиңелгәч патша хөкүмәте аңа салымсыз сәүдә итү хокукы бирә.

Тарих Казан артын сыйнфый сизгерлек хисе белән тәрбияли. Хезмәт халкының сыйнфый сизгерлеге асылда патриотизмга алып килә инде ул. 1812 елда Наполеон гаскәрләре Россиягә басып кергәч, Арча чиркәвендә бу вакыйгага багышлап дога уку оештырыла. Чиркәүнең пономаре Александр Ильин шул вакытта, программада каралмаганча чыгыш ясый: — Җәмәгать,— ди ул,— изге җиребезгә дошман бәреп кергән. Безнең бурыч — сәламәт булганнарыбызга сугышка китәргә, монда калганнарыбызга сугышта җиңү өчен ярдәм күрсәтергә...

Арчада ополченецларның зур отряды төзелеп Казанга килә.

Җире аз якта халык һөнәрле була. Электән дә һөнәр иясе булган, ил-җир күреп йөргән, сәүдә иткән бу халык Казан артында сәүдәне җанландырып җибәрә. Сәүдә үзәге — аерым регионнар өчен — базар. Казан артында акрынлап зур-зур базарлар оеша. Боларның иң мәшһүре — Чепья һәм Әтнә базарлары. Аннан кала Арча, Апаз, Күлле-Киме, Балтач, Иске Ашыт, Кенәр, Рус Алаты, Мәмдәл базарлары. Һөнәрчелекнең үсүенә базарның йогынтысы зур була, ләкин шул ук вакытта базарның үсүендә һөнәрчелек үзе зур роль уйный. Сәүдәгәрлек исә һаман киңәя, үзенә зур юллар таләп итә башлый. Казан арты крестьяннары катлавыннан акрынлап ерак юлларга йөрүче сәүдәгәрләр, Казан фабрикантларының товарларын «оптом» сатып алып, авылларда таратып йөрүчеләр барлыкка килә. Гасырлар узу белән, авылдан җир азлыкка чыдый алмыйча чыгып киткән крестьяннарның саны арта. Казан арты крестьяннары нигездә өч якка миграция кичерәләр: беренчесе Казан шәһәренә — ялчылыкка, хезмәтчелеккә.

Түбән Сәрдә һәм Дөбъяз ягы кешеләре, мәсәлән, Казанда «барабыз»-лыкта хезмәт иткәннәр, ат белән кибетләрдә эшләгәннәр. Бу традиция (ат җигеп юл йөрү) Казан артында зур абруй әше иде, әле 1950 елларда да кышын ат җигеп Арча базарына килгәндә Сәрдә, Ашабаш, Штерә, Орнашбаш ирләре билне кызыл комач белән буып, аның очларын ике якка асылындырып куялар һәм билендә кызыл комач путасы булмаган ирне ат җигүчегә исәпләп тә тормыйлар иде... Ул комачның нинди мәгънәсе булгандыр инде, ихтимал, аны Н. Исәнбәт, Н. Фәттах кебек язучылардан сораргадыр...

Шәһәрдә эшләп йөргәннәрнең бер өлеше анда утырып ук калган. Алардан ахырдан приказчиклар (кибетчеләр), сәүдәгәрләр, унтугызынчы гасыр ахырына таба эшчеләр сыйныфы формалаша. Казан арты крестьяннарының җир азлыктан җәфа чигеп, бу якны ташлап хәзерге көньяк-көнбатыш Башкортстан җирләренә күчеп утыруларын Д. Рамазанова архив документлары белән раслады [3]. Миграциянең тагын бер тармагы — Уральск, Троицк, Оренбург якларына. Монда күчеп килүчеләрнең бер төркеме — тегүчеләр, төрле һөнәр ияләре, икенче бер төркеме сәүдәгәрләрне тәшкил итә, өченче бер төркеменнән шулай ук эшчеләр сыйныфы формалаша. Ни өчен Уральск, Троицк, Оренбург? Чөнки алар — Урта Азия, казах-кыргыз далалары белән эчке Россия базарларын тоташтыручы олы юл өстендә капка. Казах-кыргыз далаларыннан Россия фабрикаларына чимал җыю, озату өчен иң кулай кешеләр татарлар булып чыга (диннең берлеге, телләрнең кардәшлеге,

[3] Рамазанова Д. Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань, 1984 г.

сәүдә юлында йөргәнлектән шомарган булу зур роль уйный, әлбәттә) һәм Казан артының җирсез халкы бик күпләп шул якка күчә. Игътибар итик: Кырлайдан Габдулланы алып китүче Бәдри солдат 1898 елда ук Уральск шәһәренә күчкән һәм ул бер дә изелгән татар түгел, Казанда бары тик кунакханәгә генә туктала. Сәгъди абзый белән сөйләшкәненә игътибар итегез: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга...» Ятим малайның киләчәк язмышын хәл итүгә әнә шулай дәүләт теле һәм элементар юриспруденция катнашкан. Юл йөргән кеше андыйның рәтен белә инде ул... Хәер, Алты-биш Сапый да Уральск шәһәреннән килгәч Казанда номерга гына төшә. Тукайның бала вакытта ук Уральск шәһәренә барып чыгуы, анда туганнары яшәве, бик күп якташларын табуы — бер дә очраклы түгел. (Мәсәлән, Уральскидагы «Казан» кунакханәсендә уздырылган кичәдә Тукай үзенең «Теләнче» шигырен укый. Шунда ук сәхнәгә хәерче киеменә киендереп Казан арты Иске Кишет авылы егете Хәкимҗан Йосыповны алып чыга). Уральскида Казан арты — Әтнә, Бирәзә, Кишет, Өчиле, Чиканас, Гөберчәк егетләре, тегүчеләр, кәсепчеләр байтак булган. Әмма, монысы инде аның — яңа тарих. Ә искерәге?

Сәүдә үзеге Әтнә-Мәңгәр тирәсендә акрынлап акча тупланган. Сәүдә эшен йөртү, алып бару өчен гыйлем-мәгърифәт кирәк булган. Сәүдә, базарлар үсү белән бергә Казан артында мәдрәсәләр ачыла башлаган. Арадан иң зурлары — Кышкар, Курса мәдрәсәләре булган. Кечерәкләрдән — Ташкичү, Казиле һ. б. мәдрәсәләр. Әйтергә кирәк, бу мәдрәсәләрдә укыту системасы һич тә без күз алдына китереп өйрәнгән схоластикадан гына тормаган. Мәсәлән, бу уку йортларында география, астрономия, хисап буенча заманына күрә гыйлем бирелгән. Сәүдә эше белән көн иткән «ак» халыкка бик тә кирәкле мәгълүматлар бу. Мәдрәсәләрне сәүдәгәр байлар тоткан. Болар, әлбәттә, инде шәһәрчә яшәргә тырышканнар, затлы йортлар салдырганнар (Мәңгәр авылындагы архитектура үрнәкләре), тәрәзә капкачларын элеккеге Казан шәһәрендәге традицияләр үрнәгендә челтәрләп бизәгәннәр, авыл җиренә шәһәр культурасын керткәннәр. Архитектурадагы бу матур традицияләр әле дә булса Балтач, Арча, Биектау, Кенәр якларында дәвам итә, тәрәзә наличникларының күп гасырлык орнаментлары Казан артына һичшиксез, Казан шәһәреннән күчеп килгән.

Мәдрәсә акча булган җирдә генә яши ала. Мәңгәр-Әтнә байлары шулай Кышкарда, Иске Масра, Курса сәүдәгәрләре Югары Курсада заманына күрә зур уку йортлары салып куялар. Казан артында шәһәр традициясе буенча укымышлылык, китап язу, гыйлем эстәү дәвам итә. Әйтик, Ш. Мәрҗанинең әтисе Баһаветдин — Казан артының мәктәп-мәдрәсәләрендә күп төрле фәннәр укыткан, гыйлемлелеге белән мәшһүр кеше, Урта Азиядәге галимнәр белән арадаш булган. Шиһабетдинның әнисе ягыннан бабасы Габденнасыйр — Ашыт авылының зур укымышлысы. Оныгы Шиһабетдинның формалашуында аның роле зур булган. Әтисе ягыннан бабасы Сөбхан — гарәпчә һәм фарсыча зур мәгълүматлы кеше, үз гомерендә берничә китап күчереп язган, оныгының тарихчы булып китүенә беренче этәргеч ясаган. Казан артының Ташкичү һәм Япанчы исемле кечкенә авылларында Шиһабетдинның ата-бабасының зур-зур китапханәләре булган. Ә авыл җирендә китапханә акрын хәрәкәт итүче «шартлаткыч» кебек инде ул: ул — гасырлар өчен эшли, акрын, эзлекле, әмма нәтиҗәле эшли. Мәңгәрләр, Ташкичүләр, Япанчылар шуның өстенә тагын Урта Азия белән зур сәүдә алып баралар. Казан артында кибетләр тоталар. Шиһабетдинны да Бохарага Мәңгәр сәүдәгәрләре алып китә: 1838 елда, әтисе Ташкичүдән Мәңгәргә китереп Мохтар бәк Мөхәррәм (бәк!) исемле сәүдәгәрнең кәрванына урнаштырып гыйлем эстәргә Урта Азиягә озата.

Шунысы характерлы, Казан арты сәүдәгәре кая гына барып чыкмасын — эше рәтләнеп китүгә, шул төбәктә мәдрәсә сала. Мәдрәсә сала, үзе белән китап, кульязма алып бара, төрки халыклары арасында шуны тарата. Арадан дин китабы да байтак булгандыр, әмма тарихта алары түгел, ә чын әдәбият кына файдалы эз калдыра. Әйтик, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең күп кенә вариантлары Казан артыннан табылган. Әмма Казан артында күчерелгән бу вариантлар читкә дә китеп таралганнар. Мәсәлән, поэманың Олы Мәңгәрдә күчереп язылган нөсхәләре ерак-еракларда табылган. Әйтик, Әстерханда. Димәк, Казан арты сәүдәгәре белән килгән. Инде бастыручыларны әйткән дә юк: гел Казан арты. Рәхмәй тылмач беренче басмасын дөньяга чыгарса, Түбән Курса авылы крестьяны (әлбәттә, сәүдәгәр инде)

Шәмсетдин Хөсәенов 1885 елда университет басмаханәсендә шуны ук яңадан бастыра һәм аннан соң да халыкка кирәкле күп китаплар чыгара. Казан арты кешеләренең университет басмаханәсеннән шулай файдаланулары бик гыйбрәтле. Хөсәеновларда «Йосыф китабы»ның кулъязмасы да сакланган булган.

Бик кызыклы күренеш: минем туган авылым Гөберчәк — XIX гасырда Казан артының иң кара авылларыннан берсе булган. Әмма 1961 елда мин анда «Кыйссаи Йосыф»ның бер кулъязмасын таптым. Бу хәзер фәнни әйләнешкә кереп китте (37 сан белән). Каян килгән?— дип егерме елдан соң кабат кызыксынсам — Шиһабетдин Мәрҗани авылы Ташкичүдән икән. Безнең авылның революциягә кадәрге мулласы Хәким хәзрәт Ташкичүдә туып, Кышкарда укып, монда китерелгән булган икән. Кулъязманың юлы әнә шулай ачыкланды. Тукай әнә шул — мәшһүр поэманың бик күп таралган төбәгендә балалык елларының бер өлешен уздыра. Бу, әлбәттә, тәэсирсез калмый. Аның беренче шигырьләре шул үлчәүдә, шул метрикада язылган, Тукай бу поэмадагы ритм, рифманы үзенчә яңарта, заманча яңгырата. Үлчәү генә түгел, фикер йөртү формасын да алган.

Йусеф әйдүр: «Кәнганда дормыш идүм,
Бер вакыт-дә ул мәками күрмеш идем,
Кечеклекдә анда тәлим тормыш идем —
Бу тели — бән үгрәндем»— дәйүр имди.

Карале, Тукай искә төште бит: мин бераз торган идем, җирне аз-маз чәчкәләп урган идем...

Казан артының китапка, кулъязмага байлыгын раслаучы тагын бер дәлил бар: 1934 елда тарихчы галим В. Зәбиров (Тукайның апасы Газизә улы) татар кулъязмалары җыю буенча Тарих комиссиясе, Тарих - археография институты һәм Көнчыгышны өйрәнү институты тарафыннан Татарстанда оештырылган археографик экспедициягә җитәкчелек итә. Арча, Биектау, Балтач районнарында һәм Казанда эшләгән бу экспедиция тарафыннан «1203 кулъязма, бер мең данә чамасы документаль чыганаклар, 1859 басма китап җыела»[4]. Бу бит Казан артының гасырлар буе тупланган рухи байлыгы!

Сүз — мәдрәсә салу турында иде... Татарда зур, борынгы нәсел Яушевлар булган. Болар дәүләткүләм сәүдә эше йөрткәннәр... Троицк төбәгендәге Яушевлар XX гасыр башында үзләренең мәдрәсәсенә тарихта беренче буларак Земство акчасын алуга ирешү белән билгеле. Әмма Яушевларның да нигез башы — Казан артыннан. Сәүдә эше белән Кызылъяр шәһәренә (Петропавловск — Казахстанда) барып чыккан Габделбари Яушев — Казан арты Күшәр кешесе. Кышкар төбәгеннән. Ул Кызылъяр шәһәрендә мәдрәсә салдыра, ләкин үз малае Габделвәһапны ул, үсеп җиткәч, гыйлем эстәр өчен туган ягына — Кышкар мәдрәсәсенә җибәрә. Иптәш итеп Минзәлә ягы Кормаш авылыннан сәүдә эше белән килеп төпләнгән Мөхәммәтзарифның Кызылъяр мәдрәсәсендә укып яткан Әхмәт Уразаев дигән улын иярдә. Әхмәт белән Габделвәһап Кышкар мәдрәсәсендә 6-7 ел чамасы укып, җәйләрен Күшәрдә — Габделвәһапның туганнары Галибшә Яушевларда уздыралар. Атаклы «Таһир-Зөһрә»не шулай итеп Күшәр авылында торып Минзәлә тумасы Әхмәт Уразаев-Кормаши иҗат иткән. Шунда ук «Бүз егет» тә язылган. Күшәр-Кышкар тирәсендә бу ике поэманың икесен дә кулдан-кулга йөртеп укыганнар, күчереп язганнар. Тукайда «Таһир-Зөһрә» турында: «Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер», — диелә.

Мәдрәсә салу дигәннән... Халкыбызга бик зур укымышлы кешеләр әзерләшкән (Г. Ибраһимов, Ш. Бабич, Сәйфи-Кудаш һ. б.) «Галия» мәдрәсәсен салуга беренче акчаны шулай ук Казан арты сәүдәгәре, Битаман кешесе Садри Назиров биргән, ул кеше әле 1925 елда гына Казан шәһәрендә үлгән...

Татар халкына царизм шартларында белем учаклары ачу мәсьәләсендә кайбер меценатларның файдалы хезмәтен һич тә инкяр итәргә ярамый. Андрей Вознесенский болай ди: «Как обязано наше искусство меценатам. Художник хрупок. В отношениях с миром ему нужна поддержка...»

---

[4] Миннуллин Ж. Археограф Вәли Зәбиров.— «Казан утлары», 1983, 10 сан, 186 б.

Казан арты, гомумән, хәтергә, тарихка, кульязма китапларга бай булган. Олы Мәңгәр авылының «отставкада»гы мулласы Шәһиәхмәт Мөхәммәдиев, мәсәлән, 1878 елгы крестьян восстаниесендә катнашкан һәм үзе күргән канлы вакыйгаларны «Мирьат-эль вакыйгать» исемле («Булган хәлләрнең көзгесе») кульязма китапта яктырткан. Бу кульязма хәзер кайда икән?

Казан арты мәдрәсәләре акрынлап нәтиҗә бирә башлый. XIX гасырның беренче чирегендә Габденнасыйр Курсави (1776—1818) Бохара схоластикасына беренче һөҗүмне ясый — кыска гына гомерендә ул (42 яшь) үз авылларында зур мәдрәсә ачуга ирешә, «Туры юлга өндәү» исемле китап яза, кыскасы, мөселман-татарлар дөньясын шау иттерә. Курсавиның үз заманында Казан һәм Казан арты кадимчеләрен ничек тетрәтеп торуы турында Мәрҗани «Мөстафад эль-әхбар» исемле хезмәтендә искә ала: «Мулла Әбүнасыйр Бохара галимнәренең һәммәсен бер тишеккә тыгып китте... Казан шәһәрендә Апанай Хафиз әуладыннан улан байлардан кияүләренә килер иде, ул гасырында улан Казан голәмасы дәгъвәт иделдектә мәҗлесеннән качарлар икән. Бервакыт Мусабай мулла Фазылны иртә белән чәйгә алмага җибәреп, кыраеп килеп җиддекдә хадимдән: кунак, я мәҗлес бармы, дип сорагач, юк, Курса мулласы гына бар, дип җавап биргәч, бәла тәукыйф (кулга алынган кебек — М. М.) җәяүләп Яңа Бистәгә кайтып китмеш... мулла Җамалетдин әл-Сабавиның: һай шул нәрсәне Бохарада алып кына куймадылар лабаса, дидекене нәкыль кылыр иде»[5].

Курсави мәдрәсәсенең даны еракларга тарала, болар — Кышкар һәм Курса — урманлы, ташлы басулы Казан артында ике йолдыз булып калкалар. Әдәбият тарихында Һибәтулла Салихов дип йөртелгән шагыйрь дә (1794—1867) Оренбург тирәсендәге гыйлемгә генә риза булмыйча Курса мәдрәсәсенә (XIX гасырның 20 еллары), аннан Кышкарга килеп белем күтәрә. Аның мәшһүр шигыре «Тәндә җаным», ихтимал, Курса-Кышкар белем учакларын күргәч язылгандыр:

Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер, белмәдем,
Үтте гомрем, барысы хосран икәндер, белмәдем.

(Миһман — кунак; хосран — үкенеч.)

Казан артында әле Дөбъяз төбәге дә бар. Кайбер егетләр, Кышкар, Курсага гына риза булмыйлар (шул ук Шиһабетдин Мәрҗани), белем эзләп әллә кайларга чыгып китәләр: әйтик, Бәрәзә егете Хәмзә бине Мөхәммәт (Хәмзә Бәрәзәви 1775—1827) Бохарада гыйлем алып, аңа гына риза булмыйча, Кабулга китә. Кабулга китеп гыйлем эстәүче бер ул гына түгел: 1796 елда Кабул мәдрәсәләрендә, китапханәләрендә Утыз Имәни дә гыйлем эсти. Хәмзә Бәрәзәви исә, Урта Азия, Кабулда йолдызлар гыйлемен өйрәнә, халык арасында «Хәмзә мөнәҗҗим» («Йолдызларны белүче») дип шөһрәт ала. Бәрәзәгә кайта, әмма үзенең астрономия буенча белеменә ихтыяҗ күрми, шуңа күрә Казан-Бохара юлында сәүдә эшенә керешә. Астрономия буенча белгечлеген исә үзенең туганы — гыйлемгә хиреслеге булган Фәйзулла бине Мортазага (1781—1851) тапшыра, өйрәтә. Фәйзулла — Арча юлы өстендәге Мөндеш авылы егете. Агасы Хәмзәдән астрономия генә түгел, үз заманының дәрәҗәсенчә югары математиканы да өйрәнгән була. Курса мәдрәсәсенә килеп (ике авыл арасы 10—12 чакрым гына) Әбүннасыйр Курсави лекцияләрен тыңлый, бераздан үзе шунда укытучы булып кала, дәрес әйтә. Димәк, Курса мәдрәсәсендә астрономия, югары математика (риязият) буенча заман таләбенчә мәгълүмат бирелгән. Фәйзулланың үзе эшләгән астролябиясе (почмаклар, градуслар белән үлчәп, йолдызларны табу коралы — секстант) Мәрҗанинең эш бүлмәсендә сакланган. Фәйзулла мөнәҗҗим үзе ясаган кораллар белән эш итеп ай һәм кояш тотылышы, һава хәлләре үзгәреше турында алдан хәбәр бирергә өйрәнә, табель-календарь эшли, сәгатьләр поясын яза. Үзенә алмаш та хәзерли. Галимлекнең иң күркәм бер сыйфаты инде ул. Лаеш өязе Кече Әшнәк авылыннан Курсага укырга килгән егет Гатаулла — еллар буе Фәйзулла мөнәҗҗимнән математика, астрономия өйрәнә һәм Курса мәдрәсәсендә үзе дә озак кына укыта (1830—1840 еллар тирәсе — Г. Әшнәки). Йолдыз гыйлеме дигәннән, бик кызыклы күренеш: Казан артының урман эчендәге иң караңгы бер авылында — Күлтәстә — яшәгән мулла Шәмсетдин Күлтәси (1856—1930); безнең галимнәр аны ялгыш «Көлтәси» дип йөртәләр, чөнки

[5] Мәрҗани Ш. Мөстафад эль-әхбар. 2 т. Казан, 1900. 169—170 бб.

гарәп алфавитында «ө» белән «ү» һәм «у»ны белдерү өчен бер үк хәреф) йолдызлар, кояш, ай хәрәкәте турында китап язган. «Хикмәте җәдидә» исемле ул китап Казанда 1899 елда басылып чыккан һәм университет профессоры Н. Ф. Катановның мактаулы рецензиясенә лаек булган. Ш. Күлтәсинең фәлсәфә, мәгърифәт, гыйлемлек турында байтак китабы Казанда басылган. Болар: «Һәйәте җәдидә» (1896), «Мофассал һәйәте җәдидә» (1900), «Хәлемездән шикаять» (1903) һәм «Мәктәп баласы яхуд Сәхилә әби» (1909).

Казан артының татар халкын астрономиягә өйрәтүе һәрхәлдә кызык күренеш. Моңа сәбәп ни? XIX йөз башында Казанда мәшһүр университет ачылуның игелекле йогынтысымы? Курсави, Мәрҗаниләрнең татар акылын шәригать кысаларыннан азат итү буенча эшләгән эшләренең нәтиҗәсеме? Ике сәбәпнең (бәлки башка бик күп төрле) нәтиҗәсеме?

Казан артындагы сәүдәгәрлек, юл йөрү белән бәйле хезмәтләр фәннең башка өлкәләренә дә ихтыяҗ тудыралар. XIX гасыр башында Әгнәдә туган Габделхәким Габделрәшид углы Дөбъяз төбәге Мәмсәдә башлангыч белемне алгач, Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый; аннан Казан артыннан күчеп киткән халыкның балаларын укыту өчен Троицкига килеп, шундагы мәдрәсәдә дәрес әйтә. 1861 елда ул татарча география картасын бастыра, ул картада Европа, Азия кыйтгалары (сәүдәгәр татарлар өчен әлегә Америка, Африка, Австралия кирәк түгел) төшерелгән була.

Шунысы кызык, Кышкар, Курса мәдрәсәләрендә белем алганнарның бер төрлесе Казан, Троицк, Оренбург якларына китә. Татар мәгърифәтчесе, И. А. Крылов мәсәлләрен татарчага тәрҗемә иткән, әдәп-әхлак буенча күп кенә хезмәтләр язган Таип Яхин да — Кышкар шәкерте. Кышкарда укуны тәмамлагач ул Казанга килеп белемен күтәрә һәм Татарская учительская школада ислам дине курсын укыта башлый (Ш. Мәрҗанидән соң). Әмма Кышкар тәрбиясе үзенекен эшләгән була инде: 1910 елның 22 мартында Таип карт үлгәч матбугатта мондый хәбәр күренә: Таип абзый юаш, вакарьле кеше иде. Мәктәптә Таип мулла мөгаллим булганнан бирле шәкертләр дин гыйльменә бер көлке, әллә нинди аңлануы мөмкин булмаган сүзләрне бикләү дип кенә карый башлаганнар иде. «Таип абзый имтихан алдында шәкертләргә бары сораган бер нәрсәгә тукталмыйча «лыбыр-лыбыр» җавап бирүләрен үтенә торган булган». Шулай итеп, хәйләне аңлаган шәкерт имтихан билетында чыккан «тәбарәк» урынына «Ясин» сүрәсен укып бирә икән, Таип карт моңа әйбер әйтмәгән: имтихан вакытында утырып торган русларга барыбер ич».

Кышкар әнә шулай тәрбияләгән.

Кышкарда Тукайның әтисе дә укыган. «Минем атам... 14-15 яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә китеп, анда хәтме көтеб кыйлырга (укып тәмам итәргә — М. М.) гадәттә ничә сәнә кирәк булган булса, шулкадәр торып, карт атасы тере вакытта ук авылымыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр» («Исемдә калганнар»). Гомумән, Тукайның биографиясе, тегеләйме-болаймы Кышкарга килә дә бәйләнә, килә дә бәйләнә. Аның Кырлайдагы остазы Фәтхерахман Гобәев — Кышкар шәкерте. Ул — Габдулланың атасы белән бергә укыган. Уральск шәһәренә барып төшеп «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә керсә — мәдрәсә хуҗасы Мотыйгулла Төхфәтуллин — Кышкар шәкерте. Яхшымы — яманмы, Тукай тирәсендә гел кышкарлылар. Анда төрле кеше булган, алдарак бу турыда да әйтелер...

Мәҗит Гафури, яшьлегендә күп мәдрәсә күргән кеше, «Беренче озын юл җиһанда — Себер тимер юлы» дигән шигырендә, бераз үкенгән сыман, кече күңеллеләнеп болай яза:

Укыган мәктәбем Троицкида.

Баралмадык Бохара һәм Кышкар, Казан.

Ул вакытта мәгърифәтче шагыйрь өчен, димәк, Кышкар мәдрәсәсе абруйлы уку йортларыннан исәпләнгән.

Казан арты тагын кемнәрне «очырган?» Бик күпләрне. Заманында шәһәр һәм шәһәр тирәсеннән күчеп килгән халык җир, крестьян хезмәте белән физик һәм рухи яктан баеп потенциаль энергия туплаган. Күп гасырлар буе тупланган бу энергия XIX гасырда матур нәтиҗәләр биргән. Арадан берсе — Дөбъяз төбәге егете Мөхәммәтгали Мәхмүдев (1824—1891) Мәмдәл волосте Сөләнгер авылында крестьян гаиләсендә туып, Сөләнгердә һәм Казан мәдрәсәсендә белем алып, мәшһүр Казан университетында укытучы булып эшли башлый. XIX гасырда — крестьян малае университетта укыта! Лобачевскийлар, Готвальдлар эшләгән гыйлем пайтәхетендә Казан арты егете Гали Мәх-

мүдев гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнүче студентларга каллиграфия укыта, дәреслекләр төзи («Татар телен өйрәнүгә практик кулланма»). Бу китап турында үзәк рус матбугатында уңай рецензия күренә. Моннан тыш ул рус теленнән татарчага берничә брошюра тәрҗемә итә, русча-татарча сүзлек төзү эшенә керешә. Казан арты, шулай итеп Казанга белем бирә. Белем бирә, кеше бирә.

Казан арты — Кышкар мәдрәсәсе Казан шәһәренә, татар культурасына бик тә кирәкле тагын бер кешене әзерләп биргән. Ул — Олы Мәңгәр егете Габделмәннән Рахманколый. Кышкардан туп-туры Казанга килә. Җәяүләп. Татарская учительская школага кереп белем ала, Мамадыш өязе Олы Шыңар авылына барып яңача укыта башлый. Яңача укыткан мөгаллимне кыйныйлар, өркетәләр. Габделмәннән (1860 елда туган) Казанга күчеп килә. Татар мәктәпләре өчен уку китаплары чыгара, Пушкинны, Крыловны тәрҗемә итә, балалар үстерә. Бу балаларның һәрберсе татарлар арасындагы прогресска хезмәт күрсәтәчәк: Каюм, Нәҗиб, Солтан, Мәрьям. Егетләр 1905 ел революциясендә катнашачак, Солтан Рахманколый тәрҗемәче, сүзлекләр төзүче, җырчы, Тукайның якын дусты. Якташлар. Тукай белән бергә уздырган көннәр, төннәр. Бәләкәй Мәрьям аларны хәтерли — абыйсын да, Тукайны да. РСФСРның халык артисткасы Мәрьям Рахманкулова әнә шулай — этисе ягыннан — Казан арты «сандугачы».

Инде Г. Камалны да онытмыйк: ул Казанда туган, әмма әтисе дә, әнисе дә Казан артыннан. Әтисе бәхет эзләп Сикертән авылыннан килгән дә, үзеннән алдарак Казанда төпләнгән, Иске Масра авылы кешесенең (инде бай булган) кызына өйләнгән. Галиәсгар Сикертәнгә ничә тапкыр кайткандыр, Масрада бер кыш чыкканлыгы билгеле, әмма «Беренче театр»дагы тел, каламбур — Сикертәннеке. Димәк, әтисеннән. Бу авылга бүген барыгыз һәм теләсә кем белән сөйләшегез — Г. Камал комедияләренең тамырын шундук тоеп алырсыз...

Казан арты әдәбиятка тел биргән, кеше биргән.

Кеше дигәннән, тагын берәү: Нәкый Исәнбәт Казан артының бу хикмәтле кешесенә бәйле байтак мәзәк, мәкаль теркәгән. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, Н. Исәнбәтнең өч томлыгына Әтнә — Мәңгәр — Күәм зонасыннан күп хәзинә кергән. Бу — алда әйтелгән шәһәр-авыл фольклорының үзенчәлекле бер катнашмасы, сыгынтысы. Казан арты халкы игенне дә гыйлем белән иккән, аңа «кара эш» итеп түгел, акыл эше, «ак» эш итеп караган һәм шуңа күрә иген игү, ел фасылы, һава шартларына бәйле бөтен бер поэтик сүз байлыгы тудырган. Әйе, теге кеше бит әле... Рәхмәй тылмач. Тылмач — тәрҗемәче дигән сүз. «Татарга тылмач кирәкми» — дигән мәкаль «тәрҗемәче кирәкми» дигән сүз, бу — Урта Азиядә сәүдә белән йөргән Казан арты татарлары тудырган мәкаль. Чыннан да, Урта Азиядә сәүдә кылган татарга тылмач кирәк булмаган. (Бу сүз немец телендә Dolmetscher дип йөртелә, әллә немецтән татарга, әллә татардан немецкә?). Әмирхан Рәхмәтулла улы (1807—1874) Тукайның Өчилесенә якын гына Яңа Кишет авылында туган. Казанда белем ала — үзлегеннән өйрәнә, гарәп, фарсы, рус телләрен бик яхшы өйрәнә. Профессор Готвальд китапханәсендә тәрҗемәче булып утыра. Рус газеталары, рус китаплары укып дөнья хәлләре белән танышып бара. Казан губерна идарәсендә төрле эшләр башкарып дәүләт орденнары ала. Казан басмаханәләрендә яхшы кара, яхшы кәгазь белән мәктәп өчен кирәкле китаплар бастырып, Казан арты мәктәп-мәдрәсә укытучыларына шуны бүләк итүне үзенә бер шөгыльгә әйләндерә. 1839 елда беренче тапкыр «Кыйссаи Йосыф»ны, 1841 елда беренче «Горрәнамә» (табель-календарь), 1861 елда географик карта, болардан тыш төрле шагыйрьләрнең әсәрләрен җыеп «Диване ризаи» дигән китап бастыра. Ш. Мәрҗанинең якташы, фикердәше һәм замандашы буларак, ул да Казанның кара бае Ибраһим Юнусов белән конфликтта була. «Кыйссаи Йосыф»ның беренче басмасының ахырында мондый сүзләр бар: «Ушал Йосыф китабы» Казан өязе Яңа Кишет авылының Рәхмәтулла угылының хәраҗәте илән нәфгы гыйбаде мөслимин өчен, укыяннардан догаи хәер өмит итеп, Казан университетының Азиатский табгыханәсендә хәзинәлектән басма улынмыштыр, шәһре Казан, 1839 нчы елда вә гарәбия илән 1254 сәнәдә». Яңа Кишет авылы егете, шулай итеп, миллионлаган татар халкына классик поэма «Кыйссаи Йосыф»ны бастырып тарата! Шуның өстенә Арча янындагы Казиле авылы мәчете янгында һәлак булгач, Рәхмәй тылмач үз акчасыннан бу авылга кызыл кирпечтән яңа мәчет салдырып куя. XIX гасыр архитектура үрнәге буларак бу бина әле дә ха-

лыкка хезмәт итә: кирәк икән — клуб, кирәк икән — концерт залы, китапханә һ. б.

Рәхмәй тылмач артыннан күрше авыл егете — Орнашбаштан чыккан Корбангали Халиди (1846—1913) үрмәли. Анысы Кытай уйгурлары арасына сәяхәт итә, гыйлем-мәгърифәт эзләп Мисыр, Иран, Гыйрак, Иерусалим, Төркиядә йөри, күп китапханәләрне актара. «Яңа тарих сәхифәләре» дигән хезмәте 1889 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга, 1910 елда исә яңа хезмәтен «Тәварихы хәмсәи шәркыя» («Биш көнчыгыш иленең тарихы») бастыра. Чит җирдә — уйгурлар арасында 1913 елда үлеп кала...

1878 елда Казан артын дер селкеткән вакыйгалар булып ала. 1861 елгы реформадан соң авылда эксплуатация көчәя, аз җирле Казан арты халкы шулай Уральск, Троицк, Урта Азия, Оренбург якларына күпләп күчә. Авылларда күп җирле кулак катлавы оеша башлый, ярлы крестьяннар исә аларга кабалага көннән-көн күбрәк төшә, әләгә баралар. Шуның өстенә 1878 елда патша хөкүмәтенең «Мир җыемнары» турында инструкциясе чыгып, бу инструкция татар авылларына да таратыла. Инструкциядә татарлар гадәтләнгән «мәхәллә», «авыл» сүзләре урынына «епархия» дигән сүз кулланыла, янгынны кисәтү өчен авыллардагы калку урыннарга чаң куярга диелә. «Епархия», «колокол» дигән сүзләр татар агайларын сискәндереп җибәрә. Көчләп чукындыру түгелме бу? Шул шик астында Олы Мәңгәр авылы крестьяннары баш күтәрәләр.

1907 елда Тукай «Әлгасрел-җәдид»нең 2 санында «Локман Хәким сүзләре» дигән баш астында афоризмнар бастыра. Локман Хәким — легендар зат, нәкъ инде Хуҗа Насретдин кебек. Тукай аның авызыннан әйттергән булып, ихтимал, үз сүзләрен дә урнаштыргандыр. Арадан берсе: «Гадел солтан, тугъры казый, белгеч табиб, агым су, корылган базар булмаган җирдә тормак тиеш түгелдер». Акыл иясенең сүзләрен ахырдан алга таба санап барыйк: Казан артының базарларын, суларын күрдек — алары бар. Белешмәлекләр күрсәткәнчә, XIX гасырда Арчада бер доктор да булган. «Гадел солтан»нары да булган... Тарих Романовлар династиясенең никадәр «гадел» икәнен күрсәтте. В. И. Ленин Романовларның 300 еллыгы турында 1913 елда болай дип язды: «Патша карагруһлары һәм алпавытлар, бер көтү чиновниклар һәм буржуазия Романовларның «Россия»не талауларының... 300 еллык юбилеен бәйрәм иттеләр»[6]. Локман Хәким әйткән «тугры казый» исә — Казан губернаторы Н. Я. Скарятин кораллы отряд белән Казан артына үзе килеп төшә. Калганын бездә фольклорчы, галим, драматург, прозаик һәм шагыйрь Гали Рәхим сөйли. Г. Рәхим 1878 елгы крестьян восстаниеләренең тарихын язу өчен 1927 елның җәендә Олы Мәңгәргә килә. Ни өчен нәкъ менә Г. Рәхим килә? Г. Рәхимнең этисе Мөхәммәтшакир Габдрәхимов — Мәңгәр авылы крестьяны. Бәхет эзләп Казанга килә дә, шуннан мая туплап, сәүдәгәр булып китә. (З. Хәсәни һәм Р. Габдрахимоваларның (Г. Рәхимнең сеңлесе) миңа сөйләгән истәлекләреннән). Күп материаллар актара торгач, моны юкка чыгара торганы да очрады: 1934 елның августында НКВД канцеляриясеннән Г. Рәхимгә бирелгән белешмәдә «этисе — Мөхәммәтшакир Бикчәнтәй улы Абдрахимов, Лаеш өязе Олы Мәтәскә авылы крестьяны» диелгән. Бу ике факт мине бераз бутады. Шулай да, Г. Рәхимнең Казан арты белән бик нык кызыксынуы, восстание тарихын, Уразаев-Курмаши биографиясен өйрәнүе, 20 елларда Гыйльми Үзәк планы буенча «Бүз егет» операсы өчен либретто язарга тотынуы аның нәселе Мәңгәр ягыннан булгандыр дип уйларга нигез бирә.

1878 елгы чуалышларның нигезендә әлбәттә инде, беренче чиратта, социаль-экономик изү торган. Дини изү — сылтау гына...

Казан артында крестьяннар хәрәкәтенең аеруча көчле үзәген Мәмсә, Әтнә, Олы Мәңгәр волостьлары тәшкил иткән. Олы Мәңгәр волосте — анда 4000 ир кеше исәпләнгән. Халык гаделсезлеккә протест йөзеннән авыл старшиналарын, волость старшинасын урыннарыннан алып, яңаларны сайлый, полиция стражнигын кыйный. Халыкны тынычландырырга теләгән муллаларны да кыйнап ташлыйлар. Чиновниклар качып китәргә мәҗбүр булалар.

Әтнә волостенда 3500 ир кеше исәпләнгән. Анда да нәкъ шундый ук хәлләр була. Волость идарәсенә бәреп кереп андагы кәгазьләрне ертып ташлыйлар, алар старшина һәм писарь «1879 елдан чукындыру башланырга тиеш» дигән кәгазьне яшергән дип ышанып, шуны эзлиләр. Волость старшинасының печатен алалар һәм сандыкка биклән куялар.

[6] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә. 19 т., 208 б.

Мәмсә волостена 20 авыл кереп, анда 4000 ир кеше исәпләнгән. Анда да нәкъ шулай волость старшинасын алыштырудан башлыйлар. Теге приговорны таләп итеп старшина һәм писарьне кыйнап ташлыйлар. Волостьтагы 12 промышленникны, кире кайтсагыз, үтерәбез дип куып җибәрәләр.

Казаннан 500 кешелек атлы батальон белән губернатор Скарятин юлга чыга. Ул Олы Мәңгәр — Мәмсә — Олы Әтнә маршруты буенча уза. Крестьяннарны волость үзәкләренә җыялар. Тезләнеп, бүрек, кәләпүшләрен салдырып, губернаторны каршы алдыралар. Губернатор рәт араларында йөри, крестьяннарны «этләр» дип сүгә, сакалларын йолкый, күнитек белән тибә. Чиновникларга кул тидергән кешеләрне сайлап алып камчы белән ярдыра. Бәхтияр авылыннан Шакир Исхаковны, Орнашбаштан Шәмсетдин Сәйфетдиновны тотып (элек кулга алынган кешеләр) Олы Мәңгәргә Скарятин янына китерәләр. Олы Әтнәгә килгәч, губернатор волость идарәсен саклаган Хәсән Вәлиуллинны, Гобәйдулла Әхмәдуллинны, Кәлимулла Әхмәдуллинны, Гыйззәтулла Миңлебаевны үз кулы белән кыйный. Йөзләгән крестьян суктырыла, судка бирелә, каторгага озатыла. Казан арты таза, гайрәтле ирләрдән бушап кала. («Коммунизмга» газетасы, 1979 ел, 134 сан, Арча).

Тукай туарга нәкъ 8 ел вакыт бар әле...

Бу вакыйгалар турында восстаниене үз күзе белән күргән Шаһиәхмәт мулла Мөхәммәдиев сөйли. Г. Рәхимнең бәхетенә каршы, 80 яшьлек картның хәтере әйбәт була...

«Тугры казый» Казан артыннан әнә шундый канлы экспедиция белән уза. Иң асыл уллар бу вакыйганың корбаны булалар.

Казан губернасындагы крестьян чуалышлары Т. Гыйззәтнең «Ялкын» («Фәрхиназ») драмасына нигез була. Анда мондый юллар бар:

Исправник: Господин ротмистр! Боларны яклап Тигәнә, Мәңгәр авылларында көчле восстание... Генерал-губернатор Скарятин хәзрәтләре биш йөз кешелек гаскәр белән Казаннан Спаска киткән. Сезгә һич кичекмәстән Мәңгәр волостена барырга әмер иткән.

Бу вакыйгалардан соң нәкъ унөч ел үткәч, Петербургның хәрби ахуны Гатаулла Баязитов рус матбугатында патша администрациясен ялгышлар җибәргәне өчен тәнкыйть итәр: «Инде килеп, калку урыннарга чаң урнаштыру мәсьәләсен алсак, монда сүзнең мәчет манараларына чаң куйдыру турында бармаганын татарларга аңлатырга кирәк иде. Шулай ук: бер волостька рус теле дәреслекләре җибәргәннәр, ә китап ахырында христиан догалары урнаштырылган. Йә, нигә инде бу?» («Санктъ-Петербургские ведомости», 1891, 96 сан.)

Казан арты татар культурасы, мәгърифәте мәйданына әле тагы і берничә шәхес бирә. Шул чорда ул төбәктә тагын ике кызыклы кеше туа: Солабаш авылында Хәсәнгата Габәши һәм Бикнарат авылында Хәбибулла Әхмәдуллин.

Хәсәнгата Габәши мәдрәсә белеме алганнан соң Казандагы Вәли мулла мәдрәсәсендә (кара фикерле мулла) хәлфәлек итә. Көннәрдән бер көнне үзенең якташы Шиһабетдин Мәрҗани белән әңгәмәдәш булу бәхетенә ирешә. Бер-ике авыз сүздән кешене таный һәм «диагноз» куя алу сәләтенә малик булган Мәрҗани ахырдан болай ди: «Вәли мулла мәдрәсәсендә шундаен ачык фикерле шәкертнең булуына тәгаҗҗыб иттем (гаҗәпләндем), һәм шул мәдрәсәдә канәгать итеп торуына да тәгаҗҗыб иттем». Аларның танышлыгы күптәннән килә: Мәрҗанинең атлары шәп булган, җаны теләгән вакытта ул Казан артына кайтып, нәсел-нәсәбенең хәлен белеп йөргән. Хәсәнгата болай дип искә ала: «Мәрхүм илә (Мәрҗани үлгәч язган.— М. М.) без авыл юлларында очраша торган идек. Күбрәк очрашу Югары Сәрдә илә Соңгыр арасында була иде. Бервакыт кыш көне шактый буран көндә, аның — Казанга кайтышы, безнең әткәй илә Иске Йорт авылына барышымыз иде. Ерактанрак яхшы пар кара ат, мичәүләп повозкага җиккән, кучер утырткан берәү күренде. Безгә ун сажень микъдарда калгач, бер казылма янында мичәү аты читкә керде дә, кергәннән кереп, төп атны да читкә тартып төшереп, үзе карга батып егылды. Әткәм мәрхүм миңа: «Кем дә булса олугъ кешедер, чыгарыш!»—диде. Мин дә өске киемемне салып йөгереп бардым да, чанада кем икәненә күз салмастан, тизрәк мичәү атны башыннан тотып, бераз мәшәкать илә булса да, юлга чыгардым, төп ат та чыкты. Менә чанадагы белән күзебез-күзгә төште. Мәрҗани хәзрәтләре икән. Ул да буран араларыннан минем күренүемне гаҗәпсенеп: «Ни гаҗәп тәсадыф (очрашу)! Мөшкел вакытыбызда җитештең. Син Хәсәнгатамы? — диде.— Әйе, хәзрәт, мин Хәсәнгата,— дидем.— Хәз-

рәт, сезнең урында бер ишан булса, ат башында бер мөрите булса иде, әлбәттә, мине Хозыр дип санарлар вә ишанның олугъ кәрамәтеннән хисап итәрләр иде бит! — дидем дә, көлештек, соңра юлыбызга киттек...

Х. Габәши, күрәсең, Мәрҗани тәэсирендәдер, үзен тарих гыйлеменә багышлый, Мәрҗанинең әдәбият-сәнгатькә кагылышлы фикерләрен пропагандалый. Х. Габәшинең тарих буенча хезмәтләре рус мөстәшрыйкләренә (востоковед) таныш булган. Мәсәлән, академик В. В. Бартольд Себер буенча 1913 елдагы сәяхәте вакытында аның хезмәтен өйрәнгән. Һәм андагы кайбер хаталарга игътибар иткән («Вакыт», 1913, № 1240). Х. Габәши Уфадагы Диния назарәтендә казый булып торганда җыр-музыка мәсьәләсендә кара фикерле «Дин вә мәгыйшәть»челәр белән конфликтка керә. 1905 ел революциясе белән рухланган татар яшьләре һәр җирдә музыкаль кичәләр оештыра башлагач, кадимчеләр дин, шәригать дип бу кичәләрне тыймакчы булалар. Әмма Диния назарәте казые Х. Габәши яшьләрне яклап чыккач, югалып калалар. Тарихчы галим исә болай ди: халыкны җырсыз, музыкасыз калдырсаң, ул үлә. «Вакыт» газетасы Габәшине яклый, кадимчеләр исә моның өчен «Вакыт»ка һөҗүм итәләр. («Дин вә мәгыйшәт», 1915, 20 сан). Казан арты Солабаш авылыннан чыккан галим шулай итеп татар музыкасын шәригать кануннарыннан азат итәргә булыша. Шуның өстенә, үзенең улы Солтанны музыкага әзерли. Солтан Габәши — татарның беренче профессиональ композиторы булып җитешә, «Сания» операсын яза, «Эшче» операсының соавторы була, мәшһүр «Кәккүк»не иҗат итә.

Татар музыкасын теоретик һәм практик нигезләү өлкәсендә Казан артының роле искиткеч зур. Мәрҗани «музыка хәрәмме, хәләлме» дигән мәгънәсез сорауны бер селтәнү белән көн тәртибеннән алып ташлаган. «Музыканың... дөрес түгеллегенә шәрган дәлил юк, бәлки сандугач кеби тавышлары матур кошларның тавышларын ишетмәк вә тыңламак дөрес, вә тавышларның хәйваннардан чыкмакы берлән җансыз нәрсәләрдән чыкмакы арасында аерма юк».

Мәрҗани бервакыт В. В. Радловның өендә булып кайткач, кызларына болай дигән: «Радловның кызлары... музыка белә икән. Сез дә дөм сукыр булып үсмәгез».

Мәрҗанинең фикерен дәвам итеп Хәсәнгата Габәши яза: «Музыка табигатькә тәэсир итә, халыкны күркәмләндерә, вәхшилекне бетерә, канны сафлый, фикерне киңәйтә — бонлар шиксездер, фән күрсәтүе илә сабиттыр».

Дөбъяз төбәге Бикнарат авылы... Кечкенә генә авыл. Әмма шәхесне зур авыл бирә дигән зарурилык кайда? 1875 елда Бикнарат авылында туган Хәбибулла Әхмәдуллинга да музыка хисе бик якын була. Үзлегеннән музыкага өйрәнеп ил буйлап чыгыш ясап йөри. Кушаматы — «Кара малай». Чәченә чал кергәч тә аны шулай дип йөрткәннәр. Скрипка остасы Хәбибулла үзенең осталыгына мәйдан таба алмый, мәйханәләрдә, чәйханәләрдә уйнап көн итә. Гаҗәеп талантлы әсәр «Аккош» көен иҗат итә. Бу көйне (моны марш дип тә, вальс дип тә йөрткәннәр (музыка коралы осталары Минкин, Г. Сәйфуллин «Стэлла» пластинкасына язып алалар.

1883 елда Этнә авылында Әхмәтгәрәй Хәсәни туа. Бу кеше, Казанда «Гасыр» нәшрияты оештырып татар прогрессив культурасына зур өлеш кертә. 1912 елда Тукай, Әмирхан белән әдәбият, сәнгать журналы «Аң»ны чыгара башлый, русча-татарча сүзлекләр бастыра. Этнә янындагы Түбән Киек авылыннан Уральскига сәүдә эше белән киткән Ногман агайның 1887 елда кызы туа — аңа Зәйнәб дип исем кушалар. 1904 елда ул Әхмәтгәрәйгә кияүгә чыга һәм «бирнә» акчасын «Гасыр» нәшриятын җайга салу өчен исраф итә. Тукайның Клячкин шифаханәсеннән язган иң соңгы хатлары — Хәсәниләргә.

Крестьян восстаниеләренең дәһшәтле, күз яшьле вакыйгалары халык йөрәгендә кара кан булып укмашкан хәсрәтле Казан артында — шул атмосферада — 1886 елда тагын ике бала туа. Берсе — Кушлавычта, Мөхәммәтгариф хәзрәт гаиләсендә, булачак шагыйрь Тукай. Икенчесе Шиһабетдин Мәрҗани нәселендә, Ташкичү авылында хәлфә гаиләсендә — Мәхмүт Галәветдинов. Әдәбиятта — Мәхмүт Мәрҗани. Башлангыч белемне әтисендә алгач Казанга мәдрәсәгә килә, 1903 елда Әстерханда балалар укыта. Шунысы характерлы, яшь журналист үзенең эшчәнлегендә беренче көннән үк революционер Зариф Садыйков йогынтысында була. З. Садыйковның яшерен исеме — Ибраһим Моратов. Бу шәхес турында сүз чыккач (М. Галәүнең дөньяга карашын тәрбияләүдә аның роле зур була), кызыклы гына ике-өч документны телгә аласы килә. З. Садыйков — революциядә катнашкан өчен сөрелгән

социал-демократ. Әстерхан губерна жандарм идарәсенә байтак мәшәкать тудырган ул. 1911 елның февралендә Әстерхан губерна жандарм идарәсе начальнигы Уфа ГЖУ начальнигына «таныш белү» өчен бер фоторәсем җибәрә: «Ибраһим Моратов псевдонимы астында 1908 елда Әстерханда күренекле социал-демократлар арасында кайнашкан һәм матбугатта Әстерхан мөселманнары арасында пропаганда алып барган татарның фотография карточкасын сезгә юллап, 1909 елда бу кеше нинди исем астында сәяси эш буенча Уфада төрмәдә тотылганын хәбәр итүегезне сорыйм». Уфаның җавабы: «Ибраһим Моратов ул — Әхмәттин Тумаркин». Тагын бер җавап: «Карточкадагы шәхес — 1035 нче статья буенча җавапка тартылган Оренбург мещаны Габдрәүф Ниязбаев, ул ук — Казанец, ул ук — Кәримов»[7].

М. Галәүнең Әстерхан чоры революцион вакыйгаларга бай булган! Ул чыгарган журнал «Туп» кыска гомерле була, патша властьлары аны ябалар. М. Галәү Оренбургка китә һәм анда сатирик журнал «Кармак»ны чыгара башлый, китап кибете ача.

Тагын кемнәр чыга Казан артыннан? 1886 елда кечкенә генә Орнаш (Әрнәш) авылында Зөләйха исемле кыз туа. Бераздан без аны «Сәйяр» труппасында күрербез. «Сәйяр»ның күренекле артисткасы Зөләйха Богданова Тукайның яшьтәше һәм якташы — совет властеның беренче елларында театр сәнгатен үстерү эшендә күп көч куя. (Зөләйха 1950 елда Буада үлә). Аның белән бергә «Сәйяр»да тагын бер кыз уйный: анысы Зөләйханың якташы — күрше Утар Аты авылыннан Нәгыймә Таҗдарова, 1888 елда туа. Крестьян Әхмәдулла абзыйның сигезенче баласы. Бәхет эзләп Казанга килә, Гайниҗамал исемле игелекле бер карчыкка квартирага керә һәм әтисе биргән акчага тегү машинасы сатып алып тамак туйдыра. Нәгыймә укый-яза белә, Казан арты халкына хас булганча хезмәт итәргә күнекмәсе зур була, шуның өстенә яшь, чибәр. Укытучы булырга җыена. Әмма, очраклы рәвештә «Сәйяр» артисткасы Мәрфуга Иманская белән таныша һәм Мәрфуга аның турында Габдулла Кариевка сөйли.

...Утар Аты кызының күзләре Кариевны тетрәтә. Мондый күзләр сирәк була! Бу — борынгы Болгар кызларының гүзәллеге! Кариев аны сәхнәгә әзерли башлый. Ләкин Нәгыймә моңа әзер түгел. Күрсәтелгән көнгә «Шәрык клубы»на килеп, ул Кариевка болай ди:

— Мин сезнең тәкъдимнән баш тартам, укытучы буласым килә...

Сәхнә псевдонимын — Әхмәдуллина урынына «Таҗдарова»ны аңа Кариев табып бирә. Нәгыймә башта кечкенә рольләрдә чыгыш ясый. Булдыра алмый — ташлый. Бераздан Кариев аны кабат чакыра.

— Әгәр дә аллага шулай ялынсам, ул да минем сүземне тыңлар иде,— ди мәшһүр режиссер.

Н. Таҗдарованың сәхнә биографиясе Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» әсәре буенча эшләнгән спектакльдә Рокыя образын иҗат итүдән башлана. Тукайның ике җан дусты — Ф. Әмирхан һәм Г. Кариев бу рольне аның якташына — Утар Атының гүзәл, сихри карашлы принцессасына уйнатуны кирәк табалар. Н. Таҗдаровага ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Кушлавыч авылыннан чыккан Мөхәммәт Вәлишин дә артист булып китә. Иренә һәм бөек шагыйрь туган авыл исеменә ихтирам йөзеннән аның хатыны артистка Рөкыя үзенә псевдонимны әллә каян түгел, Тукай туган бишектән сайлап ала: Рөкыя Кушловская...

Тарих кызык: Зөләйхалар, Нәгыймәләр, Тукайлар туып ята. Әле кемнең кем буласын берәү дә белми. Әле Арчадагы икееллык һөнәр училищесында укып йөргән тәртипсез малай — Әмә тавыннан (Казан бистәсе) килгән Федяның да кем буласын белгән юк. Казан малае столярлык эшенә өйрәнә. Әмма дәрес вакытында берәр артык хәрәкәт эшләдеңме — хезмәт укытучысы туптуры фуганок белән суга. Гел кыйнау... Федя бу хәлгә чыдый алмый, китап төпләү классына күчә. Анда да кыен. Көннәрдән бер көнне Федя кача. Арчадан җәяүләп Казанга чыгып кача. Иске Чүриле авылына килеп җитәр-җитмәс атка атланган училище каравылчысы аны куып җитеп Арчага кире алып кайта. Федяны яткырып суктыралар. Кемне кыйныйлар диген? Бөтенроссияне һәм Парижны таң калдырачак җырчы Федор Шаляпинны...

[7] ТАССР УДА, 51 ф., 1 тасв., 175, 177, 178 эшләр

«Ул заманда Арчада яшәвемнән бер генә әйбәт истәлек калган — ул да булса — шимбә көн мунчада чабына идек һәм мунча янындагы карга чыгып ауный идек». Моны инде ул Парижда яза.

Утар Атыда, Әрнәштә, Кушлавычта Зөләйхалар, Нәгыймәләр, Габдуллалар туып ята, бишектә тибрәнәләр, Федяны училище идәненә яткырып чыбык белән туныйлар, Сембер шәһәреннән килгән 17 яшьлек Володя шул вакытта царизмның реакцион кануннарына каршы протест белдереп, университетта сходка оештыра. Болар барысы да бер-ике елда, Казан артында һәм Казанда...

Инде тагын кемне бирсен Казан арты дисәң — бәрәкәтле яктаниләр булмас... 1900 елны Казанда һөнәрче Җамалетдин Бикчәнтәев гаиләсендә бер малай туар. Чүәкче Җамалетдин — Казан арты Өбрә авылыннан. Шәһәргә бәхет эзләп килгән. Яңа туган малайга Салих дип исем кушалар. Нибары ике дистә ел үтәр — аның исеме инде Сәйдәшев дип яңгырар. Казан арты татар халкына әле алга таба да сәнгать кешеләрен бирер.

1895 елның 26 декабрендә Дөбъяз төбәге Чыршы авылының Гайниҗамал апа бер малай табар — ул малай татар сәхнәсенең сандугачы Ситдыйк Айдаров булып җитешер, татар музыка сәнгатен үстерүдә якташы Солтан Габәши белән җиң сызганып эшләр. Ситдыйкның биографиясе бик кызык: аның әнисе Чыршыдан Казанга килеп Зәңгәр Мәчет мулласы Касим хәзрәткә асраулыкка керә. (Ахырдан бу хәзрәт Тукайны күмгәндә кабер өстенә басып шагыйрьнең «Васыятем» дигән шигырен укый.) Мулла абзый Чыршы кызын Тау ягының Иске Чәчкаб авылы егете солдат Хәнәфигә кияүгә бирә, алар дөньяга Ситдыйкны китерәләр. Ситдыйкның музыкаль тәрбиясенә Сәйдәшев зур йогынты ясый, Ситдыйк исә, үсә төшкәч, Тукайның остазы Мотыйгулла Тәхфәтуллин кызы Галия Кайбицкаяга өйләнә... Галия Уральск шәһәрендә Тукай газета-журнал чыгарып ятканда туа.

Чыршы — гомумән, хикмәтле, куәтле авыл. Легендаларга караганда, Пугачевның бер кучеры Әбдрәшитов — шул авыл егете. Ахырдан Пугачев офицеры — Рус Алаты егете белән бергә алар судта булалар. 1905 елда Әтнә төбәге кечкенә Шашы авылында туган Ильяс Әүхәдиев тә скрипка остасы, сәнгать белгече, педагог булып җитешер. Өбрә — Өмбе — Әлдермеш төбәгеннән совет чорында Әнвәр Бакиров, Хәй Вахитлар чыгар.

Ләкин болары инде соңыннан...

Игътибар иткәнегез бармы? Гомеренең иң соңгы айларына кергәч язган шигырьләрендә Тукай — Атлант кебек. Бер генә вак фикер, бер генә «бытовизм» юк. Тукай 1913 елга чыккач пәһлеванга әйләнә дә куя. Күңелен аның кемнәр биләгән соң?

Толстой... Некрасов. Мәрҗани. Пушкин, Лермонтов, Жуковский. Толстой фикере белән бер-бер артлы дүрт шигырь, «Суык» поэмасы. Китап төзүче Тукайчылар юри әйтмиләр: Некрасовка ияреп язылган ул «Суык» әсәре. Һәм шулар арасында — Мәрҗани. Ник алай, нигә гомеренең соңгы айларында гына Тукай аны телгә ала? Бер дә шикләнмичә әйтергә мөмкин ки, Тукай 1913 елда кабат һәм иң көчле «прозрение» кичерә. Тарихны кабат күзаллаганда яңадан Толстой. Клячкин шифаханәсендә язган Тукайның иң соңгы шигырьләреннән берсе — «Толстой сүзләре». Тукай анда намуслы хезмәт белән яшәргә, кеше малын алмаска чакыра. Толстойның кайсы сүзләрен нигезгә алган соң ул? Ихтимал, менә боларындыр: «Кешене хезмәт кебек башка берни дә яхшырта алмый. Хезмәттән башка кеше үзенең кешелек дәрәҗәсен саклый алмый».

Толстой яза: «Яшәмәктә булган тормыш тәртибе җимерелергә тиеш... Капиталистик строй бетерелергә һәм социалистик строй белән алыштырылырга тиеш» («Огонек», 1976, № 12). Тукайда шул ук: «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм».

Тукай гомеренең соңгы айларында, гомумән, Толстой дөньясына керә. Шул ук чорда Тукай үзенең уй-хисләре белән Мәрҗанигә килеп чыга.

...Алар — Мәрҗани һәм Тукай — якташлар гына түгел. Аларның татар халкына иткән файдалары, ясаган тәэсирләре охшаш. Биографияләренең башлангыч адымы уртак. Тукай гомренең ахырында әнә шулай Мәрҗанине ача. Биографияләре дидек:

Шиһабетдинга 5 яшь тулганда аның әнисе Бибихәбибә баладан үлә. Соңгы минутында улын чакырып китереп аның башыннан сыйпый. Бер шәкерт исә Шиһабетдинны әнисенең җеназасы артыннан күтәреп алып барган.

Тукай да: «Мин монда әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан, үкереп җылый-җылый, йөгереп чыгып: «Әнкәйне бирегез!» — дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне (хәтерләвемне) язамын» («Исемдә калганнар»).

Казан артында әнә шундый биографияләр бар. Ләкин биографик параллелизмнар моның белән генә бетми. Бөек биографияләрдә һәрвакыт охшашлыклар була. Казан ягы биографияләргә, гомумән, бай. Ул биографияләр тегеләйме-болаймы, Казан артына параллель сорыйлар. Бөек шәхес Николай Лобачевский бар. 1830 елда Казан тирәсендә ваба авыруы таралгач, университет ректоры Лобачевский шул авыруга каршы көрәшү өчен галимнәрдән, табиблардан отряд оештырган, махсус халат, бияләй киеп дезинфекция төнәтмәләре ясаган, авылларга үзе чыккан, профилактика уздырган. Күпмедер дистә еллар узгач ваба авыруы Казан губернасына тагын һөҗүм иткән, әмма бөек математик инде юк. Татар авылларына профилактика белән килгән «урыс докторларын» надан муллалар кертмиләр, татар хатынының гәүдәсе — бөтен җире — гаурәт. Татар хатыны — авырый башлаган тавык кебек. Тавыкны бит беркем дә дәвалап тормый: я ул үлә, я аны чалып ташлыйлар. Ваба авыруы таралган көннәрдә Казан губернасында бигрәк тә хатын-кыз кырыла. Әмма, Ш. Мәрҗани губернатор кәнсәләреннән торып, татар муллаларына фәтва күндерә: наданлыкның корбаны булмагыз, докторларны авылга кертегез, дәва чараларын уздырырга ярдәм итегез... ди.

Алар — Лобачевский, Мәрҗани, Тукай — әллә ничек кенә бергә бәйләнгәннәр, бер үк юлдан баралар, Казан губернасының язмышын ягъни халык язмышын өчесе өч чорда, бергәләп кайгырталар. Лобачевский патша реакциясенең җәберен күреп, шәхси фаҗига кичереп (яраткан улы үлә), эшеннән алынып авыру хәленә килгәч, мәшһүр «Пангеометрия» дигән әсәрен кешегә әйтеп торып яздыра: үзе үлем түшәгендә. Мәрҗани үз шәкертләрен чакыртып үләренә санаулы көннәр, сәгатьләр калганын белә торып, тарихи хезмәтләрен әйтеп яздыра; Тукай Клячкин шифаханәсенә кергәч үз иҗатының зениты булган шигырьләрен, мәкаләләрен яза.

...Безнең фольклор галимнәре әдәби телебезнең XVI йөз Казан-шәһәр теле белән Казан арты авыл теле катнашмасы нигезендә туган халык иҗаты әсәрләре җыю буенча Арча — Әтнә — Дөбъяз — Балтач регионында соңгы елларда бик үк актив түгелләр. Фольклорчы Хуҗа Бәдигый Венгриядән килгән галимне 1907 елда нәкъ менә фольклор оясына — Курса авылына алып барган. Юлий Мейсарош белән бергә алар бик күп мәкаль-әйтем җыялар, 1912 елда Х. Бәдигый бу мәкальләрне аерым китап итеп бастырып чыгара. Казан арты җырга, бәеткә, әкияткә, мәкальгә гадәттән тыш бай: һөнәрле, сәүдәле, юл йөрешле, базарлы һәм иген-тарулы җирдә шунсыз мөмкин түгел. Халык тыгызлыгын да искә алыйк. Менә 1897 елгы халык санын алу нәтиҗәләре: Олы Әтнәдә — 2986 җан, Яңа Кенәрдә — 1998, Олы Мәңгәрдә — 1775, Яңа Кишеттә — 1326, Югары Курсада — 1197 җан. Зур авыллар!

Пугачев явында актив катнашкан авылларда, 1878 ел вакыйгаларын кичергән халыкларда азмы бәет булгандыр! Тукайның сүзләре бар: «Безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык. Чү, аз гына бернәрсә «шылт» иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга» («Халык әдәбияты»).

Казан артында булган хәлләр, гомумән, әдәбиятта зур эз калдырган. Тукайның «Шүрәле»се — бары тик Казан артыныкы. «Кәҗә белән сарык хикәясе» дә шуннан. «Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган; үзең яхшы беләсең бит печән хакын» һ. б. Тукай моны 1909 елда язган, ә әкият 1877 елда Казанда уздырылган археологларның Дүртенче съездында рус телендә хәбәр ителгән инде. Тукай әле аны язып бетермәгән, дөресрәге — туктаткан. Аның әле съездда сөйләнгән текст буенча дәвамы бар... «Су анасы» — Казан арты татарларының гасырлар буе бала тәрбияләү мәктәбе булган педагогик кулланмасы. Монда ике эш эшләнә: а) кеше әйберенә тимә; б) ялгыз су коенма. Казан артында көн уртасында, бигрәк тә көндезге 12 дә, ялгыз су коенган баланы су анасы ала дигән ышану бу якларда елгалар кибеп беткәнче яшәде әле. Тукай, авыл, табигать темасына кайда гына торып язмасын, Уральскидамы, Казандамы — тасвир бары тик Өчиледән, Кырлайдан, Кушлавычтан, Масрадан, Иске Йорт — Чиканас төбәгеннән. Бу — бәхәссез.

Казан артындагы социаль фон, сыйнфый көрәш иң зур полотно булып Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» дигән ике романында

чагылыш тапты. Монда Мәмсә, Мәңгәр, Этнә вакыйгалары да, Ш. Мәрҗанинең Казан бае Ибраһим Юнусов белән катлаулы авыр мөнәсәбәтләре дә — барысы да искиткеч зур осталык белән сәнгатьчә чагылдырылган. Кызганычка каршы, безнең әдәбият тарихында һәм тәнкыйтендә М. Галәүнең бу романнары тиешле дәрәҗәгә меңгерелеп утыртылмады. Казан арты әдипләренең язмышы өчен гадәти хәл инде ул: Тукай да шулай үз урынына менеп җитә алмый бит әле, Г. Камал да. Мәрҗани, Курсавилар да бик кыенлык белән күренәләр бит фәндә, әдәбиятта.

Тукай үзенең язмаларында бер генә тапкыр булса да «Арча» дип телгә алмый. Әбез — Арчадан чыккан әдәбият әһелләре — гел тукып торабыз: без — Тукай якташы, Тукай якташы... Арчада, хәтта, шундый әдәби берләшмә дә бар: «Тукай якташы». Язмаларында Тукай бер дә «Арчада булдым» дигән сүзне кулланмый. Югыйсә, тарихи урын: «Арча» сүзе беренче булып 1375 елгы Новгород елъязмасында очрый. Арчада бик борынгы крепость булган. Ниһаять, Арча — Балтач юлыннан Радищев узган. Арча турында көндәлегенә язган. Арча крепосте тарихы С. М. Шпилевский хезмәтләрендә чагылыш тапкан. 1900 елның җәендә Казан университетының Тарих, Этнография һәм Археология җәмгыяте Арчага махсус экспедиция оештыра. Арча крепостенең манарасын саклау эше шәһәр старостасы Н. П. Щелкинга йөкләнгән. Щелкиннар нәселе Арчада әле дә яши.

Әнә шул тарихи «шәһәрчек»тә Тукай бер тапкыр да булмаган, аны телгә дә алмаган. Дөресме бу, табигыйммы бу?

Бу сәер күренешкә ике яклап килергә кирәк. Беренчесе — Тукайның йөргән юлы беркайчан да Арчага туры килмәгән. Ул вакытта ат юлы: Өчиледән Кырлайга бару өчен Арчага керүнең хаҗәте юк. Өчиледән Яңа Масрага барганда Арча читтә кала. Мин моны күз алдына китерәм: Өчиледән туры Мөндешкә, аннан Казанбашка, аннан — Яңа Масрага. Казан-Өчиле арасында да Арча бөтенләй читтә. Тукайның очеркларында күренгәнчә, алар Казаннан Чыпчык, Коркачык, Тимерче, Кишмәт, Сәрдә юлыннан йөргәннәр. (Тукайны 1911 елның декабрендә Өчилегә алып кайтучы кеше Сәрдәнеке булган). Тукай Казанга кайтканда нәкъ шул маршрут буенча узганын яза. Бу булдымы — бер.

Икенчесе. Анысы — Тукай томнарын чыгаручыларда. Тукай Өчилегә кайтып ятуы турында «Мич башы кыйссасы» дигән очеркында яза. Анда мондый юллар бар: «Бер көнне мин, үземнең борадәр муллам белән, тәмам терелгән кеше шикелле, күтәренке бер рух белән авылымыздан ун чакрым ераклыктагы базарлы авылга киттем... Фатирчы бер карт урыска төштек. Монда бүтән авыл муллалары да бар икән, алар белән сөйләшеп чәй эчтек... Без карт урыс белән икәү генә аулак өйдә калдык». Томны төзүчеләр китап артына искәрмә бирәләр: «базарлы авылга... Олы Әтнә ... авылына». Йә инде, алай ук ярамый бит! Иң беренче: Олы Әтнә авылында базарга җыелган муллалар нишләп әле «карт урыска» фатирга төшсеннәр? Нинди зарурлык? Татар авылы — Әтнәдә — фатирга урыска төшәләрмени? Әтнә авылында аның «урысын», аның да картын, каян табасың? Булмаган анда андый фатир төшерүче урыслар! Икенчесе: Өчиледән алып Әтнәгә кадәр ун чакрым түгел, ә бик яхшы гына 30 чакрым. Алайса, Өчиледән ун чакрымда нинди базарлы, руслы авыл бар соң? Пашкау юлы белән (Пашков) Өчиледән көньяк-көнчыгышка 10-12 чакрым килсәң — Арча-урыслы авыл, дөресрәге — чиркәүле, чаңлы урыс авылы. Зур базарлы. Казан арты муллаларының һәр якшәмбедә җыелып, «урыска» фатир төшеп, базардан соң самовар янында гөлдерәп мөсахәбә кыла торган мәҗлесләре бары тик Арчада гына булган. Арчада бу традиция шулкадәр көчле иде, әле 1950—1960 елларда да Арчаның бөтен бер урамы (ялгышмасам, Покровка дип йөртелә иде) районга җыелышка, конференциягә, пленумга, базарга килгән кешеләрне квартирага төшерү белән көн итә иде. Һәр колхозның үзенең тукталу урыны бар, монда йорт-абзарлы, тагараклар, сбруй куяр өчен җылы өйалды, чәй эчү өчен аерым бүлмә, самовар һ. б. әсбаплар, толып-тун киптерү өчен мич башлары — барысы да көйләнгән. Колхоз (элек — авыл җәмәгате) бу йортны тота, бу хуҗалыкка утын, салам, бәрәңге, печән һ. б. әйберләр китереп аудара. Арча гасырлар буе шулай үз төбәгендәге крестьяннарны фатир төшереп көн итте, ул фатирларда эчке бүлмәдә буяулы идәннәр, почмакта иконалар, лампадалар, хуҗалык тәртибен күзәтеп базар көнне (якшәмбе) икона янында гыйбадәт кылып утырган, озын чәчен майлап тарап артка төенләп куйган, аллага чын күңелдән ышанган карт «урыслар» була иде. Болар дәүләт, политика, турында сөйләшергә яраталар, тәртипле-әдәпле, дөнья күргән урыслар, кайсы Уланский полкта, кайсы

Маршевая ротада патша хезмәтен узган, татарларга карата искиткеч ихтирамлы иде. Аларның соңгылары белән мин әле сөйләшеп утыргаладым. Бик өлкәннәр иде. Әмма, Тукай турында киләчәктә язармын дигән фикер башыма кереп тә карамаган иде. Казан арты русларының күркәм бер гадәте: үзләренә күрше, ызандаш, кәсептәш булган татарлар белән дуслык мөнәсәбәтләрендә яшәү, дини-милли хисләрне ихтирам итү иде. Тукайны игътибар беләнрәк укысаң, аның тәрбиясендә бу атмосфераның чагылуын сизү кыен түгел.

Өчиледән Кәбир мулла белән базарга килгәндә, Тукай, шулай итеп, Этнәдә түгел, ә Арча урысында патшалар, дәүләт политикасы турында сөйләшеп утырган. Покровка урамында революциягә кадәр салынган зур лапаслы, өч-дүрт бүлмәле йортлар, крыльцолы, зур капкалы хуҗалыклар әле дә бар. Аларда сәндерә дә сакланган әле, мич башы да. Арчаның кайсыдыр бер йортының мич башында Тукай, әнә шулай, базар көнне сөякләрен җылытып яткан... Тукайчы галим монда килсен...

Дүрттомлыктагы бу хатаны инде төзәтергә кирәк: Ибраһим Нуруллинның «ЖЗЛ» сериясендә чыккан «Тукай» дигән китабында шагыйрьнең Этнә базарында түгел, ә Арчада, рус өендә «добрый царь» турында эчтән елмаеп сөйләшеп утыруы турында әйтелә. Әһәмиятле төзәтмә бу.

Ихтимал, шундый фатирда җыелган чактадыр, Казан артының кырыкка якын мулласы — яңача укыту тарафдарлары — бөтен тирә-якның кара көче Ишми ишан өстеннән губернаторга жалоба бирү турында сөйләшкәннәр. Ләкин Ишми ишан аларга караганда җитезрәк булып чыккан һәм губерна жандарм идарәсенә «яңача укытучы кызыл муллаларның» исемлеген төзеп донос та җибәргән. 1911 елның февраль-мартында аларны җыеп төрмәгә утыртып та куйганнар. Казан арты тынсыз калган. Күпмедер тикшерүләрдән соң аларны азат иткәннәр. Әмма мулла-мөгаллимнәр, үзара сөйләшеп, моңа чик куярга булганнар һәм якшәмбеләрнең берсендә Арча базарыннан Югары Курса авылына юл тотканнар. Ул төбәктә, ни сәбәптәндер, Казаннан җибәрелгән шәһәр муллалары булган. Югары Курсада — Казан кешесе Уразгильдеев, күрше Иске Масрада — Казаннан, Мөхәммәдия мәдрәсәсе шәкерте, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар белән тегеләйме-болаймы таныш Нижгар мишәре Гаяз Фәтхетдинов, Яңа Масрада — гарәп телен камил белүче, әдәбият-тарих буенча зур әзерлекле кеше, Тукайның туганнан туганы Габдрахман Җәләлетдинов...

Казан артына белемле, үткен, телләр буенча әзерлекле муллаларны Казан, Сергач, Чистай, Нижний Новгород мишәрләрен җибәрү модада булган. Г. Камал әтисенең авылына — Сикертәнгә — Кышкар шәкерте, рус телен мөкәммәл белгән Габдулла Хәсәневне имам-хатиб итеп җибәрәләр, ул исә — үткен мишәрләр — Чистай ягыннан. Ә теге елны (1911) яңача укытучы муллалар, Курса мулласы Уразгильдеев өенә җыелып, губернаторга гариза-прошение язалар. «Безне Ишми дигән бу афәттән коткарыгыз, бу кеше безнең Казан артын бөтенләйгә харап итә», — диләр. Ахырдан Курса авылына килеп допрослар ясыйлар. Уразьгильдеевтан сорыйлар: кемнәр килде, кем яза башлады, кем нәрсә дип әйтте... Бу турыда документлар Казан жандармерия идарәсенең фондларында сакланган, мин боларны укыдым.

Казан арты — бөтен Казан губернасында иң һөнәрле як. Бу — бәхәссез. Һөнәр, кәсеп — зур базарларда гына түгел, зур җыеннарга да ихтыяҗ тудырган. Ниһаять, галимнәр моны да өйрәнә башладылар. Соңгы елларда җыеннар турында дөньяга чыккан иң әһәмиятле хезмәтләренең берсе Н. Б. Борһанованың «О системе народного праздника джиен у казанских татар» дигән тикшеренүе [8]. Моннан күренгәнчә, Алат юлында Олы Кыр, Биектау, Кушнарат, Этнә ягында Шөмбер, Мукшы тавы, Калатау, Кенәр ягында — Кенәр, Тазлар каршы, Шекә, Казакъ, Иябаш, Кишет, Дөбъяз тирәсендә Бәрәзә җыены булган. Бәрәскәнең дә үз җыены булган.

Арча тирәсе җыеннарга аеруча бай: Урман җыены (Чиканас-Өчиле), Утар, Ямаширмә, Сасмак, Сәрдә (икенче төрле — Кушлавыч), Әйше, Наласа, Күкчә, Күпербаш, Пошалым, Казан тавы җыеннары, Кесмәс буенда — Му җыены. Тар гына Казан арты өчен болар, әлбәттә, күп. Этнә — әлбәттә, инде борынгы Казан нәселе. Анда, күрше-тирә авыллары җыелып, «Кала җыены» үткәргәннәр. Риваятьләр буенча, кайчандыр бу якларга күчеп килүчеләрнең бу тирәдә «кала»лары булган, халык бу урынны гасырлар буе «Болгар каласы» дип атап йөрткән...

Бу як авылларының тагын бер үзенчәлеге — һәр авылның үзенә күрә специфик һөнәре бар. Рус авыллары — умартачы, калайдан йорт кирәк-

[8] Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Казань, 1982.

яракларын ясаучы, кием манучы, буяучы, самовар төзәтүче (Бимәр, Чуриле руслары) Ключище руслары — чүлмәк ясаучы, Өҗем, Ташчишмә — кирпеч суга, Казаклар (йомышлы татарлар) — такта яручы, Гөберчәк, Кече Әтнә — итек басучы, Мөрәле — морҗачы, Пошалым — арба, чана, дуга, кисмәк ясаучы, Кылачы, Мүлмә, Әйше, Тимерче, Сәрдә, Сасмак — чигүче, аяк киемнәре тегүче, Мөндеш — көмешче, Күпербаш — итче, базарда — маклер. Әтнә горләгән: анда биш мәхәллә! Әтнәлеләр мари ягыннан терлек-туар алып кайтып, шуны базарга чыгарган. Өйдәге хатын-кыз, бала-чага, карт-коры бүрек теккән, читек каеган. Җәйләрен ирләр күмер, деготь эшләгәннәр, бөтен Казан арты авылларына хуш исле деготь сатканнар, тимерче алачыкларын шыңгырдап торган нарат күмере белән тәэмин иткәннәр. Аннан кыш буе Орнашбаштан заказ алып мех бүрек теккәннәр. Кыскасы, Әтнәләр йоклап, ләчтит сатып уздырмаганнар гомерне.

Моннан тыш та һөнәрләр бар: Казан юлы өстендәге Чыпчык, Арча, Мәтәскә, Карадуган — фатир төшерүчеләр. Бу авылларда крестьян йортлары, зур лапаслы каралтылар, чәйханәләр, кибетләр урнашкан. Боларның бай легендалары, фольклоры, горурлыклары бар. Без бала вакыттан ишетеп таң калып үстек: Карадуганда сөргенгә узышлый Ленин куныып чыккан! Алай булмагандыр инде ул, әмма туган якны шулай данлы, истәлеккә бай, шигъриятле итеп күрәсе килә бит!

Кенәр ягы — байлар ягы. Чыпта сугучы, дуга, чана эшләүче, чүлмәк ясаучы Шеңә, Шушма якларын алар «кара як» дип атаганнар. Кенәр тирәсендә җир, урман биләүче байлар булган, бу авылда чигү, киндер сугу алга киткән. Дүрт мәхәлләле «ак авылның» һәр мәхәлләдә үз мәдрәсәсе булган, Кенәрнең вак тартмачылары мари ягына сәүдә эше белән йөргәннәр.

Курсалар — көрәшче. Казан артында татарча көрәшнең бөтен нормасы, әдәп-әхлагы, методикасы Курсада эшләнгән. «Курсалар килгән!» — шул хәбәр ишетелгәндә, Казан арты сабантуйларында таза гына ирләр җиргә иңеп алалар иде. «Курсалар килгән!» — бу инде зур, чын көрәш була дигән сүз. Колхозлар төзегәндә, аларга исемне дә шулай биргәннәр: «Батыр Курса», «Көрәш Курса».

Кызыклы күренеш: Казан артыннан чыккан шанлы-шаулы ике мәгърифәтче Ш. Мәрҗани һәм Т. Яхин — көрәшче булганнар. Ш. Мәрҗани яшьлегендә бик каты көрәшкән, батыр кала алмаган сабантуйларында начар кәеф белән йөргән. Таип исә яшьлегендә бик күп авылларда батыр калган... Боларның традициясе Арча-Балтач ягында әле дә яши... Бүгенге көндә татарча көрәш буенча Балтач егетләре республикада беренче урынны тоталар.

Арча ягындагы Кәче авылы ирләре — гасырлар буе крушниклыкта. Идел пристанена барып, гомер буе йөк төягәннәр, бушатканнар. Халкы җор, елдам, үткен. Холыклары да эленеп кенә тора — гомер буе юлда, пристаньда. Ф. Сәйфи-Казанлы хикәяләренә күп материал биргәннәр алар. Базар йөрү, юл йөрү ул — шәхес эшли. Казан артында элегрәк елларда һич тә «Казанга бардым» дип сөйләшмәделәр. «Казан йөрү», «базар йөрү» дип кенә әйтелә иде. «Й ө р ү» — зур сүз, бу инде а т л а у гына түгел, ә ил-җир күрү, агай-эне, татар, урыс, мари, мордва белән аралашу, ипле тормыш кору мәсьәләсен киңәш-табыш итү дигән сүз. Базар, сәүдә юлы, нәкъ крестьян хезмәте кебек үк, ш ә х е с я с ы й, шәхес эшли. Ә андый «эшләнгән» шәхес киләчәктә һичшиксез кирәк булачак. Бәдри солдатны хәтерләгез: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга...» Бу шәхес тарихта үз сүзен әйтәчәк, бу — патша түрәсе яткырып сукканда «ләббәйкә» дип тормаячак...

Казан артында элекке авылларны «ак як», «кара як» дип бүлгәләп йөрткәннәрен әйткән идек. «Ак як» — базар белән әвәрә килүчеләрдән ясала. Мәсәлән, Арча асты Күпербаш авылы. Базар көн — болар өчен бәйрәм. Күпербаш халкы бу көнне өйдә тәмле ризык пешерә, бер йомышы булмаса да, базарга бара, иң яхшы киемнәрен кия, кызлар бизәнә, шулай бөтен авыл Арча базарына китә. Кайтышлый өйләренә кеше төшерәләр, туган-тумача, күргән-белгәнне чәйгә алып керәләр, кунак итәләр. Бу гадәт аларда Арча базары беткәнче яшәде. Күпербаш гомергә «ак» булды.

Бөтен төрле һөнәр ияләре булып, базар корып, иген үстереп, сәүдә итеп, җыен ясап, сыйнфый ачуын вакытында чыгара белеп яшәгән Казан арты Бөек Октябрь революциясен табигый бер эш буларак, шатланып кабул итә.

1919 елда 2 нче Армиянең Революцион хәрби Советы члены Сафонов Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясенә менә нәрсә хәбәр итә: «Арчадан Вятские Поляныга китәр алдыннан халык безгә үз фикерен белдерде. Кешеләр Совет властеның нәрсә икәнлеген сезнең белән яшәгәндә генә белдек, диләр.

Бу аңлашыла да: бирелә, без бар чакта, байлар һәм полицейскийлар акыруы булмады». Икенче бер документта: «Арчада... һәм күрше-тирәдәге кайбер авылларда всеобуч көннәре байраклар, музыка һәм речь сөйләүләр белән үткәрелде» [9].

Казан артыннан — эшлекле, һөнәрле халык арасыннан чыккан укымышлылар шулай туп-туры Октябрь революциясенә хезмәткә күчте.

1923 елны татар җәмәгатьчелеге Тукайның үлүенә 10 ел тулуны билгеләгәндә, матбугатта еш кына шундый мәсьәлә күтәрелә: Тукай исән булса, бүген кем белән булыр иде? Һәм барысы да бер генә төрле җавап бирәләр: «Тукай бүген исән булса — һичшиксез, социализм төзүчеләр белән булыр иде». Алар хаклы.

...Алдарак Арча турында сүз барган иде.

Тукай һәм... аның әсәрләрендә бер генә тапкыр да телгә алынмаган Арча. Әмма, тарихта символик мәгънәләр, символик киселешләр-очрашулар бар. Тукай 1912 елның кышында Арча урысының мич башында сөякләрен җылытып яткан. Алты ел үткәч шул ук Арчада Тукайның рухи дусты Мәхмүт Дулат Али булачак: 1910 елда Тукай Казанда аларның флигелендә яшәп алган, Мәхмүт белән дуслашкан, «иптәшем Мәхмүдкә ядкарь» дип рәсемен бүләк иткән, Мәхмүт исә — РСДРП члены ук... Казанны чехлар алгач, Мәхмүт Казан арты Күн авылы егете Минһаҗ Конов һ. б. коммунистлар белән бергә Арчага күчеп китә, анда хәрби комендатурада эшли, яшерен рәвештә берничә мәртәбә Казанга барып килә, ак чехлар турында мәгълүматлар җыя. Исән булса, дусты Арча ягы егете Габдулла Тукай аңа нинди ярдәм күрсәтер иде...

Бөек шәхес Мулланур Вахитов та эш-гамәлләре белән Тукай эзләренә тоташа. Символик деталь: Мулланурны Көнгердә туган дип йөртсәләр дә, ул Казанда туган һәм Шиһаб Мәрҗани мәчете каршындагы метрикага теркәлгән! Тукай сөякләрен җылыткан Арчада Мулланурның әнисе Өммегөлсем апа була. Аны дошман тылыннан (Казанны ак чехлар алгач) Арчага Исхак Казаков алып килә һәм Арчадагы Азин дивизиясе штабы комиссары Минһаҗ Конов кулына тапшыра. М. Конов исә Өммегөлсем апаны Вятские Поляныга (Малмыж аркылы) чыгарып Мәскәүгә озата. Ә бу көннәрдә Малмыжда хәрби революцион трибунал кара реакционер Ишми ишан эшен карап ята... Тукай гына юк...

Бөеклек юллары һәрвакытта да бер төрле була. Түбәнлекләр генә һәркайсы аерым ямьсез, аерым җирәнгеч. Тукайның якташы, аннан биш яшькә яшьрәк Олы Әтнә егете Бәдри Җиһаншин ак чехлар вакытында Әтнә — Казан юлларында була. Тукай белән аларның юллары элек тә охшаш: бер төбәктә туганнар, бер төбәктә егет булганнар: Тукай — Уральскида, Бәдри — Троицкида. Тукай Уральск шәһәренең социал-демократлары белән бергә эшли, Бәдри — Троицк шәһәренең социал-демократлары белән. Бераздан юллар аерыла: Тукай Казанга китеп бара, Бәдрине төрмәгә утырталар. Тукай 1913 елда үлә, Бәдри исә флотка алына һәм 1915 елда РСДРПга кабул ителә. Партия аны үз ягына эшкә җибәрә: Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе «Бәдри матрос»ны 1919 елда запастагы Аерым батальонга политкомиссар итеп билгели. Тукай, Уральскидан кайтып, 27 нче яшендә Казанда үлә, Бәдри Җиһаншин ил азатлыгы өчен көрәшеп, Казан, Арча, Богырыслан, Бөгелмә юлларын үтеп 29 яшендә Бәләбәйдә үлә...» («Көрәштәшләр», Казан, 1972, 183—189 битләр).

Тукайны биргән Казан арты — шагыйрьнең бишеге әнә шулай вакыйгаларга, шәхесләргә, сыйнфый аңга, шигърияткә бай як. Ул вакыйгалар, ул хәлләр, шәхесләр, ул табигать аерым-аерым хис булып, матдә, тойгы булып 26 ел буе шагыйрь Тукайны ясаган, ул шигъри бишек аны гомеренең иң авыр вакытларында тибрәткән. Әнә шуңа күрә авыруы бик көчәйгән, шәһәр атмосферасы һәм социаль мохит рухын бик нык кыскан вакытларда ул туган ягына — шул бишеккә кайтып киткән, шунда рухына ләззәт тапкан.

Кырыс чырайлы тәнкыйтьче Харап икән, Казан артында барысы да шәп, барысы да ал да гөл булган икән! Аннан чыккан кешеләр гел фәрештә икән...

И агайне! (Г. Камалның әтисе туган Сикертән авылында бер-берәңә дәшүнең иң популяр формасы шул: агайне). Сикертәнлеләр әле аны үзләренчә әйтәләр: «агайны». Бу — руслардагы «дружище», Англия, Америка Кушма

[9] СССР ҮДА. 106 ф., 1 тасв., 8—9 эшләр.

Штатлары, Канада кебек илләрдәге «сэр», Франциядәге «мусье», Италиядәге «синьор», Төркиядәге «әфәндем» кебек сүзләр дәрәҗәсендә. Япониядә бу уңайдан «сан» сүзе кулланыла булса кирәк. Безнең Сикертәндә — агайны...)

И агайны!.. Сабыр ит, зинһар. Бу мәкаләдә бит Тукайны шагыйрь иткән, үз заманының зур акыл иясе иткән шартлар, тирәлек, кешелек җәмгыятенең аңа ярдәм иткән стимуллары турында сүз бара. Казан арты — тарихтан чыгарма түгел, анда нәкъ башка җирдәге кебек канечкеч алпавыт, кулак, надан мулла, куштан крестьян, ришвәтче түрә, әлбәттә, булган. Мактаулы Кышкар мәдрәсәсендә дә кадимче, искелеге белән дан тоткан баш мулла дамелла Исмәгыйль хәзрәт булган. Ф. Әмирхан яза: «Мәрҗани вакытының бик мәшһүр Кышкар дамеллаларына... бер дә әһәмият бирми, аларны наданга саный иде» (Сайланма әсәрләр, Казан, 1956, 2 т., 458—459 бб.). Әмма бөек мәсәлче И. А. Крыловны тәрҗемә иткән, балалар өчен күп китап бастырган мәгърифәтче Таип Яхин — шул тискәре хәзрәт кулында укыган. Ихтимал, кадимче Исмәгыйль хәзрәтнең искелеге Таип шәкертне яңалыкка — рус әдәбиятына этәрүче сәбәпләрнең берсе булгандыр. Русларда мондый мәкаль бар: «Нет худа без добра»... Таип Яхинның нәсел шәҗәрәсе миңа бик таныш. Аның бабасы Яхъя — Теләче ягындагы Күкчә авылы мулласы. Яхъяның бер оныгы, шигырьләр язучы (кайбер шигырьләре сакланган) Мөхәммәтгариф — минем ерак бабам. (Тукай этисе белән бутыйсы түгел!) Икенче оныгы Таип Яхин, әлеге мәгърифәтче, китапчы, дөньяга карашларында гаять дәрәҗәдә каршылыклы, ләкин яктылыкка берөзлексез юл эзләүче шәхес... Казан артының тискәре кешеләре шул Исмәгыйль хәзрәт кенә булсачы! Аларның бит сәүдәгәрләр арасында берәр терәге була. Тискәре идеология һәрчакта да акчага, байлыкка нигезләнеп туа. Казан артының кадимче муллаларын Казан артының ук кадимче сәүдәгәрләре акча белән тәэмин итә. Әйтик, Казанның кадимчесе, сәүдәгәр Вәли (Арча ягы Аты авылыннан) гел искелекне яклый. Ф. Әмирхан «У-у... шатлык» дигән фельетонда болай яза: «Утыз еллар чамасыннан Әхмәтҗан абзый Сәйдәшев туганына йөз ел буладыр. Бу елны Аты Вәли ысулы җәдидә кабул итеп, Әхмәтҗан абзыйны түрәләр хозурында эш йөртергә Петербургка җибәрергә агитация ясаячактыр». Китапның артында укыйбыз: Аты Вәли — «Казанның кадимчеләр яклы бер сәүдәгәре» (592 бит). Сәрдә авылының Гыйләҗ мулла да кадимчелек фронтының алгы рәтендә тора. Кадимче — искелек тарафдары беркайчан да тик ятмый: ул яңалыкка каршы һәрвакыт актив көрәш алып бара, китап яза, вәгазь сөйли, эш йөртә. «Яңа чүпләр» дигән фельетонында Ф. Әмирхан Гыйләҗ мулланы тешләп уза... «Әүвәлдә,— ди ул,— Ишми муллалар, әллә нинди Гыйләҗ муллалар һәзлиятләрен (көлеп, мыскыллап язылган әсәр — М. М.) үз исемнәре белән, яшеренми, качырынмый нәшер итәләр иде» (шунда ук —359 бит).

Казан арты кадимчеләрен Ф. Әмирхан, Г. Камал, Тукай җае килгән саен тәнкыйтьләп торалар. «Ялт-Йолт» идарәсеннән сораулар» исемле фельетонында Тукай, уйлап чыгарылган исем астында булса да, туган ягы кадимчесен әләктерә: «Мәскәү губернасы Олуг Мәңгәр волостеның Шилметдин Җонлыбияләев»,— ди. Бу исемнең, һичшиксез, конкрет бер кешесе күздә тотылган инде, без аны белмибез генә...

Тукай ул заманда ат белән йөргән, юлы болай: Өчиле, Югары Аты, Түбән Аты, Кушлавыч... Казанга таба: Өчиле, бер рәт Аты, Кишмәт, Тимерче, Әйше, Чыпчык, аннан — Балавыз урманнары, хәзерге Ливадия ял йорты, Казанка буйлап астан кышкы юл, Подлужная урамы, аннан өскә таба хәзерге Суворов училищесы янныннан Толстой яшәгән йорт — аннан К. Маркс урамы. Шагыйрьнең кулъязмаларында Казан артына тулы экономик, культура, рухи яктан бәя бирелә. Кишмәттән чыгып болын буйлап килсәң — Тимерче авылы. Боларда элек (Казанка харап булганчы) гел болын, гел печән кибәне генә иде. Тукайда ассоциация: «Бу авылның мулласы» Әннә солул Җәдидә...»че («Ысул җәдидәне юкка чыгара торган тимер кебек нык китап» — М. М.) һәм әллә нинди исемнәр белән ысулы җәдидәгә каршы китаплар чыгарган каһарман». Шунда ук Тукай мондагы печән кибәннәренә игътибар итә һәм болай ди: бер данә диярлек арыш, богъдай кибәне булмаса да, печән кибәне бик күп дәрәҗәсендә. «Моны күргәч: «Мулласы» «Дин вә мәшыйгать»-че булган бу авылның халкы да печән ашыймы әллә? — дигән фикерләр килде» (Шунда ук).

Күрәсең, Казан артында кара таплар җитәрлек булган. Казан арты реакцион фикеренең башында Ишми ишан торган. Аның чыгарган реакцион китаплары, гомумән, эшчәнлеге Казан алпавыты Габдрахман Ишморатов

тәэминатында булган. Казан артының бик матур бер почмагында — өч яктан урманлы Казанка елгасы буенда (хәзер ул Арча районы белән Балтач районы чикләрендә) алпавытның җәйге утары, ат заводы, кирпеч сугу, такта яру заводлары булган. Ул як авылларына мулла кую, мәчет салдыру, яңа мәхәллә ачу — барысы да Ишморатов карамагында. Яңача промышленность корган Ишморатов идеологиядә кадимчелекне бик нык яклаган һәм Казан артындагы кара реакция житәкчесе Ишми ишанны яңалыкка каршы гел өстереп торган. Ишморатов акчасына Ишми ишан Казанда «Икамәтель борһан...» дигән китап та бастырган — бөтен фикере яңалыкка каршы. Бу турыда 1969 елда «Казан утлары» журналының 12 санында язылган иде.

Кырыс чырайлы тәнкыйтьче агайне болай да ышанды, болай да безнең белән килеште инде...

Безнең бурыч шул ук — Казан артының ниндидер үзенчәлеген ачу, шул үзенчәлекләрнең тарихи җепләрен эзләү иде. Алдарак без Казан артының сыйнфый аңга зирәк булуын, эшкә-хезмәткә һәвәскәр булуын ачарга тырышкан идек. Кырыс чырайлы тәнкыйтьче, ул урыннарны язганда да, авторның күз алдыннан китмәгән иде. Әмма тарихи-матур фактлар бар. Кантарлы-балчыклы, ташлы-ярлы, чокырлы шул Арча, Әтнә ягы гаҗәп кызыклы биографияләрне һаман тудырып тора. Арча районының иң читендә бәп-бәләкәй бер авыл бар. Исеме — Миржәм. Әнә шул Миржәм соңгы 40 елда дөньяга өч герой бирде инде. Болар: Советлар Союзы Герое Нәкыйп Сафин, Социалистик Хезмәт Геройлары Дания Галимова (авыл хуҗалыгы) һәм Галимулла Әсхәдуллин (эшче). Кечкенә генә бер авыл өчен күп. Миржәмдә бит нефть чыгарылмый, мамык үстерелми. Бу төбәкнең тарихына керсәң — кызык. Ун-унбиш йортлы авылда туып-үскән Илсур Шәйхетдиновны (алда телгә алынган авыл — Әрнәш егете) бүгенге көндә бөтен Европа белә. Социалистик Хезмәт Герое Илсур менә ничә еллар инде Уренгой — Помары — Ужгород линиясендә газ үткәрә. Алда телгә алынган авыллардан тагын әллә ничә герой чыккан: Түбән Орыдан Гатаулла Салихов, Иске Кишеттән генерал Гани Сафиуллин, Арчадан Валентин Ежков — Советлар Союзы Геройлары. Түбән Көектән Нургали Бариев, Шушмабаштан Шәрифулла Сәгъдуллин — Социалистик Хезмәт Геройлары. Казаннан килеп Яңа Кенәрдә яшәгән укытучы Стелла Габдрахманованың биографиясенә күз салсак, бу профессиядә сирәк очрый торган Социалистик Хезмәт Герое дәрәҗәсенә лаек булган Стелланың да ата-анасы Әтнә ягы Кышлау авылыннан икән... Әле күптән түгел генә Казанбаш егете Мирбат Хәстиевкә дә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Дөбъяз ягына, Балтач төбәгенә мин кермим, геройлар саны артачак, Казан арты булмаган башка яклар үпкәли калырлар.

Казан арты — шагыйрь бишеге әнә шундый...

Тукайның бу якта тууы очраклымы? Һәм ике гасыр ялгамында тууы очраклымы? Юк, очраклы түгел, тарихи вакыйгалар, сыйнфый көрәш белән кысылган тар Казан арты үз фикерен әйтү өчен бер шәхесне тудырмый кала алмый иде. Ул шәхес әлеге фикерне әйтү өчен шагыйрь булып туарга тиеш иде һәм нәкъ шул чорда — заман алмашынган чорда туарга тиеш иде. Заманның бер этаптан икенче этапка күчкәндә җиргә үз улын биреп калдырып, тарихи миссиясен үтәп китүе булган инде ул. Тукайның шагыйрь булып тууы да табигый иде: кысылган халык күңеленең, җыр-бәет, «Кыйссаи Йосыфы» белән, «Таһир-Зөһрә» белән тәрбияләнгән халыкның йөз еллар эчендә бер кисәк ахак бирми калуы мөмкин түгел иде.

Тукай әнә шундый — заман ихтыяҗларын үзенә миссия итеп алган тарихи шәхес буларак, шул бишектә дөньяга килде.



**Н. Б. Баһрамов,**

КПССның Әгерҗе райкомы беренче секретаре

# ӘГЕРҖЕГӘ КИЛЕГЕЗ!

Безгә килеп төшкән юлчының игътибарын еракка-еракка сузылган тимер юл челтәре үзенә тарта. Ялт-йолт итеп торучы металл тасмалар офыкка ук барып тоташкан сыман. Әгерҗе — Татарстанның иң төньягындагы районы. Ул, йөз чакрымлы искиткеч зур уенты ясап, Удмуртия АССР мәйданына кереп тора. Безнең районга җитү өчен иң элек Киров өлкәсе аша, аннары Удмуртия АССР буйлап барырга туры килә. Казаннан кузгалсаң, 300 чакрымлап юл үтәсең.

Әгерҗе — иксез-чиксез урманнар иле. Мәшһүр рәссам Иван Шишкинның «Урманлы офык» әсәрен күргән саен күңелгә: «Бу бит — безнең як киңлекләре, мондый шаулы урманнар тагын кайда булсын! — дигән уй килә.— Рәссам бу картинаны ясарга, мөгаен, безнең төбәктә йөргәндә илһамлангандыр!»

Районның үзәге — Әгерҗе шәһәре. Шәһәр дә, гомумән, район үзе дә бай тарихка ия. Аның үткәннәре иң борынгы чорларга ук тоташкан. Төбәк тарихында бу якларның Пьянобор культурасы дип аталган махсус бер чоры да мәгълүм. Әгерҗе халкы, бүгенге тормышына ирешкәнче, катлаулы көрәшләр юлын узган: крепостнойлыктан котылу, Совет власте урнаштыру, Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгу өчен барган көрәшләрдә әгерҗелеләр гаҗәеп батырлык үрнәкләре күрсәткәннәр. Тирсә һәм Балтач крестьяннары, Иж Буби шәкертләре, якты тормыш өчен көрәшкә күтәрелеп, шулай ук тарихта эз калдырганнар. Әгерҗе тимер юлчылары гражданнар сугышы елларында яшь Совет власте өчен барган канлы көрәштә тиңдәшсез батырлык күрсәткәннәр. Тимер юлчылар поселогында шул каһарманнарның берсе булган М. В. Ометов исемендәге урам да бар. Әгерҗегә килгән кеше Каманың текә ярына салынган мәһабәт һәйкәлне күрми калмас. Бу — колчакчы бандаларга каршы сугышта аеруча кыюлык күрсәткән Н. Маркинга багышланган истәлек. Николай Маркин районның Красный Бор авылы янында барган бәрелешләрдә кызылларга ярдәмгә килгән «Ваня-коммунист» пароходындагы сугышчыларга җитәкчелек итә һәм батырларча һәлак була.

Әгерҗе өчен элек-электән шундый зур яулар баруы гаҗәп тә түгел, чөнки ул һәр чорда бик әһәмиятле роль уйнаган. Казаннан Екатеринбургка Әгерҗе аша тимер юл да салынгач, шәһәрнең дәрәҗәсе тагын да арткан. Шәһәрнең һәм районның бүгенге хәле, соңгы еллардагы үсеше исә аеруча күзгә ташлана.

Хәзерге Әгерҗедә тугыз промышленность предприятиесе бар. Алар кирпеч, бизәгеч плиткалар, кондитер, сөт ризыклары, исерткечсез татлы эчемлекләр, агач материаллары һәм халыкка кирәкле башка әйберләр җитештерәләр. Әгерҗедә локомотив һәм вагоннар депосы, тимер юл станциясе һәм аңа бәйле башка оешмалар урнашкан. Санап үтелгән һәр предприятие үзара социалистик ярыш мөнәсәбәтләрендә, бер-берсеннән уздырырга тырышып эшли. Җитештерелгән әйберләрнең күбесе Татарстанның башка якларына да, ә кайберләре ил күләмендә тарала. Мәсәлән, безнең эшчеләр ясаган вагоннар кай тарафларда гына файдаланылмый икән? Киләчәккә һәр предприятиебезнең тагын да киңрәк колачлы булуын планлаштырдык.

Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм төзелеш оешмалары да кешеләрдән рәхмәтне күп ишетә. Соңгы елларда Әгерҗедә бик күп йортлар, культура сарае, яңа кибетләр, тулай тораклар салынды. Ял итү өчен, буш вакытны файдалы иттереп

уздыру өчен мөмкинлекләр арта бара. Тимер юлчыларның махсус культура сарае бар. Кинотеатр, стадион, музыка мәктәбе — барысы да хезмәт кешесе рәхәтләнеп ял итсен өчен булдырылган. Район күләмендә исәпләсәк, клублар —56, китапханәләр —36, кино күрсәтү җайланмалары 48 гә җитә.

Авыл хуҗалыгыбыз күп тармаклы. Колхоз-совхозларыбыз игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек, умартачылык белән шөгыльләнәләр. Безнең якта табигать шартлары, республиканың көньягына яки уртадагы районнарына караганда, үзгәрәк. Язларыбыз соңрак башлана, көзләр иртәрәк килә. Бу хәл кырларыбыздан җыела торган уңышка кире тәэсир ясый. Җитмәсә, туфрагыбыз да әллә ни уңдырышлы түгел, балчыклы туфрак. Шуңа күрә алда торган иң беренче бурычыбыз — басуларыбызның уңдырышлылыгын арттыру. Моның өчен билгеләп куйган якындагы максатларыбыз да бар: безгә орлыкларның яхшырак сортларыннан файдаланырга, сугарулы җайланмаларга күбрәк таянырга, агротехника чараларын камилләштерергә кирәк. М. Гыйззәтов, И. Ямалиев кебек уңган механизаторларыбыз алга куелган бурычларны җиңеп чыгуда төп терәгебез булып тора. Нәкъ менә шундый булдыклы кешеләр Жданов, К. Маркс исемендәге, «Родина», «Таң», «Коммунизмга» колхозларында мул уңыш җыярга мөмкинлек тудыралар. Алар ярдәмендә Әгерҗе районы 1985 елда бөртекләләр сату буенча дәүләт планын үтәп чыкты. Игенчеләребез уңышына М. Рафикова, Г. Зарипов, В. Мулланурова, Р. Андреева, Ф. Әхмәтшина, С. Садыйкова, Ф. Миннәхмәтова, В. Иванова кебек өлгер терлекчеләрнең зур өлеше дә өстәлә.

Күп хуҗалыкларыбызда хезмәт кешесенең кадерен белүче, сәләтле, укымышлы җитәкчеләр бар. Алар авылларның төзеклегенә, матураюына да игътибар итәләр. Ата-бабалары кан коеп яулап алган туган җирдә хәзер тормышның күркәмлеге өчен көрәш бара. Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуыбызның 40 еллыгын халык аеруча зур уңышлар белән каршылаган иде. Моның сәбәбе ачык. Әгерҗе Бөек Ватан сугышы фронтларына үзенең 9625 кешесен озаткан. Шуларның 6350 се ил азатлыгы хакына яу кырында мәңгегә ятып калган. Меңнәрчә сугышчыларыбыз орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән. Арада өч Советлар Союзы Герое да бар: Асаф Абдрахманов, Борис Шабалин, Гали Шәмсетдинов. Каһарманнарыбызның якты истәлеген мәңгеләштерү өчен 1985 елның 9 маенда Әгерҗедә Җиңү мәйданы булдырылды. Батырларга багышлап куелган һәйкәл алдында мәңгелек ут яна.

Безнең районда туып-үскән кешеләр арасында әдәбият, сәнгать һәм фән өлкәсенә зур өлеш кертүче шәхесләр дә күп: Таҗи Гыйззәт, Давыт Гобәйди, Юныс Әминов, Мансур Вәлиев, Роза Камалетдинова, Рәгъде Халитов, Венера Шәрипова, Җамал Вәзиева, Алмазия Нуриева, Маһирә Максудова, Әнвәр Тукаев... Аларның һәммәсен без районыбызның мактанычыннан саныйбыз, алар белән горурланабыз.

**Марат Бибишев,**

«Камгэсэнергострой»ның йортлар төзү комбинаты начальнигы, ТАССРның атказанган төзүчесе

# КЕШЕЛӘР ХАКЫНА

Мәгълүм булганча, «Казан утлары» журналы редакциясе Татарстан атом электр станциясен салучылар коллективы белән хезмәттәшлек килешүе төзегән иде. Килешүгә куллар куелганнан соң өч елдан артык вакыт үтте. Бу еллар дәвамында журнал сәхифәләрендә АЭС төзелешенә багышлап язылган уннарча очерк-мәкаләләр, шигырьләр, җыр һәм роман басылып чыкты. Иң яхшы алты язманың авторына төзелешнең премиясе тапшырылды. Иң алдынгы унбиш төзүчегә журналның мактау кәгазьләре һәм еллык саннары бүләк ителде.

Төзелеш торган саен киңрәк колач ала бара. Яңа уңышлар белән бергә көтелмәгән кыенлыклары да чыга. Бу хәл төзелеш җитәкчеләреннән идарә итүнең тагын да камилрәк ысулларын табуны таләп итә. КПССның XXVII съезды карарларын тормышка ашыру җәһәтеннән мондый таләп хәзер бөтен кискенлеге белән чынбарлыкка әйләнде. Шушы мәсьәләләрне күз алдында тотып, редакция хәбәрчесе Кама Аланында яңа шәһәр салучы 12 нче идарәне дә эченә алган Брежневтагы Йортлар төзү комбинатының начальнигы Марат Шакирович Бибишевка берничә сорау биргән иде. Түбәндә төзелеш яңалыкларына, яшь коллективтагы үзгәрешләргә, яшьләрне тәрбияләү мәсьәләләренә кагылышлы шушы сорауларга карата алынган җаваплар урнаштырыла.

* * *

Безнең коллективның бөтен максаты кешеләрнең тормышын мул, рәхәт, матур итүгә юнәлдерелгән. Исеме үк шуңа ишарә — йортлар салучы комбинат. Безнең хезмәт Кешенең җирдәге иң беренче ихтыяҗын канәгатьләндерә, баш өстендә түбә булуын тәэмин итә. Бу мәсьәлә — әлегәчә ил күләмендә иң четерекле проблемаларның берсе. Моңа КПССның XXVII съездында да игътибар ителде, төзүчеләр алдына бик төгәл бурычлар куелды, гасыр азагына кадәр һәр гаилә торак белән тулысынча тәэмин ителергә тиеш дип табылды. Сүз дә юк, без бу карарның олылыгын, шәфкатьлелеген һәм җаваплылыгын яхшы аңлыйбыз.

Кама Аланындагы торак йортлар мәйданы инде алтмыш мең квадрат метрдан артыграк булган иде. Быел шәһәр тагын җитмеш мең квадрат метр торак алырга тиеш. Ашханәләр, мәктәп, балалар бакчалары, кибетләр арта тора.

Станцияне салучылар март аенда беренче энергоблок өчен нигез әзерләргә тотындылар. Әгәр аларның: «1989 елда Татарстан АЭСе беренче реакторны эшкә җигәчәк! Кама Аланына атом кояшы балкып чыгачак!» — дигән йөкләмәләренә игътибар итсәк, мондагы эшнең ни дәрәҗәдә катлаулы һәм җаваплы икәнлеген чамаларга мөмкин. Әле бер генә атом электр станциясенең дә мондый кыска арада салынганы юк.

Без, шәһәр салучылар, мәсьәләнең икенче, тагын да мөһимрәк ягына да игътибар итәбез. Яңа шәһәрнең йортлары тиз салынуы белән генә түгел, уңайлы, матур булулары ягыннан да кешеләрне сокландырырга тиеш. Һичшиксез! Чөнки хәзер өлгергән өйләрдә яшь буын — киләчәк көннәребезнең хуҗалары яшәячәк. Алар якты тормышта гына түгел, өйләрнең дә иң матурында торсыннар. Һәм, әлбәттә, үзләре дә һәрьяктан яхшы кешеләр булсыннар иде! Хәзер миннән: «Кама Аланындагы бүгенге төзелешнең иң кайнар ноктасы, иң кискен көрәш барган урыны кайда?» — дип сорасалар, һич икеләнмичә: «Киләчәктәге иң камил җәмгыятьтә яшәргә лаек кеше өчен көрәшәбез!» — дип җавап кайтарыр идем. Әле буыннары ныгып җитмәгән яшь коллективта бу бурыч безнең алга бөтен кискенлеге белән килеп баса.

Бер карасаң, зурайганнан-зурая баручы планнарны үтәү өчен хафаланып йөргәндә, моңа вакыт та, мөмкинлек тә җитенкерәмәс кебек. Тирәннән уйласак, безнең бөтен кылганнарыбыз кеше хакына лабаса! Әвеш-түеш китереп, ашык-пошык корашатырып куелган йортлар, бәлки, беренче килеп урнашучыларга ярап та торыр иде. Йортсыз кеше, яңа фатирга тиенгәндә, җитешсезлекләрне кичерер дә иде, мөгаен. Тик без хәзер үзебез үк мондый эш ысулыннан, төрле ташламалардан баш тартырга өйрәнеп киләбез инде. Безнең бүгенге ташпулатлар гасырларга исәпләп салына. Димәк, аның ныклыгы гына түгел, архитектурасы да, уңайлыклары да йөз еллар буена горурланырлык булсын!

Инде шундый әйбәт шартларда яшәүче төзүчеләребезнең үз-үзләрен тотышлары, осталыклары, омтылышлары, ял вакытларын ничек уздырулары, гомумән, чын кеше буларак формалашулары турында уйлап карыйк. Соңгы вакытта без нәкъ шул хакта, кешеләребезнең заманга лаеклыгы, укымышлылыгы, күңелләренең яктылыгы турында кайгыртучанлык тоябыз.

Моңа кадәр бу юнәлештәге тәрбия эшләренә эчүчелек нык комачаулап килде. Кулыннан гөл түгелердәй осталарыбыз, егет солтанылай асылларыбыз эчеп харап булгаладылар. Кайберләрен бөтенләйгә югалттык без аларның. Без ял өчен калдырылган буш вакытны файдалы да, күңелле дә итеп уздырырга хәзерлексез булып чыктык. Бөтен нәрсә җитеш, акча күп, буш вакыт та арта бара — шул шартларда матур иттереп көн күрәсе урынга арага аракы килеп керде.

Эчкечелеккә каршы һичнинди ташламаларсыз кискен көрәш минем өчен яңалык түгел. Әле Чаллыда КамАЗ салына башлаганчы ук,мин бер төзү-монтаж идарәсендә начальник идем. Хәтеремдә: аерым талантлы бер оста бар. Хатыйпов. Электр белән эретеп ябыштыручы. Аның эшенә, тикшереп-нитеп тормыйча ук, бик яхшы билгесе куярга мөмкин иде. Коеп куя. Тик, хезмәт хакын алгач, бер-ике көн эшкә көтмә инде син аны. Эчеп ята. Тыела алмыйча, авырып эчә.

Башта аңа шелтә белдердем. Аннары да тыела алмагач, каты шелтә бирдек. Алай да үзгәрмәде. Эштән азат итәргә туры килде. Үзе бик кирәк иде ул безгә. Аның урынына куярдай башка төзүче дә юк иде. Иптәшләремнең кайберләре Хатыйповның эчкечелегенә күз йомарга да өндәп карадылар. Әмма чигенмәдек. Эчкечелек белән көрәштә икеләнүләр бары тик зарар гына китерә, яшьләр өчен, әле бу зәхмәтнең яман тәэсиренә бирелеп өлгермәгәннәр өчен начарлык булып калкып чыга.

Эчкечелекнең барлык тамырларына балта чапкан вакытта алдынгы эшчеләрнең, җитәкчеләрнең үз-үзләрен ничек тотуы бигрәк тә мөһим. Талантлы оста азып-тузып йөргәндә, без аның эшен мактап телгә алабыз икән, башкаларга,аеруча яшүсмерләргә, иң әүвәл аның яман сыйфаты күренә, алар әлеге мактаулы хезмәткәрнең әнә шул начар ягын үзләренә маяк итеп күчерәләр. Чөнки монысы — иң җиңеле. Аннары инде, ник эчәсең дип сорасаң, ул теге талантлы кешегә төртеп күрсәтәчәк. Әнә бит, ул да эчә, янәсе. Нәкъ шуңа күрә дә бу көрәштә йомшарып калмаска, икеләнеп тормаска туры килә. Алкоголизмны коточкыч авыру дип таныйбыз икән, аңа каршы көрәшү чарасының да иң үтемлесен, кисеп ташлый торганын сайлап алыйк!

Безнең коллективта минем бу карашым күптән мәгълүм. Әмма коллектив зур, хезмәтебез киң колачлы. Татарстан атом электр станциясе төзелеше дә — аның бер кечкенә кисәкчәсе генә. Кама Аланындагы торак төзелеше өчен җаваплы 12 нче идарә начальнигы Рәис Сәләховтан гел сорашып торам:

— Исерекләр белән нишлисез? — дим.

— Яхшылап кисәтүне аңламасалар, килгән якларына ук озатабыз,— ди.

Беләм: Рәис тә эчүчелекне өнәми.

— Эчми торган тәзүчеләр белән эшләү рәхәтме соң? — дим.

— Анысы рәхәт, тик әллә ни алга китеп булмый әле. Материал белән тәэмин итеп өлгертә алмыйлар. Аек кешегә киерелеп торып эшләргә чама юк...

Күрдегезме? Әнә ничек тирәнгә киткән ул яман гадәтнең тамыры! Без эштәге исерекләргә ияләнеп җиткәнбез. Хезмәт ритмы бозылган. Ритмның нормальләшүе кайберәүләрне аптыраштa калдыра. Үзләре аек кешеләр дә исерекләрчә фикер йөртергә, алар җаена торырга күнеккәннәр. Шунлыктан хәзер кемнеңдер исереклегенә аркаланырга ияләнгән аек ялкауларның да эшкә карашын тамырдан үзгәртергә туры килә.

Бу юлда иң алга җитәкченең шәхси үрнәге чыгып баса. Безнең комбинатта бу мәсьәлә күптән хәл ителгән: идарә җитәкчеләре дә, баш инженер да, аның урынбасарлары да электән үк исереклеккә баш-аяклары белән каршы. Оешмаларда исерткечләр куелган табыннарның, күңел ачканда аракы эчүнең ишетелгәне дә юк. Бәйрәмнәрдә татлы бәлешләр китертәбез, хуш исле чәй тәкъдим итәбез, бер-беребезне котлау сүзләрен кызганмыйбыз, аннары һәвәскәр артистларыбызга сүз бирәбез. Бик күңелле була. Һәркем шатланып, тыныч күңел белән өенә кайтып китә. Шунда аз гына аракы керсен — бөтен коллектив бутала башлар иде. Берсе сүгенеп куяр, икенчесе аңа ачуланыр, өченчесе килделе-киттеле фәлсәфә куерта башлар... Аракы бит ул телләрне чишеп кенә калмый, тотнаклылыкны да бетерә; чамадан яздыра, хайвани инстинктны калкыта.

Безнең бөтен максат — кешеләребезне авыр хезмәттән мөмкин кадәр азат итү, ял вакытын арттыра бару. Монысы бик яхшы. Инде ял вакытларыбызны мәгънәле, файдалы иттереп оештыра белергә дә өйрәнергә тиешбез. Хезмәттән буш ара — безнең гомернең иң кадерле чагы, аны исраф итүдән саклансак иде! Минем карашымча, монда кешеләрнең культурасын үстерү, физик культурага күнектерү — иң ышанычлы чара.

Үзем мин — Чаллы баласы. Кечкенәдән физик эш белән,физик культура белән шөгыльләнмәсәм, утыз өч ел буе шушындый җаваплы, киеренке хезмәтне тартып бара алыр идемме?! Гомеремнең бер чорында эш белән генә мавыгып китеп, физкультурадан читләшә башлаган идем. Әллә нәрсә, авыраеп, салмакланып калдым. Яңадан тимераякка, чаңгыга бастым. Дөрес, махсус шугалакка ял көннәрендә генә йөрим. Эш көннәрендә исә җәяү йөрергә тырышам. Ифрат файдалы.

Хәзер безнең Брежнев шәһәрендә спорт комплексыбыз бар. Салуы да, аңа кешеләрне ияләндерүе дә җиңел булмады. Әмма аңа бер аяк басканнар кире китә алмыйлар инде. Бассейнының да, көрәш залларының да, башка секцияләрнең дә үз каһарманары бар.

Бассейн дигәннән, Кама Аланындагы яңа балалар бакчасында да бар ул. Әле тәпи йөри белмәгән сабыйларны йөзәргә өйрәтәбез. Шәп! Мин ул балаларның киләчәген күз алдыма китерәм: әгәр тәрбияләү системасына хата килеп кермәсә, алар искиткеч нык, рухи таза, эш ярата торган бик матур кешеләр булып үсәчәкләр.

Без барыбыз да, аеруча җитәкчеләр, физкультура һәм спортның бик файдалы чара икәнлеген хәтердән чыгармаска тиешбез. Бүгенге көннәрдә аек кеше, киләчәкнең һәрьяктан килгән горур кешесе өчен көрәшкә чыкканбыз икән, һичшиксез барлык чараларыбыз да гаять төгәл, конкрет булырга тиеш. «Аракы эчмә!», «Физкультура белән шөгыльлән!» — дип, өндәмә ташлау гына җитми. Барын да үз кулларыбыз белән ясап та бирергә тырышыйк! Үзебез башлап йөрик! Нәтиҗәсе озак көттермәс!

## Фәүзия Бәйрәмова

# КӨРӘШ

Бу көрәш ничә елларга сузылды икән? Авыл халкы җиде-сигез еллар дип бара, Балтачта, ун еллар чамасы, диләр. Миңа калса, бу көрәш инде миллион еллар — кешелек барлыкка килгәннән бирле дәвам итәдер. Яктылык һәм караңгылык көрәше, намус һәм яла көрәше. Корбаннары да күп булгандыр бу көрәшнең. Ике як та үзен хаклы дип санагандыр. Агын — акка, карасын карага бары тик Вакыт кына аерып күрсәтә.

Балтач районының иң төньяк чигендә җыйнак кына бер авыл бар. Моңа кадәр әле аның яхшы яктан да, начар яктан да телгә, тарихка кергәне булмаган. Ә менә шушы көрәш башлангач, аның исеме Мәскәүгә, иң югары оешмаларга хәтле барып җитә. Хат авторы башта кемлеген яшерә, аннан, кыюланып китеп, үзен хаклы санап, исемен дә күрсәтеп яза башлый. «Яшь ленинчы» газетасыннан башлап, республиканың барлык газета-журналлары, Казан һәм Мәскәү комиссияләре шушы хатларда язылганнарны тикшерәләр. Һәр хатта ярдәм сорау, мәсьәләгә тизрәк ачыклык кертү, урынсызга рәнҗеткәннәре өчен гаепле кешене хөкемгә тартырга чакыру: «Мин, «Якты юл» колхозының элекке члены Гыйләҗетдинов Гәрәфетдин, III группа инвалид, колхоз председателе Хәмит Гәрәев аркасында авылдан куылдым. Чөнки ул миңа эш бирмәде. Малларымны көтүгә чыгармады. Балаларым мәктәпкә йөри алмады. Хатыным да авыру. Без биш бала белән авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булдык. Гәрәев үзе колхоз байлыгын урлый. Мотоцикл, машина, тана сатып, акчасын үзенә үзләштерә. Килеп тикшерүегезне сорыйбыз».

Хатлар әнә шулай языла. Хәвефле хәбәр бик күп кешене аякка бастыра һәм Гыйләҗетдиновның һәр хаты саен эшне җентекләп тикшерә башлыйлар. Ун елга якын председательнең һәр адымын, һәр кылган эшен җиз иләктән уздыралар, дисталәгән кеше белән сөйләшәләр, ләкин һәр очракта халыкның, кыя булып, председательне яклавын күреп, гаҗәпкә калалар. Инде тикшерүләр һаман кимемәгәч, эшләргә, яшәргә комачау итә башлагач, колхозның барлык коммунистлары җыелып, партиянең район һәм өлкә комитетларына хат язалар. Хатта болай диелә:

«Якты юл» колхозы Хәмит Гәрәев эшли башлаганнан бирле гел үсештә. Колхозның экономикасы ныгыды, шушы елларда дәүләттән алынган бурычлар түләп бетерелде. Халык җитәкченең эшеннән канәгать. Ни өчен «шабашник»ның сүзенә ышанып, коммунист җитәкченең эшенә, тормышына шундый ревизия ясала? Ни өчен бу тикшерүләргә һаман чик куелмый? Без, колхоз коммунистлары, нигезсез бу жалобаларны тикшерүне туктатуны сорыйбыз. Гәрәев халык өчен кирәк. һәм без аның өчен көрәшәчәкбез. Ә Гыйләҗетдинов кебек типлар авыл, ил өчен түгел, бәлки үзләре өчен генә яшиләр. Колхоз тормышында шундый кешеләрнең тон бирергә тырышуларына каршы да без көрәшәчәкбез».

Кемгә каршы шулай күтәрелеп чыга соң авыл халкы һәм кемне һәртөрле усаллыктан, нахактан якларга, сакларга тырыша? Алар икесе дә — бер авыл, бер чор кешеләре. Ир уртасы кешеләр, берсенең — биш, икенчесенең дүрт баласы бар. Нинди шартларда, нәрсә хакына кан дошманга әйләнә соң бу ике авылдаш?

...Моннан ун-егерме ел элек республиканың төньяк районнарында яшәүче ир-атларның канына сеңгән бер гадәт бар иде: бераз гына тормыш авырая башладымы, балтапычкыларын җыялар да, күрше өлкәләргә чыгып китәләр. Колхоз кырында эшләргә кеше юк, абзарлар җимерелеп килә, юллар йөрерлек түгел, ләкин акча эшләргә китүчене ул борчымый, аның күз алдында үз хуҗалыгы, үз йорты, үз балаларының киләчәге. Һәм ул, баш күтәрми, бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле балта белән селтәнеп, үз кесәсенә тиенләп акча җыя, гаиләсен, балаларын сирәк күрә, ләкин тормышының көннән-көн ныгый баруын сизенә ул. Гыйләҗетдинов та менә шушындый «оста»ларның берсе

була. Берничек тә колхозда эшләтеп булмый аны. Авыруын исәпкә алып, каравылга чыгарга да тәкъдим итеп карыйлар — ризалашмый, фермага терлекләрне ясалма орлыкландыручы итеп чакыралар — якын да килми. Балтасын ала да тагын авылдан чыгып китә, һәм бер китүендә 5—6 ел рәттән шабашкада йөри ул. Ә үзе колхозда исәпләнә — гаиләсе авылда яши, бәрәңгесен утырта, мал-туары колхоз җирендә йөри. Бераздан олы малаен да үзе белән ияртеп алып китә. Аларга карап, авылның башка ирләре дә шул якка каерала һәм яңа гына председатель булып эшли башлаган Хәмит Гәрәев, идарә әгъзалары белән килешеп, кискен нәтиҗәгә килә. Гыйләҗетдинов кебекләрне туктатмасаң, болай да дәүләткә миллионлаган бурычы булган колхоз бөтенләй авыр хәлдә калырга мөмкин. Кисәтеп-кисәтеп тә теләсә кайда акча эшләп, үз тормышын гына кайгыртып йөрүеннән туктамагач, җыелыш җыеп, Гыйләҗетдиновны колхоздан чыгаралар. Зур янау, шау-шулар белән ул күрше Киров өлкәсенә күчеп китә. Шунда барып совхозга урнаша һәм Гәрәев өстеннән берсеннән-берсе усал, күләмле жалобалар ява башлый. Авылда калган туганнарына Гарәфетдин еш кайтып йөри, Гәрәевнең «гаепләрен» җентекләп җыя, һәр адымын, һәр сатып алган әйберен теркәп бара һәм шул мәгълүматлар белән күрше Чепья авылына төшеп китә.

Шушы урында язмабызга тагы бер «герой» килеп керергә тиеш иде. Ләкин сугыш ветераны икәнен искә алып, без ул агайның исемен күрсәтмәскә булдык. Гәрчә аның кулы белән язылган хат-жалобалар бик күп кешеләрнең вакытын, тынычлыгын, сәламәтлеген алса да. Язу-сызу осталыгы чамалы булган Гыйләҗетдиновка бөтен жалобаларны, тәртибен китереп, күп нөсхәләрдә, илнең төрле тарафларына барып җитәрлек итеп, шушы агай язып бирә. Һәм ун ел буе уннарча кешеләр, төп шөгыльләреннән бүленеп, шул хатлардагы һәр пунктны, Гәрәевнең һәр кылган эшен тикшерәләр. Инде председательнең үзеннән бер генә кыңгыр эш тә таба алмагач, дәгъвачылар колхозның экономикасына анализ ясый башлыйлар, акча мәсьәләләрен күтәреп чыгалар. Гарәфетдиннең авылда калган туганнары кирәкле бөтен мәгълүмат белән тәэмин итеп торалар. Көрәш кискенләшкәннән-кискенләшә бара, районадагы зур-зур иптәшләр дә, бу мәгънәсез һөҗүмгә вакытында нокта куясы урында, көрәш сызыгының ике ягына бүленәләр, фикер каршылыгында яшәгән кайбер җитәкчеләр өчен «Гәрәев эше» үзара һөҗүм итешү коралына әйләнеп китә. Мәсьәлә, куерып, тагы Казан белән Мәскәү арасында йөри башлый. Гыйләҗетдиновның шәхси усаллыгы социаль төс, социаль бәлагә әйләнү куркынычы туа. Һәм колхозның коммунистлары, председатель Хәмит Гәрәевне яклап, тиешле оешмаларга хат язарга мәҗбүр булалар.

Кем ул Гәрәев? Жалобаларда язылганча, куркыныч бер тип, карак, җинаятьчеме, әллә, авыл коммунистлары бәяләгәнчә, принципиаль, акыллы, кешелекле җитәкчеме? Бу сорауларга җавап бирергә ашыкканчы, 16 ел буе Гәрәев җитәкләгән колхозга, кешеләр тормышына күз салыйк әле! Кешенең тормышы аның өстеннән күпме жалоба язылганга карап түгел, аннан соң ни калуына карап бәяләнә.

Әгәр 16 ел гомерен шушы Гыйләҗетдинов белән генә көрәшеп уздырса, хәтта җиңеп, акланып чыкса да, Гәрәев бу язманың герое була алмас иде. Ләкин шушы 16 ел эчендә Гәрәев зуррак максатлар — авылдагы яңа тормыш, кешеләрнең аңында яңа караш өчен дә көрәшкән икән бит! Кечкенә генә бер колхоз мисалында җирнең, кешеләрнең нинди могҗизалар тудырырга сәләтле булуын күрсәткән ул. Күп кенә хуҗалыкларда бүген генә күтәрелгән проблемалар монда инде берничә ел элек хәл ителгән, без сокланып сөйләгән күрсәткечләр — монда инде гадәти хәл, күпләр өчен хыял булган тормыш монда — чынбарлык.

1964 елда, Хәмит Гәрәевич председатель булып эшли башлаганда, «Якты юл» колхозының дәүләткә берничә миллион бурычы була. Хәзер исә колхозның 1 миллион сум чиста үз маясы бар. Бүгенгесе көндә дә дәүләткә муеннан бурычка баткан колхозлар өчен бу хуҗалыкның күтәрелү тарихы бик гыйбрәтле. «Нәрсәдән башладыгыз соң?» — дигән сорауга Хәмит Гәрәевич бүген: «Барысыннан да»,— дип җавап бирер иде. Кешеләрдән, тәртиптән, яңалыкларны белеп, ышанып файдаланудан һәм... өметтән. «Бу авыллар барыбер үзгәрергә, яхшырырга тиеш!» — дигән якты өметтән. Хәмит Гәрәевич үзе агроном кеше, һәм үзгәреш кертүне җирдән башлавы да гаҗәп түгел. Тагы саннарга күчик. Ул эшли башлаганда, һәр гектар җирдән 9—10 центнер уңыш алынса, узган ел ул — 31,4 центнер булган. Ә бер участокта, тәҗрибә өчен чәчеп караган бодай гектардан 44 центнер уңыш биргән. Сере нидәме? Башны туктаусыз эшләтеп торуда. Әйтик, шушы бодай кырына Гәрәев бөртекне... тоташ чәчтергән. Ничә еллар кулланылган рәт-рәт чәчү алымы белән түгел, борынгырак ысулдан файдаланган председатель. Чәчкечләрне дә үзләре ясаганнар. Быел кырларга алты шундый чәчкеч чыгарырга торалар, көздән, тәҗрибә өчен, 7—8 гектар арышны шулай чәчеп караганнар. Болай чәчү — Гәрәевнең балачак хыялларының берсе.

Районда беренчеләрдән булып, алар җирне яссы кискечләр белән эшкәртә башлаганнар. Монысы — Мальцев ысулы. «Сельская жизнь»да шул турыда мәкалә укуга, Гәрәев

Целиноградка, махсус заводка кеше җибәрә. Ләкин башта аларга ул яссы кискечләрне бирмиләр, Мәскәүдән махсус хат яздырып алгач кына, 5 яссы кискеч алып кайталар, хәзер бу деталь аларда уннан артык. Ләкин аны теләсә ничек, һәр елны файдаланмыйлар бу колхозда. Бер елны җирләрне гадәти сукалыйлар, икенче елда инде яссы кискечкә күчәләр. Камыл өстә кала, җирдә йомшак катлам барлыкка килә, туфракта дым саклау, һава алмашыну өчен дә бу ысул бик файдалы, эрозиядән дә коткара.

Соңгы елларда шундый зур уңыш алуның өченче сере — ашламада, аны җиргә дөрес кертүдә. Киров өлкәсеннән ташып, һәр гектар җиргә берәр тонна фосфорит кертәннәр. Органик ашламалар да һәр участоктагы туфракның мөмкинлекләрен күздә тотып кулланыла. һәр елны мул иттереп пар җире калдыралар. Җир белән биредә әнә шулай бик сак, уйлап, киләчәкне дә күздә тотып эш итәләр. «Бу кырлар гектардан 50 шәр, 60 шар центнер уңыш бирергә сәләтле,— ди Хәмит Гәрәевич.— Тик моның өчен әле сортларны да яхшыртырга, яңартырга кирәк, сугаруны да көйләп җибәрергә...»

Гәрәев җитәкләгән колхозны игенчелек буенча республика тарихыннан сызып ташлап булмый. Кәрәшнең бу тәрәндә ул җиңеп чыкты. Халык алдында, ил алдында, эш белән. Инде колхозның терлекчелектәге хәлләренә күз салыйк.

Моннан 15—16 ел элек терлек ябарга абзары да булмаган колхоз бүген нәсел таналары үстереп сату буенча республикада иң эре хуҗалыкларның берсе санала. Биредә хәзер 2500 баш мөгезле эре терлек бар, һәр ел саен шуның 1100 ен, 420 шәр килограммга җиткереп, 5—6 айлык буазлык белән, республика хуҗалыкларына саталар. Тәүлеклек артым (601 грамм), терлекләрнең яхшы нәселле, нык булуы ягыннан «Якты юл» колхозы шундый 42 махсус хуҗалык арасында республикада беренче урында тора.

Бу хәтле терлекне карарга кайдан кеше табып бетерә соң Гәрәев? Таналарда гына да 70 кеше эшли, инде 1976 елдан бирле терлекчелектә ике смена. Мәктәпне тәмамлаган кызлар фермага бик теләп киләләр. Авылдан китүчеләр юк диярлек. Колхоз бөтен язгы-көзге кыр эшләрен бары тик үз көче белән генә башкарып чыга. Читтән китереп эшләтү биредә юк. һәр колхоз җитәкчесенең хыялы бит бу! Гәрәев, ярты көчен, сәламәтлеген жалоба тикшерүләргә сарыф иткән Гәрәев, ничек ирешкән соң моңа? Бу тыйнак, моңсу, әдәпле кешедә халыкны шулай үз артыннан ияртә алырлык нинди көч, җан олылыгы бар соң? Моның да сере, җавабы бик гадидер — кешеләр аның үзе өчен түгел, ил, халык өчен шулай тырышып йөрүен күрәләр бит. Кешеләр барысын да күрә: председательнең өе иске икәнен дә, 50 яшьлек юбилеен уздырырга урыны югын да. Шул ук вакытта ел саен икешәр-өчәр кешегә колхозның өй салып бирүен дә күрә. Куныр авылында хәзер әр-яңа урам — колхоз төзеткән йортлардан гына торган яңа урам барлыкка килде. Анда гел яшьләр генә яши. Кешеләр председательнең соңгы елларда йөрәк авыруыннан җәфаланып, больницаларга кереп ятуын да күрәләр. Күрәләр, саклый алмаганнарына үзләренең йөрәкләре өзгәләнә, шуңа күрә авылда «Хәмит хакына» дип әйткәннәрен ишетеп гаҗәпләнергә кирәкми. Хәмит дигән Кеше хакына биредә халык хәзер барысын эшләргә дә әзер. Председательнең иң якын киңәшчеләре, таянычы — колхозның партком секретаре Мөхәммәт Гыйниятов, агроном, элекке бригадир Галимҗан Гыйльмуллин, механик Равил Хәбибуллин, баш зоотехник Илдар Минһаҗев, ветврач Габдулла Гомәров, терлекчеләр Рабига Гыйләҗева, Минзирә Әхмәтшина, Мөзәянә Мөбарәкшина, Мәрзия Хәбибуллина, механизаторлар Нуретдин Шәйхетдинов, Динус Мәгъсүмов, Әскар Миргалимов, Габделфәрт Әүхәдшин, Рәхимҗан Әшриев, Гарәфетдин Фәсхетдинов һәм башка бик күп, бик күп иптәшләр. Куныр, Шода авыллары халкы. Җитәкчене шул хәтле изгеләштереп, зурлап, аның хыялларын тормышка ашыруда җанын да, аһын да кызганмаган мондый кешеләрне минем очратканым юк иде әле. Гәрәевнең бөтен гомере, тормышы, җаны авылдашларының күз алдында. Әтисе Солтангәрәй авылның иң абруйлы кешесе була, әнисе Оркыя да әдәплелеге, тыйнаклылыгы ягыннан авыл хәтерендә калган. Бу нигездә җиде бала үскән. Армиядән тыш, Хәмитнең авыл күзеннән озакка югалып торганы да юк. Аның каядыр еракка, ялга китеп баруын да хәтерләмиләр. Соңгы елларда бөтенләй дә ялсыз эшли. Бер караганда, игенчелек, терлекчелек рәткә салынган, җитәкчегә бераз кызулыкны киметә төшәргә дә ярый кебек. Ә ул әнә һаман туктауны белми. Авыл тормышында тулы гармониягә ирешү өчен игенчелек, терлекчелектәге уңышлар гына аз. Кешеләрнең үзендә үзгәреш кирәк, шәхси хуҗалыкларның тормышын үзгәртергә кирәк, авылга матурлык кирәк! Куныр, Шода авылларын урап алган тау битләрендә яшь урман шаулый. Хәмит урманы ул. Бу якларда шулай дип атыйлар. 1967 елдан башлап, тау битләренә һәр елны 20—30 гектар урман утырткаННар. Бу игелекле эшне дә Гәрәев башлап җибәргән. Хәзер дә, һәр язны кирәк тотып, мәктәп балалары белән бергә тауга чыга. Инде яшь урман 300 гектар мәйданда шаулый. Гасырлар буе шаулаячак...

«Якты юл» колхозы — район үзәгеннән иң ерак колхоз. Балтачка —40, тимер юлга — 70 чакрым. Күп хуҗалыкларның йөрәгенә төшкән юл мәсьәләсе бу колхозда ничегрәк тора соң? 1973 елда биредә нык таш юллар күтәртелгән булган. Ләкин Хәмит Гәрәевич моңа да вакытлы хәл дип карый. Аның хыялы — авыл юлларын асфальт белән каплау. Колхоз-

ның хәзер моңа мөмкинлекләре, рәте бар инде. Гәрәев үзендә кечкенә генә асфальт заводы ачуны планлаштыра. Шул хакта килешү өчен, инде Воронежга кешеләр дә җибәрелгән. Һәм быелдан да калмый, эшне көйләргә уйлыйлар. Куныр, Шода авылларын гына түгел, тирә-яктагы күп хуҗалыкларны юллы итәр әле Гәрәев заводы. Чөнки бирегә уйлаганны үтәмичә калмыйлар.

Авылда тагы нәрсәләр эшләргә була? Хыялның, мөмкинлекләрнең чиге юк икән. Куныр, Шода авыллары тормышыннан күпләр көнләшерлек. Сер түгел, печән өсте җитсә, авыл кешесе яныл-көеп, терлегенә печән әзерли башлый. Колхоз эше дә онытыла, тәртип бозулар да булып ала, җинаятькә-урлашуга кадәр барып җиткән очраклар да бар. Гәрәев бу хәлдән ничек чыккан соң?

Бирегә бу эш берничә көндә хәл ителә. 207 гектар чамасы җирдән печәнне колхоз үзе чаптыра, бүлә, тракторын бирә, һәм аз вакыт эчендә бөтен шәхси хуҗалыклар кышка азыклы булалар. Печән шулай ике тапкыр бүленә. Икмәк белән дә шул ук хәл — колхозда эшләүче һәр кеше 20—30 центнердан да ким икмәк алмый. Саламын, чөгендерен, итен, сөтен — барысын да колхоздан яздырып алырга була. Колхозның моңа рәте бар. Үтенечле кеше моннан башын иеп борылып китми. Хәтта күрше Чутый авылында йорт янгач та, ярдәм сорап, «Якты юл»га килгәннәр. Хуҗалыклар башка булса да, җир бер бит, ил бер. Һәм бәла төшсә дә, сөенече булса да, халык Гәрәевкә ашыга.

Республикада «Халык мәгарифе отличнигы» исемен йөртүче председательләр күп түгел. Шуларның берсе — Балтач районы «Якты юл» колхозы председателе Хәмит Гәрәев. Гомер буе башлангыч мәктәпле Куныр авылы 1981 елда колхоз хисабына салынган урта мәктәпле булды. Колхоз хисабына Кунырда — 75, Шодада 50 бала өчен бакча төзелә. Куныр балаларына хәзер ул гына аз — бакчаны 125 урынлы итеп үзгәртергә уйлап торалар. Авылда яшь гаиләләр күп, йорт саен 2—3 бала үсә. Мәктәп-бакчаларыңны гына өлгерт! Һәм төзи колхоз. Авылларының шулай гөрләп яшәвенә сөенә-сөенә төзи. Бирегеге ике катлы таш кибетне, аның эчендәге мал-мөлкәтне хәтта кайбер район үзәкләрендә дә күрмисең. Мондагы яхшы җиһаз, суыткыч, келәм, мотоцикл, хрусталь, фарфор савыт-саба, соңгы мода белән тегелгән туннар, аяк киемнәре — барысы да колхозчылар өчен. Аскы катта азык-төлек сатыла, кулинария цехы эшли. Чәкчәк, бәлеш, паштет, кош теле — нәрсә телисең, барысын да пешереп бирәләр. Авыл туйлары шушы цех ярдәменнән башка узмый хәзер.

Председательнең акыл көче кергән, үзе башлап оештырып йөргән тагы нинди эшләр бар икән авылда? Күрәш бизмәнендә ике кешенең яшәү рәвешен салгач, барысын да күрсәтәсе килә. Бу тирәләрдә табигать биргән зур сулар юк. Халык никадәр бай, матур яшәсә дә, сусыз моңсызрак, җансызрак кебек булыр иде. Һәм Хәмит авылын ясалма күлләр белән әйләндереп ала. Аларга Арча балык хуҗалыгыннан алып кайтып, балыклар җибәрәләр. Балыгы — халыкның үзенә, матурлыгы да үзенә. Балыктан тыш, һәр язны колхоз авыл халкы өчен үрдәк, бройлер чебиләре кайтарта. Кемгә күпме кирәк, алдан исемлек җыела. Колхозчы, бар эшен ташлап, район үзәге белән ике арада йөрми монда. Намус белән эшләсен генә, колхоз аның тормышын җиңеләйтү, матурлау өчен бөтенесен оештыра.

Ә хыялның барыбер чиге юк икән. Клублары хәзер дә менә дигән, әмма колхозга аерым спорт залы булган культура сарае кирәк. Туйлар уздыра алырлык банкет залы кирәк. Хәмит Гәрәевич хыялында ул тулы бер комплекс булып яши — көнкүреш йорты, саклык кассасы, яңа кунакханә, медпункт. Ә нигә хыялда гына? Алар инде колхозның алдагы еллардагы планында да бар.

Язмамның ахырында Шода авыл кешесе Фатыйма Хәбибуллинаның колхоз председателе Хәмит Гәрәевкә язган хатыннан юллар китерергә телим: «...50 яшь артыннан 40 килми. Бөтен көчегезне колхоз өчен түктегез. Сезне, зур эш эшләп уздырды гомерен дип, җаным якын итә. Бөтен авыл сезгә озын гомер, сәламәтлек тели».

Кем ул Гәрәев? Ул — «Якты юл» колхозы, аның иминлеге, төзеклеге. Ул — колхозда барган яңа төзелешләр, шаулап утырган яшь урман, зәңгәр күлләр, гектарыннан 40 ар центнер уңыш бирүче иген кырлары... Ул — киләчәк кешесе, илнең терәге.

Ә кем ул Гыйләҗетдинов? Ул — кичәгенең бер кара төне. Ил өчен түгел, үзе өчен генә көрәшеп, кешеләргә тынычлап яшәргә, эшләргә комачау итүче тар карашлы бер бәндә. Бер авыл, бер җир кешеләре, ләкин бер фикер кешеләре түгел! Һәм Вакыт, Тарих, Хакыйкать аларның һәрберсен, кылган эшләренә карап, үз урыннарына куйды. Шулай булырга тиеш тә иде.

Рафаэль Мостафин

# ЯЗУЧЫ ҺӘМ ТЕЛЕВИДЕНИЕ

«КПСС хезмәт иясе массаларының рухи һәм материаль культура байлыкларын тулырак һәм тирәнрәк үзләштерүенә, аларны художество иҗатына активрак тартуга зур әһәмият бирә»,— диелә Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Программасының яңа редакциясендә.

Совет халкының культура дәрәҗәсе үскән саен, сәнгатьнең җәмгыять тормышына, андагы мораль-психологик климатка йогынтысы көчәюе Программада аеруча басым ясап әйтелә. Әлеге йогынты күп дәрәҗәдә массовый информация һәм пропаганда чаралары, аерым алганда, тормышыбызда көннән-көн ныклырак урын ала барган телевидение челтәре аша гамәлгә ашырыла. КПСС Программасының яңа редакциясендә әйтелгәнчә, «телевидениене үстерүгә, халыкны радио һәм телепрограммалар белән колачлауны бөтен яктан киңәйтүгә, тапшыруларның эчтәлеген, идея-художество дәрәҗәсен яхшыртуга һәм мавыктыру көчен арттыруга аеруча зур игътибар биреләчәк».

Телевидение тапшыруларының тәэсир көчен һәм сәнгатьчәлек дәрәҗәсен күтәрү юллары, язучыларның телевидениедә катнашуы үзенчәлекләре, ниһаять, сәнгатьнең яңа төре булган телевидение белән әдәбиятның нәтиҗәле хезмәттәшлек мөмкинлекләре... Журналыбызның бу санында менә шушы мәсьәләләр турында үзенең уйлanулары белән уртаклашу өчен язучы Рафаэль Мостафин сүз ала.

## Сәхнә арты хәлләре

Телевидение аша беренче тапкыр чыгыш ясавымны һич онытасым юк. Телекамераның кызыл күзе әле кабынырга да өлгермәде, ә минем инде алдан ук әзерләп-өйрәнеп куйган сүзләр баштан очып чыгып та бетте. Бу минутта үз экраннары аша миңа текәлгән меңләгән чырай күз алдыма килде: аларның кайсыдыр мыскыллы елмая, кайсыдыр өметсезләнеп кул селти кебек иде... Алдымдагы кәгазьгә карарга оят, сүзләр каядыр бугазда бөялеп калды, тел әйләнми, ул саташулы төш күргәндәге кебек, бөтенләй оеп калган бугай. Аркама шыбырдап тир бәреп чыкканын тоям... Ниһаять, зур авырлык белән генә нәрсәдер оештырып әйттем шикелле. Үземнең фикер ярлылыгыма хәйран калдым һәм «тамашачыларга берничә сүз әйтергә» ризалык биргән сәгатемне каһәрләдем шулчак... Шактый вакытлар узгач кына, мин үземнең ул чактагы халәтемне аңладым: психологлар моны телекамера каршында сихерләнү дип атыйлар һәм хәтта... буар елан авызына кереп баручы куян белән чагыштыралар икән.

Шулай да телевидениедә язучыны сагалап торган кыенлыкларның иң зурысы әле бу түгел.

Күз алдына китерик: көннәрнең берендә хөрмәтле язучыбыз телестудиягә үзенең яңа әсәрен — повестен, хикәясен яисә поэмасын күтәреп килде ди. Әкияттәгедәй уңышлы ситуацияне алыйк: әсәрне барысы да бик ошатып, аны шунда ук планга кертергә һәм

---

РАФАЭЛЬ МОСТАФИН (1931) — тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, ТАССРның атказанган культура работнигы, М. Җәлил иҗатына, татар совет әдәбияты проблемаларына багышланган, үзәк һәм республика матбугатында басылган күп санлы мәкаләләр, шулай ук татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Өзелгән җыр эзеннән», «Образ времени» һ. б.— барысы егермедән артык китап авторы. Казанда яши.

эфирга чыгарырга әзер торсыннар ди. Хәзер инде тик бер генә шартны үтисе кала: телевизион сценарий язарга кирәк. Кочак җәеп каршы алудан, мактаулардан күңеле йомшарган, хәтта бераз башы әйләнә башлаган язучыбыз, әлбәттә, бу шартка гына бик рәхәтләнеп күнә. Телевизордан аның әсәрен күрсәтәчәкләр бит!

Ләкин беркатлы автор, башына төшкәч, мөһим бер нәтиҗәгә шактый тиз төшенеп өлгерә: йомшак кәнәфидә, телевизор әрҗәсе каршында кофе эчкәләгән булып, мыек астыннан гына көлемсерәп утыру бер нәрсә, ә үзең сценарий төзеп карау бөтенләй икенче нәрсә икән ул! Бер атна, бер ай азаплана безнең автор, бүтән сценарийлар белән танышу өчен студиягә дә йөреп карый, язган нәрсәсен бер түгел, биш кат эшкәртә, худсовет утырышларында, тикшерүләрдә катнаша һәм... бөтенесен яңабаштан башларга туры килә. Ниһаять, сценарий тәмам «киртәсенә кергәч», язучыга әле режиссер белән бергәләп актерларны сайлап алырга, художник-оформительләргә киңәш-юнәлеш бирергә, тапшыруны бизәү өчен төрле сурәтләр (фото, рәсем, документлар һ. б.) табарга, күпсанлы репетицияләрдә һәм кинога төшерүләрдә катнашырга туры килә. Инде эфирга чыгу көне килеп җиткәч, көтмәгәндә генә бер актерның авырып киткәнлеге, икенчесенең гастрольдә булуы, ә кайсысынындыр «ансамбльгә туры килмәве» билгеле була. Иң соңгы минутта нәрсәнедер кире эшләргә, кыскартырга, өстәп язарга кирәк... Кыскасы, «эфир аша тапшыру» өчен язучы әсәрнең үзен язуга караганда да бик күпкә артыграк көч һәм вакыт сарыф итәргә мәҗбүр була. Менә шуннан соң инде язучы халкын телевидениегә «аяк-кулын бәйләп» тә китереп булмавының сәбәпләре аңлашыла башлый.

Шул ук вакытта без төп хакыйкатьне истән чыгара алмыйбыз: бүген телевидение тормышыбызның түренә кыю адымнар белән үтеп, хуҗаларча гына түгел — хакимнәрчә тәхеткә менеп утырды. Әле кайчан гына: «Дустым сине яр итәрмен, телевизорың булса...» — дип шаярталар иде, инде менә ул байлык билгесе, өй күрке булудан узып, тормыш-көнкүреш ихтыяҗына, бик мөһим информация чыганагына әверелде. Социологлар, буш вакытның гомум бюджетында (ә бу — илебездәге һәр кешегә елына уртача 1800 сәгать дигән сүз) телевизор карау беренче һәм төп урынны алып тора (ягъни елга 550—600 сәгать туры килә), дип раслыйлар. Ә бу бит — китап укуга киткән вакыттан уртача биш тапкыр күбрәк!

Укудан, хәтта зиһенне эшләтүдән биздерә дип, телевидениене күпме теләсәң шулхәтле сүгәргә була (монда хаклык та шактый), тик бер нәрсә белән килешми мөмкин түгел: телевизор экраны бүген массаларга идеологик һәм эстетик тәэсир ясауның бик куәтле чарасына әверелде. Әлеге дә баягы социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, илебезнең «уртача» кешесе кино, театр, концерт, күргәзмә залларында көненә нибары 5—10 минут кына вакытын сарыф итсә, «үз аягы белән килгән» әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен карау өчен, ул көн саен уртача 1 сәгать тә 40 минутлап телевизор каршында утыра.

Әйе, күп кенә язучылар әлегә кадәр «искечә» — телевидение «васвасәсенә» бирелмичә, кабинетлар тынлыгына чумып эшләүне хуп күрәләр. Ә бит «васвасәгә» бирелмәслек тә түгел: уңышлы килеп чыкканда, телевизион тапшыруның берсе генә дә кайбер язучыга бөтен иҗат гомере буена җыя алмаган «тираж»ны яуларга мөмкинлек бирә! Шигырь китабы уртача 3—5 мең, ә проза 15—30 мең данә булып басылганда, безнең республика телевидениесенең бер тапшыруын, ким дигәндә, 1 миллион 200 мең кеше карый. Үзәк телевидениенең аудиториясе исә йөз тапкыр зуррак. Мәсәлән, Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» пьесасы буенча Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры куйган спектакльне үзәк телевидение аша илебездәге йөз миллионлап кеше карый алды. Бу хәтле тамашачыны җыяр өчен театрга, шәт, өч йөз ел тирәсе вакыт кирәк булыр иде.

## Телевизион сәхнәдә...

Басым ясап әйтергә кирәк: телевидение — язучы сүзен һәм аның әсәрен миллионлаган тамашачыларга җиткерергә мөмкинлек бирүче куәтле техник чара гына түгел. Ул, барыннан да элек, сәнгатьнең мөстәкыйль төре, яңа мөмкинлекләргә, специфик үзенчәлекләргә ия булган, автор-сценаристка үзгә таләпләр куя торган төре. Әгәр дә инде телевидение әлегә кадәр үз функцияләрен тиешенчә үк башкара алмаган икән, монда һич тә яңа сәнгать үзе гаепле түгел, төп сәбәп — аның мөмкинлекләрен санга сукмауда, спецификасын бәяләп бетермәүдә, техник җәгәрен азакка хәтле файдалана белмәүдә.

Без телевизор аша төрле кинофильмнарны һәм гадәти спектакльләрдән трансляцияләүләрне яратып карыйбыз. Мондый очракларда телевидение бары тик сәнгатьне өйгә китереп бирүче функциясен генә башкара. Ләкин, шуның белән бергә, соңгы елларда махсус, әле еш кына — күп серияле, дәвамлы телефильм һәм телеспектакльләр гадәткә кереп, популярлаша бара. Мондый тапшыруларны, «Мең дә бер кичә» әкиятендәге кебек, көннән-көн арта баручы кызыксыну белән, һәр кичне бөтен гаилә бергә җыелып карыйлар.

Икенче көнне эштә дә сүз гел шул турыда гына була, тәэсирләр уртаклашу, бәхәсләшү берничә көнгә сузыла. Менә шушы күп сериялелектә үк телевидениенең үзенә генә хас мөмкинлекләре күренә. Чынлап та, уйлап карасаң, 5—6 шар, кайчакта әле 10—15 әр кич рәттән театрга яисә киногa йөрергә теләүче табылыр иде микән!. Һәр көнне безнең өйләргә «үзе килеп йөргән» телевидение өчен исә бу бик гадәти хәл. Берничә серияле булу, үз нәүбәтендә, катлаулы, күп планлы әдәби әсәрне, әйтик, театраль инсценировка яки кино вариантына караганда, тирәнрәк һәм тулырак итеп аңлау-тою мөмкинлеген бирә.

Театрдан аермалы буларак, телевидение үзен төрле шартлылыклардан, кысалардан бәйсезрәк хис итә, хәрәкәт мөмкинлекләрен чагыштыргысыз дәрәҗәдә киңәйтеп җибәрә: геройларны җиңел генә бер мохиттан икенчесенә күчерә, күз ачып йомганчы аларның үткәненә, яисә киләчәгенә алып китә. Кинодан үзгә буларак исә, телевидение тамашачыга якынрак, өй шартларына яраклашканрак, «кулга ияләшкәнрәк» дип әйтергә мөмкин. Ул экрандагы геройның йөзенә игътибар беләнрәк, текәлебрәк карарга, аның «сиңа гына» сөйләгән сүзләрен күңел салыбрак тыңларга, хис һәм фикерләрен тирәнрәк кичереп кабул итәргә мөмкинлек бирә. Әлбәттә, һәр нәрсәнең үз киртәләре, үз чикләре бар. Әйтик, табигать манзарасын ерактан, киң иттереп төшерү яисә күп кешеле баталь күренешләр кинода бер төрле сурәтләнсә, телевизор экранында алар бөтенләй башкача килеп чыга. Телевидение — барыннан да элек, якыннан алып, эре план белән сурәтләү сәнгате ул. Шуңа күрә анда ялгыз актер да тамашачының игътибарын тотып тора ала, һәм, киресенчә, массовый сәхнәләр (мәсәлән, опера яисә балет күренешләре) театрга караганда күп кайтышрак тәэсир калдыра.

Менә шушы бай мөмкинлекләр һәм үзенчәлекләр Татарстан телевидениесе тарафыннан ничегрәк файдаланыла соң?

Безнең телевидение сәнгате кулында искиткеч хәзинә ачкычлары бар. Темалар, образлар, идеяләргә юмарт ул хәзинәнең исеме — классик әдәбият мирасы. Классика, бер яктан, актерларның сәхнә осталыгын үстерүдә менә дигән мәктәп булса, икенче яктан, ул тамашачыны вакыт сынавын узган әсәрләрнең сулмас гүзәллеге белән җәлеп итә. Классик репертуардагы пьесаларны (Кәрим Тинчурин, Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи һ. б. әсәрләрен) күрсәтү белән бергә, Казан телевидениесе соңгы елларда берничә оригиналь постановка да тәкъдим итте. Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повесте һәм Мирсәй Әмирнең «Саф күңел» романы буенча куелган кызыклы телеспектакльләр әле дә истә. И. Нуруллин китабы буенча — Габдулла Тукай, М. Гали романы нигезендә — Каюм Насыйри, Ш. Маннур романы буенча Муса Җәлил турындагы күп серияле постановкалар шулай ук зур кызыксыну белән кабул ителде. Аларның күбесе, тамашачылар соравы буенча, кабат-кабат күрсәтелде.

Шулай да, дөреслекне танырга кирәк, бу юнәлештә әле без беренче адымнарны гына ясадык.

Быел әдәбиятыбыз классигы Фатих Әмирханның йөз еллыгы киң билгеләп үтелде. Ф. Әмирханның татар культурасы үсешендә тоткан зур урыны, әдәби мирасының кыйммәте һәркайсыбызга билгеле. Ярымфантастик, ярымсатирик «Фәтхулла хәзрәт» повесте нигезендә генә дә нинди үткен, күңелле тамаша күрсәтеп булыр иде! Ниһаять, Ф. Әмирхан хикәяләрендәге геройлар — үз заманының караңгы почмакларыннан, ярыкларыннан яктыга тартып чыгарылган, гаҗәеп буяулар һәм нечкә штрихлар белән сурәтләп бирелгән кабатланмас типлар! Аларның бит һәркайсы тупырдап сәхнәгә чыгарга тора...

Яисә Заһир Бигиевның «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» дигән романын искә төшерик. Маҗаралы сюжет, байлык артыннан кууны сатирик фаш итү, тирән социаль эчтәлек — болар барысы да бик үзенчәлекле телевизион постановкага нигез була алыр иде.

Классик мираста нәкъ менә телевидение аша үзенең икенче тормышын башлап җибәрерлек, чын-чынлап үз яңгырашын табарлык әсәрләр бар. Һади Такташның «Җир уллары» һәм Гафур Коләхметовның «Ике фикер» пьесалары әнә шундыйлар рәтеннән. Алар шартлы, хәтта беркадәр гайре реаль образлылыкка корылган. Телевизион техника әлеге шартлылыкны үзенчә ачу, әсәрнең тирәнрәк катламнарына алып керү, үзәк идеясен калкурак итеп сурәтләү мөмкинлеге бирә.

Мираска мөнәсәбәт кебек традицион мәсьәлә телевизион ракурстан әнә шулайрак күренә.

## Төп юнәлеш — заман темасы

Әйе, хәзинәдә байлык аз түгел... Шулай да, аңлашыла ки, тамашачының игътибарын аеруча җәлеп иткәне, аның уй-хисләренә, тормышына аерата зур йогынты ясаганы — бүгенге заман турындагы әсәрләр. Бу өлкәдә дә безнең телевидениенең хезмәтләре игътибарга лаек дип әйтәсе килә. Аерым алганда, режиссер Ә. Зариповның «Йолдызлар җитә һәркемгә» (Әхсән Баяновның «Тау ягы повесте» буенча), «Генеральный уборка» (Ша-

риф Хөсәенов пьесасы), «Җомга көн кич белән» (Аяз Гыйләҗевның шул исемдәге повесте буенча), «Намус» (Гомәр Бәширов романы буенча эшләнгән) һ. б. телепостановкаларын билгеләп үтәргә мөмкин. Рус телендәге постановкалардан режиссер В. Кременчугскийның Диас Вәлиев пьесасы буенча куйган «Өйләнеп кайтучылар» исемле бик тә үзенчәлекле хезмәте хәтердә калган.

Тормыш үзе күрсәткәнчә, бик күп очракларда телевидение укучыны китаптан аера һәм әсәрне әкренләп, дикъкать белән укудан биздерә дигән сүзләр хак булып чыкмый. Киресенчә, әдәби әсәр нигезендә эшләнгән тапшыру еш кына әдәбиятны пропагандалау эшенә өлеш булып керә, укучыларда теге яки бу язучы һәм аның әсәренә карата кызыксыну уята. Китапханә хезмәткәрләренең әйтүенә караганда, мәсәлән, Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романы һәм Вакыйф Нуруллинның «Күпер чыкканда» повесте буенча куелган телевизион тамашалардан соң, әлеге әсәрләргә укучыларның игътибары күзгә күренеп арткан.

Татарстан телевидениесе күпмилләтле совет һәм дөнья әдәбиятының да иң яхшы үрнәкләренә мөрәҗәгать итә. Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» повесте һәм япон драматургы Несимораның «Шантажчы» пьесасы буенча күрсәтелгән телеспектакльләр татар тамашачыларында зур кызыксыну уятты.

Кабатлап әйтәм: уңышлар бар. Матур омтылыш һәм аның матур нәтиҗәләре күз алдында. Ләкин, әгәр без бүгенге татар әдәбиятының торышы һәм аның экранда чагылышы турында таләпчән сүз башлый калсак, ике арада гаять зур бушлык күрер идек. Тирән эчтәлекле, укучыларны чын-чынлап дулкынландырган күп кенә әсәрләр телевидение хезмәткәрләренең игътибарыннан читтә калып килә. Шуның нәтиҗәсендә, кайвакыт экранда аларның урынын көнкүреш ыгы-зыгысыннан гына гыйбарәт әсәрләр ала, чырайсыз персонажлар, күңелсез бертөслелек беренче планга чыга.

Тамашачы үзе яшәгән мохит, тормыш, заман турында иң борчулы сорауларына җавап эзли. Катлаулы хәлләрдә, четерекле мәсьәләләр алдында калганда яраткан герое нинди юлны сайлар? — тамашачы шуны белергә тели. Аңа курчак уены түгел — характерлар чынлыгы, дөреслеккә охшатып ясалган хәрәкәтләр түгел — тормыш фәлсәфәсенә үтеп керү кирәк. Нәкъ менә шундый таләпләргә туры килә торган әсәрләр язган Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Рафаил Төхфәтуллин кебек өлкән буын әдипләребез иҗатын, ни өчендер, телевидение сценаристлары бөтенләй диярлек күрми яшиләр. Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев яисә Марсель Галиев кебек урта һәм яшь буын язучыларның әсәрләре дә экранда гәүдәләндерү өчен гыйбрәтле материал бирә алыр иде. Бу материалдан әле үтә аз файдаланабыз.

Бигрәк тә яшүсмерләр өчен постановкалар мәсьәләсе көн тәртибендә тора. Яшьләрне җәгәрсез хәрәкәт, сару кайнатырлык геройлар белән җәлеп итә алмыйсың. Бары тик зур хыяллар, романтик ашкынулар белән тулы дөнья гына яшьлеккә канат куярга, илһам бирергә сәләтле. Шундый якты, оптимистик рух, мәсәлән, Габдрахман Әпсәләмов әсәрләреннән бөркелеп тора. Хәлбуки, Казанда телевидение барлыкка килгәннән бирле үткән еллар эчендә, хәтерем ялгышмаса, Г. Әпсәләмовның нибары бер әсәре («Ак чәчәкләр» романы) буенча гына постановка күрсәтелгән иде. Хәтта ил бәйрәмен — Бөек Җиңүнең 40 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнгәндә дә сценаристлар, нигәдер, аның «Кызыл йолдыз», «Ак төннәр», «Газинур» һ. б. ш. мавыктыргыч, героик рухлы әсәрләрен файдалана белмәделәр.

Соңгы елларда безнең әдәбиятта детектив характерындагы әсәрләрнең күтәрелә баруы күзгә ташлана. Зөфәр Фәтхетдиновның «Ачылган серләр» повесте укучыларда гаять зур кызыксыну тудырды. Әлеге әсәр мавыктыру сәләте белән генә түгел, совет чекистларының героик һәм авыр хезмәтен тормышчан итеп, романтик буяуларга манып тасвирлавы ягыннан да игътибарга лаек. Бу әсәр Ю. Семеновның «Язның унҗиде мизгеле» рәвешендәрәк, үзенә җәлеп итәрлек күп серияле телевизион постановка булып күз алдына килә. Кызганычка каршы, ул постановка әлегә минем хыялымда гына яши...

Профессиясе буенча юрист булган Мәгъсүм Насыйбуллинның китаплары да укучылар арасында бик популяр. Документаль кинокадрларга таянып, тикшерүчеләр һәм шаһитлар чыгышыннан файдаланып, телевидение әлеге әсәрләрнең документаль нигезен тагын да көчәйтә алыр иде. Тамашачыларга хокук тәрбиясе бирүдә мондый тапшыруларның эффекты күңелсез вәгазь укулардан бик күпкә нәтиҗәлерәк булыр иде, әлбәттә. Бездә әле һаман детектив жанрына карата алдан ук билгеле тискәре мөнәсәбәт яшәп килә. Янәсе, буш бер тамаша гына дип гаепләүләре бар. Ә бит үзәк телевидениенең бу өлкәдәге тәҗрибәсе (мәсәлән, һәркемгә таныш «Знатоки» сериясе) әлеге шикләнүләрнең нигезсез булуын күптән раслады инде.

Туры мәгънәсендәге тамаша кору, мавыктыра белү — җитдилекнең капма-каршысы түгел ич. Киресенчә, коры, күңелсез тапшыру барганда, тамашачының телевизорны сүндереп үк куюы мөмкин һәм әллә нинди җитди фикерләр дә аңа килеп җитмичә сүнеп калачак. Ә үткен, мавыктыргыч формада бик җитди проблемаларга да колакны торгызыр-

га, аларны үткәзеп әйтергә була. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, телевизор караучыларда иң зур кызыксыну уятканы — сатира һәм юмор кичәләре. Бу кызыксыну еш кына хәтта популяр эстрада җырчыларының концертына караганда да зуррак булып чыга. Үзәк телевидениенең «Вокруг смеха» тапшыруын алып баручы А. Ивановның иseme элегрәк поэзия сөючеләрнең дә бер өлешенә генә билгеле булса, хәзер ул популярлык ягыннан, шәт, иң танылган артистлар белән ярыша ала торгандыр. Уйлап карасаң, безнең телевидениедә дә шундыйрак цикл башларга була. Алып баручысын да әллә кайдан эзлисе түгел. Актерлар йортында оештырган ШТМ («Шаяннар һәм тапкырлар мәҗлесе») кичәләре белән язучы Роберт Батулла әлеге вакансиягә бик туры килүен күрсәтте. Телевидение тарафыннан исә юмористик һәм сатирик жанрларга карата бик үк ышанып җитмәү кебек мөнәсәбәтне генә үзгәртәсе бар.

Тагын бер кат ассызыклап әйтәсе килә: без эчтәлек турында гына түгел, материалны ничек җиткерү турында да күбрәк уйланырга тиешбез. Экранда бирелгән вакытны уздырып җибәрү артык читен булмас, ә тамашачының игътибарын, ышанычын яулау ифрат кыен. Эшнең ахыргы нәтиҗәсе исә нәкъ менә шул ышанычны яулауга бәйле.

Әлбәттә, камил телевизион постановка әзерләү өчен изге теләк кенә җитми. «Бал, бал» дигәннән генә авызга тәм керми диләр. Иң әүвәл яхшы әзерлекле белгечләр, режиссерлар, операторлар һ. б. кирәк. Телевидение кодрәтле көчкә әверелсә дә, бездә әле аңа кадрлар әзерләү мәсьәләсе бик начар куелган. Казанда, мәсәлән, профессиональ дәрәҗәдәге телевидение сценаристы, ягъни телевидениедә үзенең яшәү, иҗат мәгънәсен күргән һәм, әлбәттә, махсус белем алган бер генә кеше булса да бар микән?! Хәзергә кем тели, шул алына бездә телесценарий язуга. Беренче кыенлыкларга очрау белән һәм бу эштә әллә ни мантып булмаслыгына төшенгәч, әлеге «кем тели» кулын селтәп китеп тә бара.

«Хәзер массакүләм информация чараларының нәтиҗәлелеге һаман зуррак әһәмият ала бара,— диде М. С. Горбачев КПССның XXVII съездында.— Үзәк Комитет аларны иҗади төзелеш коралы итеп, ведомостволык һәм урынчылык белән уртаклыгы булмаган гомумпартия карашын чагылдыручы итеп карый».

Җитди эшкә мөнәсәбәт тә җитди булырга тиеш. Проблемаларны хәл иткәндә, телевидениегә даими авторлар рәвешендә драматик жанрда үзләрен таныткан осталарны, әйтик, Туфан Миңнуллин, Әхәт Гаффар, Рөстәм Мингалимов, Ризван Хәмид, Диас Вәлиев һ. б. драматургларны чакырып булыр иде. Аларның һәркайсының диярлек телевидениедә кызыклы гына сценарийлар, оригиналь постановкалар белән чыгыш ясаганы бар, кайберләре хәтта заманында телестудиядә эшләде һәм бу изге эшкә бөтен күңелләрен салып, талант көчләрен җигеп керешә алырлар иде.

Хәзергә исә, турысын әйтик, телевидение тулысынча диярлек фидакарьләр җилкәсендә яши һәм аның бүгенге көне мәсьәләнең материаль ягына артык игътибар итмәүче авторлар энтузиазмына гына бәйле. Шундый энтузиастларның берсе — тележиссер Әхтәм Зарипов. Ул сценарийларны үзе дә яза, башкалар язган йомшак, чиле-пешле сценарийларны да «деңгә кертә» (моны ул күп вакыт бернинди түләүсез эшли), татар әдәбияты әсәрләрен экранлаштыруга зур көч сала. Татар теленда әзерләнгән иң әһәмиятле әдәби-драматик тапшыруларның бөтенесе диярлек турыдан-туры аның катнашы белән әзерләнгән.

## Тормышның үзендәгечә

Телеспектакль һәм күп серияле телевизион постановкалардан тыш, язучы һәм телевидение арасындагы бәйләнешләрнең шундый ук зур әһәмияткә ия булган бүтән формалары да бар. Шуларның берсе — язучы публицистикасы. Тамашачы экранда үзенең яраткан язучысын күрергә, тормыш проблемалары, әдәбият һәм сәнгатьнең актуаль мәсьәләләре буенча аның фикерен белергә тели.

Безнең язучылар халык белән очрашуның мондый формасын кире кагалар яисә баялап бетермиләр дип булмый. Бигрәк тә тормышның, заманның йөрәк тибешен тоеп яшәгән, шул уңайдан әйтер сүзе булган язучылар телевидениедән еш һәм бик рәхәтләнеп чыгыш ясыйлар. С. Хәким, Г. Ахунов, Т. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Миңнуллин, Р. Харис, М. Зарипов, Г. Паушкин, Д. Вәлиев, Р. Кутуй, Ш. Рәкыйпов, С. Радзиевская... Бу исемлекне тагын да бераз дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Соңгы елллардагы телевизион программаларны анализлаганда, телевидение белән азмы-күпме элемтә тотучы язучылар саны егермеләп җыела. Беренче карашка аз түгел кебек. Күп кенә өлкәләрдәге студияләр мондый сан турында хыяллана гына алалар. Әмма ләкин безнең иҗат союзындагы членнар саны 200 гә җитеп килгәндә, бу әллә ни күп тә түгел. Ун язучының берсе генә телевидениегә мөнәсәбәтле булып чыга лабаса! Бигрәк тә алар арасында яшь язучыларның бик сирәк очравы борчуга сала. Телевидение — яшь сәнгать, гаять зур темплар белән үссә дә, әле ул асылда беренче адымнарын гына атлый. Бу хәл инде нәкъ менә яшьләргә, кем әйтмешли, мач килеп тора!

Дөрес, кулына каләм тота белгән теләсә кемнең телевидение рухына туры килеп тә бетмәве бар. Моны истән чыгарырга ярамый. Телевидениедә чыгыш ясау өчен гадәттән тыш җыйнаклык, зиһенне, фикерне бергә туплап, иркен, табигый итеп сөйли белү кирәк. Радиода әле алдан әзерләнгән текстны шытырдатып укып чыксаң да була — беркем дә моны күрми (гәрчә кәгазьдән уку барыбер сизелеп торса да), ә экрандагы кеше — уч төбендәге кебек. Анда темага битарафлыгыңны да, фикерләү дәрәҗәң түбән булуын да яшереп кала алмыйсың. Чыгыш ясаучы югары эрудицияле, үз-үзенә һәм үз сүзенә тирән ышанган, тамашачыны сөйкемлелеге белән дә җәлеп итә торган кеше булырга тиеш.

Художестволы программалар буенча баш редактор булып эшләгән дәвердә бер чиктән икенче чиккә ташлануның төрле рәвешләрен күрдем мин.

Аларның берсе — язучыны үгетләп торырга да кирәк булмаган чак. Ул студиягә бик теләп килә һәм вәкарь белән генә, лекция яки вәгазь укыгандагы кебек, озын итеп, күңелсез итеп сөйләп чыга. Әлеге язучы телевидениенең нечкәлекләрен белми, һәр чыгышның эчке драматургиясе булуын, андагы образлылык, хис-дәрт зарурияттен аңларга теләми. Шунлыктан, аның өчен бу очрашу соңгысы булырга да мөмкин.

Икенче төрле язучылар да бар. Алар телевидение кыенлыкларын артык зурайтып, «бүкәй»гә охшатып күрәләр, ә үз мөмкинлекләрен бик түбән бәялиләр. Заманында берничә ел буе Әмирхан ага Еникины тамашачылар күзенә күренергә димләп йөргән идем. Юк, сүзем үтмәде. Безнең телевидение тамашачылары Нәкый Исәнбәт, Нурихан Фәттах, Шәриф Хөсәенов кебек яраткан язучыларын да йөзгә танып белмиләр диярлек. Мондый тыйнаклыкны аңлап була. Ләкин аклап булмый. Ниндидер уңайдан карыйсың — тегеяки бу язучының сурәтен теркәгән материаллар бөтенләй юк булып чыга. Габдрахман Әпсәләмов, Гариф Галиев, Шәйхи Маннур китаплары укучыларның яңа буыннарын җәлеп итеп яши, ә аларның — арабыздан әле кайчан гына киткән язучыларыбызның — тере сурәтен телевизор экранында без инде күрә алмыйбыз. Танылган язучылар катнашында булган тапшыруларны киләчәк өчен саклау, аларның алтын фондын булдыру турында уйларга вакыт.

Язучының телевидениедә катнашу мөмкинлекләреннән янә берсе — укучылар белән очрашу кичәсеннән язып алынган тапшырулар. Останкинодагы концерт студиясендә танылган әдәбият һәм сәнгать әһелләре белән иҗади очрашуларны тамашачы ничек яратып кабул итә! Һәр очрашуны күп миллионлы аудитория карый. Тамашачы өчен мондый тапшыру вакыйгаларның күз алдында баруы, көтелмәгәнчә үсеш алуы белән кызыклы. Язучы үз әсәрен укып яисә аның турында сөйләп кенә калмый. Ул залдан килгән төрле сорауларга җавап та бирә. Без аның четерекле сорау алдында тәртелебрәк торуын күрәбез, аннары үткен җавабын ишетәбез, тапкырлыгына, югалып калмавына сөенәбез. Мондый кичәләр өчен төп шарт — алдан һәммәсен дә «оештырып» куймау, бик яхшы итеп, нечкәләп әзерләнгән тәкъдирдә дә чәчәнлеккә, җанлы сүзгә, зирәк фикергә киң урын калдыру.

Безнең телевидение дә язучылар белән очрашулардан берничә кызыклы тапшыру күрсәтте. Татар дәүләт академия театрында булып узган Сибгат Хәким кичәсе бигрәк тә уңышлы булып чыкты. Анда сүз, шигырь, җыр, музыка бер-берсенә үрелеп барды. Укучы, үзенең яраткан шагыйрен якыннан күрү, тыңлау нәтиҗәсендә, аның иҗатын тирәнрәк тою мөмкинлегенә иреште. Мөхәммәт Мәһдиев, Миркасыйм Госманов, Вакыйф Нуруллин, Гәрәй Рәхим, Нәби Дәүли һ. б. язучылар белән очрашулар да истә калды. Кызганычка каршы, мондый кичәләр әле безнең телевидениедә гадәткә әверелеп җитмәгән. Алар әллә нигә бер үткәрелә, өстәвенә язучының юбилеена да бәгышланса, һичнинди хаҗәте булмаган купшылык белән аерылып тора башлый. Безгә дә, үзәк телевидение үрнәгендә, әлеге кичәләрне әдәби театр рәвешендә оештырырга вакыт. Моңа Татарстан Язучылар союзын, әдәбиятны пропагандалау бюросын, китап сөючеләр җәмгыятен һәм шул юнәлештә эшләүче башка оешмаларны да җәлеп итәргә кирәк.

Гамәлдә расланганча, вакыйга барган урыннан трансляцияләү, студиянең үзендә оештырылган тапшыруга караганда, күпкә зуррак кызыксыну уята. Күрәсең, төп хикмәт — вакыйганың «күз алдында» баруы, тамашачыга үзе дә шунда катнашкан кебек хис итәргә мөмкинлек бирелүе белән бәйледер. Әз генә ясалмалык, фальшь сизелдеме — шунда ук кызыксыну сүрелә, эффект кими.

Үткән елның 7 сентябрендә, мәсәлән, Бауман урамындагы китап кибетеннән ярыйсы гына тапшыру оештырылган иде. Тәнкыйтьче Фоат Галимуллин нәшрият чыгарган яңа китаплар турында сөйләде, аларны тамашачыга күрсәтте. Шунда ук сатып алучылар кайнаша, гадәти китап сәүдәсе дәвам итә иде. Болар барысы да табигый һәм ышандырырлык булып барды. Ләкин, әһәмиятсез генә булып тоелса да, үкенечле бер хата тапшыруны бозып ташлады. Вакыйф Нуруллин китабына килеп җиткәч, тәнкыйтьче болай гына тирәягына карап алган булды да гаҗәпләнүдән кычкырып җибәрде: янәсе, бәрәч, бу китапның авторы да монда икән ләбаса! Әйтегез әле, зинһар... Билгеле, мондый кыланмыш телевизор караучыларның шаркылдап көлүенә һәм усал репликаларына гына лаек булды. Тамашачы җүләр түгел, нәшриятның баш редакторы нәкъ шул вакытта китап кибетендә чуалып йөридер дип аны ышандыра алмыйсың. Баш редакторны әлеге тапшыруга махсус чакырдык дип әйтсәң, намуслырак та, җиңелрәк тә булган булыр иде.

## Яңа формалар эзләргә

Казан телевидениесеннән әдәби тапшыру барганда, тамашачыларның түземсезләнеп, кызыклырак нәрсә эзләп, бүтән программаларны боргалауларын әрнеп күзәтеп торган чакларым күп. Моның өчен тамашачыны гына гаепләү дә кыен: безнең әдәби тапшырулар, чыннан да, нигәдер шактый күңелсез һәм гаҗәп бертөсле килеп чыга. Лирик музыка фонында туган як күренешләре сурәтләнгән кинокадрлардан башланып китәр ул, аннары язучының тормышы һәм иҗаты турында сөйләү белән аның әсәрләреннән өзекләр уку чиратлашып барыр... Кайвакыт тапшыруда күбрәк кеше катнашыр, әсәр рольләргә бүлеп укылыр, ләкин аңа карап кына эшнең асылы үзгәрми.

Бу бертөрлелектән ничек котылырга? Монда ниндидер әзер рецепт язып бирү кыен, һәм андый рецепт, күрәсең, юктыр да. Инде әйтелгәнчә, телевидение — сәнгатьнең яңа бер төре, ә сәнгатьтә гомумән һәр юлны яңабаштан эзләргә туры килә. Сәнгать шаблон белән сыеша алмый.

Әйтик, бездә әле тамашачыны дулкынландыра торган мәсьәләләр буенча язучы белән актуаль интервью формасы җитәрлек файдаланылмый. Диспутлар һәм бәхәсләр бик сирәк оештырыла. Мин, әлбәттә, студиядә утыручыларның барысы да бер балык башын чәйнәгән ясалма «бәхәсләр»не түгел, ә чыннан да кызыклы гына фикерләр, үзенчәлекле позицияләр бәрелешеннән гыйбарәт, тамашачыны да битараф калдырмый торган тапшыруларны күздә тотам.

Үзәк телевидение тәҗрибәсеннән күренгәнчә, тамашачы аерым бер рубрикаларга күнегә, аларны көтеп ала башлый. Әлеге рубрикаларның ярты уңышы алып баручыдан тора. Мәсәлән, «Киносәяхәтләр клубы», «Кинопанорама», «Хайваннар дөньясында», «Ап-ачык һәм акылга сыймаслык» кебек тапшырулар әнә шундый.

Бездә үзләре яхшы чыгыш ясау гына түгел, тапшыруны әйбәт итеп алып бару осталыгы да булган язучылар шактый. Шагыйрь Роберт Миңнуллин, әнә, берничә ел дәвамында балалар өчен бик кызыклы «Шигъри тәлгәшләр» рубрикасын алып барды. Бу рубрика бигрәк тә яшьләр арасында татар шигъриятен пропагандалауга күркәм өлеш кертте. Заманында Казанның Актерлар йортында яшь язучылар, артистлар, композиторлар катнашында кызыклы гына иҗат кичәләре уздырыла иде. Ул кичәләрнең җаны, алыштыргысыз сценаристы, режиссеры һәм алып баручысы Роберт Батулла булды. Нигә әле шундый матур традицияне телевидение экраннарында дәвам итмәскә? Батулла димәктән, ул аеруча соңгы елларда юмористик миниатюралар остасы буларак танылып өлгерде. Телевидениедә лирик һәм сатирик миниатюра театрын, бик күп сүзләргә сәбәпче булган «бер актер театры»н нәкъ менә ул башлап җибәрә һәм җитәкли алыр иде кебек.

Телевидениедән чыгыш ясау сәнгате — сирәк очрый торган сәләт. Үз вакытында телевидениедән «Соня әби хикәятләре»н укып килгән София Радзиевская балалар арасында искиткеч популярлык казанган иде. Язучы Шамил Рәкыйповның билгесез каһарманнарны эзләүгә багышланган тапшырулар циклы да киң яңгыраш алды. Төрле сәбәпләр аркасында бу язучылар телевидениедән читләштеләр. Ә аларга лаеклы алмаш хәзергә кадәр юк.

## Телевизион тәнкыйть ... Кайда ул?

Ниһаять, тагын бер, күптән өлгергән проблема — бүгенге телевизион тәнкыйтьнең торышы. Чынлыкта, сүз аның торышы хакында да түгел, ә бөтенләй диярлек булмавы турында бара.

Сәер хәл түгелмени: берничә мең данә булып чыккан шигырь китабына икешәр-өчәр рецензия басылгалый. Берничә йөз генә кеше карап өлгергән спектакль тәфсилле анализга, бәягә лаек була. Ә «тамаша залында» йөз меңләгән кеше утырган телевизион тапшыруларның бик күбесеннән матбугатта берннди дә эз калмый. Моны бары тик начар гадәт дип кенә аңлатып була.

Әдәбият һәм сәнгатьнең үсешендә тәнкыйть тоткан урынны яхшы беләбез. КПСС Үзәк Комитетының 1972 елгы мәгълүм Карарында да, партиябезнең XXVII съездына КПСС Үзәк Комитетының Политик докладында да тәнкыйтьнең әйдәүче роленә һәм җаваплылыгына басым ясап күрсәтелде. Телевидение кебек яшь сәнгатькә аның йогынтысы тагын да зуррак булырга тиеш. Бу, бер яктан, телевидение хезмәткәрләренең осталыгы үсүгә ярдәм итәр, таләпчәнлекнең артуына китерер иде. Икенче яктан, телевизион тәнкыйть — тамашачылар өчен чын сәнгатьне танырга, аның идея асылын һәм үзәк фикерен тирәнрәк аңларга өйрәнү мәктәбе дә ул.

Кыскасы, тәнкыйтьнең «кирәкле шәй» булуын аңламаучы, шик астына алучы табылмастыр. Ләкин кирәклекне тану гына җитми. Беренчедән, безнең матбугат органнарының телевидениегә йөз белән борылуы сорала. Телевизион сәнгатьнең игътибарга лаеклы әсәрләренә тиешле бәя икенче көнне үк булмаса да, өченче-дүртенче көнне инде матбугатта күренсен иде. Моңа ирешергә кирәк. Сәнгатьнең оператив төре буларак, телевидение

тәнкыйтьтән дә шундый ук өлгерлек таләп итә. «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Вечерняя Казань», яшьләр һәм балалар газеталары битләрендә, «Литературная газета» үрнәгендә, даими айлык телевизион күзәтүләрне гадәткә кертәсе иде. Булачак телеспектакльләргә рәсемле анонслар бирү, тамашачыларның хатларын һәм фикерләрен әледән-әле бастырып тору да файдалы булачак.

Мәсьәләнең икенче ягы — телевизион рецензентлар әзерләү. Бу өлкәдә эшләүче тәнкыйтьчедән телевидение сәнгатенең үзенчәлекләрен яхшы белү, режиссура, монтаж кебек хасиятләрен тирәнтен аңлау таләп ителә. Казан дәүләт университетының журналистика кафедрасы әлеге эштә үз өлешен кертә алыр иде. Татарстан Язучылар союзының тәнкыйть секциясендә дә телевидение тәнкыйтьләренә махсус игътибар бирергә вакыт.

Партиябезнең XXVII съезды культура, тәрбия һәм пропаганда өлкәсендә сәнгатьнең барлык төрләре алдына җитди бурычлар куйды. Телевидение безнең көнкүрешнең гадәти бер күренеше генә түгел. Ул — үсәннән-үсә, яңа формалар таба баручы сәнгать. Әле менә соңгы елларда гына телевизор экраннарында, аның сурәт һәм образ мөмкинлекләрен баетып, салават күпере төсләре уйный башлады. Язып алу хикмәтләре уңышлы тапшыруларны кабатлап күрсәтергә, телевизион постановкалар хәзинәсе булдырырга мөмкинлек бирде. Бик якын киләчәктә видеомагнитофоннар гадәти күренешкә әверелеп, үзеңә охшаган тапшыруны теләсә нинди вакытта «әйләндереп» карау җае булачак. Күләмле телевидение өлкәсендәге экспериментлар алып барыла. Гаять зур экранлы телевизорлар эшләнә. Безгә, язучыларга, мондый яңалыклардан хәбәрдар булырга кирәк. Гомумән, заманнан артта калмыйк дисәк, без барыбыз да сәнгатьнең бу яңа, чын мәгънәсендә массовый төренә йөз белән борылырга тиешбез.

# КИЛӘЧӘК БҮГЕН БАШЛАНА

ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕ — ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫ, ЖДАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗНЫҢ АЛДЫНГЫ КОМБАЙНЧЫСЫ, КОММУНИСТИК ХЕЗМӘТ УДАРНИГЫ **ГАБДЕЛХАК ТӨХВӘТОВ** БЕЛӘН ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬЧЕ **МАНСУР ВӘЛИЕВ** ӘҢГӘМӘСЕ.

— Мин — татар әдәбиятының гап-гади бер укучысы. Басылып чыккан һәммә әсәрне укып барам дип әйтә алмыйм, әмма үземне кызыксындырган әдипләр иҗатын игътибар белән күзәтәм. Белгәнегезчә, андыйлар бездә байтак. Өлкән буын әдипләр Гомәр ага Бәширов, Әмирхан ага Еники, Сибгат ага Хәким, Нури ага Арсланов, Нәби ага Дәүли һ. б. лар, әсәр арты әсәр иҗат итеп, укучыларны куандыралар. Шулай ук урта буын язучылар да безгә бик еш шатлык китерәләр. Исемнәре соңгы елларда гына күренә башлаган яшьләр арасында да хәтергә кереп калган каләм ияләре бар.

Әнә шуңа күрә без бөтен гаиләбез белән «Казан утлары» журналын да, «Азат хатын» белән «Ялкын»ны да көтеп алабыз. Күп кенә әсәрләрне кычкырып та укыйбыз. Китапханәгә килгән яңа җыентыкларны да укырга тырышабыз.

Әдәбиятыбызның их яхшы әсәрләре безгә зур ләззәт бирә. Алай гына да түгел, аларны укыгач, ничектер, дөнья киңәеп киткәндәй тоела. Зур дөнья борчулары белән очрашасың — күңел күзе күбрәк күрә башлый, игътибарлырак буласың... Чын әдәбиятның әнә шундый серле көче бар бит аның...

Ә уңышсыз килеп чыккан әсәрләр бик тә борчый мине. Андый повесть-хикәяләрне укып чыга алсам (ә моның өчен, үзегез беләсез, бик зур түземлек кирәк!), иң башта аны язучы кешенең үзе белән очрашып, ачыктан-ачык сөйләшәсем килә. Аның үз әсәрендә тормышны нилектән шулай үтә беркатлы, җиңел һәм артык гадиләштереп сурәтләвенең чын сәбәпләрен беләсем килә. Әнә шул хикмәтне аңлыйсы килә... Бүгенге кайнап торган дөньяда яшәп, нихәтле күңел тетрәнүләре янәшәсендә йөреп тә, битараф рухта язу шактый гаҗәпләндерә мине...

Инде хәзер Сезнең, тәнкыйтьче кешенең дә, бу хакта фикерләрен беләсе килә. Татар совет әдәбиятының бүген, безнең көннәрдә яки соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре Сезне нинди кичерешләргә баеталар? Үзләре хакында ниндирәк уйлар тудыралар?

— Бик дөрес әйтеп үттегез — Сезнең кебек укучылар безнең әдәбиятның бүгенге торышы һәм киләчәктәге үсеше өчен җаваплылыкны үзләрендә язучылардан бер дә ким сизмиләр... Татар әдәбиятының мондый укучысы булу — бик күңелле хәл. Әдәбиятны үстерү өчен иң кирәкле шартларның берсе ул. Сезнең чын сәнгать әсәрләрен ничек

шатланып укуыгыз, ә бик үк уңышлы килеп чыкмаган әсәрләргә борчылуыгыз, гаҗәпләнүегез дә бик аңлашыла. Чынлап та, алар — күпләргә хас уй-кичерешләр, тәэсирләр.

Татар совет әдәбиятының бүгенгесе турында минем фикерләргә килсәк, аларны кыска гына итеп әйтеп бирү шактый кыен. Ни өчен кыен? Чөнки, үзегез беләсез, безнең татар әдәбияты да, башка әдәбиятлар кебек үк күп кенә жанрларга бүленә. Бүгенге көндә ул жанрларның һәрберсендә дистәләгән язучы актив иҗат эше белән шөгыльләнә. Димәк, алар татар совет әдәбияты дигән зур рухи байлыкка килеп өстәләчәк яңа әсәрләр язалар дигән сүз. Хәзер без, татар әдәбиятының бүгенге хәленә тулы һәм объектив бәя бирергә теләсәк, аларның һәрберсенең иҗатын искә алып фикер йөртергә тиеш булачакбыз. Сафында ике йөзгә якын Язучылар союзы әгъзасы һәм шуның өстенә тагын байтак кына яшь язучысы булган зур әдәбият хакында, әлбәттә, тиз генә ниндидер бер гомум фикер әйтергә ашыгырга ярамый. Шуның өчен, бәлки, соңгы елларда безне өметләндергән кайбер кызыклы эзләнүләр, юнәлешләр, омтылышлар турында сөйләшү урынлырак булыр? Әдәби жанрларның да барысын иңләп алу мөмкин түгелгә күрә, бәлки, нигездә проза әсәрләрен генә күздә тотып фикер йөртербез?

Ә проза өлкәсендәге байтак эзләнүләр һәм шулар нәтиҗәсе буларак туган күп әдәби күренешләр һәрвакыт чынлыкны ничек сурәтләүгә килеп бәйләнәләр... Безнең язучылар — алар, әлбәттә, социалистик реализм ысулы белән иҗат итүчеләр, тормышны шул таләпләрдән чыгып сурәтләргә тырышалар. Ләкин бу язучыларның иҗат практикасында ничек, ни дәрәҗәдә чынга аша соң?

Әдәбият белеме китапларында шактый төгәл һәм ачык әйтелгән билгеләмәләрне искә төшерик. Мәсәлән, типик характерларны типик шартларга куеп сурәтләү реализмның нигезен тәшкил итсә, социалистик реализм исә тагын тормышның революцион үсештә, үзгәрештә аңлануын һәм тасвирлануын сорый. Ләкин, без бирегә, әлеге билгеләмәләрне искә төшерү белән үк, шунысын да онытмаска тиешбез: алар — иҗат өчен, конкрет әсәр туу өчен нигез генә. Белгәнебезчә, бер үк нигездә төрле кыяфәттәге, сыйфаттагы корылма салып була. Анысы күп вакытта төзүченең тәҗрибәсеннән, осталыгыннан, тырышлыгыннан тора.

Мөгаен, әдәби иҗатта да шулайдыр.

Шуңа күрә безгә дә бүгенге иҗат процессы турында сөйләшкәндә, хәзер эчтәрәк яткан серләр хакында күбрәк уйланырга, шуннан чыгып күзәтүләр ясарга кирәк. Аерым алганда, минем менә мондый бер нәрсәгә игътибар юнәлтәсем килә. Әйткәнемчә, ул әлеге дә баягы чынлыкны аңлауга бәйләнгән.

Әдәби әсәрләрдә без нәкъ тормыштагыча тасвирланган һәм тормышчан булган геройларны, характерларны еш кына очратабыз. Алар төрле-төрле вакыйгаларда катнашалар, күп санлы эшләр башкаралар — һәрхәлдә укучыны ышандырырлык итеп яшиләр. Ләкин кайвакытта, тыштан караганда бик актив кебек күренгән хәрәкәт, тормыш барышы ахыр чиктә укучы өчен кызыклы һәм яңа мәгънә китереп чыгармый, «нуль нәтиҗә» белән бетә. Ә без анда типик тормыш һәм типик характерлар юк дип әйтә алмыйбыз. Шулай булгач, эш нәрсәдә соң?

Мондый очракта, мөгаен, тормышның сәнгать биеклегенә күтәрелеп сурәтләнүе җитмидер. Сәнгать биеклегенә күтәрелгән — димәк, көчәйгәнрәк, тулыланганрак, тирәнәйгәнрәк яшәү җитмидер анда.

— Әйе шул, без күңелебез белән бик тә тансыклаган, чын сәнгать көченә ия булган реалистик әсәрне язучы кеше,— ул бит әле тормышны һәм телне һичшиксез яхшы белү өстенә тагын шунысына да ирешә — тормыштагы яңа көчләрне һәм яңа мөнәсәбәтләрне табып алып, үз әсәрләрендә аларның асыл табигатьләрен ачып бирә. Андый әсәрләрдә без үзебезне күге биегрәк, офыклары киңрәк икенче дөньяга килеп кергәндәй тоябыз.

Тик менә бу сыйфатлар киләчәктә нинди нигездә һәм кемнәр, нинди реаль көчләр хисабына чынга ашар соң?

— Кеше күңеле туктаусыз үсә, яңа биеклеккә күтәрелә барганга һәм аның рухи ихтыяҗлары да югарырак дәрәҗәдә булганга күрә, укучыны тулысынча канәгатьләндерә алу беркайчан да мөмкин түгелдер дип уйлыйм. Ихтыяҗлар, таләпләр тормышның һәрбер өлкәсендә чынлыкка караганда кызурак тизлек белән үсә бара һәм шушы таләпләрне канәгатьләндерергә омтылу һәр тармакның алга барышын хасил итә бит. Әдәбият өлкәсендә дә шулай: халыкның, укучыларның җан таләпләре, рухи ихтыяҗы гел алдарак яши, әдәбиятны даими рәвештә үсешкә, хәрәкәткә өндәп тора.

Бу күренештән Сезнең сорауга җавап та табарга мөмкин. Сез бераз гадиләштереп әйткәндә, әдәбиятның сыйфат ягыннан үсеше нәрсә хисабына, нинди көчләр нәтиҗәсендә килеп чыгар дип сорыйсыз. Югарыда без аңа берникадәр җавап бирдек тә. Ягъни тормышның үзендә, рухи яшәү дәрәҗәсенең үсүе нәтиҗәсендә, киләчәктә әдәбиятны алгарак этәрәчәк яңа иҗат көчләре тәрбияләнә. Алар, чынбарлыкта булган яшь көчләр, әкрен-әкрен булса да, әлбәттә, зур әдәбиятка да килмичә калмыйлар. Бигрәк тә безнең чорда, әдәбият турында халык һәм партия кайгыртуы аеруча көчәйгән заманда.

Биредә инде үзебезнең иҗат чынбарлыгын мисалга китереп үтмичә һич мөмкин түгел. Җитмешенче еллар татар совет әдәбиятына яңа иҗатчыларның ничек мул килүен ачык күрсәтте. Хәзер, сиксәненче елларда исә, актив эшкә тотынган, якын елларда зур гына әсәрләр тудырырга сәләтле яшьләрне һәр жанрда да күп күрәбез. Төп тармакта — проза һәм шигърият өлкәсендә алар, минемчә, бигрәк тә өметле.

Билгеле, әдәбиятның сыйфат ягыннан үсеше яшь, яңа язучылар хисабына гына бара дияргә җыенмыйм. Чынбарлыкта ул һичкайчан да алай гына була алмый. Чөнки, үзегез әйткәнчә, өлкән яшьтәге әдипләр дә, урта буын язучылар да — әгәр алар тынгысыз рухи тормыштан аерылмаган икән — иҗатларын туктаусыз үстерә, әсәрләрнең тормыш һәм сәнгать көчен арттыра киләләр. Мәсәлән, бүген өлкән яшьтәге прозаиклар һәм шагыйрьләребез арасында урта буынны, яшьләрне сокландырырдай иҗат утында янып яшәгән, картаймаган йөрәкле әдипләр күпме! Алар булу — татар әдәбияты өчен һәм, гомумән, укучылар, халык өчен зур бәхет!

— Сез әдәби үсешнең гомумирәк күренешләре турында сөйләп киттегез. Ул фикерләрнең дөреслегенә, әлбәттә, ышанабыз. Ләкин безне кайбер конкретрак нәрсәләр борчый. Шулардан берсе. Алдарак Сез: «Соңгы еллар татар совет әдәбиятында югары сәнгатьлелеккә, фәлсәфилеккә таба көчле омтылыш сизелә», — дидегез. Ә без, укучылар, менә шундый дәрәҗәдән шактый ерак торган китаплар белән, язучылар тарафыннан иҗат ителгән бүтәнчәрәк әсәрләр белән ел саен әллә ничә мәртәбә очрашабыз. Ничектер, әдәбиятның без уйлаган һәм көткән дәрәҗәсе аның чынлыктагы халәтеннән шактый аерыла түгелме?

— Минемчә, Сезнең бу күзәтүегез дөрес. Чынлап та, безнең укучыга андый әсәрләр әле шактый еш эләгә. Шул ук вакытта без язучыларыбыз иҗатындагы куанычлы үзгәрешләр турында да сүз алып барабыз. Бу ике күренеш чынбарлыкта ничек сыеша соң?

Аларны дөрес аңлау өчен, без бер нәрсәгә игътибар итәргә тиештер. Югары сәнгатьлелеккә, фәлсәфилеккә көчле омтылыш дигәндә, әле әдәбияттагы реаль чынбарлык үзе түгел, хасил булган җирлек, туфрак түгел — ә аларның әсәрләрдә күренгән чалымнары, беренче билгеләре тел төбендә ята. Ягъни югары сәнгать кануннары күп әсәрләрдә тулысынча хакимлек итми әле, алар үзләренә торган саен таләпчәнрәк тавыш белән хокук кына даулый баралар. Сәнгатьлелек һәм фәлсәфилек кануннары әсәрләрдә үзләренә тулы, иркен яшәү таләп итәләр. Алар инде еш кына очракларда иҗади дөньяларның (аерым язучыларның) юнәлеш бирүче маякларына әйләнеп баралар.

Ләкин андый маяклар һәм таләпләр булу — бер нәрсә, ә җанлы иҗади чынбарлык икенче әйбер бит ул. Анда барысы да әлеге таләпләргә туры килеп бетмәскә бик мөмкин. Тик якындагы билгеле бер баскычта югары сәнгатьлелек һәм фәлсәфилек таләбе инде күпләр өчен уртак ихтыяҗга әйләнәчәк. Алдарак без әнә шундый таләпләрне күздә тоткан идек.

Бүген без югары сәнгатьлелекне иң кирәкле һәм иң җитешмәгән нәрсә дип саныйбыз. Әмма акыл белән ирешелгән бу дәрәҗәгә чынлыкта ирешү өчен шактый гына вакыт кирәк. Һәм иң мөһиме — иҗат көчләренең әлеге биеклеккә чынлыкта күтәрелеп җитә алулары кирәк.

— Хәзер Сезгә бирелəчәк соравым алдагысының дәвамы бугай. Алар икесе дә безнең татар әдәбиятының һәм, гомумән, әдәбиятның бүгенге торышына карыйлар, икесе дә соңгы вакытта мине бик еш уйландыра торган сораулар. Ә мәсьәләнең төбе шул: менә без әле генә әдәбиятның үсүе хакында сөйләдек. «Тормышта әдәбиятның роле үсә бара»,— дигән сүзләрне дә еш ишетәбез. Ә Сез чынбарлыкта бу сүзләргә каршы килә торган кайбер үзгәрешләр күрмисезме? Мәсәлән, экономик яктан алга киткән күп кенә илләрдә әдәбиятка булган игътибарның сизелерлек дәрәҗәдә кимүе, халык тормышында кино һәм телевидениенең күбрәк урын ала баруы күзәтелә түгелме? Сез моңа ничегрәк карыйсыз?

— Юк, мин биредә «Әдәбиятның тормыштагы роле үсә» дигән фикерне юкка чыгара алырдай принципиаль каршылык күрмим. Чөнки, әдәбиятның үсүе һәм шуңа бәйле рәвештә кеше тормышында әһәмияте арту турында сүз барганда һич тә сан күрсәткечләре генә күз алдында тотылмый. Бусы — бер. Икенчедән, әгәр халыкның күпмедер өлеше китап укуны ташлап, телевизор каршында утыра, спорт уеннары карарга чаба башлаган икән, бу — әдәбияттан җиңелчә кызык тапкан укучы китә дигән сүз. Югары сәнгать көченә ия әсәр белән ялгызың гына, бергә-бер генә калуның һич нәрсәгә алыштыра алмаслык бәхетен белмәгән, аңламаган кеше китә дигән сүз.

— Алайса, әдәбият чагыштырмача таррак даирә кешеләр өчен генә булып кала түгелме соң? Бу очракта аның роле үсүне ничек итеп аңларга?

— Шуңа күрә мин фикеремне «биредә сан күрсәткечләре генә хәл итми» дип башлаган идем дә. Әлбәттә, сыйфат ягын күз алдында тотып, әдәби әсәрләрнең тәэсир көчен уйлап.

Югары сәнгатьле әсәрләрнең кеше тормышындагы роле үсә. Чөнки халыкның эчке дөньясындагы уй-кичерешләр хәрәкәте активлаша, күңел, рух яшәеше киеренкеләнә.

гомумән, рухның реаль тормыштагы көче үсә, әһәмияте нык арта бара. Аны аңларга, рухның бөтен хасиятләренә төшенергә теләү дә үсә. Әдәбият-сәнгать — бу мәсьәләдә кешегә ярдәм итәрдәй бердәнбер чыганак.

Кешенең рухи яктан, күңел үсешен дөрес алып баруны — әдәбият-сәнгать үзенең иң изге вазифасы дип саный. Тормышта очраган төрле борылышларда кешегә дөрес юнәлеш табарга булышу, иң ышанычлы юлын югалтмый калырга һәм алга таба барып, шәхесне көчәйтәчәк, матурайтачак яңа биеклекләрне яуларга ярдәм итү. Кешелекнең дөрес, чын иманын тормышның төрле чорларында, рухка бик авыр туры килгән вакытларда да саклап һәм яшәтеп кала алу... Менә шушы олы, изге вазифаны үтәү әдәбият-сәнгатьнең генә көченнән килә. Хәзер, безнең чорда, әдәбиятның роле үсү иң башта әнә шул мактаулы вазифаны үтәү белән бәйләнгән.

Акыл көче арту, фән һәм техника үсү аркасында бүген кешелек үзенә бик зур мөмкинлекләр алды. Бүгенге кеше — көчле, ул бик күп нәрсәләр эшли ала. Ләкин әнә шул бик көчле кеше, акыл гына сизә алмаган ниндидер бер адымны ясаганнан соң, үзенең гасырлар буенча ныгып, үсеп килгән кешелек үзәген сындырырга мөмкин. Минемчә, кешенең мөмкинлекләре, көче арту белән бергә аның кешелеген югалту, юлдан язу, үзенең һәлакәтенә очрау (мин биредә аерым кеше, бер шәхес турында гына түгел, ә гомумән кешеләр турында, гомумән кеше хакында әйтергә телим) ихтималы да үсә бара. Шушындый чорларда әдәбият кеше күрәчәк иртәгесе көнне, басылачак яңа баскычны алдан сиземләтә. Ул кеше инде килеп җиткән, менә-менә аяк басарга тиешле тормышның, якын киләчәкнең төп диалектикасын тоярга һәм андагы дөрес юлны чамаларга булыша. Әдәбият аркасында кеше күңеле чынбарлыктагы тормышны бераз узыбрак, киләчәкнең эченә керебрәк яши ала...

Менә шушы зур вазифаны торган саен тулырак үти бару, минемчә, тормышта әдәбиятның роле үсүне китереп чыгара. Икенче яктан карaганда, бу күренеш әдәбиятның үз асылына тагын да якыная төшүе, үзеннән көтелгән «эш»не күбрәк башкаруы дигән сүздер.

— Сезнең әле генә әйткән фикерләрегез безнең татар әдәбиятына турыдан-туры кагыла — шулай бит? Ә мәсьәләне конкретлаштырып карасак, соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләр безнең халык тормышы өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле? Ягъни, югарыда сөйләнгән сүзләрне үз мисалыбызда ничегрәк расларбыз икән?

— Минемчә, бу уңайдан һич икеләнми мисалга китерердәй әсәрләр безнең әдәбиятта байтак. Халыкның иң тирән күңел яшәеше хакында сүз чыкканда, аның әдәбиятта ничек чагылуын күзәткәндә, соңгы елларда без һәрвакыт диярлек Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники әсәрләрен телгә алабыз. Ә бу бит — әдәбиятның иң мөһим юнәлеше дигән сүз. Шушы юл белән язучылар безне тормыштагы бик олы күренешләр эченә алып керә, аларны укучы күңеленә нечкә җепләр аша китереп тоташтыра. Аңларга, төшенергә ярдәм итә. Алар күп нәрсәне өр-яңадан ача дисәк тә була. Тормыштагы байтак күренешләргә карата безнең күңел күзебезне ача.

Менә Ә. Еникинең онытылмас әсәрләреннән берсен — «Тынычлану» хикәясен алыйк. Анда безнең бүгенге яшәвебез өчен никадәр мөһим булган мәсьәлә үзәккә алына! Зур вакыйгалар, олы эшләр белән шаулап торган, актив һәм кызу хәрәкәтле замана тормышында — бер карауга бик матур һәм бар да үз урынында, дөрес сыман тоелган тормышта — кешеләргә күп изгелекләр эшләгән өлкән яшьтәге галим Гасыйм Сәләховичның ялгызлыкта үлеп китүе. Кешенең кадере китү. Шул хакта уйландыра торган аяныч хәл.

Әмирхан Еники безнең чор кешеләрен бу күренеш турында җитди уйланырга чакыра. Әйтерсең ул җан авазы белән: «Кеше кадәр кешенең дә кадере беткәч, тагын нәрсәнең генә әһәмияте кала соң?» — дип дәшә, безгә карап. Менә шундый сизгер җан авазы ачык булып ишетелгән әдәби әсәрләрне укучы ничек тиз генә онытa алсын да, бу аның үз тормышына нишләп тәэсир итмәсен ди!

Шулай ук Сез Атилла Расихның «Сынау» романын да укыгансыздыр дип уйлыйм. Анда замандашларыбызның гаилә тормышы тирән яктыртыла, шул нигездә шәхес өчен мөһим әхлак мәсьәләләре калкып чыга. Мәсәлән, кешенең тормыш алдында җаваплылыгы, үзен кеше иткән өлкәннәргә бурычлы булуы, кеше ясаган һәр адымнан әкренләп язмыш җыйналу, бер күренешнең икенчесенә бәйләнгән булуы... Романның бу мәсьәләләргә багышланган битләре укучыны һич тә битараф калдырмый, аның фикерен дә, күңелен дә активлаштыра. Димәк, әдәби әсәр шуның белән тормыштагы уңай якларны күбәйтергә, аларны көчлерәк итәргә булыша. Әдәби әсәрнең тормышка булган тәэсире дә шулай килеп чыга. Әлеге ике әсәр мисалында ук күргәнебезчә, татар әдәбияты соңгы елларда әхлак мәсьәләләре эченә кыю кереп һәм аларны тирән яктыртып, укучы каршында үз абруен нык кына үстерде.

Мисаллар эзләп, башка жанрларга мөрәҗәгать итсәк, андый әсәрләрне тагын да күбрәк күрербез. Драматургиядә, мәсәлән, Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» исемле әсәре, моннан ун ел элек иҗат ителсә дә, бик тә истә калды. Нәрсәсе белән?

Шулай ук үзәгендәге бик үткен мәсьәләсе, халык алдына куелган мөһим сораулары белән. Кешенең тормышта тоткан ныклы юлы — олы иманы булырга тиешлек, чамадан тыш җәйлашу башланса, аның югалуы, шәхеснең үзенең ваклануы, кечерәюе әлеге драмада шактый гыйбрәтле итеп сурәтләнә.

Поэзия әсәрләреннән Сибгат Хәкимнең «Күги» һәм «Кырыгынчы бүлмә» поэмалары ялкынлы пафосы, укучының йөрәгенә көчеп янучы уты белән истә калган. Соңгысы бөек Тукай турында булганга гына түгел, ә, гомумән, кешенең чын олылыгы ничек, каян башлану хакында булганга — теле үткәнне сөйләсә дә, шагыйрьнең күңел күзе бүгенгене, безнең замандашларыбызны күреп, күзәтеп барганга күрә укучыга бик якын ул поэма.

Әдәбиятыбызның иң төп көчләре, безне сөендерә-сөендерә, замандашыбыз күңел дөньясының һаман эченәрәк керә баралар. Сезнең һәм безнең өметләрне тагын да тулырак аклау өчен тырышалар.

— Киләчәккә бик зур ышаныч яңгыраган Сезнең сүзләрегезгә мин тагын капма-каршы бер фикер өстәмәкче булам. Без иң уңышлы дип санаган әдәби әсәрнең бүгенге кешегә ни дәрәҗәдә тәэсир итә алуы, аның тарафыннан нихәтле үзләштерелүе уйландыра мине. Киңрәк алганда — әдәбиятның чын тормышка тәэсире. Менә әле генә Сез мисалга китергән, безнең әдәбиятның иң уңышлы дип саналган әсәрләрен алыйк. Шик юк, аларда кешегә бик кирәкле, бик мәгънәле фикерләр, файдалы эчтәлек була. Ләкин... ләкин мин бик күпләрнең чынбарлыкта ни рәвешле яшәгәннәрен, гомер иткәннәрен карап торам да — әнә шулай аерым-аерым кеше тормышларын искә төшерәм дә — үземнең әдәбият хакындагы кайбер фикерләремә шикләнеп тә куям. Без сокланып, һушыбыз китәрлек булып сөйләгән китаплар бериш кешеләргә яфрак селкенгән сыман да тоелмый түгелме соң? Мәсәлән, китапларны байтак кына күп җыйган бер танышым бар минем. Ул әсәрләрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең барысын да аңлап бара, бу яктан аны тиешле дәрәҗәдә тора дип әйтергә мөмкин. Әмма андый аңлаудан кемгә нинди файда? Бик тирән, бик ачынып язылган үтә яхшы китапларны укыганнан соң да, аның һәм аның кебек бүтән кешеләрнең яшәве элек ничек булса, шулай дәвам итеп кала.

Менә шушы сорауга мин ышанычлы җавап эзлим һәм, кызганычка каршы, әле аны табып җиткерә алганым юк. Бәлки бер мин генә дә түгелдер, бәлки башка бик күп әдәбият сөючеләр дә шулайдыр...

Ә Сез әлеге мәсьәләне ничек аңлыйсыз? Бәлки минем бу фикер дөрес түгелдер?

— Сезнең укучыларга (китергән мисалыгыздан күренгәнчә, бигрәк тә авыл укучысына) ышанып җитмәвегезнең төбендә нәрсә, нинди шикләнү ята икән? Әйе, соңгы вакытта, бигрәк тә алтмышынчы еллардан соң, илебез халкының материаль көнкүреше нык яхшырды. Хәзер бу күренеш авыл җирендә бигрәк тә ачык күзгә ташлана. Әлбәттә, тормышыбызның бай, җитеш булуы барыбызны да куандыра. Сез дә моңа каршы түгел, билгеле. Сизгәнемчә, Сезне тормышның бер ягы кызурак темпта яхшыру, шул сәбәпле икенче якның артталыгы борчый бугай. Ягъни рух, әхлак дәрәҗәсенең материаль як үсешеннән калышуы. Хәтерлисездер, бу хакта партиябез документларында да әйтеп үтелгән иде. Мондый тигезсезлек озак барса, мещанлык, милекчелек һәм башка шуныңише куркыныч күренешләр көчәю мөмкинлеге күрсәтелгән иде. Әлбәттә, мондый сүзләр юкка гына әйтелмәде. Әлеге без теләмәгән күренешләр тормышта еш очрый башланганга, замандашларыбыз көнкүрешенә үтеп кергәнгә, кисәтү сыман ишетелде алар. Кисәтү һәм шул ук вакытта аларга каршы кискен көрәш ачу өчен әйтелде ул сүзләр.

Сез ул күренешләрне татар әдәбияты әсәрләре белән бәйләнештә карарга тәкъдим итәсез. «Безнең иң уңышлы әсәрләребез андый кешеләргә берәр ничек тәэсир ясый аламы?» — дисез. Билгеле, әдәбиятның яшәү максатын югарыда без телгә алып үткән хәлләргә каршы көрәшүгә генә кайтарып булмый. Аның күп төрле бүтән вазифалары да бар — эстетик тәрбия, тормышны танып-белү чарасы буларак әһәмияте һ. б. Ләкин соңгы еллар тормышында очрый башлаган мещанлык, милекчелек, эгоизм күренешләренә каршы торуда, аларга актив һөҗүм ясауда әдәбият-сәнгать әсәрләренең роле зур.

Әдәбият аларга ничек тәэсир итә соң?

Минемчә, моның иң беренче юлы — андый типларны халыкның күз алдына, әдәбият мәйданына, яктыга чыгару. Шулай итеп җәмгыятьнең бу мәсьәләгә игътибарын юнәлтү. Аларның каян, нинди җирлектә һәм ни сәбәпле туууларын ачыкларга тырышу. Җәмгыятьнең алдынгы көчләренең бу хакта уйлануы. Менә болар инде әлеге без теләмәгән күренешнең социаль тамырларын ачып салырга ярдәм итә. Килеп чыгу сәбәпләре, тамырлары ачыклангач, билгеле, көрәш шактый җиңелләшә.

Ә икенче юл, күрәсең, мондыйрактыр. Әдәби әсәрләр, әзме-күпме дәрәҗәдә, безнең эчке дөньябызны матурайталар, безне үзебезгә сиздерми генә тәрбиялиләр. Димәк, күңелебезнең яшәү мохитен югарырак күтәрәләр, биектәрәк итәләр. Безнең әйләнә-тирәгә карашыбыз да инде бүтәнчәрәк була, кайбер нәрсәләргә килешмәүчән мөнәсәбәт туа. Ягъни без үзебез телибезме-теләмибезме, теге типлардан күпмегәдер аерылабыз, ераклашабыз. Бүген әле шактый күп санда күренүләренә карамастан, без инде аларның

чын кешелеккә ят икәнлекләрен сизәбез. Шулай итеп, минемчә, җәмгыятьтә аларга каршы өнәмәүчән караш яши башлый. Ул тора-бара активрак, эшлеклерәк төс алырга, төрле чаралар белән ныгытылырга да мөмкин. Һаман активрак була барган менә шушы күрәшнең нигезен, иң беренче талпынышларын, инде алда әйтеп үткәнебезчә, әдәбият хасил итә. Начарлык белән килешмәүнең тәүге орлыкларын безнең җанга ул сала.

— Ә менә Сез әсәрләрдәге нindирәк геройлар, тормыш хәлләре яисә конфликтлар укучыга ныграк тәэсир итә дип уйлыйсыз? Кайсы әсәрләрнең тормыш өчен «файдалы эш коэффициенты» күбрәк икән?

— Мин Сезнең сорауда яңгыраган «файдалы эш коэффициенты» дигән сүзләрне бары тик бик киңәйтелгән мәгънәсендә генә куллануга риза. Ә болай үзенең туры мәгънәсендә исә — юк. Чөнки файда дигән төшенчәне әдәбиятка карата турыдан-туры кулланырга һич тә ярамый. Әгәр дә без бу сүздә Сез аңлаган төсмерне — яшәешкә булган уңай йогынтыны аңлыйбыз икән, ул чагында да әлеге йогынты, алдарак сөйләп узганыбызча, бик күп башка нәрсәләр аркылы гына сизелә, чынга аша.

Мисалга, прозабызның кызыклы гына күренеше саналган бер әсәрне — Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестен алыйк. Геройлар — повестьның исеменнән үк күренгән кешеләр: ана һәм аның уллары. Автор әсәрдә аларның тормышын шактый тәфсилләп сөйли, һәр герой диярлек безнең хәтергә уелып кала, күпләгән эпизодлар күңелне кузгата. Ә менә Сез сораган нәрсә — тормышка йогынтысы ничегрәк икән бу әсәрнең? Һәрхәлдә бер укучы да ул геройлар сыман яшәргә омтылмаячак — монысы Сезгә дә, миңа да ачык. Чөнки анадан һәм тагын бер улыннан кала әсәрдә бүтәннәр бик үк үрнәк алырдай геройлар түгел, алар — нигездә гыйбрәтле тормыш кичерүче кешеләр. Аннан соң, бер кешенең яшәве икенчегә бик туры килми дә бит әле ул. Аларның һәркайсы — үзенә аерым гомер, бүтән юл. Уртак нокталар шактый аз табыла кешеләрнең язмыш борылышларында...

Шулай булгач, повесть укучыга ни рәвешле йогынты ясый икән соң?

Минемчә, әдәби әсәрне укыган вакытта иң көчле тәэсир итүче фактор ул — әсәрдә язучының күңел, рух көче белән хасил ителгән үзенчәлекле климат, эчке мохит. Тулаем әнә шул мохитның безне үзенә буйсындыра, ышандыра алуы, үзенең бөтен тулылыгы, җанлылыгы белән эчке дөньябызга үтеп керә алуы. Автор рухи дөньясының иң тирәндәге, иң нечкә омтылышларына кадәр безгә күчә алуы, безнең үзебезнекенә әйләнеп китә алуы.

Хәсән Сарьян повесте җирлегендә карасак, язучы рухы тудырган дөньяның иң төп омтылышлары нинди соң? Язучы күңеле үз геройлары тормышы буйлап нәрсәгә таба бара?

Әсәрнең иң төп омтылышы — чиста, пакь җаннарны тормыш чынбарлыгында озаграк, дәвамлырак яшәтәсе килү, алар өчен борчылу. Әсәр үзенең бөтен барлыгы белән керсез җанның җирдәге гомерен озайту юлларын эзли кебек. Андагы һәр җөмлә, сүз шул эзләнүгә булыша сыман. Ә без исә әлеге бик кадерле һәм тәэсирле процесста катнашабыз шикелле...

Сез тагын: «Нинди геройлар тормышка күбрәк тәэсир итә?» — дип сорыйсыз. Мөгаен, мондый сорауны кую урынлыдыр. Без йогынтыны, гомумән алганда, турыдан-туры булмый дип үтсәк тә, укылган китапларны чагыштырып, берсе янәшәсенә икенчесен куеп карасак, аларның бер ишләре безгә көчлерәк тәэсир иткәнен, икенчеләрнең тәэсире йомшаграк икәнен күрербез.

Геройларның нindиләре безгә күбрәк тәэсир итә? Озын гомерле геройларның бик күбесенә хас сыйфат, минемчә, шул бугай: алар кешелек җәмгыятенең әхлакый тормышы өчен мөһим мәсьәләләр күтәрәләр, әсәрләрдә үз гомерләре белән әнә шул озын гомерле рухи мәсьәләләрне чишәргә омтылалар. Аларны җәлеп иткән сораулар кешелек игътибарыннан тиз генә төшми. Шуңа күрә геройлар үзләре дә төрле чорларның укучылары өчен кызыклыкларын югалтмыйлар, хәтердә озак сакланалар.

— Без, укучылар, газета-журнал битләрендә басылган рецензияләрне, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен дә кызыксынып укып барабыз. Теге яки бу әсәр уңае белән үзебездә туган фикерләрне шушы өлкә белгеченең анализы хисабына тулыландыргач, әдәби әсәр тагын да зуррак мәгънә ала, андагы яңа фикер катламнары ачыклана. Андый мәкаләләрне укыганнан соң бездә еш кына сораулар да туа. Шуларның берсен хәзер Сезгә бирәсе килә.

Күп кенә мәкаләләрдә берәр әсәрне тикшергән вакытта «конфликт» сүзе актив катнаша, шул хакта сүз йөртү еш очрый. Аннан башка әсәр бөтенләй яши алмый сыман тоела кайбер мәкаләләрне укып чыккач. Ә кайбер язучыларның әйбәт кенә әсәрләре өчен мондый «куркыныч» сүзләрнең, төшенчәләрнең бөтенләй кирәге дә юк кебек күренә безгә...

— Әдәби әсәргә тулаем бәя бирә торган төшенчә-таләпләр бар. Мәсәлән, югары сәнгатьчәлек, әдәби әсәрнең идея-эстетик бөтенлеге һәм тагын берничә шундый категория әсәрләргә шактый тулы һәм төрле яктан карау мөмкинлеге бирә. Тик аларны зур

сизгерлек, тикшерүче кешенең нечкә тоемы белән куллану кирәк. Шулай түгел икән — әдәбият белеменең һәрбер төшенчәсе әдәби әсәрләрнең җанын кыючы, һәрбер эчке тибрәнешен сүндерүче салкын бер механизмга әйләнеп кала.

Конфликт мәсьәләсендә дә эш шулай торадыр дип уйлыйм. Хәзер безнең татар әдәбияты өчен бу аеруча хәлиткеч нәрсә. Чөнки сүз әсәрнең мәгънә үзәге хакында бара, аның умыртка сөяге турында. Конфликт дип нәрсәне карау, аны ничек аңлау әсәрнең бөтен язмышын билгеләргә мөмкин.

Конфликт дигәч, без шундук нинди дә булса каршылык булу, бәрелеш килеп чыгуны күзаллыйбыз. Әсәрләрдә дә конфликт яшәве күп вакытта нәкъ менә бәрелеш, кемнәрнеңдер бер-берсе белән чәкәләшүе рәвешендәрәк чагыла. Тышкы каршылыкка гына корылган конфликт та күп очрый. Ягъни, кирәк булганга гына уйлап чыгарылган каршылык, кеше характерларының үзеннән табигый рәвештә килеп тумаган бәрелеш... Мондыйлары производствога багышланган әсәрләрдә күп була инде аның.

Болар, минемчә, конфликт төшенчәсен гадиләштереп аңлау нәтиҗәсе. «Конфликт кирәк» дигән таләпнең үзен генә ныгытып үзләштерү җимеше. Ә конфликтсызлык теориясенең нәрсәгә китереп чыгаруы безгә шулай ук билгеле. Андый әсәрләрдә гадәттә бик шома, җайлы агучы тормыш — ясалма яшәү була. Күргәнебезчә, ике чиккә ташлану да сәнгатьтән читкә алып китә.

Ә әдәбият осталары бу мәсьәләне үз иҗатларында ни рәвешле хәл итәләр соң?

Безнең чор рус әдәбиятындагы иң күренекле хикәячеләрнең берсе Василий Беловның «Чок-получок» дигән әсәре бар. Аның кыскача эчтәлеге болай.

Бер төркем егетләр-кызлар кунача ял итү өчен урманга чыгалар. Кичен караңгы төшкәч, гадәттәгечә учак ягып җибәрәләр. Учак тирәли җайлап утырышалар, күңелле сөйләшү башланып китә. Егетләр һәрвакыттагыча кызлары янында үзләрен батыр тотарга тырышалар. һәрберсенең чын егет, кавалер булып күренәсе килә. Шулай учак яна, төрле-төрле сүз белән кич матур гына дәвам итә... Бераздан яшьләр янына бер чит кеше килеп чыга. Ул ауда йөри икән, болар янына утырып ял итәргә теләге барлыгын белдерә. Яшьләр аңа кешегә чын күңелдән сөенеп, үз араларына алалар. Кичке әңгәмә тагын да җанланыбрак китә. Ә тора-бара сүзнең мондые чыга: элек офицерлар арасында рыцарьлыкны, кыюлыкны сыный торган шундый бер уен булган. Аның кагыйдәсе мондый икән: уенда ничә кеше катнашса, шуның хәтле патрон алына, ләкин аларның берсе генә корыла. Тыштан карап торуга алар барысы да бер төсле — кайсы буш, ә кайсының эчендә дары бар икәнен белү мөмкин түгел. Менә шул патроннарны тагын бер кат бутаганнан соң, әлеге уенның иң куркыныч өлеше башлана. һәр офицер бер патрон ала, шуның белән револьверын кора, үзенең маңгаена тери һәм чакмага баса. Арадан берәүгә бу басу соңгысы була. Чөнки патроннарның берсе корылган бит! Менә шундый куркыныч, ләкин нинди дә булса хикмәте булган уен. Шушы мавыктыргыч хикәя сөйләнеп бетәр-бетмәс егетләрнең берсе: «Әйдә без дә сынап карыйбыз!» — дип әйтеп ташлый бит кызулык белән. Авыздан сүз очып чыккач, кызлар да карап торганда, егетләр, билгеле, кире чигенми инде. Аучы да озак тормый гына патроннарны әзерләп китерә. Нәкъ уен таләп иткәнчә — берсе корылган дип. Ул патроннарны җирәбә кебек сикертә, тәмам бутый да — уртага куя. Инде хәзер чират буенча һәркем үз патронын алырга, аның белән мылтыкны корырга һәм маңгаена терәп атып карарга тиеш. Аучы сөйләгәндә егетләр кызыккан уенның шарты әнә шундый.

Әмма әле генә бик батыр кыланган егетләрнең берсе дә, кулын сузып, үз патронын ала алмый. Алар куркалар... Әкренләп таралышалар да...

Тик егетләрнең берсе үзенең куркуына эчтән бик хурлана, моны авыр кичерә. Төнлә байтак газапланып яткач, ул торып әлеге патроннар арасыннан берне ала да — мылтыкны кора, аннары калтырана-калтырана маңгаена тери һәм озын таяк ярдәмендә чакмага баса. Егетнең бәхете җиңә — ату булмый. Шуннан соң ул тәмам һушына килә: калган патроннарны да ачып, тикшереп чыга. Баксаң — алар бар да буш икән! Аучы боларны сынап кына караган икән!

Василий Беловның «Чок-получок» хикәясе менә шушы вакыйгага нигезләнгән. Күргәнебезчә, безнең заман егетләрен шактый эчтән яктырта аның сәнгате. Ә конфликт бармы соң биредә? Хикәядән аны тиз генә табып алып, менә ул дип күрсәтү кыен. Биредә ул ике көчнең ачыктан-ачык бәрелеше төсендә түгел, ә кешеләр эчендәге, табигатендәге нинди дә булса шактый билгесез каршылыкларның тоташ агымы, хәрәкәте сыман яши. Хикәядә алынган тормыш күренеше ул агымны үз табигыйлегендә, әмма калкурак, күренерлегрәк итеп укучы күз алдына бастыра. Билгеле, ап-ачык конфликт таба алмаган кебек, бик начар һәм бик яхшы кешеләрне дә күрсәтү мөмкин түгел биредә. Минемчә, хикәядә киң мәгънәдәге кеше тикшерелә, сынала. Әлеге егетләр сүздә генә, тел белән генә батыраючылар булып чыга. Хикәянең бөтен агышы, бүгенге яшьләрнең кем икәнлекләрен белергә, аңларга тырышу булып аңлашыла.

В. Белов хикәясендә без иярәнгән ачык конфликтка әллә ни мохтаҗлык та сизелми. Аның булуы да шикле. Бәлки аны элекке офицерларның кыюлыгы, тәвәккәллеге һәм

хәзерге яшьләрнең берникадәр йомшаклыгы арасында каршылык дип кабул итәргә кирәктер? Ул чагында конфликт бер-берсеннән бик ераклашкан көчләр арасында булып чыга. Конфликт сүзенең үз мәгънәсе дә сакланмый сыман.

Ләкин биредә шунысы ачык — без иялнгән конфликт булмаса да, эчкәре яшеренгән зур каршылыклар барлыгы чагыла Василий Белов хикәясендә.

— Алайса Сез иң мөһим дип нәрсәне санныйсыз соң?

— Иң мөһимеме? Минемчә иң мөһиме — әсәрдә яшәүнең, чынбарлыкның эчкәре катламнарына алып кереп китәрдәй бер көчле «бөтерчек» булырга тиеш. Ул җәмгыятьтә яңа гына хасил булган зур әһәмиятле үзгәреш-тенденцияләрдән барлыкка килсен. Ул «бөтерчек» үзенең холкы, табигате белән кабатланмаган, ачылмаган, әле моңарчы безнең тарафтан аңланмаган, ачыкланмаган булсын. Аны аңлау — дөньяны һәм яшәүне төшенү юлында зур бер баскыч тәшкил итсен.

Чын сәнгать әсәрләрендә әнә шундый олы хасият сизелә. Ул булса, бүтән бик күп нәрсәләр хакында еш кына бөтенләй онытасың да.

— Ә шул ук сорауны иҗатчы шәхесенең үзенә карата куеп карасак ничек була икән? Ягъни Сез бүген язучы кеше өчен нинди сыйфатлар бигрәк тә кирәкле дип саныйсыз? Әлбәттә, талант булуны без иң беренче шарт итеп беләбез. Ансыз, гомумән, теге яисә бу каләм иясен язучы дип тә атамас идек. Биредә сүз талант, тырышлык янәшәсенә баса алырлык бүтән сыйфатлар турында бара. Сез аларның иң беренчесе итеп кайсын атар идегез?

— Минемчә, тормышта туа килгән яңа мөнәсәбәтләр, яңа бәйләнеш — бәйләнышларны нечкәләп һәм тирәннән сизеп, тоеп тору. Калыплашып килгән яңа мөнәсәбәтләрнең тормыш чынбарлыгына ни рәвешле тәэсир ясый башлауларын гадиләштермичә аңлый алу. Шул гаять нечкә, сизелер-сизелмәс барган үзгәрешләрне сәнгатьчә итеп, кешегә көчле йогынты ясарлык дәрәҗәдә сурәтләп бирү.

Сез башта әйтеп үткән талант, тырышлык һәм алар янына тагын менә шушы сыйфатлар булса, бүгенге язучы иҗатында без көткән зур әсәрләр туарга мөмкин. Калганнары исә әкренләп, тәҗрибә туплый-туплый табылачак.

— Ә менә әдәбият хакындагы төрле сөйләшүләр, мәкаләләр һәм тулы бер фәнни хезмәт кебек әйберләр язучы иҗатына файда китерә микән? Безнең ишетүебезгә караганда, кайбер язучылар андый фикерләргә бик үк колак та салмыйлар бугай бит...

— Минемчә, әдәби әсәр иҗат итү һәм аның хакында фикер йөртү — алар икесе ике төрле эш, ике стихия. Кайбер язучыларның әдәби тәнкыйть фикеренә артык исе китмәве бәлки әнә шуның белән аңлатыладыр да. Ягъни, иҗат дөньясында яшәүче язучы үз туфрагында үзен шактый ышанычлы сизә, ул күңеле белән интуитив рәвештә дөреслеген тоя. Аның әнә шул дөньядан аерылсы, башка яшәү мохитенә (анализ ясау, конкрет фикер йөртү, нәтиҗәләр ясау өлкәсенә) күчәсе килми. Иҗат кешесенең язасы һәм язасы килә, ул, үзенең хыялына ияреп, ашкына-ашкына эшли, яңа геройлар тудыра. Минемчә, аны дөрес түгел дияргә берниндн дә нигез юк.

Әмма икенче яктан, әдәбият турындагы хезмәтләр, мәкаләләр бу өлкәнең серләрен күбрәк белүгә ярдәм итәргә тиешләр. Соңгы елларда безнең әдәби тәнкыйть алдына әсәрләрне тормыш белән бәйләп тикшерү бурычы куела килә. Бу әдәбиятның һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләренең реаль тормышка йогынтыларын көчәйтү өчен кирәк. Чыннан да, әсәрләрне чынбарлык тудырган җанлы мохит дип карау фикерне киңәйтә, укучыны заманның үткен мәсьәләләре эченә алып кереп китә. Андый мәкаләдә әдәбият терминнары гына хакимлек итми, бер әсәр нигезендә тормышка карата яңа мәгънәле сүз әйтергә омтылу да була. Андый тәнкыйть мәкаләләре инде язучыга да, укучыга да кызыклы. Чөнки чын тормыш эченәрәк керәсең, рухың активрак яши башлый.

Әдәби әсәрләрне тулаем тоеп, тулаем рухи анализ үткәрү нәтиҗәләрәк сыман тоела минем үземә. Чөнки әдәби әсәр ул — бөтен организм. Аны тулаем карап, тулы килеш тоеп, күреп кенә бар дөреслегендә күзаллап була. Хәзер медицина да кешенең аерым әгъзаларын гына түгел, ә тулы организмны бер бөтен итеп алып, комплекслы дәвалау, шул рәвешчә эш итү юлларын эзли бит. Минемчә, әдәби әсәр хакында безнең фикер йөртүебез дә аны һәрчак әнә шундый «җанлы бер бөтен» итеп тоюга омтылырга тиеш.

— Бусы күбрәк Сезнең үзегезгә — әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүчеләргә карыйдыр инде, шулай бит?

— Бәлки шулайдыр да. Әмма әсәрне мөмкин хәтле тулырак, тирәнрәк аңлау — китап укучы өчен дә кирәк.

— Әйе, бу сөйләшү безнең өчен бик күп уртак мәсьәләләр барлыгын ачыклады. Алар барыбызны да борчый һәм уйландыра...

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

**Журналның 2 санында Р. Сафаров һәм Л. Леронов хатлары белән тәрҗемә турында сөйләшү башланып киткән иде. Аннан соңгы саннарда М. Рафиков, Р. Кукушкин, Н. Арсланов, Р. Юсупов язмалары урнаштырылды.**

**Бу санда сүзне тәрҗемәче Л. Хәмидуллин белән шагыйрь һәм прозаик Ә. Баянов дәвам итә.**

## Лерон Хәмидуллин:

Бүгенге заманда бер генә әдәбият та аралашмый яши алмый. Ул үз ана телендә туган әсәрләрне башка телләргә күчерү мохтаҗлыгы кичергән кебек, үзе дә теге яки бу күләмдә башка халыклар үрнәген тәрҗемә итәргә тиешле. Үз-үзенә генә чикләнгән иҗат дөньясының югары уңышка ирешүе мөмкин түгел.

Безнең әдәбиятта бу өлкәдә нәрсәләр эшләнгән соң? Без кемнәрне татар укучысы белән таныштырганбыз да, кемнәр безнең әсәрләребезне үз иткән? Бу юнәлештә безнең алда тагын нинди бурычлар бар?

Иң әүвәл башкарылган эшне барлыйк. Укучыларыбыз кулына 1979 елдан башлап иллегә якын тәрҗемә китап барып ирешкән. Әлеге санның яртысын рус совет әдәбияты һәм рус классик язучыларының әсәрләре тәшкил итә. Бу чорда без үз ана телебездә Алексей Толстойның «Михнәтле заман» һәм «Аэлита», Николай Островскийның «Корыч ничек чыникты», Юрий Бондаревның «Кайнар кар» романнарын, Виктор Астафьев, Анатолий Алексин, Владислав Крапивин, Валентин Распутиннарның илкүләм танылган повестьларын, Константин Паустовскийның хикәяләр тупламасын кулыбызга алдык. Аларны күренекле тәрҗемәчеләребез Афзал ага Шамов, Кыям Миңлебаев, Яхъя Халитов, Таһир Нурмөхәммәтов һәм башкалар уңышлы тәрҗемә иткәннәр.

Башка милли әдәбиятлардан унбиш китап татарчалаштырылган. Алар арасында казах язма әдәбиятына нигез салучыларның берсе Абай Конанбаевның иҗади мирасын барлаучы «Абай», хәзерге заман казах әдипләренең кызыклы сигез повестен туплаган «Ак дөя» китаплары, танылган белорус язучысы Василь Быковның СССР Дәүләт премиясе алган ике повестен берләштергән «Һәйкәл» җыентыгы, белорус Елена Кобец-Филимонованың фашистлар тарафыннан яндырылган Хатынь авылы балалары язмышына багышланган «Хатынь тургайлары» һәм украин язучысы Любовь Коваленконың дәһшәтле сугыш көннәрендә ике яшүсмернең язмышын тасвирлаучы «Кәләш» повестьлары бар.

Бик үк тулы булмаган шушы исемлектән күренгәнчә, тормышның төрле заманын, төрле катламын чагылдырган шактый гына кызыклы әсәрләр татарчалаштырылган икән. Бигрәк тә сугыш темасы, сугыш алып килгән фаҗига-авырлыкларны тасвир итүче әсәрләр бу исемлектә беренчелекне алып торганлыгы күзгә ташлана. «Кайнар кар», «Талау», «Һәйкәл», «Онытма гомергә», «Хатынь тургайлары», «Кәләш», «Ак дөя» — боларның барысы да канлы сугышны тасвирлауга, шул сугыш алып килгән авырлыкларны сурәтләүгә багышланган бик гыйбрәтле китаплар. Җиңүнең кырык еллыгына багышлап чыгарылган күләмле «Рәхмәт сиңа, солдат» җыентыгына утыз тугыз авторның берәр әсәре тупланган. Бу авторларның күпчелеге — сугышны үз күзе белән күргән, корал тотып утка кергән кешеләр яисә алгы сызыкта еш булган язучылар, журналистлар.

Инде үз әдәбиятыбыз республикадан читтә ничек тарала соң? Шушы ук дәвердә татар язучыларының әсәрләре кайларда басылган, нииндирәк әйберләр сайлап алынган? Иң элек шунысы күзгә ташлана — татар китаплары Мәскәү белән Ташкентта, рус һәм үзбәк телләрендә иң күп чыккан икән. Мәскәү һәм Ленинград нәшриятларының безнең әдәбиятка игътибары аңлашыла. Бу чорда безнең Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, М. Җәлил, Г. Бәширов, С. Хәким, Ә. Еники, З. Нури, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Э. Касыймов, М. Хәбибуллин, Р. Фәйзуллин һәм башка язучыларыбызның берәр-икешәр китабы башкалада дөнья күргән, бөтен илгә таралган.

Ә башка республикаларда башка телләрдә (чит илдә чыкканнарын исәпкә алмыйча) тагын утыз алты җыентык басылган. Әйткәнемчә, аларның иң күпчелеге — җиде китап — үзбәк телендә «сөйләшү» бәхетенә ирешкән. Кызганычка каршы, бу дәвердә бездә бер генә үзбәк китабы да дөнья күрә алмады. 1986 елда Ташкентта тагын әле Габдулла Тукайның «Сайланма әсәрләр»ен чыгарырга планлаштыралар. Үзбәклә рдән кала безнең әдәбиятны ка-

захлар — биш, каракалпак һәм украиннар дүртәр тапкыр, белоруслар — өч, әзербайҗан, башкорт, чуваш, молдаван, кыргызлар икешәр мәртәбә тәрҗемә итеп бастырганнар.

Шул телләрдә укучылар кулына безнең нинди әсәрләребез юл яра соң? Бу җәһәттән беренчелекне, әлбәттә, Муса Җәлил иҗаты алып тора. Рафаэль Мостафинның Җәлил һәм җәлилчеләргә багышланган әсәрләре өч тапкыр басылып чыкты. Башкорт, төркмән, үзбәк телләрендә Самат Шакир әсәрләре, украин һәм молдаван телләрендә Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» әкияте дөнья күрде. Арада берничә күмәк җыентык та бар: казахча «Татар повестьлары», үзбәк һәм каракалпак телендә хикәя җыентыклары, украин һәм каракалпак телләрендә татар шигърияте тупланмалары нигездә уңышлы тәрҗемә ителеп, яхшы сыйфат белән чыктылар. Әйтергә кирәк, бу күмәк җыентыкларны ул республикаларга тәкъдим итү өчен безнең Язучылар союзының идарәсе дә байтак эш башкарган иде.

Республикабызда яшәп русча язган авторларның китапларын татарчалаштыру хакында бер-ике сүз әйтми ярамас. Геннадий Паушкинның сугыш күренешләрен чагылдырган «Кайтыгыз, ләкләкләр» повестен прозаик Ә. Баянов, Зөфәр Фәтхетдиновның «Ачылган серләр» исемле маҗаралы повестен Р. Сабиров, Марсель Зариповның «Үзеңнеке — үзәктә» китабын Я. Халитов тәрҗемә итте. Шушы ук дәвердә танылган драматург Диас Вәлиевнең сигез пьесасы ике китапка бүленеп «Язмышның чарасы бер генә» һәм «Әгәр үзеңә хыянәт итсәң» исемнәре белән басылып чыктылар.

Димәк, безнең республикада тәрҗемәнең ике юнәлешендә дә байтак эш башкарылган икән. Бик күп үзенчәлекле әсәрләрне татарчалаштыру нәтиҗәсендә татар әдәбияты шактый баеган, тирән эчтәлекле һәм кыйммәтле рухи азык алган. Әйтик, Бөек Ватан сугышына багышланган күпчелек повесть һәм хикәяләрне, Ю. Бондаревның Сталинград төбәгендә каты бәрелешләрне кырыс чынбарлыгы белән бик реаль сурәтләгән «Кайнар кар» романын мин үзебезнең әдәбиятны баетучы шул төр әсәрләр рәтенә кертәм. Үзебездә дә сугыш хәлләрен яхшы белгән, аны үз җилкәсендә татыган әдипләрнең ишле генә булуына һәм кырык ел дәвамында «Кызыл Йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше» (Г. Әпсәләмов), «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» (Н. Дәүли), «Һәркемнең гомере бер генә» (Х. Камалов) кебек роман, повесть, хикәяләр язылуга да карамастан, әлеге тәрҗемә әсәрләре дә безнең әдәбиятка бик кирәк. Алар тематиканы тулыландыра төшәләр, укучының офыкларын киңәйтәләр.

Шундый ук хәлне яшь буынга, яшүсмерләр һәм мәктәп укучыларына атап язылган әсәрләрдә күрәсең. Бу чорда тәрҗемәче-әдипләр иҗаты аша Анатолий Алексинның «Шалтыратыгыз да килегез», Альберт Лихановның «Минем генералым», Владислав Крапивинның «Баһадир шлемы», Евгений Носовның «Ике дус», Виктор Астафьевның «Бәхилләшү», чит ил язучылары Александр Дюманың «Өч мушкетер», Жюль Вернның «Серле утрау», Этиль Войничның «Кигәвен» кебек роман һәм повестьлары исәбенә балалар әдәбияты тагын да үстерелде.

Безнең Рәис Даутов, Яхъя Халитов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтов, Фәния Гайнановалар кебек утызар еллык тәҗрибә туплаган оста тәрҗемәчеләребез бар. Әмма бу эштә бер проблема да яши: милли телләрне белүче әдипләр бетеп бара диярлек. Әүвәл бездә казах, үзбәк ише тугандаш телләрне яхшы үзләштергән олы буын вәкилләре булган. Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис әнә инглиз һәм чуваш телләрен яхшы белгән, К. Ивановның «Нарспи» поэмасын һәм В. Шекспир сонетларын оригиналдан тәрҗемә итеп калдырган. Андый белгечләр хәзер сирәгәеп бара. Байтак кына союздаш республикаларда тәрҗемә эшенең бу проблемаларын уңай хәл итү мисаллары бар. Әйтик, Грузия, Латвия, Украина, Белоруссия оешмаларында илебез халыклары телен өйрәнүне оештыралар, аерым әдәбиятлар белән аралашырдай махсус белгеч-кадрларны хәзерлиләр. Безгә дә бу хакта уйлана башларга вакыт.

Тәрҗемә эшендәге уңышларыбыз күз алдында. Ә җитешсезлекләр бармы соң? Алар нидән гыйбарәт? Элекке елларда тәрҗемә ителәчәк әсәрләрне сайлап алуда талымсызлык күзгә бик ташлана иде. Бүген инде теләсә кемне түгел, бары тик үз әдәбиятыбыз югарылыгында торган үрнәк әсәрләрне генә беренче чиратта бастыру хаҗәте туды. Узган биш еллыкта бу таләп нигездә үтәлгән, очраклы авторларга, әһәмияте шикле роман, повестьларга мәйдан бирелмәгән диярлек. Тәрҗемәнең сыйфаты да уңай якка нык үзгәрде. Яшь тәрҗемәчеләр дә иң әлек осталары күзәтүендә тәҗрибә чорын үтәләр.

Әйе, тәрҗемә дә — әдәбиятыбызның бер мөһим тармагы. Аңа караш һәм таләпләр шулай ук югары булырга тиеш. Нинди әсәр тәрҗемә ителергә тиешлеген сайлаганда да, ул эшне кемгә тапшырырга кирәклеген уйлаганда да, китап нәшрияты белән Язучылар союзы киңәшеп эшләргә бурычлылар. Шуны истә тотып узган ел бу ике оешма вәкилләре киләчәк ун елда татарчалаштырылырга фараз ителгән автор һәм әсәрләр исемлеген төзеделәр. Димәк, киләчәктә очраклы әсәрләр гомумән дә дөнья күрмәс дип ышанырга була.

## Әхсән Баянов:

1. Теге яки бу әсәрне бүтән телгә тәрҗемә иткәндә, иң мөһиме — әсәрнең настроениесен, рухын, кичерешләр тирәнлеген тулы һәм дөрес җиткерү дип исәплим. Тышкы калыбы сакланып та, әсәрнең җаны исән калмаса, тәрҗемәдә мәгънә юк. Миңа сүзләр түгел, тойгылар тәрҗемәсе кирәк. Әлбәттә, форманы, эчтәлекне, милли колоритны төгәл саклауның максатка ирешүдә хәлиткеч чара икәнләген дә, шуңа өстәп шигырьдә строфалар, ритмика, инструментовка (авазлар, сүзләр яңгырашы), авторның шәхси стиле, конкрет әсәрнең стиле һ. б. үзенчәлекләре саклануын да истә тотарга туры килә. Ләкин шушы чаралар белән, техник алымнар белән коралланган оста, әсәрне тәрҗемә иткәндә, автор кебек үк әсәрләнсә генә тәрҗемә икенче телдәге сәнгать фактына әверелә һәм тере организм сыйфатында яши ала. Монысы теориядә, идеалда. Практикада хәл катлаулырак. Монда табигыйлек хакына, табышлар бәрабәренә, гадәттә, тел аермасы аркасында килеп чыга торган югалтулар белән килешергә тиеш булабыз.

2. Тәрҗемә ителә торган әсәрне оригиналда укый алу—бәхәтле сыйфат, ә халыкның тарихын, культурасын аңлап эш итү — мәҗбүри шарт. Ләкин телне белеп тәрҗемә итүчеләр һич тә җитәрлек түгел. Шуның аркасында подстрочник ярдәменә мохтаҗлык туа. Бу инде законлы рәвештә кергән хәл. Киресенчә, подстрочниктан файдаланмау хәзер җитди кимчелек булып тора. Хәлбуки бездә бер телгә тәрҗемә ителгәнне (башлыча русчага тәрҗемә ителгәнне) кабат икенче телгә тәрҗемә итү кебек җавапсызлык яшәп килә. Хуҗа Насретдинча — шулпасының шулпасы килеп чыга һәм, икенче төрле әйткәндә, тәрҗемә профессиональ дәрәҗәгә күтәрелә алмый. Һәвәскәрлек бигрәк тә башка халыклар әсәрләренең үзебезнең телгә тәрҗемә ителешендә озакка сузылды. Бу практикага чик куярга бик вакыт, чөнки бит материалны тиешле дәрәҗәдә белгән хәлдә генә осталык турында сөйләргә мөмкин. Һөнәрнең тиешле дәрәҗәдә үзләштерелгән булуы күнегүләргә генә кайтып калмыйча, тәрҗемәченең эрудициясен дә эченә ала. Аларны бер-берсеннән аеру мөмкин түгел. Шул ук вакытта бу ике шарт берлеге дә бөтен нәрсәне берьюлы хәл итә торган кодрәт түгел. Чөнки ахыр чиктә әсәргә җанны ни өрә? Талант. Хәлебез тәрҗемәләр азлыгыннан әллә ни зарланырлык булмаса да, тере характерларның, темпераментлы әсәрләрнең аз булуы хакында еш әйтергә туры килә.

3. Идеалда тәрҗемә оригиналның бөтен байлыгын биреп бетерергә тиеш. Ләкин чынлыкта тәрҗемә барыбер оригиналның үзе түгел бит. Кайбер югалтулар котылгысыз. Ләкин компенсациягә ирешелгән очракта отылыш булмый диярлек.

Художество кыйммәтенә ия хәлдә тәрҗемәгә бирелми торган проза әсәре була алмый. Ә шигырьләр байтак очрый. Милли телдә яңгыраш матурлыгына гына кайтып калган риторик әсәрләр (һәм шагыйрьләр) башка телгә авыр күчә. Тәрҗемә еш кына укучыны алдау, Фәрхетдинне Фәтхетдин дип тәкъдим итү булып чыга. Андый әсәрләрне тәрҗемә итмәү хәерлерәк.

4. Оригиналдан тәрҗемә итү иң табигый һәм хаклы таләп булса да, тормыш моны башкачарак хәл итә. Оригиналдан начар тәрҗемә ителгән әсәргә караганда, подстрочник ярдәмендә талантлы эшләнгән тәрҗемә кадерлерәк. Димәк, өстенлек ысулга түгел, нәтиҗәгә бирелә.

5. Подстрочниклар ясау проблемага әйләнде. Подстрочник осталары соңгы елларда нык азайды. Икенчедән, кызыклы хәл: үзебез союз аренасына чыгуны активлаштыру, системага кертү хакында шаулашабыз, ә шул ук вакытта подстрочниклар өчен түләүне туктатабыз. Димәк, бу мәсьәләдә сүз бүтән аспектта барырга тиеш була. Тәрҗемә — иҗади эш. Ләкин ул да, иң беренче чиратта, материаль җирлеккә бәйле булып кала.

6. Подстрочник ясаучы да, шигырьне калыпка кертүче дә чын тәрҗемәче түгел. Подстрочник фикер генә бирә, калыпка салу да шуннан ары уза алмый. Чын тәрҗемә — әсәрне икенче телдә терелтү дигән сүз.

7. Кызганыч, классиканы русчага тәрҗемә итү һаман башланыш хәлендә таптана бирә. Әсәрләрне башка халыкларга классик дәрәҗәдә җиткерерлек тәрҗемә табу кыен. Булганнарын тәртипкә китерәсе, булмаганнарын булдырасы бар. Бу зур бурычны чираттагы әңгәмә белән генә хәл итә алмабыз кебек. Оештыру чаралары кирәк.

8. Бүгенге шагыйрьләрнең русча чыккан китаплары белән дә эш шулайрак тора. Сыйфатка бер генә сүз белән бәя бирү мөмкин түгел. Хәл катлаулы, чуар. Әйбәт китаплар күренә, урта кул дигәннәре һәм чыкмаска тиешләре дә чыккалый. Ләкин система һаман сизелми.

9. Проза китаплары хакында да шуны гына әйтә алам.

10. Мөмкинлекләр? Алар чикләнмәгән. Ләкин аларны тормышка ашыру өчен күп кенә практик мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк әле.

# ШИГЪРИ КҮПЕРЛӘР ОСТАСЫ

Шагыйрь Әхмәт Исхакның күптән түгел «Илһамнар чишмәсе» дип аталган күләмле китабы басылып чыкты[1]. Авторның әлеге китабына аннотациядә күрсәтелгәнчә, төрле ил шагыйрьләреннән алып тәрҗемә ителгән шигъри әсәрләре тупланган. Бөек рус шагыйрьләре А. Пушкинның «Руслан һәм Людмила», «Балыкчы һәм балык турында әкият»ен, М. Лермонтовның «Демон», «Мцыри», Н. Некрасовның «Тимер юл» кебек мәшһүр поэмаларын беренче тапкыр мәктәп елларында аның тәрҗемәсендә укыгангадыр, күрәсең, шагыйрьнең бу җыентыгын да без аерым бер кызыксыну һәм ихтирам белән кулга тотабыз. Китап әдипнең сиксән яше тулу хөрмәтенә — юбилей уңае белән чыгарылган. Әмма аның бик үк гадәти китап булмавы моның белән генә чикләнми. Әдәбиятыбызга алтмыш елдан артык хезмәт итеп килгән өлкән язучыбызның ул ярты гасырлык иҗат җимешләрен бергә җыйнавы белән дә аерым игътибарга лаек. Тәрҗемәләр белән иркенләбрәк таныша башлагач, җыентыкның эченәрәк үтеп кергәч, аның башка бик күп яклары белән дә гади-гадәти бер китап кына түгеллегенә ныграк төшенәсең.

«Кемне яисә нәрсәне тәрҗемә иткән?» «Ничек тәрҗемә иткән?» «Ник тәрҗемә иткән?» — кебек сораулар йогынтысына бирелеп һәм билгеле бер дәрәҗәдә шуларга җавап эзләп, без күпмедер таныш һәм шул ук вакытта яңа да булып тоелган тылсымлы шигърият дәрьясына кереп чумабыз. Ә инде эстетик ләззәтләнү кичерергә дә, җитди уйлануларга бирелергә дә этәргеч көч булырлык илһам чишмәләре чынлап та аз түгел биредә.

Китап иң элек үзенең географик киңлеге, шигъри әсәр авторларының төрле илләрдә яшәгән халык вәкилләре булуы белән игътибарны җәлеп итә. Масштаблылык шигъри багланышның бөтен җир шарын иңләве белән генә түгел, өч мең елга якын сузылган зур вакыт аралыгын колачлап алуы белән дә билгеләнә. Без монда тарихның төрле борылыш-үсеш этаплары сулышын китереп җиткергән 35 милләтнең йөздән артык шагыйре һәм аларның дүрт йөзләп шигъри әсәре белән очрашабыз. Шундый зур пространство һәм вакыт үлчәмнәрен, гаҗәеп төрле язмышларны бергә җыйнаган көч — һичшиксез, чынбарлыкка шигъри мөнәсәбәт, шигъри яну гәүдәләнеше дә. Шәхесләрнең һәм талантларның бөеклеге дә нәкъ әнә шул изге утның зурлыгы, аның кешелеккә хезмәт итүе белән билгеләнмимени?! Без баш игән бөек затлар исә биредә, әйтерсең лә, бер трибуна артына, бер шигъри бәйге тантанасына бергә җыелган. Безнең эрага кадәр үк яшәп иҗат иткән борынгы Кытай, Япония, Корея һәм Греция шагыйрьләре, Көнчыгышның тугандаш төрки халыклары классиклары Н. Ганҗәви, Г. Нәсими, Галишир Нәваи, М. Фөзули, Мәхтүмколый, Абай Кунанбаев, Г. Сабир, Көнбатыштан Һ. Һейне, А. Мицкевич, Ш. Петефи, Дж. Родари, руслардан А. Пушкин, М. Лермонтов, И. Крылов, Н. Некрасов, В. Маяковский, М. Горький, М. Исаковский, В. Инбер, К. Симонов һ. б. әдипләрнең әсәрләре китапның төп өлешен-үзәген тәшкил итә. Бер уйласаң, күпме чорлар, күпме континентлар, күпме язмыш, күпме шигъри ялкын-хис кисешә тәрҗемәче йөрәгендә... Шунысын да искәртеп китик: бу җыентык Ә. Исхак тәрҗемә иткән барлык әсәрләрнең уннан бер кадәресен генә үз эченә ала.

Ә. Исхакның дөнья классиклары иҗатына салган шигъри күперләре ике юнәлешле булулары белән дә аерылып тора. Борынгы татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабыннан күренгәнчә, әлеге поэманы бүгенге татар теленә күчерүдә, Ф. Фәсеев һәм А. Нуриевалар белән бергә, Ә. Исхак та катнаша. Шуның белән бергә, шагыйрь биредә поэманың русчага сүзгә-сүз тәрҗемәсен дә эшләп чыккан. Милли культурабызны дөнья культурасы белән якынайтуда, димәк, әдип бүген дә җиң сызганып хезмәт итә. Әдәбиятыбызда ул чын-чынлап шигъри күпер коючыларның берсе — мактаулысы. «Шигърь китапханәсе» сериясендә чыккан китабының кереш сүзендә тәнкыйтьче Р. Мо-

---

[1] Әхмәт Исхак. Илһамнар чишмәсе. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1985.

стафин, Ә. Исхакның йөз мең юл шигъри әсәр тәрҗемә итүен күрсәтеп, «акрынрак эшләүче икенче берәүгә моның өчен бөтен бер гомер кирәк булыр иде», дип язган иде. Берәдә тәрҗемәченең тиз яки акрын эшләвен кистереп кенә әйтү кыен, әмма тәрҗемәгә аның болай да инде бөтен бер гомер юлын багышлавы — күз алдында!

Инде тәрҗемәченең кайбер иҗат үзенчәлекләре һәм аның ничек тәрҗемә итүе мәсьләсенә күчик. Шунысы хөрмәткә лаек: Ә. Исхак рус, украин, белорус, үзбәк, казах, төркмән, әзербайҗан, уйгур һ. б. телләрдәге әсәрләрне турыдан-туры оригиналдан эшли. Әлеге сыйфат тәрҗемәченең, әлбәттә, гаҗәеп зур потенциаль мөмкинлекләре турында сөйли. Тәрҗемәләренең кайберләрен ул «шул телдәге үрнәкләре белән китерелгән юлга-юл прозаик тәрҗемә ярдәмендә», беркадәресен «русчага шигъри тәрҗемә аша» үз телебезгә күчерә. Аның үз алдына куйган таләпләре белән танышу да укучыларга кызыклы булыр дип уйлыйбыз. Тәрҗемәләр китабының керешендә Ә. Исхак болай дип яза: «Тәрҗемә иткәндә мин тәрҗемә итүнең төп принцибын — бернинди ireклелеккә бирелмәү, авторның төп фикерен һәм кичерешләрен укучыга төгәл ирештерү, оригиналның ритмик төзелешенә туры килә торган үлчәмне табып куллану, язылышының һәркем аңларлык дәрәҗәдәге гадилеген һәм милли колоритын саклау, үзлегеңнән бер генә сүз һәм бер генә образ да өстәмәү яки төшереп калдырмау, шул ук вакытта, тәрҗемә итүченең үз телендә язылган оригинал әсәр кебек яңгыравына ирешергә омтылу принцибын үтәүгә бөтен көч һәм сәләтемне куярга тырыштым».

Әлеге өземтәдә бүгенге көн тәрҗемәләре алдына куелган нигез таләпләр бик тулы чагылыш таба. Ә теоретик әзерлекле булу, максат ачыклыгы исә, белгәнебезчә — ярты уңыш диган сүз. Хәер, Ә. Исхак практик яктан да үзенең бу таләпләре алдында бурычлы булып калмый. «Яхшы», «начар» кебек абстракт бәяләр белән канәгатьләнмичә, аның тәрҗемәләре хакында, һичшиксез, алар безнең телдә чын-чынлап яши дияргә мөмкин. Безнеңчә, тәрҗемәче хезмәтенә иң югары бәя әнә шул! Әлеге нәтиҗәнең ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүен үзе күрсен һәм конкрет күзалласын өчен, без биредә укучыга кечкенә бер «сәяхәт» тәкъдим итәр идек.

Китап бөек рус шагыйре А. Пушкинның «Ирекләлек» одасы белән башланып китә һәм аның зур ышаныч белән киләчәккә төбәлгән тавышы, «Кайтаваз» шигырендәге шагыйрь авазыдай җавапсыз югалып калмыйча, әсәрдән-әсәргә ныгый барып, безнең көннәрдә яңгыраш таба:

Без көтәбез изге азатлыкның
Минутларын һаман интегеп,
Ышанычлы кавышу минутларын
Көткән кебек гашыйк яшь егет.
(«Чаадаевка»)

Пушкин шигърияте китапта билгеле бер дәрәҗәдә камертон хезмәтен үти. Аның авазын һәрьяклап баетып, төрләндереп, көчәйтеп, әмма шул ук шигъри дәрт-ялкынын саклаган көе, төрле илнең, төрле заманның башка шагыйрьләре тавыш бирә сыман:

Без чигендек сүзсез генә озак.
Көттек сугыш, әрнү белән тыңлап
Сукрануын картларның:
«Калабызмы торып кышка әллә?
Командирлар безнең кыймый мәллә
Рус штыгы белән теткәләргә
Мундирларын ятларның?»
(М. Лермонтов, «Бородино»)

Безнең алга революцион «сул»га басып, горур рәвештә В. Маяковский килеп чыккандай була:

Коралларымның
иң яраткан төре —
үткен сүзләр кавалериясе —
ыргылырга тора,
югары күтәреп
рифмаларның очлы сөңгесен.
Егерме ел буе
җиңүләрдә җилгән,
Баштанаяк коралланган
гаскәремнең барын

соңгы битенәчә
сиңа бирәм,
планетаның пролетары!
(«Бөтен тавыш белән»)

Китапта рус шагыйрьләрен тугандаш Көнчыгыш халыкларының мәңгелекнең үзе белән тоташкан сабыр һәм хикмәтле шигърияте алмаштыра:

Чигенә життем жиһанның очрашу өмет итеп,
Чапты аерылу кылычы тән аша жанны тетеп.
Бу йөрәк өмет юлында булды бер кәрвансарай,
Күпме хәсрәт кәрваны шуның аша китте үтеп!
(Низами)

Горурлыгың ташытма, мин матур диеп,
Кыйммәтле тире һәм ефәк кием киеп.
Каурый һәм йоны матурлык аркасында
Һәлак булды ауда күпме кош һәм киек!
(Нәваи)

Күз алдыбызда гына Ерак Көнчыгыштан кытай, япон халыкларының чык бөртегедәй саф һәм садә лирик шигърияте ялтырап китә:

Жил тындымы — дулкын тынып кала,
Жил истеме — дулкын кузгала.
Бик күптәнге дуслар,
Димәк, алар,
Тиз аңлашкач шулай үзара!
(Ки-Но Цураюки)

Әмма шунысын да искәртик, китаптагы йөзләгән шагыйрьләрнең талант көче һәм бөтен язган әсәрләре бертигез була алмаган кебек, тәрҗемәченең осталыгы да, һичшиксез, һәр урында да бар тулылыгы белән ачылып китәргә мөмкин түгел. Димәк, бирегә аның уңышлары белән бергә, күпмедер дәрәҗәдә кылган кайбер «гөнаһлары» турында да берничә сүз әйтеп үтәргә тиеш булабыз. Тәрҗемәче ул, кем әйтмешли, сират күперен кичкәндәй, нечкә кыл өстеннән уза. Авторны һәм аның әсәрләрен сайлап алуы белән дә, оригиналның, бөтен нечкәлекләрен саклаган хәлдә, икенче бер телдә адекват яңгырашын табуда һәм аңа җан бирүдә дә укучысы алдында иң элек ул җавап бирә. Шуларның берсеннән аз гына читкә тайпылдыңмы — бердәнбер дөрес юлыңны, шушы диалектик берлек гармониясен югалттың дигән сүз. Ә. Исхак тәрҗемәләрендә дә, әлбәттә, кайбер андый тайпылышлар үзен бер дә сиздерми калмый. Шуларның беренчесе итеп без тәрҗемәнең кайвакытларда татарча табигый агышын югалтып куюын күрсәтер идек. Ә. Исхак кебек логик төгәллек һәм ачыклык белән тасвир итә торган шагыйрь иҗатында бу аеруча тиз сизелә булса кирәк. Дөрес, мондый логик чатаклык тууның бирегә үзенә күрә бер «объектив» сәбәбе дә бар — ул, безнеңчә, тәрҗемәченең аралаш рифмалар белән язу омтылышыннан килә.

Исән чакта йөрәк намус өчен
Һәм азатлык теләп янганда,
Күңелләрнең гүзәл омтылышын
Багышлыйк без, дустым, ватанга!
(«Чаадаевка»)

Өченче һәм дүртенче юллардагы «омтылышын» һәм «ватанга» сүзләренә рифма яраклаштыра торгач, күренә ки, беренче һәм икенче юлларның логик яктан икесе ике эзгә төшеп, үзара «тарткалаша» башлауларына китергән. Шулай итеп, рифма табу бирегә логик төгәллеккә зыян китерә, ул, үзмаксатка әверелеп, телнең табигый агышын юкка чыгара. Рифма җөмләгә инверсия ясалу юлы белән барлыкка килгәндә, тасвирны кабул итү аеруча авырлаша:

Фөзули, Толстой, Данте, Шекспир
Дөньяга мәхәббәт белән күз салды.
Миллионнарга алар иттеләр тәэсир,
Алардан күңелдә гүзәл эз калды.
(Сәетзадә, «Атом гасыры»)

Китапта шулай ук бүгенге татар укучысына бик үк аңлашылып җитмәгән борынгы алынма сүзләрнең («И Нәваи, бу җиһанда тәмгысыз беркем дә юк. Тапсаң андый бер кеше, булсын аңарга зур шәрәф»), я булмаса «ә хатыным юа кер генә шыр ялангач балалар өчен» (60 бит) кебек башка логик чатаклыкларның, ә кайвакыт уңышсыз ясалма образларның очраштыргалавын да әйтеп китмичә булмый:

Өрекмә син һәм атылма бер дә,
Тукта, кошкай, юкка куркасың!
Кошчыгыңны җылытыйм күкрәгемдә,
Җырларымның чишеп якасын!
(Чиковани, «Карлыгач оясы»)

Әмма ассызыклап әйтәбез, әлеге кайбер җитешсезлекләр очраклы-хосусый характерга ия. Димәк, аларга җентекләп тукталып торуның биредә хаҗәте күренми. Әлеге китапка, һичшиксез, югарырак ноктадан, аның татар әдәбиятына алып килгән шигъри яңалыгы, шигъри нечкәлеге аспектыннан чыгып карау һәм фикер йөртү урынлырак булыр иде. Ә инде әдәбиятыбызны шигъри баетуга килгәндә, ул чыннан да мактаулы зур эш башкара.

Шигъри сәяхәтебезне дәвам итик. Безне үзенең кешелеклелеге һәм хыялый шаянлыгы белән Н. Некрасовның Мазай карты каршы ала. Ул безгә авылларының шәп аучылары турында чираттагы мәзәген сөйләргә керешә:

Кузя ваткан мылтыгының чакмасын,
Алып йөри тулы шырпы тартмасын.
Көртлек кәтеп, куаклыкта ята ул
Һәм тишеккә шырпы кабызып ата ул.
(«Мазай бабай һәм куяннар»)

Ул да түгел, җылы лирик агымга килеп керәбез. Лирик кичерешләрне хикмәтле шигърият үрнәкләре алыштыра:

Яу күрсәтер батырлыгын егетнең,
Аерылышу — тугрылыгын хатынның.
Тапталмаган тау сукмагы күрсәтер
Осталыгын, кыюлыгын атлының.
Еллар бирер хезмәтеңә чын бәя,
Бәла әйтер кем икәнен чын дусның.
Төзәлмәслек чир күрсәтер дөньяда
Нинди матур икәнлеген тормышның.
(Иосыф Хаппалаев, «Сынау»)

Жанр һәм стиль төрлелеген генә түгел, китап әдәбиятыбызга кабатланмас геройлар һәм аларның үзенчәлекле психологиясен ачу ягыннан да кызыклы табышларын тәкъдим итә. Ул геройлар фаҗиганең күзенә карап көлә беләләр:

Чегән кызы тотты кулым
Һәм әйтте шул чагында:
«Үтәр, диде, җиде елың
Хәсрәт белән кайгыда».
«Җиде ел күп түгел кебек.
Аннан ни булыр миңа?»
«Ә аннан соң, чибәр егет,
Күнегерсең кайгыңа!»
(Иван Франко)

Иң әһәмиятлесе шунда: китапка кергән бөтен шигырьләр дә кешелекнең, мәхәббәтнең, тормышның салкын шыксыз үлемнән өстенлеген ачып сала. Әлеге зур гуманизм тойгысы җыентыкның буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла. Бу уңайдан М. Горькийның «Кыз һәм Үлем» әкияте аеруча истә кала. Хәер, моңа гаҗәпләнерлек урын да юк — геройларның мондый көчле романтик кичерешләр ташкынында хәр тормышка омтылуы, буяуларның тасвир тукымасына Горькийга хас кыю, мул һәм тәэсирле итеп салынуы, шигъри деталь-образларның төгәллеге һәм ачыклыгы безнең тыйнак әдәбиятыбызда бик еш кунак түгел. Китаптагы тәрҗемәләр кешелек дөньясының күп тавышка җырланган яңа, югары идеяләрен, поэтик көчен чагылдыралар һәм, табигый ки, бер үк вакытта алар тәрҗемәченең дә гражданин, көрәшче, шагыйрь буларак шигъри йөрәк авазын ишеттерәләр.

Әмма шушы урында куңелдә туган тагын бер теләкне дә белдереп үтәсе килә: җыентыкка шагыйрьләрнең саллыракларын гына сайлап тәкъдим итү уңышлырак булмас идеме икән?! Саннары азрак булса, иҗатларына да урын күбрәк бирелер иде бит. Берике шигырьдә генә авторның шигъри йөзен күреп алуы авыр. Димәк, бу очракта билгеле бер чуарлык кына барлыкка килмиме? Дөрес, җыентык болай шигъри букет сыман кабул ителә. Әмма бәйләмгә дә бит барлык чәчәкләр куелмый. Аларның төре азрак булган саен, букет төзүченең зәвыгы да, чәчәкләрнең хуш исе дә ачыграк сизеләнә түгелме соң? Бәлки бу тәрҗемәләрне берничә китапка бүлеп (әйтик, Көнчыгыш шагыйрьләре, рус шагыйрьләре һ. б.) чыгару кирәк булгандыр. Һич югы, киләчәктә тәрҗемәченең бигрәк тә Көнчыгыш тугандаш төрки халыклар иҗатына күбрәк игътибар итүен теләргә кирәктер. Безнеңчә, Ә. Исхак монда үзен иркенрәк тә сизә, һәм кардәш халыклар шигъриятен русча тәрҗемәләре аша күзалларга тырышкан яшь буын укучылары өчен дә моның әһәмияте аеруча зур. Низами, Хәйям, Нәваи, Мәхтүмколый һ. б. бөек төрки шагыйрьләрнең китапларын үз телебездә әзерләп бастыру күптән кирәк югыйсә.

Инде без билгеле бер дәрәҗәдә үзебезнең өченче сорауга — «Ник тәрҗемә иткән?» дигән сорауга да җавап биреп киттек бугай. Димәк, тәрҗемәче үзенең укучыларын яңа шагыйрьләр, яңа шигъри ачышлар белән таныштыра. Шуның белән ул милли әдәбиятка үзенчәлекле яңа әдәби агымнар китереп кертә, аны яңа иҗади мөмкинлекләр белән баета. Кешелекнең классик шагыйрьләрен шундый тиз арада туган телеңдә сөйләштерә башлау үзе зур бер бәйрем түгелмени!

Әмма тәрҗемә сәнгатенең тагын бер җитди хасияте бар — ул әдипләргә (шул исәптән укучыга да) зур поэтик иҗат мәктәбе булып тора. Чыннан да, укучыны таныштыру өчен генә бүгенге көндә Пушкин, Лермонтов, шул ук Горький, Маяковский әсәрләрен татар укучысына зурдан кубып тәрҗемә итеп тору үзен аклар идеме икән?.. Бит бүгенге татар укучысы аларны оригиналларында укып та бик яхшы төшенә. Хәер, без, нигездә, шулай уйлап эш итәбез дә бугай инде. Һәм бик нык ялгышабыз. Бу уңайдан минем укучының игътибарын бер гыйбрәтле фактка юнәлтәсем килә.

Болгариядә, әйтик, соңгы илле ел эчендә А. Пушкинның «Евгений Онегин» романы унике (!) тапкыр тәрҗемә ителеп чыга. Григор Ленков эшләгән соңгы вариант исә, тәнкыйтьчеләрнең бердәм фикере буенча, Болгария культура тормышында бер вакыйга булып таныла. Әлеге тәрҗемәче уңышның серен үзенә кадәр бу өлкәдә эшләгән әлгәреләрнең тәҗрибәсенә таянуында күрә...

Гыйбрәт эзләп ерак китмичә, үзебезнең Тукай, Әмирханнарыбызны гына искә төшерү дә җитә. Тукайның шигъри теле халык теле, халык шигърияте белән ачылган кебек үк, аның шигъри иҗаты, Пушкин, Лермонтовлар шигърияте белән дә күпмедер азыкланып, яшәеш тапкан түгелме соң?

Совет шагыйрьләреннән М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, С. Баттал, Н. Арсланов, З. Нури, шулай ук Ә. Исхак үзе дә бу эштә күп көч куйды. Әмма бүгенге буын шагыйрьләрен тәрҗемәдә алай актив димәс идек. Пушкин, Лермонтовларның соңгы тәрҗемә китаплары чыкканга да утыз елдан ашып китте.

Әлбәттә, безнең буын шагыйрьләре күп укыйлар, белемлеләр. Әмма укып оныту бер хәл, иҗат газабы аша каныңа сеңдереп тапкан хакыйкать — бөтенләй икенче. Бүгенге поэзиябезнең иң зур кимчелеге — бик күп шагыйрьләребезнең шәхес булып ачылып җитмәвенең бер сәбәбе дә шуңа бәйле түгелме икән?! Тәрҗемә ул шигъри фикерләү генә дә түгел, ул дөньякүләм процесска бербөтен булып кушылу һәм шулай ук шәхес буларак үсү дигән сүз. Бүгенге көндә яшь шагыйрьләребезнең борынгы кытай, грек, рим шагыйрьләрен, Шекспир, Гете кебек дөнья классикларын ярыша-ярыша тәрҗемә итүләрен хыялый рәвештә күз алдына китергәч... елмаеп куясың. Кызганыч елмаю, әлбәттә. Кыскасы, яшь буын шагыйрьләре үз укучыларын дөнья шигърияте белән бәйләнештә тотуда халык һәм поэзия алдында, үткән буыннар һәм киләчәк алдында, ниһаять, Заман алдында нык бурычлылар әле.

Өлкән әдипнең әлеге китабы тәрҗемәләр турында, бүгенге поэзия турында әнә шундый уйлар, борчылулар кузгатуы белән дә зур әһәмияткә ия. Яшьләр алдында ул фидакарьлекнең матур бер үрнәге булып тора. Шигъри тәрҗемәләргә нокта куярга иртә. Шигъри дәрт, шигъри бәйге дәвам ителергә тиеш. Шигърият чишмәләрен саектырырга безнең хакыбыз юк!

Равил КУКУШКИН.

# ФАТИХ ӘМИРХАН ХАТЫ

Түбәндәге хат әдип Фатих Әмирхан тарафыннан әниемә язылган. Аңа кыскача аңлатма биреп китүне кирәк саныйм.

1907 елның җәендә минем әнием, Зәйтүнә Мәүлүдова, үзенең әнисе һәм апасы белән Чистайдан Казанга күчеп килә. Әлбәттә, алар зур шәһәрдә озак яши алмыйлар. Казандагы кыйммәтчелек, тормыш авырлыгы аларны тагы Чистайга куып кайтара. Ләкин шул бер ел вакыт әниемнең гомерендә мәңге истә калырлык һәм аның тормышына көчле йогынты ясарлык дәвер булып кала. Хикмәт шунда, әнием шигырьләрен ифрат яраткан шагыйре Габдулла Тукай белән таныша, һәм бу эштә аңа әдип Ф. Әмирхан ярдәм итә. «Әльислах» газетасының фактик редакторы Ф. Әмирхан әниләргә күптән мәгълүм кеше була, алай гына да түгел, ул чыбык очы туган да, Чистайда яшәүче абзасы Нәҗип әниләргә җизни тиешле кеше, әниемнең туганнан туган апасы Камиләнең ире.

Кыскасы, Казанда әнием һәм аның апасы Бәдриҗиһан «Әльислах» редакциясендә еш булып, андагы язучылар белән аралаша башлыйлар, үз кеше булып китәләр.

Тукайның әниемә булган чиксез мәхәббәте, Әмирханның хөрмәте араларны көннән-көн кыскарта, мөнәсәбәтләр самими дуслыкка әйләнә. Бу хат исә шуның бер билгесе. Әйтергә кирәк, әниемә әдиптән килгән хатлар бер генә булмагандыр. Әниләр үнөченче елны Троицкига күчеп киткәч тә, әнием Казан белән араны өзмәгәндер. Хәлбуки сакланган хат шушы гына. Хатта искә алынган Ибраһим — Ф. Әмирханның туган энесе.

*Атилла Расих.*

* * *

Зәйтүнәкәй,

Сиңа сәламнәрем!

Бүген генә синең Троескидан язган хатыңны алдым. Искә төшерүең өчен рәхмәт.

Мин әле өченче көн генә сәфәремнән кайттым, аякланып кайтмадым кайтуын, шулай да бераз файдаландым шикелле.

Синең кәеф ничек? Тереләмсең? Син инде анда уку-укыту белән азапланмыйча, тәмам терелеп җитәргә тырыш. Дөньяда торырга теләгән кеше өчен сәламәтлек уку-укытуларның һәммәсеннән алда тора бит, гөлкәем.

Мин сиңа бер хат язарга уйлап тора идем дә, адресыңны белми идем. Син үзең хат яздың, анда да адресыңны язмагансың. Менә бу хатны инде мин тәхмини адрес белән, бәлки житешер дип кенә язып салам.

Троескине син бик яратып язгансың. Ул «кыргыз» шәһәренең кай җире сиңа бик ошады? берәр кыргыз егетенә влюбиться итмәдеңме син?

«Ибраһим абзый Казандамы, нишли?» — дип сорагансың. Ул Казанда. Әле бер мөгаен эшкә керешкәне юк, бәлки шушы көннәрдә керешер. Кызлар артыннан чаба, ухаживать итә.

Троескидән син кайчан кайтырга уйлыйсың? Киләсе язгадыр бит? Мин сине инде сагына башладым, бик мәхәббәтле кызый бит син.

Нишләп торганыңны, сәламәтлегеңне, нинди хисләр белән гомер иткәнеңне бик тәфсилләп язып миңа бер хат җибәр, ярыймы?

23 үктәбер 1913 сәнә. Фатих Әмирхан.

Сәвия Михайлова

# ХАЛЫК МӘГАРИФЕН ӘЙДӘҮЧЕ

«Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур». Бөек Тукай Казан каласына әнә шулай мәдхия җырлады, аның халык мәгарифе өлкәсендә тоткан урынын әнә шулай бәяләде. Мәгърифәт-культура учакларыннан Казанның ак колонналы университеты аеруча зур әһәмияткә ия. Аның аудиторияләре һәм лабораторияләре, Октябрь революциясенә кадәр үк, дөнья күләмендәге мөһим ачышларга шаһит булдылар. Дөнья фәненең Н. И. Лобачевский, А. М. Бутлеров, М. Н. Зинин һ. б. даһилары Казан университетында эшләде. Университет Л. Н. Толстой, С. Т. Аксаков, П. И. Мельников-Печерский, В. В. Берви-Флеровский, М. А. Балакирев кебек шәкертләре белән хаклы рәвештә горурлана. Күренекле педагог, демократ, В. И. Ленинның әтисе И. Н. Ульянов та Казан университетында белем ала.

Татар халкының бөек уллары И. Хәлфин, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри һ. б. бик күп шәхесләрнең эшчәнлеге дә университет белән тыгыз бәйләнгән.

Бөтендөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы, коммунистлар партиясенә һәм Совет дәүләтенә нигез салучы В. И. Ленинның университетта укыганда революцион көрәш юлына басуы безнең өчен аеруча якын һәм кадерле.

В. И. Ленинның университетларга зур әһәмият бирүе — тарихта билгеле факт. Октябрь революциясенә кадәр үк ул университетлар эшчәнлеген нәтиҗәле милли тормыш белән яшәүнең мөһим күрсәткече дип бәяләгән һәм аларны «...политик ризасызлык...» үзәкләренең берсе дип санаган.

Патша Россиясендә 12 университет булган. Идел буе һәм Урал ягының экономик, политик, культура һәм административ тормышының борынгы үзәге булган Казанда университет 1804 елның 5 ноябрендә ачыла. Патша хөкүмәте Казан университетын, беренче чиратта, дәүләт аппараты өчен чиновниклар, укытучылар, врачлар һ. б. белгечләр хәзерләү максатыннан чыгып оештыра. Шуның өстенә университетка нигез салучылар аны күп милләтле Идел-Урал төбәген христианлаштыру үзәгенә әйләндерергә һәм хөкүмәт алып барган колонизаторлык политикасының таянычы итәргә дә уйлыйлар. Ләкин бу ниятләр тормышка ашмый кала: университет христианлаштыру үзәгенә дә, колонизация терәгенә дә әверелми. Киресенчә, ул уку-укыту һәм фәнни үзәк булып үсеп китә, Россиянең иҗтимагый-политик һәм революцион хәрәкәт тарихында зур роль уйный.

Идел-Урал, Кавказ, Казахстан һәм Себердә халык мәгарифенең формалашуы һәм үсеше аерылгысыз рәвештә Казан университеты белән бәйләнгән. Университетның озак еллар буе күп милләтле Казан төбәгенә мәгърифәт нуры таратуы фәнни әдәбиятта шактый тулы яктыртылган. Шуңа күрә биредә әлегә кадәр матбугатта чагыштырмача аз яктыртылган мәсьәлә — Казан университетының Себердә төрле уку йортлары оештырудагы һәм алар өчен укытучылар хәзерләүдәге эшчәнлеге турында сөйләрбез.

XIX йөзнең сиксәненче елларына кадәр Себер Казан уку-укыту округына кергән. Гаять зур мәйданны билгәгән бу округта, Казан университеты ачылган вакытта, барысы 45 халык училищесы булып, анда нибарысы 2 304 кеше укыган һәм 95 укытучы эшләгән. Бу уку йортлары аерым кешеләрнең матди ярдәменә мохтаҗ була; анда бердәм укыту программалары булмаган, аларга методик ярдәм күрсәтелмәгән, шуның өстенә укытучыларның күбесе руханилар катлавыннан чыккан була.

1804 елгы Мәктәп уставы Россия күләмендә мәктәпләрнең дәүләт системасына нигез сала. Казан уку-укыту округындагы мәктәпләр эшенә җитәкчелек итү өчен, университетның иң күренекле галимнәреннән махсус комитет төзелә. Н. И. Лобачевский ректорлык иткән вакытларда аның составына И. М. Симонов, П. С. Кондырев һ. б. алдынгы карашлы галимнәр кергән. 1811 елда Казан уку-укыту округындагы мәктәпләрнең саны 45 тән 61 гә җитә. Җиде халык училищесы гимназия итеп үзгәртелә. Ул вакытларда бөтен уку-укыту округына бердәнбер булган Казан гимназиясенә Иркутскида (1805), Әстерханда (1806), Нижний Новгородта (1808), Сембердә (1809), Тобольскида (1810), шулай ук Пензада (1804), Пермьдә (1808), Вяткада (1811) ачылган гимназияләр килеп кушыла. Университет җи-

тәкчелегендә, кагыйдә буларак, җаны-тәне белән фәнгә һәм халыкка бирелгән алдынгы карашлы шәхесләр торган. Университет тарафыннан оештырылган төрле өяз, халык училищеларының яшәвен патша хөкүмәте белемгә омтылган халык массаларының басымы астында гына санкцияләргә мәҗбүр була. Яңа ачылган төрле уку йортларын рәсми рәвештә тану — царизмның халык массаларын тоташ наданлыкта тотып булмавын аңлавыннан һәм илнең социаль-экономик үсеше ихтыяҗларына бәйле рәвештә килеп туган хәл ул. Әлбәттә, царизм халык мәгарифе өлкәсендә төрле киртәләр кую өчен мөмкин булганның барысын да эшләргә тырышты. Хөкүмәт халык өчен ачылган уку йортларына материаль ярдәмне аз яки бөтенләй күрсәтми иде; уку-укытуның сословиеле характерын саклауга һәм ныгытуга бөтен көчен куйды. Ләкин бу чаралар гына гомум тарихи үсешкә киртә булып тора алмыйлар.

Университет халык өчен ачылган мәктәпләрнең материаль базасын ныгыту өчен иганә — акчалата ярдәм итүне оештыра. Ярдәм итүчеләр арасында төрле социаль катлау кешеләрен — крестьяннарны, сәүдәгәрләрне, мещаннар һәм дворяннарның алдынгы катлавыннан чыккан кешеләрне күрергә була. Дворяннардан җыелган акча асылда аларның үз балалары укый торган гимназияләр, пансионнар файдасына тотыла. 1825 елда Казан уку-укыту округында инде 10 гимназия, 2 баш халык училищесы, 78 өяз училищесы, 2 кече халык училищесы була, укучыларның саны 6621 гә, ә укытучыларның 419 га җитә.

Н. И. Лобачевский университет ректоры һәм күренекле галим булгач та, мәктәпләрдә еш була, яңа мәктәп биналарын салу һәм ремонтлау белән танышу өчен урыннарга чыгып йөри. Профессор П. С. Кондырев та Казан губернасындагы һәрбер халык училищесында була, ә Е. П. Манассеин халык мәгарифен юлга салу өчен Кавказ губернасына җибәрелә, һәм ул анда яңа ачылачак мәктәпләр файдасына 60 мең сум күләмендә иганә җыюны оештыра. Шундый ук максатлар белән профессор И. Ф. Яковкин Пенза губернасына, ә И. И. Запольский Оренбург губернасына җибәрелә.

Билгеле булганча, Казан университеты галимнәре һәм студентларының халык мәгарифе өлкәсендәге хезмәтләре Идел-Кама төбәге белән генә чикләнми. Иделдән алып Ерак Көнчыгышка кадәр сузылган уку-укыту округының үзәге булган Казан университеты мәгърифәт нурларын Себер киңлекләренә дә мул сибә. Мәктәпләрнең азлыгы, укытучы кадрларга кытлык, укучыларның, бигрәк тә рус булмаган халык вәкилләренең азлыгы — XVIII гасырдан Казан уку-укыту округына Себер җирендә энә шулар мирас булып калган.

Элементар грамоталылык ягыннан карaганда, Себердәге татарлар һәм казахлар арасында мәгариф эше башка рус булмаган халыклар белән чагыштырганда яхшырак куелган була. Ләкин аларның бөтен укулары асылда ислам дине нигезләрен өйрәнүгә кайтып калган.

Казан университетының Себердәге мәктәпләр белән җитәкчелек итүе М. В. Ломоносовның талантлы шәкерте С. Я. Румовский Казан уку-укыту округы попечителе булып торган вакытларда башланган. 1805 елда ук ул империядәге училищеларның Баш идарәсеннән Иркутск гимназиясендә якут мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләргә рөхсәт ала. Шулай итеп, беренче якут мәктәпләре рус җәмгыятенең алдынгы карашлы вәкилләре тырышлыгы нәтиҗәсендә ачыла. Мондый мәктәпләргә, гомумән алганда, XIX йөзнең икенче яртысында нигез салынган. Шул чордагы бер укытучының язуына караганда, «якутларның белемгә омтылышы бик көчле була». Бу мәктәпләр тулысынча халык хисабына яшәп килгән, аларның тулай торaклары һәм якут телендә юньле дәреслекләр дә булмаган, шуның өстенә староста, писарь, старшина кебек «җәмәгать хадимнәре»нең башбаштаклыгын да татырга туры килгән ул уку йортларына.

Казан университеты Себердә ачылган гимназияләрдәге, өяз мәктәпләрендәге уку-укыту эше белән турыдан-туры җитәкчелек итә. Шул максатлардан чыгып, профессор Эрдман, адъюнкт Ренардо гимназияләргә эшкә җибәрелә. Университет профессоры А. Н. Аргольд Тобольск гимназиясе, ә аннан соң Тобольск училищелары идарәсе директоры итеп билгеләнә.

Халык мәгарифе каһарманы П. А. Словцовның эшчәнлеге дә Казан университеты белән тыгыз бәйләнгән. Иркутск училищелары директоры булып эшләгәндә ул Казан университеты Советы аша гимназиядә музыка, ә 1817 елда рус хокук белеме предметы кертүгә ирешә. Университет Словцовка Казаннан алып Томскига кадәр булган җирләрдәге уку йортларына күзәтчелек итү эшен йөкли, соңыннан ул укыту округына кергән бөтен уку йортларының күзәтчесе була. Словцов Себергә руслар килгәнче үк мондагы җирле халыкларның бай тарихы булганлыгын икърар итә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Себер халыкларын ул, патша чиновниклары кебек «инородец»лар дип түгел, ә «гражданнар» дип атый.

Казан университеты Себер өчен кадрлар хәзерләү үзәге булды. Шул ук вакытта төрле профессия кадрларына чиктән тыш кытлык университетта хуҗалык һәм административ эшчәнлек өчен кадрларны Себернең үзендә дә хәзерләү идеясен китереп чыгара. Шул максаттан чыгып университет Югары Себер училищесы ачу турында карар кабул итә. Проект буенча бу уку йортында төрле социаль катлаулардан чыккан яшьләр укырга тиеш була. Булачак училищеның программасына көнчыгыш тел-

ләрен өйрәнүне кертү дә күздә тотыла. Ләкин патша хөкүмәте бу проектны расламый. Шулай итеп Казан университетының халык мәгарифе өлкәсендәге тагын бер гүзәл башлангычы тормышка ашмый кала.

Төрле профессия кадрларына чиктән тыш кытлык 1835—1842 елларда хөкүмәтне Казан университетында укучы Себер яшьләре өчен махсус стипендияләр булдырырга мәҗбүр итә. Шундый стипендиягә белем алып чыгучылар Себердә иң кимендә ун ел эшләргә тиеш булалар. Ләкин билгеләнгән стипендия студентларга көнне-көнгә ялгарга да җитми. Әмма хөкүмәт университетның стипендияне арттыру турындагы тәкъдимнәрен һәрвакыт кире кагып килгән.

Себер стипендиатлары Россиянең башка университетларында да укыган, шулай да аларның зур күпчелеге Казан университетында белем алган. Россиядә, беренче революцион ситуация алдыннан һәм ситуация елларында, андый стипендиатларның саны илдәге университетлар арасында түбәндәгечә була:

Социаль яктан караганда, Себер стипендиатлары төрле катлаулардан чыккан яшьләрне тәшкил итә. Е. П. Манассеин язуынча, университет белеме алу өчен ул яшьләрнең кайберләре хәтта Себердән Казанга кадәр җәяү килгәннәр.

1875 елда Казан, Мәскәү һәм Петербургтагы югары уку йортларында Себердән килгән 289 студент белем алган. Бу вакытта Себердә барысы 5 гимназия, 3 реаль училище һәм 4 дини семинария эшләгән.

Казан университетының бәрәкәтле йогынтысы һәм ярдәме белән Себердә барлыкка килгән мәктәпләр тора-бара үзләре дә мәгърифәт учакларына әвереләләр. Шундыйларга мисал итеп Троицко-Савск крепостенда оештырылган мәктәпне күрсәтергә мөмкин. Галсан Никитуев кебек талантлы укытучылар эшләгән бу мәктәптә рус һәм бурят балалары белем алган. Университетта көнчыгыш телләрен өйрәнергә теләгән бер төркем укучыларын Галсан Никитуев Казанга кадәр озата бара. Аларның берсе — Доржи Банзаров — соңыннан көнчыгышны өйрәнүче күренекле галим булып җитешә. Күренекле галимнәр Н. И. Лоба-

| Университетлар | 1855 | 1856 | 1857 | 1858 | 1859 | 1860 | 1861 | Барысы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәскәү | 4 | 1 | 1 | 4 | - | 2 | 4 | 16 |
| Санкт-Петербург | 2 | 1 | 1 | 4 | 3 | 3 | 6 | 20 |
| Казан | 6 | 6 | 8 | 12 | 6 | 17 | 22 | 77 |
| Барысы | 12 | 8 | 10 | 20 | 9 | 22 | 32 | 113 |
| Күрсәтелгән елларда университетларга кергән кешеләр саны | 13 | 11 | 12 | 21 | 14 | 26 | 35 | 132 |

*Таблица СССР Үзәк дәүләт тарих архивы (733 ф.), Ленинград өлкәсе тарих архивы (14 ф.) һәм ТАССР Үзәк дәүләт архивы (977 ф.) материалларына нигезләнеп төзелде.*

чевский, И. М. Симонов, Д. И. Мейер, П. И. Котельников һ. б. Доржи Банзаровны казак сословиесеннән чыгаруда зур тырышлык күрсәтәләр.

Себердән чыккан күренекле тарихчы галим, узган гасырның 60—70 елларындагы иҗтимагый хәрәкәтнең актив эшлеклесе, азатлык җырчысы А. П. Щаповның да исеме Казан университеты белән тыгыз бәйләнгән. Аның идея ягыннан формалашуы һәм тормышының иң давыллы чоры Казанда үтә.

Казан университеты күп кенә Себер яшьләре өчен иҗтимагый эшчәнлеккә, революцион көрәш юлына аяк баскан урын. Томск гимназиясен тәмамлаган А. Курбаковский 1861 елда университетка укырга керә. Бөтенроссия күләмендәге революцион оешма — «Земля и воля»ның члены була һәм 1863 елларда тарихта «Казан заговоры» дип аталган күренекле вакыйгада актив катнаша. 1860 елда Иркутск семинариясен тәмамлаган И. Орлов, Тобольск гимназиясеннән Н. Копиченко һәм А. Балакшин, И. Иконников, А. Иваницкий, С. Сретенский, Ф. Некрасов һ. б. Себер яшьләре нәкъ менә Казан университетында укыганда революцион көрәш юлына басалар, шунда беренче чыныгу алалар.

Себернең табигатен, бигрәк тә анда яшәүче төрле халыкларның тарихын, культурасын, телләрен өйрәнүгә дә Казан университеты галимнәре зур өлеш кертәләр. Рус география җәмгыятенең Себер бүлеге белән берлектә университет Себерне өйрәнү буенча фәнни экспедицияләр оештыруда актив катнаша. Бу өлкәдә Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте зур тырышлык күрсәтә.

Казан университеты Себердә ачылган беренче югары уку йорты — Томск университеты өчен дә кадрлар хәзерләүнең төп үзәге була. Томск университеты ачылгач, Казан университеты галимнәренең бер өлеше яңа вузга эшкә күчә.

Томск университеты ачылган вакытта биш миллион халкы булган Себердә барысы 1440 мәктәп булып, анда 49118 укучы белем алган.

Йомгаклап әйткәндә, Себердә халык мәгарифен, алдынгы иҗтимагый фикерне тудыруда һәм үстерүдә, җирле халыкларны гомумроссия азатлык хәрәкәтенә тартуда Казан университеты зур роль уйный. Ләкин Себер халыкларына фән һәм культураның, мәгарифнең югары баскычларына ирешү бары тик Бөек Октябрь революциясеннән соң гына мөмкин булды.

*Аек бул — заманга лаек бул!*

**Рэисэ Ишморатова**

# КИЧКЕ ҖИДЕДӘН СОҢ

БЕР ПӘРДӘЛЕК ПЬЕСА

**КАТНАШАЛАР:**

М ә ү л и я — М о с т а ф а
Х а т и м ә — В ә л и
Р ә г ы й д ә — Д ә ү л ә т ш а

**Сәхнә икегә бүленгән. Берсе аш-су бүлмәсе. Икенчесе түр як. Бер як стена кырыенда карават, ул чаршау белән капланган.**

**Пәрдә ачылганда, тәрәзә буендагы өстәл янында Мостафа утыра. Аның алдында банка белән самогон тора. Ул кызмача. Мәүлия ике бүлмә арасында кызу-кызу нидер эшләп йөри.**

М о с т а ф а *(җырлый)*:

Талы, талы, талы бөгелеп тора...
Ачма тәрәзәңне мин килмичә...
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора... Эх!

М ә ү л и я. Җырласаң адәм рәтле җырла. Берсенең башын, икенчесенең азагын... Тавышың да моңлы гына сыман.

М о с т а ф а *(үз-үзенә)*. Тормышы да аның шундый, бер алды, биш арты. Уф!.. Тавышны ярыйсы дисеңме, Мәүлияттәй?

М ә ү л и я. Рәтләп җырламыйсың бит, бәлки ярыйсыдыр да.

М о с т а ф а. Да!.. Минем тавыш заманында ярыйсы гына түгел, отлично иде. Яшь чакта безнең авылның егетләре-кызлары миннән башка бер концерт та куймыйлар иде. Әллә ничә мәртәбә Казанның үзенә барып җырладык без заманында.

М ә ү л и я *(кызу гына килеп, Мостафа янындагы тәрәзәнең пәрдәсен төшерә)*. Я, җырла, җырла, минем теге якта эшләрем барые.

М о с т а ф а. Бәлки Хәтимә килгәч җырлармын.

М ә ү л и я. Ул килгәч, башкачарак җырларбыз.

М о с т а ф а. Ничек инде ул, башкачарак?

М ә ү л и я. Барсын да алдан белеп утырма әле *(өстәлдәге банканы алып китеп, яңа банка китерә)*. Мә, пирвачын гына эчеп җибәр...

М о с т а ф а *(әз генә эчеп куя)*. Шәп нәрсә бу, каһәр төшкере. Уңган икәнсең, Мәүлияттәй, курыкмый-нитми дим, мәтәштерәсең...

М ә ү л и я. Мин бит үзем өчен генә, синең шикелле яхшы кешеләр өчен генә...

М о с т а ф а. Рәхмәт, рәхмәт. Теге вакытны, беренче килүдә дим... Йортыгыз яныннан узып барабыз, бер яшь кенә егет әйтеп салды бит, әйдәгез, дуслар, кереп чыгыйк әле шушы түти өенә, су эчеп, тамак ялгап ди. Ризалаштык, ерак юлдан кайтып килә идек бит. Ә ул егет монда кергәләгән икән. Күрәм, болдырда чибәрнең дә чибәре, яшь кенә хатын басып тора. Безне күргәч, ялт! Каядыр качты. Больше күренмәде. Син безгә су урынына шушы хикмәтне эчердең... И без киттек! Ә теге — хатынмы, кызмы — һаман күз алдымнан китми бит. Мин тагын килдем, тагын шушы хикмәтле суны эчтем, ә ул, юк, күренмәде...

М ә ү л и я. Һаман күрештерә алмадым шул, ни Мостафа. Менә бүген күрешерсез боерган булса.

М о с т а ф а. Кайда эшли дидең әле син аны, Мәүлияттәй?

М ә ү л и я. Яшелчәдә, яшелчәдә. Хәзер бит үзең беләсең, иң булган хатын-кыз сыер сава. Менә ул да шунда...

М о с т а ф а. Ничек инде, яшелчәдә, сыер сава?

М ә ү л и я. Әй аллам, сорауларың белән уйларымны чуалттың. Яшелчәдә, яшелчәдә... Әй, фермада дигәнем...

---

Үзешчән театр коллективларына тәкъдим ителә. (Редакция).

Мостафа. Я, ярар, анысы ул кадәр важный түгел. Кеше булсын. Ничек әлегә кадәр ирсез яши соң ул?

Мәүлия. Ире булмагач, яши инде.

Мостафа. Кая киткән соң аның ире?

Мәүлия. Кая китсен, үзе янында...

Мостафа *(урыныннан сикереп тора)*. Нәрсә, нәрсә?! Соң атаң башы, Хәтиманең ире булгач, ни нәмәрсәмә дип мине тинтерәтеп йөртәсең. Кавыштырам, имеш! Нәмәрсәмә кирәк миңа ирле хатын? Миңа өйләнергә кирәк, хатын кирәк... *(Кесәсеннән акча чыгарып, өстәлгә бәрә)*. Мә, сасы самогонның өчен, ал! Киттем!

Мәүлия. Әй, буталып беттем синең белән. Минем иремне сорыйсың дип торам. Минем ирем Хәйрулла урамда туңып үлде, мужет ишеткәнсеңдер, безнең авыллар арасы ерак түгел.

Мостафа. Миңа синең ирең кирәкми. Үлгән икән, ничек үлгән, туңганмы, янганмы, анысы аның үз эше *(Самогонны эчеп куя)*.

Мәүлия. Гафу ит инде, Мостафа, әзрәк башым әйләнгәләп китте.

Мостафа. Чөмермә пирвачыңны...

Мәүлия. Мин эчмим. Ә син җырлап утыр. Хәзер килә Хәтимә...

Мостафа. Нәрсә җырлыйм?..

Әнкәй мине тапкачтын да
Ак биләүгә биләгән,
Ак биләүләргә биләгән,
Бәхете булсын димәгән...

Бәхетле булсам, сөйгән хатыным, улым белән мине ташлап, кара күргә кереп ятмас иде. Эх!.. *(Тагын аз гына эчеп куя)*.

Мәүлия. Нигә әле үзеңне бәхетсез дисең син... Тап-таза ир. Чибәр, кесәң тулы акчаң... Мин сиңа менә дигән ирсез хатын табам.

Мостафа. Кирәкми миңа беркем дә, күрсәт, сөйләштер әнә Хәтимә белән... Шуны хәл итим дип, отгул алып, синең яныңа килдем.

Мәүлия. Хәзер, хәзер килеп керер Хәтимә...

Мостафа. Әй, кара әле, Мәүлия түти... Хәтимә килгәч бу сасыны эчеп утырып булмас. Берне булса да затлы аракы табасы иде. Кибетләргә сугылдым. Таныш сатучылар да күренмәде. Синдә юкмы соң?

Мәүлия *(уйланып кала)*. Ак баш бит ул хәзер алтын бәясе. Үзе юк, үзе кыйбат.

Мостафа. Әй, акчасыннан тораммыни инде мин... Мә. *(Акча суза)*.

Мәүлия. Белмим шул. Кичә генә Әлмәт ягыннан апам килгән иде. Берне калдырып китте. Лапас түбәсе яптырасым бар иде, шуңа ике-өч шешә алган идем ди. Хәзер акча алмыйлар, аракы сорыйлар. Бик кыйбатка алган шул.

Мостафа. Бәясеннән тормыйм... Беләсең бит минем кайда эшләгәнне.

Мәүлия. Заготзернода, икмәк кабул итеп торам дисең ич.

Мостафа. Унбиш ел инде, хөкүмәт икмәген кабул итеп, озатып торам мин. Әмма, унбиш елга унбиш тиенлек тә хилафлык кылмадым. Икешәр, кирәк булса өчәр смена эшлим, уч тутырып алам акчаны... Хатыным исән чакта рәхәтләнеп яшәдек. Машина да алдык, курортларга да бардык. Казанга да үз машинабызга гына утырып барып кайта идек. Хатыным исән чакта мин тәмәке тартмадым, әнә ул яшел еланның төсен дә күрмәдем.

Мәүлия. Анысы инде ир кеше эчмим дип мактанса, мәзәк булып китә.

Мостафа. Аракы белән агуланган кешеләрнең тормышлары мәзәк икән ул, Мәүлия апа... Я, ярар, бир яртыңны. Мә унбиш сум...

Мәүлия *(мендәр артыннан аракы алып бирә)*. Тик зинһар, эчеп исерә күрмә. Исерек кеше ишегемнән чыкмасын минем.

Мостафа. Рәхмәт, рәхмәт, курыкма, баш анлык кына эшли. *(Җырлый)*.

Таң атканда уянырмын,
Җилкәңә шәл салырмын, Сәҗидәм...

Мәүлия. Кычкырыбрак җырлый башладың, әкренрәк. Берәрсе ишетсә... Бу заман тычканнар таякка атланып йөри торган заман.

Мостафа. Аңлашылмый. Ничек инде ул, тычканнар таякка атланып йөри?

Мәүлия. Мәгънәсен үзем дә белеп бетермим. Күршебез Әхмәдиша бабай сирәкмирәк булса да, алыш-биреш белән маташырга ярата иде. Шул мәрхүм әйтер иде, сак булырга кирәк, тычканнар таякка атланып йөри торган заман диер иде.

Мостафа. Атланып дисең, тотынып дилеең дөресрәк. Таймас өчен, маңгае белән барып төргелмәсен өчен...

Мәүлия. Әллә бераз ятып торасыңмы, Мостафа... Арыдың.

Мостафа. Әзрәк черем итеп алсам... Зарар булмас. *(Караватка килеп ята)*.

**Мәүлия түр якның утын сүндереп, икенче якка чыгып эш белән мәшгуль. Әкрен генә ишек кагалар. Ишекне ача. Чалбар, килешле куртка кигән яшь кенә кыз — Рәгыйдә керә.**

Мәүлия. Абау! Нишләп мондый караңгыда йөрисең?

Рәгыйдә. Егетем армиядән отпускага кайтып төште. Бөтенләй уйламаганда, көтмәгәндә... Хезмәтеңне әйбәт башкарасың дигәннәр дә унбиш көнгә ял биргәннәр.

Мәүлия. Идрис кайттымы? Әй шатлык, әй бәхет...

Рәгыйдә. Шул бәхетне юарга кирәк, Мәүлия апа. Бер яртыны зинһар табып бир. Кайчакларда синдә нәрсәдер була торган иде бит.

Мәүлия. Нәрсә булсын миндә. Әнә, ике литр чамасы квас бар, ал шуны.

Рәгыйдә. Мәүлия апа җаныем, матурым, миңа квас түгел, акбаш кирәк, яхшылыгыңны онытмам. Мә, акчасыннан тормыйм, менә унике сум акчам...

Мәүлия. Энем Оренбургтан алып кайткан яртым бар да бит... Мал-туар суйганда кирәк булыр дип алган идем ди. Ат бәясе түләдем ди. Әллә унбиш сум диде. Хәзер бит бәһасын түшәмгә кадәр күтәрделәр.

Р ә г ы й д ә. Риза, риза. *(Акча бирә дә, шешәне алып чыгып китә).*

М ә ү л и я *(аны озатып керә).* Әй, яшьлек, кош тоткандай булып йөгерде. Егете бик холыклы, бик булган егет шул. *(Эш белән мәшгуль).*

М о с т а ф а *(теге яктан).* Мәүлияттәй, кая әле, бер чәшкә чәй китер әле. Өең бик тынчу. Әчим дә, китим әле.

М ә ү л и я. Әле йокламыйсыңмыни?

М о с т а ф а. Йоклап булмый шул. *(Мәүлия чәй кертә. Мостафа чәйгә игътибар итми, Мәүлиягә карап тора).* Мәүлия түти, яшең ничәдә синең?

М ә ү л и я. Культурный ирләр хатыннарның яшен сорамый диләр акыллы кешеләр. Нәрсәгә сиңа минем яшем. Әллә өйләнергә уйлыйсыңмы?

М о с т а ф а. Тышкы кыяфәтеңә карап, сиңа өйләнеп тә куярга була... Ә менә нутрең?..

М ә ү л и я. Нәрсә ул нутре?..

М о с т а ф а. Эчең, эчең дигән сүз. Эчең хөрт синең.

М ә ү л и я. Каян белдең минем эчәгеләремнең хөрт икәнен?

М о с т а ф а. Аңламамышка салынма... Нутрең хөрт синең, беләсеңме, нутрең!..

М ә ү л и я. Алай булгач нәмәрсәмә дип, минем янына килеп, самогон таптырасың?

М о с т а ф а. Самогон таптырмыйм. Хатын кирәк миңа! Хәләл җефет. Акыллы иптәш. Якын дус. Фу-у, баш әйләнә... *(Торып утыра).*

М ә ү л и я. Менә монда мамык мендәр өстенә генә башыңны куеп тор әле.

М о с т а ф а. Фу!.. Юк...к! Китәм... *(Аягүрә баса).*

М ә ү л и я. Син исердең, телең бутала. Ят! Урамга чыгуың булыр, милиция тотып алыр. *(Көчләп утырта).*

М о с т а ф а. Бу авылда милиция юк.

М ә ү л и я. Нииндиләре генә әле...

М о с т а ф а. Булса, ни пычагыма дип, синнән самогон кайнаттыралар да, ярты литр аракыны биш бәягә саттыралар?

М ә ү л и я. Әстәгъфирулла! Өтермәгә китәрлек сүзләр сөйлисең. Мин сине үз итеп, актык шикәремне сала-сала шифалы су ясап, синең өчен тырышам. Ә син... Кил, утыр.

М о с т а ф а. Теге кызны әйтәм, чалбары да бар, егете дә бар, аракысы да булды. Ә яшьлеге юк.

М ә ү л и я. Нәрсә такылдыйсың. Унсигезе дә тулмаган кызның нишләп ди яшьлеге булмасын!

М о с т а ф а. Ә мин яшь чакта, малай чакта әтинең ертык чалбарын өстери идем.

М ә ү л и я. Ярар, ярар, сугыш чорындагы яшьлек белән, хәзерге яшьлекне бутама. Яшьләр бәхетле хәзер, укыйлар да, эшлиләр дә, җаннары ни тели шуны эшлиләр. Үзләре табалар, үзләре кабалар. Инде очрашу хөрмәтенә үз акчасына бер яртыны алган икән, сүз итеп сөйләргә дә түгел ир башың белән.

М о с т а ф а. Ә мин сиңа әйтәм, Мәүлияттәй. Мондый гөл кебек кызга аракы сатма, самогон да бирмә. Безгә, тормыштан төшеп бара торганнарга, кайчакларда ярый ул. Кайгы-хәсрәтне басарга. Ә бу гөл кебек кызның, дөньяда әле бик күп юллар узасы бар, бик күп шатлыклар кичерәсе бар. Шундый матур тормышның көннәренә, сәгатьләренә аракы шаукымы кертмәсен. Нигә ул егетен аракы эчереп каршы ала, ә... Аракы эчкәч ике анын егете егет булыр, ә аракы эчкәч ике йөзле, мәгънәсез сүзләр сөйләүче, теләсә кайда йөрүче шалапай булыр. Чыннан да йокы баса мине, йоклыйм әле Мәүлия түти... Хатимәне күрми китмим, китмим булгач, китмим!..

М ә ү л и я. Ят, ят, Мостафа, өстеңдәге киемеңне дә сал. *(Мостафа ятарга җыена).* Менә шулай. Үзеңне мамык юрган белән ябыйм әле. Хәзер Хатимә килә.

М о с т а ф а. Миф ул синең Хәтимәң... Миф!

М ә ү л и я. Нәрсә ул тагын мифе?

М о с т а ф а. Ялган сүз, ялган!

М ә ү л и я. Булыр ялган! Күрерсең, хәзер килеп керер. Тик син аны бу хәлдә каршы алма, бераз айны.

М о с т а ф а. Монысы дөрес сүз. *(Чишенә. Караватка кереп ята.)* Утыңны сүндер. Чыннан да йокы баса. Ну, мендәрең дә мендәрең... Саҗидәм бәгырькәемнең дә мендәрләре мамык иде. Эх, Саҗидә, салдың башкайларымны хәсрәткә. Шулай йөрдемени әлек синең Мостафаң?

М ә ү л и я. Йоклап ал, аннан һәйбәтләп баш төзәтеп алырсың.

М о с т а ф а. Юк, юк!.. Мин баш төзәтерлек пьянчуга түгел. Йокыдан соң баш төзәтүчеләрне, беләсеңме, кем диләр. Алкаш, алкоголиклар диләр. Мин мондый хәлгә калмаган. Насыйп та булмасын. Алкаш дигән хурлыклы исемне ишеткәнче, җир астында череп ятуым яхшырак.

М ә ү л и я. Алкоголиклар алар, төн буе аунап чыгалар да иртән баш төзәтәләр. Ә син йомшак мамык юрган астында рәхәтләнеп йокла, ял ит. Мә, иркәләнеп әз генә тамак чайкап куй.

М о с т а ф а. Юк, юк! Әгәренки бик куе чәй, сөтле чәй булса...

**Ишек шакыйлар.**

М ә ү л и я. Бәй!.. Хәтимә инде бу... *(Үрелеп тәрәзәдән карый).* Бәрәч!.. Моңарга нәрсә калган тагын? Бригадир Вәли.

М о с т а ф а. Теге алкашмы? Кичке җидедән соң, кибет ябылгач килә торган кунакмы?

М ә ү л и я. Булыр сиңа, алкаш... Заманында аунап-аунап эчкән иде шул. Казанда дәваланып кайтты. Хәзер үзе алкашларны тотып йөри.

М о с т а ф а. Фу, черт! Аның белән очрашырга ярамый миңа.

М ә ү л и я. Ярамый-ярамый. Ул үзе һәйбәт кеше. Ә хатыны гайбәт чүлмәге. Сине күрдем дип кайтып әйтсә Вәлие, шул минутта бөтен авылга таратыр. Мәүлия янында Мостафа дияр.

М о с т а ф а. Безобразие. Адәм көлкесенә калуың да бик тиз. Кая качыйм соң?

М ә ү л и я. Әнә караваат башына кереп пос.

М о с т а ф а. Көләсең? Мин посарга әллә берәр жуликмы?

М ә ү л и я. Алай булса караватка менеп ят, өстеңә ястык-мендәрләр өям.

М о с т а ф а. Тончыгып үләргәме? Өең болай да мунча кебек...

М ә ү л и я. Пос дим!

М о с т а ф а. Чәнчелеп беткере. Каярак посыйм?

**Мәүлия аны карават артына төртеп кертә, өстенә әйберләр ташлый. Ишек шакыйлар.**

М ә ү л и я. Хәзер, хәзер өстемә генә киям.

М о с т а ф а. Ну, әләктем... Бер гөнаһсызга бит.

М ә ү л и я. Шым, Мостафа... Хәзер, хәзер ачам *(Ишекне ача. Вәли керә. Шактый исерек.)*

В ә л и. Бик озак, әллә егетләрең бар инде.

М ә ү л и я. Әстәгъфирулла! Төн уртасында нинди егетләр ди ул?

В ә л и. Егетләр төн уртасында гына йөриләр дә инде.

М ә ү л и я. Үзең нишләп төн уртасында бу кыяфәттә йөрисең? Хатының авыл буйлап мактанып йөри. Бер грамм да эчми ди. Дәвалану бик килеште ди.

В ә л и. Сөйләр ул минем хатын. Потому болтун ул! Утырыйммы, җырлыйммы үзеңә бик матур җыр, Мәүлияттәй?.. Йөрәк янганда, эч пошканда гына җырлый торганны.

М ә ү л и я. Төн уртасындамы? Көндезен дә ул җырулардан колагым тонып бетте.

В ә л и. Кем ул шулай синең колагыңны тондырырлык җырчы? Кая ул?..

М ә ү л и я *(куркып кала)*. Юк ла, җырчы түгел. Бала-чага тәрәзә төбендә туп уйный. Шау-гөр киләләр.

В ә л и. Малай-шалай шундый инде алар. Туп тибә, тәрәзә вата. Ә мин җырлыйм...

Агыйделдән агып килә
Мәүлия исле сабын;
Берәү булса үләр иде,
Әлдә мин үзем сабыр.

М ә ү л и я. Ярар, ярар, җыр тыңлап торырга вакытым юк. Ни йомыш? Йомышла да үкчәңне күтәр, я хатының килеп алыр үзеңне.

В ә л и. Чишенимме, Мәүлияттәй?

М ә ү л и я. Йомышың нәрсәдер бит, чишенеп торырлык микән?

В ә л и. Ярар, ярар, чишенеп тормыйм алайса. Кая әле, бер ярты банкы гына салып бир әле.

М ә ү л и я. Бәрәч! Нәрсә салыйм мин сиңа?

В ә л и. Пирвачын гына. Иске дуслык хакына.

М ә ү л и я. Көлмә әле. Тол хатын дигәч тә... Мин инде картаеп барам.

В ә л и. Кая әле сиңа картлык! Яшьләр эшли алмый торган могҗизалар эшлисең әле син. Әнә кибетче Бикә апа картайган дисәң дә була. Кич сәгать җиде булды исә, шалт, аракысын да, коньягын да бикли дә куя. Кая инде бригадирга бер ярт ыны сату, алла үзе килсә дә бер грамм юк. Менә бу картлык инде...

М ә ү л и я. Бик дөрес эшли.

В ә л и. Сиңа дөрес тә бит, миңа яхшы түгел. Берәр нәрсә тап инде, Мәүлия түти...

М ә ү л и я. Юк дим, валлаһи, җир йотсын... юк.

В ә л и. Кайсысы юк, самогонмы, ак башлысымы?

М ә ү л и я. Берсе дә юк, катырма башымны!

В ә л и. Кызганыч! Ә мин сиңа күр, нәрсә алып килдем. *(Материал курсәтә.)*

М ә ү л и я *(материалга барып ябыша)*. Абау матурлыгы, әллә инде крепдишин?..

В ә л и. Крепдишин генәме бу, Мәүлия апай... Креп чудо бу!

М ә ү л и я. Бигрәк тә затлы инде, Вәликәем.

В ә л и. Затлы булса, мә ал, сандыгыңа тондыр. Ә пирвачны бир.

М ә ү л и я. Теге вакытта хатының бик елый иде, мескен. Вәли өемнән бөтен затлы әйберләремне сатып эчә ди торган иде. Өйрәнелгән гадәт, яман чир кук тиз генә бетми икән шул.

В ә л и. Күп сөйләнмә, синең эшең түгел аңысы.

М ә ү л и я. Юк, юк, бер нәрсәм дә юк. Закон бик каты хәзер. Хөкүмәт законына каршы бара алмыйм. Мин хулиганский элемент түгел, законга каршы барырга...

В ә л и. Хулиганский элемент... *(Кычкырып көлә. Караватт артында Мостафа да көлә. Вәли тирә-юньгә карана.)* Чү, миннән башка кем бар тагын монда, пырхылдап көлеп ята?

М ә ү л и я. Үз көлкең үзеңә кайта. Радио ул, радио!

В ә л и. Сөйләмә юкны. Мин әллә исерекме! *(Урыныннан тора, эзләнә.)* Кемдер бар монда...

М ә ү л и я *(куркынып кала)*. Юк, валлаһи, беркем дә юк. Мә, мә, нәрсә бирим, акнымы, самогонмы?..

В ә л и. Икесе дә ярый.

М ә ү л и я. Бир материалны! *(Материалны алып мендәр астына куя.)* Тыныч кына утыр, мин хәзер! *(Икенче бүлмәгә чыгарга бара.)*

В ә л и. Әйдә, мин дә синең белән. Ул чудо-казанны карап килим әле... Самогон заводыңны дим.

М ә ү л и я. Сансызланма, Вәли. Ниткән казан, нинди самогон заводы.

В ә л и. Карыйм әле, карыйм. Бәлки миңа да шундый һөнәр белән маташырга кирәктер. Колхоз эше бик авыр.

М ә ү л и я. Нәрсәсе авыр инде аның. Үз колхозыңда рәхәтләнеп эшләсәң, әгәр...

В ә л и. Авыр булмаса, нигә үзең колхоз эшеннән баш тартасың...

М ә ү л и я. Билем, билем, күземдә дә авыр эш эшләргә ярамый торган авыру таптылар.

В ә л и. Кем тапты? Иртәгә фельдшер белән сөйләшим әле.

М ә ү л и я. Юк, юк... Өйдә бергәләшеп сөйләшкән сүзләрне барысын да кешеләргә сөйләп йөрсәң, нинди ир кеше инде син.

В ә л и. Аңлашылды Мәүлияттәй. Башым авырта, өең бик тынчу, кая, бераз сихәтләним әле.

М ә ү л и я. Хәзер, хәзер. *(Булмәгә кереп китә. Вәли як-ягына карана, ул хәзер исерек роленнән чыга.)*

**Мәүлия шешәгә салып самогон чыгара. Вәли әз генә эчеп куя.**

В ә л и. Эх, шәп нәрсә!..

М ә ү л и я. Бик чиста итеп, шикәр белән генә эшләдем. Эч, эч, рәхәтләнеп китәрсең.

В ә л и. Эчәм, эчәм. Кая, берәр литр салып бир әле, Мәүлияттәй, хатынга да алып кайтыйм әле.

М ә ү л и я. Хатыныңның кем икәнлеген белмисеңме, бөтен авылга данымны таратырга телисеңме?

В ә л и. Хатынымның кем икәнлеген беләм анысы. Колхозда алдынгы сыер савучы.

М ә ү л и я. Алдынгы сыер савучының ире алкаш...

В ә л и. Минме алкаш? Ә син алкашның кем икәнен беләсеңме? Бер нәрсәгә яраксыз, паразит, беркемгә кирәксез хәшәрәт ул, беләсең килсә... Ә мин — кеше! Намуслы кеше! Бригадир! Кая бир әле минем крепдишинны. Самогонның су гына. Тозы да, борычы да юк.

М ә ү л и я. Әй мокыт... Самогонда тоз, борыч буламыни?

В ә л и. Сыер сөте буламы әллә?

М ә ү л и я. Шулай ди, самогонга сыер сөте әрәм итәләр иде ди. Болай да бик яхшы чөмерәсез.

В ә л и. Ярар, чөмергән кеше чөмерер, ә минем чөмерәсем килми. Киттем, кибетчене барып уятам да, бер яртыны бирер әле. Бир креп-чудоны...

М ә ү л и я. Мә, алайса, үзем бирим бер яртыны. Энем калдырып киткән иде. Терлек-туар суйдырганда кирәк булыр дип. *(Аракы бирә).*

В ә л и. Үз бәясеме?

М ә ү л и я. Каян килеп үз бәясе... Энем бит тоже кулдан алган, унбер сум диде. Мә, мә... Әй, аллам. Хатының: «Дәваланды, эчми» — дигәч, шатланган идем. Кара энем, Вәли, исерек башың белән миннән алган аракыны кешеләргә күрсәтеп йөрмә. Син ышанычлы кеше, һәйбәт кеше.

В ә л и *(шешәне өстәлгә куя).* Ышанычлы дисең, ә? *(Исерек роленнән чыгып).* Рәхмәт яхшы сүзеңә. Дөньяда ышанычлы кеше булып яшәүдән дә зур бәхет юктыр, мөгаен...

М ә ү л и я. Кара, кара, нинди акыллы сүзләр сөйли. Тәмам айныды.

В ә л и. Исерек түгел мин, Мәүлияттәй. Хатын дөрес әйткән сиңа. Вакытында дәвалану миңа да, семьяма да зур файда китерде. Рәхмәт кешеләргә, яңадан кеше төсле яшәргә, кеше төсле эшләргә ярдәм иттеләр. Ә син мине яңадан хурлыкка, түбәнлеккә өстерисең. Оялмыйча, унсигез яшьлек Рәгыйдәгә аракы тоттырып җибәргәнсең. Егете белән күрешер өчен, очрашу хөрмәтенә мәҗлес үткәрер өчен.

М ә ү л и я. Минем ни гаебем бар? Ул сорады. Мин аны җәлләп бирдем. Үз акылы кая?..

В ә л и. Син кем?! Олы яшьтәге хатын, ана. Әгәр үз балаларың эчеп, юлдан язып йөрсәләр, хурлыктан кая барып бәрелергә белмәс идең... Кәнсәләрдә бүген бухгалтер санап чыкты — бер атна эчендә Хәтимә белән икәүләп никадәр ризыкны агуга әйләндергәнсез.

**Каты итеп ишек шакыйлар.**

М ә ү л и я. Вәли җаным, атам бул, абзам бул... *(Йөгергәләп йөри).*

В ә л и. Ач ишегеңне. Кичке сәгать җидедән соң килә торган кунакларыңдыр.

**Мәүлия ишек ача. Хәтимә керә. Зур төргәк күтәргән, аны идәнгә бәрә.**

Х ә т и м ә. Яшер тизрәк, казаныңны, аппаратыңны яшер! Мә, алып куйган песокны да яшер, өйдә тотып булмый. Дәүләтша әйнең астын өскә китерә.

М ә ү л и я. Нәрсәмне яшерим, урлаган әйберем юк минем.

Х ә т и м ә. Харап... Әйттем мин сиңа! Үз авылыбыздагы кешеләр белән бәйләнмә дидем. Рәгыйдәнең аракы алып кайтканын әнисе белгән дә, бригадир Вәли янына чабып барган.

В ә л и. Нихәл, Хәтимә?

Х ә т и м ә. Бәрәч! Вәли ич! Вәли абыкаем, зинһар, ни инде, мин бит, әнә Мәүлияттәй кушканга гына.

М ә ү л и я. Алай икән... Кушканга гына! Әнә Вәли синең кибеттән күпме он-песок ташыганыңны үзе санап бирер.

В ә л и. Вәли түгел, идарә, колхоз идарәсе санар. Эшкә дисәң, берегезнең биле авырта, икенчегезнең икенче сәбәп, ә самогон кайнатырга, ярты литр аракыны ике-өч бәясенә сатарга вакытыгыз да, саламәтлегегез дә бар. Җәфалар, аяклы казалар сез.

**Дәүләтша керә. Ул ярсыган. Аның кулында икегә бөкләп тоткан бау.**

Д ә ү л ә т ш а. Монда качып котылмакчы идеңме син, юньсез. Әйдә, мена шушы бауга бәйләп икегезне дә колхоз идарәсенә илтеп тапшырам.

Х ә т и м ә. Караул!..

Д ә ү л ә т ш а. Акырма, юньсез! Белмәсләр, дидеңме? Ай-һай, соңгы вакытта кәнфитләнә башладың. Яңадан яңа күлмәк текterәсең. Сасы самогон сатып киенергә, матурланырга уйладыңмы?..

Х ә т и м ә. Дәүләтша, җаным, гафу ит, үзем дә белми калдым. Ничек тотындым шундый хурлыклы эшкә.

Д ә ү л ә т ш а. Кит янымнан *(этәреп җибәрә. Хәтимә Мостафа турысына караватакына килеп баса. Аны Мостафа кочып ала).*

Х ә т и м ә. Ой, караул, кем бу? Нишлисең, нәрсәгә миңа ябыштың?.. Дәүләтша дим, кем бу?

М о с т а ф а. Кычкырма, Хәтимә җаным. Бу мин — Мостафа, сине көтеп ятам... Курыкма, кил бире. Сине җәберләргә беркемгә дә ирек бирмәм. *(Чыга.)*

Д ә ү л ә т ш а. Бу нинди дивана тагын?

М о с т а ф а. Син үзең дивана түгел микән әле, кеше хатынын бау белән ишәргә йөрисең?

Д ә ү л ә т ш а. Нәрсә сөйлисең син, башың беткән алкаш. Минем хатын ул.

М о с т а ф а. Тукта, тукта ни хакың бар синең мине алкаш дип оскарбит итәргә? Алкаш кем? Кем алкаш? *(Дәүләтшаның өстенә кила.)*

Х ә т и м ә. Гафу ит мине, Дәүли җаным. Хур иттең башларыбызны, Мәүлияттәй. Түти дигән исем җәл сиңа. Албасты син!

Д ә ү л ә т ш а. Өйгә аягыңны атлыйсы булма! Аерам мин сине, талак, талак, талак!.. Хур иттең башымны, хәерсез хатын! *(Этәреп җибәрә.)*

В ә л и. Күрдеңме, Мәүлияттәй, күз алдыңда гаилә җимерелә. Ир кадәр ир хурлыкка кала. *(Мостафага карап.)* Чү, чү! Син бит Заготзерно — Мостафа абзый...

М о с т а ф а. Әйе, нәкъ үзе.

В ә л и. Районның хөрмәтле кешесе. Башыгызга нинди нужа төште, Мәүлияттәй караваты астында аунарга?

М о с т а ф а. Очраклы килеп эләктем. Ялгызлыгымны ерып чыгу иде ниятем. Әнә, *(Хәтимәгә күрсәтә,)* шуны хатынлыкка димлим диде. Минем хатыным үлгәннән бирле башымны кая куярга белми аптырап калган көннәрем бу, туган... Хәтимәне беренче кат күрәм. Җәберләмәгез аны, Дәүләтша туган. Ул да минем шикелле капкынга килеп эләккән. Барысы өчен дә Мәүлия абыстай җавап бирергә тиеш. Мин, кәнсәләргә барып, барысын да сөйләрмен.

В ә л и. Үзегез турында да...

М о с т а ф а. Әйе, әйе, үземне дә читтә калдырмам.

М ә ү л и я *(барысын да күзләре белән сөзеп чыккач).* Ай-һай, ансат кына, ә?.. Барын да ятимә хатын — минем өстемә аударып, үзегез бер читтә торып калыр идегез бугай? Юк әле! Ашыкмагыз, Мәүлия апагыз алай җиңел генә бирешә торган кеше түгел. Мин — сугышта катнашучылар семьясы. Ике абыем сугышта үлде. Үзем сугышта катнашмасам да, 14—15 яшьтән җир сөрдем. Урак урдым. Урманга утынга бардым. Утын кистем. Менә бу бармакларым утын кискәндә шулай гарипләнеп калды. Мәүлия самогон ясап сата имеш. Кемнәр килде соң миңа самогон ди-ди, баш авырта ди-ди, каладан кунаклар килде, ревизия килде ди-ди, шуларны сыйларга кирәк, коткар, зинһар, коткар дип, иң башлап син килдең бит, Вәли. Хәзер каты закон чыккач, барына да мин генә гаепле димәкче буласыз. Алай гына булмый ул. И, булмас та! Сезнең дә башыгыздан сыйпамаслар. Мин җинаятьче булсам, сез — мине җинаятькә этәрүчеләр, сез ул, беләсегез килсә!..

**Кызу гына бүлмәгә кереп китә, самогон ясый торган аппаратлар, чиләкләр, чүмечләр, капчыкка салган шундый әйберләрне идәнгә чыгарып өя.**

Менә ул «самогон заводы»... Менә мичкәсе, менә чөмерә торган чүмече... Менә шешәләре, ә менә акыллы баш — Хатимә китергән шикәр *(Капчыкны атып бәрә).* Менә, районның хөрмәтле кешесе Мостафа биргән акчалар!

**Берәм-берәм барысын да атып бәрә. Барысы да ни әйтергә белмичә, бер-берсенә карашып тын торалар.**

*Пәрдә.*

## ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Апрель аенда Берләшкән Милләтләр Оешмасының мәгариф, фән һәм культура мәсьәләләре буенча комитетының (ЮНЕСКО) Париждагы штаб-квартирасыннан «1986-1987 елларда бөек кешеләр һәм тарихи вакыйгаларның еллыкларын бәйрәм итү» турында календарь алынды. ЮНЕСКО программасы кабул иткән тәртип буенча календарьга мәгариф, фән, культура һәм коммуникация өлкәләрендә кешелек дөньясы тарихында зур эз калдырган бөек кешеләрнең һәм тарихи вакыйгаларның 100 һәм 100 санына үсә барган туган яки үлгән еллыклары һәм тарихи даталар гына теркәлә.

Календарьның СССР тарафыннан тәкъдим ителгән даталар арасында татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай да бар. ЮНЕСКО календареның Г. Тукайга багышланган өлешендә түбәндәге мәгълүматлар язылган: «26 апрель, Габдулла Тукай. Татар халык шагыйре, публицист, яңа татар реалистик әдәбиятына һәм бүгенге татар әдәби теленә нигез салучы. Тууына 100 ел тулу көне. Календарьга СССР тәкъдиме буенча кертелә».

РСФСР Язучылар союзы идарәсе ЮНЕСКО эшләре буенча Совет комиссиясе карамагына Г. Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган материаллар тапшырды. Алар арасында Тукай турында мәкалә, аның төрле елларда төшкән фоторәсемнәре, китаплары һәм әсәрләреннән фоторепродукцияләр, аның сүзләренә язылган «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк» кебек җырлар, ул яраткан «Иске кара урман» көе, Н. Җиһановның «Кырлай» симфоник поэмасы, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетыннан сюита язылган магнитофон тасмалары бар. ЮНЕСКО члены булган дәүләтләрнең теләсә кайсы бу материалларны соратып алдыра һәм үз илендә файдалана ала.

Шулай итеп, башка күп кенә атаклы кешеләрнең юбилейлары белән бергә, Г. Тукай бәйрәме дә ЮНЕСКО илләре аша халыкара мәйданга чыга, ул бөтен дөньядагы төрле илләр һәм халыклар бәйрәменә әверелә.

26 апрельдә Казанда Г. Тукайның туган көненә багышлап уздырылган традицион шигырь бәйрәме булып узды.

Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре юлбашчыбыз В. И. Ленин һәйкәленә, А. Пушкин, М. Горький, Г. Тукай, М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәк бәйләмнәре куйганнан соң, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янында Г. Тукай һәйкәле алдында шигъри митинг башланды. Аны кереш сүз белән Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган юбилей тантаналарына әзерлек һәм аларны үткәрү буенча республика комиссиясе председателе, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

Тукай иҗаты турында шагыйрь С. Хәким чыгышыннан соң сүз 1986 елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләренә лаек булган шагыйрь Х. Камалов һәм рәссам В. Кудельскинга бирелде.

Шигърияте без аксакаллары Н. Арсланов, Н. Дәүли, шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Г. Рәхим, Р. Миңнуллин, Зөлфәт, Э. Шәрифуллина, Р. Зәйдуллин, Г. Моратов, Мәскәү шагыйрьләре М. Акчурин, В. Евпатов, Башкортстаннан Н. Нәҗми, Р. Мифтахов, Мари АССРдан А. Тимиркаев, Удмуртиядән А. Леонтьев, Магнитогорскидан вагон депосы токаре, Бөек Ватан сугышы ветераны Р. Мостафин, Биектау районыннан V класс укучысы Э. Нигъмәтҗанова Г. Тукайга ихтирам һәм мәхәббәтләрен шигырь телендә белдерделәр. Үзешчән артистлар оештырган җырлы-биюле уеннар шигырь бәйрәмен тагын да ямьләндерде.

Шигъри митингны шагыйрь Р. Харис алып барды.

Шигырь бәйрәмендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев катнашты.

3 апрельдә Татарстан Художниклар союзының Күргәзмәләр залында бөек шагыйрьгә багышланган күргәзмә ачылды.

Күргәзмәне кереш сүз белән Г. Тукай юбилеен үткәрү буенча республика комиссиясе председателе, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСРның атказанган художнигы Ә. Тумашев, ТАССР Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мостафин, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән фәнни сотруднигы Р. Әмирханов һ. б. Г. Тукайның әдәби мирасының әһәмияте турында сөйләделәр.

Күргәзмәне ачу тантанасында КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев катнашты.

Күргәзмәгә йөздән артык художникның 500 ләп әсәре куелган. Алар арасында Казан һәм республикабызның төрле шәһәрләрендә яшәүче, шулай ук Ленинград, Волгоград, Куйбышев, Уфа художниклары әсәрләре бар.

Казанда бөек шагыйрь юбилеена багышлап, Бөтенсоюз студентлар фәнни конференциясе үткәрелде. Конференцияне В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты оештырды. Аңа Әзербәйҗан, Башкорт, Казах, Кыргыз, Мари, Таҗик, Ташкент, Удмурт,

Чуваш дәүләт университетларының студентлар гыйльми җәмгыятьләре вәкилләре килде.
Конференция Укытучылар йортында Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан зур интернациональ фестиваль белән ачылды.
Конференциядә катнашучылар университетның В. И. Ленин мемориалында һәм музеенда булдылар, яшь Владимир Ульянов һәйкәленә чәчәкләр салдылар, сынлы сәнгать музеенда Г. Тукайның 100 еллыгына багышланган күргәзмәне һәм бөек шагыйрьгә бәйле истәлекле урыннарны карадылар.

24 апрельдә Татарстан атом электр станциясеӊ төзүчеләр яши торган Кама Аланы поселогында Г. Тукайның туган көненә багышланган шигырь бәйрәме булып узды.
Казаннан һәм Брежневтан килгән шагыйрьләр Р. Низамиев, М. Галиев, Н. Алешков, Л. Зөлкарнәев, прозаик Г. Кашапов шигъри митингта үзләренең Г. Тукайга багышланган әсәрләрен укыдылар, бөек шагыйрь иҗаты турында сөйләделәр.

Әлмәттә һәм район авылларында Г. Тукайның 100 еллык юбилее уңае белән шәһәр һәм авыл китапханәләрендә шагыйрьнең әсәрләреннән күргәзмәләр, укучылар конференцияләре уздырылды.
Клубларда поэзия кичәләре, язучылар белән очрашулар үткәрелде. Нефть төбәгендә яшәүче язучылардан Ә. Маликов, Р. Тәхфәтуллин, Ә. Гаффар, К. Булатова, Э. Мөэминова, Н. Әхмәдиев, Ф. Гыйльми һ. б. Әлмәттәге картиналар галереясында, М. Горький исемендәге клубта, пионерлар йортында, Колшәрип кошчылык фабрикасында чыгыш ясадылар. Алар бүгенге татар әдәбиятында Г. Тукай традицияләре турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Брежнев шәһәренең «Энергетик» культура сараенда Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Фойеда шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган бай күргәзмәне кичәгә килүчеләр яратып карады.
Г. Тукай сүзләренә язылган җырлар һәм халык җырлары башкарылды.
Шагыйрь Х. Хәснуллин һәм С. Шәрипова Г. Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар.

Брежнев шәһәренең картиналар галереясында, Г. Тукайның тууына 100 ел тулуны каршылап, 1 нче балалар художество мәктәбе укучылары ясаган рәсемнәрдән күргәзмә оештырылды. Анда Г. Тукай әсәрләренә ясалган сурәтләр, шагыйрьнең балачагын, тормышын тасвирлаган рәсемнәр тупланган иде.

26 апрельдә Уфада Башкорт дәүләт филармониясе Зур залында Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.
— Татар халкының бәхетенә, дөнья шигъриятенең шатлыгына, моннан төгәл йөз ел элек, нәкъ Казан артында якты дөньяга Габдулла Тукай килде. Ул үз халкының меңәр еллык газапларыннан һәм өметләреннән, моңнарыннан һәм ораннарыннан, тир катыш канлы туфрагыннан һәм тере рухыннан яралды,— диде Башкортстан халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты Мостай Кәрим кичәне ачкандагы кереш сүзендә.
Күп милләтле культурабыз тарихында Габдулла Тукайның роле һәм урыны турындагы доклад белән филология фәннәре кандидаты шагыйрь Р. Бикбаев чыгыш ясады.
Башкорт шагыйрьләре Г. Рамазанов, А. Игебаев, Г. Шафиков, Татарстаннан кунак булып килгән шагыйрьләр Ә. Баян һәм Р. Гатауллин Габдулла Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар.
Республиканың сәнгать осталары концерты булды.
Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре Т. И. Ахунжанов, БАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ф. В. Солтанов катнашты.

Свердловск шәһәренең Лавров исемендәге культура сараенда Г. Тукайның тууына 100 ел тулу көненә багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Аны РСФСР Язучылар союзының Свердловск язучылар оешмасы һәм Бөтенсоюз китап сөючеләр җәмгыятенең өлкә идарәсе оештырды.
Кичәдә Татарстаннан килгән кунаклар Р. Даутов һәм Р. Вәлиев катнашты. Соңыннан Г. Тукайга багышланган зур концерт булды.

Арча районында сөекле шагыйребезнең туган көненә хәзерлек чаралары 1985 елдан ук башланды. Ятим Габдуллага якты чырай, күңел җылысы биргән һәм аны туйдырган Сәгъди абзый йорты, каралтылары яңартылып, элекке рәвешенә китерелде.
Тукайның музей йортына шагыйрь яшәгән замандагы өстәмә әйберләр, киемнәр алынды.

ТАССР Спорт комитеты һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә 13-15 яшьлек үсмерләр арасында республика беренчелегенә татарча көрәш ярышлары үткәрделәр.
Бу ярыш 19-20 апрельдә Казандагы үзәк культура һәм ял паркында урнашкан югары спорт осталыгы мәктәбе залында үтте. Анда катнашучылар 11 үлчәү авырлыгында чыгыш ясадылар. Республикабыз районнарында, авылларында яшәүче үсмерләрнең җиңү яулаганнары истәлек бүләкләре, дипломнар алудан тыш, спортка беренче адымнарын ясадылар.

«Планета» нәшриятында «СССРдагы истәлекле урыннар» сериясеннән Тукайга багышлап открыткалар комплекты чыгарылды. 15 открыткадан торган бу җыелмада В. Мельниковның төсле фоторәсемнәре Тукайның балачагына бәйле урыннарның гүзәллеген, авылларның милли үзенчәлеген, шагыйрь яшәгән «Болгар» мосафирханәсен, Тукай-Кырлайдагы аның музеен һ. б. күз алдына китереп бастыра.
65 мең тираж белән чыгарылган открыткалар җыелмасы Тукай турында әнә шундый күп кызыклы мәгълүматлар бирә.

26 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры драматург Т. Миң-

нуллинның «Без китәбез, сез каласыз» исемле драмасы буенча куелган яңа спектакль күрсәтте.

Г. Тукай тормышының бер күренешен тасвирлаган, бөек шагыйрьгә багышланган бу әсәрне сәхнәгә СССРның халык артисты М. Сәлимҗанов куйган. Рәссамы — Р. Газиев.

Тукай ролен артист И. Әхмәтҗанов һәм яшь артист Р. Төхфәтуллин башкара.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

29 апрельдә узган ачык партия җыелышында «КПССның XXVII съезды карарлары яктылыгында әдәби тәнкыйть жанрын җанландыру» дигән темага эшлекле сөйләшү булды. Әдәби тәнкыйтьнең бүгенге торышы һәм тәнкыйтьчеләр алдында торган бурычлар турында Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мостафин сөйләде.

Фикер алышуларда тәнкыйтьчеләр А. Әхмәдуллин, Б. Гыйззәт, Ф. Мусин, М. Вәлиев, прозаиклар С. Сабиров, М. Хәбибуллин, шагыйрьләр Ә. Рәшитов, М. Шабаев, тәрҗемәче С. Ибраһимова һ. б. чыгыш ясап, тәнкыйть жанрының кимчелекләре турында сөйләделәр, тәкъдимнәрен әйттеләр.

### ТЕАТР ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

14 апрельдә Казанның Актерлар йортында Бөтенроссия театр җәмгыяте Татарстан бүлегенең XVIII отчет-сайлау конференциясе булды. Анда отчет доклады белән идарә председателе, РСФСРның халык артисткасы Р. А. Җиһаншина чыкты. Ревизия комиссиясе отчетын комиссия председателе, РСФСРның атказанган артисты Ю. В. Борисенко ясады.

Докладлар буенча фикер алышуларда катнаштылар: РСФСРның халык артисты, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Р. А. Тажетдинов, ТАССР культура министры М. М. Таишев, Бөтенроссия театр җәмгыяте идарәсе президиумы председателе ярдәмчесе И. Д. Ярцев, драматург Р. Г. Мингалимов һ. б.

Конференциядә КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады.

Конференция эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зыятдинова катнаштылар.

Конференция Бөтенроссия театр җәмгыяте Татарстан бүлегенең яңа идарәсен, ревизия комиссиясен һәм Бөтенроссия театр җәмгыятенең XV съездына делегатлар сайлады.

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе итеп РСФСРның халык артисткасы Р. А. Җиһаншина сайланды.

### ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

21 мартта Казанның Актерлар йортында Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган культура работнигы Фәнис Яруллинның иҗат кичәсе булып узды.

Кичәне язучы Р. Батулла алып барды. Кереш сүз белән шагыйрь М. Шабаев чыкты. Аннары Ф. Яруллин үзенең яңа шигырьләрен укыды, тамашачыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде. Артистлардан И. Баһманов, Р. Шәрәфиев, М. Галиев, Г. Сафиуллина, Р. Гатауллин һ. б. башкаруында шагыйрьнең әсәрләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

28 мартта Казанның Актерлар йортында шагыйрь Әхмәт Рәшитовка 50 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсе булды. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары драматург Р. Хәмид, язучы Р. Кәрами сөйләде. Соңыннан шагыйрь әдәбият сөючеләрнең күпсанлы сорауларына җаваплар бирде, яңа әсәрләрен укыды.

### АНСАМБЛЬНЕҢ ЗУР УҢЫШЫ

15 апрельдә Мәскәүнең П. И. Чайковский исемендәге концерт залында илебездәге җыр һәм бию ансамбльләренең II Бөтенроссия конкурсы тәмамланды. СССРның халык артисты И. Моисеев җитәкчелегендәге абруйлы жюри халык сәнгатен профессиональ югарылыкта пропагандалаучы 15 коллективның осталыгына бәя бирде. Ярты елга сузылган сәнгать бәйгесендә җиңүче дип бертавыштан Татарстан АССР дәүләт җыр һәм бию ансамбле игълан ителде. Ансамбльгә беренче урын һәм беренче дәрәҗәдә лауреат дипломы бирелде.

### СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ ИТАЛИЯДӘ

Әле күптән түгел генә Ю. Мориц, Р. Фәйзуллин һәм А. Веселецкий составындагы совет язучылары делегациясе Италиядә булып кайтты.

«Лунарио нуово» поэтик җәмгыятенең чакыруы буенча барган совет шагыйрьләре Италиянең башкаласы — Римда, Сицилиядәге Катания, Сиракуза, Ачериали, Рандаццо, Ачибонаккорса шәһәрләрендә булдылар, анда яшәүчеләрнең тормыш-көнкүреше белән таныштылар, шәһәрләрнең җитәкчеләре белән очраштылар. Совет шагыйрьләрен поэтик кичәләрдә бик җылы кабул иттеләр, шигырьләрен яратып тыңладылар. Ике атна дәвам иткән бу сәяхәт Совет-Италия әдәби багланышларының ныгый баруына бер дәлил булды.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен язучылар Мәгъсүм Насыйбуллин һәм Сафа Сабировка Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 2 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы Зилә Сөнгатуллинага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 28 март Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Алсу Гайнуллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 13 март Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Руслан Дәминовка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 13 март Указы белән «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет хореография сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе балет артисткасы Эльба Закировага һәм балет артисты Виктор Шәрәфетдиновка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 13 март Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Сынлы сәнгать өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен рәссам-монументалист Абдулхак Хөснетдинович Мусаловка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 29 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен түбәндәге иптәшләргә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 31 март Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде: Шамил Бариев, Зөлфирә Зарипова — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары; Марсель Җаббаров, Нуриәхмәт Сафин — Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПОСТЫНДА

1983 елда «Казан утлары» журналы һәм Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр коллективлары арасында хезмәттәшлек килешүе төзелгән иде.

Хезмәттәшлек килешүе төзелүгә өч ел тулган көннәрдә — 27 февральдә төзүчеләр янына «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, журналның бүлек редакторы Рәшит Әхмәтҗанов, шагыйрь Р. Миңнуллин, язучы Г. Кашапов, композитор Р. Абдуллин килде.

Алар элек Брежнев шәһәрендә «Камгэсэнергострой»ның йортлар салу комбинатында булып, комбинат житәкчеләре һәм хезмәткәрләре белән очраштылар. Партиянең XXVII съездына багышлап уздырылган митингта чыгыш ясадылар.

Кичен Кама Аланы клубында атом электр станциясен төзүчеләр белән очрашу кичәсе булды. Кичәне «Камгэсэнергострой»ның йортлар салу комбинаты партия оешмасы секретаре М. А. Барашов ачты. Р. Харис журнал һәм төзүчеләр арасындагы хезмәттәшлекнең соңгы бер еллык эше турында сөйләде, редакциянең иҗади планнары белән уртаклашты.

Бер төркем төзүчеләр редакциянең Почет грамоталары һәм «Казан утлары»на еллык подписка белән бүләкләнделәр. Алар арасында 12 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәләхов, шул ук идарәнең түбә ябучысы Фания Хәбибуллина, «Атомэнергострой»ның монтажчылар бригадиры Артур Уразаев, монтажчы Әнвәр Ибраһимов, партком секретаре Рифкат Кәтиев бар. Килешү шартларында күрсәтелгәнчә, «Казан утлары» журналының АЭСка багышланган иң яхшы әсәрләре акчалата премия белән билгеләнә. Быел бу бүләкләргә язучы Б. Камалов очеркы һәм композитор Р. Абдуллинның «Кама Аланы» (Р. Харис сүзләре) исемле җыры лаек булды. Төзүчеләргә әдипләр үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр.

# САБАН ТУЕ — ХЕЗМӘТ ТУЕ

Татар сынлы сәнгатендә сабан туе темасы аерым урын алып тора. Гасырлардан килүче әлеге халык бәйрәме менә инде ярты гасыр буе рәссамнарны иҗатка рухландыра: нәкышчеләрне дә, графикларны да, скульпторларны да, көнкүреш сәнгате осталарын да... Төрле буын вәкилләре тарафыннан иҗат ителүче әсәрләрдә хезмәт тантанасы рәвешендә үткәрелә торган милли бәйрәмнең яңадан-яңа яклары ачыла.

Чагыштырмача яшь буын вәкиле булып саналучы рәссам Шамил Шәйдуллин сынлы сәнгатькә нәкъ менә сабан туе темасы аша килде шикелле. «Минем авылымда бәйрәм. Сабан туе...» һәрхәлдә аның танылуы менә шушы картинадан башланды. Әлеге әсәр күп кенә күргәзмәләрне «урап чыкты», сәнгать белгечләренең югары бәясен алды.

Җитмешенче еллар сынлы сәнгатендә чынбарлыкны шагыйранә күзлектән сурәтләүгә игътибар сизелерлек көчәйде. Иҗат юлын шушы чорда башлап җибәргән Ш. Шәйдуллин да халык тормышындагы этик-эстетик башлангычны күп бизәклелек призмасы аша чагылдыруны үзенә төп алым итеп сайлады. Рәссам иҗаты үзәгеннән үтә торган әлеге лейтмотив «...Сабан туе» картинасында бигрәк тә ачык күренә.

...Табигатьнең гүзәл урынына халык бәйрәм итәргә җыелган. Эштән соң уйнарга ярый дигәндәй, авыл бердәм туй итә. Сабан туе гөрли! Ерактан балкып күренүче игеннәрнең алтынсу нурлары хезмәтне бәйрәмгә әверелдерүче кешеләрнең йөзләрендә чагыла шикелле. Сабан туеның төрле күренешләре картинада бер композицион «җеп»кә тезеп бирелгән. Халык арасындагы малайның кураеннан агылучы моң, әйтерсең, бәйрәмнең төрле эпизодларын үзара бәйләп тота. Гасырлардан килүче гүзәллек символы, әнә шулай, бихисап күзләрдәге нурны бер үзәккә туплый. Сабан туе гөрли. Яшәү матурлыгын гәүдәләндерүче хезмәт туе бөтен төсләрдә балкый.

**Екатерина КЛЮЧЕВСКАЯ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Буа районы, Күл-Черкен авылының «Әйлән-бәйлән» балалар җыр ансамбле. Җитәкчесе — ТАССРның атказанган культура хезмәткәре, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Алсу Гарифуллина.


**Р. МАНСУРОВ** һәм **М. КОЗЛОВСКИЙ** фотолары.

# САБАН ТУЕ

Риф Якупов фотохикәясе.







Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)